ISSN 0206–4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

10.2004



# КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ—1000 ЕЛ



*«Ташаяк» ярминкәсе*



***Кабан күле***

*XX гасыр башында алынган фотосурәтләр.*
*Абдулла Дубин коллекциясеннән.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2004

# 10

**(984)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөсния**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Ихтыяр Гаязов, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркатип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
Факс — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әхсән БАЯН. Казан чишмәсе. *Шигырьләр.* ... 6
Хисам КАМАЛОВ. Үксезләр. *Роман.* ... 10
Мостай КӘРИМ. Төрле еллар лирикасы. *Шигырьләр.* ... 46
Марат ӘМИРХАНОВ. Мөкәррәмә. *Повесть.* ... 51
Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Ә җаным—канатлы кош кебек. *Шигырьләр.* ... 108

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Яшәешнең аның үз кануны. *Шигырьләр.* ... 112

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рафаэль ХӘКИМ. Кайда безнең кыйбла? ... 116

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Уңай герой югалу: сәбәпләр, нәтиҗәләр. ... 134
Бикә РӘХИМОВА. Җиң сызганып эшләү заманы килде. ... 145

**ХӘТЕР**

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. СССР әдәби фондының Татарстан бүлеге. ... 149
Нәҗибә САФИНА. Кара шикәр. *Истәлек-хикәя.* ... 157
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Актүбә мизгелләре. ... 166

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Ләйлә МИНҺАҖЕВА. Бәхетле иҗат иясе. ... 163

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ... 168

**ЮМОР-САТИРА**

Тәлгать НӘҖМИЕВ. Саба хикмәтләре. ... 179

«Казан утлары» архивыннан. ... 176
Котлыйбыз! ... 178
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 187
Тышлыктагы сурәтләр. ... 191

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*


"Проза и поэзия": роман Х. КАМАЛОВА "Сироты" (начало), повесть М. АМИРХАНОВА "Мукарама"; стихи А. БАЯНА, М. КАРИМА, Ф. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ, Г. БАЙРАМОВОЙ.
"Публицистика": Р. ХАКИМ. "Где наша Мекка?"
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
Дискуссия "Герой нашего времени": Д. ЗАГИДУЛЛИНА. "Исчезновение положительного героя: причины, выводы"; Б. РАХИМОВА. "Время работать засучив рукава".
"Память": Л. ХАМИДУЛЛИН. "Татарстанское отделение Литфонда СССР"; Н. САФИНА. "Черный сахар"; Р. МИР-ХАЙДАРОВ. "Актюбинские зарисовки".
"Книжное обозрение": статья Л. МИНГАЗОВОЙ посвящена творчеству поэтессы Р. ВАЛИЕВОЙ.
"Юмор-сатира": Т. НАЗМИЕВ. "Забавные истории".
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина художника Р. САЛАХОВА посвященный татарскому эпосу; поэтесса Фирдаус АГЛИЯ.


# IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*


"Prose and poetry": novel by H. KAMALOV "Orphans" (beginning), short novel by M. AMIRKHANOV "Mukarma; verses by A. BAYAN, M. KARIM, F. GIZZATULLINA
"Creativity of the young": verses by G. BAJRAMOVA.
"Publicism": R. HAKIM "Where is our Mecca?"
"Science": A. TIMERGALIN. "Dictionary of the nation".
Discussion " Hero of our time": D. ZAGIDULLUNA. "Disappearance of the positive hero: reasons, conclusions"; B. RAKHIMOVA. "Time to work having rolled up the sleeves".
"Memory": L. HAMIDULLIN. "TATARSTAN branch of Litfond of the USSR"; N. SAFIN. "Black sugar"; P. MIR-HAIDAROV. "Aktyubinsk sketches".
"Book review": article by L. MINGAZOVA devoted to creativity of the poetess R. Valieva
"Humour-satire": T. NAZMIEV. "funny stories".
From photo-archive of the magazine.
Diary of public—cultural life.
On our covers: work of artist R. SALAHOV devoted to the Tatar epos; poetess Firdaus AGLIA.



★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.09.2004 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7025. Заказ Э—663
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2004 ел.



## Әхсән Баян

# КАЗАН ЧИШМӘСЕ

### Баллада

Таштан ыргып ташка, чишмә чаба,
Чишмә чаба чордан чорга таба.
Кушылып бара дәрья агышына,
Әверелеп илнең язмышына.
Чишмә башы—җиде кат җир асты,
Тишеп тауны-ташны, өскә ашты.
Азатлыкка ашты көмеш ак су,
Көмеш ак су—тыелгысыз ярсу.

Тыелгысыз ярсу — илнең җаны,
Һичкем мәңге туктаталмас аны.
Туктатыр көч әмма килеп чыккан,
Яратылып кара явызлыктан:
Вакыт җиткән, шулай, сәгать суккан,
Тау астыннан дошман юл казыткан.
Тутырганнар мичкә-мичкә дары,
Өстә калган кальга, су юллары.

Күрми шуны, өстә кешеләр йөргән,
Кисмәк-кисмәк су алырга килгән.
Һәр йотым су—исән калган гомер,
Һәрбер гомер исән илгә тиңдер.
Ә өстәге кала, су юллары,
Су алырга килгән ил уллары,
Ачып күз йомганчы, юкка чыккан,
Тузан төсле тузып, күккә очкан.

Әхсән БАЯН (1927) – *Татарстанның халык шагыйре; күпсанлы проза һәм драма әсәрләре, шул исәптән биштомлык "Сайланма әсәрләр" (2003) авторы. Казанда яши.*

Ак су янган, чишмә тынып калган,
Йотым сусыз гаскәр нишли алган?
Тупка, утка сөңге белән барган,
Аягурә янган, тоткан мәйдан.
Кан, яшь—дәрья, ага кара гасыр...
Кансыз, яшьсез чишмә кайчан кайтыр?
Җиде кат җир һәм таш тауны тишеп,
Гасырларны кичеп, ургыр ничек?

Аккан суга булмый диләр киртә,
Өмет—исән, белми тынгы һич тә.
Күмелгәнме әллә мәңгелеккә?
Казан — сабыр, Казан көтә, көтә.
Үксеп, күкрәп, коелгандыр яңгыр,
Күз яшьләре коелып җыелгандыр.
Төшләрендә тауның ургый ак су,
Ургый ак су—тыелгысыз ярсу...

## Оясыз кош моңы

Туган җирдә, туган өемдә
Йокы килми миңа төнен дә.
Тәрәз кага кемдер, уянам,
“Кемнәр икән?”—диеп уйланам.

Кош тавышы килә еректан,
Нәрсә эзли, нәрсә югалткан?
Җил генәме елый чормада?
Кемнең үкси җаны морҗада?

Онытылган көйләр, тавышлар...
Хәтерләсәң, барысы танышлар.
Әткәм, әнкәм кайткан, туганнар—
Көн дә, бәлки, кайта торганнар.

Буш утарда озак йөрделәр,
Җыйнаулашып өйгә керделәр.
“Өйне сагынып кайттык без!”—диләр,
Ут алырга шырпы эзлиләр.

Лампа балкыр, учак кабыныр.
Ызбуттагы шырпы табылыр.
Шырпы ләкин, никтер, табылмый.
Эзләр икән алар тагын ни?

“Туган җиргә, туган өебезгә
Нишләп әле кайттың син генә?
Әйдә, монда ялгыз тилмермә!”—
Дип, дәшәләр Тәңре иленә.

Әй, ник, ник сез ашыктырасыз?
Болай да бит вакыт уза тиз.
Чакыру көтмичә дә китәрмен,
Яныгызга барып җитәрмен.

Уйлата да шулай, моңайта,
Уйлый торгач, сызылып таң ата.
Тып-тын гына алар шул чакта
Югалалар китеп еракка...

Оясыз кош моңы сизелә
Ерактагы урам көендә.
Мин оясыз монда үзем дә—
Туган җирдә, туган өемдә.

## Упкын

Уза да тора гомерләр,
Китә дә бара еллар.
Җыелган җирләре бардыр,
Бар микән барыр юллар?
Кайдадыр Галәм читендә,
Уртасында, ихтимал,
Күрде адәм "Кара упкын",
Дөньялар йота торган.

Җирдәге еллар, гасырлар,
Миллиард һәм сансыз чорлар,
Сансыз кавемнәр, дәүләтләр
Киткәндер төшеп шуңар.
Төпсез шул упкын ярына
Юл табып бармак булам.
Яр читенә аяк сузып,
Кармаклар салмак булам.

Кармакларымны кабарлар
Йолдызлар, тере җаннар.
Балыклар төсле ялтырап,
Безнең чорга чыгарлар...
И, бәндә, гөман корасың,
Упкын йота гөмансыз.
Син түгел, йолдызлар, сүнеп,
Йотыла ихтыярсыз.

Ничек саклыйм сине, Тормыш,
Ничек коткарыйм, Дөньям?!
Упкынны, Газинур сыман,
Томаламакчы булам.

## Тимер юл буенда

Ни генә юк тимер юлда—
Тимер-томыр, күмер, таш.
Күмерле, ташлы юлларны
Каралткан дегет тоташ.

Күмерле, ташлы комлыкта,
Күр, ничек чәчәк үскән!
Матурлыкның батырлыгы
Менә ул кайда икән!

Тыңлый белсәң, аңлый белсәң,
Сүзсез сөйләячәкләр—
Яшәүнең нәрсә икәнен
Әйтәчәкләр чәчәкләр.

Төтенле җилләр иссә дә,
Калмый алар боегып.
Гайбәт төсле кара корым
Таҗларга калмый йогып.

Чак кына яңгыр яуса да,
Шатланып куя алар.
Рәхмәт әйтеп, сафлык сирпеп,
Дөньяга елмаялар.

Этборын, гөләп киммени
Бакчадагы гөлләрдән?
Тәкъдирдән ник, бакча димим,
Кыр, урман бирелмәгән?

...Эшли юлда кәйлә, чүкеч
Тоткан кызлар, хатыннар.
Чәчәкләр шушы кызларга,
Хатыннарга тартымнар.

***

Битне биткә куеп саубуллашкач,
Киткән чакта, ябып ишекне:
"Әллә ниләр уйлап китмә!" — дигән
Үтенечле тавышың ишеттем.

Нәрсә уйлыйм? Кемне сөйгәнеңне
Белеп кенә киттем—бары шул.
Дәгъваларсыз, вәгъдәләрсез генә
Төгәлләнде безнең танышу.

Җиңелү юк монда, тик шулай да
Кисәтелгән сыман хис тоям:
Җиңелә дә белү кирәк безгә,
Саклау өчен үзеңә ихтирам.

***

Төнгә каршы барган юлда
Куера кара болыт.
Кичке шәфәкъ алсулыгын
Томалый караңгылык.

Алда ни бар? Әллә күл, яр,
Әллә тау, әллә урман.
Серләреңне ай беләдер...
Ул болытларга чумган.

Үзең әзли чыгарсыңмы,
Адашып калсам әгәр?
Мәхәббәткә барган юлым
Юлсызлыкка бәрабәр.

•••

Сәер Уй килде башыма:
Тәрәзә аша очып,
Туп-туры узды түремә
Төн төсле кара кошчык.

Ничек кенә тырышсам да,
Чыгаралмадым өйдән.
Ташлап чыксам, Уем күктә
Тилгәнгә әверелгән.

Сизмәгәнмен, баш өстемдә
Ул күптән очып йөргән:
Картлык атлы тилгән шулай
Мине алырга килгән.

Кит, тилгән, кит, оч еракка,
Болытларыңа күмел:
Синең белән очрашырга
Мин әле әзер түгел.

Кал адашып, бу якларга
Юл таба алмый тилмер...
Карыйм әле яшәп тагын
Бер-ике генә гомер?!

*2003–2004*



## Хисам Камалов

# ҮКСЕЗЛӘР

РОМАН

1

Бу яз бик иренеп кенә килә, кояшлы җил карны эретеп бетерсә дә, көннәр җылытмый аптырата иде. Шуна агроном Вәзыйх идарәгә калынрак киенеп менде. Районга барасы бар иде.

Ул анда үзен зур күңелсезлекләр көткәнен белә, мәгәр бармый калу мөмкин булмаган эш. Елан авызына таба кереп баручы бака сыман...

Әлмәткә таба юнәлгәч, хәтер йомгагы үзеннән-үзе сүтелә башлады. Ник дисәң, тормыш башы шушы авыл белән бәйләнгән иде. Аның әтисе тумышы белән бу төбәктән. Әнисе ерактан, Казан ягыннан. Свияжски-Вязовойда техникум тәмамлагач, Әлмәткә җибәрелгән. Райкомда эшләүче әтисе белән шушында сукмаклары бергә туры килгән. Озак та үтми аларны Чүпрәлегә күчерәләр. Татарстанда беренче электростанция шунда төзелгән. Әти райком инструкторы, ә Кушаев электростанциядә парторг. Яшьләр тиз танышып, дуслашып китәләр. Бер-берсенә табындаш булалар, йөрешәләр. Яшьләрдә уен-көлке. Шомлы шәүләләр күзгә чалынса да, яшьлек ваемсызлыгы белән белмәмеш-күрмәмешкә салышалар. Кара шәүлә тиккә генә буталып йөрми. Бер төнне ул әтине үзенең тырнакларына эләктерә. Әти суга төшкәндәй юкка чыга. Озак, авыр билгесезлектән соң, аның Тәтеш төрмәсендә икәне беленә. Әни мең бәла белән шунда ашыга. Мең бәла белән әтине күрүгә ирешә. Әти бик беткән, танырлык та булмаган. Ике үпкәсендә элеккеге каверналары ачылган. Сулыш ала алмый, ютәл буа. Кул ымы, ярым-йорты авазлар белән белдерә: мин бетәм, өмет юк!—дип кул селти ул. Утырган җирдән идәнгә иелгән һәм әнинең туфли кунычына бер кәгазь кыстырган. Бәхилләшкәннәр. Чыккач, кәгазьне алып, әни укыган: «Кушаев показаниеләре буенча мина ялган гаеп тактылар. Син моны белергә тиеш...» Әни Чүпрәлегә кайтканда Кушаев каядыр киткән икән. Ул аның каршына барырга курыккан... Бер айлап вакыт үткәнме-юкмы, төрмәдән әтинең үлүе хакында хәбәр килгән... Әни бар дөньяны каһәрли-каһәрли үзенең туган җиренә, Бөреле станциясе кырындагы авылга кайтып егылган...

Шуннан бирле кая барсам, нишләсәм дә, бәла минем белән йөри. Институтта ул һич көтмәгәндә минем тез астына сукты. Татар теленнән

Хисам КАМАЛОВ (1926) – *Татарстанның халык язучысы; «Безне өйдә көтәләр», «Үлгәннән соң яздым», «Түләнмәгән күз яше» һ.б. күпсанлы шигырь һәм проза китаплары авторы. Казанда яши.*

табар дигәндәй, КПСС тарихы буенча лекция вакытында: безнең строй дөньяда иң гадел, иң гуманлы җәмгыять ди-ди мактауга һәм мактануга каршы мин: «Менә, кара тир түгеп эшләүче колхозчыларга ничәмә-ничә еллар хезмәтләре өчен берни бирелми. Балалар ачтан интегә, моны ничек гуманлы, гадел тәртип дип әйтеп була?»—дип әйтеп ташладым. Телдән ничек ычкынганын сизми дә калдым. Әлбәттә инде, мине югары кабинетка алып менделәр: каян синдә мондый антисоветчыл фикерләр, кем котырта сине, ди-ди җанга төштеләр, әле тегеләй, әле болай тарткалап-йолыккаладылар. Мин тормышта булганны гына әйттем бит, үзегез дә аны беләсез, дидем.

Алар иреннәрен кысып, башларын чайкадылар, мине җәлләүләрен әйттеләр.

Мин бер ЖКУга истопник булып эшкә кердем. Барактан фанер белән бүленгән бер почмак бирделәр. Институтны тәмамлагач, ни өчендер еракка—Әлмәт төбәгенә билгеләделәр. Әллә әтинең шушы якныкы булуын искә алдылар микән?

Хәер, уй йомгагының башы Кушаев иде бит әле. Бюрода еш кына мине сәяси гаептән аралап калуы әни белән очрашу нәтиҗәсеме? Әйтүе кыен.

Вәзыйх ак ташны шакмак-шакмак кисеп салынган йортларны күреп, уйларын бүтән нәрсәләргә күчерде. Ул алгы бүлмәгә кергәндә алар участогы лаборанты сөйкемле кыз Лениза анда иде.

Карасу түгәрәк йөз, килешле борын, чишмә төбендәге зәңгәр ташлар төсле сөйкемле күзләр, ак кофтасын тыгызлап торган тыйнак күкрәкләр. Әле яңа гына пешеп өлгергән, кем әйтмешли, бер кашык су белән кабып йотарлык. Шушы байлык-матурлык бер бәхетле адәмгә була инде, дигән көфер уй килде Вәзыйхның күңеленә. Күңел тиле дә инде, шушы матурлыкны бөтәннән күпсенә.

Ләкин иң гаҗәбе шул, авылда калган баш механик Шаяз да аның янында иде. Ничек болай? Миннән авылда калган иде бит? Егет Вәзыйхның аптырап ачылган күзләрен күреп булса кирәк, ана якын ук килеп:

—«Сельхозтехника»дан чылтыраттылар,—диде.—Сошниклар кайткан. Матай белән генә элдерттем...—диде.

Лениза Шаязны эчкәре бүлмәләргә алып кереп китте. Болар танышлар икән ләбаса, дигән нәтиҗә чыгарды Вәзыйх кыяфәтләреннән сиземләп.

Култыгына кәгазьгә төргән нәрсәдер кыстырып Шаяз чыкты һәм, Вәзыйхка шаян күз кысып алды да, ишеккә ашыкты. Ни уйларга белми торган Вәзыйхны кыз үзенең эш бүлмәсенә алып керде. Ике тумбалы өстәлнең икесе ике ягына утырыштылар. Лениза киштәдән амбар кенәгәсен алды. Актарып, тиешле битне ачып куйды. «Чишмә төбендәге зәңгәр ташлар» ялык-йолык килде, озынайтылган авыр керфекләр лепердәде. Белешмә графасына язганчы, кыз Вәзыйхка карады:

—«Саратовская—29»ның тишелеше 77 процент кына,—диде.—Борчак, солы, арпаның чыгышы да шул чама. Ничек языйм? Иван Мөхәммәтович кызган табага бастырмасмы?

—Ну, нишләп алай? Симәнә әйбәт иде...—Вәзыйхның йөзенә ризасызлык чыкты. Каты бәрелергә кыймады, хәлбуки, кызның аларга хәерхаһ булуы сизелеп тора иде.

—Бер үк сортны аерым-аерым биш туфрактан тишелдерәбез. Ялгышлык булмасын өчен...—диде кызый.

—Әллә бүтән сорт китерелгәнме?—Вәзыйх башын як-якка чайкап, ни әйтергә белми утырды. Шул мәл ишектә колхоз рәисе, таза гәүдәле, зур башлы, текә маңгайлы Вил Садриевич күренде.

—Машина янында көттем, юк,—диде уенчак тавыш белән гөлдердәп.—Сине кызлар магнитлаган икән...—Ул соры габардин пальто, яшел эшләпәдән иде. Аяк кагып кына кызга сәлам бирде.

Вәзыйх аңа таба борылды. Вил Садриевичның йөзендә канәгатьсезлек болыты иде. Вәзыйх аның эше уңмаганлыгын чамалады.

—Ул нефтьче бюрократларга эшең төшмәсен,—дип куйды Вил Садриевич.

—Симәнә белән дә эш кәкәй әле...—Вәзыйх рәискә карады. Кыз тутырган графалы кәгазьне аңа сузды. Ул кәгазьгә күз йөртеп алды да, кызга төбәлде.

—Кызым, бу дөресме?

—Ышанмыйсызмы?

—Юк, ышанабыз ансы...—Рәис тавышының көчсезлегендә үзенең ниндидер гаебен исенә төшергән төсмер сизелеп калды. Ул тагы нидер әйтергә итеп, Вәзыйхка күз чылгыен сирпеп алды, ләкин ниятеннән кайтты. Кызның монда ни гаебе сон?

Алар, кузгалып, ишеккә борылдылар... Вәзыйхның чыраенда аптыраулы сорау иде. Нишләп болай килеп чыккан? Симәнә ярыйсы иде ләбаса.

Авыл хуҗалыгы идарәсенә килгәндә дә берни ачыклый алмадылар. Ничек җавап тоту турында сүз беркетмәделәр. Идарә рәисе Иван Мөхәммәтович болай гади, әйбәт кеше. Әмма рәсми кабыгында булганда бик каты кылана. Ул таза гәүдәле, ирләрчә эре сызыклы мәһабәт чырайлы, кинчә борынлы, башкаларда үзенә ышаныч белгертә торган олпат кыяфәтле кеше. Мәгәр эштә аның белән аралашканда нәчәлникләрдән шүрләп торуы сизелә. Ул аларның бер сүзенә дә каршы килми. Үзенең гаепсез булуын әйтергә дә йөрәге җитми хәтта.

Менә рәис белән агрономның ишектә күренүе булды, Иван Мөхәммәтович, рәхимсез рәсмилек белән аларны тиргәргә тотынды. *(Симәнә турында аңа житкергәннәр)*:

—Икегезне бер агачка асып куясы бар!—ди-ди кычкырынды. Авызыннан яшен утлары чәчә. Болар яшен алгычлар сыман өнсез басып торалар.— Чәчү борын төбендә, бу нинди саботаж? Горкомда белсәләр, нишләрбез, ә?! Харап итәсез бит, ник мина баз казыйсыз? Иптәш Мәмәшев, бу ни хәл? Сине районда Социалистик хезмәт Герое итәргә ничә ел тырышабыз, ә син? Иң югары уңыш синең колхозда булырга тиеш! Ну?!

Геройлык турында сүз чыккач, Вил Садриевич каушап калды. Бер кулы белән чигәсен ышкыштырырга тотынды.

—Иван Мөхәммәтович,—диде, майлы ялагай тавыш белән,—без бу упущениене ике-өч тәүлектән төзәтербез! Ышаныгыз! Безне беләсез. Менә агрономның тәҗрибәсе җитеп бетмәү сәбәпле махы биргән, понимаешь!

Аның аңлатып маташуын Иван Мөхәммәтович юньләп тыңламады да шикелле. Өстәл артында калкына биреп, югалыгыз күземнән, дигәнне аңлатып, кулын кат-кат селтәде. Үзенең шулай каты булуына ул үзе соклана иде шикелле. Йөзендә шул нәрсә сиземләнде. Рәис белән агроном, бер-берсенә карарга уңайсызланган хәлдә, аякларын песи шикелле пружиналандырып кына атлап, чыгып киттеләр. Рәис бар гаепне аның өстенә аударуына Вәзыйх кәефсезләнгән иде. Төбендә исә планны иң алда үтәр өчен симәнә орлыгын триер аша бер генә тапкыр чыгарттырды. Вәзыйх әйтте: симәнә ике тапкыр триер аша үтәргә тиеш, диде. Бер уч бодайны уч төбенә таратып тикшерде. Берничә зәгыйфь бөртек табып рәискә күрсәтте. Вил Садриевич моңа әһәмият итмәде. Үз сүзен сүз итте...

... Машина янына чыккач, Вәзыйх шул хакта сүз катарга уйлаган иде. Рәиснең ачуын китерермен дип, эчтән тынды. Хәер, рәиснең бу чалымы гадәти күренеш иде. Вәзыйх теге Тукай шигырьләрендәге таз малай шикелле гаепне аңа япсаруларына күнегә башлаган иде инде. Яшәү бит—түземлек, сабырлык, дип үзен юату әмәлен тапты ул.

Машина янында әз генә кинәшләшеп алдылар. Ни эшләргә кирәген Вәзыйх бик яхшы белә иде. Рәисне тыңлап торды. Чөнки Вил Садриевич боерык бирергә бик ярата. Бу аның өчен иң ләззәтле гамәл. Аның тавышы көрәя, йөзенә өстен булу нурлары тибә: «Ирләрдән өч сменалы звено төзеп, шуларны триерга куй. Өзлексез эшләп торсын триерлар. Шаяз лапаска ут кертсен, машиналарны көйләсен... Мин иртәгә кайтам. Бүген оныгымның туган көне, Сәнифәләрдә булам...»

Вәзыйх машинасын кабызды. Аңа хастаханәдән чыгасы укытучы Фаяз Бортасовның хатынын юл уңае алып кайтырга кушылган иде. Хастаханә Иске Әлмәттә, Зәй буендарак.

Мамык шәлгә төренгән, резина табанлы киез итекләр кигән, йөзенә сары тимгелләр чыккан хатынны ике няня култыклап алып килеп машинага утырттылар. Вәзыйх кабина ишеген чартлатып ябып, аның хәлен сорашты.

—Үләргә кирәк инде мина, үлеп кенә булмый,—диде ул сүнек тәссез тавыш белән. Башын урын артына ташлады да күзләрен йомды. Тагын сүз кату унайсыз иде...

Вәзыйх, юлда рәхәт уйларга бирелеп, хыялында ял итәргә ярата иде. Теге чибәр лаборант кыз тагы уйларына килеп уралды. «Ни хикмәт бу?.. Колхоз эшендә, билгеле, жан тупаслана. Кайбер эшләр кычкырыш-дәгъва аша бара. Кайберәүләр колхоз эшен үз теләге белән, булсынга эшләми. Шул нигездә башлык белән хезмәткәр арасында конфликт туа. Мөнәсәбәтләр кискенләшә. Жанда ачуташ ачысы. Кайчак барсына да кул селтәп качасы килә. Жан бизүе белән яшәве бик авыр. Әмма лаборант кыз кебек чибәрләр очрагач, каткан жан эри. Бизүләр әзәя төшә. Тагы эшлисе, яшисе килә башлый. Юк, хатын-кыз матурлыгы зур көч һәм һәр жанга тәэсир итә. Моны жирдә тереклек чылбыры өзелмәсен өчен табигать үзе тудырган. Табигать ана күпне һәм мул итеп биргән. Ул матур кыздан минем нәрсәдер аласы килү тойгысы азыну түгел. Табигатьтә дә мона мисаллар күрергә мөмкин. Әнә төклетура хуш исле матур чәчәккә килеп куна һәм энәдән нечкә борыны белән аның нектарын эчә. Ә чәчәк ул бөжәккә берни тиеш түгел. Төклетура сорап-нитеп тормый, килә дә нектарны суырып алып китә. Табигать адәм заты женесләрен бер-берсенә бурычлы, нәрсәдер тиешле итеп яраткан, ахрысы. Ир белән хатын-кызның бер-берсенә тартылуы табигать тарафыннан «программаланган» ди бит галимнәр. Мин дә ул кызга «программа» буенча нидер өмет итеп карыйм кебек. Ә шаярмыйча әйткәндә, бу жилбәзәклек, ахмаклык! Шулай да рәхәт бер мизгел. Ләкин үземнен кызыгуымны да кызга бервакытта да белгертмәячәкмен. Иң рәхәте хыялда гына ярату, хыялда гына кинәнү.

Без хатыным Рәмисә белән бик алама хәлләрдә очраштык. Бер кышкы буранлы төндә котельныйда зур мичкә ташкүмер кисәкләре ыргытып утырам. Кинәт ишекне ачып, ап-ак карга уралган бер кеше килеп керде. Кагынды-селкенде, карасам, хатын-кыз икән. Танышу шунда булды. Ул бер хәлле кешедә өй жыештыручы булып торган. Хатыны ирennән көнләшеп, моны төн уртасында урамга куып чыгарган. Ә мине институттан сөргәннәр иде. Икебезнен дә жаннар жәрәхәтле чак. Бергә торып киттек. Шәһәрдә тормыш итүе бик кыен. Матди яктан гына түгел, рухи яктан да. Жанга тыкшыналар, рухка диверсия ясыйлар. Юкка гына Такташ: «Казан фахши шәһәр», дип әйтмәгәндер. Шәһәрдә ялган күп. Анда ялганны һич тотып булмый. Ә авылда ялган, хәйлә азрак. Шуна жанга иркенрәк. Эш өчен авылны сайлауның бер сәбәбе шунда иде...»

... Эшне кызу тоттылар. Машина белән кешеләр жыйдылар. Амбарлар белән тоташ эшләнгән ындыр табагы лапасына берьюлы ике триерны көйләп эшләтә башладылар. Шаяз шактый казына торгач, өченче триерны да худка жибәрде. Шакылдау, гүелдәү һәм симәнә-бөртекнен ышылдап мөшкәгә төшүе лапасны тутырды. Эш көйләнеп киткәнгә күнелләре булып, ике башлык бер читкәрәк китеп бастылар. Вәзыйхнын йөзенә кызыксыну галәмәте чыкты:

—Карале, теге лаборант кыз Лениза сина ничек таныш?—Уң аягын алыштырып, бер яккарак авышып тора башлады. Шаязнын калын иреннәре жылылык төсмерләре белән тулды. Көттереп кенә әйтте:

—Бөгелмәдә механизаторлар техникумында укыган чакта мин кичке мәктәпкә йөрдем. Бер группада өч ел укыдык.

—Ул безнен симәнәгә «путевка»ны жайлый алмас микән?

—Белмим. Бик принципиаль кыз,—дип куйды Шаяз, ничектер горурланып.

—Сезнен ара ничек сон?—Вәзыйхнын кызыксынуы әрсезлек иде. Шаяз жавап урынына ике бармагын янәшә куеп күрсәтте. Аннары өстәде:

—Мин бүген монда кунам, төнлә триерларнын кәжәләве мөмкин...

Алар лапастан чыктылар. Шаяз тегермән өенә таба атлады. Вәзыйх машинасына утырды.

Ул болдыр баскычын атлаганда үзенең бик нык арыганын тойды. Өйгә керсә, Рәмисә, дәрес хәзерли торган өстәленә терсәкләре белән таянган килеш, башын ике учына алып, елап утыра. Чәчләре сүтелеп таралган, халаты иненнән шуган, челтәр бюстгалтерын ими башлары төрткән, борынының ике ягында кызыл тасма. Вәзыйх бер минут дәшми торды, Рәмисә башын күтәрмәгәч:

—Ни булды тагы?—диде, юатулы-иркәләүле рәвештә.

—Чапбаев дәресемне өзде. Хулиган! Аны Таһия котырткан мөгаен. Ый-ый...

—Шул гынамы? Һи-и! Нишләп Таһия булсын? Чапбайның бабасы ат карагы булган. Оныклар бабага охшыйлар, ди.

—Беләсең ич, Таһия миңа һәр төштә астан гына аяк чала! Юк, мин монда эшли алмыйм?

—Ну, билләһи, чебен тимәс чер итәр булдың...—Вәзыйх портфеленнән алып Рәмисәгә чытыр-чытыр килеп торган ике юка целлофан пакет сузды. Анда тән төсле модалы капроннар иде. Шуны күрүгә хатынның йөзе яктырып китте. Күзләре очкынлы җанландылар.

—Әйдә, чәйләп алыйк,—Вәзыйх кухняга борылды. Рәмисә оеклардан аерыла алмыйча:

—Анда әзер, бар инде үзең генә...—дип мыгырданды, чытыр-чытыр китереп пакетларны ертты, оекларны кулына алды, сузды, кире бөкләде.

Вәзыйх чәй эчеп кергәндә, Рәмисә бот төбенә хәтле житкән капроннарын аягыннан сыерып, салып маташа иде. Капрон аның бик үк төз булмаган балтырларын матурайтып күрсәтә икән. Хатын оекларны төреп, пакетларына куйды.

—Боларны киеп барсаң, сигезенче класс малайларының күзләре минем аякта гына булачак,—дип мыгырданды Рәмисә. Караваттагы кабарынкы мендәрләрне кучергәләп, ятарга әзерләнә башлады.

—Мине борчыма, ишетәсеңме?—диде, аркасы белән генә.

—Саңгырау түгел,—дип, Вәзыйх та кәефе кырылуын сиздерде. Ул хатынының холкын белә: Рәмисәнең ялындырасы килә иде. Еш кына шулай Вәзыйхны газапларга ярата. Шуңардан ниндидер рәхәт таба иде кебек. Вәзыйх ялынмый, эчтән генә үзен батырайта: «Сиңа теләнеп барырга тагы, тот менә... Бик исем китә иске чикмәнгә...»—Ул ак җәймә җәеп диванга сузылды.

«Ярар, бик әйбәт, ансыз да яшәрбез...» Бергә йоклау календарен Рәмисә алып бара иде. Шуңа ятакта тарткалашу булмый. Югыйсә күп ирләр шул мәсьәләдә хатыннары белән бозылышып бетә. Сугышуга чаклы барып җитәләр. Иртән эшкә килгән хатыннарның битләрендә «фонарь»лар күренгәли. Хатынның үзен куя белмәүдән, ирен режимга өйрәтә алмаудан бу. Рәмисә тәртип ярата. Ул Казанда яһүд профессорында, аннары зур бер язучыда өй җыештыручы, пешекче булып эшләгән. Тормышның күп өлгеләрен шулардан алган... Ул, мәсәлән, йөрми торган ирләр булмый, ди. Фикере катгый, нык. Әйткәне бар, йөрсәң миңа белгертәсе булма дип. Бүген кырын торуы сәер. Әллә теге лаборантка кызга соклануым нуры күзләремдә калганмы? Рәмисә шуны... Мине һәрчак күз карашым, чыраем сата...

Әмма симәнә орлык тишелешенең начар булуы Вәзыйхның йокысын качырды. Ул төнне борчылып, талауланып чыкты. Таң белән торып, юынып та тормыйча лабораториягә килде. Бу алты почмаклы иске йорт иде. Салкын. Аралыктан утын-ярка табып, кече яктагы тимер мичкә ягып җибәрде. Өйгә бик тиз җылы төште.

Вәзыйх порцияләп салынган һәм сорты язылган пакетларны сүтте. Менә «Саратовская-29». Бөртекләрен микроскоп астына куеп, күздән кичерә башлады. Тукта, нәрсә бу? Әһә! Унбиш бөртекнең өчесендә ак сызык—кабыгы купкан эз бар. Кабыгы купкан, димәк, бөртек яралы дигән сүз.

 Яралы бөртек, әлбәттә, тишелеш бирми, ягъни шыта алмый. Шытып чыкса да, зәгыйфь буладыр. Билгеле инде, зәгыйфьтән зәгыйфь токым... Шайтан алгыры, менә эт башы кайда күмелгән икән! Симәнәне алыштыру нигезендә «Кызыл көч»тән алган идек?

Ишек ачылганга караса, Шаяз кереп килә. Төнлә йокламаса да, йөзендә йончылганлык әсәре юк. Вәзыйх ачыш ясаган, әмма үртәлүле тавыш белән симәнә тишелеше турында сөйли башлады. Нәрсәдән бөртекнең тышчасы купкан, ак сызык булып тора. Бөртек кабыгында яра кебек ул ак сызыкча. Ә яраланган бөртек шытым бирәме?.. Шаяз да микроскоп белән маташты. Вәзыйх әйткәннәрне үз күзләре белән күрде.

—Да-а,—диде,—муен артын кашып, беләсенме, бу бодайны яна «Нива» белән суктырганнар. Әйе, әйе, «Нива»да ике барабан. Бөртекне саламда тамчы да калдырмый, бөртек ике барабан аша уза. Каты суга һәм кайбер бөртекләрнең тышчасы купшаклана... Симәнәгә кулай булмый...

—Ник син моны хәзер генә әйтәсең?—Вәзыйх кычкырып җибәрүен сизми калды.

—Хәзер генә бу хәл башка сукты,—диде Шаяз, тыныч кына.—Маңгай бәрелмичә, күз ачылмый инде безнең...

Тынлык урнашты. Вәзыйх, башын үртәлүле читкә борып, уйга калган иде. Тимер мичнең гөрелдәп януы гына тынлыкны бозды. Сөйләшә башладылар. Хәзер чигенү мөмкин түгел. Симәнәне гектарга бераз арттырып бирергә туры килә. Моны читкә чыгармаска килештеләр. Запас бар иде. Вәзыйх эчтән үзенең сукырлыгын битәрләде: «Мин тун башка зур сабак бу! Һәр эштә күзеңне ачып йөрергә, шик аша карарга кирәк. Шик бөек нәрсә, шик кенә ачышлар ясый... Үз гаебең аклар өчен адәм баласы философ булып ала...»

Шаяз идарәгә ашыкты. Вәзыйх тартмада тәҗрибә-туфракка күмелгән бөртекләрне бармаклары белән актарып карады. О-о, әнә ниндиләр: кабыкны ярып шытып чыкканнар. Тормыш пружинасы үренте бөртекнең яртысын яралгыны үстерү өчен ризык итә—имә башлаган. Үрчү яралгысын үз эчендә тоткан бөртеккә бик авырдыр. Бала табучы хатын шикелле. Ләкин аның ыңгырашуын, уфтануын безнең колаклар ишетә алмый. Табигатьнең күпме ыңгырашу-зарларын ишетмибез һәм ишетергә дә теләмибез түгелме соң?

## 2

Фаяз лапаста «Дружба» пычкысы белән утын турады. Мотор тавышыннан колаклары тонды. Пычкы авыр иде, беләк мускуллары тартылды. Учына чыккан кабырчыклар тишелеп әчетте, шулай да ул канәгать иде. Башкарган эш җанга ниндидер рәхәтлек бирә. Ул, өстенә ябышкан пычкы чүбен кага-кага, өйгә таба атлады... Тәрәзәдән күзенә чалынды: кухняда кайнана чәй хәстәрләп йөри иде... Шушы кичерәк кенә алты почмаклы мәктәп йортында алар өчәү яшиләр. Дүрт ел чамасы элек, Рабига каты авыруга дучар булгач, аны әнисе килеп карый башлады. Алар бу авылныкы түгел, урман артындагы Шарламадан. Кайнана да башлангыч класс укытучысы, кызының хәленә керер өчен стаж буенча пенсиягә чыккан. Ул кысык күзле, караңгы чырайлы. Калын сөзәк ине, тәбәнәк буе аны йомры итеп күрсәтә. Кызының өметсез авыруы исә йөзенә кайгы билгеләре салып, җыерчыкларын күбәйткән.

Алгы якта чишенгәч, Фаяз юынгычта кулларын су белән йөгертеп алды. Чәчләрен бармаклары белән рәтли-рәтли кухняга керде. Өстәл янында Рабига һәм әнисе утыралар иде. Фаязга да өлеш тәлинкәсенә итле бәрәңге салынган. Рабигага әнисе ялына:

—Әз генә капкала ичмаса, ничек терелергә уйлыйсын?

Ананың күзләрендә өмет чаткысы көйри, ә Рабига йөзендә тәмам бетерешкәнлек, бар нәрсәдән бизгәнлек иде. Кыстау аның ачуын гына китерә, шуна күрә Фаяз эндәшмәде. Рабига бал кашыгы белән чәен көчсез генә болгаткалый, башын түбән игән. Балавыз төсле саргылт маңгаен

җыерчык сызыклары кискәләгән, кашыгын куеп, ул кесәсеннән бер кәгазь чыгарды.

—Менә,—диде башын күтәрә төшеп,—ВТЭК справкасы. Бортасова Рабигада төзәлми торган авыру. Яңа чыгарылган РСФСР гражданнар кодексының фәлән статьясы нигезендә Бортасованың ире икенче хатынга өйләнергә хаклы...—Рабига сүзләреннән ананың күзләре шар булып ачылды, кабымы тамагына утырды. Рабига кәгазьне әнисенә бирде. Ана справканы бер укыды, ике укыды, йөзенә берни аңлый алмау галәмәте җәелде. Кызына бик сынаулы карашын төбәп торды.

—Юк,—диде, ныклы рәвештә.—Рабига, син балалыкка төшеп барасың, ахрысы? Кем шундый справка бирсен, ә?

—Мин ВТЭК комиссиясенә гариза яздым,—диде Рабига, бер дә каушамыйча.

—И-и, бала-бала,—диде ана кеше, тәмам рәнҗүле гаҗиз төстә авыр сулап.—Аңыңа зыян килгән, ахрысы?

—Чынлап, әни,—диде Рабига чигенергә теләмичә, хурлап әйткән сүзләрне ишетмәгән дә шикелле.—Бала елаганны ишетәсем килә минем. Идәндә бала тупырдап йөргәнне күрергә телим. Гомерем күп калмагандыр, сүземне аяк астына салмагыз!—Ул Фаязга карады, аның фикерен белү иң мөһиме иде. Фаяз исә моны Рабиганың балалар уены итеп карый шикелле иде. Ни әйтергә белми, бер-берсенә карарга кыймыйча тынып тордылар. Шунда Рабиганың күз яшьләре борчак кебек өстәлгә тәгәрәп төштеләр. Шып-шып-шып...

Эшнең уен булмавын күрделәр. Фаязның йөзе җитдиләнде, башына уй төшкәнлеге беленә иде. Ана исә курка калды. Хатын белән ир—икесе бер мир, ди. Белмәссең, аллә сүз берләшкәннәрме?.. Ул класста дәрес укыткан кебек хәлне шәрехләргә кереште:

—Икенче хатын алса, Фаязны кем укытучы итеп тотсын? Әдәп-әхлак дигән нәрсә бар бит әле?—Ул һаман күз кырые белән Фаязны күзәтә иде.

—Кемнең ни эше бар, рас закон рөхсәт итә икән? Эш Фаяздан гына тора?—Рабига юеш битләрен учы белән сөртте.

Фаяз лапаска чыкты. Рабига өчен кәҗә тоталар иде. Шунын астын чистартырга кереште. «Бу хатыннар мине тәмам изеп бетерәләр инде. Неужели һаман шулай барыр? Бу эт тормышы тагы күпме дәвам итәр? Бернинди котылу әмәле күренми. Нишләп мин бу тикле бәхетсез икән? Адәмнең бәхете үзеннән тора, дигән булалар тагы! Үземнән тиешлесен мин йөз процентка үти килдем. Әмма язмыш—үги ана, тез астына сукты, барысын бетереп ташлады. Башта Рабига бик матур кыз иде. Түгәрәк аксыл йөзле, елмайганда битендә сөйдергеч чокырчыклары пәйда була. Үзе шаян, куштан, яткач, Фаязның күкрәгенә учлары белән чәбәкли-чәбәкли: «Нишләп мин сине өзелеп яратам икән, ә?»—ди-ди көлә, шатлана. Син мин яратканның чиреге кадәр генә яратасың, эгоист, дип, җилкәсенә суга, шуклана. Авырга узганы беленгәч, шул тикле шатланды, очынды. Юләрем, артык сөенергә ярамый! дидем, тыймакчы булдым. Ә ул һаман канат чыккан кебек йөрде. Әмма бераздан салкын тигерде һәм баласы төште. Шуннан авыру аны тәмам аяктан екты. Сары булган, диделәр. Әлмәттә озак дәваладылар, файдасы булмады. Аннан Казанга озаттылар. Өч ай ятып кайтты. Бер дә алга китеш булмаган. Врачлар әйткән: барча дәваларны бирдек, хәзер организм үзе көрәшсен, дигәннәр. Рабига горур, баш имәс зат, сырхавын бик авыр кичерә. Үз-үзенә бер-бер хәл эшләмәгәе, дигән уй килә".

Өйдә ялгызы гына калганда, тәрәзәдән тышка карап, моңсу тавыш белән җыр суза:

*Гөл утырттым, гөл кучердем,*
*Чәчәк атты яраны.*
*Үз бәхетсезлегем белән,*
*Бәхетсез иттем аны...*

Туры килгән саен Фаязны өйләнергә үгетли: «Шушы яшенә җитеп синең

бер рәхәт күргәнең юк. Усал үги ана сине кыерсыткан, түбәнсеткән. Сине һаман кыйнап торган, шуна син һәр нәрсәдән курка торган булгансың. Детдомда да көн күрсәтмәгәннәр. Армиядә дә рәтле жиргә туры килмәгәнсен. Салкын якта хезмәт итеп сәламәтлегең какшап калган. Бер кеше башына күпме газапсызлек! Нормаль тормыш корырга синең хакың бар лабаса, җаным! Башка җиргә күч тә, шунда өйлән. Анда сине чуртым да белми. Син безгә барыбер ярдәм итәчәксең. Хатының усал булса да безне ташламаячаксың, җаным...»

Фаяз дәшми генә тынлап тора. Авыруның күңеле төшмәсен дип, ни генә күтәрмисең. Усал хатынга туры килсәң, беттең инде, дигән уй башыннан уза. Ул усал теләсә нинди ирне бөгеп сала. Ата-анасын онытгыра. Рабига китапча фикер йөртә. Авыру аны реаль тормышның изә торган ваклыкларыннан аерган, бала халәтенә төшергән. Әмма аның моннан качып кит, дигән сүзендә нииндидер мәгънә бар. Каядыр еракка олагырга да, тормыш корырга. Ә анда да тормышың барып чыкмаса? Кая барсаң да кара сакалың үзеңнән калмый бит!

Дөрес, әле ана кызлар карамаслык түгел. Ул дәрескә кергәндә пальтосын укытучылар бүлмәсендә калдыра. Кайтканда, кулын кесәсенә тыкса, анда хатлар, запискалар була. Җыештыручыларны яллыйлар, ахрысы. Уку барышында шул рәвешле Зөмәрә исемле кыздан өч хат алды. Кичке унынчыда укый ул. Билгеле, бернинди җавап бирү мөмкин түгел. Зөмәрә исә күзгә-күз очрашудан качып йөри. Ояты килә торгандыр инде... Җәй урталарында чыгарылыш кичәсе булды. Балигъ булып житкән егетләр, кызлар, барысы да эшлиләр. Кайсылары колхозда, кайберләре нефтьтә. Кичә күңелле оештырылган иде. Рәсми бүлектән соң—чәй мәҗлесе. Чәй янында мәй куелмый калмый. Җырладылар, биеделәр... Фаяз кичәдән иртәрәк китте. Өйгә кермичә, капкага сөялеп, тәмәке көйрәтеп тора иде. Якынлашкан аяк тавышына башын күтәрде, төпчеген ташлады. Сыек караңгылыктан ана таба бер аксыл сын якынлашты. Кем булыр бу, дип торган мәлдә мамыктай йомшак ике кайнар кул аның муенына килеп сарылды. Ул аның Зөмәрә икәнен абайлады. Ни эшләргә белми, каушап калды. Дер-дер калтыранган кыз аның колагына:

—Фаяз абый, үләм, мин сине яратам!—дип, уттай сулыш белән пышылдады. Чәчләре битен кытыклады, ут бәреп торган күкрәкләре Фаяз тәненә елдырым дулкыны уяттылар. Каның кайнарлатып баш миенә кудылар. Шулай да кызның дерелдәвен бетерергә теләп, биленнән ныграк кысты. Бик тиз аңын барларга өлгерде һәм кызны юатырга керешге:

—Зөмәрә, Зөмәрә, исенә кил!—дип тәкрарлады. Бу хәл Фаяз өчен бик көтелмәгән нәрсә түгел иде. Дәресләр вакытында Зөмәрәнең ана күңеле төшеп йөргәнен ничектер сизенә иде. Үз укытучыларын ярату кызларда еш очрый. Укытучысы моны белмәмешкә салыша... Зөмәрә, аның муеныннан кулларын алды да, йөзен читкә борды. Мышык-мышык килеп тавышсыз гына елый иде.

—Зөмәрә, йә тынычлан, ник елыйсың?—диде Фаяз, кулы һаман кызның билендә иде.

—Белмим, белмим!—дип пышылдады кыз, җәберсенгән тавыш белән. Аннан капылт кына читкә тартылды һәм, ике учы белән йөзен каплап, тиз-тиз караңгыга атлады...

... Фаяз, уйлана-уйлана, абзарны чистартып бетерде. Кәҗәнең муенына озын гына бау бәйләде. Исәбе тауга менгереп арканлау иде. Анда таудан яшел шырпылар шикелле булып яна үлән баш төртеп килә.

Капкадан чыгуга күрде: юлның теге ягында, тау итәгендә, бригадир Лотфуллин белән өлкән ат караучы Кәлимуллин әйткәләшәләр. Алар янында колынлы бия тора. Тезгене ат караучы кулында. Тауга тышауларга алып менә булыр... Фаяз аларга якынлашты. Лотфуллинның авызында папирос:

—Нурмыйга ат бир, утынга барырга, ишетәсеңме?—дип каударлана. Иреннәре майлы, күзләре елтырый. Салмыш икәне сизелеп тора. Хәер, аның аек булган чагы бик сирәк.

—Ат юк!—диде Кәлимуллин, кулы белән һаваны кисеп. Ул эчкә баткан озынча яңаклы, какча гәүдәле, алга бөкрәйгән, шуңа аркасы чыккан, тормыш тәгәрмәче аны нык таптаган күренә:—Әле генә,—дип, тегенә аңлата,—факелда фураж киптерергә ике олау җибәрдем. Бүген киптерсәләр, тегермәнгә илтергә, анда как раз безнең чират.—Ул буйсынучан, күндәм карашы белән бригадирга карый. Ләкин Лотфуллин аның сүзләрен ишетергә дә теләми. Кире тибәрә торган итеп кулын гына селти.

—Мин—баш, мин әйткәнне син үтәргә обязан и бетте! -Ул тавышын күтәрде, тамак кыргалады, төкеренде. Җыерчыклар ермачлаган уч төбе хәтле битләре дәһшәтләнде, төймә кебек күзләре ачу белән очкынланды.—Онытма, мин сине үз канатым астында тотам. Син бит чит элемент. Беркем эшкә алмаган чакта, үз өстемә политик җаваплылык белән сине кунних итеп куйдым...

—Шуның бәрабәренә бригаданың барча эше минем җилкәдә,—дип сүз кыстырды Кәлимуллин.

—Дөрес әйтәсең,—диде бригадир, горурланган кебек. Ул куннихка яхшылык эшләвен һәрчак тәкрарлый, бригада эшен кайгыртып, ана каршы килүләрен шуның белән җинә. Моны халыкта: яхшылык эшли дә, шуны костыра, диләр. Лотфуллин да шундый зат: яхшылык эшләгәнен һәрчак искә төшереп, йөзеңә бәрә. Яхшылыкны фәкать бурычка гына эшли иде.

—Нурмыйга ат юнәт! Все!—дип Лотфуллин беткән төпчегеннән яңа папиросына ут элдерде.

—Нурмый сыйлаган инде сине, беләм. Болай барча атларны эштән чыгарасың, көне буе эшләгән атны төнлә утын ташырга бирәсең! Ат юк, барсы да эштә.

—Киреләнмә, Кәлимуллин, кем булуыңны онытасың,—дип, бармак янап әйтте Лотфуллин.—Мин тегендә бер сүз әйттем и сине алалар да китәләр...

—Алсыннар, кансә канис, ник син шуның белән һаман җиламны суырасың?—Кәлимуллинның тезген тоткан кулы калтырап, читкә тырпаеп китә иде, шул тартылудан ат йөгәнендәге авызлык тимерләре чылтырады. Ул алга—дугадай бөгелгән кыяфәттә тауга таба атлап китте. Лотфуллин, хәтәр яный-яный, сүгенде, аннары Төбәккә илтә торган тыкрыкка юнәлде. Фаяз кәҗәсен сөйрәп, Кәлимуллин артыннан барды. Кәлимуллин ярым үле кыяфәттә: йөзе сүнгән, күзләре берни күрми кебек, дөньядан тәмам бизгән, өмете тапталган... И-и, аның күргәннәре. Ул ниместә әсирлектә булган. Власовчы дип, сәяси ышанычсызга чыгарылган.

Үзен сорау алулар, изү-таптауларга карамастан, Кәлимуллин һәркемгә хәерхаһ булуын киметмәгән. Үз нәселенең буыннан-буынга бирелә килгән игелек фонды күпме тукмауларга чыдарга, кешелеген җуймаска көч биргән. Заман һаман да кырыс, ә кешеләр заманнан да кырыс, рәхимсезрәк.

Тау башында зират иде, Фаяз кәҗәнең арканын шуның киртәсенә бәйләп төште. Кәлимуллин атын тауның култыклы төшенә ары башка илтә иде...

Фаяз өстен алыштырды да мәктәпкә керде. Мәктәп бер йорт аша гына иде. Ишектә директор Зәйнагов очрады. Чыраенда һәрчак хәстәрле мөһимлек, властьлылык. Ул бервакытта да көлми. Юморны аңламый. «Чаян» журналын антисоветчыл дип атый. Ул ияк ымы белән үз бүлмәсенә керергә кушты. Үзе ишекне ачып торды. Директор өстәле артында көл төсле тузган чәчле, кара кучкыл калын битле, эшлекле кыяфәтле колхоз рәисе Вил Садриевич Мәмәшов утыра. Аның янында серле төскә чумып ревком Мөхетдинов чүмәшкән. Әмма болай җитди булуы бик сирәк, ул шаян, бөтерчек холыклы кеше. Мондый җитдилектә чак-чак чыдап утырганы сизелә. Нәрсә булган? Боларның серле, куркулы кыяфәтләреннән Фаязның күнеленә дә шик йөгерде. Өстәл өстендә өем-өем укучылар дәфтәре. Әллә политик хата киткәнме? Зәйнагов дәүләт сере чишкән кебек пышылдап кына аңлатты. Рәис өстеннән югарыга анонимка җибәргәннәр. Укучы кулы белән язылган. Дәфтәрләрдәге язуны анонимка почеркы белән чагыштырып, теге явызны табарга кирәк. Аның сүзләрен куәтләгән кебек, рәис әйтеп куйды:

—Күпме казганасын, юк, кешегә һич кенә дә ярап булмый!

Анын сүзләре ачынып чыкты. Ул тикшерә торган дәфтәрен читкә этәрде дә авызына тәмәке капты.—Бу мәктәпне салдыру өчен инстанцияләрдә күпме йөз суы түктем. Ак кирпеч дефицит иде. Авылда салам түбәләрне бетерттем. Иске йортлар бик сирәк хәзер. Үзәк урамнарга асфальт җәйдерер өчен чабам. Газ кертү турында эшне кузгаттым... Юк, барыбер ошатмыйлар. Әллә нинди кыргый авыл. Элек монда ат караклары күп булган, диләр. Нәсел-нәсәпкә, тилчә тамырга дип әйтәләр. Таһиягә килеп ялагайланалар, табанын ялыйлар, астан үзләре үк яман атны саталар. Юаш, авыл, имеш.—Ул торды да тәмәке төпчеген чүп савытына ташлады. Элгечтән плащын, кепкасын алып киде. -ПМКдан килергә тиешләр, чаптым,—диде дә тиз генә ишек артында юк булды. Анын артыннан Мөхетдинов та кузгалды... “Главный бүре качкач,—диде шаяртып,—анын артыннан яраннары шыпан-шыпан табан ялтыраталар...”

Фаяз өстәлдә яткан шакмаклы дәфтәр битен—анонимканы алып күз йөртеп чыкты. Һи, дөрес язган бит, дип чак әйтеп ташламады. Бәла һаман шул Вил Садриевичнын усал хатыны Таһиядән башланган икән. Кибеттә шундый хәл була: бакчаларын кискән өчен ачуланып нефтьче Чамай хатыны Вил Садриевичны: кабәхәт адәм, жир бит!—ди-ди яманлый. Таһия дә шунда икән. Моны кандала урынына сытарга итеп Таһия Чамай хатыны каршына баскан:

—Кабәхәт дип әйтәсен, әллә ыштанынны төшерә башладымы, әҗәтканә!—дигән ул, күзеннән ачу чаткылары чәчеп.

Чамай хатыны:

—Кәбих, кара эчле, астыртын баз казучы!—ди-ди, чәр-чәр килә икән. Таһия, чыдый алмыйча, Чамай хатынынын янагына чалт берне! Хатын, янагын тотып, үкерә-үкерә чыгып киткән... Шушы хәл халыкнын ачуын кузгаткан. Мона рәиснен һәм Таһиянен бик күп яман якларын өстәгәннәр. Мәмәшевләр үзләрен элеккеге боярлар кебек тота, кешегә түбәнсетеп карый, дип язганнар.

—Минем өстән дә шушы кул язган иде,—дип, Зәйнагов тумбочкага штабельләп өйгән дәфтәрләрнен берәзын Фаяз алдына куйды. Ишекне бикләде. Икесе дә дәфтәрне ачып чагыштырырга тотындылар.

«Кем язганын тапсам да, әйтмәячәкмен»,—дип уйлады Фаяз. Ул рәисне һәм Таһияне, үзе әйтмешли, «нутросы» белән яратмый иде. Мәктәптә секретарь гына булып ярты ставкага эшләсә дә, Таһия барча кешенен эшенә тыгыла. Аерым хөрлек, өстенлек белән файдаланып Зәйнаговка ошамаган укытучыларга тегеләй яки болай басым ясый. Берәүләр эшләрендә үшән булсалар да, Таһия аларны мактый, өстен куя. Ә тырыш, эшчән, укучыларны белемле итәр өчен җан-тән белән казганучыларны күрмәмешкә салыша. Аларны җае чыккан саен «чеметкәләп» ала. Әйдәле, сүз бар, дип бик серле итеп үз бүлмәсенә алып керә, шунда «эшкәртә». Коллективта нервозлылык тудыра. Таһиядән куркалар. Шуна күрә кайберәүләр ана ялагайланалар.

Укытучылар арасында Таһиягә баш имәүчеләр дә бар, билгеле. Вәзыйхнын хатыны Рәмисә Таһиянен ялганын тотарга, гайбәтләрен яктыга чыгарырга ярата. Анын кайнарланып акыл сатуларына шырпылы теле белән салкын су сибә. Таһия дә җавапсыз калмый. Астан гына Рәмисәгә каршы берәр этлек эшли. Шул рәвешле алар арасында күзгә күренми торган салкын сугыш бара иде... Әмма шуны әйтми булмый: Таһия бик зиһенле, башы эшли торган, алдан күрүчәнлек сәләтенә ия иде. Идарәдә рәис, парторг, ревком четерекле хәл турында кинәшеп утыралар. Хәл мөшкел: алай итсән дә вай, болай итсән дә вай. Нишләргә? Вилгә төбәләләр: Таһия белән кинәш әле. Вил өйгә кайтып кинәшә һәм Таһия әйткәнчә эшлиләр. Дөрес булып чыга, шайтан алгыры! Берәр кискен хәл туганда, алда ничек буласын белер әмәл булмаганда, житәкче ирләр, идән буенча йөренә-йөренә, юк, Таһия белән кинәшми булмый, диләр...

3

Иртәдән бирле Вил Садриевич сыерлар фермасында кара болыт булып йөри. Бер сарайдан чыга, икенчесенә керә. Ярый әле юлларга вак таш җәйдергән иде. Һаман шушы ферма белән җыкланасың. Көн туды исә күпме сөт савылды, дип районнан тыкырдата башлыйлар. Кичә сөт мәсьәләсендә горком бюросында утлы табага бастырдылар. Сыерларның сөте кимегәннән кими бара иде. Сөт сәяси мәсьәлә. Катгый куелган. Сөт буенча обкомның махсус комиссиясе шөгыльләнә. Мәгълүмат алышу цифрлар белән генә алып барыла.

Ул савымчылар бүлмәсенә керде. Калын такталардан әтмәлләнгән озын өстәл артына барып утырды. Ишек каты, стена буендагы эскәмияләрдә— савымчылар, ферма эшчеләре. Сөт исе, бозау бәвеле һәм силос исләре катнаш үзенә аерым ис җәелгән иде. Рәис, үҗәт маңгаена, таза битләренә борчылу-хәстәрчәнлек чалымнары чыгарып, уйланып торган кебек итте дә, сүз башлады:

—Нишлибез, сөтне ничек арттырабыз?—диде, башын күтәрә төшеп, ферма эшчеләрен күзеннән кичерде. Берсе дә үз сүзен әйтергә атлыкмый иде. Шуңа сүзне үзе дәвам итте.—Сыерларга бик әйбәт рацион азык бирелә. Ә сөт артмый. Көн саен сөтне арттырыгыз дип район бугазга ябыша. Ни эшләргә, ә? Хикмәт нәрсәдә? Сез артта сөйлисез: Таһия Вилдән акыллырак дип. Чынлап та шулай. Ул веттехникумда укыган. Малның җаен белә. Анардан киңәш сорадым. Ул әйтә: башак биргәндә сыерларга онны нормадан мулрак сибәргә кирәк, ди. Ә сез ничек уйлыйсыз? Практик эш нәрсә күрсәтә?

Рәис сүзен бетереп, көткән кыяфәт белән эшчеләргә карап тора башлады. Һәркем диярлек карашын читкәрәк авыштыра иде. Фуражир Ирек Варраев үзенең таза гәүдәсе белән ничектер савымчы кызлар артынарак посарга итә сыман. Шунда өстәлгә якын гына утыручы ферма мөдире ярдәмчесе Түрфәндә Түрәева кузгалып куйды. Як-ягына каранды, учы белән калку түшен сыпырды, кофта итәген тарткалады. Матур мөлаем йөзендә яктылык пәйда булды, рәискә текәлеп, ым белән рөхсәт сорады да сөйләп китте:

—Чынлап та, Таһия апаның сүзләре һәрчак мәгънәле була. Бу мәсьәләдә генә түгел. Әйе, әйе, башакка онны арттырырга кирәк. Онда барча витамин, углеводлар...—Ул беразга туктап калды, тамак кыргалады. күзе исә рәисне күзәтте. Рәиснең йөзендәге борчылу сызыклары язылганнар. Таһияне мактап телгә алганга күңеле булган. Ә Түрфәндәнең сүзләрендә башлыкка ярарга тырышу төсмере бар иде. Кем генә башлыкның күңелен табарга омтылмый сон?—Минем сөт ике-өч литрга артык чыга,—дип Түрфәндә сүзен дәвам итте.—Ни өчен? Чөнки кызлар жилендәге сөтне азагына хәтле савып җиткермиләр, мин исә җилен төбен бер дә калдырмыйм. Мона иренмәскә кирәк. Аннары курмы мәсьәләсе. Фуражир күп чак норма онын биреп җиткерми. Тар капчыкларга сала, күп булып күренсен өчен... Комбикорма өләшкәндә дә төгәллек юк...

—Капчыклар стандарт,—дип фуражир Ирек каршы төште. Ул тулы тыгыз битле, таза иңле, юмакай ягымлылыгы белән яктырып торган чырайлы. Түрфәндәнең бу сүзләренә әллә ни ыжламады. Тыныч кына әйтте. Ләкин Түрфәндә фуражирның «өч борынга» кергәләвен күргәләгән. «Фуражның тар капчыкларга салынуының хикмәте шул «өч борын»да түгелме икән?»— диде. Бу сүзгә Ирек чәчрәп чыкты:

—Тоттыңмы? Авызыңны чамалап ач!—диде коры гына. Ләкин чыраенда ягымлылык чаткысы бетмәде.—Тел өчен баш җавап бирә...

Түрфәндә шүрли торганнардан түгел, Ирекнең ниндидер кимчелекләрен тезә башлаган иде, рәис кулын күтәреп, аңа туктарга ишарә ясады. Ирекка хәерхаһ булуы сизелеп тора. Түрфәндә активист, эшне әйбәт оештыра, аның белән дә санлашмыйча һич ярамый. Ирекне сүзсез генә яклавының артында шул ята: Ирекнең апасы Таһиянең әшнәсе. Шәһәрдә укып-өйрәнеп кайткан оста тегүче. Таһиянең барча костюм-юбкаларын соңгы модалы итеп ул тегеп бирә. Шуның өстенә Таһиядә Ирекка ниндидер күңел ятуы да бар

шикелле. Идарәдә очрашсалар, авызлары авызда була. Таһия иренен колагына Ирекнең булдыклы, игътибарлы булуы турында һәрчак быжылдап тора иде. Шул сәбәпле Ирекне идарәгә алырга кирәк дигән фикердә йөри. Ирекнең эше чынлап та хуплауга лаек. Фермада тәртип тотып тора. Эшкә иренми. Түрфәндә дә эшкә бик задур. Шунлыктан эш өчен алар арасында чәкәләшеп алулар булгалап тора. Ләкин икесе дә акыллы, тирәнгә җибәрмиләр. Ирек ирләрчә ваксынмаучылык күрсәтә. Сөйлиләр: Түрфәндә белән тынышмаунын төбендә, имеш, Ирек бу аппетитлы хатынны «бөгелдермәкче» булган, ботына үрелгән, ә Түрфәндә тегенен яңагына чалтыраткан... Булса да булыр. Түрфәндә буе-сыны, йөзе-чырае мөлаемлыгы һәм тәмле сүзле булуы, чаялыгы белән күп ирләрнең күзен яндыра. Хатыннарыннан тәмам туеп косасы килү хәленә җиткән ирләр ана сүз кушкалыйлар. Ләкин Түрфәндә каты тора, бәясен һич тә төшерми. Сөйлиләр, ялгыз хатынның гайбәтен саталар, югарыдан бик үк яшь булмаган урыс вәкиле килгәндә күнел ачарга Түрфәндәне алып киләләр, ди. Чөнки хатын русча әйбәт сөйләшә иде...

Ирекнең әшнәлек аша башлыкларга якынаюын барсы да белеп торганга күрә, рәис күзгә төтен җибәрү өчен генә әйтә куйды:

—Мөхетдинов,—дип Вил мич янындарак утырган ревкомга дәште.—Түрфәндә дельни әйтә, колагына эл! Утсыз төтен чыкмый.—Ул башын аска иеп утырган фуражирга елмаеп күз кысып алды. Янәсе хатын-кызга бераз ташлама ясамый булмый. Вәзыйх урынында кузгалып, башын рәискә таба борды.

—Әйдә, синдә нинди план?—диде рәис, аңа сүз биргән төстә.

—Комбикорманың сыйфаты начар,—дип башлады Вәзыйх.—Аксым җитми...—Текә маңгаена хәстәрчәнлек җыерчыклары сыр-сыр булып ятты. Ул борын кырыен бармагы белән ышкып алды.—Анда ашлык бөртеге бик әз. Димәк, аксым да әз. Әнә, тиресне карасагыз, ак бөртекләр күрерсез. Бу—сыер ашказаны эшкәртмәгән ашлык бөртекләре, булган бөртек тә тирескә чыга. Аксым булмаса, сөт артмый, моны яхшы беләсез. Вил Садриевичның тәкъдиме хаклы, он нормасын арттырырга кирәк. Арыш отходы бездә бар, байтак. Киптереп, тарттырырга...

—Ә атларга нәрсә?—дип аваз салды ветсанитар Мотыйк.

—Атларның сабан сөрәсе юк,—диде Вил Садриевич ябктырып.—Аларга люцерна, клевер ярап торыр. Вообще, атларны бойнига тапшырырга кушалар.

—Отходны киптерү бик кәнителле.

—Факел астында кыш буе киптерделәр бит.

—Хәзер анда кереп буламы соң?

—Әнә Юкәлек, Урсудагыларга таш юл салынган.

—Ике факел белән генә җитешеп булырмы?

—Киптерү эшен өч сменага көйләрбез,—диде Вил Садриевич, хәлдән чыгу әмәлен тапкандай җанланып.

Сөйләнгән чаралар тиздән гамәлгә керде. Сөт савымы бераз артты. Шулай да артталыкны бетермәде. Алдынгы колхозлар савымны өч мең литрга җиткерделәр. Аннан да уздырдылар. Ә «Ирәч» колхозы ике мең җиде йөздән уза алмый иде. Барча резервларны кулланып беттеләр. Хәзер нишләргә? Районнан көн саен кысалар, яныйлар. Хуҗалыклардан җыелган сөт исә валовой планны тутыру өчен языла.

Вилне тагы бюрога чакырып каезладылар. Авыл хуҗалыгы идарәсе рәисе Иван Мөхәммәтовичка да каты эләкте. Соңгы кисәтү ясалды. Нишләргә? Алар башлары иелгән, бөкреләре чыккан кыяфәттә Иван Мөхәммәтович кабинетына кайттылар. Чырайлары чытык, битләре кайрак кебек кара янган. Нахакка кыйналганны йөрәк белән кичереп утырганда эчтәге ачу-ут әнә шулай биткә тибеп чыга. Бер-берсенә туры карарга уңайсызланып, папирос кабыздылар да, уйга чумып, көйрәтәләр. Телефон чылтырады.

—Син кем белән анда?—Иван Мөхәммәтович хатыны.

—Колхоз рәисе белән.

—Син тагы соңарасың бит...—диде властьлы тавыш. -Пирогны табадан алдым.

—Хәзер, хәзер,—ди-ди ялагайланды Иван Мөхәммәтович. Трубканы куйгач өстәде:—Өй прокуроры ашыктыра... Ну, нишлибез, ә?

—Тәмам аптыраган инде, Иван Мөхәммәтович. Башка колхозлар ничек сөтне планга житкерәләр? Аңлый алмыйм...

—Хәйләлиләр. Һаш ике О ны беләсеңме?

—Әһә, беләм, беләм.

—Зиһенеңне жик. Мин моны сиңа әйтмәдем, син ишетмәден. Вчу!

—Ишетмәдем, юк! Рәхмәт!—диде Вил, укытучы артыннан кабатлаган укучы кебек. Алар икесе берьюлы урыннарыннан кузгалдылар.

Кайткач Вил моны Түрфәндәгә дәүләт сере итеп әйтте. Һәр савымчы фәкать үзе генә белсен. Сөткә су кушуны беркем күрергә тиеш түгел. Иптәш савымчы да, бүтән дә. Беленгән очракта җаваплылыкны бары үз өстенә генә алсын.

Әйе, планда бер «лазейка» бар иде. Таләп литрлар санын пландагыга житкерү. Сөтнең куелыгы-майлылыгы таләп ителми. Сөткә су өсти башлагач, билгеле, литрлар саны артты. Билгеләнгән саннарга якынлашты. Бюрога чакырып каезлаулар тынып калды.

Моның уйдырма хәл икәнен барысы да белә. Ләкин беркем бер сүз дәшми. Берләшеп дәшмәү барысына да уңай кебек. Бу инде коллектив ялганлау белән бер. Ялган ерак бара алмый, ди. Берләшеп оештырылган ялганның юлы бик озын. Өстән реаль булмаган, ялган кушылган план төшерделәр. Астагы баскычта торган тир түгеп эшләүчеләр бар көчләрен салсалар да планны үти алмадылар. Ахырда ялган белән планны тутырырга мәҗбүр булдылар. Бер ялган икенче ялганны китереп чыгарды.

Сөтне арттыруның реаль юлы ул сыерларның нәселен яхшырту. Аксымга бай кормалар бирү. Нәселне яхшырту бер бишьеллыкта гына хәл ителә алмый торган нәрсә. Ә генераль планда сөтне арттыру куелган, цифрлар китерелгән. Ул планны теләсә нинди юл белән үтәргә кирәк. Һәм ялган белән үтиләр.

Вил Садриевичның бу хәлләргә бер дә исе китмәде һәм борчылмады да. Нинди генә канлы ялганнарны йотып яшәргә туры килмәде ана! Бу ялган исә чүп кенә, гадәти нәрсә. Дөресен әйткәндә, ялгансыз бер көн дә яшәлми, алдаусыз барып булмый. Ялган дөреслек урынына йөри. Дөреслектән әйбәтрәк булып йөри. Ялганны кешеләр дә өни төшә. Чөнки ялган вәгъдәләр белән ышандыра, баштан сыйпый, тынычландыра.

Ә Вәзыйхның бу хәрәмләшүләргә эче поша, җаны әрни. Үзебезне үзебез алдыйбыз бит! Моның азагы яхшы булмас, юк. Бер зур фаҗига килеп чыгуы ихтимал. Экономиканың кануннары катгый, анда алдалап эшләү мөмкин түгел, дигән тәгъбир каяндыр колагына кереп калган. Бактың исә, мөмкин икән бит! Юк, моңа минем башым гына житми. Вил Садриевич белән сөйләшеп карарга кирәк. Ул өчъеллык партшкола тәмамлаган кеше. Коммунистларның берәр яшерен серен беләдер? Бик күп җирләрдә эшләгән. Гел житәкчелек эшендә. Күп тәжрибә туплаган, какланып беткән...

Әллә Вәзыйхның борчылуын, нидер әйтергә теләвен сизеп, районнан кайткач, Вил бер аулакта үзе сүз башлады:

—Син анда тагы нәрсәләр сөйләнден, ә?—диде, шомлы-куркыныч төстә.—Тегендә барып ишетелгән, понимаешь!

—Нәмә, нәмә, аңлап житмим?—Вәзыйх, күзләрен тасрайтып, рәискә карады.

—Ярамаган сүз ычкындыргансың, вәт шул! Анда боргалана алмыйсың...

—Кромольный сүз сөйләгәнем юк, Вил Садриевич!

—Исбатла үзеңнең кара эчле түгел икәнеңне, ә? Тагы сине якларга туры килде. Үз башыма алырга...

—Эш интересы өчен генә бит, Вил Садриевич. Үзең дә беләсең. Турылык инде.

—Кеше күңеле—кара урман. Авызыңны чамалап ач! Матри аны!—Вил

Садриевич кинәт кенә борылды да бухгалтерлар бүлмәсенә юнәлде.
Рәиснең болай уяулык турында искәртүе беренче генә түгел. Ана Вәзыйхның биографиясендә булган чатаклыкларны житкергәннәр, билгеле. Институттан чыгарылуын да, кайбер тәнкыйть сүзләре әйткәләвен дә. Бәлки үзе сораткандыр. Югарыдагылардан өлге ала ул. Үз кул астындагыларны куркытып тотарга маһир. Әнә бит сине яклады дип, үзенә бурычлы итә. Әллә яклаган, әллә юк. Яклавына ышанмасаң да, ышанырга туры килә. Ә куркытылган кеше көн-төн эшләсә дә зарланмый. Чөнки үзен билгесез гаеп белән гаепле дип саный... Менә теге әйтергә теләгән ялган сөт турындагы фикерләрең кинәт куркыныч булып тоела башлый. Һәм син эчтән тынасың. Ул хактагы уйлар артка чигәләр һәм үз башың кайгысы жаныңны били. Реаль көнкүрештән кабынган чын фикер утына әнә шулай су сибелә, сүндерелә...
Хәрәмләшү дигәннән, узган елларда да андый хәлләр булгалады.
Ел саен көтү чыгар алдыннан барча мөгезле эре терлекләргә ветеринария каравы уздырыла. Малларның тазалыклары тикшерелә. Бу бик мөһим профилактика.
Ирәч авылы тулысы белән чокыр-чакырларга, коры үзән култыкларына, инеш буе тугайларына утырган. Бер генә төз, тигез урын юк. Югары очта кибет янында берничә торым туры тыкрык сузыла. Яр асларындагы, төрле төбәкләрдәгеләр сыерларын шул төз тыкрыкка китереп капкаларга, читән-киртәләргә бәйләделәр. Көн кояшсыз, төньяктан салкын жил исә, малларны күшектерә, кешеләрнең муеннарыннан үтеп кереп, тәннәрен чиркандыра иде. Тирә-юнь сыер мөгрәгән, яки бик сузып «үә-үә-үә» авазлары чәчеп үкергән тавышлар белән тулды. Кайбер сыерларның абзарда калган бозаулары тавыш бирә. Сыер үз баласын танып, тагы да ныграк үкерергә, тартылырга, башын чайкый-чайкый күзләрен алартырга тотына. Ничек тә ычкынырга итә. Хужа хатын, йөзен тар гына калдырып, шәмәхә яулык бәйләгән, сыерны көчкә тыя, тынычландырыр өчен ипи сыныклары каптыра. Икенче бер мимылдап торган симез сыер ферма ягына башын сузып шәрран яра. Хатын-кызлар сөйләшәләр: үгез сорый бу, үгез,—диләр. Хужасына карап:
—Үгезгә күрсәтмәдегезмени?—дип, жәлләү белдерәләр. Вакытында үгез күрмәсә, кысыр кала инде, дип хужасына борылалар. Бүтәнчә үгез теләмәве ихтимал. Әнә мал сизенеп ничек борчыла, ычкынырга ыргыла... Кай арададыр бавын өзеп, сыер ычкына алды һәм ферма ягына элдерде. Авыз ачып калган хужа карчык аңа иркәләп дәшә-дәшә артыннан китте. Хатыннар исә: мал иясенә охшамаса хәрам була, диләр, ди-ди, гайбәт сата башладылар. Карчыкның малае—сыерның хужасы бик мут икән. Факел янында фураж киптерергә төнге сменага ялгыз хатын куелса, үзе теләп, шунда бара. Көндез эшләгән булса да. Хатыны да әйбер әйтми, ди... Әнә теге сыерлар тик күшәп торалар. Хужалары да бик тыныч холыклы, иплеләр. Әнә теге ала сыерның хужасы да керделе-чыктылы чуар күңелле адәм. Әнә тегесе исә бер өзлексез тамак төбе белән күкле-яшелле тавыш чыгарып үкерә дә үкерә. Теңкәгә тиеп бетә. Иясе дә юк өчен тавыш куптара торган затсыз нәрсә...
Менә кибет янына читән арбага кысылып утырган ветврачлар килеп төште. Шәп ат жиккәннәр. Кузлада ветсанитар Мотыйк бик мөһим эш эшләүче кыяфәте белән утыра. Ул аларны түбән очтан алып килде. Урамда пычрак, аяк атлый торган түгел. Маллар бәйләгән тыкрык түбә урын булганга корырак иде. Арбадан ак халат кигән өч ир кеше сикереп төште. Озын буйлы, какча гәүдәлеләр. Баш ветврач Черипанов авылга таныш. Ел саен айгырлар печәргә килә. Байтак елларны бу участокны алып бара. Иң элек сыерны ул капшап-тоткалап карап уза. Аннан теге икесе шприц белән сыерның муен тамырына укол кадыйлар. Мотыйк мөгездән тотып тора һәм амбар кенәгәсендәге исемлеккә билге куярга өлгерә. Бераз эшләгәч, тәмәке көйрәтергә туктыйлар. Бертуктаусыз мәзәк сөйлиләр.
Имеш, бер эшче нәчәлнигыннан: «Югарыдан тәнкыйть ничек була соң?»—дип сораган. Нәчәлник трибунада торган көе төкергән һәм төкерәге эшче

башына эләккән. «Менә югарыдан тәнкыйть шулай була дигән. Ә хәзер син мина төкер»,—дип әйткән. Эшче төкергән. Төкереге үзенең башына килеп төшкән... Менә монысы түбәннән тәнкыйть дигән нәчәлник... Ике тәнкыйть тә түбәндәгенең башына төшә... Тәмәке төтененә тончыга-тончыга көлештеләр... Аннары укол кадый-кадый рәттән киттеләр...

Сыерларга уколның тәэсире булды, ахрысы, тыныбрак калдылар. Врачлар тәмәке кабызып, читән арбага утырдылар. Мотыйк атны Түбән очка юнәлтте. Сыерлар янында хатын-кыз, бала-чага калды. Укол салгач, ике сәгать үтәргә тиеш. Моны һәркем белә. Балаларга пирке ясаган шикелле. Вакыт узсынга тегене-моны сөйләшәләр. Беришләре мактанып канәгатьлек таба, икенчеләре зарланып. Нефтьче хатыны: менә безнеке премияне генә биш йөз алды. Ике ай бораулыйсыны кырык көндә бетергәннәр... Сельпога ботылар кайткан, ләкин илле күкәй тапшырсаң гына бирәләр. Каян житкермәк кирәк. Әле кайчан гына ак чиләкләр тотып, укытучылар күкәй жыеп йөрделәр. Аларга авыздан өзеп бирәсең инде. Бирмәсәң, баланның аттестаты рәтле булмый. Бала сабагын яхшы белә дип, ничек исбат итәсең! Һаман шул, ни булса, авыл халкына төшә...

Врачларга калҗалы әбәд әзерләгәннәр иде. Анда аларны Мөхетдинов сыйлап йөрде. Черипанов белән күптәнге танышлар. Хәрәмләшкән хәлләре дә булмады түгел. Бергә хәрәмләшү кешеләрне бик нык бәйли. Хәзер алар бер-берсен бер ым белән аңлыйлар. Өй алдына чыгып тәмәке көйрәтә-көйрәтә, шыпырт кына сөйләштеләр. Районнан күрсәтмә бирелгән иде. Менә табигый чирле табылган сыерлар өстенә тагын кемнәрнең сыерларын «браковать» итәргә тиешле—шуны тәгаенләделәр. Мөхетдинов баш ветврачка яшерен исемлек язылган кенәгә тоттырды. Болай: Мөхетдинов үзендәге исемлектән сыер хуҗасының фамилиясен атый. Черипанов үз кенәгәсенә күз төшереп ала да, чирлегә чыгарасы булганда, аеруча җентекләп карый һәм чирне аңлата. Мөхетдинов хуҗага аның әйткәннәрен тәрҗемә итә...

Һәркем белә, чирле маллар калмаска тиеш. Һәр елны эшләнә торган бу чара кешеләрнең сәламәтлеге өчен кирәкле нәрсә. Шуңа бу профилактикага каршылык күрсәтү гадәттә булмый.

Кызыл төстәге сыеры янында сырма кигән, битенең бер ягын бөтенләй каплап калын яулык бәйләгән, нәүмиз кыяфәтле хатын тора. Күп балалы Заһидә. Ире бик эчә торган адәм. Тормышны хатын алып бара. Сыерын чирлегә чыгаргач, еларга тотынды.

—Балаларыма ни ашатыйм? Алар иртән тору белән ашарга сорап итәгемә ябышалар.

Врачлар аның елаганын ишетмәмешкә салышып, ары киттеләр. Мөхетдинов белән Мотыйк хатынны юаталар. «Сыерында чахотка башланган, сөтен эчәргә ярамый. Сезнең җылы сараегыз юк бит, үпкәсенә салкын тигәндер»,—диләр.

—Юк, кыерсытудан бу,—диде Заһидә.—Эчә торган кешегә ничек тә бата, дип кимсетүдән генә!

—Әнә минекен дә «браковать» иттеләр,—дип усал итеп кычкырды Мөхетдинов.—Нишлим, минем язвыга да кәҗә сөте кирәк...

—Сез идарә күселәре җаен табарсыз, ә мин балаларга... Сез карт сыерыгызны браковать иттереп фермадан нәселле бозау аласыз! Әллә белмиләр дисезме?

—Заһидә, син чамалап!—Мотыйк моннан ашыгып киткән Мөхетдинов артыннан элдерде. Заһидә әллә белеп, әллә кыек атып туры тигерде: Мөхетдиновның үз сыерын чирлегә яздыруының сере нәкъ шулай иде. Чөнки фермага шәп нәселле сыерлар кайтаралар. Шулардан туган бозауны алып үстерергә ниятли ул. Бу хакта хатыны колак итен ашый: үзең активист, көн-төн казна эшендә, ә үзең кәҗә кебек тә сөт бирми торган сыер асрыйсың...

Икенче берсе, бай тормышлы, бик саранннар. Хатын модалы бәрхет тышлы жакеттан, ялтыравык боты кигән, янып торган чырайлы, җептән нечкә иренле.

—Юк, сыерны бирмим, лутчы үзем суеп ашыйм,—ди-ди, чәрелдәргә тотынды. Тавышы норсызның, колакларны авырттыра. Мөхетдинов тәҗрибәле, мондый затларны артларына ничек утыртырга белә.

—Йә, бик безелдәмә,—диде,—курма урлап тотылгач, минем алга ирең белән икегез артыгыз белән шуып килгәнегезне онытма! Аның шаһиты бар. Эш худка китсә, сыердан гына түгел, бүтән нәрсәләрдән дә колак кагарсыз...—Мөхетдинов, кинәт шым булган хатынга зәһәрле күз сирпеп алды да, ары китте. Ул белә: һәркемнең нинди дә булса гөнаһы—пычрак ягы булмый калмый. Теге бик ярпачлана башласа, Мөхетдинов аның тизәген борынына китереп иснәтә. Теге шунда ук канатларын җыя, юашланып кала.

Тәгәрмәч остасы Нурмый Черипанов белән үзе сөйләште. Ул рус боярында үскән, русчаны ана теленнән яхшырак белә. Баш врач белән нык тарткалашты. Сыерының чирле түгел икәнен төгәл белә иде. Туры сүзлелеге, ялагай булмаган өчен властьлар аны үги итәләр. Сәяси ышанычсыз, янәсе. Сыерны чирлегә чыгару шуның хикмәте. Ул үз хакын хакламакчы итеп нәрсәдер исбатлап маташа. Черипанов аны тыңламады, башка сыерларга күчте. Мөхетдинов Нурмый колагына: «Абзый, алар барыбер үзләренекен итәләр, белмәссең, карышуыңның үчен алмагайлары...»,—дип пышылдады. Нурмый, ачуыннан буыла язып, көчкә тынычланды. Власть ничек теләсә шулай эшли инде, билгеле нәрсә.

Ике көннән көтү чыкты. Чирле табылган сыерларны көтүгә кертмәделәр. Авыл активистлары бик кырыс кыландылар.

Көтүгә чыгармыйча абзарында сыер асрап булмый. Кайбер күп балалы хуҗалар азык юнәтеп, тауларда арканлап йөртеп карадылар. Бу озакка бармады. Көне буе бер кеше сыер белән генә булырга тиеш. Шунлыктан сыер таккан олаулар Бөгелмә юлына агыла башлады. Анда малны бойнига алалар һәм әзрәк акча тулиләр иде.

Крестьян җилкәсенә төшкән бу бәла кайдан, ничек башланды дигәндә, аның тамыры тирәндәрәк иде. Союзның берничә өлкәсе ит заданиесен яртылаш та үтәмәгәннәр. Кайсында корылык, кайсында ящур афәте малларны кырган, ди. Шулар өчен һәм тагы өстәмә рәвештә ит заданиесен үтәргә кирәк. Кайсы өлкә, республика күпме үз өстенә йөкләмә алала? Безнең республика башлыгы өстәгеләргә ярарга теләп, йөкләмәне бик күп алган. Мәскәүдән кайткач, райкомны—беренче секретарьларын җыйган да һәр районга ит заданиесе бүлеп биргән... Райком исә ничек булдыра ала, шулай планны тутырырга керешә... көн-төн тир түгеп эшләүчеләр авызыннан тартып алып ит түшкәләре Вьетнамга, Кубага, тагы башка карамораларга озатыла иде. Ә бит ватаныбызга ерткыч баскыннар тагы һөҗүм итә калса, аларга каршы шул хәләл сөттән, иттән мәхрүм ителеп, бәрәңге белән үскән малайлар күкрәк куячаклар. Ә теге безнең нигъмәтләрне ашаган чит ятлар түгел...

Казна төрлечә хәрәмләшеп крестьяннан байлык суыра. Крестьян үз нәүбәтендә казна нигъмәтен кайда туры килсә шунда шудыра. Баш на баш дигәндәй. Авылда азык мәсьәләсе бик кискен. Болыннар юк. Кайбер эшчән адәмнәр урман посадкасы чистартып печән әзерли. Посадка күпләргә тәтеми. Фермалардан арткан саламны хезмәт көненә бүләләр. Ул да бик аз. Кул чанасы белән барып салам эскертләрен кимерәләр.

Баштарак Вил колхоз милкенә ягылучылар белән рәхимсез көрәште. Ишек төбендә иярле ат тора иде. Сигнал булу белән атлана да чаба, каракларның үкчәсенә баса, берничә угры суд эскәмиясенә утырды. Күпләрне штраф белән өркетәләр иде. Халык та эсалланды. Бер көнне телефон баганаларына: «Вил, әгәр янә болай эшләсәң, без сине ничек җыярга белербез, сөягеңне дә таба алмаслар!»—дигән язулар ябыштырып чыкканнар иде. Утыртылганнарның шәһәрдәге туганнары яный булыр. Юк, болар шаярмыйлар, диде зиһене алдан йөрүче Таһия. Нигә син берүзең генә гаепле булып каласың. Караклык бетә торган түгел, моның белән җәмәгать көрәшсен... Бу файдалы киңәш иде. Активистлардан бер төркем

оешты. Башлыклары тынгысыз Мөхетдинов, ана булышчы Ирек. Бик тырыш егет. Идарә белән колхозчылар, нефтьчеләр арасында туган конфликтларны алар тикшерә, хөкем чыгара. Җәмәгать бик актив эшли, Вил канәгать булып, мыек астыннан гына серле елмаеп йөри.

... Сигнал килә: фермага азык ташучы Зелпе кушаматлы тәбәнәк кеше төнлә силос урлаган... Мөхетдинов иртүк чанага әзрәк корма сала, бер-ике активистны утырта да Зелпеләргә юнәлә. Сырма кигән, кырынмаган, шуңа зелпе каерысыдай кара янаклы хуҗа үзе килеп чыга. Капканы ачып, олау белән эчкә узалар.

—Зелпе, менә кичә урлаган силоска добавка, идарә җибәрде, кабул итеп ал!—дип Мөхетдинов сүз башлый, астан гына Зелпене күзәтә. Сәнәк ала да корманы абзарга ташыган итә. Кичәге силос өемен күреп алалар. Зелпенең чигенер урын калмый. Бу хикмәт аның үзән миенә китереп суга. Эшнең хәтәр төс алуын аңлый, ирен кырыйларыннан төкерекләре агарга тотына. Ул төкереген «эссеп-эссеп» дигән авазлар чыгарып эчкә ала. Силосларны сәнәк белән кире ташырга тотына.

—Егетләр, зинһар, бәлаләмәгез, ә? Моннан соң ак тәүбә, кара тәүбә! Ике бала мәктәпкә йөри, ким-хур итмәгез! Мин болай нәфседән генә. Нәфсе шайтан котыртты—шайтан шул хатын инде. Хатын сүзенә карап соң...

—Зелпе, моның бит статьясы бар!—Бу сүзләрдән соң Зелпе сәнәген тоткан килеш тынып калды. Күз кырыйлары юешләнде. Мөхетдинов чаманы белә, кешене артык түбәнәйтергә ярамый. Сиңа ачу белән төйнәлгән дошман әзерләвең мөмкин.

—Ярар, Зелпе, силос хакын кассага кертерсең,—диде Мөхетдинов һәм Зелпегә кинәт җан кергәндәй булды.—Рәхмәт, туган, рәхмәт!—ди-ди урынында таптанды. Шелтәләүнең бер чигендә гафу итә белергә дә кирәк. Кешедә җитәкчелеккә карата үчле фикер калмасын...

Алар сөйләшә-сөйләшә кибет янына килеп җиткәннәр икән.

Бик эшлекле, зур эш кырып йөргән кыяфәттә, өч чөлти алдылар да бүлеп эчтеләр. Тормыш каршылыкларыннан, эчке киеренкелектән баш миенә авыр булып утырган юшкыннарны юдырып төшергән кебек булды...

Мөхетдинов Бишмунча очында яши иде. Ул караңгы урамнан шул якка атлады. Өйгә кайтасы килми иде. Хатыннан да бизелгән, балигъ балалар да якты чырайлы түгел. Дөрес, аның сугыштан соңгы елларда гөнаһлары булмады түгел. Хатын сабыр иде. Иренең чыгырдан чыгып йөрүе күңелен җәрәхәтләде. Шуннан ахры, салкынаеп калды. Аны гаепләп булмый, чөнки ул эштә арый, кайткач та эш. Аңарда нинди җылы, нинди дәрт калсын. Шулай хатыннан бизелде. Юк, махмырлау түгел. Махмыр үтә, бизү үтми...

Шаяз, кесәсеннән ярты уч гәрәбәдәй тары ярмасы алып капты да, чәйни-чәйни атлады. Ярма эчемлек исен бик тиз бетерә. Ул идарәгә керде. Бухгалтер бүлмәсе ишеге ачык, анда парторг Зәйнагов белән бухгалтер Сәрия кызып-кызып нидер сөйләшәләр. Сәрия:

—Юк, Мөнир Сөнгатович, мине катнаштырмагыз, мин берни дә белмим,—ди-ди өтәләнә. Шаязны күргәч, тынып калды да, эчкә узды. Аның мөлаем түгәрәк битләрендә гасабилану тимгелләре күзгә чалынды. Зәйнагов, ияге белән ымлап, Шаязны рәис бүлмәсенә дәште. Шаяз аңлады. Зәйнагов Вил Садриевич өстеннән килгән аниномканы тикшерүне оештырып йөри икән. «Көн саен горкомнан чылтыраталар,—дип зарланырга тотынды ул.—Мин болай гына калдырмакчы идем. Авыр йөкне тартып бара, нигә аның тәгәрмәченә таяк тыгарга? Син ничек уйлыйсың?..»—Зәйнагов Шаязның чын уен чамаларга теләи. Рәис белән баш механизатор болай килешеп эшлиләр. Шаяз күндәм, үзсүзле түгел. Ләкин горурлыгы да бар. Югарыга омтылу чалымы сизелә. Кешеләр белән эшли ала, шуңа сәләтле. Димәк, хаклы. Ул укытучылар гаиләсендә үскән. Укытучыларны авылдан-авылга күчергәннәр. Бу авылда әтисе мәктәп завучы булган. Әнисе башлангычта эшләгән. 1949 нчы елны гаилә зур фаҗигага дучар була. Бер төнне әтисен алып китәләр. Моны әтисе Закир алдан сизенә һәм хәлне Шаязга аңлата. Улым, ди, минем белән берәр хәл килеп туса, сине халык дошманы малае

дип укудан куарлар. Әйе, тынлап, сәерсенмә. Ә син болай ит: мин әтидән баш тартам, дип комсомол райкомына гариза яз! Йә, йә, чыраенны сытма, башынны борма. Үзем кушам миннән баш тартырга. Акланырга нигез бар. Курыкма! Бишмунчада укуынны дәвам ит! Нык бул!

Шаяз башта әтисен анламый, сүзләре бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга. Әмма әтисен нахакка гаепләгәч, ул өнсез кала. Берничә төн ана йокы керми. Әнисен дә, аны да мәктәптән читләштерәләр. Менә шул моментта әтисенен сүзләре исенә төшә. Ничек була сон бу? Атадан баш тарту бер әхлакка да сыймый. Әнисе әйтә: намус турында түгел, үзен турында кайгырт, ди. Укымасан, төшеп каласын... Шул чакта Шаяз комсомол райкомына әтисе әйткәнчә гариза язып бара. Шуннан хәлләре бераз җайга керә. Укырга алалар. Сталин үлгәч, әтисен кайтаралар. Ләкин инде тәмам эштән чыккан. Урын өстендә генә ятарлык хәлдә.

Әтисе белән мөнәсәбәт һаман да катлаулы. Арага ниндидер кара күләгә яткан. Кешеләр арасын боза торган барыш күләгәсе. Ләкин кайчак авыр сүзләр ишетергә туры килә... Бер төнне сон гына ашыгыч эш чыкты да (сулдан бик кирәкле запчасть китергәннәр) Шаяз рәиснен өенә барды. Ләкин капканы ачуга Таһия бәйдәге эт кебек ана ташланды. Син ярарга күтәчләнеп йөрисен, үзенне генә кайгыртасын. Карьера өчен әтиеннән баш тартырга да тайчынмыйсын, фәлән-фәсмәтән.

Шаяз чыраена пычрак белән бәргән шикелле хис итте. Таһия усал, мәкерле хатын. Моны беләләр. Шундый холкы белән иренен дә абруен төшерә ул. Бүтәннәрнен гайбәтен чәйнәргә яратканга күрә үзенен дә гайбәтен чәчәләр...

—Мин дә шулай уйлыйм,—диде Шаяз, байтак дәшми торганнан сон. Тулы түгәрәк йөзендә, биек мангаенда, бер-берсенә кушыла язган калын кашларында хәерхаһ хәстәрчәнлек чагылды.—Моны Таһиягә үч итеп язганнар. Бигрәк үзен әби патша итеп тота башлады...—Шаязнын сүзләре дөреслеккә туры килә иде, авылда рәиснен хатынын әби патша дип йөртәләр. Зәйнагов моны белсә дә, раслап ым какмады, эм-м-м, диде дә бетерде. Эчтән уйлады, хатны тикшергәндә алай туры әйтмәс, рәискә каты бәрелмәс, ди иде. Вил алдында Зәйнаговнын үз хәле дә эчне тырный торган: Вил белән дә мөнәсәбәтне кискенләштерү һич ярамый, ә горкомнан исә тикшерегез, дип көн дә чылтыраталар. Вил үтенә: «Тикшереп чиләндермә, җавапны тикшердек, дип язып җибәр»,—дип ялына. «Юк,—ди Зәйнагов,—форма өчен генә тикшерик, авыр сүз ишетмәссен»... «Тикшерүгә куйма, беләм мин нәрсә әйтәселәрен»,—ди Вил каты гына... Әйткәләшеп китәләр... Бергә эшләүче иптәшенне парткомда тикшерү ин авыр хәл. Шул чытырманлы хәлдән ничек чыгарга? Горком ягыннан торсан, Вил үчләнәчәк, ә Вилне араласан, горком кода-кодагыйлык диячәк. Пәрәме аптыраш?

Аноним турында өйдә Вил белән Таһия көн-төн бәхәсләштеләр. Таһиянеке һаман шул: «Моны идарәдә эшләүчеләрдән кемдер язган. Әйе, әйе, Сәрия үзе кул уйнатмагандыр, әмма материалны төгәл ул биргән, ул!»

—Юк,—диде Вил.—Син Сәриядән көнләшәсен. Әлмәткә киткәндә галстугымны ул рәтләгән өчен дә көнләшеп: «Сез күз зинасы кыласыз!»—ди-ди бәйләнәсен. Югары белемле була торып?! Тукта, тукта, Сәриягә зарбы булсын дип моны син яздыргансыңдыр?

—Нәрсә син, әллә шөрепләрен бушый башладымы?!—диде Таһия, пырылдап.—Ятканда коньяк эчмә дип әйтәм мин сина! Әҗәткана, мәткәсен ышыклар өчен хәләл хатынына кара яга! Мин сине иркәләп, син талантлы, даһи зат ди-ди боздым, ахрысы! Эт симерсә, иясенә ябыша. Вәт син, ә?!—Бер ычкынса Таһияне туктатыйм димә. Вил анардан курка иде. Ничек җаена ятарга белмәде... «Мин сине районга барып фаш итәрмен,—дип котырды хатын.—Мин синен нутронны беләм. Анда көтеп кенә торалар...»

Мәгәр Зәйнагов тикшерүне ике яктан да канәгать итәрлек итеп оештырды. Горкомнын да авызын ябарлык булсын, Вилнен дә укасы коелмасын. Мәктәптә Зәйнагов кабинетына кич белән җыелдылар. Бары дүрт-биш кеше.

Мөхетдинов кыска сөйләде. Монда һәр сөйләүченең үз исәбе, үз хәйләсе чагыла. Ул бер сүз әйткән саен рәискә карап ала, сүзе тегенең кәефенә туры киләме, юкмы? Рәиснең чырае гүя барометр. Сүзләрне ничек, кайсы якка үзгәртергә?

—Бу анонимка эш кешесенә яла ягу,—диде ул.—Эшкә аяк чалу. Яхшылык теләүче дип атый үзен, әмма явыз җан икәнен үзе үк фаш итә. Хәлнең бары өске ягын гына күрә. Аскы якны күрми. Явызлыгы комачаулый. Кыскасы, бу явыз затны белергә һәм суд җаваплылыгына тартырга...

—Дөрес! Шулай итәргә!—диештеләр. Рәис киң җилкәләре уртасына зур башын индергән, йөзенә өстенлек яктысы җәелгән. Гүя әйтә: әйдә, лыгырдый бирегез, миңа барыбер...

Вәзыйх сөйләми калу мөмкин булмаганга күрә генә сүз алды. Ул колхозны запчасть, ашлама, комбикормы белән тәэмин итүдә ике төрле гамәл яшәвен әйтте. Планда каралган техника, запчасть һәм башкасын алыйм дисәң, юк, беткән. Ә аста, кибетнең арткы ишегендә барысы да бар. Анда план дип авыз ача алмыйсың, «взятка давай». Чын гамәли хәл шундый. Рәис нишләсен, туры юлдан барып булмый. Бүтән юл эзли. Вил Садриевичка рәхмәт укырга тиешбез, ул юлын таба. Колхозны алдынгы сафта алып бара. Колхоз производствосын алып бару гаять катлаулы. Рәиснең эш характеры шундый, аны бүген хезмәт герое итәргә барча ныклы нигез, дәлил бар. Пожалысты! Һәм шулай ук бүген аңа гаеп тагарлык эшләр дә юк түгел. Экономика шулай корылган. Экономика капкынынннан беркая китә алмыйсың...

—Хак сүз!—диешеп куйдылар. Рәис берни дә белгертмәде, өстәл өстендә бармаклары бер бит кәгазьне бөтерә, сүтә иде. Вәзыйх сизде, аның сүзләре рәискә бик үк ошап җитмәде. Ул Вәзыйхның аңардан бик куркып тормаганын белә. Чөнки Вәзыйх рәиснең күп эшләрен үз җилкәсендә алып бара. Дөресен әйткндә, рәис бик хәйләкәр: барча механизация Шаях Шамкин җилкәсендә, ә бөтен агрономия эшләре Вәзыйхта. Вил Садриевичта гомуми җитәкчелек һәм сәяси стратегия.

Фаяз партияле түгел, Зәйнагов башта ук анонимканы ана күрсәткәнгә күрә тикшерүгә катнаштырды. Аннары Зәйнагов үзе әйтергә курыккан сүзләрне аның авызыннан әйттермәкче. Үзе яхшатлы булып калмакчы. Ә Фаяз туры кеше. Югалтыр нәрсәсе юк. Рәис һәм хатыны Таһиянең үзләрен бариннарча тотулары аның да саруын кайната. Дус кешенең йөзенә бәреп әйтеп булмый бит.

—Ошамаса да, әйтмичә булмый, хатта дөрес сүзләр дә бар,—диде Фаяз маңгай астыннан гына үз алдына карап.—Рәис үзе, хатыны Таһия үзләрен башкалардан өстен тоталар. Таһия һәм Вил Садриевич тирәсендә ялагай-ябышкаклар төркеме. Әйе... Таһия мәктәптә бер укытучыны икенче укытучыга каршы котырта. Үзе яратмаган кешеләрнең балаларына түбән билге куйдыра. Рәиснең колхоз байлыгын унга-сулга таратуы да кешеләрне борчый. Моны Мөхетдинов, Зәйнагов бик яхшы беләләр, ләкин дәшмиләр, әшнәлек өстенлек итә...

—Син ялага ышанасың икән,—дип бүлдерде Вил.

—Юк, ялага түгел, үзем белгәнгә, күргәнгә ышанам,—диде Фаяз, бер дә каушамыйча.

—Сез хәлнең тышкы ягын гына күрәсез шул!—дип, үпкәләгән тавыш белән Вил каршы төште.—Хәлнең эчке ягы да бар. Кечкенә бер шишка-мишкага ярамасаң, ул сиңа запчастьның, ашламаның исен дә иснәтми. Запчасть, комбикорма минем үзем өченмени? Мин аны үзгәртә аламмы?—Вил кулын өметсез селтәп, башын икенче якка борды.

Бераз тын булып торды. Зәйнагов алдан язган беркетмәне алдына куйды да, иптәшләренә күз йөртеп чыкты. Әкрен генә укып китте. Анда бары дүрт-биш җөмлә иде. Рәискә яла ягылган, партия әгъзасын пычраткан өчен хат иясен табарга һәм җәза бирергә!

Парторг Зәйнаговка тикшерү, шелтә эшләрен ничектер ничьяга бетерергә кирәк иде. Һәм ул теләгенә ирешә. Мөнәсәбәтләрне

кискенләштерүдән дә алама нәрсә юк. Рәискә, Таһиягә әйтеләселәр әйтелде. Ара да бозылмады.

Берничә көн үтте. Вил Садриевич көн дә идарәгә килеп наряд, күрсәтмәләр бирә, үзенең йөзе кара янган, каш, маңгай җимерелгән, тырт-пырт кына анда-санда бер сүз әйтеп куя. Кәефе начар, якын килерлек түгел. Эчендә уйлар кайнаганы бер ноктага төбәлеп торуыннан сизелә. Башында уйлар карусельдәй әйләнә-әйләнә шик-шөбһәләре ачыклангандай итә иде. Анонимкадагы мәгълүматларның күбесе бит бары бухгалтер Сәрия Чулаевага гына билгеле иде кебек? Аннан башка Мөхетдинов хәбәрдар иде. Ул серне читкә чыгара торган түгел. Таһия әйтә, бар явызлык шул мыштым Сәриядә ди. Көнчелек белән әйтәме, Сәрияне идарәдән күчермәсән, хезмәт герое булу бервакытта та тәтемәячәк дип ышандырмакчы була...

Уйлый, баш вата торгач, Вил катгый карарга килде: Сәрия Чулаевадан арынырга! Ләкин ничек итеп? Сельпога күчәргә риза булмас микән? Анда ана исәп-хисап эше табылыр иде. Ә андагы бухгалтер керәшен хатынын идарәгә алырга, ә?

Юк, бу план барып чыкмас, сельпо рәисе көнчел, әләкче адәм. Авыштуеш китерергә риза булмас. Хәер, анда Сәриягә эш табылыр иде югыйсә?.. Чулаева эштә ыхтымат түгел, документларны югалткалап башны әйләндерә. Кая куйганын оныта. Әле генә акча белән матавык чыгарды. Игътибарсызлыгы аркасында. Банкта тиешле акчаны кирәгеннән ким биргәннәр. Шуны абайламый кул куйган. Акчасы эш хакына түләргә җитмәгәч кенә алданганын сизде. Еларга, чәчләрен йолкырга тотынды. Тизрәк, комиссия төзеп, тикшердек. Чынлап та, акчаны ким биргәннәр... Шул эш өчен күпме бусага таптарга, әчелешле булырга мәҗбүр ителдем...

Зәйнагов, Мөхетдинов белән сөйләште дә, Чулаеваны эшеннән бушату турында боерык чыгарды. Боерыкта Чулаеваның эшкә салкын каравы, документларны югалтуы әйтелә. КЗОТның 33 нче статьясы: “Не соответствует занимаемой должности” буенча эштән алына.

Боерыкны Сәриягә Мөхетдинов күрсәтте. Хатын кәгазь битен кулына тоткан килеш тораташ катып калды. Шунда ук тын җыйды һәм рәис янына атылды. Боерыкка ышанмады. Ләкин рәис юк иде. Икенче, өченче көннәрне дә күренмәде ул.

Ләкин Сәрия югалып кала торган түгел. Ул ятимлектә үскән. Интернатта тәрбияләнгән. Тормыш ана үги ана кебек бик кырыс, рәхимсез булды. Һаман типкедә яшәү Сәриянең холыгын ныгытты, үҗәтләнергә, үзе өчен тора белү кыюлыгы бирде. Иң якын дип йөргән, сердәш, иптәш кызлары сатты аны. Бергә булырга ният беркеткән, кочышкан, хисләр бүлешкән егете алдап качты. Нәрсәләр генә күрмәде, кичермәде. Барысы да сынау, сабак булды. Интернат аны икееллык бухгалтер-экономистлар мәктәбендә укытты. Сәрияне шушы колхозга билгеләделәр. Колхозларга бухгалтер-экономист вазифасы кертелгән вакыт иде. Арифмометр бирделәр. Әйбәт кенә эшләп китте. Бер карчыктан почмак алды. Ана янкорма эшләтте. Төскә-биткә, буйга-сынга табигать аны кимсетмәгән. Ак кофта, кара юбкасын тезләре турында гына итеп кия. Йөргәндә биле як-якка чайкалуы, тән төсле капроннан таза балтырларының ялтырап калулары ир-ат күзе төшәрлек иде. Бер ирне үзенә каратты. Ләкин килешеп озак яши алмадылар. Ир китте. Сөйләделәр, имеш, Сәрия салкын тәнле, назы юк. Китүенә сәбәп шул, имеш. Гайбәт ни сөйләмәс. Кешеләрнең иң яраткан нәрсәсе гайбәт. Таһия белән Сәрия башта ахириләр булдылар. Йөрештеләр, серләштеләр. Бераздан Таһиянең көнләшүе аркасында тәмам бозылышып, дошманлаштылар.

Сәрия, туры горкомга барып, тиешле кеше янына керде, хәлен сөйләп бирде, суган суы сыгып алды. Үзенең эштән чыгарылуына төпле нигез юклыгын исбатлады.

Күп тә үтмәде Вил Садриевичны горкомның эчке бүлегенә чакырып алдылар. Бүлмәдә ике таза яшь кеше. Берсе мыеклы, икенчесе—күзлекле.

Мыеклысы усал тавышлы иде.

—Нишләп син хатының сүзе белән сотрудникларыңны җәзалыйсың? Үз башың кая?

—Кая дип,—диде Вил, бераз аптыраулы тавыш белән.—Чулаева эшендә ялгышлар җибәрә, понимаете ли! Үземә чабарга туры килә...

—Син үзең бер дә ялгышмыйсыңмы? Вәт коммунист, хатыны юбкасыннан башын чыгармый, ә?—Кара күзлекле дә каты шырпылы иде.

—Чулаева эшкә салкын карый, яңа гына акча чегына ялгыш кул куеп, ун көнлек болгавыр ясады, понимаете ли. Әнә доказательстволар...—Ул портфеленнән кәгазьләр чыгарып, тегеләр алдына куйды. Ләкин алар моңа бөтенләй илтифат итмәделәр.

—Ә бездә контр доказательстволар менә күпме!—Кара күзлекле алдында яткан папканы өстәл өстендә күтәреп куйды.

—Колхоз эшләрен, җәмәгать интересларын постельдә хәл итә! Бу нинди безобразие, ә?—Мыеклының йөзе тартылган, күзләренә ачу, дәһшәт тулган.—Менә коммунист, ә?

—Юк, мин бабник түгел,—диде Вил, үзен кулга алып.—Телисезме, иртәгә ул хатынны аерам? Гаебе сезнең намуста?

—Сделка тәкъдим итәсеңме?! Билетсыз каласың киләме? Икейөзлеләнмә!—Мыеклы кискен-җитди иде.—Моннан соң колхоз эшләрен постельдә мәтәштермә! Килештекме! Ике сөйләшерлек булмасын. Чулаева бүген үк үз эшенә кайтсын!—Тавышы куркыныч-янаулы иде. Вил шактый шүрли калды. Болар белән сүз көрәштермәү хәерле. Болар каршында үзенең чүп икәнен тойды һәм:

—Ярый. Ярый. Сезнеңчә булсын,—дип мыгырданды Вил һәм папкасын үрелеп алды да, портфеленә урнаштырды. Башын якалары эченә батырып, ишеккә таба атлады.

Барысы да шул Таһия аркасында, нәләт суккыры! Яхшылык эшлим дип тырыша бит, ачуым да бер килмәгәе! Номенклатурадан мәтәлүгә дә ул сәбәпче булды. Сугыштан соңгы еллар. Мин—Беренче май райкомында, Таһия—түрә кызы. Яңа гына веттехникум тәмамлап, шунда эшли. Үзе чибәр, тулышып өлгергән. Күкрәкләре ак кофтасын калкытып лепердәп торалар. Аксыл матур йөзеннән, ак кулларыннан, ак киемнәреннән ак нур бөркелә, минсиңайтим! Эш беткәч, шул тылсымнары белән Таһия килеп керә һәм, ишекне бикли дә, тезләр өстенә менеп утыра. Бар төшең ут булып янарга тотына. Аң каядыр югала. Котырган хисләр кодрәте эчендә каласың. Кем чыдар моңа, Өстәвенә кызның ботларында уч төбе кадәр пәрәвез сыман нәрсә генә... Авырга бик тиз узды. Башланды зилзилә. Кай җирең кычыта. Моны көтеп үк торганнар икән. Хатыннан аерылырга һәм Таһия белән кушылырга мәҗбүр иттеләр. Шул чакта чәчемә ак тасмалар сузылды... Биредә эшләү мөмкин түгел иде. Икенче районга күчерделәр. Әмма аерган хатынның энесе өлкәдә "шишка" иде. Йөреп, мине түбән тәгәрәттерде. Беренче әйтте: өстән көчле басым, диде, чара юк, райисполкомга күчеп тор. Гауга тынгач, без сине райкомга алырбыз...

Ләкин Сталин үлгәч, күп үзгәрешләр килеп чыкты. Планнар буталды, вәгъдәләр онытылды. Кайберәүләрнең элеккеге кара эшләре калкып чыга башлады. Вил дә хаталардан хали түгел. Яңа газетаны кулына алганда йөрәге куркудан еш-еш тибәргә тотына иде.

## 4

Көннәр җылыга китте. Кояш ниндидер яшь көч белән үзенең эссе нурларын җәлләми яудыра. Тау битләрендә яшь егетләр мыегы кебек чирәм шытып чыкты. Иген кырлары кыштан арынуга сөенгәндәй киң күкрәк белән сулыш алып яталар. Межа кауданында тургайлар, һавага уктай очып менәләр дә, биеккә элеп куйган вак кыңгырау—шөлдерләр шикелле өзлексез моңлы авазлар коялар. Ишек аллары, урам-тыкрыклар балалар шау-шуы белән яңгырап тора. Качышлы уйныйлар, такмаклары аермачык ишетелә.

*Алатыр, пулатыр,*
*Таң артыннан таң атыр.*
*Чистай чигәнәк,*
*Алабуга бигәнәк.*
*Аларды, муларды,*
*Ялтан, ялпак.*
*Ти-ти, чыпчык,*
*Син кал, бу—чык!*

Кайсынындыр мич артында утырган ана казның чыкканын көтеп ала алмыйча ата казы шәрран яра.

Вәзыйх идарәдән төшеп килә. Башында уйлар кайнаша.

Утын, терлек азыгы авыл кешесенең иң авыр нужасы. Утын, курма әзерләү бик күп көч таләп итә. Ул гына түгел, каян, ничек әзерләргә, Менә шул жанны кисә. Хужалыкка курма бирергә колхозның хәле юк. Үз малларын көчкә-көчкә тукландырып тота. Болын, печәнлекләрдән дә мәхрүм. Утын, агач мәсьәләсендә дә шулай. Шунлыктан каршылыклар чыгып кына тора. Кытлык караклык китереп чыгара, явызлык тудыра. Авылны шәһәрнең жылы квартирында сагынып яшәү генә әйбәт. Син авылда яшәп, эшләп чиенне чыгарып кара...

Вәзыйхка хат килгән иде. Кемнән диген? Курган өлкәсе "Заветы Ильича" колхозының танылган кырчы-агрономы Терентий Мальцевтан, академиктан. Алар күптән языша. Кинәш—табыш итешәләр иде. Терентий Семенович үз колхозы базасында тәжрибә станциясе оештырган. Чүп үләннәрен ничек бетерү, уңышны күтәрү буенча тәжрибәләр алып бара. Чүп үләннәренең иң яманы ул овсюг, солы чүбе. Аны солыча, кара солы дип тә әйтәләр. Язда бик иртә тишелеп чыга да игенне томалап үтерә. Агулар, гербицидлар аны берни эшләтә алмый. Күкрәп үсүен белә. Соң нишләргә? Иң элек овсюгның үзенчәлеген белергә кирәк, дип өйрәтә Терентий Семенович. Овсюг өч стадия белән үрчи. Менә көз көне солычалар туфракка сибелә. Алар өстә калмыйлар, ә туфракны бораулап эчкә керәләр. Кар бетүгә, салкында орлыклар шыта. Игеннән алда үсә башлый. Иген тамырына жайлашып аның сутын суыра һәм корыта, үстерми. Күп тә үтми, овсюгның бөречәләре катылана, орлыклары житешә. Алар жил белән туфрак өстенә сибелеп шактый мәйданны чүплиләр. Бераздан урта ботакчыклардагы бөртекләр өлгерә. Жил аларны тарата. Бик тиз тишелеп чыгалар. Культуралы үсемлеккә тын алырга да әмәл калмый. Овсюг очындагы өченче стадиядәге бөртекләр иген белән бергә жыеп алына. Суктырыла. Бөртекне овсюгтан чистарту өчен ике-өч мәртәбә триер аша уздырырга кирәк. Кыскасы, овсюг бик зур бәла. Иген уңышын бермә-бер киметә ул. Соң нишләргә? Язын жир өлгереп житү белән чәчә башларга ярамый. Дүрт-биш көн сабыр итәргә кирәк. Шул көннәрдә туфрактагы овсюг орлыклары шытып чыга. Яшел энәләр жир өстен каплый. Яшел шытымнар өстенә дискалы культиватор кертәсең. Бу овсюгны "провокацияләү" дип атала. Дискалы культивация овсюг үрентеләрен юкка чыгарып бетерә. Менә шушы профилактик чараны башкарганнан соң, рәхәтләнеп игенне чәчәсең. Ана инде бәла янамый.

Әмма район Авыл хужалыгы идарәсе ашыктыра, бугазга ябыша. Ана план үтәү кирәк. Хәзер әле аны киләсе уңыш кызыксындырмый. Давай, давай, бүген күпме чәчтең? Сводка таләп итә. Шушы кискен ситуациядә дүрт-биш көн чыдарга, вакытны отарга кирәк. (Сүз жаенда әйткәндә, соңарып чәчкән өчен Терентий Семенович ел саен райисполкомнан шелтә ала. Уңыш бүтәннәрдән күп чыккач, көзен шелтәләрен сызалар. Егерме биш ел буе).

Рәис өстәгеләргә бик яраклаша торган кеше, башта Вәзыйхны аңларга теләмәде. Вәзыйх хәйләләп, акыш-макыш китереп, бер-ике участок бодайны үзе теләгәнчә, солычасын "провокацияләп" чәчә алды. Уңыш бик күпкә артык чыкты. Рәискә моның тәме йөгерде. Икенче, өченче елларны рәис чәчү алдыннан дүрт-биш көнне отарга, солычага провокация ясарга булышты. Тәвәккәллек алдамады. Районда иң зур иген уңышы "Ирәч"тә

булды. Рәисне "Москвич" белән бүләкләделәр. Тагын да сөенечлесе: башка колхозлар эш көненә килога якын гына бүлделәр, ә "Ирәч" кило өч йөз бирде. Колхозчыларның эшләү дәрте артты. Урлаулар да кими төште. Байлык әхлаклылыкны ныгыта торган нәрсә. Ул гынамы, "Ирәч" рәисен Хезмәт Герое исеменә әзерлиләр дигән сүзләр йөри башлады.

Быел район идарәсе белән әчелешле булмас өчен Вәзыйх солычадан чистарак басуны бик иртә чәчәргә тиешле бодай, арпа, борчакка әзерләгән иде. Әмма һәр яз кышкы планнарга төзәтмә кертә. Быел колхоз умарталыгын Чияле урманына куялар икән. Бодайга билгеләнгән җиргә соң культура—карабодай һәм кукуруза чәчәргә, диләр. Бодай, арпа бик чүпләнгән басуга туры килә. Овсюгның шытканын көтеп, аннан культивацияләү зарур. Дүрт-биш көн отарга кирәк. Ә район тын алырга бирми: лавай, давай, чәчү турында сводка тапшыр!

Вил Садриевич йөрәк белән авыргалый иде. Теге хәлләрдән соң (анонимка) сәлперәеп калды. Больничный алды. Вәзыйх көне буе кырда тракторчылар янында. Әле бер сводка бирелмәгән. Шулай да Вәзыйхның коерыгына бастылар. Таң белән машина килеп, аны бюрога алып китте. Шаяз РТСта булып калды.

Башка вакытта бюро алдыннан Иван Мөхәммәтович колакка шыпырт кына әйтә торган иде:

—Надыйров, үпкәләмә, синә шелтә бирербез инде, яме,—ди-ди алдан юатып, булачак зарбыга әзерли торган иде. Күңеле әйбәт аның. Гомумән, яхшы кеше ул. Тик йомшаклыгы бар. Бюрода шелтә бирсәләр, бераз вакыт узгач, ул шелтәне алу җаен таба иде. Бүген исә ерактан гына ияк кагып узды да бер бүлмәгә кереп китте. Вәзыйх юньләп күрми дә калды. Яхшы фал түгел иде бу.

Бюроны Икенче секретарь Митрофанов алып бара икән. Иван Мөхәммәтович аның янындарак утыра. Үзен танырлык түгел. Чырае тартылган, карага коелган. Өстәгеләрдән үзенә каты эләккәндер, ахры. Митрофанов зур башын аңа таба борган, нәрсәдер шыпырт кына сөйли. Тегене юаткан шикелле төс белән карый. Митрофанов бик мәһабәт кеше, хәлгә керүчән, итәгатьле. Нефть башлыгы Шмарев белән бик әшнә булган. Поташная Поляна урманчылыгында юртак атлар тоталар, имеш. Шмаревны Казанга Совнархозга алгач, Митрофанов үзе юртак ярышларында катнаша, ди. Өстәлнең ары башында тәэсирле кыяфәтле мөһим генерал. Пенсиядәге бер-ике элеккеге райком төлкеләре.

Иван Мөхәммәтович сөйли башлады. Аның русчасы шома түгел иде. Ул язгы чәчү компаниясенең гаять зур политик әһәмияткә ия булуына, бу хакта Партия пленумында әйтелүенә басым ясады. Халыкара әһәмияте булган язгы чәчү компаниясен өзәргә тырышу ул империалистлар тегерменәнә су кою белән бер, диде. Андый колхозлар бар. Менә "Ирәч" колхозының баш агрономы Надыйров әле бер гектар да чәчмәгән. Моны ничек аңларга? Иптәшнең сәяси наданлыгымы, әллә аңлы рәвештә саботаж ясаумы? Ул үзенең житлекмәгәнлеге белән башкаларга начар үрнәк күрсәтә. Ана ориентир тоталар, ул чәчсә—чәчәләр, ул чәчмәсә, көтеп торалар. Шуның белән колхозлар арасындагы социалистик ярыш гамәлен боза. Мондый эшне артка калдырган практиканы тамыры белән йолкып атарга кирәк. Идарә Надыйровны эшеннән алырга карар чыгарды...

Аның сүзе беткәч, барысы да Надыйровка төбәлделәр. Каушамаска, үзеңне кулга алырга кирәк иде. Ул русча сөйләргә үзен-үзе өйрәтеп байтак газапланган иде. Хәзер югалып калмыйча, һушны җыеп, тыныч кына бер-ике җөмлә әйтергә. Аннары сүз сүзне тартып чыгара ул... "Әз генә соңарып чәчүнең зыяны юк,—диде Вәзыйх.—Бу вакыт эчендә овсюгны дискалы культиватор белән бетерәсең, чистартасың. Овсюгтан чистарган җирдә уңыш бермә-бер артык була. Моны үзебезнең практикадан чыгып әйтә алам. Менә академик Терентий Мальцевның киңәш-рекомендациясе дә шулай. Мин һавадан алып түгел, ә академик күрсәтмәләре белән эш итәм..."

—Быел жәй коры, чәчүне сонарту һәлакәтле булуы мөмкин,—дип бүлдерде аны Иван Мөхәммәтович.

Вәзыйхның менә җавабы әзер иде.

—Мондый очракта академик *(бу сүзне ул юри еш кабатлый)* бөртекне тирәнрәк күмдерергә куша. Тамыры тирән булса, башак эре була, бөртеге дә шуңа нисбәтән... Социалистик ярыш: уйлап карагыз, бер колхозның җире чәчү өчен иртә өлгерә, икенчесенең өлгерми әле. Монда нинди ярыш турында сөйләргә мөмкин. Абсурд бу!

Митрофанов бүлдерде:

—Узган ел район буенча ин күп уңыш кайсы колхозда булды?

—Алар колхозында,—дип, ияге белән Вәзыйхка ымлады Иван Мөхәммәтович.

—Алайса, Надыйров тәҗрибәсенә колак салыргадыр, бәлки?

—Хикмәт аның чәчүне сонартып саботаж ясавында, иптәш Митрофанов.

—Аны үз идарәгездә хәл итегез, нигә горкомга өстерисез? Барыгыз!—Икенче секретарьның тавышы бик тыныч һәм хәерхаһ иде. Иван Мөхәммәтович аптырабрак калды. Әмма зиһенен тиз туплады. Алдында яткан кәгазьләрне тиз-тиз җыеп, папкасына салды. Авыр гына кузгалды да ишеккә юнәлде. Вәзыйх та аның артыннан иярде.

Баскычтан төшкәндә Иван Мөхәммәтовичның кыркулыгы бераз йомшый төшкән сыман иде. Чөнки Митрофанов аның тәнкыйтен хупламады. Академик Мальцев исеме чыккач, калын кашлары җыерылды. Тирәнгә керәсе килмәде, бюродан сөргән кебек чыгарып җибәрде. Шулай да Иван Мөхәммәтович үзенең баш кеше икәнен күрсәтәсе килә. Түрәлек горурлыгы бар бит. Абруй шуңардан тора. Әз генә йомшарсаң, саңга сукмый башлыйлар. Һәркем үз урынын белергә тиеш.

—Надыйров, нигә син һаман идарә тәгәрмәченә таяк тыгасың, ә? Үзең аңлы кеше, понимаете ли?

—Мин таяк тыкмыйм, мул уңыш булсын дип казганам,—диде Вәзыйх, эчтән ачуын тыеп. Кызып китеп, әллә ниләр әйтеп ташлармын дип курка иде.

—Мин уңыш өчен тырышмыйммыни?

—Сезгә план кирәк. Ә безгә уңыш булсын!

—Тәртип шундый: планны вакытында үтәмәсәм, мине урынымнан алып ташлыйлар. Үзең дә беләсең ич. План үтәргә комачаулаучыны мин үз чиратымда алыштырырга тиеш!

—"Кресло" өчен куркасыздыр инде,—Вәзыйх эчтән шүрләп, шулай диде.

—Куркам, яшермим. Ә син мине нишләтә аласың? Нәчәлникнең боерыгы закон. Үтәлергә тиеш! Тәртип шундый. Шулай булмаса, тормыш алга бармас иде.

—Сез хаклы, Иван Мөхәммәтович,—диде Вәзыйх, авыз эченнән генә.—Миңа нишләргә соң?

—Мәмәшев эш табар, мин әйтермен...—Иван Мөхәммәтович сүз беткәнне белгертеп, калын квадрат ияген какты да, ашыгып китеп барды. Вәзыйх баскан урынында аякларын кымшата алмый тора. Ботинка табаннары ябышкан диярсең, аяклары гер таккан шикелле авырайганнар. Эх, миңа нишләргә хәзер, дип ник әйттем. Конкретлаштырмаска кирәк иде. Мәмәшев эш табар дигән сүзе өметне өзгәндәй итте. Әллә Кушаев янына сугылыргамы? Хәер, аны өйдә түгел, диделәр. Митрофановның бюродан чыкканын көтәргәме, ул ни әйтер? Үзегез идарәдә хәл итегез, диде бит. Мондый хәлдә нишләргә соң? Тагы тәгәрмәч казылмага төшеп батты. Тукта, караңгы уйларын ера-ера күңелдә нур чаткысы яктырды: мөнә кимчелекне төзәттеләр, саботажчыны юлдан алдылар, чара күрелде. Бер-ике көн чәчү турында сводка сорамаячаклар. Көннәр коры, кояшлы. Овсюг борын төртеп шытачак. Аннары дискалы культивацияне җибәрәсең... Миңа начар булса булсын, әмма уңыш өчен әйбәт җай лабаса бу!

Юк, бу колхозда күпме генә тырышсаң да, бәяләмәячәкләр. Барча кешеләр, аеруча башлыклар, вакытлы гына эшләүче настроение белән

йөриләр. Мондый натроение рәистән бүтәннәргә күчә, ахрысы. Бу хәлне алар үзләре дә абайламыйлар... Ничек тә биредән ычкынырга кирәк. Менә шунын өчен җай чыкты түгелме соң?.. Ул горкомнын тимер рәшәткәле капкасыннан чыкты да унга борылды. Караса, "Москвич" машинасы янында Шаяз басып тора. Бәйрәмчә киенгән, чырае гадәттәгечә уйчан, сүрән. Вәзыйх ана аптыраган, гаҗәпләнгән сораулы карашын төбәде. Шаяз сизде һәм хәлне бер-ике сүз белән анлатты:

—Теге ни... Без Лениза белән язылышырга барабыз...—Ул төртелеп, Вәзыйхка бу эшне алдан белтертмәгәненә унайсызланып калды. Хәзер менә яшерен эш өстендә тотылган кыяфәттә иде. Вәзыйх исә кәефе бик начар булса да, ясалмарак шатланды. Шаязнын бу эшен күтәреп алды.

—Әһә-ә, шулаймыни?!—диде.—Котлыйм, дустым, чын күнелдән унyш телим!—ди-ди, ике кулын кыса-кыса сайрады.

Шаязнын да чыраена яктылык чыкты.

—Вәзыйх,—диде, үзенең ипле тавышы белән,—язылышканда шаһит була алмассынмы?

Вәзыйх аяк астына карады, эчен теге эштән алу зарбысы көйдерә иде.

—Эх, дустым,—дип авыр сулап уфтанды ул.—Бик срочно идарәгә кайтырга кирәк. Гафу ит! Эх!—диде йөрәк белән кулын селтәп.—Иван Мөхәммәтович мине эштән алды... Ярый, мин таксига чабам...

Вәзыйх кул изәгән кебек итте дә йөгерә-йөгерә китеп барды. Шаяз зиһенен җыя да алмый калды. Нәрсә әйтте ул?

Вәзыйх такси тота алмады. Әлмәт—Азнакай автобусына чак өлгерде. Ул төрле сәбәп, әмәлләр уйлап, үзен тынычландыра башлаган иде. Автобуска утыргач, Шаяз һәм Лениза турында астан ишетелгән хәлләр исенә төште. Ә-ә, әйе, элек трикотаж фабрикасы бухгалтериясендә Лениза белән бергә эшләгән хатын сөйләгән иде. Алар Рәмисә белән заочныйда укыйлар... Хәтер аны бераз тынычландырды, үз хәлен артка чигерде.

Болай була. Лениза эштән бик сон кайта. Түше киткән, өсте-башы да пөхтә түгел. Капрон оегы да сыпылгалаган. Моны күреп әнисенең борчылуы куба. Ни булды? Әмма кыз эндәшми. Карашын яшерә. Әни кеше анын беләге сыдырылып канаган булуын, аягында кара янган эзләр шәйли. Ник дәшмисен? Бик тыкырдаткач, кыз мыгырдап әйтеп куя: берни дә булмады, бәйләнмә зинһар!.. Шулай да әнисе тартыша-тартыша Ленизаны таныш врачына алып бара. Шунда кайбер нәрсәләр ачыклана. Фабрика мөдире кызны көчләргә маташкан... Әллә көчләгән үкме, ачыкланмый кала. Әнисе врач белешмәсе ала. Бу чатаклык Ленизанын абыйсына барып житә. Абый кеше "шишка-мишка", органнарда эшли. Кыз белән сөйләшә. Кыз эшне "шито-крыто" гына йомарга тели. Шау-шу кубарырга кирәкмәс, ди. Мин аннан китәм... Юк, ди, абыйсы ачуланып, җинаятьче җәзасыз калырга тиеш түгел... Хатын-кызларга якын бармаслык итәм мин аны. Сезнен арада ни дә булса булдымы?—М-м, юк ди кыз, нидер әйтеп бетерми. Врач справкасы нигезендә мөдирне арестовать итәләр. "Дело" ачалар. Суд тикшерүчесе эшкә керешә. "Очная ставка" процедурасын үткәрергә тиешле. Лениза: юк, бармыйм, ди. Минем йөргән егетем бар. Без тиздән өйләнешәбез, дип, кыз елый башлый. Юк, барасын, ди абыйсы үҗәтләнеп. Егетенне беләм, ул әйбәт малай. Бу хәлләрне барыбер ишетер. Аны да алып барабыз. Белеп торсын кем белән бәйләнүен. Хатын-кызлар ир-атларны капкынга эләктерүчән булып киттеләр. Шалишь! Мине дә алдадылар...

Лениза абыйсына ялынырга тотына. Зинһар, Шаязга белдермә. Ул шикләнер һәм мине ташлар. Син мине бәхетемнән мәхрүм итмәкче буласынмыни?.. Өч-дүрт көн тарткалашалар. Шаязга сиздермәсәләр дә, Лениза белән абыйсына "очная ставка"га барырга туры килә.

Менә алар милиция частендә. Казенный бүлмә, казенный өстәл, урындыклар. Суд тикшерүчесе лейтенант шунда утыра. Төсе-кыяфәте берни белгерми, таш чырайлы, ала күзле. Озын буйлы сержант арестант мөдирне алып кереп каршыга бастыра. Мөдир ябык-озынча чырайлы, куш иякле, ягымлы гына мөлаем адәм икән. Хатын-кызнын күзе төшмәслек түгел.

Тикшерүче Ленизага күрсәтмәләр бирергә боерды.

—Эльдар Алексеевич эштән алып кала,—дип сөйли Лениза.—Бүлмәсен эчтән бикләп ала. Шоколад конфетлар белән сыйлый башлый. Ул конфетлар эчендә ликер икән. Мин исереп киткән кебек сизәм. Шунда ул кочарга, үбәргә тотына. Эчке киемне салдырырга итеп, аяк араларына кулы белән тыгыла. Күлмәгем, капроннарым ертыла. Ул кызып китә, ныклап тотына, мин бирешмим. Явыз нияте булуын сиздем, ләкин ычкындырмый. Озак тартыштык... Кирәкмәс җиргә кулын сузгач, мин бар көчем белән аны этеп җибәрдем һәм бүлмәдән чыгып чаптым...

Аннан Эльдар Алексеевич күрсәтмә бирә.

—Биредә аңлашылмаучылык килеп чыккан,—ди ул.—Без бит Лениза белән бер-беребезне яратабыз. Бу бит ярату уены. Сез исә төймәдән дөя ясап ятасыз. Лениза, мин сине үлеп яратам бит! Сиңа һаман шуны тукыдым. Син дә миңа битараф түгел идең. Шулай бит? Без шаярдык, көлдек. Ну, мин бераз кайнарланып киткәнмен, яратудан, бары шул гына!

—Ярату, яратмау—ул мораль фактор,—дип каршы төшә тикшерүче,—аларны Закон исәпкә ала алмый. Синең кызны көчләргә маташуың медицина справкасы белән раслана. Көчләргә маташу 117 нче статья нигезендә җәзага тартыла...

—Без бит шаярдык кына, Лениза, шулай бит? Мин сине үптем, син дә мине. Көлдең, чытлыкландың. Мин сине теләвемне белдердем, син дә мине телисеңдер дип уйладым. Хатын-кызның шаяруы, чытлыклануы аның теләккә каршы түгеллеген аңлата түгелмени?—Эльдар Алексеевич Ленизага өмет белән ымсынып төбәлә.

—Син нәчәлник, мин синең кул астында эшләүче, буйсынган кеше,—ди Лениза.—Ничек битараф буласың? Югары зарплаталы урынга күчермәсме дип өметләнгәнмен. Шуңа аның кәефен табарга тырышасың, шаярасың, көләсең, кочуын да кире какмыйсың. Мин дә шундый хәлдә идем...

—Димәк, болар барысы да расчет белән эшләнгән, ә? Юк, син миңа битараф булмадың?!—Эльдар Алексеевич үзенекен каера.

—Синең хатының, балаң бар, нишләп мин андый арбалы-йөкле кешегә өмет сузыйм. Башыма тай типмәгән әле!—Лениза бик тыныч тота үзен. Эльдар Алексеевич баскан урынында кинәт сикереп куя"

—Димәк, бу бик оста оештырылган шантаж! Моның артында кемнәр кулы уйнаганны шәйлим мин...

—Көчләргә маташуың врач справкасы белән раслана, бу факт. Җинаять факты! Җинаять җәза алырга тиеш!—дип кычкыра тикшерүче.

—Юк, бу әшәке шантаж! Мин күрсәтмә бирүдән баш тартам. Сөйләгәннәрем берсе дә дөрес түгел, мәҗбүр итеп сөйләттеләр дип белдерәм...—Эльдар Алексеевичның муен тамырлары буй-буй кызара. Күзләре үзенә тагылган хөкемне кире кага алмау көчсезлеге белән көйриләр. Тикшерүче ым кага, Эльдар Алексеевичны алып чыгып китәләр. Аннары Ленизага төбәлә:

—Мөдир Эльдар Алексеевич мине көчләргә маташты, фәлән-фәлән тән җәрәхәтләре ясады, дип гариза яз. Без аны утыртабыз,—дип боера ана.

Лениза уйланып кала. Абыйсы да: "Яз, нигә куркасың,—ди.—Җинаятькә җәза бирелмичә калырга тиеш түгел!" Лениза озак уйлап утыра. Кинәт туган ачу-хис аны идарә итми шикелле. Аек акылы аны уйлап эшләргә этәрә. Андыйларны, акылы алдан йөри, диләр.

—Юк, язмыйм,—ди, кат-кат уйлап тайпылышсыз карарга килгән кебек.—Аны утыртсалар, минем аркада кеше газап чигә була. Бу хәл минем үземә дә газап китерә. Минем катнашымда кеше җәзалана дип хәтер миңа тукып торачак, яшәвем яшәү булмаячак. Шуңа күрә...

—Үзенә тән җәрәхәте ясаган, горурлыгыңны таптаган кешене гафу итәсеңмени?—Тикшерүченең сораулары катгый.

—Гафу итмим, әмма гариза язмыйм,—ди кыз үз сүзен бирмичә.

—Яз, Лениза, яз!—дип кыстый абыйсы.

—Без ул сволочьны таш капчыкка утыртабыз!—дип кыҗрый тикшерүче.

—Утырта алмыйсың, ул партийный,—дип куя абый кеше.

—Утырмаса, партиядән очачак, менә шул!

—Лениза, ник ул кабахәт бәндәне яклыйсың, жәза бирергә теләмисең, ә? Димәк, сезнең арада нидер булган?—Абыйсы һаман тирәнгә чокый.

—Бары тик кешене бәлалисем, кеше тормышын жимерәсем килми, шул гына,—диде Лениза, бу эш аркасында өстенә өелгән авырлыклардан арына барган төстә.—Каргыштан куркам мин...

—Совет кызы үзе, әллә нинди хорафатларга ышана? Моны ничек аңларга?—Тикшерүче аптыраган чырай белән абый кешегә борылды.

—Хатын-кыз белән ир арасында ни булганын белеп булмый инде, юк,—дип башын селкеде абый кеше, бу өлкәдә каза күргән кыяфәттә.—Соңгы сер бары хатын-кызда кала. Ул яшерсә, чуртым да берни белә алмый...

Шушы вакыйга хәтере аша узгач, Вәзыйхның инрәгән нервысы басыла төште. Бәлагә эләккән кеше бүтәннәр бәласен исенә китереп тынычлана. Вәзыйх: бу Лениза ирләрчә нык характерлы икән, хис буенча йөрми, акыл кушканча эшли, дип, сокланып уйлады. Хәлбуки, Рәмисәдә һәм үзендә әнә шул сыйфатлар житешми иде.

...Бу вакытта Иван Мөхәммәтович телефон аша колхоз рәисләрен тыкырдата иде:

—Тельманны бир әле? Галиәхмәтов, синме? Күпме чәчтең? Планны күпмегә үтәдең, дим мин сиңа?—Иван Мөхәммәтовичның тавышы коры, усал иде, колхоз рәисе каушый язды. Ләкин һәрчак хәйләле белүе алга чыкты.

—Ни бит, Иван Мөхәммәтович, әнә күрше маягыбыздан яна гына кайттым. Надыйров әле башламаган...

—Күрсәтермен мин сиңа Надыйровны!—дип кычкырды Матшин.—Надыйров эшеннән алынды, бернинди маяк юк! Хәзер үк чәчүгә тотын. Кичкә сводка көтәм.

—Маякны сүндердегез алайса?

—Теленә салынма, кичкә план бирмәсәң, мин сине!—Матшин, ачуына төенеп тагы янады да, трубканы ташлады.

—Фрунзены бир әле! Фрунземы? Сальмушев, күпме чәчтең? Әле тотынмадың, ни сәбәп? Махмырлап йөрисеңме?

—Иптәш Матшин, эш болай: кырлар бик овсюглы, туфрак әле чәчәргә өлгермәгән, жылынмаган. Ә-ә, әйе, әнә Надыйров та...

—Надыйров саботаж ясаган өчен арестовать ителде! Сине хәзер айныткычка озатам. Ишетәсеңме?

—Надыйровны арестовать итеп овсюг бетми бит, иптәш Матшин?

—Чәчә башлыйсыңмы-юкмы?!

—Юк, чөнки авыз пеште, уныш булмаячак. Әйдә, Надыйровка анда скучнодыр, иптәшкә мине дә арестовать итегез.

—Туктале, махмыр, син кем белән сөйләшкәнеңне беләсеңме соң?

—Белмим, мин сезне танымадым. Идарәдәндер инде. Матшин авырый дип ишеткән идем...

—Сволочь, хәзер айныткычка алырга машина жибәрәм!—Иван Мөхәммәтович ачуына буылып, трубканы ташлый. Бераз тынычлангач, бүтән колхозларны тыкырдатырга тотына.

Чынлап та бераз вакыттан районнан унбиш чакрым ераклыктагы теге колхозга милиция машинасы килә. Ләкин Сальмушевны беркайдан да таба алмыйча, кире кайтып китә.

Вәзыйх идарәгә бармады, туры өенә төшеп калды. Капкадан керүгә төнгә бәйдән ычкындырылган Муйнак өтәләнә-өтәләнә аның аякларына килеп сарылды. Энгер-менгердә маңгаендагы ак төс сызыклары күз кашы шикелле булып күренә иде.

Түр якта ут юк иде. Рәмисә яткандыр, ул сәгать тугыздан калмый. Йокы капчыгы. Күптән аны минем эшләр кызыксындырмый. Ул бирелән китәргә уй беркетеп куйган. Хәзер эштән алуларын әйтсәң, Рәмисә мыгырдарга тотыныр: син инде "неудачник", кайда гына эшләсәң дә шулай булачак,—

ди-ди безелдәр. Юк, әйтеп тормыйм. Минем "неудачник" булуым эшлексезлектән түгел бит.

Ул юынды да кухняга узды. Суына башлаган бәрәңге, чәй бар иде. Шулар белән тамак ялгады да, үз якларына керде. Анын кыштырдавына Рәмисә караватында уянды да, йокылы тавыш белән:

—Мине борчыма,—дип, икенче ягына әйләнеп ятты. Вәзыйх: "Эһ", дип, диванга урын җәйде һәм шунда сузылды. Уйлары үҗәтләнде: юк, янына барып теләнмәм, мин хәзер женси дәртемне тыярга өйрәнеп киләм. Кайбер хатын-кыз үзенен шул бот ерыгы белән торговать итеп, иргә баш була.

Иртән рәис бүлмәсендә Вил белән Зәйнагов утыра иделәр. Утяганов кулындагы кәгазьне селки-селки сөйли. Утяганов җәйге колхозга билгеләнгән горком вәкиле. Вәзыйх килеп керүгә дә әһәмият итмәде. Тукта, нәрсә ишетә ул.

—Надыйровны эшеннән алу турындагы бу телефонограмма белән һич килешмим,—диде ул.—Бу партия политикасына каршы килә. Ин мөһим чорда чәчү кампаниясенә аяк чалу бу! Моны буллдырмаска минем вәкаләтем бар!—Ул өстәл артында утырган Вил каршына туктады да.—Нигә тындыгыз?!—дип аңа таба килде.—Әллә арт як юешләнә башладымы! Зәйнагов, протокол яз! Беренче янына барам...

—Язуын ансы язармын,—ди-ди, парторг кәгазь-каләм кыштырдата башлады. Анын Утяганов ниятенә каршы түгеллеге чыраена чыккан иде. Шулай да шиген чыгарды:

—Үзен кул куярсынмы соң?—Ул вәкил безне мушкага ала бугай дип шөбһәләнә иде.

—Хәзер. "Беломор" гына алып керим,—дип, Утяганов чыгып китте. Каршыдагы урам аша гына кибеткә кергәне тәрәзәдән күренде.

—Бу махмыр партизан сүзе белән йөрсән...—Вил бөтен кыяфәте белән Утяганов гамәленә каршы икәнен белгертеп, эчтәге бүлмәгә—бухгалтерлар янына юнәлде. Вәзыйх белән сөйләшеп торуны да кирәк тапмады. Киселгән икмәк, янәсе...

Ул арада идарәгә амбарщик килеп керде. Анда арпа симәнәсе буталган, диде. Кайсы бүлектә алыштырып алганы, кайсы үзебезнен орлык? Триерчы кызлар ялгыштырганнар... Амбарщик мондагы хәлләрне белми иде, Вәзыйх та әйтергә уңайсызлана, чөнки урыннан алынды. Шуна Зәйнагов Вәзыйхка төбәлде.

—Вәзыйх, бар, эшендә бул!—диде ул, башын күтәрмичә һаман язуын дәвам итеп.—Урынында каласын...

Амбарщик Вәзыйхка карап алды, Зәйнагов йөзендә ниндидер киеренкелек чалымын сизеп өлгергән иде. Читән арбага утырганда сорады:

—Вәзыйх, әллә бер-бер хәл булдымы?

—Юк, юк, әйдә, ку атынны!—Вәзыйх эчендәге давылны яшерер өчен шаркылдап көлгән булды. Амбарщикнын кызыксынуы төкәнде, бүтән сүз катмады. Атны нык кына юырттырта башлады... Вәзыйх Утяганов сүзләрен миендә эшкәртә иде. Ми монын ихтыярыннан тыш эшли. Горком төзелгәч, кадрларны ныгыту максаты белән обком Утягановны Әлмәткә җибәргән. Ул секретный бүлек мөдире булган. Ләкин түрәләр белән тынышып, эшләп китә алмаган. Аппаратта калдырып, икенче бүлеккә күчергәннәр. Утяганов бераз салып алган чакларда зур учларын як-якка җәеп:

—Алар барысы да минә монда!—дип горкомдагыларга ишарәли. Мин алардан курыкмыйм, алар миннән шүрлиләр, дигән мәгънә анлата иде. Утягановнын бу өянәге һич көтелмәгән нәрсә иде. Шуна күрә ышануы да кыен. Әнә Вил Садриевич аны "сәрхүш партизан" дип җибәрде. Утягановнын: "Астына кәк иттенме әллә, герой алырга көчәнәсен!" дигән сүзләренә Вил хәтәр ачуланды, чыраендагы тамыр-сенерләре бүртеп-бүртеп чыктылар. Битләре көрән төскә керде. Эчендәге ярсуын көчкә тыеп калганы сизелә иде. Утяганов район кешесе. Герой исеменә куйсалар, анын да фикерен сораячаклар. Араны бозарга һич ярамый... Вил Садриевичнын

исә район карарын хуплаганы сизелеп тора. Телефонга тотынуы ясалма каударлану гына булган. "Төптән уйлаганда, икебез өстенә төшәсе шелтәне мин үзем генә күтәрдем. Без үзара кинәшеп, чәчми торырга, "овсюгны провакацияләргә" дигән карарга килдек ләбаса. Бәлане дә бергә күтәрергә тиеш идек. Юк, Вил Садриевич читкә тайпылды. Гомумән, ул эшнең юан башын минем жилкәгә салучан. Мин моны беләм, ләкин эндәшмим. Түзәм. Шулай да нигә кискен хәлләрдә мине саталар? Бүтәннәрдә генә түгел, үземдә дә гаеп бардыр, мөгаен?.."

Ул беренче тапкыр techинститутның тарих бүлегенә кергән иде. Шуннан куылуы ничек булды? Без бүлмәдәш өчәү сөйләшеп утыра идек. Дүртенче бүлмәдәш кайтты. Ул бездән өлкәнрәк фронтовик иде. Әйтте:

—Иван Грозныйның Казанны тар-мар итүе реакционмы, әллә прогрессив булганмы?—диде һәм каршыдагы креват каршына утырды. Минем белән бер савыттан ашап-эчеп йөрүче дустым Хатиатуллин утырган жиреннән калкынып куйды да әйтте:

—Әлбәттә, прогрессив булган!—диде.

Теге фронтовик кинәт аңа таба сузылды:

—Юк, реакцион булган!—дип кычкырды һәм Хатиатуллинның яңагына жинелчә генә тиеп алды. Хатиатуллин минем яклавымны көтте шикелле. Мин дәшмәдем. Ул торды да бүлмәдән чыгып китте... Берничә көннән мине парткомга чакырдылар. Парторг чал чәчле мәһабәт кеше әйтә:

—Син Иван Грозныйның Казанны алуын прогрессив түгел,—дигәнсең. Без мондый антисоветчик студентны институтта тота алмыйбыз...—Үзе өстәл артына баскан килеш минем йөземә төбәлгән.

—Юк,—мин әйтәм,—минем авыздан андый сүз чыкмады...

Парторг кнопкага басты, ян ишектәге пәрдә артыннан Хатиатуллинның күзлек пыяласы ялтырады. Ул барсын да ишетеп торган, билгеле.

—Әйе, прогрессив түгел, дип әйтте,—диде.

Мин:

—Юк, әйтмәдем,—дидем.

Ул:

—Мин синең чыраеннан белдем,—дип куйды.

Парторг:

—Вот что требовалось доказать!—диде шатлангандай.

Икенче көнне мине чыгару турында приказ эленде. Хатиатуллин күренмәде. Кара-каршы очрашудан качты. Кичен тулай торакта кунарга рөхсәт итмәделәр... Һаман әледән-әле бер уй килеп йөрәкне чәнчеде: Хатиатуллин нигә миңа бәла якты икән? Чыраеннан белдем, имеш. Соңыннан ишеттем, Хатиатуллинны стипендиат иткәннәр. Икенче тапкыр мин авыл хужалыгы институтына кердем. Аннан да кудылар, заочный укырга гына рөхсәт иттеләр. Әллә чынлап та, картлар әйтмешли, сөйкемсез сөягем бармы? Инде килеп хәзер Вил Садриевич мине "козел отпущения" ясый. Нинди хикмәт бу? Нindидер дәрәжәгә, унышка ирешү өчен кемсәләр минем өскә бәла өяләр. Түбән төшерәләр. Югарыга менәр өчен кемнәрнедер түбән төшерергә кирәк микәнни?!

Вәзыйх, амбарда эшләрне жайга салып, шул ук ат белән кайтып та житте. Кабинетында парторг Зәйнагов ялгызы гына, нидер укып утыра иде. Йөзе килгән булка төсле тулы чыраен аңа таба борды. Вәзыйхның сораулы житди кыяфәтен чамалап, сүз башлады:

—Урындагы партячейканың өстән төшкән фәрманны кабул итмәскә хакы бар,—диде, нәсихәтле тавыш белән.—Уставта искәрмә бирелгән. Ләкин практикада кулланылмый... Тәвәккәлләп карыйк.—Ул үткен-чагыр күзләре белән Вәзыйхка текәлде, башын алгарак сузды. Аңардан нindидер фикер көтә. Зәйнаговның күз карашы, һәр сүзе сынаулы иде. Вәзыйх моны белә, шуңа жилкәләрен каймылдатып, гаепле елмайды. Ни кылсагыз да сезнең иректә дигән төслерәк...—Вил Садриевич нигәдер кире тора,—дип дәвам итте Зәйнагов, бер сүз дә әйтмәгәч.—Принципмы, ресчетмы? Ул тагы сүз көтеп, Вәзыйхка маңгай астыннан карашын юнәлтте. Ни дә

булса әйтми калып булмый иде. Рәиснең моны "расчет" белән эшләвен белә ул, тик бу хакта белгертергә ярамый. Ишетсә, Вәзыйхка каныгуы мөмкин. Зәйнагов үзе дә рәис белән арасын бер дә кискенләштерми. Чөнки барча материаль байлык рәис кулында. Шулай да рәис белән бик әшнәләшми дә шикелле. Дистанция саклый. Бу исә рәисне бераз шүрләтеп тоту өчен кирәк.

—Белмәссең аныкын,—диде Вәзыйх. Бу мөгаен берни белгерми торган "тайгак" сүз иде. Зәйнагов та анын эчтә әйтелми калган уен чамалады булса кирәк, килешкәндәй итеп, ияген кагып куйды.

Вил Садриевич теге бүлмәдән чыкты. Өстәлдәге әйберләрен җыеп, тартмаларын бикли башлады. Зәйнаговка карап:

—Мин ашыгам, үзегез генә хәл итегез,—диде, качмакчы булып. Зәйнагов ана ачу белән төбәлде:

—Бу бик мөһим мәсьәлә, синнән башка булмый,—диде, үткәрерлек итеп. Вил Садриевич каршы төшмәкче иде, Зәйнагов кулын күтәрде һәм утыр дигән ым ясады. Йөзе бик дәһшәтле һәм властьлы иде. Тагы бер-ике партком әгъзасы кергәч, барып, ишеккә эчтән бик салды да, өстәл артына килеп утырды. Шакмаклы күлмәккә кигән көрән галстугын рәтләде. Җаваплы сүз башлау алдыннан шулай итә иде. Бер-ике җөмлә белән хәлне анлатканнан соң, ул:

—Горкомның вәкаләтле вәкиле Утяганов бу бәладән котылу юлын безгә күрсәтә,—диде, өстәл өстендә яткан кулларын кушыра биреп.—Ул күрсәткәнчә эшләргә кирәк, иптәшләр. Чөнки бик җаваплы, хәлиткеч момент! Хәзер партком һәм идарә исеменнән карар—протокол язабыз. Ул документка барыбыз да имза салырга тиеш...

Имза дигәч, тынып калдылар. Имза кую ул уен-муен түгел.

—Мин кул куймыйм,—дип, Вил Садриевич тынлыкны бозды. Ул өстәлдә ята торган кызгылт-көрән портфеленә беләге белән таянган иде. Таза кызгылт чырае һәм куш керфекле булганлыктан чепи булыбрак күренгән күзләре житди-эшлекле төстә иде.

—Ни өчен? Әйт, әгәр сер булмаса?—диде, Зәйнагов бер дә гаҗәпләнмичә. Гүя ул рәистән моны көткән һәм анын һаман үз карьерасы өчен генә тырышуына эчтән ачуы чыга башлаган шикелле иде.

—Мин район идарәсенә буйсынулы. Беләсез ич...—диде ул, үзен бик хаклы санаган төстә.

—Надыйровны эшеннән аласынмыни? Ә бүген иң җаваплы кыр эшләрен кем майтарыр? Надыйровтан башка бу эшне башкара алучы юк?

—Әнә лабораториядә оператор Кәтиева.

—Юк, ул бутап бетерәчәк!—диде Вәзыйх, Зәйнагов сүзенә куәт өстәгәндәй итеп.

—Ашлама картографиясе бар бит...—Вил Садриевич бирешергә теләми. Ул картографияне Вәзыйх ике-өч ел буе эшләп, гамәлгә быел гына кертә башлаган иде.

—Кая! Ана ул эшне тапшырырга! Што сез? Каш ясыйм дип күз чыгарачак,—диде Зәйнагов, бу хакта бәхәсләшү урынсыз икәнен белгертеп.

—Балага лезвие тотыру белән бер,—диде Мөхетдинов, парторгны яклап. Үзе Вил Садриевичка карады, ачуы килерме? Чөнки ул рәистән шүрли. Бу юлы ничектер кыюланып алды. Әллә хәлнең кайсы якка таба авышуын чамаладымы...

—Вил Садриевич,—дип дәвам итте Зәйнагов.—Икегезнең уртак эш өчен Надыйров җәза алды. Җәзаны уртаклашасы урында син читкә тайпыласын! Бу бит сугыш кырында яралы иптәшенне ташлап китү шикелле. Намусына тимиме, ә?

—Туктале, нишләп минем шәхесне тикшерәсез? Кем права бирде?—Вил Садриевич өстәл артында торып басты. Муен тамырлары бүртеп чыкты, куллары портфель тирәсендә мәшәләнәләр иде. Күз керфекләре керпе энәләрен хәтерләтеп тырпайдылар.

—Юк, без язгы чәчү кебек иң мөһим мәсьәлә хакында сөйләшәбез. Тик

колхоз башлыгының шул эшкә аяк чалуы белән килешмибез,—диде Зәйнагов, тегенең тискәрелеген сындырырга итү үҗәтлеге белән. Парторгның аңа күптән ачуы килеп йөргәнлеләгән беләләр иде.—Син кызма, Вил Садриевич, бирелдә бары яхшылык теләүчеләр генә...

—Мин эшкә аяк чалмыйм,—диде Вил Садриевич, үзен кулга ала төшеп.—Мин бары принцип өчен! Уставны онытып җибәрәсез, иптәш Зәйнагов! Үз өстегезгә бик күпне аласыз!

—Ә син җаваплылыктан арт тайдырасың, качасың!—дип чәнчеде Зәйнагов.—Ә намусың? Кешелегенне җую хисабына принципиаль буласың түгелме?

—Принципиальлек түгел бу,—диде Утяганов.—Җаваплылык алырга курку!—Ул баядан бирле болар нишләрләр икән дип дәшми утыра иде.

—Нинди курку! Өстән төшкән фәрман—мина закон!—дип кычкырып җибәрде Вил Садриевич.—Бездән намус сорамыйлар, көн дә ит, сөт, икмәк таләп итәләр. Айдан төшкән кешеләрчә сөйләшәсез. Кайсыгыз югарыдан килгән боерыкны үтәми кала ала? Йә? Тәкъва булып кыланырга?—Аның тавышы калтыранды. Нервылары тимерчыбык түгел шул.

Тынлык урнашты. Зәйнагов өстәл өстендәге папка-кәгазьләрне өстәлнең бер башыннан икенчесенә әвештереп әвәрә килде. Аның фикер туплаганы кыяфәтенә чыккан иде.

—Әгәр өстән абсурд карар төшерәләр икән, түбән баскычтагылар аны кире кагарга хокуклы,—диде Зәйнагов, сөйләшүгә нокта куярга теләгәндәй.—Хәзер партия шулай куша! Таләп итә! Без агрономны эшеннән алу белән килешмибез! Чөнки чәчү—иң җаваплы чор! Иген уңышын хәл итә торган момент. Партком карары шундый. Надыйров, бар да эшенә тотын! Һәр сәгате кадерле! Бар!..

Барысы да Вәзыйхка карадылар. Ул исә күз кырые белән генә Вил Садриевичны күзләп алды. Нәрсә әйтер? Әмма рәис башын читкә борып, ачуына төелеп утыра. Дәшергә җыенмый кебек. Дәшмәү ризалык билгесе, имеш. Бирелдә дәшмәү хәтәр дошманлашу күренеше инде. Вил Садриевич моны болай гына калдырыр дисеңме? Ул Зәйнаговны урыныннан төшертер. Үз кулы белән моны эшләмәс, ә райондагы яраннары аша эшләтер. Районда аның "выкормышлары" байтак.

Вәзыйхның аяклары тигән җиргә тиде, тимәгән җиргә тимәде. Аңа канатлар куйган кебек булды. Ашау-эчүен дә онытып, идарә артындагы ат абзарында тарантас җикте. Тизрәк Бикәнәйдәге тракторчылар янына барырга кирәк. Алар аркылы культивациягә керешергә тиешләр иде... Тарантас тыкрыкка борылганда, аны ветсанитар Мотыйк туктатты. Фермада бер сыер бозаулый алмый интегә, диде. Ике тәүлек инде. "Әллә, дим, син дә, мин, ревком акт язып хәл итикме?". Аның озынча алсу битен тирән сызыклар ермачлап-ермачлап төшкән. Агарынган иреннәре купшакланып тора. Вәзыйх ни дип тә әйтмәгәч, ул тагы сөйләп китте: "Вил Садриевичка әйтсән, канитель тудыра. Җаваплылыкны өстенә алмый иза чиктерә. Баш ветврачка чылтыратырга куша. Ул килгәнче сыерның әрәм булуы ихтимал. Болай симез генә үзе"..

Аның сүзләре Вәзыйхның бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга. Әле генә булып узган тетрәнүләрдән айный алмый, икенчедән, уйлары белән ул тракторчылар янына ашыга. Аннан, колхоздагы кискен мәсьәләләрне чишкәндә җаваплылыкны үз өстенә алудан туйган иде инде ул...

—Мин ашыгам,—диде Вәзыйх.—Вил Садриевич белән хәл итегез. Мөхетдинов та шунда...—Ул атының дилбегәсен тартты...

Районнан Утягановка хатыны ияреп кайткан иде. Вәзыйхның аны сыйларга дигән нияте барып чыкмады. Ярый, барыбер сыйламый калмас. Вәзыйхка ул кыскача гына аңлатты: Кушаев тегенә чылтыратты.

—Нишләп чәчү кампаниясендә саботаж ясыйсың? Бирелеп эшләгән кешене егасың?—ди. Иван Мөхәммәтович акланырга тотынды: имеш,

Надыйров единоначалиене боза. Колхоз рәисләре мине тынламый, Надыйров сүзенә колак сала...

Кушаев:

—Синең властьны танымыйлар икән, үзенне куя белмисен. Надыйров гаепле түгел...

Иван Мөхәммәтович:

—Кызып кителгән, ялгыш төзәтелер...—ди-ди өтәләнә.

Тагы бер тәүлектән иген чәчеләсе басуга дискалы культивация кереп китте. Хәерле сәгатьтә! Жир өстенә затлы тукымадагы кебек тигез сырлар сузылды. Вәзыйх ызанга тезләнде дә туфракны күзәтә, тикшерә башлады. Әнә ак жепселләр өскә чыгып калганнар. Солыча-овсюг тамырлары. Әһә, менә кара күмер кисәге кебек солычасы өстә ята. Үренте жибәреп маташкан, нәләт! Юк инде, хәзер үрентен корыячак. Тамырлар туфрактан аерылган. Янгыр гына ява күрмәсен. Бүген-иртәгә явым булырга тиеш түгел. Прибор һава басымын түбән күрсәтә... Ул кушучына туфрак алды, аны бармак араларыннан үткәрде. Дым бар әле, шулай да бөртекне әз генә тирәнгәрәк күмдерергә кирәк булыр... Учларын бер-берсенә суккалап какты да, иркен сулап куйды, күккә карады. Күңеленә ниндидер канәгатьлек, күтәренкелек тулды. Көчен, ниятен белән эшләнгән эш тудырган шатлыктан да ләззәтлерәк тагы ни бар?.. Аның күз кырыйлары кычытты, керфекләре чыланды... Тургайлар чурый-чурый, чер-чер килеп сайрыйлар. Күктән тоташ моңлы музыка авазлары коелып тора. Бу исә ашлыкны харап итүче овсюгка реквием шикелле ишетелә. Йөрәккә сары май яккан кебек итә. Монсу да, әзрәк тантаналы да. Жанда канәгатьлек хисе ташый. Әмма шатланырга иртәрәк әле. Ник дисән, эшнең соңы ни булып бетәсе билгесез. Авыл кешесе алдагы өмет һәм билгесезлек арасында кыйналып яши. Күккә ялварып карый. Уңышның язмышын бит күк хәл итә. Райком түгел, ә күк идарәсе.

Шушы жир ничә буын адәм балаларына тормыш биргән, жаннарын саклаган. Бүгенге көнгә хәтле китереп житкергән. Бөек һәм мәрхәмәтле Жир-Ана! Тик адәм балалары бик һавалылар. Үзләрен тудырган, тәрбияләп үстергән Жир-Ананың кадерен белмиләр. Аны бер дә бәяләмиләр. Ана үги итеп карыйлар. Тик Жир-Ана бик сабыр, үз балаларын кызганучан. Ул үзе үстергән балаларның йөрәкләре йомшаруын, намуслары уянуын көтә. Жирнең тормыш тоткасы булуын кайчан аңларлар икән, ди.

## 5

Мәктәптә үз предметы булмаганга, Зөмәрә тарих укытырга мәжбүр иде. Ул моңа авырсынмады, киресенчә, бу эшкә бик кызыксынып керешә. Тарих күп нәрсәләргә күзне ача торган фән ул. Үткән чор, ул вакыттагы вакыйгалар, гыйбрәтле хәлләр. Гореф-гадәт, йолалар. Патшалар, аларның шәхси тормышы, яшәүләре, холык-фигыльләре—барысы да аң-акыл өчен гаять кызыклы.

Кышкы каникулда Укытучыларның белемен күтәрү институты буенча ул Ленинградка тарихчылар семинарына эләкте. Менә кайда белем хәзинәсе! Күренекле профессорлар лекция укый. Берсеннән-берсе ымсындыргыч. Әллә нәрсәләр беләсен. Патша Иван IV-нчене ни өчен Грозный дип атаганнар—шул ачылды. Аның жиде хатыны була. Василиса исемле икенче никахлашмаган хатынын нәрсәгәдер ачуланып, тере килеш диярлек каберга күмдерә. Икенче мәшһүр патша Петр I ниләр генә кыланып бетмәгән. Ышануы авыр, аң кабул итми. Әмма профессор Алексеев булган хәлләрне сөйли. Уйлап чыгарып булмый торган вакыйгаларны... Патша сараенда Мария Гамильтон дигән гүзәл шотландка пәйда була. Ассамблея вакытында Петр аның белән бии. Гүзәлне яратып китә. Ә Мария деньщик Иван Орловны сөя, аңа тугрылыклы. Петрны кире кага, аңа бирелми. Патша хатыны Екатеринаның алтыннарын урлап, Орловка бирә, шуңа Марияне төрле гаепләр тагып, зинданга ябалар, кыйныйлар. Мәгәр Деньщикка булган мәхәббәтеннән баш тартырга мәжбүр итә алмыйлар. Яраннар Марияне

ватанга хыянәт итүдә гаепләп җәзаларга дигән карар чыгара. Процесска Петр үзе дә килә. Кызны кулыннан тотып күперчеккә менгерә. Мария Петр белән танышкандагы ак ефәк күлмәген кигән. Күперчеккә менгәч, Мария Петр алдында реверанс ясый. Патша аның кичерү соравын, ялваруын көтә. Ә Мария тизрәк читкә атлый. Петр кинәт аның кулыннан тартып үзенә якын китерә. Мария йөзендә үзенә карата үтергеч нәфрәт күрә һәм кулын ычкындыра. Петр аңлый: мәхәббәт үлемнән көчлерәк икән... Кыз бик кыю рәвештә башын тумран өстенә куя... Соңыннан барча җыелган халык алдында Петр кызның канлы башын тотып, иреннәреннән үбә һәм башны кунсткамерада сакларга боера... Патшалар җаннары ни теләсә, шуны эшләгәннәр.

Тагы Вера Засулич эше... Петербург шәһәре начальнигы генерал Трепов төрмәдә бер тоткынны кыйната. Шуңа нәфрәтләнеп народница Засулич Трепов кабинетына керә һәм аңа пистолеттан атып яралый. Гаҗәбе шунда, мәхкәмә Засуличны аклый. Кешелек морале ягыннан Треповны хаклы түгел дип таба. Ул чакта демократия булган микәнни сон?..

Кайтуга эш, мәшәкатьләр бугаздан тотып алды. Укыту эшләреннән тыш, тормыш кирәк-яраклары хәстәрләү күп көч, вакыт сорый иде. Аңа күршедәге механизатор егет булышкалый. Хак алмыйм дисә дә, Зөмәрә түләми калмый. Кышлык утынын әрдәнә итеп куйды. Газ баллоннарын алыштырып алып кайта. Радиола антеннасын, кечкенә телевизорны көйли. Яңгырлы караңгы пычрак төннәрдә каршы алырга мәктәпкә килә. Ләкин аның сәрхүшләнгән булуы сизелә иде. Зөмәрә түзмәде, турысын әйтте: "Болай сәрхүш булсаң, минем тирәдә чуалма!" "Мин кыюлык өчен генә",—дип мыгырданды теге. Хәзер ул гадәте кабатланмый шикелле. Шулай да аңа һич тә күңеле ятмый. Нишләргә инде? Үзе болай әйбәт кебек ул. Өйләнгәч кеше йөз сиксән градуска үзгәрә, диләр бит... "Һаман бер карарга килеп булмый. Нидер көтә. Менә-менә бер хәл килеп чыгар да, барысын яхшы якка үзгәртеп җибәрер. Җан сулык-сулык инри. Бәгырьне сава торган билгесезлек бетәр, яшәү тәгаенле эзгә төшәр. Каршылыклар, үз-үзенә, бүтәннәргә ачу-рәнҗүләр кимер. Җан тынычланып калыр... Әмма көткәне килми, һаман бертөрлелек, сүрәнлек. Шул эчне пошыра. Кулына эш алса, төшеп китә. Ямь-тәм калмый... Кияүгә чыгарга кирәк, ахрысы?—дип уйлый кызый. Организмы шуны таләп итә шикелле... Ләкин алга бик күп шик киртәләре килеп баса. Кайчак яшьрәк укытучы хатыннар, ачылып китеп, сөйләшеп алалар:

—Егет башта бик яратам, дип, кызны ашыктыра, өйләнә. Ләкин бишалты айдан суына, борынын җыера. Чөнки кыздан туя башлаган...

—Ир-атның, барысы да шул кавем!

—Бер-берсенә гашыйк булып өйләнешкәннәр иде. Күпмедер вакыт әйбәт кенә яшәделәр. Хәзер Флюра нишләргә белми: ирем миннән туйды, махмырлады, дип хафалана. Ничек ирне үзеннән туймаслык итәргә? Флюра коллективтагы һәр хатыннан шыпырт кына белешеп чыкты. Төрлесе төрлечә җавап бирде. Ир-атны һәрчак сине теләп торырлык итү хатыннарның бик әһәмиятле проблемасы ул.

—Чынлап та ничек ирне синнән бизмәслек, сине тансыклап кына торырлык итәргә? Күп ирләр хатыннары белән үзләрен мәҗбүр итеп, теш кысып түзеп кенә яшиләр бит...

Алар көтмәгәндә очраштылар. Әлмәткә балаларның язгы олимпиадасына укучылар алып килгәннәр иде.

—Язмышмы бу, ялгышмы бу?—диде Фаяз, көлеп, техника йортының фойесында Зөмәрәне күргәч.

—Ниндидер дулкын безне тагы бергә китерде...—дип, Зөмәрә дә көлеп җибәрде. Фаяз кинаяне аңлап җитми кызга төбәлде. Шул ук аксыл, түгәрәк йөз, матур борын, алсу иреннәр. Тик соры күзләрендә моңсулык, күз карашларында ниндидер әчке сызлау шәйләнә иде. Ләкин аларга сөйләшергә бирмәделәр, җитәкчеләр килеп, һәр предметка билгеләнгән бүлмәләргә алып киттеләр. Фаяз биология буенча иде. Зөмәрә тарих-географиядән икән. Бүлмәләре өченче катта булып чыкты.

Занятиеләр сәгать өчләрдә генә тәмамланды. Укучыларны ашханәдән алып кайтып, бер гомуми торак бүлмәләренә урнаштыргач, урамга чыктылар, байтак сөйләшеп йөрделәр. Сүзләр күп җыелган, Фаяз үзенең хәзерге яшәү хәлен бер дә зар кушмый гына сурәтләп бирде. Зөмәрәнең аны җәлләүдән күз кырыйлары юешләнде, кайгы томаны белән өретелде.

—И-и, Фаяз абый,—диде, борчулы рәвештә.—Шәхси тормышың юк инде. Үзгәртергә дә омтылмыйсың. Бераз эгоист булыргадыр бәлки синә?

—Төрлечә уйлап карыйм, бернинди юл тапмыйм, Зөмәрә.

—Шулай төтенсез янып бетәрсеңмени инде?

—Мина шулай язгандыр димәсән...—Фаязның тавышы ачынулы-төшенке иде. Күзләре дә моңсулык күкселлеге белән тулды. Зөмәрә ана күз сирпеп алуга йөрәге сулкылдап куйды. Җәлләү хисе күңелен утлы энә кебек чәнчеп үтте. Фаяз моны сизгән кебек булды, тамагын кыргалады, йодрыгын авызына китереп йөткергәләде. Үзен җәлләтәсе килми, горурлыгына тия иде. Ясалма, көр тавыш белән сөйли башлады:

—Әйткәнем бар, башта ук бәхетем булмады. Мин әниемне белмим. Үги ана таш бәгырьле иде. Әти үлгәч, бөтенләй убырга әйләнде. Сугыштан соңгы өзеклек. Язга таба җан асрата торган бәрәңге дә бетте. Үги әни мине хәер сораныга чыгарга куа. Бик хәтәр ачуланып өйдән куып чыгара да ишекне бикли, кертми. Мин хәер сораныга оялам. Үги әни бер көнне бик каты кыйнады, үзен белештерми, үтерә дип торам. Миргә чыгарга мәҗбүр булдым. Кичтән әзерләнгән иттем дә таң белән торып киттем. Үз авылыбызда йөрергә хурлана идем. Күрше Бишмунчага юнәлдем. Апрель урталары. Төнлә бик нык туңдырган, аяк асты шатыр-шотыр килә, пыяла ватыкларына басып барган шикелле. Чабата табанын ашый гына. Мин чабата табанын юкәгә сүс кушып "тезгән" идем, катыга бирешми, аякка юешне дә үткәрми. Беләсең, Бишмунча зур авыл. Мин өске урам буенча киттем. Бик әз тамызалар. Кайсы берни бирми. Кайсы капкада күренүгә: "Вон!" дип кычкыра. Урамның ары башына житкәнче аяк асты тоташ су булды. Кояш бик каты кыздыра иде. Урам башында туктап, уйланып тордым. Кайту ягына борылдым, каршыдагы йортларга керә-керә киттем. Шунда малайлар очрап, таяклары белән аркага төртә-төртә мине кудылар. Иң хәтәре шунда, кайтсам, авыл кырыендагы чокыр ярган. Ургылып-ургылып ташу ага. Нишләргә, ачудан, үртәлүдән, көчсезлектән елап җибәргәнемне дә сизмәдем. Чокырның теге ягында ферма өйләре. Кешеләр, мине күреп, яр буена килделәр. Мина колга ыргыттылар, шуңа атынып чык, дип кычкыралар. Колганың башын ташуның юл катысы турындагы тар җиренә төртеп карадым. Бер секундта колганы агызып китә. Юк, булмый. Бер ат менүле җайдак, чокырның ерактагы очыннан урап, минем янга килде. Иң элек капчыгымны теге якка томырды. Сизми дә калдым, мине баштан һәм аягымнан эләктерде дә теге яктагыларга:

—Тотыгыз!—дип кычкырды, мине утын пүләне кебек итеп ташу аша ыргытты. Мин йомшак куллар өстенә барып төштем... Миргә бүтән чыкмадым. Ачылган эскерт төпләреннән башак-бөртек җыйдым. Ул елны карабодай бик уңган, җыелмый кар астында калган иде. Шуны җыеп колхозга тапшырасың, алмашка әйбәт он бирәләр, чөнки кар астыннан чыккан ашлык ашап үләләүчеләр булды... Мин исән калдым. Тик тормыш мина гел кире ягы белән торды. Бу хәл мине чыныктырырга, үзем өчен тора белергә өйрәтергә тиеш иде. Әмма юашлык, кыюсызлык... бетми икән...

Бераз тынып бардылар. Зөмәрә сүзне элеккегә әзгә төшерде.

—Врачлардан язу бар дисең бит. Тормыш үзгәртүең—законлы!

—Анысы шулай. Ә хатын газап эчендә ятканда мин ничек нормаль яши алыйм?

—Бүтәннәр яшиләр...

Зөмәрә сүзләренә җавап итеп, Фаяз кулларын як-якка җәеп төшерде. Алар иске Әлмәткә житкәннәр иде. Элеккеге РИК каршындагы бер йортка керделәр. Болдырны узып, бүрәнә янкорманың ишеген ачтылар. Бер тәрәзәле кечкенә бүлмә. Иске генә диван, иске өстәл, ватык-сынык ике

урындык. Ишек катында чаршау, анда кечкенә плитә, Зөмәрә чаршау артында өс-башын алыштырып чыкты. Аяк йөзеннән кыштырдап торган зәнгәр халат кигән иде. Фаяз да плащын, ботинкасын салып түргә узды. Диванга урнаштылар. Сүзләр кирәк булмады. Куллар кулга тоташты. Назга тәмам сусаганнар икән, иреннәр иреннәрдән куба алмый иде. Зөмәрә Фаяз кочагыннан тыны бетә язып, уф! дип тайпылды. Ачылган аякларын халат чабуы белән төргәләде. Фаяз тагы аны үзенә тарта башлаган иде, Зөмәрә аның кулларын кире этеп, телгә килде:

—Теге рус теле укытучысы Фатыйховны хәтерлисенме? Педучилищеда бергә укыдык дигән иден?

—Соң? Соң? Өйләнгән, баласы бар иде?

—Унынчыны бетергән бер кызны алган да җылы якка тайган...

—Чынмы, китсәнә!..—дип, Фаяз бик гаҗәпләнде, житү чәчен артка таба сыпыра-сыпыра, ни әйтергә белмәде. Зиһенен җыйгач, сүзен ялгады.—Бик зур башсызлык эшләгән. Баланы ничек ташларга мөмкин?

—Неужели шундый ярату була икән, ә?—Зөмәрә ияген селкеп торды.—Яратуы өчен хатынын, баласын калдырып киткән бит.

—Юк, бу бәлки, аның өчен котылудыр? Хатын белән яшәү мөмкин булмый башлагач, нишләсен? Бүтәннәр инде моны бары азу дип кенә бәяли.

—Адәм баласы үз башына төшкәч кенә белә. Шунарчы ул бүтәннәрне—кара, үзен ак дип яши...

—Фатыйхов партийный иде, ничек шулай эшләгән? Хәлләр кыскандыр инде. Теге яшь кыз башын әйләндергәндер.—Фаяз гаҗәпләнүдән арына алмый иде.—Түбән төшкән...

—Киресенчә, ул югары күтәрелгән,—диде Зөмәрә, күз чылгые белән Фаязга күлемсерәп.—Җан яраткан кешесе белән кушылган.

—Ә син Фатыйхов кебек эшли алыр иденме, ә?—Зөмәрә кискен соравын йомшарту өчен көлемсерәп карады.

—Юк, мин алай ук кыю түгел шул,—диде Фаяз.—Киртә сикерү, ай-һай, миннән булмас.

—Нигә, нигә, син кемнән ким?—Зөмәрәнең тизрәк нидер беләсе килә иде.

—Кыйналып, авыр тормышта үскән кеше тәртип бозарга курка шул.

—Дөрес әйтмисең, Фаяз абый,—диде Зөмәрә, ничектер оялчанлык белән.—Син просто чынлап яратмыйсыңдыр...

Фаяз башын күтәрде, кызның чыраена, матур муенына сокланган караш белән төбәлде. Зөмәрә үзалдына карап, уйга чумган иде. Нинди сөйкемле, җанны һаман үзенә тартып торган саф, садә ул! Дөнья байлыгы, Бөек тылсым. Яшәтүче һәм һәлак итүче башлангыч!.. Ә Зөмәрәнең миендә нindидер фикерләр көрәшкәнен битләрендә сизелер-сизелмәс беленеп киткән шәүләләрдән чамаларга була иде. Ул башын бормый гына тигез тавыш белән әйтте:

—Фаяз абый, теге вакытта: үз тормышыңны төзү ягын кара, миндә өмет юк, дигән иден. Менә уйладым да тәвәккәлләдем, кияүгә чыгарга булдым.

—Чынлапмы?—Фаяз, үзе дә сизмәстән, кызның беләген тотып алды да, йөзен бормакчы итте. Аның сүзләре дөресме, түгелме икәнен чыраеннан белмәкче булды. Ләкин кызның чырае ачык кына берни дә белгерми иде.

—И, Зөмәрә, сине югалту миңа авыр булачак бит,—диде ул, кимсенүле үртәлеп.—Мин моны теге вакыттан соң аңладым. Әйе, әйе!

—Ә теге вакытта!

—Минем аркада бәхетен таба алмый кала күрмәсен дип җәлләгән идем. Хәзер менә әллә нишләдем, үзем дә аңламыйм.—Фаязның битенә каушау кызыллыгы йөгерде. Зөмәрә ни әйтергә белми, күкрәге өстендә ятучы чәч толымын бармагына бер урый, бер сүтә иде. Озак кына дәшми торганнан соң, кыз нindидер сүрән тавыш белән баягы фикерен дәвам итте:

—Яратып түгел, билгеле,—диде. Тынып торгач өстәде:—Тәҗрибәле хатыннар әйтә: үзен ятканга түгел, сине яраткан кешегә чык, диләр...

—Ничек ул алай?

—Үзең яратып барсаң, киявеңә гел ярап, тәлинкә тотарга туры килә. Шуңа кадерең дә шул тикле генә була. Сине ратканга чыксаң, ирең сине кадерләп тора, ди.

—Монда психология бар,—дип куйды Фаяз, ирен кырыйлары белән елмаеп.—Ә ярату?

—Берничә вакыт бергә яшәгәннән соң, ирләрдә ярату сүрелә, ди. Тагын бераздан бетә, имеш.—Зөмәрәнең иреннәрендә кинаяле елмаю нуры беленде.

—Юк, дөрес түгел,—дип кире какты Фаяз, бу мәсьәләдә белдекле төстә ияк кагып.—Күп ирләр хатыннарына тоткын булалар. Хатын сүзе белән генә йөриләр. Тормышта үзең дә күрәсеңдер...

—Фу, кол ул төче, күңел кайтаргыч инде,—диде Зөмәрә, эчендәге яшермичә.

—Әмма хатыннар шуны бик яраталар,—дип Фаяз елмайды.—Алар власть ләззәтен тоеп кинәнәләр...

Шунда ул кинәт бу сөйләшүнең үзе өчен мәгънәсез булуын абайлады. Ана Зөмәрәне нәрсә беләндер өметләндерергә, кыю адым ясаудан тыелып торырлык итәргә кирәк ләбаса! Ник дигәндә, Зөмәрә аның караңгы тормышында берданбер өмет нуры бит. Анардан мәхрүм калса, нишләр ул? Моның өчен бераз эгоист булып алырга, кыз күңелен үзенә бәйләү өчен хәйләгә барсаң да хилаф булмас, шәт?

Бераз тынып торганнан соң, сүзне икенчегә борып, әйтте:

—Механизаторга чыгам дисең инде, ә? Ә ул эчә торган булса нишләрсең?

—Үзем дә шунардан куркам шул,—диде Зөмәрә, зур шиктән котылу чарасы эзләгәндәй.

—Эчә торган кешене берничек тә төзәтеп булмый. Күпме газапланалар хатыннар?!

—Өйләнешкәч авызыма да алмыйм, дип антлар итә ул?

—Һи-и, сала торган кешенең антына ышанырга ярыймы соң, юләр!

—Кешегә гел ышанмыйча да булмый бит,—Зөмәрә гаепле сыман көлемсерәп куйды. Ул, башын күтәреп, Фаязга карады. Карашлары очраштылар. Фаяз күзләрендә сабыр итеп тор әле, дигән мәгънә укыды ул. Үзенең күз карашы белән ул адымны атлаудан тыелып торырга нитләвен белдерде. Фаяз моны шул мәлдә аңлап алды һәм күңелләнеп китте. Сәгатенә карап алды да: "Вакыт икән!"—ди-ди, урыныннан кузгалды.

—Фаяз абый, кал!—диде Зөмәрә, гади генә берницди арткы исәпсез. Чөнки аның тотанаклы икәнен яхшы белә. "Юк"—диде Фаяз, иркәләгән тавыш белән көлемсерәп.—Иртәгә, яме?—Ул тиз-тиз өстенә киеп, чыгып китте... Тәнендә дәрт дулкыны кузгалуын тойган иде. Бу сукыр көчле дулкынның, сизмәстән, гөнаһ чоңгылына китереп ташлавы мөмкин... Ул шунардан шүрләде. Зөмәрә янынннан качып чыгып киткән кебек тизрәк шылды.

Тәмам күз бәйләнгән икән инде. Биредә иске Әлмәттә урамнар караңгырак, ә өске як—яңа Әлмәттә бик күп гирляндалар балкып тора. Атлаганда башын күтәреп, сул тарафка карады. Урсалы тавында ялгыз факел дөрли иде.

Алар бүтән очраша алмадылар. Зөмәрә группасын иртүк "Дружба" нефть үткәргеченә экскурсиягә алып киткәннәр. "Дружба" тарихи урынга әверелде. Биредән торбалар буенча Европадагы демократик илләргә кара алтын елга булып агып тора. Ә үзебезнең машиналарга бензин, солярка житешми. Авылларга газ уздырылмаган... Әйе, бу сәясәт дигән дәжжал безнең яшәү сүлен суыра, тамырны корыта...

*Дәвамы киләсе санда*



## ОЛУГ ШӘХЕС, БАЙ ИҖАТ

*Бөек шагыйрьләр үлемсез булсалар да, фани дөньяда җисмән озак яшәүләре белән һич кенә дә мәшһүр түгелләр. Хәтта, киресенчә әле: гадәттә, аз гомерләләр алар. "Үлемнәре белән үлемсезлек яулап ала безнең шагыйрьләр". Әдәбиятыбызның горурлыгын тәшкил иткән шагыйрьләрне искә төшерик: Тукай, Бабич, Такташ, Җәлил... Бу дүртәүнең беренче икесенә —27 һәм 25 яшь, Такташка—30, иң "өлкәне"—Җәлилгә—38 яшь... Дөрес, гасыр ахырына таба, сирәк булса да, озаграк яшәгәннәр дә булды. Х. Туфан—80, С. Баттал 90 га кадәр яшәде, ә С. Кудаш 99 яшькә үк җитте. Әмма болар, гомум кагыйдәдән чыгарма. Бәхетебездән дип әйтик, әнә шул чыгармага кергәннәр арасына тагын бер исемне өстәп әйтә алабыз, ул—Мостай Кәрим. Шушы айда аңа 85 яшь тулды.*

*Мостай Кәрим—каһарман шәхес, чын мәгънәсендәге олпат ир зат. Заманының азамат улы буларак, ул һәрвакыт Ил-халык тормышының үзәгендә: яу булса—арсландай батыр сугышчы, тыныч чакта—эш аты—ир-егет булды. Безгә, әлбәттә, аның төп гомер хезмәте—әдәби иҗаты кадерле. Киләчәктә күп буыннар өйрәнерлек гаҗәеп бай һәм күпкырлы иҗат ул.*

*"Европа-Азия" шигырьләр циклы, "Кара сулар" поэмасы, күпсанлы фәлсәфи-лирик шигырьләр аны чорыбызның олуг шагыйре дәрәҗәсенә күтәрсә, "Озын-озак балачак", "Ярлыкау", "Авылым адвокатлары" исемле чәчмә әсәрләре аны проза остасы итеп танытты. Ә "Ай тотылган төндә", "Айгөл иле", "Ташлама утны, Прометей!" кебек пьесалар авторын тамашачылар атаклы драматург итеп бәяләде. М. Кәримнең йөзләгән тәнкыйть, әдәби-публицистик язмаларын укыган кешеләр аны халкының хәким елъязмачысы итеп кабул итте.*

*Мостай Кәрим совет чорындагы илкүләм дәрәҗәле бөтен исемнәрне яулап алган әдип. Ул инде 44 яшендә үк Башкортстанның халык шагыйре иде. Ул—СССР Дәүләт премиясе лауреаты, РСФСРның Станиславский исемендәге һәм Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе лауреаты...*

*Мостай Кәрим Казанга еш килә, Татарстан җәмәгатьчелеге белән һәрчак дустанә мөнәсәбәттә. Зур тантаналар, Тукай, Җәлил кебек шәхесләргә багышланган юбилейларда еш катнашты, онытылмас чыгышлар ясады, мәкалә-хезмәтләр язды, бәйрәмнәребезне уртаклашты, табын күрке булды. Үзенең дә байтак китаплары Казанда басылып чыкты. Татар әдәбиятының бөек әдәбият икәнен яшьли үк танып, аның корифейлары белән горурланып яшәде һәм хәзер дә шул тойгылар белән яши дип беләбез.*

*Без, "Казан утлары" редакциясе хезмәткәрләре, журналның күпмеңләгән укучылары исеменнән яраткан әдибебезне олуг юбилее белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, иҗат уңышлары телибез.*

# Мостай Кәрим

## ТӨРЛЕ ЕЛЛАР ЛИРИКАСЫ

### Таш өстендә гөлләр

Син язасың: "Еллар, юллар буйлап
Ераклашкан саен аралар,
Синең хатлар сүзгә һәм назлауга
Һаман сараная баралар.

Мин уйларның әле дә йә давыллы,
Йә тын диңгезендә йөзәмен;
Аерылышу ахры суытадыр,
Таш итәдер ирләр йөрәген..."

Син әйләнеп кара Уралдагы
Артта калган язгы көннәргә.
Исеңдәме, хәйран кала идең
Таш өстендә үскән гөлләргә.

Эссе нурлар гөлнең сабакларын
Шундый чәнечкеле иттеләр.
Ә чәчкәләр, кояштан күз алмый,
Җәйләр буе хуш ис сиптеләр.

Әгәр утлар янган минем йөрәк
Мөмкин икән ташка әйләнү,
Сиңа булган мәхәббәтем минем
Ташта үскән гөлләр бәйләме.

***

Батыр күрсәм, шул батырлык диган
Тәүге тауга менгем килде.
Дан капкасы күрсәм, шул капканы
Шакып ингем килде.

Кош сайраса, шушы моңлы кошның
Җаны булгым килде.
Илдәге бер иң чибәрнең
Яры булгым килде.

...Өченче көн инде яңгырлар юк,
Исә афәт җиле.
Җирем көя. Тик бер генә явар
Яңгыр булсам иде.

***

Ташлап киттең мине, йөрәгем.
Йөрәксез бар кемгә кирәгем?
Гүя кашы сынган йөзек мин,
Аты егып качкан егет мин...

***

Син киткәндә тулган ай иде,
Яфракларга агач бай иде.

Сагыш кына бөкте шул айны,
Сине көтеп яфрак саргайды.

Минем башым һаман югары,
Үзем кеше генә нибары.

***

Алыс юлга җибәрәләр
Атларның иң яхшысын.
Зур йомышка җибәрәләр
Ирләрнең иң затлысын.
Кунак алдына куялар
Сыйларның иң татлысын,
Бәйрәм көнне яндыралар
Шәмнәрнең иң яктысын.
"Олы юлга чыккан юртак,—
Димә,—бердәнбер генә".
Күпме атлар, күпме атлар
Тиргә батып җир сөрә!
"Зур йомышны йомышлаучы,—
Дисәң,—бердәнбер батыр",
Ә кемнәр соң иген игәр,
Тимер чүкер, таш ватыр?..
Кунак сыен татыганда:
"Бу иң татлы!"—димә син.
Тәелдерер буразнада
Умырып капкан икмәгең.
Бәйрәм шәме үтә якты,
Тик карама бик озак.
Ул тиз сүнә, һәм күзләрең
Күрмәс булырлар азак.
Дан җырлансын яхшы атка,
Затлы иргә, зур шәмгә.
Тик күп җырлансын—дөньяны
Алып барган адәмгә.

***

*Хәсән Туфанга*

Сандугачка нигә буй-сын,
Нәрсәгә аңа бизәк?
Таңда бер сайрап җибәрсә,
Биш кат өзелә үзәк.

Шагыйрьгә нигә чин кирәк,
Нәрсәгә аңа титул?
Патшалар ятлап алырлык
Шигырьләр яза бит ул.

## Шагыйрь шатлыгы

Шатлык сөйләргә шагыйрьгә
Килерме кем дә берәү?
Шатлык канатлы заттан ул—
Кирәкми аңа терәү.

Кешеләр килә шагыйрьгә
Мәшәкать, хәстәр белән,
Керфекләре очындагы
Тулышкан яшьләр белән.

Бар галәмне юатырга
Шагыйрь дә алла түгел.
Телгәләп үк бирер иде—
Йөрәге алма түгел.
Калдырып китәләр аңа
Борчу, әрнүләр, яра...
Шуңа аның карашында
Моңсулык арта бара.

Бер кич шагыйрь күзләреннән
Бөркелеп нурлар акты,
Гүя, Чулпан алдан калкып,
Чылтырап таңнар атты.

Шагыйрь өендә шундый бер
Тамаша булган икән:
Таянып килгән таягын
Бер карт онытып киткән.

***

Хатыннарга ирләр чәчәкләрне
Төнгә каршы бүләк итәләр.
Шуңа күрә шиңгән чәчәк белән
Каршылана байтак иртәләр.

Беркатлырак шаян чакларымда
Ул хисләрне мин дә татыдым,
Чөнки төнгә каршы
Төнге сукыр
Чәчәкләрне мин дә ташыдым.

Таңда торып хәзер кырга китәм,
Чыклар кипмәс борын гөлләрдә;
Кояш чыккан чакта чәчәк куям
Ул баш салган йомшак мендәргә.

## Таулар

Таулар кешеләр шикелле—
Биек булган саен,
Гомерләре бәхәслерәк,
Язмышлары кыен.

Түбәләргә болыт кунса,
Тиз китәргә кунмый;
Түбәләрдә бозлар туңса,
Тиз эрергә туңмый.

Искән чакта җилләр анда
Исә зәһәррәк,
Кыяларны онтап,
Яшен
Уйный хәтәррәк.

Таулар зарланмый. Горурлык
Башларыннан ашкан,—
Кем кояш белән син дә мин
Шул таулардан башка?

Кешеләр таулар шикелле—
Биек булган саен,
Тормышлары бәхәслерәк,
Язмышлары кыен.

Мин дәрәҗәне әйтмимен,—
Ул мәңгелек түгел,
Югарылыкны билгели
Тик югары күңел.

Югары күңел гел генә
Аяз булып тормый,
Сагыш чорный бик еш аны
Яки шикләр тырный.

Заманның давыллары
Аңа килеп суга.
Ә шулай да кояш тәүдә
Аның өчен чыга.

Түмгәккә болыт уралмый,
Кагылмый яшен.
Зарланма. Зарлана күрмә,
Югары кешем!

## Ярлар кала

Бер пароход, төти-төти,
Агыйделдә дулкын яра.
Палубада
Түбәтәйле,
Чабаталы малай бара.
Малай бара. Кая бара,
Капчык асып аркасына?
Белми әле кагылырын
Нинди язмыш капкасына.

Малай уйлый: "Ни гаҗәп бу,
Күзләремме шулай алдар?—
Мин торамын, ага таулар,
Ага ярлар, ага таллар".

Ул малай—мин. Еллар аша
Эндәшәмен: "Әй,—дим,—бала!
Без йөзәбез. Таулар кала,
Ярлар кала, таллар кала..."

Менә хәзер басып торам
Язмышымның корабында,
Чайкала ул тормыш-дәрья
Ярларының арасында.

Мин торамын. Дулкын үтә,
Үтә
Канат кага-кага.
Мин торамын, көннәр ага,
Айлар ага, еллар ага.

Теге малай еллар аша:
"Әй, агай!—дип сөрән сала,—
Без йөзәбез. Көннәр кала,
Айлар кала, еллар кала...

Заман кала. Җавап бир син,
Көч китерми иманыңа,—
Нинди бизәк, нинди куәт
Өстәдең син заманыңа?"

Йөрәгемдә яңгырау тора:
Заманыңа... заманыңа...
Заманыңа...



## Марат Әмирханов

# МӨКӘРРӘМӘ

ПОВЕСТЬ

Кара инде ул Керпе Маһирәсенә, үләрсең кыланышына, жандар биясе шикелле урамны тутырып кайтып килүен генә күр. Бүртенгән чистый, тыгынган инде, тиенсезгә бит. Кулында калын гына төргәге дә бар, монысы бүләктер инде, мөгаен. Бер дә харап икән, солдатка, имеш…

Соңгы елларда Жиңү көне әнә шулай Мөкәррәмә карчыкның иң сөймәгән бәйрәменә әйләнде. Адашкан сарык шикелле хис итә ул үзен бу көнне, кая барып бәрелергә белми йөдәнә. Ник бер искә алучы булсын? Әйтерсең лә, зәхмәткә тарган яман бәндә. Башка корткалар клубта рәхәтләнеп күңел ачып, кәеф-сафа корып йөргәндә, ул буш өендә ялгызы изалана. Югыйсә, сугыш вакытында да, аннан соң да әлеге карчыкларның берсеннән дә ким эшләмәде. Окобын да казыды, салын да агызды, урманын да кисте, мал да карады… Гомере аяк өстендә үтте.

Жиңү көнен халык теге вакытта тыны белән суырып китерердәй булып көтеп алды. Әле дә хәтерендә, казна эшеннән котылып кына кайткан чагы иде, иртән ул пароход тавышына уянып китте. Бәләкәйдән үк таныш, якын тавыш. Түбән Сөннән Агыйделгә кул гына сузмалы. Сөн нәкъ менә аларның авылыннан ике-өч чакрымда Ак елга белән кавыша. Бөркет тавының бер ягында Агыйдел җәйрәп ята, икенче ягында—Сөн биләмәләре.

Авылга башлыча пароход тавышларының иртәнгеләре генә килеп ирешә. Сугыш чорында ул сагышлы, моңсу төсмергә керде. Чөнки фронтка кешеләрне пароход ташый. Көне-төне. Якыннарың белән аерылышу ачысы сеңеп беткән инде ул тавышларга.

9 майда исә пароход тавышы башка бер нәрсә белән дә чагыштырып булмый торган күңел күтәренкелеге алып килде. Мөкәррәмә дә нинди куанычым бар соң әле минем бүген, дип уянды. Торып ишек алдына чыкты. Көн матур иде. Тирә-якны ал нурга манып, Бөркет тавы артыннан кояш күтәрелеп килә. Үлән яфракларында чык бөртекләре жемелдәшә, гүя жиргә асылташ сипкәннәр. Бакча эчендә кошлар сайрый. Тын. Яфрак та селкенми. Җәннәтнең җәннәте.

Мөкәррәмә дөньясын онытып, берара әлеге илаһи манзараны күзәтеп торды. Их, тормышы да шушы ямьле көн сыман якты, нурлы булса иде!

---

Марат ӘМИРХАНОВ (1933) *— прозаик; «Безнең лауреатлар», «Таш һәйкәл», «Чулманның ак йолдызы», «Сөн моңы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

—Кызым, әбәтеңә ике кукәй дә пешереп салдым,—дип, келәт эченнән әнисе Нәгыймә килеп чыкты.—Үзебезнең дә эчне тишмәс дидем, гелән генә хөкүмәт булмас, бирәннән ким җире юк, бар нәрсәне йотарга гына тора.

Мөкәррәмә кычкырып көлеп җибәрде.

—Шушы ике кукәй микәнни инде, әнкәй, минем шатлыгым?

Нәгыймә һични аңламады, башын гына чайкап куйды. Кызлар шулай инде алар, сәке ярыгыннан да кызык табып көләләр. Хәер, ул үзе дә бу араларда өч басасын бер генә басып йөри. Ире Сафагәрәйнең үле хәбәре килгәннән соң бик тә бетерешкән иде. Мөкәррәмәсе кайтып төшкәч, кайгылар чигенеп торгандай булды. Кызы өйдә озак юанмады, эшкә дә чыкты әнә. Өченче көн инде. Бәхетеннән, тәуфыйгыннан гына аерма, ходаем.

Ул арада Мөкәррәмәнең кулдашы Дәүҗия читән аша аваз салды.

—Бәй, апай, тордың да мыни инде?—диде ул гаҗәпләнгәндәй,—мин тагын, читтә сәгатьле эштә генә эшләп йокы туйганчы йомшак караватта аунарга үрәнгәндер инде бу кыдый дип, гоманлаган булам, уятмакчы ием...

—И, Дәүҗикәем, әйттең сүз,—дип кызы өчен тезеп китте Нәгыймә,—ул сәгатьле эш дигәнең анда ярты тәүлеккә сузыла икән ләбаса. Нурмыңны тутырмасаң, кайтармыйча саклап эшләтәләр ди...

—Китчәле, шулаймыни, вәйт бит, ә?!

—Хәдичәләр җитешкәләгәнче кузгалу хәерлерәк булмасмы, Дәүҗияттәй?—дип, Мөкәррәмә әңгәмәне эшлекле юнәлешкә борып җибәрде.

Алар ат чәчкече белән чәчү чәчәләр. Хәдичәләр—ярышташлары. Дәүҗиянең беренчелекне бирәсе килми. Мөкәррәмәнең шуңа ишарәләве.

—Хәдичәләрнең җирән алашасына камыт тигән әле анда,—дип, чабатадай калын иреннәрен җәеп көлде Дәүҗия,—шул кирәк ул иске бистә асрауларына.

—Дәүҗияттәй, син инде бигрәк, бер колхознықылар ич без. Аларның эше безнең җилкәгә төшәчәк ич,—диде Мөкәррәмә.

—Төшмәгәе, аның урынына җыелышларда бедне мактап сүләрләр...

Басуга алар иң беренче булып килеп җиттеләр. Ләкин симәнәче күренми иде әле.

—Ну, ишәм бу малай актыгын, күдемә генә күренсен,—дип сөйләнә-сөйләнә, Дәүҗия үз-үзенә урын таба алмыйча, чәчкеч янында әрле-бирле йөрештерде.

—Дәүҗияттәй, әвен очына әллә флаг кадаганнар инде, күрәсеңме?—дип сорады Мөкәррәмә.

—Бәй, апай, флаг бугай ул...

—Әнә, бер атлы безгә таба чаптырып килә...

—Симәнә турындадыр инде, Әҗәкүлгә генә төшәсе булмаса ярар иде, ходаем...

Ат өстендә, чыннан да, симәнә ташучы Нуретдин иде. Килер-килмәс борын ук Дәүҗия аңа ябырылды.

—Синмени әле бу, имгәк, артыңа кояш төшкәнче йокы бүсәсең. Күпме көтәргә була, әйт, кая симәнәң?

—Симәнә кайгысы юк әле монда...

—Кара, нәмә сүләгән була, директорыгыдга әйтергә дә күп сорамам мин. Бабасыр кергән күек йөрисең...

—Сөенчегә ни бирәсез, бер бик шәп хәбәр әйтәм,—диде Нуретдин Дәүҗиянең тузынуына игътибар итмичә.

—Балта сораганда шөшле тоттырма, җәме, бияләй авыз,—дип сукрануында булды Дәүҗия,—симәнәң кая дип сорыйлар синнән...

—Нинди хәбәр ул, үскәнем, җә, әйт инде,—дип, Мөкәррәмә малайны юмаларга керешә,—күкәй белән сыйлармын үзеңне...

—Ә-ә, кәкре каенга сөямәкче...

—Әллә юк дисеңме?

—Каян белим, мин әүлия түгел лә.

Мөкәррәмә бөрмәкәеннән йомырка алып, малайга сузды.

—Сугыш беткән!—диде Нуретдин,—аның иреннәре, күзләре генә түгел, колакларына кадәр елмая иде.—Кызыл флагны күрмисезмени?

—Әлекәйгенәм, алайса минем Мәгъфүрем дә кайта инде, иеме, апаем?—дип, Дәүҗия балаларча беркатлылык белән сүрелә төште. Әйтерсең лә, барысы да шушы орчык буе малай теләгеннән тора иде.

—Кайта, Дәүҗияттәй, күреп торырсың, бүген-иртәгә кайтып төшәчәк!
—Менә бу сөенеч дисәң дә сөенеч, рәхмәт, энем. Иртәдән бирле күңелем шуңа җилкенгән икән.
Мөкәррәмә малайга соңгы йомыркасын да тоттырды. Ә үзенең йөрәге чәнчеп куйды: их, исән булса, Вәлинур абый да кайтып җитәр иде…
Кыз мөлдерәп чыккан күз яшьләрен күрсәтмәс өчен читкә борылды.
—Тизрәк җыеның, әвен янында җыелыш була, парторг апа ашыктырырга кушты,—дип, Нуретдин сабанчылар тарафына элдертте.
Җиңү хөрмәтенә сыер суеп, бөтен авылны итле шулпа белән сыйладылар бу көнне, чын бәйрәм ясадылар. Хәзер генә ул кешеләрне аералар.

* * *

Сугыш чоры балалары бала килеш җитлекте. Мөкәррәмәнең дә күкрәкләре иртәрәк бүртеп чыкты. Балтырлары тыгызланды, биле нечкәрде. Күреме килде. Башта ул бу үзгәрешләрдән бик нык оялган иде. Кеше күрмәсен-сизмәсен дип күкрәген тастымал белән кысып урап та йөрде әле. Тик өлгергән чия шикелле тулышып барган гәүдәне тастымалга гына төреп бетереп була ди мени? Кызының халәтен иң беренче булып әнисе абайлады. Элек алар мунчаны бергә керәләр иде. Соңгы вакытта Мөкәррәмә төрледән-төрле сәбәп табып, әнисеннән аерылып кала башлады. Әни кеше белмиме соң? Кызының хәйләсен бик тиз тотты. Берсендә сөлге илтү сылтавы белән искәртмәстән өстенә барып кермәсенме!..
Мөкәррәмә, аягүрә баскан килеш, тәненә су бөркеп тора иде. Буй-сыны яшь колынныкы кебек шома, ыспай. Күкрәк алмалары учка керерлек булып тырпайган. Янбашлары да түгәрәкләнеп килә икән. Тиздән, бик тиздән ул бөреләрен чыгарып бетерәчәк, чәчәк атачак.
—Сөбханалла!
Әнисенең авызыннан ычкынган бу сүз гаҗәпләнү идеме, шатлык-куанычмы—белмәссең. Кыз исә кыенсынуыннан сыгылып төште. Үзе куллары белән әле күкрәген, әле төкле урынын каплый…
—Әнкәй, мин оялам,—дип, Мөкәррәмә өстенә сөлге япты.
—И, гомерләр, Ходай бәхетеңнән, тәүфыйгыңнан гына аермасын кызым,—диде Нәгыймә.
Мөкәррәмә ара-тирә кич чыга башлады. Дөрес, клубтагы бию кичәләренә укучыларны кертмиләр. Анда мөгаллимнәрдән кем дә булса сакта тора. Укучылар атнага бер мәртәбә мәктәпкә җыелалар. Пионер җырлары җырлыйлар, шигырьләр сөйлиләр, бииләр. Шулай да, әнисе әйткәндәй, "җиткән кызлар"га бу җим генә аз иде инде. Күңел башка уен тели. Колакларның бөтенләй икенче сүзләрне ишетәсе килә. Әлеге уеннарны уйный, әлеге сүзләрне әйтә торган урын да бар, билгеле. Аныcы аулак өй дип атала. Тик ул тыелган. Мәктәп директоры Сафура апалары кубанка бүреген кырын салып, укучыларны өй борынча диярлек үзе тикшереп йөри. Әмма аулак өй утлары авылның әле бер, әле икенче очында кабынып кына тора.
Көннәрдән бер көнне Мөкәррәмәне дә аулакка чакырдылар. Мәктәптә дружинаның чираттагы сборы бара иде. Хафәзә исемле кыз бер җаен табып колагына пышылдады: "Мөнҗияләрдә аулак өй, сина да дәшергә куштылар."
Мөкәррәмә югалып калды. Чөнки әле аның андый яшерен җирләргә йөргәне юк иде.
—Директор белсә нишләрбез?—диде ул икеләнебрәк.
Хафәзәнең төймә борыны кабарынып шар кыяфәтенә керде.
—Шул "Бүрек"тән куркып торырга әллә бөтенләй, эт өрә, бүре йөри…
Мөкәррәмә биш карышка үсте. Күр, аны зурлар рәтенә кертәләр ләбаса! Чыны да шулай ич инде. Быел җиденчене бетерәчәк. Нигә әле ул кеше йөргән җиргә йөрмәскә тиеш? Әнисе дә ачуланмас, карап-күреп кайтудан кемгә зыян?
—Малайлар да була,—дип өстәде Хафәзә.
Мөкәррәмә аның бу хәбәрен ни өчендер бик тыныч кабул итте, гүя моңа кадәр дә малайлар белән чуалып йөргән.
Мәктәптән барысы да өйләренә таралды. Директор капка янына чыгып, аларны үзе озатып калды. Ләкин бу ике яктан да күз буяу гына иде. Аулагөйчеләр ферма ышыгында качып-посып тордылар да, урамда кеше тынгач, берән-сәрән клуб урамына

таба юнәлделәр. Мөнҗияләр шунда тора, кырыйдан икенче генә йорт.

Барысы җиде-сигез кыз җыйналды. Тиз генә өйне җыештырып чыгардылар, кулларына күз иярми. Шунда ук кучкардагы көмеше яртылаш коелган көзге алдында да бөтерелеп алалар. Тәрәзә пәрдәләренә дә тынгы юк, ачалар да карыйлар, ачалар да карыйлар. Шунда Сәмига исемле кыз йөрәк өзгеч тавыш белән:

—Киләләр!—дип кычкырып җибәрде.

Кызлар утырган-баскан урыннарында тораташ булып каттылар. Өй эче тынып калды.

—Чикерткә тавышына гына алдангансың син,—диде йорт хуҗасы Мөнҗия.

—Юк инде, капка шыгырдавын ишеттем,—дип борсаланды Сәмига.

Шушы урында бәхәс өзелде, чөнки өйалды ишеген дөбертәтергә тотындылар. Кызлар чыр-чу килә, чабышалар, берише тәрәзәгә капланды, берише ишек янына барып басты. Ду-галәмәт.

—Ача күрмәгез, уф, үләм, ача күрмәгез!—дип, Сәмига чытырмандай ишек келәсенә барып ябышты. Мөнҗия аны көч-хәл белән суырып алды. Тегесе корт чаккандай тузынып, мич арасына кереп югалды.

Дөбердәү көчәйде.

—Бераз ялындырыйк әле,—диде Хафәзә исе китми генә. Күрәсең, ул арада иң тәҗрибәлесе иде. Мөкәррәмә тыштан караганда тынычрак күренсә дә, аның да эчендә атлар чабыша иде. Йөрәге лепер-лепер килә, күңеле ашкына, гүя аны менә хәзер чанага салып урлап алып китәчәкләр.

—Әллә ачыйммы соң, кызлар,—диде Мөнҗия,—ишекне ваталар бит инде, әнкәй кайткач кирәкне бирер.

—Ач, ач...

Малайлар шыбырдашып өйгә кереп тулдылар. Туңып-калтыранып беткәннәр. Көндезләрен кояш мәрхәмәтле үзе, инде кар эреп бетте диярлек, озакламас Сөн бозы да кузгалыр. Тик иртә-кич барыбер әле җиһанга Кыш бабай хуҗа.

—Гармун алып килдегезме?—дип сорады Мөнҗия.

—Юк, Салих чирләгән бит,—дип җавап бирде барысы өчен дә Каюм исемле малай.

—И-и, салам торханнар...

—Әйдәң, алайса кара-каршы җыр җырлашып биибез.

Бу тәкъдимне Хафәзә кертте. Һәм үзе үк җыр башлап җибәрде. Җырга маһир ул, тавышы матур, тыны җиңел.

*Ал алъяпкыч челтәрле,*
*Илдә чибәр бетәрме?*
*Илдә чибәрләр бетәрме,*
*Җан сөйгәнгә җитәрме?*

Кушымтаны кызлар дәррәү күтәреп алдылар.

*Челтәр элдем читәнгә,*
*Җилфер-җилфер итәргә...*

Җавап сүзен малайлар җырлап бирергә тиеш иде. Ләкин көзге әтәч тавышлары чыгарып, берсе чана юлыннан, берсе арба юлыннан китте. Хафәзә ярдәмгә килмәсә очлап чыгулары икеле иде.

*Без килмәдек буш китәргә,*
*Килдек алып китәргә...*

Тагын бер җырлы уенга тәвәккәлләп карадылар. Берәүләр такмак әйтте, икенчеләре чиратлашып биеде.

*Аллия, Гөллия,*
*Гөллия белән Бану;*
*Сиңа да, миңа да авыр*
*Гыйшык утында яну...*

Җыр-биюне "Сукыр тәкә" уены алыштырды. Өйнең асты-өскә килде. "Без, без, без идек..." тә бик күңелле булды. Монысында Мөкәррәмә өстен чыкты. Шуңа күрә ул нинди дә булса яңа уен уйлап табарга тиеш иде. Бу аны үсендереп җибәрде.

—Әйдәгез, тапкыр сүз әйтешәбез,—диде ул.

—Ә-ә, акылың алтын икән, башта өйрәт,—диде кемдер.

—Моның бер авырлыгы да юк, без аны ана теле дәресендә гел уйныйбыз. Мин башлыйм, сез тәгәллисез. Аңладыгызмы?

—Сузма инде…
—Кызык,—диде Мөкәррәмә.
Өйдә бер мәлгә тынлык урнашты. Сукыр лапма фителенең чытыр-чытыр янганы да ишетелеп торды хәтта.
—Җә, дәвам итегез, кем батыр?—дип, Мөкәррәмә яндагыларга күз йөртеп чыкты.
—Мызык,—диде Мөнҗия телен күрсәтеп.
Кычкырып көлештеләр.
—Алайса монысын үзем әйтәм,—диде Мөкәррәмә.—Кызык, ике таба сызык.
—Тагын…
—Төлкедән кал…
—Көлкегә бар,—дип элеп алды Сәмига.
—Уен уен белән…
—Җилкә муен белән!
Каюм менә күрдегезме дигәндәй, борынын чөеп, як-ягына каранып алды.
—Уйнавын уйна…
—Эшеңне дә уйла!
Уен кызганда гына Мөнҗия идән уртасына чыгып басты.
—Бу үктәберәтләр уены уйный торган урын түгел,—диде ул кырыс кына,—ә хәзер—йөзек салыш!
Кызлар кулларын чәбәкләде. Чөнки бу иң көтеп алынган уен. Аулак өйнең тажы. Моңа кадәргеләре әлегесенә хәзерлек кенә булып тора. Җиңүче егетләр чиратлашып, өйалдына үзләренә ошаган кызларны чакырып чыгаралар. Шунда кем белән куну мәсьәләсе хәл ителә.
Каюмның Мөкәррәмәгә күзе төшкән булып чыкты. Алар бер класста укыйлар. Шулай да Каюм яшькә зуррак. Бишенче класста ике ел утырган, мәктәпкә дә соңлап кергән булса кирәк. Кыскасы, борынына ис кереп маташа. Нык бәдәнле юантык малай Каюм. Әтисенә ошап, буе гына калыш. Шуңа күрә аны "кәрлә" дип йөртәләр.
—Бүген мин синең белән кунам,—дип, ул Мөкәррәмәгә үзенең карарын җиткерде. Бу кызга ошамады.
—Кунды диярләр кә…
Мөкәррәмәнең авызыннан чак кына кәрлә дигән сүз ычкынмады, соңгы секундта гына тыелып калды.
—Нәмә, башка берәү белән килешеп куйган идеңме әллә?—дип чекерәйде Каюм,—икегезне дә идәнгә салып тунармын, бел.
Хафазә Мөкәррәмәне куну турында алдан ук кисәтеп куйган иде, кыргыйланма, ия чыкмаса адәм мәсхәрәсенә калырсың дигән иде. Шуңа күрә ул хатын-кызларга гына хас кыланчыклык белән килеп туган киеренке хәлне төзәтергә ашыкты.
—Шаяртып сөйләшергә дә ярамый икән кеше белән, укаң коелмыйдыр бит?—дип, читкәрәк борылып басты, үпкәләде, янәсе.
—Шаяртырга мин бала-чага түгел,—диде Каюм.
Бер сәке булып тезелешеп яттылар. Мөкәррәмә бөрешеп катты. Каюм елышыпмы-елыша. Артка таба шуышыр иде, анда да кеше. Теге көнне мунчада әнисе белән егетҗиләп хакында да сүз булган иде. Дөресрәге, әнисе сөйләде, ә ул чөгендер кебек кызарып тыңлады. "Биленнән түбән үзеңә дә ышанма,—дип кисәтте әнисе,—кыз баланың исеме кыл өстендә, кыл өстеннән төшсә—ил өстендә…"
Шул сүзләр хәтеренә төшеп, Мөкәррәмә дерт итеп китте, ачу белән Каюмның кулын читкә этәрде. Ләкин егетнең дә егетләгән итәсе килә, әлбәттә, күкрәк алмаларына таба үрелә. Кунуның бөтен кызыгы шунда ич инде аның, ими капшау. Егет кәмәшләре шуның белән мактана. Тик бөтен каптырмаларына да каптырылган бишмәт изүен алай тиз генә ачып була димени?
Башкалар ничектер, алар әнә шулай сүзсез генә көрәшеп яттылар. Мөкәррәмә кунуның бер фәтвәсен дә тапмады. Юкка гына шапырыналар икән. Кайтырга да вакыт җитәдер, әтәч кычкырганчы ятмассың бит инде кеше өендә, дип уйлады.
Каюм бераз тынып торганнан соң янә һөҗүмгә күчте.
—Бишмәтеңне ычкындыр, ату каптырмаларын умырып төшерәм,—дип янады.
Бу янау чын идеме, әллә куркыту өчен генә әйтелгән идеме, Мөкәррәмә белми калды, берьюлы ишек-тәрәзәләрне шакый башладылар. Кунучылар барысы бергә дәррәү булып сикерешеп тордылар, әйтерсең лә, өсләренә салкын су койдылар.

—Уф, үләм, директор бу кызлар, директор,—дип Сәмига үрле-кырлы сикерә. Мөкәррәмә дә пошаманга төште. Чыннан да, урамда директорның катгый тавышы ишетелде.

—Ачыгыз!

—Ача күрмәгез, уф, үләм,—дип Сәмига тагын ишек келәсенә барып ябышты.

—Сәлимова, сиңа әйтәм, ач!!!

Директорның тавышы тимергә тимер органдай чыңлап ишетелде.

Мөнҗия тәвәккәл кыз икән, шүрләп калмады, үзенчә тозактан котылу әмәлен дә уйлап тапты.

—Мин капылт кына ишекне ачам, ә сез барыгыз бергә тышка ябырылыгыз, һәм шундук таралышып та бетегез,—диде.—Танымый да калырлар.

—Ә үзең?—дип сорады Мөкәррәмә.

—Минем өчен кайгырмагыз, җаен табармын.

Тик эш тәгаенләнгәнчә барып чыкмады. Иң беренче булып ыргылган Сәмига тупсага абынып китте дә, өйалды идәненә мәтәлеп төште. Башкалар утын пүләне шикелле аның өстенә аудылар. Директор аларны берәм-берәм якаларыннан өстерәп торгызды. Аңа янындагы ике укытучы ярдәм итеп торды.

—Хәзер үк өйләрегезгә таралышыгыз, уйнашчылар,—диде ул, сүзләрен теш арасыннан гына сөзеп,—калганы турында иртәгә мәктәптә сөйләшербез.

Сөйләшергә оста иде директор. Кечкенә генә нәрсәдән дә мөгез чыгара белә иде. Мөгез дигәне—сәясәт. Шуның белән балаларны гына түгел, бөтен авыл халкын дер селкетеп тота иде.

Аулагөйчеләргә дә бик нык эләкте. Янына чакырып кызларның эчләрен капшап-капшап чыкты, янәсе, авырга узмаганнармы? Ә Мөнҗиядән:

—Синең көмәнең тулып килә икән ич, кайчан бәбилисең инде?—дип мыскыллап көлде. Мөкәррәмәне дә буш калдырмады. “Имиең дә чыкмаган килеш ничек итеп балаңны имезерсең соң?”—диде авызын кәмшәйтеп.

Мөкәррәмә үксергә тотынды. Шуны гына көткәндәй башкалар да мышык-мышык килә башладылар. Мөнҗия генә бирешмәде. Чәтрәннәп, керфек тә какмыйча, директорга карап тора, күзеннән ник бер тамчы яшь сытылып чыксын? Сәмига исә куркуыннан ул көнне мәктәпкә дә килмәде, юк йомышны бар итеп, күрше авылдагы туганнарына ук китеп барган, имеш.

—Уламагыз!—дип йодрыгын өстәлгә китереп сукты директор. Ул үзе дә дулкынланган иде булса кирәк, кыска итеп кистергән чәчләрен еш-еш сыпыргалап куя, күзлегенә дә тынгы бирми, әледән-әле пыялаларына тын өреп, кульяулыгы белән сөрткәләп-сөрткәләп алгалый.

—Бөтен совет халкы немец-фашист илбасарларына каршы авыр сугыш алып барган ифрат та җаваплы көннәрдә сез өегешеп йөрисез,—диде ул аты-юлы белән.—Бу ясины укылган Гитлерга имән терәү кую дигән сүз, аңлыйсызмы шуны, әнчекләр!

Директор бик озак дулады. Аннан соң һәрберсеннән аңлатма яздырды, бүтән аулак өйләргә йөрмәскә сүз бирдерде. Аның бүлмәсеннән чыгуга Мөнҗия телен күрсәтте.

—Бүрек! Ирдәүкә!

* * *

Кырык икенче елның җәе көйсез кияү кебек кыбырсык булды. Көн рәтләнде дип шатланырга да өлгермисең, кояшны колакка охшаш ак нур камап ала. Бу көнне инде яңгырның куна киләсен көт тә тор. Җилнең дә үзгәрәсе булмады, һаман көн ягыннан исә, ташый гына яңгыр болытларын, кай арада оешып бетәләр дә, кай арада килеп җитәләр. Авылның аксакалы Гыйндулла бабай әйткән, имеш, элҗен үтте—җәй бетте, дигән. Ничек инде июнь уртасында җәй бетсен ди, картны да орышып ташладылар.

Игеннәрнең әле яртысыннан артыгы сабакта утыра. Шуңа күрә кешеләр басуда куна-төнә ята. Уңышны бөртекләп диярдәй җыялар, һәр башак исәптә. Район вәкиле өстән торып эшләтә, әзер ашлыкны минуты-сәгатендә заготзерного озаттыра. Фронттан да бик күңелсез хәбәрләр килә. Немец Иделгә ашкына, Мәскәүне көньяктан боҗрага кысмакчы, ди.

Мөкәррәмәне, гәүдәле булгангадыр, күрәсең, ашлык җилгәрүдән алып, уракка куштылар. Ул ике җәпле агач сәнәк белән машина алдыннан егылып чуалган сабакны торгызып барырга тиеш. Бик авыр эш булып чыкты ул. Куркыныч та. Аяк асты таеп-

таеп китә, шул вакытта ургыч өстенә килеп менәр шикелле тоела. Ә машинист аңа-моңа карап тормый, атларын каулый гына. Алгы аттагы малайга озын чыбыркысы белән сыдырып та алгалый хәтта. Мөкәррәмәне дә онытмый. Бар белгәне: "Әй, йокламаң". Минут саен шул сүзне кабатлый. Тизрәк, ятрәк дип әйтергә теләведер инде. Шунысына да төшенде Мөкәррәмә, әлеге кисәтүне машинист туры мәгънәсендә дә куллана икән. Кичке якта Нуретдин йокымсырап, атыннан егылып төшмәсенме.

—Бер йокыңа баш була алмыйсың, чыбыркы белән сыдырганны көтәсеңме,—дип сукте аны машинист.

Малай да "уйт" дигәндә "туйт" итеп тора торганнардан түгел иде.

—Фронтка киткәч белерсез әле, мин анда кузгә шырпы белән терәү куячакмын,—диде.

—Абзар арты сиңа фронт, әбрәкәй чыпчыгы.

Кәтүк кадәре генә булса да Нуретдин ут борчасыдай тере малай. Атларны бик ярата. Ә йокы йокы инде ул, нишлисең, сорап килми. Күзләр үзеннән-үзе йомыла, сизми дә каласың.

—Бәләкәй бит әле ул, нигә аңа каты бәреләсең?—дип, Мөкәррәмә малайны яклыйсы итте.

—Күп сөйләшмә, урыс колагыңны кисәр,—диде машинист.

—Кемнекен кисәр бит әле,—дип шукланды кыз.

—Телеңә салынма, чикерткә. Жә, кузгалдык.

—Башта мине атландыр әле,—дип күзләрен тасрайтты Нуретдин.

—Бәла, имезлек тә кирәкмиме, жыен бала-чага,—дип сукрана-сукрана машинист малайны күтәреп алып ат сыртына утыртты.

Болытлар оеш-оеш булып укмашып, югарырак күтәрелә башлады, кояшның да елмаюы ешайды. Көн яктырып, мөлаемланып китте. Офык аръягында Торачы урманының иярле атка ошаган сурәте пәйда булды.

"Ходаем, көннәр утырып кына китсә ярар иде!" Халык шушы теләкне теләде.

—Әй, йокламаң! Каула!

Ургыч келтер-келтер килеп эшли. Тешләре тырпайган канатлары белән тук башакларны кочагына тартып кертә дә, өем-өем итеп теземнәргә сала. Ара-тирә атлар пошкырып куя, кемдер шаркылдап көлеп жибәрә, кайсыдыр жыр башлый. Басу гөж килә. Эш көйле барганда үзе бер рәхәт бит ул!

—Әй, йокламаң! Чикерткә сиңа әйтәм!

—Кычкырмасана, китек ирен,—дип ачусыз гына орышып алды Мөкәррәмә.

Көн уртасына Мөкәррәмә телен аркылы тешләр хәлгә житте. Эш эшләп бу кадәре арыганы юк иде әле аның. Табаннары уттай кызыша, нигәдер балтырлары катты, әйтерсең лә, зәнбил ташы тагып куйганнар.

Машинистның үзенә рәхәт, утырып кына йөри, әнә, утыргычы ничек тирбәнә, бишек диярсең. Кылтыкның кылтыгы. Исеме дә әллә нинди төче исем. Вәлинур. Вәлие ярый инде, нуры нәрсәгә? Бөртек тә егетләр исеменә ошамаган.

Мөкәррәмә машинист егетнең гел гаебен генә табарга тырышты. Әле исеме туры килми, әле ирене китек...

Вәлинур дөрестән дә һавалы егет. Ул үзен авылда иң чибәр егет дип саный. Чыны да шулай. Яшьләр арасында төскә-биткә, буй-сынга аңа житкәннәр юк диярлек. Чәчләре шомырттай кап-кара, кашлары кыйгач, күзләре янып тора. Чибәрлеге өстенә, искиткеч уңган, эшлекле, житез. Кеше берне күтәргәндә ул икене күтәрә, кеше берне ураганда ул икене урый. Үзен машиналы эшләрдә генә эшләтәләр. Башта атлы чапкыч белән печән чапты, урып-жыю вакыты житкәч, ургычка утырды. Колхоз рәисе дә, бригадир да аркасыннан гына кагып торалар. Әнисе Сәгыйдә икенче яктан үсендерә. Улының кесәсенә тәмәкесенә кадәр үзе юнәтеп салып тора. Кием-салымын да карый. Иреннән ул хәлле калды.

Мөкәррәмә әбәтне көч-хәл белән генә житкерде. Атларны тугарута, елга буена йөгерде. Кызлар белән жыелышып, чыркылдаша-чыркылдаша су коендылар. Арыган тәнгә моннан да зуррак рәхәтлекнең булуы мөмкинме соң? Шөкер, көне дә утырып киткәнгә ошап тора. Күк зәңгәрләнеп китте, офык тәмам ачылды. Башкорт ягындагы әрәмәлекләр дә аерым ачык күренә башлады.

—Кызлар, сезне әбәткә көтәләр!—дип кычкырды кемдер.

Уттай эш өстендә озын-озак юанып торып була димени, йөгерешеп судан

чыктылар. Тик киенә алмыйча гына азапландылар. Шук малайлар аларның күлмәкләрен бәйләп ташлаганнар иде. Озак кына мәшәкатьләнергә, төеннәрен теш белән чишәргә туры килде.

—Каз боты тәмле булдымы?—дип көлде Нуретдин Вәлинурга күз кыса-кыса.

—Аттан мәтәлеп төшкәнеңне бел, йокы чүлмәге,—диде Мөкәррәмә,—кулыңны кыскартырга да күп сорамам.

Вәлинур, әле генә күргәндәй, кызга текәлеп карап торды да:

—Кардле, кай арада буй җиткердең соң әле син, чикерткә?—дип сорап куйды.

Мөкәррәмәнең әлеге сүзләргә кәефе килсә дә, ачылып китмәде, чөнки ачуы басылып җитмәгән иде. Шулай да җавапсыз калмады.

—Мин чикерткә булсам, син китек ирен,—диде.

Вәлинурның иренендәге бу җөй—шуклык бәласе. Бала вакытта колхоз бәрәңгесен алганда уйнашып-шаярышып киттеләр дә, Вәлинурның иренәнә бер малайның көрәге тиеп китте. Ул аны ямьсезләми, киресенчә, ир-егетләргә генә хас ниндидер кырыслык, тәвәккәллек биреп тора. Мөкәррәмәнең дә күзе иң беренче шуңа төште.

Егет аның кушамат тагуын килештермәде.

—Минем ирендә эшең булмасын,—диде.—Атларны бергәләп эчерегез, мин бәләкәй генә хәл алып торам,—дип яннарыннан китеп тә барды.

Мөкәррәмәнең тагын ачуы кабарды: каян килгән алланың кашка тәкәсе, аның, әнә, бармак аралары кабарып чыккан, бу җәрәхәтләре белән ничек эшләр дип уйлый икән? Хәл ала, имеш. Иртәгә бу якка борылып та карамаячак ул, колхозда башка эш тә бетмәгәндер әле, кеше ялчысы булып йөрергә монда әллә теге...

Урган җирне үлчәргә килгән бригадирга да шул хакта әйтте, мине моннан алыгыз, диде, алай да машинист белән тынышмыйбыз димәде, аңа сүз тигезмәде. Тегесе: "Синнән дә чырышрак кызларым юк бит, гөлкәем, анда көлтә бәйләүче олы хатыннарны куеп булмый ич инде",—дип ялынса да, Мөкәррәмә аяк терәп киреләнде. Бригадирның да сүзен аста калдырасы килми.

—Ярар, иртәгә хәл итәрбез,—диде.

Ә иртәгәсен бер хәвефле вакыйга көтеп торган икән. Һәрвакыттагыча, кояш чыкканда Вәлинур утарда иде инде. Атларны ул барында алып кайттылар. Күзләрен уа-уа Нуретдин да өстерәлеп килеп җитте.

—Мин Кара алашаны йөгәнлим, син Мортаза биясе белән "Бүләк"не тот,—диде Вәлинур аңа.

—Ә чикерткә?—диде малай елардай булып. Аның "Бүләк"кә атланып басуга егетләнеп кенә барасы, башкаларның күзләрен кыздырасы килгән иде. Ә хәзер менә ат тагып бар. Кичтән үк планлаштырып куйган иде югыйсә...

—Сикерде чикерткә,—диде Вәлинур,—әллә шуңа сөмсерең коелдымы?

—Юк ла,—диде Нуретдин,—гарык инде ул кыз аламаларыннан.

—Ә-ә, беләм, Кара алашага өметеңне сузасың инде син. Әйдә, ярар, миннән булсын яхшылык, тот бүген Кара алашаны.

Монысы малайның хыялына да кермәгән бәхет иде. Чөнки Вәлинур бу атын җаныннан да якынрак күрә. Кулыннан килсә, өстеннән кош та очырмас иде. Чыннан да, кеше акыллары бар анда. Бервакытта да дилбегә кактырмас. Көче дә, солы да җитәрлек. Нуретдинга бигрәк тә аның килеш-килбәте ошый. Озын аяклы, киң күкрәкле бик матур ат ул Кара алаша. Юырта башласа, чабыш атларың бер якта торсын мәгәр.

Малайның табаннары гына ялтырап калды. Тик бер-ике минут үттеме-юкмы, көтү эченнән аның шомлы тавышы ишетелде.

—Вәлинур абый, Вәлинур абый...

Бу орчык башына тагын ни булды икән инде, дип йөзен чытты Вәлинур, үлеш бу бала-чага белән.

Нуретдин Кара алашаның күкрәгенә ятып күз яшен түгә иде. Вәлинурның йөрәге жу итеп китте.

—Нәрсә бар, ник елыйсың?—дип сорады ул.

—Кара алашаны суйганнар...

—Ни сөйлисең син, үләт, ат яныңда лабаса!

—Әнә, кара, крис ясаганнар...

Вәлинур малайны читкә этеп җибәрде дә атны күзеннән кичерде. Кара алашаның камытлыгын үткен пәке белән тәре рәвешендә яргалаганнар иде. "Күрсәтәм әле мин

сезгә, кара еланнар, күрмәгәнегезне",—дип йодрыкларын кысты егет. Чөнки Кара алашаны икенче тапкыр урлары иде инде. Узган көз сабан сөргәндә дә шундый хәл булган иде. Айга якын җигәргә ярамады. Милиция дә эзләп карады бу кансыз бәндәне, таба алмады. Немец шпионы түгелме икән дип тә юрап карадылар. Ләкин Вәлинур үзе ишеләргә сылтый. "Синә атларның әйбәтен бирәләр, сине яклыйлар, шуна күрә сутыең күп чыга",—дип, күзенә дә бәреп әйткәләделәр. Алдынгы булу өчен яхшы ат янына тырышлык, осталык кирәклеген аңларга теләмиләр. Бу, мөгаен, чебен Сәхи кулыдыр. Бик астыртын малай, кулак калдыгы. Әтисен дә төрмәдән сугыш кына коткарып калды бит. Хәйләкәр, артыннан эз калдырмый. Кулыннан тотмагач, син дип әйтеп булмый.

Монысында да шаулаштылар да, тындылар. Сорау алулар бернинди нәтиҗә бирмәде.

Мөкәррәмә бу хәбәрне ишеткәч, үзенә-үзе урын таба алмыйча йөрде. Үпкәләрен онытып, бригадирдан шул эшенә кире кайтаруын сорады. Тик көннәр рәтләнеп китү сәбәпле, ургычка өстәмә кеше куюның кирәге беткән иде инде. Шулай да Вәлинур белән Мөкәррәмәнең юллары янә кисеште. Егетне, күп тә үтми завхоз итеп куйдылар. Мөкәррәмә амбарда ашлык киптерүдә эшли иде. Алар өч хатын-кыз. Сушилкага үзләре яга, ашлыкны үзләре кертә, үзләре җыя, үзләре үк кипкән бөртекне капчыкларга тутыра. Олауларны да дәүләткә шуннан озаталар. Тәүлек буе ыгы-зыгы тынмый. Бер-берсенә салгалашмыйча тату гына эшләп яталар иде. Ләкин яңа житәкче себеркене янартты, үзенчә себерә башлады. Элеккеге завхоз аларга хәзинәсеннән аз-маз өлеш чыгаргалый иде. Балы-мае дигәндәй, балалы хатыннарга ярап куя иде. Ә амбарда, сушилкадагылардан кала, күпчелек балалы хатыннар көч түгә.

—Кызлар, нәфсегезгә булышып, кесәгезгә бодай сала күрмәгез, кесәгә салган нәрсә бурлык санала, әз-мәз генә сөт шешәләрегезне файдаланыгыз,—дип завхоз үзе өйрәткәли иде. Сөт шешәләрендәге бодай нигә бурлык саналмагандыр, анысы аңлаешсыз калды.

Вәлинур боларның барысына да чик куйды. Әбәт вакытында җыеп әйтте:

—Мин сезнең төрмәдә утыруыгызны теләмим, колхозда болай да кеше житешми,—диде. Хатыннар өнсез калды.

—Нәмә, кеше житешсә, безне өтермәгә тыгар идеңме әллә?—дип кадалды аңа арадан бер кыюрагы.

Вәлинур әйткән сүзенә кыенсынмады да, гафу да үтенмәде. "Мине тентергә этәрмәгез",—диде дә китеп барды. Бәлкем, аның үзен дә кисәткән булганнардыр, чөнки күрше авылда берничә кешене ашлык белән тотканнар, имеш. Ачык суд ясаганнар. Сигезәр ел биргәннәр, ди. Шөкер, әлегә Түбән Сөнгә андый бәла-казаның килгәне юк.

Яңа завхозның усал дигән даны таралды. Мөкәррәмә исә аны бөтенләй күрмәмешкә салынып йөри хәзер. Ник дисәң, беренче көнне үк ул аңа бар халык алдында "Чикерткә" дип дәште. И, оялды да инде, җир ярыгына төшеп качардай булды. Чистый бала-чага итте, санга сукмаган була. Алай бик масаеп йөрсә, ирене икенче яктан да кителеп төшәр әле.

Мөкәррәмә гарьлегеннән ташландык келәт эченә кереп туйганчы елады. Кулдашы Кәшифә аны шуннан эзләп тапты.

—Бәрәкалла—бәрән сыйрагы, гашыйк булгансың ич син, кызый,—дип озак кына Мөкәррәмәнең чәчләреннән сыйпап торды.—Үзебез дә шулай йөрдек инде, сеңелкәем, алар өчен яшь түгәсе түгел дә бит, түктерәләр шул имансызлар. Гыйрфан абзаң, исән булгыры, башта эре-эре генә атлап китештергән булып караган иде дә, үзенә дә йоктырдым чиремне. Тотам да калмый исәркәем, тизрәк өйләнешик инде дип, бер алдыма, ун артыма төшә башлады...

Кәшифә узган мәхәббәт кыйссаларын хәтерендә яңартып, хыял канатларында тибрәлеп алды. Мөкәррәмәне дә онытмады, кисәтеп әйтте:

—Күңелеңә авыр алма, сеңлем, Вәлинур белән борчагызгыз пешмәс сезнең. Ул инде азау ярган, күпне күргән егет, ераграк булырга тырыш син аннан. Берүк яратканыңны сиздерә күрмә, әрәм итеп ташлар. Сак бул.

—Мин аны күрәлмим,—диде Мөкәррәмә яшь аралаш,—ул мине гел мыскыл итә. Яратмыйм да...

—Баш-аягың белән чумгансың икән инде, сеңлем, ул гыйшык-мыйшык дигән

татлы диңгезгә. Их, тагын бер кайтарасы иде шул иләс-миләс килгән вакытларны. Төннәрен саташып Гыйрфанымны эзлим, уянгач түшәмнәргә менеп китәрдәй булып тулышам. Белсәң син, ул рәхәтлекләрне! Ялгышып кыек юлларга гына кереп китмәсәм ярар иде дип, кайгыра башладым инде, сеңлем, ходай сакласын.

Кәшифә үзенекен тукыды. Әмма Мөкәррәмәгә бу сүзләр аңлаешсыз иде. Ул аларны тоемлый гына, мәгънәсенә төшенеп җитми. "Вәлинурга гашыйк булгансың" дигән сүзе гүпчем дә дөреслеккә туры килми бит инде. Әйтте ич инде ул аңа, "күрәлмим", диде. Юк, һаман үзенекен сайрый. Ә ул Вәлинур дигәннәре чыннан да азгын егет ахры. Кичә аулакта бер яшь хатынны кымтырыклаганын күреп калды. И, оялды инде, әйтерсең, үзенең изүен чиштеләр. Тегесе дә чытыкланыпмы-чытыклана. Ул булса, касыгына гына тибеп җибәрер иде...

Шулай да Мөкәррәмә үзен сынап карарга булды: гашыйкмы ул Вәлинурга, гашыйк түгелме? Гашыйк кеше, мәсәлән, гел генә гыйшкы турында уйлый, ди. Ә Мөкәррәмәне күбрәк әнисе кызыксындыра. Әтисе тизрәк сугыштан кайтсын иде дә, элеккечә гөрләшеп яши башласыннар иде, ди. Вәлинур ни өчендер төшенә керә. Тик гыйшыкмы бу, юкмы, тәгаен генә әйтә алмый. Кызлар яраткан егетенне күргәч, йөз кызарып чыга диләр. Мөкәррәмәнең дә Вәлинур белән очрашкач, бите кызыша башлый сыман. Бәлкем шулай тоела гынадыр, бәлкем дөрестән дә кызышадыр. Көзгегә карасаң, күренер иде дә, урамга көзге куймаганнар шул. Вәлинурны чеметеп аласы килә аның, монысы менә хак.

Яшенле яңгыр алдыннан кыргый җанварлар тынычсызлана башлыйлар, имеш. Яшьлек мәхәббәте дә яшенле яңгыр сыман җил-давыл белән, шом белән килә. Мөкәррәмә дә шундый хәлдә иде, күрәсең. Бимазалана, борсалана, үрсәләнә...

Беркөнне кичке якта яңгыр явып үтте. Иште генә. Ә үзе ничек кисәк кенә башланган булса, шулай кисәк кенә бетеп тә китте. Күк йөзен гүя себереп алдылар, яп-якты булып калды. Әмма кояшның юлы көянтә буе гына калып бара иде инде. Офык сызыгында асылынып калган челтәр болытлар ал төскә кергән. Тирә-як йомшак, серле тынлыкка тарган. Тау астындагы йомры күлдә кайнашкан казларның үзара сөешеп каңгылдашулары бу тынлыкка ниндидер ямансу моңсулык өсти иде.

Мөкәррәмә әсәрләнеп калды. Йөрәге нигәдер ашкынып-ашкынып тибә иде. Хәтта янына Вәлинурның килеп басканын да сизми калды.

—Нишләп болай оеп калдың әле, чикерткә?—дип сорады завхоз.

Мөкәррәмә бурлык өстендә тотылган кешедәй сискәнеп китте.

—Капчыкларны селкергә чыккан идем,—дип акланды. Һәм ул беренче тапкыр "чикерткә" дигән сүзгә кабынып китмәде. Егет бу юлы ничектер, аны ошатып, үз итеп әйтә кебек иде. Башыннан хыяллану түгел, төшенә дә кермәстәй үтә дә тәвәккәл уй йөгереп узды: "Ул мине ярата, ярата!"

Кыз күзен аска салып кына Вәлинурга карап алды. Егетнең иренендәге җөе бу минутта шундый якын булып тоелды ки, ул аны кулы белән сыйпаштырырга, алай гынамы, үбеп алырга да әзер иде.

* * *

Вәлинур соңгы вакытта бик нык үзгәрде. Элек тә авылда күз өстендә каш кебек иде. Ул кунып йөргән кызларга берәү дә аннан рөхсәтсез кагыла алмый иде. Кунак кызлары да аның иләге аша уза. Клубта да ул нинди уен теләсә, шуны уйнадылар. Хәзер бөтенләй азды. Аның үзен иң оста биюче, иң оста җырчы, иң оста уенчы, иң кыю һәм иң тәвәккәл егет солтаны итеп исбатлыйсы килгәне әллә каян күренеп тора иде. Мәхәббәт шулай бит ул, кешене үзгәртеп кенә калмый, таптый, изә, җелеген суыра, әллә нинди рәвешләргә кертә, әллә нинди гамәлләргә этәрә. Вәлинур да яраткан затының бит юган суын эчүне бәхет дип санау чигенә җиткән иде.

Кем соң ул асыл егетнең төн йокыларын качырган бу гүзәл кыз? Юк, Мөкәррәмә түгел. Вәлинур өчен Мөкәррәмә фәкать чикерткә генә, сары томшыклы шыксыз кош баласы. Аның йөрәген башка берәү җилкендерә. Бу—Өммия! Фельдшер кыз. Шул өзә аның үзәген. Өммиянең Минзәлә медицина техникумын тәмамлап, Түбән Сөн авылына җибәрелүенә әле ике-өч кенә атна. Бер күрүдә әсир итте кыз Вәлинурны. Дөрес, чибәрлек ягыннан авылда Өммияне уздыручылар да бар. Шул ук Мөкәррәмәне дә, әнә, фәрештә үбеп үстергән. Тик читтән килгән кызны авылныкылар белән чагыштырып буламы соң? Үзе укыган! Ә киеме? Андый киемле кызларны кинода

гына күрергә мөмкин. Аягында куныччы балтырына сыланып торган йомшак хром итек, өстендә чем кара кыска итәк, ап-ак кофта. Ул аяк атлаулары: әйтерсен лә, канатларын җәеп очып китәргә җыена. Чәче бөдрә, үзе искиткеч мөлаем. Сөйләшкәндә бит очындагы чокырлары уйнаклап-уйнаклап ала.

Мөгаен, авызы уймак, бите коймак дип шундыйларга карата җырлыйлардыр. Вәлинур аңа көннәр буе карап утырыр иде, һич ялыкмас иде. Тик кыз бер кешене дә аермый. Һәркем белән дустанә мөнәсәбәттә. Кич чыкмый, клубка йөрми. Күрәсең килсә, медпунктка барырга кирәк. Ә анда һәрвакыт кеше була. Вәлинур да теш сызлый дигән хәйлә белән барып карады. Фельдшер:

—Сезгә район хастаханәсенә мөрәҗәгать итәргә кирәк,—дип, бер кәгазь кисәге тоттырды.

Ник бер мәртәбә елмаеп карасын?

Икенче баруында Вәлинур үзен кыюрак тотты. Кызны төрле мәзәк сүзләр белән көлдерергә тырышып карады. Ә ул һаман шул термометрлары, дару-сарулары белән кайнаша, авызыннан сүзне ыргак белән тартып чыгарырга кирәк. Нишләргә соң, нишләргә? Тагын буш кул белән китәргә туры килә микәнни инде? Юк, ходай бар икән, хәленә керде бит тәки, рәхмәт төшкере. Ишек тоткасына ябышкач кына кылт итеп пунктның өйалды идәне хәтеренә төште. Хикмәт шунда, моннан алдагы фельдшер черегән идән сайгакларын алыштыру артыннан озак кына йөргән иде. Җитешә алмый калды, үзен икенче авылга күчереп куйдылар. Ул аны әйтеп калдырган булырга тиеш. Мөгаен, әлеге мәсьәлә бу чәчбине дә кызыксындыра торгандыр. Кылын тартып карау зыян итмәс.

—Пунктта култык таягы бармы?—дип сорады Вәлинур үзенчә бер шуклык белән.

Кызның кашлары биешеп алды. Күзләрендә—гаҗәпсенү.

—Кирәге чыгып куюы бар,—дип шәрехләде Вәлинур үзенең соравын.

—Кемгә, мәсәлән?

—Үзеңнән дә ерак йөрмәс. Әнә, өйалдының идән сайгаклары шартлап сынарга тора.

Черегән идән шартлап сынмый, билгеле, шулай да егет морадына иреште. Кызның җитди йөзенә күбәләк кунды.

—Ә-ә, аны әйтәсез икән…

—Ярдәм итә алам,—диде Вәлинур түрәләрчә борынын чөебрәк,—андый мөмкинлекне табарга була…

Ләкин кыз уңганлыгын күрсәтеп өлгергән икән инде.

—Рәхмәт, авыл Советы бу хакта белә, оста карап китте инде,—диде.

—Хәмзәме?

—Мин аның исемен сорамадым.

Һай шома кыз, балык кебек кулдан шуып төшәргә генә тора. Моңа кадәр аны бер мәртәбә дә кире какканнары юк иде әле. Алай гынамы, "яратам" дигән сүзләрне кызлар үзләре ишеттерә иде. Бу чибәркәй белән нишләргә соң? Бер генә минутка да исеннән чыгып тормый бит.

Медпункттан Вәлинур туп-туры колхоз остаханәсенә, яшьтәше Хәмзә янына юнәлде. Сугышка кадәр монда аның әтисе, тагын берничә кеше эшли иде. Көпчәкләр ясыйлар, дуга бөгәләр, арба-чана төзәтәләр… Кыскасы, хуҗалыкның агач-ташка бәйле бөтен хаҗәтен үтиләр иде. Хәзер бу эшләрнең барысы да титак Хәмзә җилкәсенә калды. Аның сул аягы тездән язылмый, атлаганда авып-түнеп китә.

Хәмзә ниндидер зур гына рамга такта кадаклый иде. Ишек уемында Вәлинурның төз гәүдәсе күренүгә авызын чабатадай ерып, такылдарга керешә.

—Кыдлар диеп чыккан ием, кыдыл бодау абдарда, дигән ди берәү. Бик әйбәт булды әле сугылуың, яшьти, әйдә, тот тактаның аргы башыннан, ярдәмче кирәк диеп бригадирга күпме ялындым, колагына да элмәй…

—Нәрсә була соң бу?—дип сорады Вәлинур.

—Мактау тактасы. Синең күек алдынгыларның сүрәтен эләргә, ди. Сафура апа ясарга кушты. Кызыл ситсага төргәч, менә дигән була ул.

—Тагын нинди кичектергесез эшләрең бар?—диперактанрак суктырды Вәлинур.

Хәмзә колак артына кыстырылган каләмен алмыйча гына башын кашып торды.

—Эшнең андые-мондые юк инде аның, яшьти, ватык рамнар күпме җыелды, әнәтрәк, көпчәкләр… кулың гына җитешсен…

—Тагын?

—Ат дагалаганда бака күек ботын кыстыручылары да табыла. Пункт идәнен дә миңа тагып куйдылар әле менә...

—Такталарың бармы соң?

—Ни сүләйсең син, авыл Советының бете дә юк ич аның, анысы синнән инде, яшьти.

—Миндә Әндри казнасы юк,—дип, Вәлинур сүзгә нокта куйды. Ул кирәкле мәгълүматны алган иде инде. Башындагы нияте дә өлгереп җитте.

—Яшьти, кая болай кабаланасың, юньле-башлы тел дә кашымадык бит әле,—дип сөйләнеп калды Хәмзә.

—Телеңне тешеңә кыстыр,—диде Вәлинур.

Бу сүзләрне әйткәндә ул ишекнең теге ягында иде инде.

Вәлинур ниятен гамәлгә ашырырга тотынды. Башта идән сайгакларын колхозның алма бакчасына ташып куйды. Беренчедән, монда аулак. Икенчедән, медпунктка киртә аша гына сикерәсе.

Арып-талып авыл халкы төнге йокыга талуга, ул эшкә керешге. Пунктның йозагы әйле-шәйле генә иде, йодрыкка да чыдамады. Складтан элмә лампа алып килгән иде, шуның яктысында тирләп-пешеп иң элек чергән сайгакларны куптарып ташлады, аннан соң алар урынына яңаларын җәйде. Хәмзә шикелле оста булмаса да, барыбер әмәленә китерде, ике-өч сәгатьтә башкарып чыкты. Иске такталарны амбарга илтеп куйды, алар исәп-хисап өчен кирәк булачак. Аның гамәлен, әлбәттә, рәис хупламаячак, нигә миннән узып, рөхсәтсез-нисез колхоз әйберсен әрәм-шәрәм иттең диячәк. Вәлинур җавапларын да әзерләп куйды: "Медпункт колхозчыларга хезмәт күрсәтә бит",—дип, рәиснең авызын каплаячак. "Нигә син?"—дип сораячак ул, билгеле. "Мин комсомол члены ла, буш вакытымда җәмгыятькә файдалы хезмәт белән шөгыльләнәм икән, бу хуплауга гына лаек",—диячәк.

Вәлинур баскыч төбендә тәмәке көйрәтеп таң аттырды. Аның әле болай иркенләп кояш чыгуын күзәтеп торганы юк иде. Җәйнең көз белән очрашу вакыты. Әмма көз әле ишек кагарга гына чамалый. Әлегә барысы да җәйдәгечә. Әнә, авылны тузанга күмеп көтү чыгып китте. Шуның артыннан ук атларны алып кайттылар. Кеше пунктка эшкә барышлый сугыла. Берәүләр күзенә тамчы салдыра, икенчеләре дару каба, укол кадаттыра. Шуңа күрә Өммия иртән иртүк килә. Кайвакыт аеруча нык ашыгучылар аның үзен дә көтеп алалар. Шунлыктан, баскыч төбендә Вәлинурны күргәч кыз һич тә гаҗәпләнмәде.

—Берәр нәрсә булдымы әллә?—дип кенә сорады.

—Нигәдер эчем бора,—диде егет мутланып.

—Әйдәгез, узыгыз, мин хәзер, кулымны гына чайкыйм да...

Алар өйалдына үттеләр. Күзе үткен икән Өммиянең, үзгәрешне шундук күреп алды, башын борып, Вәлинурга сораулы караш ташлады.

—Кабул итеп ал,—диде Вәлинур,—дәгъваларың юкмы?

Кыз аптырап китте, беравык ни әйтергә белмичә торды.

—Нигә инде...

—Безнең авылда шулай, туташ, кызларны өркетеп сыныйлар,—диде Вәлинур һәм дөп-дөп басып ишек катына юнәлде.

—Вәлинур, бер генә минутка,—дип туктатты аны Өммия. Алар бер-берсенә карашып тордылар. Кызның күзләре дә йөзе кебек үк мөлаем иде. Карашы беренче кар кебек йомшак, мәрхәмәтле. Бу мизгелдә ул сөеп туймаслык иде.

Вәлинур аның кулларыннан алды, куйнына кертмәкче булды. Өммия дерелдәп китте, йомран тизлеге белән егетнең кочагыннан чыкты.

— Вәлинур, тынычланыгыз әле, аңлашыйк әле,—диде.

Өммия еш-еш сулый иде. Күрәсең, ул да үзен көч-хәл белән генә тыеп тора иде.

—Аңлашыйк соң,—диде Вәлинур.

—Сез миңа ошыйсыз,—дип дәвам итте Өммия,—без, мөгаен, бер-беребезгә пардыр. Ләкин...

—Нәрсә ләкин?

—Әйдәгез, дус кына булып калыйк.

—Яраткан кеше белән дус булып була димени? Яраткан кешене яраталар аны... үбәләр... кочалар...

Кызның иреннәре калтыранып куйды.

—Була,—диде ул,—үзеңне кулга алырга гына кирәк. Зоя Космодемьянская шикелле, без комсомоллар ич.

—Ә нигә дус кына?

—Чөнки мин фронтка китәргә гариза бирдем, Вәлинур. Бүген-иртәгә чакыру көтәм.

—Минем дә тиздән унсигезем тула...

—Шулай булгач соң...

* * *

Кызык та икән бу гыйшык тотучының хәлләре. Йокыдан уянып өлгермисең, гыйшкың инде күз алдында тора, әйтерсең лә, сагалап кына йөри. Ятсаң да, торсаң да, утырсаң да, барсаң да уеңда һаман сөйгәнең. Ул әйбәт тә, матур да, булдыклы да, көчле дә, мәрхәмәтле дә. Ни генә очып килми хыял канатларында. Дөресендә исә, мәхәббәт беркайчан да мәрхәмәтле була алмый. Кайсыдыр аксакал әйткән, имеш, “Оҗмахка юл җәһәннәм аша”, дигән. Мәхәббәт тә шулай. Аның сагышлары, борчулары түбәдән аша. Мәхәббәт башкача була алмый.

Болар Мөкәррәмәгә дә киләчәк. Ә хәзергә ул бетмәс-төкәнмәс шатлык, күңел күтәренкелеге генә кичерә иде. Дөнья шундый күркәм, шундый пакь, шундый шәфкатьле—җырлыйсы, биисе генә килеп тора. Бер урында секунд та утырып тора алмый, чабыш атыныкы шикелле йөрәге кага. Иртән эшкә киткәнче ялт иттереп идән-сәкеләрне юып чыгара, суын ташып куя, әнисенә кыл да кыймылдаттырмый. Эштә дә алны-ялны белми, ут уйната. “Синең әле буыннарың ныгып бетмәгән, ул кадәр каударланма”,—дип тә карыйлар, юк, колагына да элми, зур-зур капчыкларны җилтерәтеп кенә йөртә.

Хәтсездән инде аның Вәлинурны якыннан күргәне юк. Ул ашлык киптерү пунктына килгәндә йә йомыш табып китеп бара, йә ниндидер аулак урынга кереп поса. Урамда күренсә дә кырт борылып кире якка элдертә. Вәлинур моны үзе белсә, шаккатыр иде. Чөнки аның йөрәге Өммия дип тибә, аңа Өммия кирәк. Егеттән аермалы буларак, Мөкәррәмә кысыр мәхәббәткә дә риза. Дөресрәге, аның әле яратуның, сөешүнең тәмен, ләззәтен татып караганы юк. Шуңа күрә ул аның өчен татлы хыял гына булып кала бирә.

Базар көнне Мөкәррәмә Мөнҗияләрдә кунды. Дус кызы аңа чүпрәк-чапракларын күрсәтте. Тегү-чигүгә бик оста ул, кулы ятып тора. Аның әнисе дә авылда бер тегүче. Аяклы машиналары да бар.

—Мин зуррак кызларга да кульяулыклар чигәм,—диде Мөнҗия,—сорыйлар, кем вәгъдә бүләгенә, кем сабан туена...

Арадан аеруча ак батис кульяулык ошады Мөкәррәмәгә. Чит-читләре челтәрле. Нәкъ уртасында кызгылт күзле, ал томшыклы пар күгәрчен сурәте төшерелгән. Берберсенә карашып торалар. Шундый мөлаемнәр, шундый чибәрләр, уч төбенә утыртып кына йөртәсе килә үзләрен.

—Күгәрченнәр бервакытта да ташлашмыйлар,—диде Мөнҗия.

—Минем дә тырнакларга күгәрчен сөте бик еш төшә, нигәдер туры гына килеп бетми, яңа кием сирәк эләгә,—дип ялгап китте Мөкәррәмә дустының сүзен.

—Анысы башка,—диде Мөнҗия,—мин мәхәббәт турында әйтәм.

—Синең берәр малайга кульяулык биргәнең бармы?—дип кызыксынды Мөкәррәмә үз чиратында.

—Башта үзләре бирсеннәр әле,—диде Мөнҗия.

—Нигә, кызларга башлап бүләк бирү ярамыймыни?

—Җүләр, үзеңнән көлдерергәме? Бер үпкәнгә кульяулык бирде дип сөйләп йөрерләр иде бугай.

—Син бик күп беләсең,—дип көнләшеп куйды Мөкәррәмә.

—Мин бит бишенче класстан бирле үк кунып йөрим,—диде Мөнҗия. Аның бу сүзләрендә горурлык хисләре ярылып ята иде.

Мөкәррәмә Мөнҗияләрдән бик рухланып, канатланып кайтты. Кичләрен үзе дә чигү чигә башлады. Болары әле өйрәнчек кенә иде, аерым-аерым атламнар, чүпләмнәр, сурәтләр. Ә күңеленә, кулына энә тоткан көннән алып, сөйгәненең җанын эретердәй бик гүзәл бер кульяулык чигү хыялы кереп утырган иде. Ул аңа һич тынгы бирми, мәхәббәт шикелле һаман йөрәген җилкетеп тора. Шикләнүе дә бар: булдыра алырмы,

хисләрен аңлатырлык алымнар табып җиткерерме? Вәлинур бик четерекле егет, ошатмыйча кире боруы да ихтимал.

Ниһаять, икеләнүләрне читкә куеп, тәвәккәлләде Мөкәррәмә. Ай дигәндә кульяулык әзер иде инде. Ләкин нәкъ шушы көннәрдә аның канатын каерып, Кәшифә ачы хәбәр җиткерде.

Әбәтләп утырулары иде. Ризык көндәгечә: ипи, бәрәңге, сөт. Шөкер, быел икмәк уңды, акмаса да тама. Хезмәт көненә икешәр йөз граммнан ашлык бүлделәр инде. Хөкүмәт планы арттырып үтәлсә, тагын өлеш чыгармакчылар, ахры. Мөкәррәмәләрнең кишерләре уңды, әнисе бөрмәкәенә көн дә бер-ике кишер салып җибәрә. Кәшифә кыяклы суган алып килә. Шуларның барысын бергә кушкач, менә дигән табын оеша, ашъяулык туп-тулы була.

—Ишеттеңме, безнең тәти егетебез брач кыз артыннан чаба икән бит, кичә төн чыкканчы пунктка яңа идән җәеп куйган,—диде Кәшифә.

Мөкәррәмәнең авызындагы кабымлыгы тамагына тыгылды, бермәл йотып җибәрә алмый торды. Чөнки ул кем турында сүз барганын шундук төшенеп алган иде. Вәлинурны Кәшифә генә “тәти егет”дип йөртә.

—Ул кызның борынына тугыз күркә кунарлык ич аның,—диде Мөкәррәмә бар ачулы мыскылын шушы сүзгә салып.

—Танавы олы булса да, брач дигән исеме бар аның, үскәнем, культурнай, синең белән минем күек җилдә бит ярып йөрми.

Шушы сөйләшүдән соң Мөкәррәмәнең үз-үзен тотышы бермә-бер үзгәрде. Элек сөйгәненең күзенә күренергә дә оялып йөргән кыз, хәзер аның артыннан тотам да калмый күзәтеп йөри. Менә бүген дә клуб почмагына сыенып сакта тора. Әлегә кадәр Вәлинур белән Өммияне бергә күргәне булмады. Бу аны сөендерә дә, көендерә дә. Яратышсалар, кичәләргә бергә чыгарлар иде, бүтәннәр шикелле бергә-бергә биерләр иде, дип уйлый. Димәк... Бәлкем, Вәлинур кызның фатирына куна барадыр? Брач дигәннәре Фазилә әбиләрдә яши. Аның өе иркен, такта белән бүленгән. Егет кертергә бик уңайлы. Бәлкем... Әнә шул “бәлкем” Мөкәррәмәгә ышаныч бирә дә инде. Шул дөрескә чыкса, үзен бәхетле кызлар рәтендә дип исәпләр иде.

Аның янынннан титаклый-титаклый сәвит Миһран узып китте. Һәр шимбәдә сәгать кичке унда яшьләрне клубтан үзе куып тарата. Кич озак йөреп, йоклап калмасыннар, янәсе. Беренче урында күңел ачу түгел, эш булырга тиеш. Әле сугыш чыккан мәлне клубны бөтенләй ачтырмый азапладылар. Мәскәү янындагы җиңүдән соң гына бераз тезгенне бушаттылар.

Күп тә үтмәде, дөбер-шатыр килеп клубтан яшьләр ишелеп чыга башлады. Сөн урамына таба борылучыларны энә күзеннән үткәргәндәй итте кыз, араларыннан Вәлинурны эзләде. Ә ул күренмәде. Әллә абайламый калдым микән, мин күрмәгәндә китеп бармагандыр ич, дип борчылды. Югыйсә, бик уяу торган шикелле иде. Юкка гына хафаланган икән. Клубта ут сүнүгә, мөдир күренде, аның янында Миһран белән Вәлинур да бар иде. Быдыр-быдыр сөйләшеп тордылар да, һәркайсы үз юлына китеп барды. Мөкәррәмә Вәлинурга иярде. Фазилә карчыклар ягына каерылырмы, өйләренә таба атлармы? Егет исә бөтенләй икенче кешенең капка төбендәге эскәмиягә барып чүмәште. Озак кына тәмәке төрде, чакма ташын да озак кына чыжылдатып азапланды. Ниһаять, кабызды ахры, авызына кисәү шикелле ут кубызы элде. Курыкмый да икән, ут күрсәтмәскә кушалар ич, штраф салалар. Тәрәзәләрне дә каплаталар. Шуларга карап, немец самолетларының авылны бомбага тотулары ихтимал, имеш.

Вәлинур авыз эченнән генә нindидер көй мыгырдый, ара-тирә уфылдап куя, төкеренеп ала.

Мөкәррәмә аны ябалдашлары җиргә кадәр салынып төшкән карама агачы ышыгыннан күзәтеп тора. Караманың кәүсәсе читәннең эчке ягында булса да, ботаклары ярты урамны диярлек биләп тора. Тынын да курка-курка гына ала, Вәлинур күреп алса, ни дип җавап бирер?

Берара җил исеп китте. Яфраклар шыбырдаша-шыбырдаша гәпләшеп алдылар. Күрәсең, Җилбикә яфракларны гына түгел, болытларны да тузгытып җибәргән иде, ай да оялып кына йөзен ачты. Дөнья яктылыкка чумды. Нindидер әкияти шәһәрчекне хәтерләтеп, караңгылык эченнән йокыга талган авыл урамы, ике яклап тезелешкән йортлар, каралты-куралар калкып чыкты. Көтүче чыбыркысы буе булып сузылган

күләгәләр артында әллә нинди пәри затлары яшеренгәндер, хәзер йөгереп чыгарлар да җырлап-биеп китәрләр төсле.

Шулай да, Җилбикәнең болытларны төбе-тамыры белән болгатып ташларга көчкуәте җитеп бетмәде, ахры, тирә-якка янә кара пәрдә төште. Нәкъ шушы вакытта читән буенда эт өреп җибәрде. Мөкәррәмә чырылдап яктыга ыргылды. Үч иткәндәй ай да балкып китте.

—Нәрсә, тешләдеме әллә?—дип, Вәлинур кызның каршысына килеп басты.

—Жу-у-ук,—дип суызды Мөкәррәмә, үзе дер-дер калтырана. Ул эттән бик курка иде. Югыйсә, тешләгәннәре дә юк. Була бит шундый сәбәпсез шомланулар. Ләкин бу минутта Мөкәррәмә эткә караганда да егетнең сорауларыннан күбрәк курка иде. Төнге урамда япа-ялгыз яшеренә-яшеренә йөрүен аңлатыр хәлдә түгел иде ул. Бәхетенә, Вәлинур төпченеп тормады.

—Менә шулай, Мөкәррәмәкәй,—дип, көрсенгәндәй генә итте, гүя серен ачып салырга тели.

Кызның үз гаме—Вәлинурның аңа исемен әйтеп мөрәҗәгать итүе барсын да оныттырды. Моңа кадәр һаман "чикерткә" иде бит әле. Әмма иң зур шатлыгы—егетнең менә шулай ялгызы гына утыруы иде. Өммия артыннан чабуы дөреслеккә туры килми түгелме соң? Әгәр хак булса, берүзе төнен тәмәке суырып уздырмас иде, сөйгәне янына барыр иде.

—Егетең кая, шулай бик оялчанмыни?—дип сорады Вәлинур. Ул Мөкәррәмәне карама ышыгында егет белән юанып торган, дип уйлый иде, ахры.

—Бернинди дә егетем юк минем,—диде Мөкәррәмә.

—Ә нишли идең соң ялгызың гына карама ышыгында?

—Син үзең дә ялгызың гына утырып торасың бит әле…

—Алайса кайтышыйк, иртәгә бәйрәм түгел,—дип, Вәлинур кисәк кенә әңгәмәне өзде.—Кызыл олау буласы.

—Кипкән бодай күп,—диде кыз,—ике кызыл олауга җитәрлек.

—Беләм,—диде Вәлинур,—алай да йоклап кала күрмә.

Мөкәррәмә өенә тыныч күңел белән кайтты. Төш тә күрмичә рәхәтләнеп йоклады. Эшкә килгәч тә язгы чыпчык шикелле чыркылдады. Кәшифәнең сөтле шешәсен яшереп куеп, бер мәзәк тә ясап алды. Тегесе: "Кар базы авызында онытып калдырганмын икән, кибәк баш",—дип кайтырга ук җыенган иде, Мөкәррәмәнең ерык авызын күргәч кенә хәлгә төшенде.

—Кызый, үчен кайтарам әле мин моның,—дип бармак янады.

Сүз иярә сүз чыгып, әбәт вакыты үткәнен сизми дә калдылар. Кәнсәләрдән Вәлинурны эзләп килмәсәләр, әле һаман тел кашып утырган булырлар иде.

—Амбардадыр, безнең янда алай озын-озак кәнфитләнеп тормый ул, ай күрә, кояш ала,—диде Кәшифә.

—Бәрәч, мин шуннан киләм ласа, андагылар сушилкада диделәр.

—Әтекәйгенәм, анда да, монда да баш күрсәтмәгәч, брачы янында инде. Таһир белән Зөһрә булдылар тәки, чукынмышлар…

Мөкәррәмә: "Юк, ул аның янына йөрми",—дип кычкырып җибәрә язды. Ләкин телен тешләп булса да түзде, серен ачмады. "Каян беләсең?" дип сораулары да бар бит әле. Кечкә кадәр башын да күтәрмичә эшләде дә эшләде. Күңелендә кырык төрле уй. Уйланган саен шөбһәсе көчәя генә барды. Иртәрәк тынычланды бугай ла ул. Мөгаен, Вәлинур әлеге төнне теге олы танау янына ашыккандыр. Кайтышыйк, имеш, иртәгә бәйрәм түгел, янәсе. Төлке. Кәкре каенга сөяде дә китте, ә ул шуның тасма теленә ышанды. Мөкәррәмәкәй дигән була бит әле җитмәсә. Китек ирен.

Мөкәррәмә бу кичтә урынын үзгәртте, Фазылә карчыклар ихатасы янына барып басты. Аның өе Сөнгә аяк терәп утыра. Капка каршында—пар тирәк. Авылның бөтен каргасы диярлек шунда оялый. Башкалар өй түбәсен черетә, бәбкәләргә тияләр дип, ояларны туздыралар, каргаларны куалар. Фазылә карчык исә, киресенчә, кошкайларым дип кенә тора. Хәзер каргаларның көтү булып оешкан чагы, хәтта төннәрен дә тынгы бирмиләр, кубып-кубып алалар.

Мөкәррәмәнең каргаларда көне юк, күзләрен очландырып ул өйдәш кызны көтә. Үзе генәме, әллә азгын мал кебек Вәлинурны да ияртеп кайтырмы?

Песиләр дә бар икән әле монда. Берсе йомгак шикелле Мөкәррәмәнең аякларына

—Мияу-мияу...

Кыз аны кулына алды. Дер-дер килә мескенем. Әллә куркытканнар, әллә өшегән. Төннәрен салкынчарак бит хәзер. Сентябрь борын төбендә.

Мөкәррәмә мәче баласын кулыннан төшереп җибәрде. Чөнки сөйләшә-сөйләшә кемнәрдер капка янына килеп туктады. Ул аларның сүзен аңышмады, чөнки ара ерак кына иде. Әмма өзек-өзек ирешкән көлешү авазларына караганда, мөнәсәбәтләр инде майланган булырга ошый. Капка төбендә озак юанмадылар, шыпан-шыпан гына басып өйалдына кереп киттеләр.

Менә кайда үтә икән Вәлинурның төннәре. Тотылдың бит, астыртын урыс. Алдакчы! Кеше белми сөйләми инде ул. Хәер, аннан аңа ни файда?

Их, Вәлинур абый, Вәлинур абый, бел, сине беркем дә, бервакытта да минем кебек чын ярату белән яратмас. Өммия сиңа тиң түгел. Ул укыган кеше, аңа үз ише кирәк. Чистый акылың томаланды, үкенергә туры килмәгәе әле, терсәк якын да, теш кенә җитми.

Миңа нишләргә соң хәзер? Кая барыйм, кемнең күкрәгенә башымны салыйм? Синнән башка тормышым юк бит минем, аңлыйсыңмы шуны, Вәлинур абыкаем? Юк, аңламыйсың. Аңларга теләмисең дә. Чөнки син бөтенләй башка берәүне назлыйсың, башка берәүне иркәлисең, сөясең... Сезнең Өммия белән җитәкләшеп баруыгызны күрү күкрәгемә хәнҗәр кадау белән бер ләбаса!

Мөкәррәмә тирәк күләгәсеннән чыкты да, Сөн сукмагы буйлап түбәнгә таба төшеп китте. Уенда ни-нәрсә—бер Аллаһы үзе генә белә.

Сөн бу урында борылыш ясый. Язгы ташу вакытында югарыдан бер-берсен куышып килгән боз өере ярны шактый җимергән, ашаган иде инде. Болайга китсә, авылыңны да ишеп төшерер бу котырган Сөн.

Кызның күңелендә бөтенләй башка уйлар иде, ахры. Менә ул түбәнгә үрелеп карады. Су өсте шыксыз иде, дулкыннар ярсу җил куып йөрткән болытлар шикелле бер-берсенә килеп орыналар да, күбекләрен ярга сылыйлар. Гөп тә гөп.

Мөкәррәмә артка чигенмәкче булды, тик соң иде инде, башы әйләнеп китте дә, түбәнгә тәгәрәде.

—Әнкәй, әнкәем...

Аның тавышын дулкыннар читкә җибәрмәде, үзләренә ялмап алдылар. Бәхетенә, бу урын сөзәгрәк иде. Бераздан ул үзенең исән-сау икәнлеген аңлап алды. Бар көчен җыеп сикереп торды да кабалана-кабалана кичү турыннан өскә үрмәләде.

Мөкәррәмә бу вакыйганы берәүгә дә белгертмәде, хәтта әнисе дә сизмәде. Вәлинурга да кискен карар чыгарды—онытырга! Күңелдән чыгарып ташларга!

Өммияне исә әлеге кичтә Вәлинур түгел, ике-өч көн элек налог агенты булып эшли башлаган яралы капитан Нургата Фәйзуллин озатып килгәнен ул белми иде.

Нургата районнан килеп төшүгә ярасын бәйләтергә дип медпунктка сугылган иде. Өммия аны бер күрүдә ошатты. Фронтовик. Офицер. Орчыктай төз гәүдәле. Үгезне дә мөгезеннән ала торган икән. Очрашу турында сүз кузгатты. Ә кыз тәкъдимне кабул итте. Фронтка әле бүген-иртәгә генә алырга тормыйлар, монда да кеше кирәк, диләр. Авыл фельдшерларына тимәскә дигән күрсәтмә дә килгән, имеш.

* * *

Сугышка алып киткәнче Вәлинурларны районга өч көнлек "уен"га җыйдылар. Беренче мәртәбә чын хәрби мылтыктан атып карадылар, окоп казыдылар. Соңгы көнне алар алдында хәрби комиссар чыгыш ясады.

—Хәзер ил язмышы Иделнең түбән агымында, Сталинград шәһәре тирәсендә хәл ителә,—диде ул,—сез беләсез, Мәскәү янында фашистлар максатларына ирешә алмады. Иптәш Сталинның зирәк җитәкчелеге нәтиҗәсендә Кызыл Армия тарафыннан тар-мар ителделәр. Шуның үчен көньякта кайтармакчылар. Ныклы ышаныч белән әйтә алабыз, 1942 елның 17 июлендә башланган Сталинград кампаниясе дә немец илбасарларына үлем алып киләчәк. Анда хәзер аяусыз оборона сугышлары бара. Сез менә шундый ифрат та җаваплы чорда фронтка алынасыз. Сезнең команданы да шул юнәлешкә тәгаенләп торабыз...

Егерме дүртенче елгылар авылда егермегә якын иде. Берәм-берәм чүпли торгач, табак төбенә өчесе генә сыланып калган булып чыкты. Вәлинур, Газыйм, Салих. Чират аларга җитте. Газыйм белән Салих терлекчелектә эшлиләр иде, аларга китү уңаеннан эшләр тапшырып мәшәкатьләнәсе булмады. Вәлинурның исә "уен"нан соң бирелгән

ике көне дә алыш-биреш белән үтте диярлек. Шуна күрә хушлашып-саубуллашып йөрергә чамасы да калмады. Ә китәсе көнне иртән авыл әйләнделәр. Вәлинур һаман бер җырны кабатлады.

*Мин киткәч, кемнәр иркәләр,*

*Син сандугач баласын...*

Басу капкасы төбенә бөтен авыл җыелган иде. Елашалар, җырлашалар, гәпләшәләр. Вәлинур гына үз-үзенә урын таба алмый. Билгеле инде, Өммия дип өзгәләнә ул. Ә Өммия күренми дә күренми. Мөгаен, килмәстер дә инде. Нургата моннан алда гына: "Нишләп ул күзгә әтәч гел синең яныңда әвәләнә?",—дип ризасызлыгын белдергән иде.

Мөкәррәмәнең дә йөрәге урынында түгел. Үпкәләре онытылды. Ул кич утырып чиккән кульяулыгын Вәлинурга бүләк итәрмен дип ниятләп килгән иде. Аңа атап чикте ич Мөкәррәмә бу кульяулыкны. Һәр бизәгенә аның саф хисләре салынган.

"Кульяулыгым сине дошман ядрәләреннән саклар, түш кесәңдә генә йөрт",—дип әйтмәкче иде. Эченнән генә булса да: "Минем сөюемнең билгесе",—дип тә өстәячәк, билгеле. Тик Вәлинурны әнисе бер генә минутка да үзеннән читкә җибәрми, эчеп исерер дип шикләнә иде ахрысы. Шулай да соңгы минутта Мөкәррәмә бар кыюлыгын җыеп, Вәлинур янына килде.

—Ә-ә, чикерткә!—диде егет битараф кына.

—Исән йөреп сау кайтырга насыйп булсын, Вәлинур абый,—диде Мөкәррәмә яшь аралаш.—Менә...

Аның сүзе шушы урында өзелде, чөнки авыл Советы рәисе Миһран Әхмәдишанның:

—Кузгалабыз!—дигән әмере яңгырады.

Кешеләр кочаклаша, елаша башладылар, гармунчы гармунын тартты. Вәлинур әнисен кочаклаган килеш, карлыккан тавыш белән җырлап җибәрде...

Олау кузгалды.

Мөкәррәмә кульяулыгын кайнар күкрәгенә кысып, бер читтә ялгызы басып калды.

* * *

Борылышта иң элек пароходның чөгә балыгыныкы шикелле очлы борыны пәйда булды. Аннан соң зурайганнан-зурая барып, ниһаять, бөтен сыны белән ике яр арасына ятты. Өч мәртәбә озын итеп кычкыртты да куласаларын шап-шоп бәргәләп, тукталышка таба елышты.

Халык корт күчедәй выжылдап, трап алдына ябырылды. Этешәләр, төртешәләр, кычкырышалар.

—Назад!—дип кычкырды шкипер Сәрби яшелле-зәңгәрле тавышы белән.—Назад! Стрелять буду!

Сәрбинең мылтыгы юк, әмма авыл кешеләрен куркытырга шул кырыс сүзе дә җитеп тора. Хәзер дә тынып калдылар.

—Әҗәкүлнең ни хатын, ни ир кешесе шушы икән,—дип, үзалдына сөйләнеп алды Нәгыймә. Мөкәррәмәгә мөрәҗәгать итеп:

—Кызым, әйберләреңне урлата күрмә, парахутта бурлар күп була,—диде.

—Ярар инде, әнкәй, гел бер сүзне кабатлама...

—Кайвакыт кабатласаң да таманга гына туры килә әле ул, син парахутларда йөргән кеше түгел, кызым,—дип, Нәгыймә үзенекен сукалады.

—Мин куркам, Мөкәррәмә, батмабыз микән без,—дип, Сәмига да шикләнүен белдерде. Куркуы хактыр да, йөзе кәгазь кебек булып агарган.

—Пароход бата димени, исәр, ялгаш түгел лә ул сиңа...

Нәгыймә янә кисәтәсе итте.

—Аң булыгыз, алмаш-тилмәш кенә йоклагыз, әйберләрегезне урлата күрмәгез.

—Әнкәй, ишеттек бит инде.

—Барып җитүгә хат яз, кызым.

—Бу турыда да мең кат сөйләштек инде, әнкәй...

—Укырга-нитәргә кыстый башласалар, ризалашма, әткәй фронтта, әнкәем бер үзе генә калды диген.

—Безне укырга җибәрмиләр бит, әнкәй, эшкә җибәрәләр.

Ниһаять, Сәрби тавыш көчәйткеч калай нәмәстәсен кипшенгән иреннәренә терәде.

—Марш! Отставить! Чират белән генә! Озатучылар на месте!

Халык этешә-төртешә пароходка тулды. Күп сыман тоелсалар да, эчкә кергәч, барысы да урнашып бетте үзе. Мөкәррәмәләр койрыкка *(пароходның арткы өлешен халык шулай дип йөртә)* урнаштылар. Монда ачык һава, җиләс. Тирә-якны күзәтеп барырга да уңай.

Кызлар пристань күздән югалганчы, тырыша-тырыша, яулыкларын болгадылар.

Пассажирлар инде тынычланды. Кайсы ашый, кайсы йоклый, бәгъзеләре әңгәмә кора. Һәрберсенең үз шөгыле. Мөкәррәмә тимер рәшәткәгә таянып, елгага текәлгән. Куласалар киң канатлары белән суны берара бөтереп-бөтереп торалар да, ургылдыра-ургылдыра артка куалар. Су чыдаша алмыйча кайный башлый, әйтерсең лә астына ут якканнар. Ә ян-яктан пароходны бару уңаена җеп булып сузылган ике ак башлы дулкын озата бара. Карыш та калмыйлар, яр читләрен капшый-капшый пароход артыннан йөгерәләр генә.

Кояш та аларга ияргән, пароходның әле бер ягына, әле икенче ягына чыга, дулкыннар өстендә җем-җем итеп уйный. Тик офык инде алланып килә, тиздән кояш бишегенә кереп ятыр. Бу ямансу көнне дә үзе белән Каф тау артына алып төшеп китәр.

Вәлинур абый да шушы болыннарны, шушы әрәмәләрне күзәтеп барган бит инде. Су өстендә аның күз нурлары да сирпелеп калгандыр әле. Их, беләсе иде, кайда икән ул хәзер, нинди уйлар уйлый икән?

Теге вакытта, тагын бер атнадан сез дә авыл белән хушлашырсыз, дип әйтсәләр, тилебәрән орлыгы ашаганмы әллә бу кеше дип көләрләр генә иде. Һич көтмәгәндә килеп чыкты бит. Бер көнне комсомол җыелышы җыйдылар, өченче көнне озаттылар да. Йомшак җәеп, катыга утыртуларын аңышмыйча да калдылар. Хәер, барып җитеп, эшли башлагач кына моның төбенә төшенәчәкләр әле алар.

Ә комсомол җыелышы сугыш вакытына хас булганча, бик күтәренке рухта үтте.

—Кызлар өчен хәрби эш белән бәйле хезмәткә ике юллама килде,—диде секретарь шатлыклы хәбәр җиткергәндәй,—мин теләүчеләр күп булыр дип уйлыйм. Әмма аның мөһим шарты да бар: бу урынга дәгъва итүчеләр физик яктан нык, таза булырга тиешләр. Фронт эше, үзегез беләсез...

Шаулашып алдылар.

—Нигә егетләргә барырга ярамый?—дип сорады Каюм,—үзем язылган булыр идем.

—Егетләр фронт өчен кирәк,—диде секретарь.—Җә, кызлар, кемне беренче итеп язабыз?

—Мине,—дип урыныннан сикереп торды Сәмига,—минем беренче буласым килә!

—Молодец, Хөрмәтуллина,—диде секретарь,—зур сәяси аңлылык күрсәттең. Тагын...

Ләкин ни хикмәттер, Сәмигага иярүче табылмады. Берара син языл да, син языл дип, төрткәләшеп тордылар. Файдасы тимәде. Секретарьның да тактикасы үзен акламады, шуңа күрә ул партия оешмасы һәм авыл Советы белән килештерелгән исемлеккә күз төшереп алды да, мәсьәләне тәгаенли төште.

—Әмирова нәрсә уйлый?—дип, Мөкәррәмә ягына борылды.

—Мин әле уйлап бетермәдем,—диде кыз.

—Бу бик мөһим поручение, Әмирова,—дип, секретарь турыдан-туры басым ясауга күчте.—Поручение гынамы, партия наказы. Тәкъдимнән баш тарту комсомолларча булмас.

—Белмим шул...

—Һи, исең китмәсен, ике айга куян тиресе дә чыдый,—дип, секретарь көлгән атлы булып кыланды. Белепме-белмичәме, аңа Сәмига ярдәмгә ашыкты.

—Язып, Мөкәр, брач Өммия шикелле киенеп-ясанып кайтырбыз,—диде.

Шушы сүз барысын да хәл итте. Аллаһы боерса, Өммия ише генә киенәчәкме соң Мөкәррәмә? Борынына чиертәчәк ул әлеге мактанчыкның. Менә шунда күрербез, Вәлинур кемгә карар икән?

Эшнең калган ягын коры тоттылар. Төнгә каршы Нәгыймәне авыл Советына чакырып алдылар. "Кызыма бит әле унбиш тә тулмаган",—дип аяк терәп каршы килүенә дә карамастан, җайлап-майлап аны да ризалаштырдылар, имзасын алдылар.

—Әй, Ходаем, талкыштай талкый бу сугыш,—дип зарланды Нәгыймә кайткач.

—Әнкәй, син инде бигрәк, акчасы булыр ичмасам, өс-башны юнәтербез әзрәк, бөтәеп калырбыз,—дип әнисен юатты Мөкәррәмә.

—Рәхмәт инде кызым, яхшы сүзенә, Нух каргасы очып житмәс жирләргә китәсез бит, чит-ят якларда адәм типкелләренә калмасагыз ярарые дип көям.

—И, әнкәй, кешеләр фронтка да китә әле…

—Ярар инде алайса, синенчә булсын, әйбәткә юрыйк.

Әнисе белән бик батыраеп сөйләшсә дә, аерылышу бер дә жиңел түгел икән. Ара ерагайган саен, күңелдә сагыш көчәя генә барды. Кичкә таба гел авыл турында гына сөйләштеләр.

—Көтү кайткандыр инде, инәкәй сыерны саварга чыккандыр инде,—дип яшьләрен корытып алды Сәмига.—Клубка барыр вакыт та житә…

—Клубның гармуны ватылган иде, төзәттеләр микән?—дип, дустының сүзен күтәреп алды Мөкәррәмә, әйтерсең лә, авылдан чыгып киткәннәренә атна-ун көн вакыт үткән иде.

—Исең китмәсен юкка, мәктәпнекен алып торырлар.

—Тоттырыр безнең директор…

—Кара коелма аның өчен, Мөкәр, бер-ике кич такмакка биерләр…

Кызлар шулай сөйләшә-сөйләшә йокыга талдылар. Нәгыймәнең алмаш-тилмәш дигәне исләренә дә төшеп карамады.

* * *

Казан аларны эчкелтем-төчкелтем сөремле һавасы, буяулары купшакланып беткән ала-кола трамвайлары, йөзләрен борчу баскан арык кешеләре белән каршы алды. Ә кызларның исә беренче мәртәбә шәһәрдә булулары, шуңа күрә кала бик күркәм, бик матур, бик зур булып тоелды.

—Мөкәр, кара әле, кара, биш катлы йорт,—дип шаккатты Сәмига,—безнең авылның янгын каланчасыннан да биегрәк бу.

—Кешеләрне күр син, Бишбүкән базары диярсең.

Кызларны елга порты янындагы агачлыкта төркемнәргә бүлделәр. Бер хәрби, командир булса кирәк, һәрберсенең янына килеп, кыскача гына тәржемәи хәлләрен сораштырды. Буталышып беттеләр. Менә командир Сәмига каршына килеп басты.

—Әмирова!—дип таныштырды кыз пионерларча көр тавыш белән.

—Минем исемлектә Әмирова берәү генә, сез каян килеп чыктыгыз соң әле,—дип сорады тегесе.

—Әмирова!—дип сөрән салды Сәмига янә.

—Сез бер-бер шымчы түгелме?—дип, сафтагыларга күз кысты командир. Ләкин куркак куяндай бөрешеп каткан авыл кызлары мәзәк аңлар хәлдә түгел иде. Үз фамилиясе урынына Мөкәррәмәнең фамилиясен әйтүен хәтта Сәмига үзе дә төшенмичә калды. Башлык тәжрибәле кеше иде, барысын да аңлады, төпченми генә алга таба узды.

Моннан аларны тимер юл вокзалына алып киттеләр. Аралары шактый ерак икән, бара-бара күзләре күгәрде.

—Эржинка* аякны кырды, уф үләм,—дип юл буе зарланып барды Сәмига.

—Баядан бирле лаштыр-лоштыр килеп баргач, уйлаганыем аны,—диде Мөкәррәмә үртәлебрәк.

—Инәкәй Юлдаш әкәеннән бер табак онга алыштырып алган иде, олырак булды шул, каһәр…

—Түзәсең инде…

Аксак-туксак бер Сәмига гына түгел иде, күрәсең, командир нииндидер дуга сыман тимер күпер янында кызларга ял бирде. Җәрәхәтләрне бәйләштереп, бераз хәл алып, янә кузгалдылар. Станциядә аларны товар поездының бер вагонына төяделәр. Ул бик исле иде.

—Бер кичкә—кер мичкә, поезд юлда тоткарланмаса, ике-өч сәгатьтән урында булабыз,—диде командир кызларның хәленә кереп.

Поезд калтырча арба шикелле шакы-шокы килеп бара, колаклары тонып бетте.

Өстәвенә, һава җитми, тын кысыла. Чөнки вагонның тәрәзәләре юк, ә ишекне тышкы яктан бикләп куйдылар.

Мөкәррәмә белән Сәмига вагонның иң түр почмагына кереп йомарландылар, яшь бәтиләр шикелле бер-берсенә елышып утыралар.

—Минем елыйсым килә,—диде Сәмига.

—Минем дә,—диде Мөкәррәмә.

—Әйдә, елыйбыз.

Аларның күзләре инде күптәннән яшь белән тулган иде.

—Бервакытта да инәкәемнең сүзеннән чыкмас идем,—дип мышкылдады Сәмига,—малларны да көтүгә үзем куар идем...

—Безнең авыл оҗмах икән ул, иеме?—диде Мөкәррәмә очкылыгы аша,—бу шәһәр дигәннәренең берниндиен гыйлләсен дә күрмим. Дөбер-шатыр, тавыш-гауга...

Сәмига дустының чәчләреннән сыйпап торды. Кулы йомшак, җылы иде. Рәхәт булып китте.

—Әйдә, Мөкәр, ахирәтләр булыйк, серләребезне дә уртак итик,—диде ул.

—Мин риза,—дип, Мөкәррәмә Сәмиганы кочаклап алды.

Караңгы иде, аларны берәү дә күрмәде.

* * *

Кызларны әштер-өштер генә әмәлләп куелган бер ташландык сарайга кертеп урнаштырдылар. Монда кайчандыр ана дуңгызлар асраганнар, эче бүлем-бүлем итеп бүлгәләнгән.

—Уф, үләм, чучка исе,—дип Сәмига борынын җыерса да аны игътибарга алучы булмады.

Сарайны яңабаштан җыештырып чыктылар: җир идәнгә салам түшәделәр, тишек-тошыкларны мүк белән ямаштырдылар, ватык тәрәзәләргә такта-токта кадакладылар. Кызлар кулы тигәч, ул кеше төсенә керде, яктырып, җылынып китте.

Шушы эшләр беткәч кенә кемнең кайсы взводка теркәлүе, төгәл йокы урыны билгеләнде. Мөкәррәмә белән Сәмиганы беренче взводка язганнар иде. Барысы егерме биш кыз.

—Минем исемем Зөфәр, фамилиям Камалов булыр,—дип таныштырды үзе белән взводный,—миңа "иптәш командир" дип мөрәҗәгать итәрсез, чөнки сез хәрби эштә. Авыл гадәтләрен дә онытып торырга туры килер.

Зөфәр тешләрен шыгырдатып куйды. Аның кырыс һәм җитди йөзендә сүз белән әйтеп бетереп булмый торган ниндидер үпкә, ачу сизелеп тора иде. Яшь булуына да карамастан, кашлары арасында ике тирән сыр буразнадай ярылып ята.

—Аксак, аксак,—дип пышылдашты кызлар.

Зөфәрнең аксак икәнлеге болай да күренә иде. Шинеленең чабуыннан тик бер генә аягы чыгып тора. Гәүдәсе култык таякларына сыланган.

—Мин фашист гадларны дөмектерү өчен барысын да эшләтәчәкмен,—дип, кулы белән һаваны ярды командир. Аның сүзләре туптан атылган ядрә шикелле шартлап-шартлап чыга иде.—Корычтай ныклы тәртип урнаштырачакмын, лодырьларга көн булмаячак. Андыйлар рәхим-шәфкать көтмәсен!

Янә шул ачыкланды, политрук вазифалары да Камаловка йөкләнгән икән. "Көн сәяси әңгәмәләр һәм соңгы хәбәрләр белән таныштырудан башланачак",—диде. Бер сәгать вакыт хәрби әзерлеккә бирелә, калган ун сәгатьтә кызлар окоп казу эше белән шөгыльләнәчәк икән.

—Акча турысында бер сүз дә әйтмәде бит бу абый,—диде Сәмига борчылып,—күпме түлиләр икән?

—Әле эш башламаган килеш нинди акча ул,—диде Мөкәррәмә бик белдекле булып,—акчаны ай азагында бирәләр инде аны...

Кызлар әле һаман акча эшләп, авылга киенеп-ясанып кайту хакында хыялланалар иде.

Беренче атна чагыштырмача җиңел үтте. Көннәр дә матур, җылы иде. Бәләкәйдән үк көрәк тотып үскән авыл кызларына җир казу эше яңалык түгел. Танышу, аралашу арасында сагыну-юксынулар басыла төште. Уртак казанда пешкән кәбестә суына кагылмадылар да. Чөнки өйдән алып килгән ашамлыклары бар иде әле. Сохари, кипкән балык, каклаган каз, кыздырылган эремчек... Әниләре кызларын ким-хур

хәстәрләмәгән. Сугышның икенче елы гына бара, элекке түл бөтенләй үк эреп бетмәгән.

Ләкин алдагы фаҗигале һәм шомлы көннәрнең шәүләсе баш очларында кара кош булып канат җәйгән иде инде. Күп тә үтми, шешнең бер башы тишелеп тә чыкты.

Мөкәррәмәнең алтмыш сум акчасы бар иде. Олтандай ике кәгазь утызлык. Ул аларны биштәрендә чүпрәккә төреп саклый. Көн саен иртән барлап ала. Чөнки аның өчен бу ике кызыл утызлык патша казнасына тиң хәзинә иде.

Ә бүген күз будылар диярсең, таба гына алмый бит шул төргәкне. Биштәренең астын өскә әйләндерде, бушатып һәр әйберен кулыннан үткәрде. Кульяулык урынында, ә акча юк.

—Сәмига, мин акчамны таба алмыйм,—диде Мөкәррәмә еларга житешеп,—әллә урлаганнар инде?

—Уф, үләм, сөйлисең дә инде мәгәр, монда соң комсомоллар гына лабаса! Әйберләрең арасында буталгандыр, җентекләбрәк кара.

—Әйдә, алайса бергә карыйбыз.

Карадылар. Аерым-аерым да, икәүләшеп тә. Тик акча гына табылмады.

Мөкәррәмә еларга тотынды. Аны кызлар сырып алды.

—Акчасын югалткан,—дип тузынды Сәмига.

—Югалтмадым, урлаганнар,—диде Мөкәррәмә яшь аралаш.

—Нәрсә булды, ник шаулашасыз?—дип, яннарына титаклап Камалов килеп житте.

—Әмированың акчасын урлаганнар,—диде Сәмига.

—Какой позор!—дип кычкырып жибәрде взводный,—а-ну-ка, построиться! Становись!

Кызлар этешә-төртешә сафка бастылар. Алар инде маршта да йөри белә, җырлыйлар да, жиде кат тирләрен чыгара Зөфәр.

—Кем эше бу?—дип, янә бугазын киереп кычкырды ул. Күзләрен кан баскан, иреннәре калтырый.—Җә, мин көтәм!

Тып-тын калдылар. Зөфәрнең тешләрен шыгырдатканы аерым-ачык ишетелеп торды.

Култык таякларының очына гына таянган хәлдә Камалов сафның әле бер башына, әле икенче башына ыргылды. Ул шулай оста йөри, гәүдәсен атып-атып кына бәрә, әйтерсең лә, циркта тамашачылар алдында фокус күрсәтә.

— Алайса башка телдә сөйләшәбез,—диде ул тынын еш-еш алып.

Бу вакыйга аны тәмам чыгырыннан чыгарган иде. Алдынгылык өчен җан атып көрәшкән бер вакытта, менә сиңа мә! ЧП! Хурлык бит. Кызларны да кулында тота алмыйсың дип, көләчәкләр ич аннан. Боевой командир лабаса ул!

—Взвод, направо! Прямо шагом марш!

Кыр казлары шикелле тезелешеп, кырга чыктылар.

—Чаще шаг!

Камалов бер биегрәк урынга басып, боерык биреп торды. Кызлар бер алга, бер артка йөгерделәр, тирләп-пешеп беттеләр.

—Җә, кем эше бу?—дип соравын кабатлады взводный. Бу да нәтиҗә бирмәде.

—По-пластунски, марш!

Ун-унбиш минут тузанда аунатканнан соң Камалов хәлдән тайган кызларның һәрберсеннән сорау ала башлады.

—Синме?

Сафның уртасынарак житкәч, ул юантыграк гәүдәле Тәлига исемле Минзәлә кызының күзләренә текәлде.

—Син!

—Мин,—дип пышылдады кыз тузанлы битен ерып төшкән тирен сөртә-сөртә.

—Кайтарып бир!

Тәлига яка эченә яшергән утызлыкларны озак кына тартып чыгара алмый җәфаланды. Куркудан-дулкынланудан аның куллары калтырана иде.

Зөфәр бу көнне үзе дә йокламады, башкаларны да йоклатмады, төне буе окоп казыдылар.

Командир Тәлиганың акча урлавын ничек белде икән, дип үзара шаккатышты кызлар. Югыйсә, моның әллә ни авырлыгы да юк иде. Чөнки Минзәлә кызы бу вакыйга алдыннан гына казармада дежур торган иде. Теләгән кешегә башкалар эштә чагында

биштәрләрне мең мәртәбә тентеп була лабаса.

Зөфәр моны башта ук сизенде, әмма сабак булсын дип җәзаны юри сузды. Ә Тәлиганы икенче көнне үк яңа урынга күчерделәр.

* * *

Монда һәр гамәлне фронт белән басалар, фронт белән изәләр. Төп сүз, әлбәттә, Сталинград янында барган дәһшәтле сугыш турында. Немецлар Мәскәүгә Идел буйлап үрмәләргә омтылалар. Әгәр ниятләре барып чыкса, бөтен Рәсәйне туйдыручы Идел—Кубан бассейны алар кулына эләгергә тиеш. Ул чагында Советлар Союзы чыннан да озакка тарта алмаячак. Гитлерның да, Сталинның да язмышы Идел буенда хәл ителә. Моны үзләре дә аңлый, билгеле. Шуңа күрә корбаннарны чутлап та тормыйлар, кешеләр чебен урынына кырылды, аларның төгәл генә исәп-хисабына да чыгарлык түгел. Сугыш аждаһасы меңәрләгән солдатларны берләштергән армияләрне бер-бер артлы йотып кына тора.

Гитлер, фельдмаршал Паулюс җитәкчелегендәге гаскәр төркеме камалуга эләккәч, теләктәшлек йөзеннән үзенең көндәлек гадәтләренә дә үзгәрешләр кертте. Ул немецларга гына хас төгәллек белән һәр якшәмбедә, нәкъ кичке сәгать унда, йокы бүлмәсендә җариясе белән очраша иде. Фюрер юан ботлы, арт саннары салыныбрак төшкән яшь актрисаларны хуп күрә. Ә кеше алдына исә камыштай төз гәүдәле Ева Браун белән чыга. Камалыш вакытында ул актрисаларын читкә этәреп, булачак хатыны белән генә канәгатьләнде.

Сталин да сәхнә йолдызлары белән мавыкты. Ул сайлаган гүзәлен иң элек күңеленнән чишендереп карый иде. Күзләрен бер генә сөзеп ала, кичен инде ул актрисаны аның катына кертәләр. Юлбашчыга зур имилеләр охшый иде. Гитлердан аермалы буларак, гадәтләре сугыш вакытында да үзгәрешсез калды.

Сталинның күңеленә бер генә тапкыр таракан кереп алды. Әле аның анысы да куркудан битәр, астан уеп, өстән җуюга юнәлтелгән мәкерле хәйлә генә иде.

Хәле мөшкел иде юлбашчының. Мактаулы Кызыл Армия сугышның беренче көннәреннән үк үзенең черек нигезгә корылганлыгын күрсәтте. Бернинди житди каршылыкка очрамыйча немец гаскәрләре Мәскәүгә кадәр килеп җитсен әле. Ил тез чүгү алдында...

Сталин көннәрдән бер көнне Кремльгә килмәде. Авырып китте микән әллә, дип борчылды көрәштәшләре. Көне буе үзләренә урын таба алмыйча йөрделәр. Ә кич Политбюро әгъзалары Ворошилов җитәкчелегендә дачага, Кунцевога юнәлделәр. Сталин аларны ачык чырай белән каршылады. Әмма кәефе начар иде.

—Мин партиянең дә, халыкның да ышанычын акламадым,—диде ул төшенке тавыш белән,—җитәкчелеккә яшьрәк, энергиялерәк башка берәүне куярга кирәк дип саныйм.

Бермәлгә бүлмәдә кабер тынлыгы урнашты. Кешеләрнең тын алганнарына кадәр ишетелеп торды.

Шулвакыт Ворошилов Сталин каршына килеп тезләнде.

—Коба, акылыңа кил, син бөек юлбашчы, ил өстенә төшкән бу афәтне син генә алып ташлый аласың, тизрәк Кремльгә кайт,—диде.

Шушы вакыйгадан соң Сталин бернәрсәдән дә тарсынып тормады, ни теләсә, шуны эшләде.

Ул чактагы пропаганданы патшаларның ничек типтерүе кызыксындырмый иде, билгеле. Әлеге мәгълүматлар алар бу фани дөнья белән хушлашкач кына өскә калкып чыкты. Ә кырылуларны пропаганда бөек батырлыкка тиңли иде.

Татарстанның Мари урманнары белән чиктәш бер ерак районында окоп казучы авыл кызлары да шул бөтергечтә бөтереләләр. Көннең бисмилласы—сәяси уку. Әле бүген дә Зөфәр взводны фронт яңалыклары белән таныштырды.

—Немец, гад, ничек кенә тартышмасын, җиңү безнең якта булачак!—дип нокта куйды ул кереш сүзенә. Сораулар булмасын алдан белеп торса да, гадәтенчә: "Кемгә нәрсә аңлашылмады?"—дигән сөален бирергә дә онытмады, бу югарыдан куелган методик таләп.

Тик бүген берсе аваз салды:

—Мөмкинме?—диде.

Зөфәр аптырабрак торды, чөнки ул авылны аңгырага, кызларны томанага саный иде.

—Нәрсә бар, Әмирова?—дип, Мөкәррәмәгә мыскыллабрак карап торды.

—Соравым бар,—диде кыз тыныч кына,—менә сез үзегез үк әйтәсез бит, немецлар барыбер монда кадәр килеп җитмәячәкләр, дисез. Алай булгач, интегә-интегә нигә казыйбыз соң без бу акупларны?

—Как так?..

Зөфәр бер генә мизгелгә төртелеп калды. Мөкәррәмәне бу аполитичный соравы өчен тетеп салырга кирәк иде. Ул шулай хәл итте дә. Чөнки армиядә командир сүзен шик астына куймыйлар, бернинди каршылыксыз үтиләр генә. Кара син бу авыл күркәсенә, нинди сорау биреп маташа бит.

Соңгы минутта гына Зөфәр тыелып калды. Дөресрәге, кызның күз карашы аны шулай сихерләде. Мөкәррәмә сабый бала шикелле мөлдерәп карап тора, гүя олы абыйсыннан яклау, хуплау көтә. Үзе дә сизмәстән егет сорауны уенга борды.

—Оппортунист син, Әмирова, менә кем,—диде ул ирен очлары белән генә елмайгандай итеп. Бу сүзнең мәгънәсенә төшенеп җитмәсәләр дә, кызларның авызы ерылды.

—Җә, җитте, шаярыштык, инде иң мөһим мәсьәләгә күчәбез,—диде Камалов кырыс кыяфәткә кереп.—Узган дәрестә мин сезгә иптәш Сталинның төп вазифалары турында сөйләгән идем. Шуларны кабатлап китик. Кем җавап бирергә тели?

—Мин,—диде Сәмига. Аның да дустыннан калышасы килми, телгә керәсе, игътибар үзгенә басасы килә иде. Тезеп китте:—Иптәш Сталин... ВКП(б)... персидәтел... үзәк... баш командующий... оборона...

—Туктале, тукта, нинди ботка бу, һич аңламыйм,—дип, Зөфәр кулларын буташтырды.

—Президиум... баш командующий... оборона комитеты... иптәш Сталин...

—Стоп! Стоп! Стоп!

—Мин өйрәндем, абый, мин беләм...

—Беренчедән, абый түгел, ә иптәш командир, икенчедән, черт знает что... хватит...

Бу туң күчәннәргә тагын бер тапкыр аңлатмый булмас, ахры, дип уйлады Камалов. Комсомоллар бу сорауга җиде төн уртасында уятып сорасалар да чатнатып җавап бирергә тиешләр. Муштра җитми боларга, муштра!

—Иптәш Сталинның вазифалары бик күп,—дип сөйләп китте ул.—Колагыгызга киртләгез, мәңгелеккә уелып калсын. Әлегә биш вазифасына тукталабыз, тора-бара калганнарын да тәфсилләп аңлатырмын. Итак, иптәш Иосиф Виссарионович Сталин ВКП(б) Үзәк Комитетының Генеральный секретаре—бер; Баш командующий—ике; Дәүләт оборона комитеты председателе—өч; Оборона наркомы—дүрт; СССР Верховный Советы Президиумы члены. Булдымы—биш!

* * *

Шушы көннән башлап Зөфәр Мөкәррәмәне күз уңында тотты. Кызның тапкырлыгы, фикер хөрлеге, һәр сүзнең очын эзләктереп ала белүе ошый иде аңа. Бу сыйфатлар, әлбәттә, армия идеологиясенә туры килеп үк бетми бетүен. Армиядә акыл сатучыларны өнәмиләр. Зөфәр үзе дә шундый тәрбия алган кеше. Ә бу кыз әйткәнне ничек бар шулай кабул итми, аны акыл иләге аша уздыра. Чыннан да, әгәр җиңүнең безнең якта булуы бәхәссез икән, нигә фронттан мең чакырым ераклыкта окоп казып азапланырга? Формаль яктан караганда, бу дөрес тә кебек, ләкин хәрби стратегиянең үз кануннары бар шул.

Әйтерең бармы, тискәре нәмәрсә. Үзе чибәр генә күренә. Чем кара чәчле чын татар кызы. Иреннәре калын, сусыл...

Зөфәрнең күзләре еш кына Мөкәррәмәнең күлмәген ертып чыгардай булып кабарган тулы күкрәк алмаларында озаклап тоткарлана, карашы белән билен сыйпап уза, балтырларын капшый... Ләкин ул игътибарын белгертми, элеккечә усал, элеккечә кырыс, элеккечә тәкәббер. Кечкенә гаеп өчен дә җәзага тарта. Кызларны тирләтә-тирләтә кросс йөгертүдән, егылганчы марш атлатудан тәм таба. Иң гаҗәбе шунда, ул үзе дә алар белән бергә атлый, бергә йөгерә. Әйтерсең лә, ике аяклы тап-таза ир-егет. Кызлар мышкылдый-мышкылдый аның артыннан көч-хәл белән җитешеп баралар.

Әле хәзер дә бер кызның стройга соңаруы аркасында бөтен взводны кыр буйлап әйләндереп кайтарды.

—Әмирова, минем белән станциягә бүген син барасың, ватык инструментларны

ремонтка илтәбез,—диде ул эш бүлешү вакытында.

Гадәттә иртән китеп, әбәткә әйләнеп кайтып җитәләр иде. Ә бу юлы ат бушамау сәбәпле, төштән соң гына кузгалдылар. Рәтлисе әйберләре дә шактый булган икән, йөк шактыйга җыелды. Шуңа күрә атны атлатып кына, ашыкмыйча гына бардылар. Мөкәррәмә дилбегәне тотып, арбада утыра. Зөфәр култык таякларын шыпылдата-шыпылдата арттан теркелди. Мөкәррәмә дә кыенсынып, арбадан төшеп караган иде дә, тегесе бик каты торды.

—Урыныңнан кузгаласы булма,—дип боерды.

Мөкәррәмә казарма тәртибенә күнегеп килә иде инде. Шуңа күрә эченнән тынды. Басуда кеше-мазар күренми. Тезелешеп утырган эскертләр генә монда күптән түгел киеренке эш кайнаганын күрсәтеп тора. Бөтен җир буш. Агач ботакларында берән-сәрән эленеп калган сары яфраклар бу бушлыкка ниндидер чарасызлык, сагыш өсти иде. Хәтта яшеллеген беренче кар төшкәнче саклый торган бәбкә үләннәре дә коры кура арасында җеп шикелле чуалышып яталар.

Мөкәррәмәнең йөрәге чеметеп алды. Их, көз кырые белән генә булса да авылны кайтып күрәсе иде, дип үрсәләнде. Бик матур бит аларның авылы, бик күркәм. Ул суы тәмле, ул җире йомшак. Кешеләре—әүлия. Бу чатакның теленә кермәс өчен әллә ни бирерсең, акыра да бакыра, котырынган үгез шикелле, күзенә ак-кара күренми...

—Атыңны каула!

Взводныйның сүзләре Мөкәррәмәне сискәндереп җибәрде, әйтерсең лә, Зөфәр аның уйларын укый иде. Еш-еш дилбегәсен тарткалап алды. Бахбай да адымын кызулатты. Озакламый станциянең озын торбасы күренде, үргә менеп җиткәч, станция үзе дә калкып чыкты. Карга оясы кебек бер түгәрәккә оешып утыра. Шул түгәрәктән агач тамырларыдай чит-читкә йортлар аяк сузган. Китек-митек урыннары да шактый. Шуңа күрә ул еррактан ясалып бетмәгән рәсемне хәтерләтә иде. Мөкәррәмәгә монысы да ошамады, үзебезнең якларга җитәме соң, дип уйлады.

Әйберләрне тапшыргач, вокзалга сугылдылар. Зөфәрнең йомышы бар иде булса кирәк. Кайдадыр кереп-кереп тә чыккалады. Берара бөтенләй югалып ук торды.

Вокзал алды мәйданы гөж килә. Кая бара бу халык, нишләп йөри, һич аңламассың. Кайсы капчык аскан, кайсы биштәр таккан. Чемоданлылары да бар. Шунда ук җигүле атлар, аларның бу ыгы-зыгыда гамьнәре юк, алларындагы печәнне ашыкмый гына чемченүләрен беләләр. Әллә кайлардан кеше җыйганчы менә кемнәрдән окоп казытырга иде.

Як-ягына карана-карана Зөфәр килеп җитте. Төенчеге дә бар. Аны култык таягының тоткасына бәйләп куйган, атлаганда шып-шып итеп бәрелеп ала.

—Хәзер поезд килә, көтик инде бераз,—диде.

Озак та тормый поезд килгәне ишетелде. Станциягә җитәрәк ул йөрешен акрынайтты. Тәгәрмәчләр рельсны ашардай булып сызгырыштылар, хәтта араларыннан очкыннар сибелде. Ләкин тормоз үзенекен итте, тәгәрмәчләргә чытырдатып йозагын салды. Шундук ишекләр ачылды, вагоннар эченнән кайсының кулы, кайсының аягы, кайсының башы марля белән уралган яралы солдатларның таушалган йөзләре күренде. Лавадан чыккан шахтерлар сыман күзләре генә ялтырый.

Зөфәр төсен җуйган бер вагон янына очып диярлек барып басты.

—Братаны, откуда?—дип кычкырды.

—Сталинград!

—А где тебя?

—Под Москвой, гады!

—Земляк, айда, за знакомство. Как тебя?

—Зуфар!

—Меня Сергеем зовут.

Сергей үрелеп сыңар кулы белән яңа дустына калай кружка белән хәмер сузды. Зөфәр аны авызына каплап кына куйды.

Поезд, озын итеп кычкыртып алды да, уфылдый-уфылдый урыныннан кузгалды.

—Прощай, Зуфар!

—Прощай, Сергей!

Зөфәр, тимер юлның уртасына басып, санитар поезды күздән югалганчы аның артыннан күз карасын түгеп карап калды.

—Бер эшелон калека,—диде ул Мөкәррәмә янына килгәч,—гады!

Кыз куркып калды. Анын Зөфәрне мондый тугарылган хәлендә күргәне юк иде әле. Хәмерне авыр күтәрә иде ахры командир. Иреннәре өреп тутыргандай булып кабарган, күзләре пыяла төсенә кергән, карашы ямьсез.

Башта ул немецларны, ниндидер булдыксыз командирларны сүгеп кайтты. Мөкәррәмә оялып бетте, чөнки анын авызыннан шактый гына чи сүзләр дә ычкынгалый иде. Ахыры түзмәде, колакларын учы белән каплап, борылыбрак утырды. Файдасы гына тимәде, Зөфәр мылтыктан аткандай шартлатып сөйли.

Бераздан җырлый башлады. Тавышы көчле, әмма ятышсыз. Җыры әйбәт. "Катюша"ны ул вакытта бөтен ил җырлый иде.

*...Про того, которого любила,*
*Про того, чьи письма берегла...*

Ярты сәгать чамасы Зөфәр сыры ашалган патефон табасы шикелле, җырнын шушы өзеген кабатлады. Җырлый-җырлый йоклап та китте. Мөкәррәмә, ниһаять, иркен сулыш алды. Аякларын арба өстенә куеп, җайлап утырды да, командиры үрнәгендә, эченнән генә белгән җырларын җырлап алды. Тик бу анын кәефен күтәрмәде, киресенчә, боегуы гына артты. Искәрмәстән битенә тамган ике-өч бөртек тамчы аны бу еламсык хәленнән тартып алды.

Тамчылар ешайды. Күтәрелеп бакса, күкне болыт каплаган икән ләбаса! Станциядән чыкканда урман очында яшәреп килүче өер-өер болытлар күзенә чалынган иде чалынуын. Зөфәр аны үзенен сүгенүләре белән шундук оныттырды. Хәер, яңгырга каршы килеп була димени? Явам дисә, ява инде ул. Ничек кайтып җитәрләр менә. Аты ат төсле булса икән, Агыйдел болыннарында йөргән Түбән Сөн атлары юк шул инде монда.

Юл читендәге куакларны пыран-заран китереп, җил бөтерелеп алды. Ул үзе белән ишеп-ишеп яңгыр да алып килде.

Күзләрен уа-уа Зөфәр торып утырды. Керфекләреннән, ияк очларыннан тып-тып су тама. Зөфәр аларны кул аркасы белән сыпырып төшерде дә, дилбегәне үз кулына алды. Ат ир кешенен каты кулын тойды, күрәсен, адымнарын ешайтты. Әмма яңгыр юлны шактый изеп өлгергән иде шул инде. Шуңа күрә бу житезлек озакка сузылмады.

Ә болыт куна килгән иде. Җил тынды, яңгыр инде утырып ява башлады. Икесенен дә өсте лычма су булды, күшегеп беттеләр. Бираз исемле мари авылына килеп кергәндә караңгы төшеп килә иде инде.

Зөфәр атын бер кечкенә өй янына китереп туктатты.

—Капканы ач,—диде ул Мөкәррәмәгә. Бу анын йокысыннан уянгач әйткән беренче сүзе иде.

—Әле соң кайтып җитмәдек бит,—диде кыз кыюсыз гына.

—Мин кайтып җиттем,—диде Зөфәр,—син дә шушында кунарсын, киемнәрне дә киптерергә кирәк. Хәзер мичкә ягып җибәрәм. Җылынырбыз.

Зөфәр, атны тугарып, абзарга кертеп япты да Мөкәррәмәгә дәште.

—Син бу утын пүләннәрен ал инде, миңа җайсызрак,—диде унайсызлангандай.

Өйгә аллы-артлы керделәр. Мөкәррәмә кеменнендер каршы алуын көткән иде, ләкин бер җан иясе дә күренмәде.

—Хәзер ут алам,—дип сөйләнде Зөфәр,—мин шушында яшәп ятам инде, вакытлыча...

Мөкәррәмә коелып төште. Ничек итеп ул шушы гыйфрит белән икәүдән-икәү бер өйдә кунсын ди, булмаганны. Төнне ат янында, абзарда уздырырга да әзер, күзенә генә күренмәсен. Ләкин Зөфәр анын ризалыгын сорап тормады, барысын да үзенчә эшләде.

Өй курчак өе чаклы гына иде, шуңа күрә бик тиз җылынды.

—Мин чыгып торам, син киемнәреңне алыштыр да кибәргә куй,—дип Зөфәр Мөкәррәмәгә гимнастерка белән галифе чалбар тоттырды.—Җәтрәк кылан, минем дә шул эшне эшлисем бар.

Кызга буйсынудан башка чара калмады. Әле ярый, айныды, дип үзен юатып та алды. Шулай да ишеккә килә салды.

Бу мәшәкатьләр тәгәлләнгәч, хуҗа табын әзерләде. Станциядә паегын алган икән. Өстәл өстенә ит консервасы, бер буханка ипи, май, шешәле сөт, ике-өч кисәк шикәр шакмагы чыгарып куйды. Мөкәррәмәнен авызыннан сулар килде. Анын күптәннән инде бу ризыкларны татып караганы юк иде. Алай да сер бирергә ярамый. Шуңа күрә

аларны күрмәс өчен өстәлгә яны беләнрәк борылып утырды.

—Табынга рәхим ит, Әмирова,—диде Зөфәр,—чәй ясау синең өстә. Анысы әле соңрак...

—Рәхмәт, минем ашыйсым кил...

Зөфәр аны ярты юлда бүлдерде.

—Утыр!

Мөкәррәмә куркынып кына артын буш урындыкның бер читенә терәде.

—Солдат киемендә матуррак та икән әле син,—дип, Зөфәр кызга сөзеп карап алды. Мөкәррәмә оялуыннан башын түбән иде.

Зөфәр стаканнарга хәмер агызды.

—Бу дару,—диде ул табибларга хас вәкарьлек белән,—чахотка эләктерәсең килмәсә, төбенә кадәр эчеп бетер.

Мөкәррәмә борынын җыерып, урындыгын читкәрәк шуыштырды. Ләкин Зөфәр чигенергә уйламый да иде.

—Ну, кемгә әйтәләр!—дип чекрәйде.—Мин синең өчен җавап тотам.—Йомшара төшеп:—Әниең янына исән-сау кайтасың да бар бит әле,—диде.

Әлбәттә, Мөкәррәмәнең әнисе янына исән-сау әйләнеп кайтасы килә. Тик бу сасы әйберне ничек капмак кирәк?

—Артыннан ук күп итеп су эч,—дип өйрәтте Зөфәр,—әчесен сизми дә калырсың.

Кая ул сизмәгән? Үләксә йотсаң да болай булмастыр, мөгаен. Мөкәррәмәнең иң элек тыны куырылды, әйтерсең лә, тамагына ут төрттеләр. Аннан соң борынына чәберчек йомырка исенә ошаган сасы ис капланды, күзләреннән яшь атылып чыкты. Косып җибәрмәс өчен учы белән авызын япты.

—Су эч, су!—дип, Зөфәр кәчләп диярдәй су эчерде.

Бер-ике минуттан бу үтергеч халәте үтте, эченә кайнар дулкын йөгерде, күңелен моңарчы аңа таныш булмаган ниндидер битарафлык биләп алды, курку-шикләнүләре эреде дә китте. Елыйсы килә башлады, ул да булмады, сәбәпсездән авызы ерылды.

Зөфәр янә юлдагы җырын ялгап җибәрде.

*Про того, которого любила,*
*Про того, чьи письма берегла...*

Мөкәррәмә егеткә күтәрелеп карады, карашын озак кына алмый торды. Баягы шикелле күзләре керәчләнгән иде Зөфәрнең. Иреннәре дә бүртенгән. Тик бу кырыс йөзнең үз матурлыгы бар иде. Әлеге матурлыкның асылы шунда, ул ничектер Зөфәргә килешә иде, өлкәнәйтебрәк җибәрә.

Кызык, дип уйлады Мөкәррәмә, бу кешенең сөйгән кызы бар микән?

Уйларының ахырына барып җитә алмады, Зөфәр өстәлгә китереп сукты.

—Гады!

Мөкәррәмә айнып китте.

—Әмирова, беләсеңме, мин бит кадровый офицер! Миңа әле егерме биш яшь тә тулмаган. Минем служаклар фашист белән йөзгә йөз килә. Мин инде бервакытта да хәрәкәттәге армияга кире кайта алмаячакмын. Сугыш кырында башымны салган булсам, бу хурлыкларны күрмәгән булыр идем. Ә хәзер уңны-сулны аера белмәгән надан авыл кызларыннан окоп казытам. Позор!

Зөфәр башын өстәлгә салып, үксеп еларга тотынды. Мөкәррәмә аны ничек дип тә юатырга белмәде, фәкать чын күңелдән кызганды гына. Ир-егетнең елавын ишетү үзе бер газап икән.

Мөкәррәмә мич авызына күз төшерде. Андагы кузлар сүнеп кара күмергә әверелгән иде инде. Мөгаен, киемнәре дә кипкәндер—бөтен батырлыгын җыеп урыныннан торды да, өйнең яртысын биләп алган мич янына килде, күлмәкләрен тотып карады. Алар әзер иде.

Ул киемнәрен алыштырып өйгә кергәндә, Зөфәр берни булмагандай өстәл тирәсендә кайнаша иде. Башын борып, Мөкәррәмәгә текәлде.

—Сиңа хәрби кием килешәрәк төшә иде.

—Чәй ясаргамы?

—Взводта иң чибәре син,—диде Зөфәр аннан күзләрен алмыйча.

Мөкәррәмә калтыранган куллары белән өстәлдәге чәйнеккә үрелде. Бу гадәти сүзләр артында ниндидер ярсыткыч мәгънә ята. Бу көн кебек ачык. Менә хәзер нидер булырга тиеш, ул аны бөтен күзәнәкләре белән сизеп-тоеп тора. Җил-давыл куган

болытларны туктатып булмаган шикелле, бу өермәне дә тыя алмаячаксың. Ул котылгысыз. Шуңа күрә Зөфәрнең кочып алуын Мөкәррәмә үзе көтеп алды. Тыпырчынмады да, кычкырмады да. Егетнең энәдәй тырпайган төкләре сыдырып-сыдырып битен тырмады. Ләкин ни өчендер ана рәхәт иде.

Зөфәр култык таякларын читкә бәрде дә, бер аягында басып торган хәлдә, кызны күтәреп караватка салды. Шунда гына Мөкәррәмә телгә килде.

—Кирәкми, Зөфәр абый, кирәкми дим, Зөфәр абый…

Тик егетне туктатырлык көч бу дөньяда юк иде инде. Иң әүвәл идәнгә Мөкәррәмәнең киемнәре очты, алар артыннан үзенекеләр…

Тарткалашкан арада Мөкәррәмәнең кулы ялгыш егетнең яралы аягына тиеп китте. Ул бот төбеннән диярлек киселгән иде. Төп-төз аяктан бастырык башы кадәрле генә ит бүкәне тырпаеп калган…

Мөкәррәмә бер генә мизгелгә уяулыгын җуйды. Зөфәр аннан бик оста файдаланды, кулын читкә шудырды. Әмма егетнең шатлыгы озакка бармады. Чөнки кызның сүс бау белән чияләп бәйләнгән алача штанын салдыру аның көчле кулларыннан да килә торган эш түгел иде.

Еш кына Мөкәррәмәне әнисе: "Билдән түбән үзеңә дә ышанма",—дип кисәтә иде. Күрәсең, ул нәкъ менә шушындый хәлләрне исендә тоткандыр.

Сүс бауны пычак белән генә кисеп өзәргә була иде, тик ни сәбәпледер бу уй Зөфәрнең башына килмәде. Бәхетенәме, бәхетсезлегенәме, Мөкәррәмә исән калды.

Шушы хәлләрдән соң ул төшендә Вәлинурны күрде… Солдат киеменнән иде. Йөзе борчулы. Сынар каенга сөялгән дә моңсуланып җыр җырлый:

*Кулымдагы йөзегемнең,*
*Исеме Мөкәррәмә.*
*Ятлар куенына керДең,*
*Йөрәгем өзгәләнә.*

—Әһә, терсәгеңне тешләр чагың җиттемени, күрмәмешкә салынып кына китеп барган идең дә,—дип, иреннәрен кыйшайтты Мөкәррәмә.

Вәлинур сагышлы күзләрен тутырып карап торды.

—Нигә, әллә дөрес әйтмимме?—диде Мөкәррәмә.

—Дөрес,—дип башын түбән иде Вәлинур,—саташып йөргән чаклар иде бит…

—Бик исе китте Өммиянең, налог кешесенә ябышкан иде ич инде ул.

—Миңа син кирәк, Мөкәррәмә…

—Мин сиңа кульяулык чиккән идем, бирергә җае гына чыкмады…

—Чынлапмы?—дип җанланып китте Вәлинур,—син мине яратасың, иеме?

—Яратам, бик яратам…

—Алайса нигә ул титакның куенына кердең соң?

Мөкәррәмә тотлыгып калды... Уянган иде инде. Уянган булса да әлеге сорауга барыбер җавап таба алмады.

Зөфәр белән алар башка очрашмадылар. Чөнки аны хәрби комиссариатка алдылар. Хәзер шунда эшли. Гомумән, Мөкәррәмә Зөфәргә ачу тотмый. Берәү җәфалап, эштән чыгарып бетергән булыр иде. Ул исә вакытында чигенә белде, көч кулланмады. Ә иртән үзен, берни булмагандай, галәттәгечә кырыс һәм тәкәббер тотты.

* * *

Бүген эшләре үрчемәде. Тагын ташлы катламга килеп төртелделәр. Монда җир әллә нинди, кыстыбый кебек катлам-катлам. Кайбер урыннары тигәнче үк ишелергә тора, шунда рәттән генә көрәкнең очын да кертә алмыйсың. Бригадир (эш вакытында алар белән бригадир җитәкчелек итә) болар белән чутлашып тормый, бар белгәне: "әйдә дә әйдә". Шуңа күрә үзенә Әйдәгаллэм дигән кушамат та тагып куйдылар. Әле дә искәрмәстән генә яннарына килеп басты, бүртенгән.

—Авызыгыз белән карга тотмагыз, кызлар, җәтрәк, икенче взвод планын үтәде инде, әйдә-әйдә,—дип тезеп китте.

—Көрәк керми бит ,—диде Мөкәррәмә,—җир беләүләнеп каткан.

—Лом белән, кызлар, лом белән… иплэп кенә, җайлап кына…

—Галләм абый, үзегез күрсәтегез әле, ничегрәк җаен китерергә соң,—дип Мөкәррәмә кызларга күз кысты. Бригадир кыйналган бүре иде, алай тиз генә капкынга керергә ашыкмады. Хәйләкәр генә елмаеп куйды да, шадраларын елкылдатып әйтте:

—Кул белән тотып, кызлар, кул белән, җә, әйдә-әйдә…

Галләм пулеметтан сиптергәндәй әйтәсен әйтте дә үз юлына китеп барды, анын кул астында кеше күп.

Сәмига бу сөйләшүләрне чынга алды, күрәсең, "Уф, үләм, адәм тәгәнәләре, каян әле, мин аны үзекәем хәзер әфтәрләп ташлыйм",—дип, ломга килеп ябышты.

—Кит, чебеш, борыныңнан тотсаң җаның чыгарга тора, сукәлмә, җә бәла булырсың,—дип, Фатыйма исемле кыз анын кулыннан ломын тартып алды.

Сәмига соңгы вакытта дөрестән дә бик бетереште, тәнендә чеметеп алырлык та ите калмады. Җир эше болай да авырлардан санала. Өстәвенә, ашау каты-коты. Җаннарын ничек асрыйлар әле, көнгә ике мәртәбә бирәр җамаяк кәбестә суы бирәләр дә, бер сынык ипи. Анысы кече телгә дә йокмый. Өйдән килгән байлыклар инде күптән вәссәлам. Сәмигага исә кәбестә ярамый икән, битенә тимгел бәреп чыга. Шуңа да карамастан, үзен бик кәттә тота. Әнә, хәзер дә юка иреннәре чалшаеп китте.

—Браматка чыкмадым әле,—дип, зазурлана-зазурлана эшенә керешә. Тик ташлы җирнең генә бирешергә исәбе юк, ломны бүксә шикелле атып-атып кына бәрә.

—Их, бу кызны боханы чыкканчы ашатасы иде, кыланып та күрсәтер иде мәгәр,—дип көлде Фатыйма.

Сәмига кеше сүзен колагына да элми. Менә ломны бар булган көченә янә ташка орды. Әллә ныграк көчәнеп ташлады, әллә җайсызрак басып, аягы таеп китте, ничектер күзләре әлле-мәлҗе килеп алды да чокыр эченә сыгылып төште.

Бу шундый көтелмәгәндә булды ки, кызлар бермәл нишләргә белмичә аптырашып тордылар. Фатыйма гына югалып калмады, тиз генә су алып килеп, Сәмиганың маңгаена су койды. Сәмига күзләрен ачты, елмайгандай итте. Йөзе кәгазь шикелле ап-ак иде.

Мөкәррәмә бригадир артыннан йөгерде.

—Галләм абзый, Сәмигага әллә нәрсә булды,—диде еларга җитешеп.

—Күрәм,—диде тегесе коры гына.—Ә сез нәрсәгә җыелдыгыз, аю биетәләрме әллә?!—дип, ул кызларны ачуланып ташлады,—эшегездә булыгыз, әйдә-әйдә!

—Кая, мин дә…—дип Сәмига да кузгалмакчы итте.

—Кабаланма, бераз ял итеп ал,—диде аңа Галләм,—ә син, Әмирова, менә шушы язу белән кухняга бар.

Галләм бу хәлнең ачлык галәмәте икәнен бик тиз аңлап алды, тәҗрибәсе бар иде, чөнки моңа кадәр дә булгалады андый очраклар.

Мөкәррәмә әлеге язу буенча зур гына телем ипи, шикәр, сөтле чәй алып килде. Сәмига аларны ялт иттерде, хәлләнеп киткәндәй булды. Аны әле тагын өч көн дәвамында казан тирәсендә тоттылар. Аякка басты тәки. Тик кәбестә суына кучкач, янә күтәрәмгә калмасмы, дип борчылды Мөкәррәмә. Анын үзенең дә вакыт-вакыт башы әйләнгәли. Сәмига хәленә калуың да бик ихтимал. Өстәмә азык бик ярап куяр иде. Тик аны каян алырга? Уйлана торгач, әмәлен дә тапты шикелле.

Мәктәптә укыганда аларны колхозның инде алынып, эше беткән бәрәңге басуына йөртәләр иде. Казыштырып чүпли торгач, хәтсез бәрәңге җыялар иде. Монда да бардыр лабаса ул бәрәңге җире! Мөкәррәмә көндезге ял вакытында тирә-якны караштырып кайтырга ниятләде. Ләкин юлы уңмады. Кая барса да салам эскертләренә барып төртелде. Хәерчегә җил каршы, булмады инде бу дип, кул селтәргә исәпләгәндә генә Зөфәр белән станциягә сәяхәте хәтеренә төште. Алар кунган мари авылы урман читенә утырган иде, шырпыдай төз чыршылар өйләргә авам-авам дип кенә тора иде. Юл шул урман чите буйлап сузыла да, тау итәгендә капыл гына борылыш ясый. Әнә шунда Мөкәррәмәнең күзенә буш басу чалынып киткән иде. Бәрәңгене алып бетергәннәр икән инде, безнең авылда соңармадылар микән, дип уйлап куйган иде. Менә кая барырга кирәк аңа! Ерак түгел ул, тау төшәсе дә урман ягына каерыласы. Иренмәде, барып тикшереп кайтты. Һәм икенче көнне төш вакытында берничә кызны ияртеп, шул тарафка юнәлде. Буш кул белән кайтмадылар. Учак ягып, туйганчы бәрәңге пешереп ашадылар. Күңелләре күтәрелеп китте кызларның. Ә яшьләр булган җирдә уен-көлке.

—Әйдәгез, йөзек салышлы уйныйбыз,—дип уртага атылып чыкты Сәмига.

—Әйдәгаллләм агаң аттан узып карама тәртә булып йөрүеңне ошатыр микән соң?—диде җор телле Фатыйма.

—Исем китте бик, Зөфәр солдатка да баш бирмәдек без. И-их!

Сәмига орчыктай бөтерелеп биеп китте. Үзе такмак әйтә:

*Карурмандагы яфрак,*
*Зимагурга олтырак;*
*Ник моңаймасын ул мескен,*
*Туган иле бик ерак.*

—Тукта, житте!—дип, Фатыйма Сәмиганы жилтерәтеп алды.—Шушы да булдымы жыр? Алдынгы совет яшьләре менә мондыерак жыр жырлыйлар.

*Комсомоллар эшкә бара,*
*Иңбашында көрәге;*
*Алтмыш буржуйны куркыта*
*Бер комсомол йөрәге.*

—Дөрес! Бик дөрес, Хамматова, без зимагур түгел, ә ил сагында торучы патриотлар. Безнең сафларда төшенкелеккә урын юк! Бәхетле тормышыбыз өчен без иптәш Сталинга рәхмәтле булырга тиеш.

Әлеге сүзләрне әйтүче бригадир Галләм иде. Кызларның колаклары шәм булды. Югыйсә, бу алар өчен уен гына иде, гади бер шаяру. Ә бригадир чынга алганга ошый. Посып кына тыңлап торуын күр син. Шымчы!

Киеренкелекне Фатыйма йомшартып жибәрде.

—Киңәшләрегез бик урынлы, Галләм абый, рәхмәт,—диде ул житди бер кыяфәт белән,—комсорг буларак, кимчелекләремне таныйм, тәрбия эшен бик тә яхшыртасы бар әле, бик тә…

Галләмнең күңеле булды ахры, калын иреннәрен ялмап алды.

—Хәзер, кызлар, эшкә, әйдә, әйдә…

Ул китеп күздән югалгач, туйганчы көлештеләр. Кәеф күтәренкелеге көне буена барды, тук корсакка эш тә жиңел кебек иде. Көрәк чыны еракларга ишетелеп торды, әйтерсең лә, печән өсте.

Кичен дә сайраштылар. Элек алар һаман авыл, әти-әниләре, туган-тумача турында гына сөйләшәләр иде, күзләреннән яшь кипми иде. Чөнки аерылышу жәрәхәтеннән сагыш булып кан саркып тора әле. Вакыт үтү белән ул жәрәхәт акрынлап бөтәште. Сагыну баштагы мәлдәге шикелле йөрәкне алай ук телгәләми иде инде. Кеше ачлыктан кала барысына да күнә, яраклаша икән.

Бүген алар егетләр хакында гәп кордылар.

—Минем юньле-башлы үбешкәнем дә юк бит әле, ахирәткәй,—диде Сәмига зур серен ачкандай.

Зөфәрнең кочулары, иркәләүләре хәтеренә төшеп, Мөкәррәмәнең йөзенә кызыллык йөгерде. Ул беренче булып Вәлинурның үбүен теләгән иде, чынлыкта исә төкләре белән тырный-тырный аны бөтенләй чит кеше үпте. Күз алдына да китерергә оят, ул хәтта карышып та тормады. Кызык, нигә шулай рәхәт икән ул үбешү? Үбешү генәме, зуррагы да чак кына булмыйча калды бит, жүләр. Ходайга рәхмәт, саклады. Мәгәр була иде хәлләр…

—Хәниф белән кунып йөргән идегез ич,—диде Мөкәррәмә уйларыннан арынып,—үбешмәдегезмени?

—Каюм белән үбешә идегезме әллә?—дип сорады үз чиратында Сәмига.

—Шул кәрләгә үптереп торам ди…

—Хәнифнең авызы исле ие… балык исе… мин балык яратмыйм…

Һәрберсе үз уен уйлап, берара тыныч кына яттылар. Казарма эче тып-тын; аратирә кемнеңдер саташып, быдыр-быдыр сөйләнүе генә бу тынлыкка ниндидер жан өрә иде.

—Без Зөфәр абый белән үбештек,—диде Мөкәррәмә. Һич көтмәгәндә сере түгелде дә китте.

Сәмига урыныннан ук сикереп торды.

—Уф, үләм, шул гарип беләнме?

—Ул кызыл командир,—диде Мөкәррәмә ачуы чыгып.

—Сөйлә әле, сөйлә, ничек булды?—дип, Сәмига дустын тарткаларга тотынды.

—Йоклыйсызмы сез бүген, юкмы?—дигән ачулы тавыш яңгырады.

Дуслар ятакларына сеңделәр.

—Бер иркен чакта сөйләрмен әле,—дип пышылдады Мөкәррәмә.

* * *

1942 елның 12 сентябрендә Баш командующий Иосиф Сталин үзенең ставкасында Көньяк һәм Кавказ юнәлешләрендәге командармнар катнашында киңәшмә уздырды. Анда хәрби элитаның каймагы җыелган иде. Идел буендагы хәлләр турында тирән энтәлекле докладлар тыңланды.

Сталин төребкәсен суыра-суыра өстәл араларыннан ишекле-түрле йөренде дә йөренде. Һәм, һич көтмәгәндә, сүзне башка сукмакка кертеп җибәрде.

—Миңа килгән мәгълүматларга караганда,—диде ул җыелышучыларны күзеннән кичереп,—немецлар фронт яны территорияләрендә ныклы шпион челтәре булдырганнар. Безгә беренче чиратта шуны нейтральләштерергә кирәк.

Сталин тагын нинди сүзләр сөйләгәндер, анысы билгесез, әмма ул сүзләрнең кайтавазы озак та үтми окоп казучыларга да килеп иреште. Беркөнне йокысыннан уятып, Мөкәррәмәне штабка алып килделәр. Штаб элекке каравыл өендә урнашкан иде. Ишек төбенә җитәрәк сакчының каттый тавышы яңгырады:

—Тукта, кем килә?

—Бөркет,—диде Мөкәррәмәне алып килүче әрмис.

—Узыгыз!

Мөкәррәмәнең җаны табанында иде. Нинди гаебем бар икән, нишләп җиде төн уртасында башкалардан аерып штабка чакыралар икән, дип борчылды. Бәрәңге мәрәкәсен янадан калкытып маташалармы әллә? Бәйләнүдән туктаганнар иде бит инде, чистый каныктылар. Басуда калган бәрәңгене чүпләү нинди бурлык булсын ди инде? Колхоз үзе җыймакчы, янәсе. Җыйды пычагым. Шуннан соң атна буе яңгыр яуды. Яңгырга карап тормаслар иде анысы, юлга сакчы куйдылар. Рәхмәт Әйдәгалләмгә, бу юлы нишләптер кызлар ягына басты, эшне зурга җибәрмәде.

Һәм менә тагын…

Ишекне ачып, әрмис Мөкәррәмәне өй эченә этеп кертте, үзе тышкы якта калды.

—Мондарак уз!

Мөкәррәмә як-ягына каранып алды, ләкин беркемне дә күрмәде. Караңгы иде. Бераздан, күзләре өйрәнгәч, өй түрендә тычкан күзе кадәре генә яктылыкны шәйләп алды. Тавыш та шул яктан килә иде.

—Уз,—дип кабатлады әлеге тавыш,—уз!

Мөкәррәмә идән сайгакларын шыгырдатып алгарак атлады. Сукыр лампа куелган өстәл кырына җиткәч кенә тукталып калды.

Хуҗа үзе күренми, мичкә эченнән кычкыргандай калын тавышы гына ишетелә. Шомлануы тагын да көчәйде Мөкәррәмәнең, нинди галәмәт бу?

—Исемең, фамилияң ничек?—дип сорады Тавыш.

—Әмирова Мөкәррәмә…

—Актаныш районы, Түбән Сөн авылыннан, шулай бит?

—Әйе.

—Әтиең фронтта фашистлар белән йөзгә-йөз килеп Ватаныбызның азатлыгын яклаган бер вакытта, син ничек антисоветчина баткагына тәгәрәдең, Әмирова?—диде Тавыш кызгануга охшаш төсмер белән.

Мөкәррәмә чын-чынлап шөбһәгә төште, шушыннан туп-туры төрмәгә алып китәләр икән дип коты чыкты.

—Шулай да минем сиңа ышанычым зур, Әмирова,—дип, Тавыш аның күңеленә өмет чаткылары сипте.—Чөнки синең күкрәгеңдә Ленин комсомолы йөрәге тибә, ә комсомол булу, беренче чиратта, Совет власте дошманнарына аяусыз булу дигән сүз ул. Дөрес әйтәмме?

—Дөрес…

—Шулай булгач соң. Әйдә, Әмирова, болай килешәбез, син үзегезнең взводтагы хәлләр турында миңа җиткереп торасың: кем нәрсә сөйли, кем белән элемтә тота, җитәкчелеккә мөнәсәбәте нинди? Ә хәзер менә шушы кәгазьгә имзаңны сал.

Өстәл өстендә бер кәгазь пәйда булды. Каләме дә шунда. Мөкәррәмә калтыранган куллары белән имзасын сырлады.

—Кирәге чыккач, мин сине үзем чакырырмын,—диде Тавыш.—Безнең сөйләшү турында беркем дә белергә тиеш түгел!

Бу төнге сәер очрашу турында күп уйланды Мөкәррәмә. Баштарак хәтта кызларның сүзләренә колак та салгалады. Ләкин әлеге әңгәмәләрдә калын тавыш иясе

кызыксынган мәгълүматлар юк иде. Барысы да гадәти: авыл, әти-әни, дуслар, егетләр...

Беркөнне Сәмига аның колагына: "Сез хәзер барыгыз да минем кулда, авызыгызны үлчәп ачыгыз",—дип пышылдады.

—Үзеңне бел, саескан,—диде Мөкәррәмә. Шунда ук ток суккандай башына уй бәрде: тукта-тукта, бу лыгырдык теге адәм сүзләрен кабатлый түгелме соң? Димәк, Сәмиганы да чакырып сөйләшкән.

—Сиңа әлеге очрашу хакында сүз чыгармаска куштылар лабаса,—дип, Мөкәррәмә дустын кармакка алды.

—Ә син каян беләсең?

—Беләм,—диде Мөкәррәмә мәгънәле генә итеп,—тартар теленнән табар ди, сак бул.

Сәмига керфекләрен каккалап дустына текәлде.

—Алай да син бар әле...

Бер-беребез өстеннән шымчылык итәбез икән, дип уйлады Мөкәррәмә.

* * *

Көннәр бер-бер артлы үтә торды. Аларның һәммәсе дә су тамчыларыдай охшаш иде. Әмер белән йокыдан уяталар, әмер белән яталар. Әмер белән эшлиләр, әмер белән ашыйлар. Соңгы вакытта мәшәкатьләре тагын да артты.

Хәл болай булды. Чираттагы тәнәфес вакытында (аларга бер сәгать эшләгәч, ун минут ял бирәләр), гадәттәгечә, Фатыйма җыр башлады. Нindидер сагышлы, моңлы җыр...

*...Көзге ачы җилләрдә ләй,*
*Туган-үскән илләргә.*

—Кызлар, уф үләм, бер мәзәк сөйлим әле, гелән җырларга да еларга димәгән,—дип Сәмига күтәрелде.

—Сөйлә-сөйлә,—диеште кызлар.

—Ике марҗа коймак ашап утыра, имеш.

—И-и, синең шул марҗа булыр инде...

—Бүлдермә, сөйләп бетергәнне көт. Кайда калган идем әле? Ә-ә, коймак. Әйе, болар коймак сосып утыралар икән. Ике марҗа. Берсе дөм сукыр икән, ә икенчесе бер күзле, ди. Сукыр берьюлы ике коймак, аннары өчне эләктереп алып ашаган да, берни әйтмичә—шап сыңар күзленең яңагына!

— Ник миңа сугасың?—ди күзлесе.

Теге әйткән:

—Мин икене-өчне алганда бер сүз дә дәшмәдең бит. Димәк, син үзең шыпырт кына алтышар коймак тарттырып утырасың, убыр!—дигән.

—Син безне сукырга чыгармакчымы?—дип, инде Фатыйма кузгалды.—Булыр, сукыр, мин әле синең маңгаеңдагы бетенне дә күрәм.

Кызлар ябырылып Сәмиганы сырып алдылар. Чыннан да, аның маңгаенда бет йөри иде.

—Уф, үләм,—дип, Сәмига бетне кулы белән сыпырып төшерде.

Бер-берсенең башларын карашырга тотындылар. Шуннан бирле бет эзләшү китте. Бер яктан караганда, моңа гаҗәпләнәсе дә юк, килгәннәренә ай ярым узды инде, шул вакыт эчендә бер мәртәбә дә мунча кергәннәре булмады. Бет акрынлап киемнәргә күчә башлады, җөйләргә чат беркәләр, чүпләп кенә бетерермен димә. Ә зарланырга ярамый, монда очлы колаклар күп, хәзер койрыгыңа басалар. Кызлар шулай дәшмитынмый гына бет үтерештеләр. Фатыйма эче китеп сырхауханәгә эләкмәгән булса, ихтимал, шулай дәвам дә итәр иде.

Ул кадәр бетне табипларның да күргәне булмаган икән әле. Шунда ук килеп җиттеләр. Тагын бер-ике көн соңарсалар, тиф кузгаласы икән дип сөйләделәр соңыннан. Ул көнне эшләтмәделәр, урман каравылчысы утарында мунча яктылар, ул ерак түгел иде. Ләкин мунчага кадәрге вакыйгалар үзе бер хикәят булды. Башта кызларны сафка тезеп, хәлне аңлаттылар.

—Гөлкәйләрем, без сезгә хәзер дезинфекция үткәрәбез,—диде ак халатлы тәмле телле олырак яшьтәге табибә.—Исемлек буенча чиратлашып керәсез, чират белән чыгасыз. Бернинди карышу, киреләнү булмастыр дип уйлыйм...

—Нәрсә соң ул дезинфекция?—дип пышылдады Сәмига.

—Мин каян белим, врачтан сора,—диде Мөкәррәмә.

—Иң әүвәл беренче камерага узасыз,—дип, табибә калай белән тышланган вагонга төртеп күрсәтте.—Анда бик әйбәтләп сезнең чәчләрегезне карыйлар, аннан соң тәпи-тәпи мунчага барасыз. Ә сез юынган арада без киемнәрегезне дезинфекциялибез, ягъни чистартабыз. Аңладыгызмы, гөлкәйләрем?

Ул бер мәртәбә дә бет сүзен кулланмады. Шуңа күрәме, моны кызлар уен итебрәк кабул иттеләр бугай.

—И, Абдул биясе мыш-мыш, рәхәтләнеп бер күңел ачыйк әле,—дип авызын ерды Сәмига,—янсын дошманнарның йөрәге.

Иң беренче булып аны чакырдылар. Шуңа куанганнары, камера дигәннәренә дә елмаеп-көлеп кенә кереп китте. Тик биш-алты минут үттеме-юкмы, вагон эченнән аның әче тавышы ишетелде. Күп тә үтми, ишектә үзе дә пәйда булды. Күзләре акайган, ярты башы такыр, калган яртысы да учка сыярлык итеп киселгән.

—Толымым, толымкаем…

Кулларын бутый-бутый чәбәләнгән Сәмиганы җәт кенә эчкә суырып алдылар. Әмма аның шушы халәттә күренеп китүе үзенең эшен эшләп өлгергән иде инде. Кызлар араларына бүре кергән көтү шикелле тирә-якка сибелде. Күзләренә ак-кара күренми. Мизгел эчендә утар эче бушап калды. Мөкәррәмә иң алдан бара. Яулык астыннан чыккан кара калын толымнары җилфер-җилфер килә. Аның чәче Сәмиганыкына караганда да озынрак, нәфисрәк. Аллам сакласын, кистерәме соң? Беткә үч итеп, тунны мичкә ягу булып чыга лабаса бу.

Абына-сөртенә йөгерә торгач, ул бер аланлыкка килеп чыкты. Ух-ух килеп, аны башкалар да куып җитте.

—Инде нишләйбед?—дип, куркынган күзләрен уйнатты бер Минзәлә кызы.

—Иң элек, әйдәгез, сүз куешыйк,—диде Мөкәррәмә,—камерага кермибез!

—Ә хәдер нишләйбед?—дип Мөкәррәмәгә бакты әлеге Минзәлә кызы.

Бу юлы сорау кызларны уйга салды. Дөрестән дә, хәзер нишләргә соң? Моның өчен аларның башларыннан сыйпамаячаклар бит. Ни дип җавап бирерләр, ни дип акланырлар?

Мөкәррәмә бу хакта да уйлап куйган иде, ахры, тәкъдимен әйтте.

—Врачлар китсен әле, аннан соң кайтырбыз,—диде.

—Аларның кайчан киткәнен каян беләсең?

—Юл читендә сагалап торабыз.

Ләкин качаклар ерак китә алмады, нәкъ каршыларына часть командиры капитан Вахитов килеп чыкты. Янында ярдәмчеләре.

—Становись!—дип урманны яңгыратты ул.

Кызларны гүя сихерләделәр, каз бәбкәләредәй шыбырдашып сафка тезелделәр.

—Сез дизертирлар,—дип оран салды капитан,—постыгызны ташлап качтыгыз! Моның өчен сезне трибунал көтә…

Агач яфракларын җиңелчә генә сыйпаштырып, җил йөгереп узды. Якында гына песнәкләр чырылдаша. Нинди саф, хозур бу табигать! Тик боларны күрүче генә юк.

—Прямо шагом марш!—дип әмер бирде командир. Ярдәмчеләре конвой шикелле як-яктан атлый, тагын кача күрмәсеннәр диләрдер инде.

Тын алырга да ирек бирмәделәр, берәмтекләп камерага керттеләр, аннан чыкканнарын шулай ук берәмтекләп мунчага озатып тордылар.

Бунт күз яшьләре белән тәмамланды.

* * *

Кызлар яулыкка төренде. Хәтта бер-берсенә дә шәрә башларын күрсәтмәскә тырышалар. Бөтен сөйләшкәннәре дә шул хакта, башка кайгылар артка чикте. Әйтерсең лә, бу дөньяда чәч толымыннан да мөһимрәк нәрсә юк. Хәер, җиткән кыз бала нинди генә шартларда да матур булырга омтыла ич инде ул, аны табигать шулай яраткан.

—Уф, үләм, өтек тавыкка әйләндек бит, Мөкәр,—диде Сәмига,—бу кыяфәттә кусалар да авылга ике аягымның берсен дә атламыйм.

—Әле җибәрәбез дә дип тормыйлар, кышын да эшләтмәкчеләр ди…

—Монысына да рәхмәт ишеткән юк, бер тиенсезгә теге… тапканнар…

—Сугыш бит,—диде Мөкәррәмә белдекле булып.

Сугыш барысын да кутәрә иде ул чакта. Булдыксызлык та, битарафлык та, шәфкатьсезлек тә—барысы да сыя иде аның каз оясыдай зур салам корсагына. Командирлар хәтта бетне дә шөрепләрне тагын да ныграк боргычлау өчен файдаландылар: тәртип катгыйланды, сорамыйча ярты минутка да китәргә ярамый, норманы бермә-бер арттырдылар, сменага хәзер метр ярым урынына өч метр окоп казып тапшырырга кирәк.

Ләкин бетләрнең бирешергә исәпләре юк иде. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, янә бер афәт—кызлар кашына башладылар. Лагерьга корчаңгы керде. Тик беттән аермалы буларак, монысына игътибар итүче табылмады. Кызлар үзләре дә ана була торган хәл, дип кенә карадылар. Сәмига, әнә, "Корчаңгы биюе" дә уйлап тапты. Һәр тишеккә чөй. Үзенә тукмак эләгеп кенә тора, ләкин шундук онытa, мөгезсез сыер кебек бернинди киртәләрне дә санга сукмый.

—Кыз кешегә кашыну килешми, әйдәгез, рәхәтләнеп биик әле,—дип, чираттагы "перекур" вакытында (монда тәнәфесне "перекур" дип атыйлар) такмак әйтә-әйтә бөтерелеп китте.

*Зимагурның аягында*
*Аршин ярым чабата;*
*Киндерәсен чорный-чорный*
*Караңгы төн таң ата.*

Тагын зимагур. Ишетсәләр сүзе була бит инде. Аңламаса да аңламас икән. Ләкин Мөкәррәмәне хуплаучы табылмады. Кызлар үзләре Сәмигага кушылып китте.

—Чабата биюе шулай буламыни?—дип, иң беренче Фатыйма түгәрәккә чыкты.—Безнең як зимагурлары тыпырдатып бииләр аны, менә болай…

Фатыйманың аяк астында тузан өермәләре купты.

—Минеке яңа бию шул, апаем,—диде Сәмига бирешергә теләмичә—"Корчаңгы биюе"… дип атала ул.

—Җүләр сатма, андый бию юк, чабата биюе генә бар…

—Мин аны үзем чыгардым…

Сәмига еландай бөтерелеп, яңабаштан төрледән-төрле фигуралар ясый башлады. Аның бөтен гәүдәсе берьюлы хәрәкәт итә иде. Шул хәрәкәт вакытында киеме кычытып интектергән урыннарны сыдырып-сыдырып ала. Тән сөешүгә охшаш ләззәт кичерә.

Кызлар әлеге рәхәт биюнең тәмен бик тиз тоеп алдылар. Дәррәү борганырга тотындылар. Ерактан караганда бу Африка негрларының бәйрәм тамашасын хәтерләтә иде.

Әйдәгаллләм кызларны беравык һични аңламыйча күзәтеп торды. Якынрак килде—барыбер аңламады. Бию дисәң бию түгел, танцы дисәң танцы дигәндәй…

—Тагын нинди әкәмәт уйлап таптыгыз инде…

—Галләм абый, син гармун уйный беләсеңме?—дип сорады Мөкәррәмә.

Бригадир сорауны ишетмәмешкә салышты, кәбестә шулпасын да бергә генә калдырырга торалар, бик бисегез килмәс, дип уйлады. Аннан соң исенә килеп, эшкә кыстый башлады:

— Әйдә, әйдә…

* * *

Әбиләр чуагы шактый озакка сузылды. Атна буе тоташтан күкне тутырып пәрәвезләр очты, болыт шикелле агылдылар. Кояш яныпмы яна. Берничә көндә яңгырлы сүрән җәйнең үчен кайтарды. Кешеләр бу хәлгә бик тиз күнектеләр, кояш гел шулай кыздырыр кебек тоела башлаган иде инде. Әмма табигать барыбер үзенекен итә ул. Җәй салкынча булса, көзе җылы килә, кышы озынга китсә, язы кыскара. Ахыр чиктә барысы да үз урынына утыра.

Сентябрьнең егерме җиденче көнен Мөкәррәмә бик яхшы хәтерли. Дежур торган иде ул көнне. Шуңа исендә калган. Дежур кенәгәсендә көне, сәгате теркәлә, нинди хәбәрләр килгәне языла, имза куела. Нәкъ менә шушы көнне окоп казучы кызларны Мәскәү янына торф чыгарырга җибәрү турында күрсәтмә килеп төште. Ә икенче көнне иртән көн бозылды, яңгырлар башланды. Аларны эшкә алып бармадылар. Сафка тезеп, командир стратегик ягулык—торф чыгару эшенә җибәрелүләре хакында әйтте.

—Ватан сезгә бик мөһим бурыч йөкли, бу ышанычны да комсомолларча акларсыз дип уйлыйм,—диде.

Болайга киткәч, авылга кайтулар тиз генә булмый икән. Ә Мөкаррәмәгә кайтмыйча һич тә ярамый. Авылда аны әнкәсе көтә ләбаса. Ялгыз башы ич ул. Соңгы хатында: "Әткәңнән бер хәбәр дә юк",—дип, борчылып язган иде.

Сагына. И, әнкәччәем, үземнең дә түзәр чамаларым калмады. Төннәрен—төшемдә, көндезләрен—күз алдымда.

Мөкаррәмәне авылга магниттай тартып торучы тагын бер мөһим сәбәп бар иде. Бу—Вәлинур! Монысы аның күңеленә мәңгелеккә кереп оялаган йөрәк сазы. Җыры да ул, моңы да, сагышы да, сере дә, шатлык-ләззәте дә... Тик авылдан чыгып киткәннән бирле аның турында бернәрсә белми. Хат аша әнкәсеннән сорарга ояла. Адресы булса, хат та язар иде әле, бәлки?

Хәзер менә торф диләр. Инде шунда китеп олагыргамы?

Адашкан каз бәбкәләре шикелле каңгырашып әрле-бирле сугылып йөри торгач, кичне җиткерделәр. Аларны таң белән эшелонга төяп, Шатура сазлыкларына алып китәчәкләр. Командир шулай диде. Хәрбиләрнең үзләрен дә яңа урынга күчерәләр ахры, ашыгып-ашыгып җыеналар. Сак кына элеккечә үк ..... Читкә-миткә китә башласаң, хәзер кычкырырга гына торалар.

Сәмига елый да елый.

—Туктасана, болай да җан үртәлә,—дип, Мөкаррәмә аны әрләп ташлады.

—Мин бер җиргә дә китмим, шушында гына калам,—дип шыңшуын белде Сәмига.

—Монда берәү дә калмый, аңлыйсыңмы шуны, алла колы.

—Ә окоп?

—Мин каян белим?

—Нишләргә соң алайса?

—Качабыз,—дип пышылдады Мөкаррәмә дустының колагына.

—Кая качабыз?

—Тсс, ишетә күрмәсеннәр. Мин барысын да уйлап куйдым инде...

Мөкаррәмә дөресен әйтмәде, чөнки бу уй капыл гына, әле шушы секундта гына башына бәрде. Ахыры ничек бетәр, әмма ул аның үзенә бик ошый иде.

Сәмига да хәлне төшенеп алды, кулларын чәбәкләп, баскан урынында сикергәләп торды.

—Уф, үләм, ну баш үзеңдә, Мөкәр...

—Матри, иләк авыз, башкаларга тишә күрмә.

—Ә кайчан кач-а-а-быз?

—Хәзер үк!

Яңгырның файдасы тиде. Сакчыларның ышыкка кереп китүләрен сагалап тордылар да, кузгалдылар. Колаклары ауга чыккан мәченеке шикелле тору. Сак атладылар, шылт иткән тавыш та чыгармадылар. Эчләрендә генә ут. Шырпы сызсаң, дөрләп китәрләр иде, шөт. Казармадан ике-өч йөз метрлар чамасы киткәч, тыннары кысылып салам эскертенә аудылар.

—Уф, үләм, аякларым камырга әйләнде,—диде Сәмига.—Инде нишлибез, кая барабыз?

Бу сорауга Мөкаррәмәнең үзендә дә җавап юк иде. Аларга, әлбәттә, пароход уңай. Әгәр утыра алсаң, ике тәүлектә кайтып җитәсең. Түлке моның өчен поезд белән Казанга барырга кирәк. Ике-өч сәгатьлек юл ул. Тик анда тикшерү күп икән. Дүкәмитсез кешеләрне тотып кына ябалар ди. Бу яктан иң кулае поездыр, мөгаен. Мөкаррәмәгә поездга эләгү җиңелрәк кебек тоела иде. Чөнки аның түбәсенә дә утырып йөриләр, Камбарка дигән станциягә барып җитсәләр, аннан Актанышка җитмеш чакрым кала. Ә Актаныштан Түбән Сөнгә күз йомып та кайтып була.

Аларга ничек тә моннан ераккарак китәргә кирәк, куа чыгулары ихтимал. Адашмас өчен тимер юл буйлап бару хәерлерәк буладыр, мөгаен. Хаҗәте чыкса, агачлар арасында яшеренергә дә була.

—Әйдә, торыйк, яктырганчы берәр аулаграк урын табарга кирәк безгә,—диде Мөкаррәмә.

—Шушы эскерт ярамыймыни?

—Бала-чага булма инде, зинһар...

Чынлыкта да, Сәмига сабый шикелле тулысы белән Мөкаррәмәгә салынган иде.

Яңгыр сибәләвен дәвам итә. Тик әлегә җир изрәмәгән. Камыл суны үзенә сеңдереп бара ахры. Көлсу туфрак болай да дым тотмый, эчкә суыра. Шуңа күрә атлавы авыр түгел. Мөкәррәмә алдан бара, Сәмига бүлтерек бәрән шикелле аның артыннан теркелди. Яктыра башлагач, бер эскерт төбенә яшеренеп, көнне шунда уздыралар. Салам эчендә ара-тирә тук башаклар да тапкаладылар. Тамак ялгарга ярап куйды.

Шул рәвешле кача-поса, кеше күзенә чалынмаска тырышып, Камбарка станциясенә таба атладылар. Шактый ерак киткән кебек булсалар да, узган ара ташка үлчим генә иде әле. Ничә әйтсәң дә, төн төн шул инде ул. Өстәвенә, артларыннан куа киләләрдер сыман тоела иде. Ни гаҗәп, нәкъ менә шушы уй балачактан килгән албасты-убыр кебек төнге хәшәрәтләрне оныттыра иде.

Шулай да тиздән олы юлга, кешеләр арасына төшәргә мәҗбүр булдылар. Сәфәрнең икенче иртәсендә, гадәттәгечә, чираттагы эскерт итәгендә урын әзерләп, йокларга яттылар. Сәмиганың башын терәгәнче үк күзләре йомылды. Мөкәррәмәне исә ач карынга йокы алмый. Ризык даулап эче тырнапмы-тырный. Чыдар чамасы калмагач, башак эзләнергә дип куышыннан чыкты.

Көн элеккечә үк еламсык иде, сытылып китәр дә, яшьләрен агыза башлар төсле. Яңгырына гына түзәрсең, суытып җибәрә күрмәсен. Шушы ике көн эчендә ниләр генә уйлап бетермәде инде ул. Баштарак куып тотарлар да төрмәгә ябарлар дип кайгырды. Аннан соң күңелен, авылга кайтып җитеп булмаса нишләрсең, дигән хәсрәт биләп алды. Ашау-эчү хакында әйтәсе дә юк, тамак ягы бер генә минутка да истән чыкмый.

Мөкәррәмәнең кинәт кенә башы әйләнеп китте. Шул ук мизгелдә ниндидер усал көч аны үзенә йолып алды, күңелен шом басты. Күтәрелеп бакса, чак артына аумады, каршында ат чаклы зур соры бүре басып тора иде. Кызның очлы күзләре тагын биш-алты бүрене шәйләп алды. Алары читтәрәк, кайсы яткан, кайсы утырган дигәндәй, һәрберсе ни беләндер мәшгуль. Ә бусы башлыклары булырга охшый. Аның томырылып бер йолкыш адәми затка текәлеп торуы кавемне дә сагайтты. Башлык ым гына каксын, хәзер ботарлап ташлаячаклар. Тик бүреләр тук иде, аудан гына кайтып килешләре. Таң алдыннан күрше авыл сарыкларын буып чыктылар. Элекке шикелле куркып-өркеп йөрүләр бетте. Сугыш бүреләргә ирек алып килде. Алар хәзер кан белән генә туклана.

Мөкәррәмә ни үле, ни тере. Ата бүренең уенда нинди гамәл оешып килә, һич аңламассың. Өернең дә кызыксынуы артты, еш-еш башлык ягына күз ташлап алалар, әмер көтәләр булыр.

Миннән күр игелек, тормышыңны үзеңә бүләк итәм, кызый, дигән фикергә килде ахыры сорыкай. Сыртын дугадай кабартып бер-ике мәртәбә киерелеп алды да, әкрен генә кавеме янына атлады. Мөкәррәмәгә дә зиһене кайтты. Йокылы-уяулы Сәмиганы җитәкләп, авыл ягына элдертте.

Бүреләр эскерт ышыгында корсакларын шиңдергән арада кызлар тирләп-пешеп, бер басу капкасы янына килеп туктадылар.

Авыл бер генә урамлы иде. Үзе тәзек күренә. Иркен яшәгәнгә охшый. Сугышка кадәр кече авыллар кайда да мул тормыш кичерде. Балына чаклы бирәләр иде. Шуңа күрә хезмәт көненең дә бәһасе зур иде.

—Бу бүреләрне әйтәм, безнең авыл этләренә юлыксалар, койрыкларын кысарлар иде, нибуч,—диде Сәмига. Ул бүре белән йөзгә-йөз очрашмады, аның шәфкатьсез күз карашын тоймады, шуңа күрә куркырга өлгерә алмыйча калды. Мөкәррәмә исә әле һаман тынычлана алмый иде.

—Сүзең сүз түгел, ичмасам авызыңны ачмый тор.

Сәмиганы бу минутта бөтенләй башка нәрсә кызыксындыра иде инде.

—Минем менә шушы өйгә керәсем килә,—дип, каршыдагы ыспай йортка бармагы белән төртеп күрсәтте. Мөкәррәмәнең дә иң кырыйдагы шушы бөтү йортка күзе төшкән иде. Нигәдер монда карчык кеше яшидер кебек тоелды. Ә карчыклар мәрхәмәтле була, юмарт була. Бер-ике кыерчык ипие белән биш-алты бәрәңгесен кызганмастыр, шәт. Бәлкем, кундырып та чыгарыр әле. Бераз хәл алырлар иде, ничек барырга кирәклеге турында да сораштырырлар иде. Болай сукырлар хәлендә ич.

Шушындый өмет белән Мөкәррәмә болдырга менеп, өйалды ишеген какты. Бер какты, ике, ләкин кеше-мазар күренмәде. Ул тирә-якны күздән кичерде. Абзар-курасы җитеш иде хуҗаның. Кышлык утыны да әзер. Киселгән, ярылган, өелгән. Бу төбәк

урманга бай шул. Актаныштагы сыман тирес кирпече якмыйлар. Ишек алдында кошкорт чүпләнеп йөри. Таныш манзара. Рәхәт булып китте, гүя үз авылында, келәт эченнән әнкәсе килеп чыгар да аркасыннан сыйпап алыр төсле тоелды.

Бәрәңге бакчасының бирге очында аркасына бау белән бәйләп коры кура аскан (шушы кадәр утыны бар өстенә анысы нигә кирәк булгандыр инде) бер карчык күренде. Кулбашында урагы. Җәт-җәт атлый. Йөген киртә янында калдырып, шундый ук тизлек белән ишек алдына узды. Чит кызларны күргәч кенә йөзе кара янып чыкты.

—Нәфисә килен дип торам, тагын ыстанса караклары икән,—диде.

—Әбекәй, без караклар түгел, без…

Карчык Мөкәррәмәне тыңламады да, үзенекен тезде.

—Ипи бирә-бирә дә ялыккан инде, япь-яшь килеш соранып йөрисез, каян җиткерим ди һәммәгезгә, үземнең дә авызымны ачсам, үпкәм күренергә тора. Таң алдыннан, әнәтрәк, өч сарыгымны бүреләр буып киткән…

—Әбекәй, без ул бүреләрне күрдек бит,—дип сүзгә кушылды Сәмига сөенче алгандай. Мөкәррәмә аңа күзенең агы белән акаеп карап алды. Тегесе шундук авызын япты.

Карчык бу иске бияләй шикелле йончып беткән арык кызларның кем икәнлекләрен бер күрүдә төшенеп алган иде инде. Бу якта акуп дигән казу эшләре башлангач, шактый күренгәләделәр алар авылда. Артларыннан куа килеп тоткаладылар да үзләрен. Сәүит халыкны бик нык кисәтте, алай-болай качкыннар килеп чыга-нитә калса, хәбәр итегез, диде. Уен-муен түгел, әнәтрәк, сугыш вакыты, диде.

Нәфисә килен дигәне авыл Советы рәисе иде. Сарыкларын бүре буган хуҗалыкларга үзем килеп чыгам, өйдә торсыннар дип кисәткән, йомышчысы авыл буйлап әйтеп йөрде. Күреп калса, бу чебешләрне каптыра да каптыра инде. Бәйдәге эттән дә битәррәк бит ул, иенә җиткермичә туктатмас. Хәер, аның үзенең дә "кансыз Бәдәр" дигән яманаты чыккан. Дөресе дә шулай. Ник дисәң, үзен-үзе белә-белгәннән бирле аны кулак калдыгы дип рәнҗеттеләр, күзен дә ачырмадылар. Шуңа күрә усалланып бетте, үч сакларга күнекте. Нигә кадалып кына китмиләр, монсында да үз кирелеген итәчәк, качакларны йолып калачак, карчыгалар тырнагына ташламаячак.

Карчык яулыгы өстеннән кигән мескен бүреген салып келәт тышындагы чөйгә элде дә, өеннән кечерәк кенә ипи алып чыгып, Мөкәррәмәгә тоттырды.

—Тизрәк олагыгыз моннан,—диде.—Әнә, бәрәңге бакчасыннан ындыр артына чыгыгыз.

—Станция кайда соң, әбекәй?—дип сорады Мөкәррәмә.

—Уңга каерылырсыз, инеш буеннан сукмагы бар аның. Барыгыз, бар…

Шуннан соң озак та үтмичә сәүит Нәфисә капканы ачты.

* * *

Станцияне озак эзләмәделәр, поезд юлы аларны шунда үзе алып килде. Ләкин янына килергә кыймадылар. Бер чокыр эчендә әлеге сәер карчык биргән ипине ашый-ашый кичне җиткерделәр. Станциядә ут алмыйлар икән, бу алар өчен уңай гына иде. Инде Камбаркага кадәр барасы поездны белешеп, шуңа эләгү җаен табасы гына калды. Кесәләрендә җилләр уйнавын исәпкә алсаң, бу бер дә җиңел булырга ошап тормый иде.

Җир өстенә эңгер-меңгер пәрдәсе җәелгәч, Мөкәррәмәләр яшеренгән урыннарыннан чыгып, вокзал янына килделәр. Вокзал бинасы таштан корылса да, зур түгел иде. Буяулары купшакланып беткән дүрт шәрә стена. Билетны тәрәзәсе тимер рәшәткә белән тышланган аерым будкада саталар. Халык шунда җыелган, поездларның вакытында йөрмәвеннән зарланалар. Хәрби эшелоннарга гына яшел ут яна. Тик алар мондый вак станцияләрдә тукталып тормыйлар.

Кызлар бер буш эскәмиягә кунакладылар. Шунда ук яннарына ун-уники яшьләрдәге бер малай килеп елышты. Бик елгыр күренә, күзләре яшен чаткысыдай ялт та йолт килә.

—Тартырга беткән икән, кая, төрдерең әле,—диде ул якын танышларына мөрәҗәгать иткәндәй.

Мөкәррәмә шөлләп калды, чөнки караклар корбаннары янына башта кечерәк малайларны җибәрәләр икән дип ишеткәне бар иде. Сөйләндерә, ачыклый. Аннан соң…

—Апаем, сиңа бәй-бәй итәргә вакыт инде, әнкәң ачуланыр, бар, өегезгә кайт,

түтәннәрнен синнән башка да мәшәкатьләре муеннан,—дип, Сәмигә гадәте буенча акыл өйрәтеп алды.

Малай кесәсеннән тәмәке янчыгы тартып чыгарды да:

—Сынар өчен генә сораган идем, саран тәреләр,—дип яңа танышларына бәясен дә чыгарып куйды.

—Станциядә нишләп йөрисең соң син?—дип сорыйсы итте Мөкәррәмә. Малайның зурларча ирәеп сөйләшүе кызык тоела башлаган иде инде. Үзе дә ишетте ишетмәгәнен.

—Сезнең эше беләткәләрнең имиләрен уарга киләм мин монда,—диде малай хихылдый-хихылдый.—Куак эченә дә алып кергәлим…

Ул искәрмәстән генә Мөкәррәмәне кочаклап алды.

—Кит, үләт, эченә тибәм бит,—дип Сәмигә ярдәмгә ашыкты.

Мөкәррәмә мәсьәләне үзе хәл итте: малайны бер селтәнүдә кубарып ташлады.

—Мин юри-чари гына егылдым,—диде малай торып баскач,—чынлап тотынсаммы, ә дигәнче икегезне берьюлы тәпәләп ташлый алам.

—Колагыңны кисеп, авызыңны ямаганны көтәсеңме?—диде Сәмигә тынычлана алмыйча,—тапкан, сиңа күкрәк тоттыралар ди, өлкәнрәк абзаннарга да тәтеми әле ул.

Пошкыра-пошкыра борылыштан йөк поезды килеп чыкты. Бик озын иде булса кирәк, станция, тирә-яктагы йортлар биш-алты минут буена табадагы борчак шикелле сикергәләп тордылар. Ниһаять, соңгы вагон көпчәкләрен рельс араларына бәргәли-бәргәли күздән югалды.

—Фронтка боеприпаслар алып китте,—диде малай белдекле кыяфәт белән,—Уралдан!

—Бәлки, башка әйбердер?—диде Сәмигә киреләнеп,—маңгайларына язылмаган иде бит.

—Без, сарапуллылар, поездларны йөрешеннән таныйбыз,—диде малай,—бу составны ике паровоз тартып бара. Платформаларында—Т-34 танклары. Өсләре ябулы…

—Син Сарапулданмыни, апаем?—дип җанланып китте Мөкәррәмә.

Сарапул аңа бик таныш исем иде. Күршеләре Локман абзыйларның туганнары яши бит анда. Кызлары Гөлсем һәр җәй кунакка кайта иде. Бергәләшеп уйныйлар, әрәмәгә бөрлегән җыярга баралар иде. Кышын әле авылныкылар Сарапулга ат белән дә йөриләр иде.

Мөкәррәмә бу форсаттан файдаланып калырга ашыкты.

—Апаем, безгә дә шул якка кайтырга бит, бергә-бергә кайтыйк әле, яме, апаем? Без юлны белмибез, поездларны да танымыйбыз…

—Апаем да апаем, нинди апаем булыйм ди мин сезгә?

—Исемеңне әйт алайса, исемең ничек соң синең?

—Мәпти.

—Мин Мөкәррәмә булам, бу—Сәмигә…

Мәпти тәмәкесен кабызды да, утын пинжәге белән каплап, бер-ике мәртәбә бик тәмләп суырды. Шуннан соң гына:

—Ярар, мин риза,—диде,—түлке бәйрәм ашы кара-каршы…

—Без нишләргә тиеш соң?—дип сорады Мөкәррәмә.

—Вакыты җиткәч әйтермен.

Мәпти берара юк булып торды. Табанын ялтыратты инде бу малай, качты, дип уйлаганнар иде. Юк, яктыра башлагач, баш очларына килеп басты.

—Торыгыз,—диде ул,—хәзер поезд килә.

—Абау, тач утырырбыз микән,—диде Сәмигә шатлыгыннан.

—Бу Казан поезды гына әле, тәпәнеңне боргалама,—диде Мәпти,—халыкны жиденче вагонга гына утыртачаклар, сез иң алга басып, ишек каршында пробка ясыйсыз, ягъни әвеш-тәвеш килеп аласыз. Миңа капшанырга ике-өч минут вакыт җитә. Сызгырган тавыш ишетелүгә аннан таясыз. Мин сезне үзем эзләп табармын.

Кызлар Мәптинең бәйрәм ашы дигәненнән бик курыкканнар иде, кулларын озынайтмакчы була икән дип уйлаганнар иде. Шуңа күрә әлеге йомышка шундук ризалык бирделәр, алдын-артын да тәгаенләп тормадылар.

Алар өч поездны шулай каршы алып, шулай озатып җибәрделәр. Шомардылар тәки. Бу шөгыль бигрәк тә Сәмигәгә ошады, гомер буе вокзалларда кесә чистартып

йөргән диярсең. Мәпти йомырка, ипи белән сыйлады. Ә кичен, ниһаять, йөк поездының аралыгына кунаклап, Сарапул ягына кузгалдылар. Камбарка Сарапулдан ике-өч сәгатьлек кенә юл икән. Монысы иң зур сөенечләре иде.

Әгерҗегә кадәр шулай җилләнеп бардылар. Суык җилекләренә кадәр төште, бармаклары әйбер тотмас хәлгә җитте.

—Кызларны җенем сөймәсә дә әллә нигә ошаттым мин сез беләткәләрне,—диде Мәпти поездан төшкәч.—Авызыгызны ермагыз, мин сезне куак эченә алып керәм әле бер...

Мәптинең җенси ишарәләренә, аты-юлы белән сөйләшүенә кызлар күнеп беттеләр инде, сүзләрен колак очларыннан гына очыртып җибәрәләр. Бер нәрсә дә эшли алмыйсың, аның аркасында поездга утырдылар, аның аркасында тамаклары тук.

—Мин монда калырмын ахры,—диде Мәпти вокзал тирәләрен урап килгәч,—төшемле күренә, әбекәйне карыйм бит мин, ике ел инде урын өстендә...

—Ә без?—дип күзләрен шардай итте Сәмига.

—Сезне утыртып җибәрәм мин анысы, хәзер ерак калмады инде...

Кичке якта, чыннан да, җае чыкты. Кызларга ике вагон аралыгында тагын урын табылды.

Аңынчы Мәпти юлдашларын кәбестә бөккәне белән сыйлады. Кап-кайнар иде, өрә-өрә суытып ашадылар. Өйләреннән чыгып киткәннән бирле авызларына мондый тәмле ризык кергәне юк иде әле.

—Их, ярылганчы ашарга иде шушы бөккәнне,—диде Сәмига,—кече телгә дә йокмады бу, йөрәк тә ялганмады...

—Юкка тырышма, Сәми, ашап алаша булган кеше юк әле.

—Сәмиганың сүзенә карама, Мәпти, теле шулай сөяксез инде аның, син егетләрнең егете,—диде Мөкәррәмә.

—Егет фартавай, атлар гына тарталмай...

—Бирермен мин сиңа тарталмайны...

Мәпти Сәмиганы чеметеп алды.

—Малай кеше чеметми ул, апаем, менә болай итеп сугып кына җиффәрә...

Кыз селтәнеп-селтәнеп торды да, Мәптинең касыгына төрткәндәй итте. Тегесе дә буш калдырмады. Әүмәкләшеп киттеләр.

—Җитәр сезгә, агач матрослар, җә чынлап торып тәпәләшә башларсыз,—дип, Мөкәррәмә икесен ике якка этеп җибәрде.

Алар көлешә-көлешә, шаярыша-шаярыша, станция бакчасына таба юнәлделәр.

—Бөрмәкәем!—дип аһ орды шулчак Мөкәррәмә.

—Кемгә кирәк синең ул искең,—дип көлде Мәпти.

—Анда минем кульяулыгым!

—Уф, үләм, кульяулык кына булмады инде ул, чистый теңкәмә тиеп беттең шуның белән,—диде Сәмига.

—Атаулы ич ул!

—Егетеңәмени?—дип иреннәрен кыйшайтты Мәпти.

—Егетенә пычагым... Вәлинур абыйның кызлары аннан башка да буа буарлык...

Бу сүзләрне Мөкәррәмә ишетмәде, бөрмәкәе артыннан киткән иде.

—Әйтсәм әйтим инде,—диде Мәпти аларны озатканда,—мин бит үзем дә кыз кеше, малай булып киенеп кенә йөрим. Исемем Мәптуха. Миңа малай булып туасы калган...

—Әйтәм җирле һаман чеметергә үреләсең,—диде Сәмига.

Поезд дөбер-шатыр килеп урыныннан кузгалды. Мәптуха тәмәкесен пыскытып, аларга кул болгап калды.

* * *

Камбаркага кайтып төшкәч тә юлда тагын атнага якын изаландылар. Икесенә дә бик каты салкын тиде. Бигрәк тә Сәмига бетереште. Гәүдәсе чыра шикелле генә калды, үзе буыла-буыла ютәлли, тәне уттай яна. Әрлән дигән мари авылында куныпта чыктылар. Янә бер көн болында печән кибәненә күмелеп хәл алдылар. Бәхетләре бөтенләй үк юк түгел икән әле. Агыйдел чыгышында ат туры килде, Актанышка кадәр шуңа утырып кайттылар.

—И, бәгырькәйләрем, тәнегездә карга чукырлык та ит калмаган бит,—дип, олаучы хатын юл буе ах-ух килеп барды.

Тик үзенең дә ярдәм итәрлеге юк иде, кәрәчингә барышы, кичкә әйләнеп кайтырга ди. Кызлар барыбер аңа бик рәхмәтле иде. Актаныш тавын менүгә Түбән Сөн күренеп тора ич ул. Озын Кул ергамагын үтеп, Өч Каен атавына җитәсең дә… аннан Шалкан чокыры… басу капкасы…

Туган як җиле Сәмигага да шифалы тәэсир итте, атлауларына кадәр үзгәрде. Элекке җинеллеге, шаянлыгы кайтты.

—Зимагурлыкта йөрүнең үчен кайтарыйк әле, Мөкәр, бүген клубларын ду китереп биибез, Алла боерса, яме,—дип авылга кадәр кәҗә бәтиедәй сикергәләп кайтты.

—Җитте, кызый, өзлегерсең!—дип кисәтте аны Мөкәррәмә.

Сәмига түбән оч кызы. Шуңа күрә басу капкасын узуга, зират юлыннан уңга кереп китте. Аннан аулаграк та, турырак та. Тау гына төшәсе…

Бераз баргач, ул кояштай балкып, ахирәтенә кул болгады.

Ихата капкасын ачып эчкә узуга, Мөкәррәмә аяклары тотмыйча җиргә сыгылып төште. Өйдән йөгерә-ава әнисе атылып чыкты.

—Кызым, балакаем…

—Әнкәй, якын килмә, мин бетле, корчаңгы…

* * *

Баерга киткән кызларның бетләп, чирләп кайтуы сәгате-минуты белән мәгълүм булды. Гайбәт төрле рәвешләргә кереп өйдән-өйгә йөрде. Авылда аяклы гәҗит тиз тарала бит ул. Имеш, кызларны юлда талаганнар икән, имеш, булдыра алмаганга бернәрсәсез куып кайтарганнар икән. Имеш… Ул "имешләр" очсыз-кырыйсыз иде. Ни генә сөйләмәделәр. Ләкин кызларның үз хәлләре хәл иде. Әнисе Мөкәррәмәнең кутырлап беткән җәрәхәтле тәнен күргәч, бер мәлгә тынсыз калды.

—И, балакаем, ничекләр түзеп йөрдең бу эшкә, күр инде, карар җирең калмаган бит,—дип аһ орды.

—Ул кадәр көймә инде, әнкәй, бетәр әле…

—Бетәр, бетәр, бетмичә тагын… җыйган үләннәрем бар, төнәтмә ясап җибәрермен, брачны да чакыртырбыз…

—Брач кем соң?—дип сорады Мөкәррәмә түземсезләнеп.

—Шул инде, элеккеге, Өммия…

—Шул олы танауга тән күрсәтәмме соң?

Мөкәррәмәнең корчаңгысын үзенең көндәше дип санап йөргән фельдшер кызга һич тә күрсәтәсе килми иде. Бәлкем, Вәлинур белән хат алышадыр, язып җибәрсә, үл дә кит.

—Киемнәрең теткәләнеп беткән икән, утка гына ягарбыз инде,—диде Нәгыймә,—бу бетне чүпләп кенә бетереп булмас, мыж бит, ходаем, мыж…

—Әткәйнең хатларын яга күрмә, бишмәт кесәсеннән алып куй,—диде Мөкәррәмә.

—Аллага шөкер, әткәң бу араларда хаттан өзми, исән генә йөрсен берүк. Теге вакытта югалып торгач бик кыен булганые.

—Башкаларның хәбәре бармы соң, әнкәй?

Мөкәррәмә бу сорауны Вәлинурны күздә тотып бирде.

—Корбангали абзаң турысында язганыем бугай, шөкер, башка яман хәбәр килгәне юк әле.

Мөкәррәмә җиңел сулап куйды, исән икән, исән!

—Чәченнән дә әрмис ясаганнар,—диде Нәгыймә,—ике ай эчендә чистый гуттан чыгарып бетергәннәр, илаһым.

—Бет өчен инде, елата-елата кырдылар…

—Кызым, сиңа мунча керергә ярамастыр әле,—диде Нәгыймә,—башыңны кайнар су белән юыйк та, чиста күлмәк-ыштаннар киеп урыңга ят. Ашарыңа да шунда гына бирермен. Тынычлап рәхәтләнеп йокларсың. Мин төнәтмә хәстәрен күрермен.

—Без Сәмига белән кич чыгарга сөйләшкән идек…

—Анысы терелгәч инде, кызым, бу килеш кеше көлдереп йөрмәссез бит инде…

Мөкәррәмәнең корчаңгысы тәмам азган булган икән, һич кенә дә кимү ягына авышмый. Югыйсә, нинди генә төнәтмәләр сөртеп карамадылар. Әрем суы дисеңме, үги ана яфрагыныкы дисеңме, гөлҗимеш суы, әрекмән, сукыр кычыткан сулары… Файдасы тия дигәч, Нәгыймә төнәтмәләрен чирмеш әкәенә барып өшкертеп тә алып кайтты. Ә үзгәреш һаман юк та юк. Елашып беттеләр. Шулай булмыйча, Мөкәррәмә

дусларын сагына, кичләрен клубларга чыгасы, биисе, җырлыйсы килә. Кеше кебек эшкә йөрер иде. Өйдә бикләнеп утырудан да авыр нәрсә юк икән. Нишләптер иптәш кызлары да хәл белергә килми.

Авылда бер генә кеше шикләнмичә анын кулларын сыйпады. Бу ашлык киптерүдә бергә эшләгән Кәшифә иде. Ул, гадәтенчә, ишек алдыннан ук сөйләнә-сөйләнә керде. Өй эче яктылык, күтәренкелек белән тулды.

—Бәрәкалла, бәрән сыйрагы, берәүләр читтән кайткан икән ләбаса, көттем-көттем дә, үзем килеп чыгыйм әле дидем менә,—дип, Мөкәррәмәне җиңелчә генә кочып алды.

—Кәшифәттәй, иплә6рәк, мин бит ни…

—Барысын да күрдек, үскәнем, бер дә борчылма, пычракка пычрак ябышмый ул.

—Шулаен шулай да…

—Чир турында сөйләп, үсендермик әле шул ләгънәтне,—диде Кәшифә,—күңеллерәк сүзләр дә бетмәгән. Һичьюгы, егетләребезнең колагын чыңлатып алыйк. Гыйрфан абзыеңа да язып җибәрдем әле, берәр әмәлен табып бер генә кичкә булса да кайтып кит, чукынмыш, чыдарлыгым калмады, алай-болай итенеп куйсам, үзеңә үпкәләрсең, дидем.

—И, Кәшифәттәй, рәхәт тә инде синең белән…

—Бишмәтем тар булса да күңелем киң минем, Мөкәррәмәкәй. Анысы син үзең дә салпы якка салам кыстырырга ясап куйган кебек, анда әрмисләр янында егет-җилән мыж инде ул, җырдагыча, юк дисәң дә булгандыр әле күңел юаткычларың…

Зөфәр белән үткәргән төн хәтеренә төшеп, Мөкәррәмәнең йөзе бурлат тукыма төсенә керде.

—Ярар, ярар, көчләмим, үскәнем, сөйләргә ярамаса сөйләмә,—дип, Кәшифә сүзне икенчегә бормакчы итте. Ләкин Мөкәррәмәнең үзенең дә гөлдере килгән иде инде.

—Берүк кешегә чыгара күрмә, Кәшифәттәй, ярыймы?

—Шөкер, шаталак булсам да иләгемдә су тора.

Мөкәррәмә әлеге төндә башыннан үткәннәрне түкми-чәчми дустына бәян итте. Боларны ахирәте Сәмигә да белми иде әле. Авызында сүз тормый дип, серен ачып бетерүне кирәк тапмаган иде.

—Кыз баланы адым саен шундый бәла сагалап тора инде аны, үскәнем, бәхетең бар икән, миһербанлы кешегә юлыккансың,—диде Кәшифә.

—Мин Вәлинур абзыйны яратам бит,—дип, Мөкәррәмә сер капчыгын төбеннән үк селкеп ташлады.—Кульяулык та чиккән идем, бирә генә алмадым. Өммия дип җилеге корыды бит…

Урамда ниндидер тавыш ишетелде. Кәшифә шундук тәрәзәгә капланды.

—Бәрәч, бригадир бит бу, әллә мине эзләргә чыкканмы гүпчем. Эшләр харап. Ә-ә, юк икән, Тимерәйләргә кереп китте. Кәрәчин бетте дигәннәрие, Әҗәкүлгә җибәрергә кеше эзлидер. Шул терсәк буе малайлар кулына калды бит калхуз, адәм таганәсе.

Кәшифә чәй дә эчеп тормады, эшенә ашыкты, алай да ишек тоткасына тотынгач, өзелгән сүзне ялгап, Мөкәррәмәгә киңәш-табыш итәргә дә җитеште.

—Торып-торып торҗагун, ди, Өммия сиңа көндәш түгел, үскәнем, ул налуг Газраилен эләктерде инде,—диде,—Вәлинурга күзең төшкәнне мин теге вакытта ук сизенеп йөри идем. Үзеңә дә әйткән идем бугай әле. Киңәшем шул, бушка авыз суыңны корытып йөрмә, хәстәрен хәстәрлә. Хат яз, әнкәсе Сәгыйдәттәйне үз ягыңа аудар. Егет җилле. Сугышы да гомергә бармас, Аллаһы боерса, бер туктар.

—Адресы юк бит… оялам да…

—Адреска гына калса, борчылма, үзем рәтләп бирермен. Ә оялам дигән сүзеңне оныт. Заманасы ул түгел.

* * *

Нәгыймә бердәнбер кызының хасталануын бик авыр кичерде. Төн йокылары качты. Төнәтмәләрнең нигәдер файдасы тимәде, өшкерүләр дә хәлен җиңеләйтмәде. Уйлана торгач, табибларны узып булмастыр ахры дигән нәтиҗәгә килде. Шуңа күрә ул беркөнне Мөкәррәмәгә:

—Кызым, мин брач чакыртам,—дип кырт кисеп әйтте.

Нәгыймә эченнән кызының аяк терәп каршы килүен көткән иде. Чөнки белә,

Мөкәррәмә үз сүзле, әйткәнендә тора торган тискәрерәк зат. Ә ул исә һич көтмәгәндә: “Ярар, әнкәй, чакыр”,—диде. Әлеге үзгәрешнең сәбәпчесе Кашифә икәнен Нәгыймә белми иде, әлбәттә. “Өммия сиңа көндәш түгел” дигән тылсымлы сүз ул көнне Мөкәррәмәнең күңелендәге шик-шөбһәләрне юып төшергән иде.

Өммия аларга килгәч, үзен бик дустанә тотты. Мөкәррәмәнең йөрәгендә нинди утлар кайнаганын белми иде шул ул. Белсә дә чәченең бөртеге дә селкенеп карамас иде. Чөнки Өммия инде ир хатыны, күмәнә сизелеп килә. Тиздән Нургата янына район үзәгенә күченергә җыена, әлегә алыштырырга кеше генә таба алмыйлар.

—Сезгә стационарга кереп ятарга кирәк,—диде ул Мөкәррәмәне җентекләп карагач,—җәрәхәтнең сөяккә төшүе бар. Юллама бирермен.

—Бик әйбәт булыр, Өммиякәем, бер дә алга таба түгел бит,—дип, аның сүзен Нәгыймә дә куәтләп алды.

Мөкәррәмәгә бу ошамады. Өммиянең чибәрлеге, ыспай киеме аның көнчелек хисләрен янә тузгытып җибәргән иде.

—Әнкәй дим, җитәр сиңа!—дип, тавышын күтәрде.

—Әниегезнең борчылуы бик урынлы,—диде Өммия чемоданын җыештырган арада.

Мөкәррәмәнең күзләре ирексездән фельдшерның кулларына төште. Яшь абыстайныкы шикелле ап-ак, нәфис, пакь иде бу куллар. Кызның ачуы тагын да кабара төште. “И, бармаклары, шүрәле бармаклары кебек, иләмсез”, дип юанды.

—Иптәшегез Хөрмәтуллина хәленә кала күрмәгез,—диде Өммия.

—Сәмигага ни булган?—диде Мөкәррәмә аның бу сүзләрен яратмыйча,—Сәмига ул...

—Температурасы югары, һич төшереп булмый. Бу килеш юлга чыгарга да куркыныч.

—Әнкәй, әйдә, Сәмигаларга киттек,—дип, Мөкәррәмә урыныннан кузгалмакчы итте.

—Сез шушы минуттан карантинда,—дип кисәтте аны Өммия,—сезгә кешеләр белән контактка керү тыела. Корчаңгы—йогышлы чир. Ә сездә аның бик авыр формасы.

Фельдшер чыгып киткәч, өй эче тынып калды. Нәгыймә моржага сөялеп, гадәттәгечә, бәйләм бәйли, Мөкәррәмә урын өстендә уйга чумып утыра. Стена сәгате дә аларга кушылып моңлана: “келт-келт; келт-келт...”

—Актаныш бүлнисенә төшәргә кирәк, кызым, язу бирәм диде бит...

—И, әнкәй, без бит качаклар, дүкәмитләр барысы да тегендә калды.

—Дүкәмит дип соң, кызым, сез авыл балалары лабаса. Олысы-кечесе белә, һәммәсе явит итәр.

—Кешеләрдән сорап торалармыни аны, әнкәй, тоталар да ябалар...

—Шулайдыр да соң, кызым, күрәләтә гүргә керергәмени инде...

Ана белән кыз уртак фикергә килә алмадылар, үпкәләшкән килеш йокларга яттылар. Ә иртәгесен җаннарын тетрәтеп коточкыч кайгылы хәбәр килеп иреште: төнлә белән Сәмига вафат булган иде.

Мөкәррәмә хушлашырга бара алмады, рөхсәт итмәделәр. Ә тагын ике көннән Нәгыймә аны район хастаханәсенә алып төшеп китте.

Сәмига клубта окоп казыганда авылны шаккаттырырга дип өйрәнгән биюләрен биеп күрсәтә алмады.

* * *

Хастаханәдә авырулар күп түгел иде. Башлыча хәвеф-хәтәргә юлыгып имгәнгән кешеләр. Хәмдия исемле кыз җәйдән бирле ята икән инде. Комбайн әвәрәсе чәчене белән баш тиресен умырып алган. Вакытны әрәм итәргә теләмичә, әвәрә әйләнеп торган килеш уракны чүп-чардан арындырырга керешкән, ди. Бу хакта ишеткәч, Мөкәррәмәнең йөрәге жу итеп китте. Ул да урак өстендә Вәлинурның лабогрейкасы алдыннан җил-яңгыр чуалткан арыш сабакларын торгызып йөргән иде бит. Аның да каршында көн буе шундый ук әвәрә бөтерелеп торды.

Кәбирә дигән хатын арба астында калган. Актаныш тавы бик мәкерле шул ул. Сөзәк булып күренсә дә шактый озын, төшә-төшә арба атны алга таба үзе этә башлый. Гадәттә, тәгәрмәчкә тышау салалар. Тау озын булгач, алар түзми. Кәбирә белән дә

шулай булган. Таунын уртасында тышавы өзелгән дә аты алып киткән... Аягы, өч кабыргасы сынган.

Берничә егет тә бар, ди. Аларны хәрби комиссариат салган.

Мөкәррәмә бу сырхауларның берсен дә күрмәде, шәфкать туташларының сөйләве буенча гына белә. Аны берәү белән дә аралаштырмыйлар, ялгызы чолан кебегрәк кечкенә генә бер караңгы бүлмәдә ята. Корчаңгы көйсез кияү шикелле бик талымлы чир булып чыкты, кадерләтепме-кадерләтә. Хәер, кешегә күренерлеге дә юк лабаса, башыннан аягына кадәр яшел даруга буяп ташладылар, әйтерсең лә, чакырым баганасы. Көн дә ике-өч укол кадыйлар, әллә нинди әчкелтем-төчкелтем микстуралар эчертәләр.

Син күр дә, мин күр, атна-ун көннән хәле яхшыра башламасынмы. И, шатланганлыгы! Җәрәхәтләренең кипшенгәнен күрер көннәре дә булган икән. Сәмига вафатыннан соң килгән беренче куанычы бу. Дөресен генә әйткәндә, әллә үлгән килеш күрмәгәнгә, дустын һаман исән итеп күз алдында тота иде: менә ул тузан туздырып юл буйлап биеп китә, икенче карыйсың, зимагур җырын сузып җибәрә, шунда ук үпкәләп иреннәрен турсайта. Минут эчендә кырыкка үзгәрә иде. Әмма ачу тота белми иде, эче-тышы бер иде.

Шулай да аның терелү куанычын җуеп ташлый яздылар. Иртәнге якта процедура кабинетыннан үз кетәгенә кайтып килеше иде. Ниһаять, бүген беренче мәртәбә уколны кешеләр белән бергә, кабинетка чакырып кададылар. Авыртуны да сизмәде. Шундый рәхәт, шундый җиңел, гүя читлектән азат ителгән кош. Аяклары тигән җиргә—тия, тимәгән җиргә—юк. Терелә бит, терелә!

Баскыч янында ике-өч егет сөйләшеп тора иде. Күрәсең, комиссия уза алмаган рекрутлар шушы инде. Мөкәррәмә йөзендәге яшел тапларны күрсәтмәс өчен килә-килешкә яулыгын тартыбрак куйды. Егетләр яныннан да, сүз куша күрмәсеннәр дип, йомшак кына басып узып китте. Бүлмәсе шундагы аралыкта, уңга гына борыласы. Ишек янына җиткәч, Мөкәррәмә тукталып калды. Кереп китәсе генә калган да соң, юк, хатын-кызларга хас кызыксынучанлык аны тыңланырга мәҗбүр итте: ни-нәрсә турында гәпләшәләр икән—шуны беләсе килде.

—Ярыйсы күренә бу күбәләк,—диде яшь әтәчнеке шикелле калтыравыклы тавыш иясе.

—Кочагы кайнардыр моның, малай, безнең авылга утырмага килсә, бер кешегә дә бирмәс идем, үзем кунар идем,—диде икенчесе.

—Их, сез, бәсәргән күзләр,—дип мыскыллы көлү белән көлде калын тавышлы егет,—корчаңгы бит ул. Кор-чаң-гы!

Мөкәррәмәнең өстенә ләгәне белән шакшы су койдылар диярсең, бөрешеп катты. Атылып бүлмәсенә керде дә йөзтүбән караватка ауды. Үкседе дә үкседе. Моңа кадәр үз чиренең бу ягы турында уйлап караганы юк иде әле аның. Баксаң, корчаңгы кешедән таздан көлгән шикелле үк көләләр икән лабаса! Гарьлеге ни тора. Корчаңгы! Болай булгач, авылда да көн күрсәтмәячәкләр. Хәзер генә төшенде: менә ни өчен дус кызлары аның хәлен белергә килмәгәннәр икән. Кайтасы калмаган. Сәмига да исән-сау булган булыр иде. Илдә чыпчык үлми диләр, җае чыгар иде әле. Хәзер менә күзгә күренергә дә оялып йөр инде. Алай дисәң, ул чирне мич башында ятып алмады ла. Фронт хезмәтендә әлекте аңа сырхау. Башкалар клубта типтереп күңел ачып йөргәндә, көнгә уникешәр сәгать окоп казыды ул.

Мөкәррәмәнең фикер агышы әнә шулай әле бер, әле икенче якка авышты. Шул фикерләр кыршавында үзе дә әле тынычланып китә, әле хафага кала иде.

Төшендә Сәмиганы күрде. Һәрвакыттагыча, буянган-ясанган. Кара каләме бетсә, кышын утын күмере белән сызып булса да каралта иде. Кершән урынына үлән сөте яга, иреннәренә балан, гөлҗимеш боламыгы сөртә. Көен китерә иде.

—Битең бигрәк ак, үлән сөтен мулрак төшергәнсең,—диде Мөкәррәмә.

—Соң, ахирәткәем, матур буласы килә бит.

—Беләсеңме, минем тәнем тулы кычу,—дип зарланды Мөкәррәмә,—һәммәсе көлә...

—Көлмәгәйләре, бер дә исең китмәсен, бие, җырла...

—Ә син үзең?

—Биюләр үкенечкә генә калды шул инде, ахирәткәем... мин бит синең төшеңдә генә яшим... битем шуңа ак... Кара, әйтергә дә онытып торам икән, Мәпти дә монда

килде бит, поезд астында калган… Әбисе кызганыч, нишләр инде?

—Син һаман үзеннекен сукалыйсың, тәнем тулы кычу дип торалар аңа,—диде Мөкәррәмә үпкәләп.

—Уф, үләм, кая, итәгеңне күтәр әле…

Мөкәррәмә итәген күкрәгенә кадәр күтәрде.

—Абау, тәнең күкәй шикелле ич синең,—диде Сәмига,—миндә булса иде шушындый тән…

—Чынлап әйтәсеңме?

Мөкәррәмәнең күзләре ачылып китте. Тиз-тиз генә тәнен капшаштырып карады. Кутырлар урынында иде. Тик алар инде авыртмыйлар да, кычытмыйлар да.

Йөзенә елмаю кунды кызның. Ә иреннәре: "Борчылма, Сәмига, синең өчен дә биермен, синең өчен җырлармын",—дип пышылдады.

Бер алга китсә, китә бит ул, Мөкәррәмә күзгә күренеп рәтләнә башлады: бит очлары алсуланды, күзләренә нур иңде. Озакламый аны хастаханәдән чыгардылар. Ниһаять, мунча керде. Бу ләззәтне әйтеп-аңлатып кына бетерергә мөмкинме соң? Әйтерсең лә, фәрештәләр белән Зәмзәм чишмәсендә юынып чыкты. Тәненнән каен җиләге исе килә, үзе шундый җиңел, өрсәләр, шәт, очып китәр иде. Пакьлек булса, аклык була, дип бик дөрес әйткәннәр. Мунчадан тәнең дә, күңелең дә сафланып чыга икән.

Мөкәррәмәнең "Каен себеркесе хан кызын терелткән" дигән әйтемне ишеткәне бар иде. Әнисе бу мәкальнең мәгънәсен дә белә икән. Сөйләп бирде. Имеш, борынгы Идел буе Болгар ханы Алмасның кызы авырган, гарәп табиблары аңа каен себеркесе белән чабынып мунча керергә кушканнар. Кыз шулай эшләгән һәм терелгән. Чабынып мунча керү шуннан башланган, имеш. Ә хан үзе мөселманлыкка күчкән, ди.

Әни белән кыз бу кичне бик озак серләшеп утырдылар. Карагат кагы салып ясалган хуш исле чәй бу әңгәмәгә үз өенә генә хас үтә бер җылылык биреп тора иде.

—Әнкәй, мин эшкә чыгармын инде,—диде Мөкәррәмә чинаягын тәлинкәсенә каплап куйгач,—болай да озакка китте, бүлнисендә генә айдан артык яттым бит.

—Чиремнән котылдым дип сөен, кызым, эш качмас. Курыккан гамәлнең ахры хәерле була ди, Аллага шөкер, дүкәмит-фәлән дә сорамадылар, нигә качып кайттың, дип тә битәрләмәделәр. Ул бәласеннән дә арындык бугай. Анысына да гел җаным кыелып йөри ие.

—Нинди эш бирерләр икән, әнкәй?—диде Мөкәррәмә. Аның инде узгандагы мәхшәрне исенә дә төшерәсе килми иде.

—Бригадир сораштырып торган ие, атлы эшкә кеше җитми дип зарланды…

* * *

Мөкәррәмә быел кыш килгәнен абайламыйча да калды. Ул хастаханәдә яткан арада чана юлы төшкән иде инде. Урамга чыккач, аклыктан башы әйләнеп китте. Кышның башка бер ел фасылы белән дә чагыштырып булмый торган үз матурлыгы бар. Аның алтын бизәге, әлбәттә, кар. Көненә карап кар мең сурәткә керә. Бер карыйсың, ялтыравыклы энҗе-мәрҗәннәре белән күзләрне камаштыра, икенче карыйсың, ул инде үзле балчык кебек—рәхәтләнеп сыннар ясa; күп тә үтми, тузганак шикелле очып йөри…

Ә бүгенге кар бәсле, уралырга гына тора. Әнә, чана табаны астында шыгыр-шыгыр килеп ни турындадыр көй көйли. Шул көйгә кырт-кырт басып салмак кына ат юырта. Аның тояклары астыннан чыккан кар йомарламнары юл читенә сибелеп-сибелеп китә.

Көн туып кына килә. Йөзе елак баланыкы сыман чытылыбрак тора. Җиһан аксыл томанга төренгән. Шуңа күрә җир белән күк тоташкан кебек күренә.

Барасы җир ерак әле. Шулай да күпләр өчен бу таныш, өйрәнелгән юл. Ел да мәктәпкә утынны Башкорт ягындагы Олы Ялан урманыннан ташыйлар. Мөкәррәмәнең генә беренче баруы. Аңа барысы да кызык, барысы да мавыктыргыч. Кышы да, юлы да, кешеләр дә. Әтисе дә ерак юлга йөри иде. Һәрвакыт Мөкәррәмәгә куян күчтәнәче дип туңып каткан ипи кыерчыклары алып кайта торган иде. Кимерә-кимерә тешләрен канатып бетерер иде. Тәмле дә иде соң ул куян күчтәнәче! Иң гаҗәбе шул, Мөкәррәмә әлеге ипи кисәкләрен куян биреп җибәрүенә ышана иде. Ихтимал, шуңа тәмле булып тоелгандыр да. Инде менә үзенә куян күчтәнәче алып кайтыр вакыт җитте.

Олаучылар әле бер чанага, әле икенчесенә утырып гәп коралар. Мөкәррәмәнең

чанасы янына да классташы Хафәзә килеп елышты.

—Әйдә, төш, җәяү атлыйбыз, нәрсә карт әбиләр шикелле кырын ятып барасың,—дип чыпчыктай чыркылдады. Аннан соң кинаяле генә итеп сорап куйды:—Әллә синә ярамыймы?

—Ярый, нигә ярамасын,—диде Мөкәррәмә.

Алар чана артыннан йөгереп киттеләр. Юл такыр. Аяклар җиңел. Ә кызлар очрашкан җирдә телгә ял юк инде ул. Бигрәк тә Хафәзәнең сораулары күп җыелган.

—Мин сезне укытучыларныкы шикелле якалы пәлтә киеп кайтырсыз дип көткән идем,—диде.

—Без бит сугыш эшендә идек, анда акча түләмиләр икән.

—Егетләр күп идеме, синең егетең бар идеме?

Мөкәррәмә мондый чакта, гадәттә, аяксыз командирны хәтеренә төшерә. Бу юлы хәтта, әллә мактанып алыргамы икән дип, талпынып та куйган иде. Әмма кыенсынуы җиңде, телен тешләде.

—Үзең кем белән йөрисең соң?—дип, сүзне Хафәзәнең үзе ягына борып җибәрде. Хафәзәгә бу ошады, ахры, күзләре төймәдәй түгәрәкләнде, сусыл иреннәре мелт-мелт килеп алды.

—Кара аны, кыз, Каюмга нәфсеңне сузасы булма, ашап бетерермен,—дип, тире бияләе эченнән бармак янады.

Бер дә харап икән, җиденче класста укыганда ук кундылар ич инде алар Каюм белән. Хафәзәнең, күрәсең, шуңа төрттереп әйтүе иде.

Мөкәррәмә дустына җыр сүзләре белән бик кинаяле итеп җавап бирде:

*Аклы күлмәк якасына*
*Брошка кадамыйлар;*
*Өзелеп сөйгән ярың булгач,*
*Ятларга карамыйлар.*

—Әйттем ич, читтә типтергәннәр дип. Җә, сөйлә инде, кем исемле, чибәрме?

—Җырның ертыгы юк, дустым...

—Син тешләктән сүз ала торганмы соң?

Атлар кызулата төште. Шуңа күрә икесе тиң чанага ауды.

—Бияләйләреңне сал, шундый рәхәт,—дип Хафәзә кулларын җилпештереп торды, эссе, янәсе. Аның күптәннән Мөкәррәмәнең шәрә кулларын күрәсе килә иде. Бу хәйләне дә шуңа уйлап тапты.

Мөкәррәмә бияләйләрен салды. Куллары чип-чиста иде.

* * *

Утынны иртән таң белән төяделәр. Ул киселгән, өелгән иде. Җайланмалары да бар икән, артык көч куярга туры килмәде. Тиз-тиз генә төяделәр дә, тиз-тиз генә юлга чыктылар.

Тиз-тиз генә дигәннән, башлыклары буаз Дәүҗия (калын гәүдәле булганга аны авылда олысы-кечесе буаз Дәүҗия дип йөртә иде) бер мәзәк сөйләп көлдерде.

—Удган кышны,—дип тезеп китте сагыз чәйнәгәндәй телен авызында әвәли-әвәли,—Гыйндулла бабай белән Идел аръягына печәнгә бардык. Каравылчы Вәләнтин белән алдан килешеп, майлап-җайлап куйган идек инде. Төн уртасында килерсегед, башланган кибәннән төярсегед,—диде. Тотыла-нитә калсагыд, мин седне белмәймен, сед мине белмәйсегед, дип тә кисәтте. Монысын куркыту өчен генә әйтә инде, ул үде каравылчы бит, дагатскут чутыннан кәеф-сафа корып йөргәнен бөтен тирә-як белә.

Менә шулай бүгенге төсле олауларны җәт кенә тәяп бетердек тә кайтырга чыктык. Атлар шәпле, артларыннан чак-чак җитешеп барабыд. Шунда Гыйндулла бабай:

—Кыдым, тид-тид генә килдек тә, тид-тид генә төядек тә, тид-тид генә кайтырга да чыктык, әллә урлаштыкмы соң бед?—дип әйтеп куймасынмы, исәркәем. Көлсәң көл, җыласаң җыла.

Әле аның хикмәтләре моның белән генә бетмәде. Сөн бодына төшкәч, бер адәм атның башыннан эләктереп алды бит, каһәр. Җаным табан астына йөгерде, баш бетте, мәйтәм, калды муен тырпаеп. Ныклабрак карасам, теге камыт аяк Вәләнтин, авыды ерык. Капшаштырырга ук тотыныды бу имансыд. Китәле, мәйтәм, коры ялан уртасында нәмәдәй сыпыргалану ул, мәйтәм. Каты да бәреләә алмайсың, исәркәем, сыер гәҗиткә генә рида түгел, аңа печән кирәк. Алдап-юллап, иртәгә-берсекөнгә дигән булып,

насила котылдым бу мир кортыннан. Шунда Гыйндулла бабай хәтеремә төште. Нигә ярдәмгә килмәдең, дип сүгәргә иде исәбем. Ә ул юк. Кычкырам, чакырам—ләм-мим. Сыпырткан икән бу диеп уйладым, шуңа кудгаласы иттем. Авылга кайтып житеп, басу капкасыннан үткәч, икенче олауның өстеннән малахай бүреге калыкты бит бабакаемның.

—Кыдым, әллә тотылдыкмы бед?—дип сорай. Печәнне чокып, шунда качып барган картлач.

Гыйндулла бабайныкы кебек үк булмаса да, Мөкәррәмәнең тәүге сәфәре дә хәвефсез генә узмады. Кышкы урманны аның күргәне юк иде әле. Ә ул искиткеч матур икән. Агач ябалдашлары ак мамыкка төренгән. Башларын иеп утыралар, гүя юлчыларны сәламлиләр. Кар өстендә ниндидер чуалышкан сурәтләр күзгә ташлана. Кайсы челтәр-челтәр булып уралган, кайсы чаршау бизәгенн хәтерләтә. Бу—эзләр! Киек-җәнлек күп булырга охшый. Һәрберсе кар эскәтере өстендә үз мөһерен төшереп калдырган. Нәкъ гарәп язуы. Шундый ук серле, шундый ук гүзәл!

Мөкәррәмә мөкиббән китеп шушы матурлыкны күзәтеп бара торгач, бөтенләй онытылып китте, чанасы салуга эләккәнен дә сизми калды. Мизгел эчендә йөкле чана юлга аркылы ятты. Шунда ул икенче хата ясады, хәлне төзәтмәкче булып, бахбайга чыбыркысы белән сыдырып алды. Ат бар булган көченә алга омтылган иде, камыт бавы шартлап өзелеп тә чыкты.

—Бәй, апай, каплана ядгансың бит,—дип Дәүҗия килеп житте. Башкалар да җыелды. Төрлесе төрле киңәш бирде. Тик эш киңәштән узган иде инде. Унбиш-уналты яшьлек бу үсмер кыз балалар тагын нәрсә эшли ала иде соң? Ярый әле, Дәүҗия апалары бар.

—Җарар, апайлар, булды, инде мине тыңлагыд,—дип юл уртасына чыгып басты.—Иң әүвәл Мөкәррәмәнең чанасын тигед жиргә чыгарып куяйыйк. Мин сбруйларыниләре белән Кара алашаны алып киләм, сед бу атны тугара торыгыд.

Иплән-жайлап кына барысы да үз урынына утырды. Дәүҗиянең запас камыт баулары да булган икән. Эш озакка сузылмады.

—Апай, җырлаганда да, сүләшкәндә дә, йоклаганда да бер күдең юлда, икенчесе атта булсын,—дип кисәтте Мөкәррәмәне Дәүҗия.—Икеләнәсең икән, тот та атыңны туктат. Бергә-бергә хикмәте табыла аның. Борчылма, ашка чебен төшмәй тормай.

* * *

Бүген Мөкәррәмә беренче тапкыр клубка чыкты. Ишекне зур дулкынлану белән ачты. Чөнки алар казна эшендә вакытта монда әллә нинди үзгәрешләр булгандыр сыман тоела иде. Бу хакта Сәмига белән төннәр буе сөйләшеп яталар иде. Чыннан да, клуб зураебрак киткән кебек күренде. Якты. Куыклы лампа алганнар икән ләбаса! Тәрәзә пәрдәләре дә элгәннәр. Тәрәзәләрне хәзер тышкы яктан каплыйлар, ахры.

Клуб мөдире Мәгъсүмҗан уен оештырып йөри. Мөкәррәмә, миңа басмасалар ярар иде дип, кеше күзенә күренмәскәрәк тырышып утырды. Тик ул игътибар үзәгендә иде инде. Нигә әйтсәң дә, читтән кайткан бит, кунак кызы дәрәҗәсендә. Егет кәмәшләренең күзе анда, чыш-пыш киләләр.

Әлегә ялгыз бию бара. Уртада—Хафәзә. Җырга гына түгел, биюгә дә оста ул. Сөяге юктыр диләр мондыйлар турында. Бер үк хәрәкәтне бервакытта да ике мәртәбә кабатламас. Сәмига булмагач, ярышыр кешесе дә юк хәзер.

Хафәзә өч-дүрт минут чамасы үзенең осталыгын күрсәтте дә, Мөкәррәмә каршысына килеп басты.

—Оборона хезмәтендә катнашкан алдынгы комсомолка Мөкәррәмә Әмирова!—дип кычкырды Мәгъсүмҗан, гүя сәхнәдән ниндидер күренекле артистны тәкъдим итә иде.

Мөкәррәмә бию ягыннан төшеп калганнардан түгел анысы. Окоп казыганда да кызлар белән төрледән-төрле биюләр өйрәнгәннәр иде. Озак уйлап тормастан, тәвәккәлләде. Ул ярдан суга сикергәндәй көй уңаена бию диңгезенә чумды. Оялуларны, кыенсынуларны ашкынулы бию үзенә йотты. Аяклар белән бергә куллар да, гәүдә дә, йөз дә хәрәкәттә—һәрберсенең үз өлеше, үз вазифасы бар.

Мөкәррәмә әйләнә, Мөкәррәмә белән бергә матчага эленгән куыклы лампа әйләнә, клуб әйләнә, кешеләр әйләнә… Берзаман күзләрен ачса, пары пәйда булган ләбаса! Каюм. Кулларын артка куйган, башын кырын салган, хәчтрүш. Элек Вәлинур гына шулай кыланып бии торган иде. Бу соң? Килешми дә әле. Егетнең исә үз мәнфәгате.

Менә ул җаен китереп кызны култыклап алды, бөтерелеп киттеләр. Шул арада Мөкәррәмәнең колагына: "Мин сине озата барам",—дип пышылдады.

Бераздан Мөкәррәмә егетнең сүзләрен дә, үзен дә онытты. Дуслары белән туйганчы биеде, җырлады, рәхәтләнеп күңел ачты. Ул бик бәхетле иде.

Ә Каюм клубтан кайтканда аны капка төбендә сагалап тора иде инде.

—Абау, кеше куркытып нишләп йөрисең монда?—дип, Мөкәррәмә тиз генә үтеп китмәкче иде дә, егет аның каршысына төште.

—Читтә эре бәрәңге ашаттылармы әллә, бик кылтаеп кайткансың,—диде.

—Кылтаерга кылы туры килми әле монда,—диде Мөкәррәмә шаяртыбрак. Аннан соң бармак янап өстәде:—Бар, Хафәзәң көтә анда, нахак сүзләрдән болай да гарык.

Каюм кызны кочмак булып биленә үрелмәкче иде дә, Мөкәррәмә аның ниятен алдан сизенеп, кисәк кенә читкә тайпылды. Егет гәүдәсен тота алмады, сукмак читендәге көрткә мәтәлеп төште. Мөкәррәмә урамны яңгыратып көлеп җибәрде.

—Хәрам юлда йөрсәң, шулай була ул!

Каюм торып өс-башын каккалады, ләкин китәргә ашыкмады.

—Миңа син ошыйсың,—диде.

—И-и, ошаган кешеләр күп булыр ул, барысы белән дә йөри башласаң...

—Яратам инде алайса...

—Миңа синең мәҗбүри яратуың кирәкми,—дип, Мөкәррәмә тиз генә ишек алдына шылды.

Кемнән чыккандыр, ничек чыккандыр, икенче көнне бу хәбәр авылга таралып өлгергән иде инде. Хафәзә белән алар ат утарында очраштылар. Йөзе кара янган иде дустының. Сәламгә җавап кайтармады. Кашын җимереп астан гына бер карап алды да тырт-тырт басып абзарга кереп китте. Үч иткәндәй аты тоттырмый гына бит. Мөкәррәмә ярдәмгә килде.

—Юкка чыраеңны сытасың, Хафәзә, минем бер гаебем дә юк,—диде ул,—вичырдан кайтканда ул безнең капка төбендә басып тора иде. Мин аны куып җибәрдем...

—Китчәле, корчаңгы тәре, бөтен авылны сасытып бетердең бит инде. Шул килеш оялмыйча егетләргә үрелгән була бит әле, җирәнгеч,—диде Хафәзә ачу белән.

Бермәл Мөкәррәмәнең күзләре әлҗе-мәлҗе килеп торды, аяклары җир катысын тоймый башлады, гүя упкынга төртеп төшерделәр. Шушы кадәр мыскылны ничекләр күтәрергә? Иң элек хәлнең асылын аңларга кирәктер лабаса, теләсә-нинди гайбәткә ышанырга ярамый бит инде. Тәмам яшәрлеген калдырмады...

—Апай, әллә берәр нәмәкәй булдымы, йөдең көл күек агарган,—дип аның янына Дәүҗия килеп туктады. Мөкәррәмә сискәнеп китте.

—Ю-юк, болай гына, Дәүҗияттәй, әллә нишләп башым әйләнеп китте,—дип алдашты.

Мөкәррәмә бу хакта әнисенә дә әйтмәде, ике-өч көн эчтән сызып йөрде. Бәлкем, кызып китү бәласы гына булгандыр, Хафәзә начар кыз түгел, акылына килер, аңлашырбыз, дип уйлады. Чыгырыннан чыгуына үзе дә үкенәдер әле.

Үзен шулай юатты Мөкәррәмә. Ә тагын ике көннән иртән иртүк аны авыл Советына чакыртып алдылар.

—Әйдүк, әйдүк, сеңлем,—дип ачык йөз белән каршы алды аны рәис Миһран.—Сине, ызначит тәк, юньле-башлы күргән дә юк бит әле. Һич бушап булмый, ызначит тәк...

Мөкәррәмә бүлмә эчен күзеннән кичерде. Түр стенадагы зур кәгазь портреттан Сталин карап тора. Ишектән килеп керүгә иң беренче булып юлбашчының кырыс карашы белән очрашасың. Нишләптер тәннәр чымырдап китә. Элек ул урында Ленин бабай рәсеме эленгән иде. Ленин бабай көләч йөзле иде...

—Ызначит тәк, Әмирова,—дип рәсми тонга күчте рәис,—сиңа бер бик җитди паручение бар...

Мөкәррәмә көләмсерәгәндәй итте. Алар дус кызлары белән Миһранның җыелышларда ничә тапкыр "ызначит тәк" сүзен кабатлаганын саныйлар иде. Кайчакта йөзәр "ызначит тәк" җыела иде.

—Менә бу пакетны, ызначит тәк, район милиция бүлеге нәчәлнигенә илтеп тапшырырга кирәк. Комсомол члены буларак, моны сиңа ышанып тапшырабыз. Хәзер үк чыгып кит. Алдан ук кисәтеп куям, ызначит тәк, пакет өчен башың белән җавап бирәсең.

—Бригадир миңа саламга барырга дигән иде, Миһран абзый...
—Борчылма, мин барысын да сөйләшеп куйдым инде.
Кышкы көн чыбыркы сабы кадәрле генә. Шуңа күрә җәт-җәт кыланды Мөкәррәмә. Әйләнеп тә кайтырга кирәк бит әле. Әнисенең юлга әзерләгән төенчеген кулына тотты да сәфәр чыкты. Пакетны ул комсомол билеты өчен махсус теккән күкрәк кесәсенә салды, йөрәк турысына. Шундый җаваплы эшне ышанып тапшыруларына чиксез шат иде. Үзен хәтта Зоя Космодемьянская шикелле батыр йөрәкле ил патриоты итеп тә күз алдына китерде. Юлда, әйтик, андый-мондый хәл була калса, пакетны авызына кабып чәйнәячәк ул. Монысын да алдан тәгаенләп куйды.
Милиция бүлеге башлыгы нindидер кинәшмәдә иде. Шактый гына көтәргә туры килде. "Нинди йомыш соң, бәлкем, ансыз да хәл итеп булыр",—дип караганнар иде дә, кырт кисте.
—Мин Түбән Сөннән бик мөһим пакет алып килдем, аны башлыкның үзенә тапшырырга куштылар,—диде Мөкәррәмә.
Башлык теше-тырнагы белән "бронь" дигән серле калкавычка ябышып ятучы күп балалы милиция капитаны иде. Аның һич тә сугышка китеп, ул-кызларын ятим итәсе килми иде. Шуңа күрә законга Аллага табынган диндар шикелле табына, югарыдан килгән әмер-күрсәтмәләрне җиренә җиткереп үти, кирәк икән, арттырып та җибәрә, фәкать начар эшли дигән сүз генә чыкмасын. "Салдафон" дигән кушаматы үзенә суйган да каплаган инде.
Хәтта ул да конверттагы язу белән танышкач, бермәл исе-акылы китеп торды. Аннан да уздыручылар бар икән ләбаса! Бу аның башына да килмәс иде, мөгаен. Вәйт нинди маладис кеше икән бу Миһран Әхмәдишин. Чын совет кешесе, чын җитәкче!
—Иптәш Мөсифуллин абзый, миңа китәргә ярыймы?—дип сорады Мөкәррәмә. Пакетны иясенә тапшыргач, үзен өстеннән тау төшкәндәй бик җиңел хис итә иде ул.
Мөсифуллин алдындагы кәгазьгә күз салды. Һәм өченче кат түбәндәге сүзләрне укыды: "Иптәш капитан Мөсифуллин! Бу пакетны сезгә тапшыручы Әмирова Мөкәррәмә Сафагәрәй кызы тупас рәвештә совет законнарын бозучы җинаятьче. Ул вербовка нигезендә оборона эшләренә җибәрелгән җиреннән качып кайтты. Бернинди документлары да юк. Чара күрүегезне үтенәм.
Актаныш районы, Түбән Сөн авыл Советы башкарма комитеты рәисе Әхмәдишин Миһран. 11 декабрь, 1942 ел".
Башлык өстәл кырыена беркетелгән кара төймәгә басты. Шундук ишек уемында озын мыеклы милиционер пәйда булды.
—Тыңлыйм иптәш капитан!
—Гражданка Әмированы изоляторга алып китегез. Төпкә менә шушы представление белән теркәсеннәр.
Капитан милиционерга нindидер язу тоттырды.
Мөкәррәмә бу сүзләргә ышанмады.
—Ярар инде, иптәш Мөсифуллин абзый, шаяртмагыз әле,—дип китәргә җыена башлады.
—Оборона хезмәтеннән качып кайткан өчен башыңнан сыйпарга кушар идеңме әллә?—дип кычкырды капитан.—Алып китегез!
Милиционер Мөкәррәмәнең кулларына богау салды.
Кар башына кар җитә, адәм башына адәм җитә. Хак әйтем. Ә хатын-кызның көнчеллеге елан зәһәреннән дә хәтәррәк. Мөкәррәмә адәми затның әлеге зәһәрлеге белән әнә шулай бик иртә очрашты. Уналты яшендә үк карама көләнә утырттылар. Бу Хафәзә эше иде. Ул аны соңыннан гына, күп еллар үткәч кенә белде. Мөкәррәмә үзләренең капка төбендә Каюм белән үбешеп тора иде дигән хәбәр килеп ирешүгә, кызның башына үч дулкыны бәрде. Уйлана торгач, әмәлен дә тапты. Комсомол секретарена Мөкәррәмә өстеннән шикаять язып бирде. Секретарь үз чиратында бу мөһим мәсьәләне авыл Советы башкарма комитеты рәисенә җиткерде. "Әмирова турында түбәннән сигналлар килә башлады,—дип язды ул аңа,—болайга китсә, безне сәяси сукырлыкта гына түгел, дәүләт мәнфәгатьләренә хыянәт итүдә дә гаепләячәкләр".
Шулай итеп, тегәрмәч хәрәкәткә килде. Бер кузгалып киткәч, әйләнә инде ул. Тотып та тыя алмыйсың. Сигналлар заманы, кешеләрне батыру заманы иде бит. Сүз дәлилләрдән өстен йөри торган заман.

* * *

Хатын-кызлардан төрмәдә алар икәү генә иде. Бурсык дигән авылдан Нәгыймә исемле хатын атнадан артык утыра икән инде. Каты бәгырьле хатын. Мөкәррәмәгә дә җебеп төшәргә ирек бирмәде.

—Монда күзләреңнән таш атылып чыкса да ишетүче юк, сеңлем, юкка бетерешмә,—дип киңәш бирде.

—Әнкәй мине районга йомыш белән генә китте дип белә бит...

—Хафаланма, яман хәбәр тиз ирешә ул, җиткергәннәрдер инде.

—Нигә бу кеше дигәнең шулай кара эчле икән, турысын гына әйтергә дә була ич?!

Мөкәррәмә яңа танышына текәлеп карап торды. Бу гади авыл хатынының килеш-килбәтеннән үк ниндидер олылык, мәһабәтлелек сизелеп тора иде. Ялгышмады. Үзенчә зирәк, үзенчә мәгънәле иде ул.

—И, сеңлем, безнең әткәй: "Ак эт ни, кара эт ни—бар да эт",—дип әйтә торган иде. Шуның кебек инде, куштаннар хөкеменә калдык. Тьфү-тьфү, әйтмәгәнем булсын, Аллаһы тәгаләне дә саташтырып бетерделәр инде ул иблис токымнары. Алла ул бер генә. Ә безне тагын бер Аллага табынырга мәҗбүр итәләр.

—Нәгыймәттәй, алай сөйләмә, мин куркам...

Хатын аны тыңламады, дәвам итте:

—Мине, өч балалы ялгыз ананы, бүген-иртәгә суд көтә. Ни өчен дисеңме? Синеке кебек үк әләк. Сүзен әйттем, танмыйм. "Китегез әле, Сталин кайгылары юк әле монда",—дидем. Соң, Сталинның рәсемен сатып алып, өй стенасына эләргә мәҗбүр итәләр бит. Рәсем сатып алырлык акчам булса, балаларыма бирәр кәнфит алып ашатыр идем. Кәнфит төмен дә белми үсәләр бит, бәгырькәйләрем. Бер куштаны сүзләремне парторгка җиткергән. Хәзер, әнә, сәяси статья чәпеп куйдылар. Моңарчы сәяси статья дигәннең исемен дә ишеткәнем юк иде...

Сүзләре шушында өзелде. Чөнки тышкы яктан тимер ишеккә уелган рәшәткәле тәрәзәнең келәсе шалтырады. Күп тә үтми, анда Мөкәррәмәгә богау салган милиционерның мыегы, аннан соң йөзе күренде.

—Әмирова, җыен, тикшерүчегә!—дип сөрән салды ул.

Нәрсәсен җыенып торасың инде, урыныңнан торасың да, шуның белән шул. Ишек ачылганчы Мөкәррәмә бусага янына барып баскан иде инде.

—Куыралар борчакны, эшне кызу тотмакчылар,—дип сөйләнеп калды Нәгыймә.

Тикшерүченең исеме җисеменә туры килми иде. Гөлүсә дигән исемне ишетүгә, күз алдына зифа буйлы, чия иренле, бит алмалары алсуланып янып торган чибәр кыз килеп баса. Тикшерүче исә кыска муенлы, калын гәүдәле, килешсезрәк кыяфәтле бер ханым иде. Ә тавышы күгәрчендәй гөрелди, ул авызын ачуга беренче тәэсирләр минут эчендә эреп юкка чыга.

—Әйдә, багалмам, уз, утыр, Тукаебыз әйтмешли, "әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем" без дә әз-мәз гәпләшеп алыйк әле,—дип, ул Мөкәррәмәне түгәрәк калай мич янындагы агач кәнәфигә утыртты. Үзе дә шунда сыенды. Әйбәт апага ошаган, чыгарып җибәрмәсме әле, дип шатланып куйды кыз. Өметсез шайтан гына ди, ул әле һаман ышанычын югалтмаган иде. Тик авылга кайтырга гына соңарды, берәрсенә куна кермичә булмастыр, ахрысы.

Тикшерүче башта әти-әнисе, туганнары, авыл, колхоз турында сораштырды, хастасы хакында ишеткәч, бөтенләй ах-ух килде. Акрынлап-җайлап кына читтәге хәлләргә күчте, окоп казу эшенең ничек оештырылуы белән кызыксынды. Ахырдан таштай авыр кулларын Мөкәррәмәнең җилкәсенә салды да:

—Ярар, багалмам, бүгенгә җитеп торыр, танышу өчен генә чакырткан идем, ипле кыз күренәсең, уртак тел табарбыз дип уйлыйм,—диде.

—Иптәш Хатыйпова апа, мине чыгармыйсызмыни?—дип, Мөкәррәмә тикшерүчегә ялварулы караш ташлады.

—Бу минем сорауларыма түкми-чәчми ихластан җавап бирүеңнән тора, багалмам,—диде тикшерүче,—иң мөһиме: исем-фамилияләр!

Хатыйпова кул да куйдыртмады, бернинди кисәтүләр дә ясамады. Шуңа күрә Мөкәррәмә шикләнүсез анда сөйләнгәннәрне Нәгыймә белән уртаклашты.

—Сеңлем, сак бул, син фамилияләрен атаган кешеләр көне-сәгате белән төрмәгә ябылачак. Моны миңа бер укытучы бик нык кисәтеп әйтте. Бер генә көн бергә булып

калдык. Аны этап белән Минзәләгә алып киттеләр. И кысты пыркарур мине дә, и кысты. Шөкер, берәүнең дә өстеннән тормадым.

—Нигә кирәк соң аларга бер гөнаһсыз кешеләрне батыру?

—Никадәр күбрәк кеше "фаш ителсә", шул кадәр яхшырак икән. Эшләре әйбәт күренә икән. Төркем булса, аеруча отышлы, ди. Хөкүмәткә халыкны йөгәндә тотарга да унай, дип сөйләде әлеге укытучы. Аны да сүз өчен кулга алганнар. Кешеләрне ачка-ялангачлыкка калдырды дип, колхозны сүккән.

Нәгыймәгә икенче көнне суд булды.

—Сыттылар, сеңлем,—диде ул камерага китереп япкач,—унбиш ел чәпәделәр. Улым белән кызларымны балалар йортына бирәчәкләр, йорт-җир, мал-туар колхозга кала. Ирем Закир сугыштан кайткач, үз өлешен кайтарып алачак, имеш. Менә шулай, сеңлем, минем тормышка крис суктылар. Дөньялары киңәер инде...

Батыр булып күренергә тырышса да, Нәгыймә бераздан йомшарып төште, үкси-үкси елый, үзенә урын таба алмыйча йөренә. Мөкаррәмә аны ни дип юатырга да белмәде. Ә иртән торганда Нәгыймәнең урыны буш иде инде, аеруча куркыныч тоткын булганга күрә аны төнлә үк алып киткәннәр иде.

Мөкаррәмәнең төрмәдән чыгу турындагы хыялларына да шуның белән нокта куелды. Ул да куркыныч тоткын. Дизертир. Тик нигәдер аның суды һаман сузылып килде. Барысы да элеккечә. Тикшерүче Гөлүсә Хатыйпова гына өстендәге сарык тиресен салып ташлады. Багалмам сүзен сатлык, контр, шпион сүзләре алыштырды. Ә сорау шул ук: качарга кем котыртты? Ни хикмәт, тикшерүче тузынган саен, кирелеге арта гына барды Мөкаррәмәнең. Ул үз язмышын кабул иткән иде инде. Аңа төрмәдән котылу юк.

Ләкин, һич көтмәгәндә, тәкъдир җиле юнәлешен бермә-бер үзгәртеп куймасынмы. Бу 1943 елның 2 мае иде. Гадәттәгечә, Мөкаррәмәне нәкъ иртәнге җиледә тикшерүче бүлмәсенә китерделәр.

—Җә, Әмирова, бүген, ниһаять, телең ачылыр дип уйлыйм,—дип каршы алды аны Хатыйпова. Беләсеңме ни өчен? Белмәсәң әйтәм, бүген Бөек Ватан сугышы тарихына алтын хәрефләр белән язып куелачак Сталинград эпопеясының зур уңыш белән тәгәлләнүенә нәкъ өч ай тулган көн.

Мөкаррәмә дәшмәде.

—Җилкәләреңне сикертмә, Әмирова, син бит кайчандыр октябрят булгансың, пионерда, комсомолда торгансың. Совет власте үзеңә белем биргән. Синең аяк терәп котыртучыларыңны яклавың ул иптәш Сталин җитәкчелегендәге большевистик коммунистлар партиясе тоткан генераль курска каршы килү дигән сүз. Менә бит эш нәрсәдә, Әмирова!

—Мине берәү дә котыртмады,—диде Мөкаррәмә,—мин үзем, үз теләгем белән качтым.

—Ә Хөрмәтуллинаны син ияртгенме?

—Ул юк инде. Үзе өчен үзе җавап биргән булыр иде.

Хатыйпова үз-үзен белештермичә өстәлгә китереп сукты. Өстәл өстендәге түгәрәк кара савыты туп шикелле сикергәләп-сикергәләп торды да, идәнгә төшеп ватылды. Бүлмәгә эт шомырты исе таралды. Күрәсең, монда да карага кытлык иде.

—Алып китегез бу контрны!—дип кычкырды ул ишекнең тышкы ягында сакта торучы милиционерга.

Мөкаррәмәне әлеге бүлмәгә өч көннән соң гына алып килделәр. Бу юлы анда яңа кеше иде. Чәчләренә сык куна башлаган олырак яшьтәге бер ябык хатын.

—Сез Әмирова буласызмы?—дип сорады ул аннан күзләренә туп-туры карап.

—Әйе-е, Ә-әмирова,—дип сузды Мөкаррәмә. Гаҗәп иде. Чөнки моңа кадәр аңа берәүнең дә сез дип мөрәҗәгать иткәне юк иде әле. Контрдан Сезгә әйләнде дә куйды.

—Әмирова, сез әле һаман да хәрби хезмәт армиясендә исәптә торасыз,—диде ябык хатын нотык сөйләгәндәй көр тавыш белән,—хәзерге теркәлгән урыныгыз—Кама урман хуҗалыгы. Иртәгәдән шунда чыгып китәсез. Документлар әзер.

—Ә... мин... ничек... апа...

Мөкаррәмә берара сүз таба алмый торды.

Хезмәт инспекторы аның халәтен аңлый иде, әлбәттә. Шуңа күрә кыска гына итеп аңлатма бирүне кирәк тапты.

—Суд эскәмиясенә утыртырга сезнең яшегез житеп бетми,—диде.

Мөкаррәмәнең миенә бу сүзләр барыбер барып җитмәде. Шулай да ниндидер эчке

сиземләү белән үзенең төрмәдән котылачагын аңлап алган иде инде. Ул түгәрәк мич янындагы кәнәфигә авып, үксеп еларга тотынды.

* * *

Бервакыт, әле сугышка кадәр, әтиләре ат җигеп, әнисе белән икесен Идел тамагына бөрлегән җыярга алып барган иде. Бөрлегән—мыж. Таллык эчендә башларын җиргә иеп мөмрәп утыралар. Берсен өзүгә, икенчесе, мине онытып калдыра күрмә, чибәркәй, дип, учка сылана. Үзләре эре, кабуга авыз тула. Татлының татлысы, кәрәзле балың бер якта торсын. Тик монда кигәвеннәр битаман бизгәге шикелле йөдәткеч икән, ябышырга гына торалар. Аэропландай канатларын җәеп очып киләләр дә тәнгә кадалалар. Күздән очкыннар чәчри мәгәр. "Әрекмән яфрагы белән куала син аларны",—дип өйрәтте әнисе. Куып кына бетерерлекмени ул канэчкечләрне, бөтен болынны урап алганнар бит, әнисе ничек түзәдер, чәбәләнми дә.

—Бар, су буйларыннан ураштырып кил, кызым, җилле җирдә булмыйлар алар,—диде әнисе аның хәленә кереп.

Мөкәррәмә пароход тавышлары ишетелгән якка йөгерде. Яр якында гына икән, тал куакларын үтүгә, борынына су исе бәреп керде. Агыйдел дә дулкыннарын чупылдатып шунда гына җәйрәп ята. Уртада ниндидер бер пароход ух-ах килә.

—Сал өстери,—диде әтисе. Ул да кызы янына килеп баскан. Күрәсең, эшен бетергән, илле усак баганалыкка язу алып килгән иде. Бәрәңге бакчасының читәнен яңартмакчы.

—Әткәй, карале-кара, әллә ут чыккан инде,—диде Мөкәррәмә куркыныбрак.

—Юк, янгын түгел ул, кызым,—диде әтисе,—салчылар әбәт пешерә булыр. Алар шулай куна-төнә сал агызалар.

—Күңелледер аларга утырып баруы...

Мөкәррәмә салчыларга көнләшеп карап калган иде ул вакытта. Ниндидер әкияти затларга ошаткан иде ул аларны. Бигрәк тә су өстендә учак ягу ошаган иде.

Үзе дә менә сал өстендә учак тергезү белән мәшгуль. Шырпыга кытлык. Шуңа күрә учакны һаман карап, күзәтеп торырга кирәк.

Сал агызу читтән күзәткәндә генә мавыктыргыч тоела икән. Чынында, бик четерекле, бик авыр эш икән. Беренче көннәрдә иңбашларына кан савып җәфалады. Кулда озын саплы багор, көнозын бүрәнә бәйләмнәрен тикшереп йөрисең. Бара-бара аларның трослары бушый икән. Җитмәсә, куркыныч та, бүрәнәләр арасында кысылып имгәнүең дә бар. Андый фаҗигале хәлләр еш булгалый, ди. Баш салчы Вәчли агай сукрана, элек кыз-катынны салга аяк та бастырмый идек, ди, салдагы кыз-катын бәлагә ул, ди. Нишлисең, ир-ат сугышта, сал агызырга яшь кызларны хезмәт армиясе аша җыярга туры килә. Вәчли агай командасында, әнә, тугыз кыз. Фронт кешеләрне генә түгел, агач-ташны да йотып кына тора икән, житкер генә.

Учак өрүгә дөрт итеп кабынып китте. Хәер, ул үзеннән-үзе дә кабынган булыр иде, мөгаен. Чөнки җәйнең кыл уртасы. Күкнең иң зәңгәр, кояшның иң кызу чагы. Төш вакытында күләгә бармак буе гына булып кала. Су өстендә җиләс. Йомшак җил иркәләнеп биткә сарыла, сал читендә дулкыннар шаярыша, вак балыклар сикерешә. Тирә-якта үзенә бер кабатланмас хозурлык. Иделнең уң ягында да, сул ягында да печән чабалар. Печән уңгандыр быел. Кибәннәр мул күренә, очлы башларын тырпайтып, Мисыр пирамидалары кебек яр буена тезелешкәннәр.

Сал шәһәр-авылларны, печән кибәннәрен артта калдырып, көне-төне агым уңаена чакрым саный. Буксир аңа чайпалырга, салуларга ирек бирмичә иплəп кенә бер эздән алып бара. Кызлар үзләре дә бүрәнәләргә көйсезләнергә ирек бирмиләр, багор белән хәзер башларына тондыралар. Адашканнарын шундук көймә белән куып тоталар. Өйрәнделәр инде. Вәчли генә һаман, сал агызу кыз-катын эше түгел дип, җаннарын битәрли.

Шуңа да карамастан, Сембер, Самара, Сарытау калаларын ялга чыккан сәяхәтчеләр кебек җырлашып кына узып киттеләр. Көн элеккечә якты, нурлы, мәрхәмәтле иде. Иртән мул булып чык төшә, көнозын күктә кояш балкый.

Ә бердән-бер көнне кояш бишегенә килеп җитә алмады, аксыл томан арасына төшеп югалды.

—Иртәгә кунаклар килер ахрысы, итәк-чабуларыгызны җыештырыбрак торыгыз,—диде башлык.

—Нинди кунаклар ул, Вәчли абый?—дип сорады Мөкәррәмә.
—Каян җыелдыгыз соң сез монда җыен аңгыра бәрән, кояш болыт эчендә баеса, яңгыр киләсен дә белмисезме әллә,—дип кабынып китте тегесе.

Кызлар, гадәттәгечә, чырык-чырык көлештеләр. Иртән дә йөзләрендә мут елмаю иде. Чөнки яңа көн дә нәкъ элеккеләре сыман якты, кояшлы иде. Шулай да яңгыр кайдадыр таулар артында мыштым гына сагалап торган булган икән. Өйләдән соң офыкта карга оясы кадәрле генә бер болыт калкып чыкты да, әче камыр шикелле кабарып, минут эчендә ярты күкне каплап та алды. Әле карасу-зәңгәр төскә керә, әле котырынып килгән ак башлы дулкын рәвешен ала. Кояш та, мескенем, тотылгандагы сыман, тоныкланып калды. Күп тә үтмәде, сулышны кысып, усал җил исеп куйды. Артыннан ук давыл купты, яшен яшьнәде, колакларны чатнатып күк күкрәде.

Буксир озын-озын итеп өч мәртәбә гудок бирде. Бу аның салдагыларны, дөресрәге, Василий Плотниковны кисәтүе иде. Үз чиратында баш салчы:

—Багорларыгызны кулларыгызга алыгыз, постларыгызга басыгыз,—дип хәрбиләрчә әмер бирде.

Берничә минут эчендә җил Иделне урыныннан кузгатып җибәрде, айкалдырырга-чайкалдырырга тотынды. Сал ишкәксез көймә сыман бәргәләнә, суккалана, бүрәнәләр шыгыр-шыгыр килеп ыңгыраша. Берзаман ул елга кырыена авыша башлады. Буксир җан-фәрманга тартыша, әгәр тростлар өзелә-нитә калса, салның таралуы да ихтимал иде.

Өстән дөбер-шатыр килеп яңгыр коя, аяк астында Идел котырына. Вәчли алардан да уздыра. Яшен шикелле, бер карыйсың, салның баш өлешендә нидер рәтли, икенче караганда, ул инде койрыкта әвәләнә. Авызында гел сүгенү, Мөкәррәмәне дә буш калдырмады, бер узуында әни-әтиләренең кабер такталарын исенә төшереп китте.

Кыз аңа әһәмият бирмәде, нииндидер шомлы тавыш ишетелгәч кенә башын күтәреп карыйсы итте. Һәм үзе дә кычкырып җибәрде:

—Вәчли а-а-бый!

Василий суга мәтәлеп төшкән иде. Кожаны күркә койрыгы шикелле кабарган. Әлегә ул троска өстерәлеп бара, тик күчә озакка барырмы?

—Аңгыра, багорыңны суз, тизрәк!—дип кычкырды Мөкәррәмәгә.

Хәзер инде кыз авыр хәлгә калды, ничек кенә көчәнмәсен, алыптай зур гәүдәле ир-атны өстерәп чыгарырлык көче юк иде. Ләкин нидер эшләргә кирәк. Ул кычкырырга тотынды.

—Коткарыгыз, коткар!!!

Мөкәррәмәнең тавышлары карлыгып бетте, берсендә, ниһаять, аның йөрәк өзгеч тавышы кызларга ишетелде. Йөгерешеп килделәр. Инде багор сабына барысы бергә ябышты. Василий да җан-фәрманга тыпырчына, тик агым көчле, күтәрелергә ирек бирми.

—Икенче багор белән бил каешыннан эләктереп алырга кирәк,—диде Мөслимә исемле Әгерҗе кызы.

—Кожаны кабарып каткан бит...

—Кәҗәненә элгәме, каешынамы, барыбер түгелмени,—диде Мөслимә.— Булышырга әзер торыгыз.

Бер омтылышта ук Мөслимә Василийның кожаныннан эләктереп алды. Тырыша-тырмаша аны сал читенә тартып китерделәр, аннан соң өскә өстерәп менгезделәр.

—Постларыгызга басыгыз!—диде Василий, үзе дә багорын кулына алды. Әйтерсең лә, бернәрсә дә булмаган иде.

Яңгыр үткәч, ул куышында көмешкә эчеп, төне буе үз-үзе белән сөйләшеп ятты. Бу хәлләрдән соң Вәчли агай: "Сал агызу кыз-катын эше түгел", дигән сүзләрен оныгыр инде, дип көлешкәннәр иде кызлар. Өметләре генә акланмады.

—И, керәшен тәре,—дип сүгенде Мөслимә.

Тагын бер хәтәр хәлгә юлыктылар әле алар. Монысында үзләре катнашмады, шаһит булып күзәтеп кенә тордылар. Әмма Мөкәррәмәнең йөрәгендә мәңгелеккә уелып калды әлеге вакыйга. Сугышның аяусызлыгын, кансызлыгын үз күзләрең белән күрү, үз җаның аша үткәрү газеталарда язганга, радиода сөйләгәнгә караганда мең мәртәбә хәвефлерәк икән.

Сталинградка якынлашып киләләр иде инде. Печән кибәннәрен, тәзек авыл-шәһәрләрне җимерек корылмалар, морҗалары гына тырпаеп утырып калган өйләр,

кара янган агач-куаклар алыштырды. Пәри туе узган диярсең.

Мөкәррәмә Мөслимә белән төнге дежурда иде. Икесе ике башта. Җәен кояш бишегендә озак юанырга яратмый ул. Батарга да өлгерми, елмаеп-көлеп килеп тә чыга. Мөкәррәмә төн үткәнен сизми дә калды. Әүвәл Идел аръягындагы әрәмәлекләр өстендәге челтәр болытларга ал нурлар кунды, аннан соң кояш үзе күренде. Шул вакыт ачык күк өстендә ике очкыч пәйда булды. Кыз моңа гаҗәпләнмәде, чөнки бу гадәти күренеш, фронт зонасында ич инде алар. Танклар да күренә, автомобильләр дә, солдатлар да. Ә бу очкычлар нигәдер үзләрен бик сәер тота. Тузынган куч кортларыдай тыз-быз киләләр. Әле моторларын үкертеп түбән томырыла, әле өскә ыргылалар. Куышып китәләр дә, инде маңгайга-маңгай бәрелешеп челпәрәмә килделәр дигәндә генә, янә аерылышалар.

—Үз башына котырына, сабакы,—диде Вәчли. Ул инде торып чыккан иде. Кызлар да аның янына тезелешеп басканнар.

—Имән түмәре шикелле тумпак борынлысы безнеке,—дип аңлатты Василий, аның һава сугышын беренче генә күрүе түгел иде.—Әнә, канатында йолдызы да бар, күрәсезме?

—Күрәбез,—диделәр кызлар бертавыштан.

—Хәзер ул немеч малаеннан әнисенең кабер тактасын санатачак.

Кызлар аһылдап куйды. Чөнки нәкъ шушы вакытта очкычлар тагын йөзгә-йөз килеп очраштылар да, күккә күтәрелеп, аслы-өсле калдылар. Шул ук мизгелдә йолдызлы очкыч тәтенгә уралды. Василий ачы итеп сүгенде.

Ул арада каяндыр тагын берничә очкыч килеп чыкты. Алар фашистка качарга ирек бирмичә карчыга кебек аның өстенә ябырылдылар.

—Маладис, каптырдымы … авызына…

Василий янә сүгенде. Ул яманлыкка да, яхшылыкка да үзенең мөнәсәбәтен шулай сүгенү аша белдерә иде.

Салны тапшырып, буксир пароходы ягулык салырга киткәч, кызлар ярты сәгатькә генә яр буена чыктылар. Исләре-акыллары китте. Бер генә төзек бина да, бер генә төзек корылма да юк иде монда. Ничек җимерергә мөмкин, шулай җимергәннәр. Бу нindидер бөтенләй башка дөнья иде, хәрәбәләр дөньясы. Шул хәрәбәләр арасында карачкы сыман кешеләр дә күренгәли. Бернәрсәдә гамьнәре юк, әйтерсең лә, тере мәетләр.

Мөкәррәмә калтыранып китте.

—Әйдә, җәтрәк атла,—диде ул Мөслимәгә,—каберлек бит бу.

Мөкәррәмә бу бинаһая зур каберлектә бер миллион йөз меңнән артык кеше күмелгәнен белми иде әле. Ихтимал, әгәр үз вакытында дөрес хәрби стратегия эшләнгән булса, бу югалтуларны күпкә киметергә мөмкин булыр иде. Тик кәтмәгәндә *(бездә һәр вакыйга шулай көтмәгәндә башка ябырыла)* сентябрьнең (1942) егерме икенче көнендә таң белән немецларның танк корпусы оборонада торган Совет гаскәрләрен икегә ярып үтә, Идел ярларына килеп чыга. Шәһәрдә ике йөз мең кеше бүленеп кала. Аларның язмышы бераүне дә борчымый. Хәтта Мәскәү түрәсе Маленковны да, монда килгәч, башлыча аны "Сталинградская правда" газетасының нигә чыкмавы күбрәк кызыксындыра.

Бераздан солдатлар күренә башлады. Бәлкем әле Вәлинур да шушындадыр, дип уйлап куйды кыз. Мөкәррәмәне күреп алса, нишләр иде икән? Мөгаен, кочаклап алыр иде, үбәр иде, ярату сүзләре әйтер иде… Ул да элекке кебек авызын йомып, оялып тормас иде…

Хыялларына бирелеп бара торгач, Мөкәррәмә алдарак атлаучы солдатларның берсен чын-чынлап Вәлинурга ошата башлады. Ул инде, ул! Әнә, ничек кәпрәеп атлый. Чибәр бит ул, шуңа кылтая. Һаман шул гадәтен ташламаган икән әле. Җанашым!

—Вәлинур, туктале, тукта, бу мин, Мөкәррәмә!—дип кычкырды кыз. Солдат борылып карады. Бу җирән мыеклы урта яшьләрдәге кеше иде. Елмаеп, Мөкәррәмәгә кул болгады.

* * *

Мөкәррәмә төшендә үзен күрде. Ләкин танымады. Башына малахай бүрек киеп нишләп йөри бу кызый урманда дип борынын җыерды. Кит инде булмаганны, биленә әллә нинди килешсез брезент каеш буган. Аякларында аю кереп оялардык зур соры итекләр. Кулында—пычкы. Урман кисүче инде бу, мөгаен. Әнә, янында үзе шикелле үк ирдәүкә кызлар яныш-пешеп ботак турыйлар.

Төймә борынлы бу кызны кайда күрде соң әле ул? Окоп казуда эшләделәрме әллә? Бәлкем, бергәләп сал агызганнардыр? Тукта-тукта, бу үзе ләбаса! Абау, ямьсезлеге. Пәри. Шушы кыяфәтендә Вәлинур күрсә, куркып качар иде...

Уянганда күзләрендә яшь иде Мөкәррәмәнең. Озак кына уйланып ятты. Вәлинурга ул тәки хат яза алмады бит. Ашкынып-дәртләнеп йөргәндә төрмәгә эләкте. Ә анда егетләр кайгысымы соң? Фронтта дошманга каршы сугышып йөргән каһарман төрмәдә утыручы кыз белән хат язышырга да теләмәс иде әле.

Вәлинур акрынлап аннан ерагая барды. Егет элек тә буй җитмәс биеклектә иде, хәзер исә хыял канатларында гына утырып калды. Сөйгән яр болытдан биграк, ул аның кинәшчесе, табынучысы иде. Һәр гамәлен иң башта Вәлинур иләге аша уздыра, күңеленнән фатыйхасын ала.

Бу көннәрдә Вәлинурга аеруча еш мөрәҗәгать итә Мөкәррәмә. Ник дисәң, бергә эшләгән иптәш кызлары аны үзләренең мәҗлесләренә, күңел ачуларга чакыралар, әллә кемнәрне димлиләр. Ә ул бозык юлга кереп китмәгәем дип шикләнә. Сөйләгән сүзләренә, үз-үзләрен тотуларына караганда, кызлар инде ир-ат якасын иснәргә дә өлгергәннәр.

Мөкәррәмә дә фәрештә кызы түгел, билгеле, уйныйсы да, җырлыйсы да, шаярышасы да килә. Ихтимал, әлеге уеннарга элегрәк үк тә катнашып киткән булыр иде, аерым фатирда яшәве тоткарлады.

"Кама" урман хуҗалыгына Мөкәррәмәне җәй башында җибәрделәр. Ул вакытта читтән килгәннәр юк дәрәҗәсендә иде әле. Шуңа күрә аны фатирга урнаштырдылар. Хуҗабикә рус милләтеннән. Бик мәрхәмәтле, юмарт карчык. Әмма каты куллы. Боргаланганны-сыргаланганны өнәми. Мөкәррәмәне дә тәртиплелеге өчен үз итте. Бергәләп матур гына яшәп киттеләр. Кызлар исә гомуми торакта көн күрәләр. Үзләренә үзләре хуҗа, ни телиләр, шуны эшлиләр. Чүлмәге булгач, капкачы табыла дигәндәй, егет-җиләнгә дә кытлык сизелми. Урман эшенә кышкы сезонга бер рота яшь солдат китереп түктеләр. Себерке асты саен кияү хәзер.

Беркөнне аны Мөслимә туган көн мәҗлесенә дәште.

—Ике-өч кенә пар булабыз, килмәсәң үпкәлим,—диде.

—Минем парым юк бит,—дип көлемсерәде Мөкәррәмә.

—Вәлинурыңа ошаган берәр солдат табылыр әле,—диде Мөслимә уены-чыны белән бергә.

—Бел, Вәлинур бер генә ул,—диде Мөкәррәмә,—башка аның белән авызыңны чайкыйсы булма.

Вәлинур мәсьәләсендә талканы коры аның. Ләкин үзе кунакка җыенганда пар күгәрченле кульяулыгын киштәгә куеп калдырды. Әгерҗедә югалта язганнан соң ул аны һәрвакыт кесәсендә йөртә башлаган иде.

—Ярар, ярар, шаяртам гына. Барыбер ялгыз гына утырмассың бит инде.

Мөкәррәмәнең бер кием базар оегы бар иде, туган көн бүләге итеп Мөслимәгә шуны алып барды. Тегесе бик сөенде. Табынны бергәләп әзерләделәр. Өстәл өстенә беренче булып Мөслимәнең әнисе җибәргән каклаган казның арт саны менеп кунаклады. Аның янына агач табакка чүмәкәй итеп өелгән бәрәңгене китереп куйдылар. Авыздан сулар китереп, булары чыгып тора. Бер бөтен ипи туралды. Бусы кызларның көнлек нормасы. Дистәгә якын йомырка—монысы инде авыл күчтәнәче. Шулар янына Мөкәррәмәнең хуҗабикәсе Валентина Петровна биреп җибәргән тозлаган кәбестә белән тозлаган кыяр да урын алгач, табын чын бәйрәм төсен алды. Тик нәрсәдер җитми иде, ахры.

—Ә... ни...,—дип, Тәгъзимә исемле кыз Мөслимәнең җиңеннән тартты.

—Тсс... егетләр,—дип пышылдады тегесе.

Табын әзер. Ләкин әле утырышырга ашыкмыйлар, ялт та йолт караналар. Тәгъзимә түзмәде, өстенә тунын элеп, урамга чыгып йөгерде. Шактыйдан соң гына әйләнеп керде. Авызы-борыны салынган.

—Күренмиләрме?—дип сорады Мөслимә.

—Юк...

Күзләр тәрәзәдә, колаклар асулы. Егетләр нигәдер көттерә. Мөкәррәмәгә кызык. Үзенең Вәлинурны сагалап йөрүен оныткан. Шулай инде ул, кешенеке төштән соң.

—Бәрәңге суына бит, өстенә тастымал ябып мендәр астына куйыйкмы әллә?—диде Тәгъзимә тирән борчылу белән.

Нәкъ шушы вакытта ишек шакыдылар.

—Ишек ачык, керегез!

Бүлмәгә өч егет аяк басты. Мөслимә белән Тәгъзимә бер тын шулар янында бөтерелешеп алдылар. Мөкәррәмә генә үксез бала шикелле мич ышыгында басып торды. Ниһаять, чишенешеп беттеләр, бүрекләр, бушлатлар чөйгә эленде. Аякларыннан гына салмадылар. Чөнки идәндә җилләр уйный иде.

—Хафизга дигән мәткәгез кая соң?—дип, як-ягына каранып алды җирән чәчле юантык егет.

—Әнә ул, әнә,—дип, Мөслимә Мөкәррәмәгә төртеп күрсәтте.

—О-о, ничего куколка, нигә мин сине элегрәк күрмәдем икән?

Солдат сиздерми генә Мөкәррәмәнең йомшак җиреннән сыйпап алды.

—И, алама малай, мине кая куяр идең?—дип чытлыкланды Мөслимә.

—Минем кайнарлык икегезгә дә җитәрлек, хи-хи-хи…

—Зөлкәбир дим, үпкәлим алайса,—диде Мөслимә иреннәрен турсайтып.

—А што, шуток не понимаешь штоли?!.

—Кунакларны өстәл янына чакырыр идең…

—Хафиз!—дип аваз салды Зөлкәбир командирларча тәкәббер тавыш белән.

Очлы иякле кара тут йөзле солдат кесәсеннән ике ярты чыгарып, өстәл өстенә утыртты.

Миңа дигән егетләре шушы икән инде, дип, үзалдына елмайгандай итте Мөкәррәмә.

—Менә хәзер пажалсты,—диде Зөлкәбир,—прошу к столу!

Утырыштылар. Чыннан да Хафиз Мөкәррәмә янына кунаклады. Бу Вәлинурның кисеп ташлаган тырнагына да тормый ич, дип уйлап алды кыз, мыш-мыш килә, сыер…

—Хафиз! Мисбах!

Егетләр урыннарыннан сикереп торып, стаканнарга хәмер агыздылар. Алар үз вазифаларын өйрәтелгән эт шикелле бик яхшы беләләр иде.

Зөлкәбир стаканны кулына алып, чәрелдек тавышы белән җырлап җибәрде.

*Айкап җибәр, чайкап җибәр,*
*Казакларның камчысын.*
*Салып биргәч эчеп бетер,*
*Калдырмыйча тамчысын.*

—Җаныеңа берәр әйбәт сүз әйтмисеңмени?—дип, Мөслимә егетенә сарылды.

—Балтун—находка для врага,—диде Зөлкәбир күзләрен уйнатып.—Прежде всего, действие, разговоры потом. Армиядә закон шундый. Правильно говорю, ребята?!

—Так точно!

—Ә мин риза түгел,—диде Мөкәррәмә,—ничек инде ул, без Мөслимәне туган көне белән котларга җыелдык түгелме соң? Һәрберебез үз сүзен әйтергә тиеш дип саныйм мин. Үзем, мәсәлән, Мөслимәнең барлык хыяллары да тормышка ашсын иде дим. Туган көнең белән тәбрик итәм, дустым, бәхетле бу!

—Браво!—дип кычкырды Зөлкәбир,—әйдәгез, шул хөрмәткә!

Мәҗлес акрынлап үз эзенә төште, телләр дә ачылып китте. Мөкәррәмә дә аз-азлап кына булса да йоткалап утырды. Читтә йөргәч, анысына да өйрәнергә туры килә икән. Җыен чәүкә арасында ак карга булып калмассың ич инде.

Хафиз каккан казык шикелле төзгә каткан, каш астыннан гына Мөкәррәмәне күзәтә, ничә карасаң, күзе аңарда. Ә авызыннан бер кәлимә сүз чыкмый, телен йоткан диярсең.

Хәер, Мисбах та тын гына утыра. Алар урынына Зөлкәбир сайрый. Шулай да Хафиз берзаман кычкырып җырлап җибәрмәсенме.

Аның җырына Мөкәррәмәдән ары игътибар итүче булмады. Чөнки башкалар сөешү белән мәшгуль иде. Ә Мөкәррәмәгә ошады. Гомумән, егет аңа килешле булып күренә башлаган иде инде. Стаканын буш тотмаса да, йомшаганы да сизелми үзенең. Димәк, өч тиенлек эчеп, биш тиенлек исереп йөри торганнардан түгел. Сүгенми, теләсә-кайсы җиргә үрелми, тәртипле күренә. Бераз тәвәккәлрәк булса да комачауламас иде анысы…

—Әйдәгез, биибез,—дип бервакыт идән уртасына Тәгъзимә атылып чыкты. Киез каталарын салып ташлады да бөтерелеп китте. Бөтен гәүдәсе селкенә, авыр сыны сөйрәлеп йөргәндәй йөри. Их, Сәмига булсын иде хәзер монда, биеп күрсәтер иде ул

сезгә, дип, Мөкаррәмә ахирәтен исенә төшереп алды.

Тәгъзимә биеп туйганнан соң нигәдер үз егетенә түгел, Зөлкәбиргә басты.

—Мин вальс, танго, факстрот шикелле классик биюләрне генә бии беләм, и то патефон музыкасы астында,—диде егет эре генә. Мөкаррәмәнең ачуы тагын тышка бәреп чыкты.

—Алай бик культурнай булгач, нигә иң әшәке авыл җырларын җырлыйсың соң?— дип егеткә кадалды.

Зөлкәбир моны комплемент дип кабул итте ахры, кычкырып көлеп җибәрде. Ул шактый төягән иде инде. "Мин урта белемле,—дип, мактануын дәвам итте,—мине институт көтә..."

Бию шул рәвешле өзелде, янә өстәл янына җыелыштылар. Бераздан Мөслимә белән Тәгъзимә чыш-пыш килеп алдылар да урыннарыннан кузгалдылар. Зөлкәбир белән Мисбах та аларга иярде. Мөкаррәмә талпынып караган иде дә, Мөслимә күл ишарәсе белән аны урынына утыртты.

—Безгә ияреп йөрергә сез бала-чага түгел инде,—диде,—әнә, икегезгә бер бүлмә, рәхәтләнеп чөкердәшегез.

—Их, үзем булсаммы?—дип угаланды Зөлкәбир. Шул арада Хафизга да йодрыгын төйнәргә өлгерде.

—Смотри, шушы кычыткан чыпчыгының кара тирен чыгармасаң, пять нарядов внеочереди алырсың. Проверю! Хи-хи-хи...

*Әнә килә автомобиль,*
*Төягәннәр апыра...*

Җырның соңгы яртысын Зөлкәбир урамда тәгәлләде.

*Урамга да чыгар хәл юк,*
*Кызлар куна чакыра.*

Мөкаррәмә бу чыш-пышларның, ташлап чыгып китүләрнең төбендә ни-нәрсә ятканын бик яхшы белә иде, әлбәттә. Кызлар аны үз кочүләренә кертмәкче, үз ишләре итмәкче.

Дуслары юкта Хафиз да кыюланып китте, Мөкаррәмәне кочаклап алды. Куллары каты, көчле иде.

—Нык кысма, авырттырасың бит,—дип пышылдады кыз.

—Минем сине үбәсем килә,—диде егет.

—Җүләр, сорап үбәләрмени аны...

—Ә ничек?

—Үзең бел...

Иреннәр бер-берсенә якынайды, алардан кайнар дулкын бөркеп тора иде. Ләкин берегешә алмый калдылар, кыз башын борды.

—Син миңа ошыйсың,—диде Хафиз,—әйдә кунабыз...

—Урын җәяргәме соң?—дип сорады Мөкаррәмә ризалыгын белдереп.

—Җәй...

Икесенең дә тәне мәмрәп пешкән чия шикелле тулышкан иде, тамак төпләренә ниндидер ләззәтле төер килеп утырды, шуны йотып җибәрәселәре килә. Алар белән инде акыл түгел, хис, хәмер идарә итә иде.

Мөкаррәмә базар киемнәре киеп йөри иде хәзер, шуңа күрә егет кайчандыр Зөфәрне тоткарлаган ыштан бавына юлыкмады. Барысы да тиз һәм каршылыксыз башкарылды. Чөнки кыз тәвәккәлләгән иде инде. Хафиз үзе бу форсатны кулыннан ычкындырды. Озак кына каешын аелыннан ычкындыра алмыйча азапланды... Төймәләре дә әллә кая кереп поскан...

Өлгерә алмады, чуаны алдан сытылды.

* * *

Рота май башларында китеп барды. Әмма үз артыннан чиләк-чиләк күз яшьләре дә калдырып китте. Күпләр чирмеш әбиләренә барып бәби төшертте. Мөслимә белән Тәгъзимә генә өлгерә алмый калды, әллә теләмәделәр. Мөкаррәмәне бу хәлләр читләтеп узды. Хафиз шул кичтән соң күзгә-башка чалынмады, оятына көч килде булса кирәк. Йорт хуҗасы да, мәҗлес вакыйгаларын ишетепме, күңеле сизенепме, кич чыгуларга чик куйды. Ул Мөкаррәмәне үз баласын саклагандай саклады. Әллә яхшыга, әллә начарга—белмәссең. Шул чакта балалы булып калган булса, бәлки

дөньясы бөтенләй башкача көйләнер иде. Әнә, Мөслимә килен рәхәте күреп яши хәзер, пычагы майда йөзә. Улы укып зур кеше булды.

Мөкәррәмә Түбән Сөнгә урман эшеннән котылгач, кырык бишнең апрель урталарында кайтты. Биш-алты ай колхозда эшләп алды. Җину хәбәре аларга чәчү чәчкәндә килеп иреште. Ләкин күңеле утырмады, бәхет эзләргә бу юлы ирекле баштан үз теләге белән чыгып китте. Ә өч елдан телеграмма белән чакыртып алдылар. Әнисе вафат иде. Ата-ана нигезен таратасы килмәде, авылда төпләнеп калды.

Авыл нык үзгәргән иде. Яңа буын яшьләр үсеп җиткән. Клублар, уеннар хәзер алар кулында. Хәлбуки, аның үзенә дә егерме бер генә тулган иде әле. Мөкәррәмә кебекләр буа буарлык. Егетләрне санарга исә ике кул бармаклары да җитә. Күпләр сугыш кырында башын салган. Үсмерләрне шахта якларына куганнар. Өстәвенә, "корчаңгы" дигән кушаматы да онытылмаган, җаен чыгарып, исенә төшереп кенә торалар. Кутырлы кызга егет карый димени?

Мөкәррәмә Вәлинурның үле хәбәрен урман эшендә вакытта ук ишеткән иде. Бик кайгырган иде, дөньяда яши алмас кебек иде. Еллар үтү белән кайгы-сагышлары акрынлап таралса да, Вәлинур барыбер аның күңелендә беренче һәм соңгы мәхәббәте булып гомерлеккә утырып калды.

Май сасымас, кыз картаймас, ди, ни хикмәттер, яше кырыкка җиткәч, Мөкәррәмә янә чәчәк атты, гәүдәсе турайды, килеш-килбәте матурайды, йөзе алсу төскә керде. Ир-ат аның артыннан тәшвишләнеп карап кала иде. Яучылар да ешайды. Тик тәвәккәллегe җитмәде. Ялгыз яшәргә күнеккән хатын-кызны кузгату бик авыр икән. Шулай да Хәмит исемле бер Илеш кешесе хисләрен чуалтып алды, шөкер, йөрәге бетләмәгән икән әле. Ул аны Вәлинурга ошатты. Хәмитнең дә иренендә Вәлинурныкы шикелле җөе бар иде. Мөкәррәмәне шул җөй сындырды. Тегесенең хатыны үлгән, балалары белән тыныша алмый икән. Ипле, сабыр, җайлы кеше күренә. "Терәгең булырмын, бергә яшик",—диде.

Өченче килүендә, ниһаять, ризалыгын бирде Мөкәррәмә. Ул үзе йортка кергән ир-атны өнәп бетерми, булдыксызга саный иде, нишлисең, тәкъдирдә шулай язылгандыр, язмыштан узмыш юк диләр бит.

Шул ук көнне никах укытырга булдылар. Мөкәррәмә мунча ягып җибәрде. Бүген менә кырык ел саклаган хәзинәңнән коры калачаксың инде, сөрсегән кыстыбый, дип, ирен очлары белән генә елмаеп, бераз куркыбрак та, үзеннән-үзе көлеп йөрде.

Хәмит тә кул кушырып утырмады, абзар-кура тирәсендә балта-чүкеч уйнаткалады, булачак хуҗа бит!

Бәлеш пеште, шулпа кайнады, мунча өлгерде. Тиздән мулла киләчәк. Инде өс-башны карап алсаң да ярый торгандыр.

—Хәмит, сиңа әйтәм, күлмәгемне алыштырганчы гына өй алдына чыгып тор әле,— диде Мөкәррәмә ниндидер бер эчке наз белән,—оялам… мин бит әле ни… и, үзең белерсең әле…

Хәмит йомшак кына итеп ишекне япты. Шулчак капка төбенә бер машина килеп туктады. Кабинадан әзмәвердәй таза егет сикереп төште. Ир ашыгып-кабаланып аның каршысына атлады.

—Бәйләп салыйммы, үзең утырасыңмы?—дип ырылдады егет.

—Улым, мин…

—Сволочь!

Егет әтисен төрткәли-төрткәли машинага утыртты да урамда тузан өермәсе калдырып, китеп тә барды.

Аның артыннан ук үкчәсен-үкчәгә бәргәләп, Җәләлетдин мулла килеп җитте. Тамагын кыргалап, догасын укый-укый бусагадан атлады.

—Ходаем, бу йортка фәрештәләрең аша иминлек, тәүфыйк, сабырлык иңдер. Әссәламегаләйкем, дин кардәшләрем, исән-сау гына торасызмы?

—Синең хәер-фатыйхаңда, Җәләлетдин абзый, шөкер Ходайның биргәненә,— дип, керфекләрен идәнгә чәнчеп кенә Мөкәррәмә мулланың сәламен алды.

—Бик хуш, бик хуш. Китап изге гамәлләрне ашыктырырга куша, сеңлем, башлыйк булмаса, тәһарәтем дә бар. Каравыл вакыты җиткәнче берәр юл печәнгә дә барып кайтырмын дип ниятләп тора ием. Бригадир ат бирәм дигән ие. Ә-ә, кияү тиешле кардәшебез кая соң?

—Ишек алдына чыгып киткән иде. Син җайлап кына менә шушы йомшак урынга

утырып хәл алып тор, Җәләлетдин абзый, мин аны хәзер алып керәм.

Мөкәррәмә яна күлмәгенең итәкләрен җилфер-җилфер китереп, ишек алдына атылып чыкты.

—Хәмит дим, Хәмит, сиңа әйтәм...

Хәмит җавап кайтармады. Хатын абзар, мунча тирәләрен карап килде, бәрәңге бакчасын күздән кичерде, хәтта бәдрәф ишеген дә дөбертәтеп алды. Ир бер җирдә дә күренмәде. Урамга ук элдерткән ахры, коты алынган җанашымның, дип куанып көлемсерәде Мөкәррәмә. Анда да юк иде Хәмит. Читән буенда уйнап йөргән кечкенә малайдан белешәсе итте.

—Үскәнем, берәр абзыең күренмәдеме монда?—дип сорады.—Озын буйлы, нык бәдәнле...

—Ул абзыйны бик матул машинага утыртып алып киттеләл бит, түтәй,—диде малай,—мине утыртмадылал...

Мөкәррәмә таш тигән пыяла өлгесе шикелле коелып төште, гүя гәүдәсе вак-вак кисәкләргә бүлгәләнде. Ничек була инде бу? Балаларым әниләренә охшап, бик усал булдылар дигән иде, димәк, әтиләренең йортка кергәнен күтәрмәгәннәр. Ә аңа нишләргә? И, илаһым, хурлыгы ни тора бит! Бөтен авыл белә иде ич. Гайбәтенә ничекләр түзәрсең?

Ул бу рәхимсез сорауларга җавап табар хәлдә түгел иде. Өйдә бит әле мулла көтә! Җире дә убылмый ичмасам, котылыр иде бу мәрхәмәтсез дөньясыннан.

Мөкәррәмә бөтен көчен җыеп, өенә таба өстерәлде.

—Җәләлетдин абзый, бернәрсә турында да сорашма,—диде ул муллага,—менә шушы бәлешне Бәдернисаттәй белән бергәләп утырып ашагыз, миннән бүләк булыр.

Хатын никах бәлешен табасы-ние белән ашъяулыкка төйнәде дә һични аңламыйча, күзләрен челт-челт йомгалап, басып торган муллага тоттырды.

—Гаеп итмә, Җәләлетдин абзый, яме, шулай килеп чыкты инде...

Мулла куркак кеше иде, төпченмәде дә, сорашмады да, тизрәк таю ягын карады, бәладән баш-аяк, дип уйлады, күрәсең.

* * *

Мөкәррәмә ялгызы картайды. Аннан гомере буе баласызлык салымы түләттеләр. Хәзер аның бердән-бер яшьлек ядкәре—Вәлинурга атап чигелеп тә, бирелми калган кульяулыгы. Җиңү бәйрәмендә дә ул шуның белән юана.

Нәкъ өйлә вакытында, өенең иң түренә кунаклаган сандыгыннан зур саклык һәм дулкынлану белән шул кульяулыкны тартып чыгара.

Аңынчы әле төзәнә-ясана, өстенә яңа күлмәген кия, көмеш алкаларын тага, ахак кашлы чулпыларын аса. Ашау-эчү әзерләп, үз-үзенә бәйрәм ясый, клубка чакырмыйлар дип тормый.

Әле дә сандыгының ачкычын борып җибәрүгә, өй эче күңелгә ятышлы моң белән тулды. Борынгы сандык ул, йозагы шулай кыңгыраудай зыңгылдап ачыла. Кульяулык иң төптә, гәзит кәгазенә төрелгән килеш саклана.

Мөкәррәмә аны иплән кенә алып, өстәл өстенә җәеп куйды, берара кытыршы куллары белән сыпыргалап торды. Ситсасы йомшак, нәфис. Чит-читләре челтәрле. Уртасында пар күгәрчен. Уң яктагысы—Вәлинур, сул яктагысы—үзе, Мөкәррәмә.

Кавышулар гына насыйп булмады.

—Киләсе елда, Алла кушса, тагын күрешербез әле, Вәлинур абыкаем...

Мөкәррәмә моннан илле тугыз ел элек чиккән кадерле кульяулыгын матурлап төреп, янә сандык эченә салып куйды.

*2002 ел.*

# Şiğriət
# Шигърият



## Флера Гыйззәтуллина

## Ә ҖАНЫМ— КАНАТЛЫ КОШ КЕБЕК...

### Ахыргача күтәрмен...

Җырларымда—килер чорлар шавы,
Иңнәремдә—каен толымы:
Толым сорап ак каенга киләм,
Мин соң әллә аклык колымы?

Әллә мин эзләгән сөю бармы
Назлы каен яфракларында?
Үз ярыма мин бит бирдем назның
Яфраклардан сафракларын да.

Бүген дә бит бу сафлыкка шаһит
Карурманда ап-ак каеннар...
"Сөям сезне!"—дигән сүзләремдә
Каеннардан алган ваем бар.

Хәзер инде бу ваемны миннән
Әҗәлләр дә тартып алалмас!
Шагыйренә толым бүләк итеп,
Җырга күчкән каен—каралмас!

Җырсызлар да батырчылык итмәс
Сөю җырын сүтеп чорнарга.
...Мин урманга үләр өчен китмим,—
Китәм чорлар шавын тыңларга.

---

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА — *шагыйрә; "Чишмә юлы", "Акчарлагым—асыл кошым", "Йөрәгемдә шаулый карурман" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Китәм санап—барлап карар өчен
Каеннарның агын, карасын—
Урман чыккан саен
Чор көенә
Сулкылдатып Язмыш ярасын.

Үз җаныма яра салган өчен
Язмышка мин ләкин "аһ" ормам.
Җан зурлыгы, сафлык хозурлыгы
Аңлашыла бит ул ахырдан.

Язмышымның соңгы әманәтен
Мин дә ахыргача күтәрмен:
"Сафлык колы" дигән юльязмамны
Чор шавына бүләк итәрмен.

## Җәйләремне бирәм...

Минем табигатем җәйгә тартым:
Кичү авыр миңа кыш айларын.
Кырыс кышта кан басымы арта—
Башны кыскан "корыч кыршау"ларның...

Минем мәхәббәтем таңга тартым:
Йөзәм нурның таңдай алсуында...
Әмма аңым җуярмын дип куркам
Кинәт купкан хисләр ярсуында.

Минем кайгым бураннарга тартым:
Басыла да кабат кубарыла.
Мөмкин түгел мәңгелек җан хәлен
Фасылларга бүлеп сугарырга.

...Җәйгә чыккан чыдамлыгым өчен
Мин барыбер бурычлымын
Кышка.
...Җәйләремне бирәм...
Мәңгелек ул—
Бер кайчан да "хезмәт итми" бушка.
...Сөюемне бирәм, сөюемне:
Күпме кирәк—шулай!
Сорасыннар...
Кышны бергә чыккан кардәшләрем
Хәтерләрен генә җуймасыннар.

## Өмет

...Авыр миңа...
Авыр язмый яшәү—
Газиз Ватан өчен янмый яшәү.
Язмасам мин күз дә йома алмыйм,
Әҗәлләрдән җанны йола алмыйм.

"...Җаным—Ватаным!"—дип язган чакта
Иңемдә мин янар таулар тойдым.
Шул тойгымны елап сугарганда
Тау юлына күз нурымны койдым.

"Күз нурларым" китап булып чыккач
Тагы да үсте,
ачыкланды аңым:
Тургай, җырлап, һаваларга чөйде
Җандай күргән Азнакаем данын.

Шигырь нурларында көйри-көйри,
Тау-түбәләр, энә, күккә ашкан...
Дөньям авырлыктан кара көеп,
Мин дә гүя акылымнан шашам!

Алла язса, туган якка кайтып,
Тау җырларын мин дә кабатлармын—
Тау-ташларда чарлап, читтә талган
Көч-кодрәтен рухи канатларның.

## Үгет—нәсихәт

Мәхәббәтне гөлгә тиңли күңел,—
Гөл дип утка куна!
Шытып кына килгән күңел җырын
Утлар белән бума...

Гөлдән үргән сөю тәкыясын
Башкаеңа кимә!
Өзүчесен ничек кенә сөймә,—
Өзелгән гөл шиңә.

Сөелдем дә, өзелеп ташландым, дип,
Таш бәгырьгә тимә!
Башта уйлар авырайган саен
Ташлар җиргә сеңә.

Мәхәббәтне гөлгә тиңлә,
син дә
Үстер, назың түгеп.
Ашыгып син антлар эчмә ләкин,
Гөл таҗларын үбеп.

Андый гөлләр җиргә орлык коеп,
Барыбер тамыр сузмый...
Башка төшкән ант та—
гомер-бакый
Башны кысып сызлый.

***

...Биегәйтер һәм киңәйтер өчен
Газиз Ватанымның күген бүген,
Күккә байрак итеп чөяр идем
Милләтемнең бөтен түземлеген...

***

Хыянәт—мәхәббәт зинданы.
Зинданга ашкына кем җаны?
...Йөрәктә богаулар чыңлады:
Зинданнар чорнады дөньяны.

***

Мәхәббәткә муллык юраганда
Алдаламый икән язгы тойгы:
Язлар—күзләремә Кояш уйды,
Көзләр—эзләремә яфрак койды.

## Бер “балкыш”

Ил, күкрәп, чәчәктә балкыса,
Аласы сулышлар киңәя.
Җир тетрәп, вулканнар атылса—
Аңлыйсың: бер “балкыш”—ни бәя...

***

Күлдә—сагыш!..
Камышлы күл буйлап
Кыр казлары йөзә каңгылдашып...
Йөрим шул сагышлы елларымның
Һәр мизгеле белән саубуллашып.

***

Җан-тамырын бөрөзлексез айкаганга,
Татар телен баскан төзәлмәстәй яра...

Башыбызны төз тотуга карамастан,
“Телкисәрләр” телдән тарта яңабаштан.

...Без ахрысы артык “уйнап—уймак”ландык?!
Телсезлектән юашландык, тыйнакландык.

“Бетерәм!!!”—дип ажгырганда сиңа явыз,
Каршы килеп нәрсә әйтсен “уймак авыз”?

## Хәтердә—вәгъдәләр елгасы

Күк күкрәп яңгырлар яуганда
Пар яшен йөрәкне чолгады.
Яшенләп, тетрәнеп, сөюем
Ярыннан чыгарды елганы.

Бу нинди газаплы сөю соң—
Йөрәккә сүнмәс ут кабызган?!
...Без сузган мәхәббәт күперен
Ярсулы ташулар агызган.

Хәтердә—вәгъдәләр елгасы!—
Ашкына хыялга җитәргә...
Кызганам яшьлегем ярларын
Күперсез калдырып китәргә.

*Яшьләр иҗаты*



# Гөлзадә Бәйрәмова

## ЯШӘЕШНЕҢ АНЫҢ ҮЗ КАНУНЫ...

***

**Яшәешнең аның үз кануны:**
**Без дигәнчә генә баралмый.**
**Сөеп яшим, дисең, тормыш исә**
**Ваклыклары белән яралый...**

**Вагаясың "акча җитми" дип тә...**
**Имеш-мимеш, гайбәт сүзләрдән.**
**Акыл туплап, хисләр сүнә төшкәч,**
**Килеп җитә аннан көзләр дә...**

**Яшәешнең, әйе, үз кануны:**
**Әйтми дөнья кая барасын...**
**Үткән кеше бармы ялгышларсыз**
**Яшәү белән Үлем арасын?!**

***

**Ул төнне мин сине көтмәдем,**
**Кайтыр дип янәдән борылып.**
**Бары тик мендәрең юксынды,**
**Калганга бер читтә боегып.**

**Урынны киңәйтеп җәймәдем,**
**Ялгызың ничек тә таң ата.**
**Алданып саташу шушыдыр—**
**Яратам... Ышанам... Югалтам...**

**Җуям да дусларны, ярларны,**
**Соңыннан юрыймын яхшыга...**
**Синең дә кайтуың көтмимен:**
**Ялгызлык әверелер язмышка...—**

**...Юрыйммы моны да яхшыга?!**

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА – *журналист; шигырьләре һәм мәкаләләре вакытлы матбугатта даими басылып килә. Казанда яши.*

***

*"Гомер буе жандаш эзлэдем мин"*
Р.Ф.

Һәр саташу миңа—сөю булды,
Һәр ярату, гүя, соңгысы...
Еллар узган саен үзенә тарта
Җырларның да никтер моңлысы.

Дусларны да хәзер күп дип әйтмим,
Калды бары җанга якыны...
Сөю бер хәл, җандаш булу җитми:
Син җандаш бул, көтмим артыгын...

***

*Хезмәттәшем Тәслимә Сибгатуллина вафатына*

Акрын-акрын син дә онытылырсың:
Хис-хәтергә вакыт аяусыз...
Бүгенгесе кыен—җанны телә,
Юклыгыңны тою—аяныч.

(Үләм диеп җиргә тумый кеше,
Яши-яши шуңа төшенә:
Тудырырга көчлесең дә Ходам,
Алып калу килми көчеңнән!)

...Урының буш—күңелләрдә бушлык,
Ачыла ишек,тик син ачмыйсың.
Югалтулар арткан саен, җанда
Ныграк тоям аның ачысын.

Югалтулар әле була торыр,
Һәрберсенең үзгә газабы.
Югалтулар—табуларга булсын,
Булмасын тик үлем—азагы...

***

Әлләни күп гомер узмаган
Иңгә-иң терәлеп, янәшә.
Син мине, мин сине белмәгән
Елларны ерактан эндәшә:
"Сак белән Сок булып яшәүдән
Бәхет соң кем табар дөньяда?
Ялгызың—аерым—кичкәндә
Куркыныч тоела елга да...
Үткәннәр—үткәндә,
Бүгеннең,
Яшәүнең кадерен белегез.
Табышкан, кавышкан күп булыр,
Югалтмый яши дә белегез."

***

Диварымдагы сәгатең
Синсез көннәрне саный:
“Келт... келт...
Кот... кот...
Түзәлмәс, килер янәдән,
Ул да бит синдәй сабый.

Үпкәлидер бер дә юкка,
Аннан—котә юату...
Сөюнең кадерен бетерә
Җанны кыйнап елату”.

## Төн. Тынлык.

Тынлыктан мин курыкмаска тиеш
Һәм качмаска тиеш аңардан:
Кемнәргәдер ошамадым диеп,
Туа алмам җиргә яңадан.

Төшенкелек миңа юлдаш булмас:
Ялгызлыктан күрмим фаҗига,
Кемгәдер ул, бәлки, әлмәк булса,
Миңа исә,
Уйланырга, бәлки җай гына...

Авыруларны,үлемнәрне күргән
Гомеремнең инде уртасы.
Күңел дөньямның да кыл уртасы,
“Яшим!” диеп яшьнәп торасы!

Ялгызың да тыңлап, аңлап була
Сандугачның өзелеп сайравын...
Парлы гына бәхетле, дип, җирдә
Чыгаралмас беркем бер канун!

***

*Рәссам Әхсән Фәтхетдинов белән сөйләшүдән*

—Җилләр белән сөйләш,—дисең,—
Табигать бит каралтмый.
Серләреңне җилгә сөйлә,
Җилләр гайбәт таратмый...

Агач белән серләш,—дисең,—
Сыен син кочагына,
Ныклыгыннан көч алырсың
Хәлсезләнгән чагыңда.

Агымсулар алып китәр:
Кайгылар агар—судай...
Хатын-кызны Кайгыда һәм...
Сөюдә сыный Ходай.

***

Гомернең узганын сизмәдем,
Әлләни арада көз җиткән,
Бердәнбер улкаем буй җиткән...
Гомернең узганын сизмәдем.

Гомернең узганын сизмәдем,
Җуела башлады туганнар.
Ишәя башлаган зиратта
Алынып куелган урыннар.

Кайчандыр каз-бәбкә саклаган,
Чәчкәләр җыелган чирәмлек—
Тоташтан зиратка әйләнгән
Мәңгелек моң сарган тирәлек...

***

*"Бер киселгән икмәк кире ябышмый".*
Халык мәкале.

Син миннән хәбәрләр көтәсең:
"Сагындым, кайт",—дигән сүземне...—
Әллә соң җиңел дип уйлыйсың
Ялгавы киселгән телемне?!

Хисләргә уралган уйларым
Акылга гел киртә булдылар...
Сагынмыйм дисәм дә, сагындым,
Абынмыйм диеп, гел абындым...

Син миннән хәбәрләр көтәсең,
Әйтмәсәм, мәңгегә китәсең.
Кемгә соң китәрсең?.. Белсәкче—
Кем безне бәхетле итәсен!

Ялгызым калам да уйланам:
Бәхет дип нәрсә соң атала,
Акыллы яшәлгән тормышмы,
Мизгелме—мәхәббәт хакына?



**Рафаэль Хәким**

# КАЙДА БЕЗНЕҢ КЫЙБЛА?

ЕВРОИСЛАМ МАНИФЕСТЫ

***“Зан итү, ягъни дәлилсез уйлау, яки нәфес теләгәнчә хөкем итү—дөреслекнең һичбер өлешенә ирештермәс” [10:36].***[1]

Минем әби динле кеше иде. Көн саен биш вакыт *намазын* калдырмады, *ураза* тотты, дуңгыз ите ашамады. Кечкенә чагымда кичләрен миңа әкият урынына пәйгамбәрләр тарихын укый иде. Казан университетының физика факультеты студенты булгач, мин кайчак аңа Коръәннең кайбер катлаулы *сурәләренә* төшенергә ярдәм итә идем. Коръәннең рус теленә И.Ю.Крачковский тәрҗемә иткән вариантын алып, үзем өчен ят темаларны әбиемә булдыра алганча татарча аңлатырга тырыша идем.

Безнең буынны диннән мәҗбүри аердылар. Физика факультетында акыллы яшьләр укый, алар квант механикасы, синхрофазотроннар, атом таркату дөньясында яши иде. Без Лобачевский геометриясен аңларга тырыша идек. Аның буенча, ике параллель сызык йолдызларның һәм планеталарның гравитация кырлары ергалап бетергән очсыз-кырыйсыз галәмнең кайсыдыр бер ноктасында кисешергә тиешләр. Ять-яшь Роальд Сәгъдиев, безгә килеп, атом-төш синтезы турында лекцияләр укый иде. Физика фәне материянең иң катлаулы законнарын аңлата ала сыман тоела иде. Аллаһ Тәгалә исә дәлилләрнең мантыйкый чылбырында артык буын итеп кабул ителә, аны шул һич югы кеше тарафыннан танылып җитмәгән билгесезлеккә кайтарып калдырырга гына була иде. Альберт Эйнштейн—менә кем иде безнең Алла!

Бервакыт мәшһүр физиклардан берсенең диндар, ягъни үтә динле кеше булганлыгын белеп мин бик каты гаҗәпләнгән идем. Атом һәм водород бомбалары ясау белән Коръән яки Тәүрат уку арасында һичнинди бәйләнеш күренми иде.

***“Дәхи Раббыңнан яшерен булмас җирдә вә күкләрдә тузан бөртеге хәтле нәрсә, ул нәрсә—кирәк тузан бөртегеннән зур булсын, кирәк—кечкенә булсын, барчасы өммул-китапта язылмыш” [10:61].***

Атомның чиксез таркалышын, берни белән дә чикләнмәгән Галәмне күзаллау, башы да, ахыры да булмаган вакытны аңлау бик кыен. Мондый төшенчәләрне без йә кире кагарга, йәисә аксиома итеп кабул итәргә тиеш. Аларны акылга муафыйк рәвештә аңлатып бирү мөмкин түгел, чөнки безнең тормыш тәҗрибәсе моңа каршы

[1] Коръән текстлары Казый Камил Имаметдин улы Бикчәнтәев әзерләгән "Коръән тәфсире"ннән алынды. Коръән тәфсире. – Казан: РИЦ "Дом печати", 2001. – 1152 бит. Квадрат җәяләр эчендә башта *сурә,* аннан соң *аять* саны бирелә.

Рафаэль ХӘКИМ (1947)—*сәясәтче; федерализм, этник мөнәсәбәтләр турындагы хезмәтләр авторы. Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. Казанда яши.*

килә һәм әлеге күзаллаулар белән ярашмый. Бирелә интуиция, ягъни тоемлау да ярдәмгә килә алмый. Чиксезлеккә бары тик ышанып кына була.

Атомны тәшкил итүче кисәкчекләрне хәтта электрон микроскоп аркылы да күреп булмый, алар махсус приборда үз эзләрен калдырып кына беленәләр. Кисәкчекләр бильярд шары кебек тотып, үлчәп карап була торган объектив җисем түгел, алар—"нәрсәнендер" прибор белән үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсе. Өстәвенә, без бу "нәрсәнедер" җисем дип тә, дулкын дип тә атый алмыйбыз, чөнки ул бер үк вакытта җисем дә, дулкын да. Безнең дөньяда үзара сыешмаган нәрсәләрнең башка дөньяда сыешуы мөмкин булып чыга. Әмма кисәкчекләрне ниндидер фантазия, интеллектуаль акылы төзелмәсе, прибордагы ниндидер эзләр дип кенә раслау да дуамаллык булыр иде. Атом бомбасы шартлагач, әлеге кисәкчекләрнең коточкыч чынбарлык икәнен барыбыз да аңлыйбыз.



Гомумән әйткәндә, безнең тормышта бик күп нәрсә—кешенең "объективлык" белән үзара йогынтысы нәтиҗәсе. Кеше тарих барышына катнашып, бу мәгънәдә тарихны үзе ясый да. Хакыйкать—катып калган абсолют нәрсә түгел, ул безнең үзебезгә бәйле. Фәрит Исак дөрес кисәтә: "Ләкин минем мәсьәлә исламнан безнең күпме һәм нәрсә алуыбызга бәйләнмәгән. Хикмәт башкада: без ана үзебез ни дә булса кертәбезме? Һәм без керткән өлеш исламның йөзен ничек үзгәртә ала? Без һәм ислам—чынлап та бер-берсеннән бөтенләй аерым нәрсәләрме? Ислам бездән башка, үзе генә яшиме? Иман заты үзенә безнең тәҗрибәдән дә берәр нәрсә ала алмыймыни?"[1]

Меңләгән еллар буе иудаизм (яһүдиләр дине), христианлык, ислам һәм буддизм ан-белем таратып гуманлык һәм мәрхәмәт хисләре тәрбияләгәннәр. Шуңа да карамастан, цивилизацияле кешеләр, ихтимал, Ходай исеме беләндер, тыныч халык өстенә атом бомбасы ташладылар. Аннан соң, тагын да ашкыныбрак водород бомбасы, химик һәм бактереологик корал эшләүгә тотындылар. Нәрсә бу? Шайтан мәкереме? Әйе, болай да аңлатып була, ләкин бу артык гади аңлатма түгелме сон ?

Ни өчен Ходай шулкадәр афәтле сугышларга, Җирне тәмугка әйләндерерлек корал уйлап табуга юл куйган? Ул бит барысын да күрә, ул һәммә нәрсәдән хәбәрдар, аның кодрәте киң һәм ул иң мәрхәмәтле.

***"Әгәр яхшылыктан сиңа бер шатлык ирешсә, ул шатлык Аллаһудан, әгәр казадан бер кайгы ирешсә, бу кайгы үзеңнең кимчелегеңнәндер" [4:79].***

Советлар иле—атеистлар иле иде. Социализм үзе үк демократиянең һәм базар икътисадының Көнбатыш моделенә каршылыкны гәүдәләндерә иде. Яхшымы-начармы, әмма без нәкъ менә шул рухи тиралектә яшәдек. Инсус Христос (Гайсә пәйгамбәр) һәм Аллаһ Тәгалә, пәйгамбәрләр урынын Ленин алган иде. Без Ленин әсәрләренең 55 томлык тулы җыентыгын, аның "васыятьләрен" бер адым да читкә тайпылмыйча, җентекләп өйрәндек. Аларны мәгънәсенә аңлыны төшенмичә ятлау иң төп идеологик коралга әйләнде. Ленин цитаталарыннан бер генә хәрефкә тайпылган кеше—еретик—*мөртәт* булып санала иде.

Дөньяны революцион үзгәрешләр белән тетрәндергән, фашизмны җиңгән, космосны үзләштерүне башлаган ил, хәрәкәтчәнлеген югалтып, "өченче дөнья" исемлегендә булып чыкты. Катып калган фикер һәм авторитетларны Аллалаштыру нәтиҗәсе булган фантасмагория иде бу.

Көнбатыш бу вәзгыятьтән сабак алды—колонияләренә бәйсезлек бирде, кайбер социалистик идеяләрне үзләштереп, мәгариф системасын үзгәртте, коммунистик куркынычка каршы берләште. Акылга сыймаслык икътисади үсеш, технология, уйлап табулар, ачышлар, тормыш дәрәҗәсен күтәрү Көнбатышны бөтен дөнья өчен үрнәк итте.

***"Аллаһ берәүне хак юлдан адаштырса, аны туры юлга кертүче, әлбәттә, булмас" [40:33].***

Әбием, үләр алдыннан, үзенең Коръәнен нәкъ менә миңа васыять иткән. Ул моны болай аңлаткан: "Ул китап ярата, димәк, киштәсендә Коръәнгә дә урын табылачак".

Менә Коръән укыр вакыт та житте...

Исламда яши торган руханилар бар, бу—аларның әлеге дөньядагы вазифасы, эше, хезмәте. Дин—аларның икмәге. Коръәннен, Сөннәтнен, хәдисләрнен, шәригатьнен бар нечкәлекләрен аңлаучы галимнәр бар. Аларның тәкъдире—мәсьәләне төрле яктан: аның бар тарихын һәм күпсанлы фикерләрне исәпкә алып шәрехләү, әйтик, ашаритларның язмышның алдан билгеләнү идеясе турында дәлилләренә, аларның бар нечкәлекләренә кадәр төшенү, мөтәзилитләрнен сайлап алу тәгълиматын белү. Әмма тормышларын исламга багышламаган, шуңа да карамастан хакыйкатьне үзләренчә эзли торган кешеләр дә бар. Алар Аллаһ Тәгаләгә үз юллары белән баралар.

Бервакыт Насретдин мулла әйткән:

—Мин караңгыда күрәм.

—Яхшы. Әмма, мулла, нигә алайса син төнлә шәм яндырып йөрисең соң?

—Башкалар миңа абынмасын дип.

***"Бәгъзе кешеләр иман китереп изге гамәлләр кылдылар, һичкемгә көче житмәгән йөкне йөкләмибез, мәгәр көче житкәнне генә" [7:42].***

Ни өчен ислам дөнья буйлап тиз тарала? Ни өчен Көнчыгыш Көнбатыштан өметсез рәвештә артта калган? Шәригатьнең минем яшәешкә ни мөнәсәбәте бар? 11 сентябрьдән, Америкадагы шартлаулардан соң дөньяга ни булыр? Бу сорауларга тәгаен генә җавап табу җиңел түгел. Минем фикерем—дин белгече яки рухани *фәтвасы* түгел. Европа белеме алган һәм үз республикасының киләчәген кайгырткан дөньяви кешенең үз фикерләре белән уртаклашуы. Барыбызга һәм дә һәрберебезгә кагыла торган мәсьәләләрне кемнеңдер аңлатып биргәнен бер читтә басып көтеп тору мөмкин түгел.

Минем борынгы бабаларым X гасырда үз теләкләре белән ислам динен кабул иткәннәр , аннан соң аны башка халыкларга булдыра алганча таратканнар. XIX—XX гасырларда татарның дин белгечләре исламны үзгәртү юлына басканнар һәм бу юлда күпкә ирешкәннәр. Безнең тарихыбыз бай, ләкин киләчәктә безне нәрсә көтә соң? Мин, билгесезлекне танып-белер өчен, һич югы, башкалар миңа бәрелмәсен өчен, шәм яндырып йөрим.

Дин белгече яки имам булмагач, ни эшкә дип кулыңа каләм алдың, диюләре мөмкин. Синең моңа хакың бармы соң? Әмма ислам—ул минем дә асылым, әгәр дә мин аны аңларга телим икән, димәк, минем өчен Коръәннән башка чыганак юк. Ни өчен мин кемнеңдер аңлатмасын тыңларга тиеш? Ни өчен Коръәнне үземә укымаска? Әллә кемнең дә булса хакыйкатьне үз кулында тоту хокукы бармы? Юк.

Коръәнне аңлар өчен гарәп теленең үзенчәлекләрен һәм нечкәлекләрен белергә кирәк, диләр. Мөгаен, шулайдыр. Ләкин хикмәт шунда ки, бүген Коръәнне оригиналда уку—үзе үк аңлатма бирү дигән сүз, чөнки дәвер дә, кешеләр дә, тел дә, сүзләрнең һәм төшенчәләрнең мәгънәсе дә үзгәреш кичерде. Сүзләрнең дә үз гомере бар. Коръән *сүраләрен* ятлау—котылу чарасы түгел. Коръән үз тавышы белән сөйләп бирә алмый, аны аңлатучылар кирәк, ә аңлатучылар исә—кешеләр. Һәр кеше, үзенең тормыш тәҗрибәсеннән, мәдәни дәрәҗәсеннән чыгып, үзе укыган сүзгә, аның мәгънәсенә үз күзаллавын сала.

Мөселманнар төрле дәүләтләрдә, төрле шартларда яшиләр. Согуд Гарәбстаны, Иран, Судан илләре бар, алар тарихи шәригатьне саклыйлар. Төркия, Мисыр кебек илләр бар, аларда законнар дөньяви, әмма җәмгыять—мөселман җәмгыяте. Россия һәм Европа бар. Анда мөселманнар христианлык тирәлегендә, азчылыкта яшиләр. Бу тирәлек алар өчен чит түгел, әмма башка тирәлек. Хәлифәтләр заманы узган. Сәид Котб фикеренчә: "Исламны канун итеп танымаган Америкада яки Россиядә иҗтимагый яки икътисадый җәмгыятькә җайлашу өчен ислам кагыйдәләрен булдырырга тырышу шактый мәзәк хәл. Бу бит ислам хакимиятенең өстенлеге танылмаган теләсә нинди илгә кагыла! Дөньяны ислам хакимиятен танымый торган хәлгә буйсындырып үстерергә тырышу һавада орлык үстерергә маташуга тиң, бу-буш гамәл, ул ислам житдилегенә тормый".[1] Бу татарларны ислам дөньясыннан чыгарып ташлауны аңлатмыймы соң? Ислам гомумкешелек кыйммәтләреннән өстен һәм алардан читтә тора дигән сүзме? Европаның елдан-ел арта барган мөселманнарына ни кала? Алар бит үзләрен мөселман дип саный.

Дөнья үзе халыкара хокук булдырган, мәдәниятле бердәм бергәлек булып бара. Ул *өммәткә* әйләнеп, чиста мөселман *өммәте* булмаса да, бердәм *өммәт,* һич югы

[1] *Юсуф аль-Кардави.* Современный иджтихад: от беспорядка к порядку. – Казань: Иман, 2001. – С.81.

сугыш һәм тынычлык, кеше хокукларын һәм дәүләтләр мәнфәгатен яклау мәсьәләләре буенча бердәм *өммәт* була бара. Мондый бергәлек Ходай ихтыярына каршы килә алмый. Әйтелгән:"Әгәр Аллаһ кешеләрне якламаса, әлбәттә, җирдәге кешеләр һәммәсе һәлак булыр иделәр. Ләкин Аллаһ—барча галәмнәр мәхлукына рәхмәт иясе" [2:251]. Халыкара оешмалар һәм үзара килешүләр рәвешендәге чикләмәләр дөнья *өммәтен* барлыкка китерә дә инде.

Өченче меңьеллык кеше һәм җәмгыять каршына бөтенләй яңа таләпләр куя. Шәхес һәм аерым халыкларның роле чагыштыргысыз артты. Алар үзкыйммәткә әверелделәр һәм мөселман берләге эчендә эреп югала алмыйлар. Дөнья инглиз телендә сөйләшүне кулайрак күрә, балаларыбыз инде Интернеттан чыкмый утыралар. Без үз тормышыбызны дистәләгән каналлы телевидениедән, электрон почтадан, кәрәзле телефоннардан, дөньяның теләсә нинди ноктасына алып бара ала торган самолетлардан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Гарәп теле һәм мәдәнияте элеккеге әһәмиятен һәм күнелгә ятышлыгын югалтты, алар кешегә бернинди дә өстенлек бирмиләр.

Безнең кыйбла кайда соң хәзер?

***"Пәйгамбәрләрне һәр заманада үз кавемнәреннән җибәрдек шәригать хөкемнәрен үз телләрендә бәян итсеннәр өчен"[14:4].***

Ислам—борынгы һәм мәңгелек дин. Әйтелгән:"Ии, мөэминнәр, әйтегез:"Аллаһуга һәм үзебезгә иңдерелгән Коръәнгә һәм Ибраһим, Исмәгыйл, Исхак, Ягъкуб пәйгамбәрләргә иңдерелгән вәхигә, аларның балаларына иңдерелгән вәхиләргә ышандык, пәйгамбәрләрне берсен икенчесеннән аермыйбыз, барчасына бертигез ышанабыз, һәм Аллаһуга итагать итеп, мөселман булабыз",—дип" [2:135-137]. Ходай Тәгалә халыкларга дини кануннарны аларга аңлаешлы телләрдә җиткерү өчен дистәләгән пәйгамбәрләр җибәргән.

Гарәпләр кайчандыр беркатлы рәвештә, изге китап гарәп телендә иңдерелгән, ә Җәбраил (архангел Гавриил) аны пәйгамбәрләрнең һәрберсенең ана теленә тәрҗемә иткән дип уйлаганнар. Чынлыкта исә, Коръән Пәйгамбәргә "иңдерелгән" [2:285;3:7;5:83], "вәхи кылынган" [4:163]. Пәйгамбәр әйткән: "Үзлегемнән Коръәнне алыштырмак яки хөкемнәрен үзгәртмәк миңа һич тә мөмкин түгел, чөнки ул Аллаһ сүзе, мин үзем дә Аллаһ миңа вәхи кылган хөкемнәргә генә иярәмен" [10:15]. Ходай сүзе барлыкка китерелмәгән, аның тарафыннан әйтелмәгән, әмма аның асылы Пәйгамбәр аша җиткерелгән. Әбү Хәнифә: "Аллаһ сөйли, әмма без сөйләгән кебек түгел. Без төрле авазлар чыгарып сөйләшәбез. Аллаһ Тәгалә сөйләменең башы да, ахыры да юк, ул туктап та тормый, чөнки ул хәрефләр дә, авазлар да түгел",—дип язган.[1]

***"Аның белән имин булган Җәбраил фәрештә иңде. Ул Җәбраил Коръәнне синең күңелеңә иңдерде, кешеләрне Аллаһ газабы белән куркытучы булмаклыгың өчен" [26:193-194].***

Аллаһ Тәгалә безнең телләргене түгел, йөрәктәгене тыңлый.

Теләсә нинди телдә сүзләр мәгънәсе аның нинди шартларда яшәвенә бәйле. "Сүзнең мәгънәсе—аның телдә кулланылышы"—дип язган Людвиг Витгенштейн.[2]

Әйтик, мин "Мелодия волнует душу" дигән җөмләне рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәм, ди. Аның төзелеше дә, сүзләре дә гади. Татарча белгән теләсә кем аны шактый төгәл тәрҗемә итәчәк: "Моң күнелне дулкынландыра". Инде киресенчә, татарчадан русчага тәрҗемә итәргә кирәк, дип уйлыйк. Менә биредә инде кыенлыклар килеп чыга, чөнки "моң" сүзенең мәгънәсе тирән һәм күптөрле: сагыш, аңлатып булмый торган хис, күңел халәте... Әлеге сүздә татарның драматик, ә кайчак фаҗигале тарихы да, барлык этник кичерешләре дә чагыла. Һәм бары тик ахыр чиктә генә "моң" сүзе "мелодия", ягъни көй мәгънәсен аңлатырга мөмкин. "Мелодичная мелодия" дип тәрҗемә итеп булмый, бу хәтта "душевная мелодия" дә түгел. Бу татар җанына кагылучы, үзәген өзүче көй. Гомумән, бу гыйбарәне башка телдә аңлату һәм аңлау кыен, чөнки һәрбер халыкның үз тарихы бар. Нәтиҗәдә, кире тәрҗемә очрагында баштагы гыйбарәдәге "мелодия" сүзенә урын калмый. "Глубокие душевные чувства волнуют сердце" дип тәрҗемә тәкъдим иткән очракта да, мине "моң" сүзен җиңелчә тәрҗемә итүемне тәнкыйтьләүчеләр

[1] Знание о боге – наиважнейшее из знаний. – Киев, 2002. – С.17.
[2] [illegible] Ч.1. – М.: ГНОЗИС, 1994. – С.90.

табылачак. Һәм алар хаклы булачак. Телдә шушы халыкка гына хас мәдәни стереотиплар яши. Аңызда ни булса, әйләнә-тирәдә шуны күрәбез. Без ишеткән сүзләр безнең бүгенге күзаллауларны сурәтли.

Мәгънә—ул кулланылыш, шуна күрә сүзләрнең мәгънәсен кайвакыт үзләре яшәгән шартларда гына аңлап була. Гарәп өчен дөя—яшәеш, матурлык, муллык, байлык символы. Ул хатын-кызны ана дөягә тиңли ала һәм бу һич тә хурлау түгел. Ә без дөянең мәгънәсенә төшенә алмаячакбыз, чөнки безнең өчен дөя—зоопарк хайваны. Коръәндәге: *"Әллә кешеләр дөяләргә карамыйлармы, ничек халык кылынганнар—яратылганнар?" [88:17]*—дигәнне укыганда, без бу җөмләнең мәгънәсенә тиз генә төшенә алмыйбыз. Төньяк кинлекләрдә яшәүче кеше өчен дөя—бары тик экзотик хайван гына.

Безгә Коръәндәге, гарәпләр тормышының мөһим нигезен тәшкил иткән: *"Инҗир җимеше илә ант итәм, вә зәйтүн агачы белән" [95:1]*,—дигән юлларны да аңлавы читен. Ни өчен шушы агачлар белән ант итәргә кирәк? Аңлашылмый.

Сүзләрнең мәгънәләре бары тик аларны кулланганда гына ачыла. Телдә һәрбер сүзнең мәгънәсе бар, ләкин аның мәгънәсенә ул сүз кулланылган тирәлектә генә төшенергә мөмкин. "Берәр нинди телне күз алдына китерү—ул билгеле бер тормыш рәвешен күзаллау дигән сүз",—дип яза Людвиг Витгенштейн.[1]

Ислам турында хәзерге заман мәкаләләренең берсендә болай диелә: "Кеше Аллаһ Тәгаләгә йөрәге белән якыная. Акыл—йөрәкнең ярдәмчесе".[2] "Йөрәк" *(кальб)* сүзенең хәзерге замандагы мәгънәсеннән чыгып карасак, бу чыннан да шулай, ләкин Мөхәммәт Пәйгамбәр заманында гарәпләрдә йөрәк—акыл савыты булып саналган. Димәк, Аллаһка йөрәк белән омтылу, Коръән буенча, аны акыл белән аңлау дигән сүз. Әйтелгән: *"Әллә алар җир өстендә йөрмиләрме, йөрсәләр һәлак булган шәһәрләрне күреп гыйбрәт алырлар иде, һәм күңелләре йомшарып Аллаһуның газабын аңлар иделәр, һәм колаклары да хак сүзләрне ишетә, йөрәкләре дә аңлый торган булыр иде, бит маңгай күзенең сукыр булуы Аллаһуны танып мөселман булудан мәхрүм итмәс, мәгәр йөрәк сукыр булса—ул мәхрүм итәр" [22:46]*. Бирелә "йөрәк аңлый" дип әйтелә, игътибар итегез: без гадәтләнгәнчә йөрәк "тоя" түгел—йөрәк "аңлый". Бүген исә безнең өчен йөрәк—акыл савыты түгел, хисләр савыты. Шуңа күрә, без Коръәндә: *"Аллаһу Тәгалә, бер кешене һидаяткә—диндә туры юлга салырга теләсә, ислам дине өчен аның күкрәген ачып куяр, янә Аллаһ, бер кешене хак диннән адаштырырга теләсә, ул кешенең күкрәген тар, күңелен хактан шикләнүче кылыр, шуннан соң бу кеше, күкрәге тар булу сәбәпле, хаклыктан тыгызланып—Аллаһ хөкемнәрен яратмыйча, гүя күккә чыгардай булыр" [6:125]* дигәнне укыганда, без сүзнең кешенең йөрәге түгел, акылы турында барганын аңларга тиеш.

Гомумән, Коръәндә 133 тапкыр искә алына торган йөрәк турында аерым бер фән барлыкка килгән. Аның зур тарихы һәм күпсанлы юнәлешләре бар. Кешеләрнең һәрбер бергәлеге төрле заманнарда бу сүзгә үз мәгънәсен, кайвакыт капма-каршы мәгънә салган. Димәк, гарәп телен белү Коръән *сурәләрен* шәрехләүләрнең барысының да бер мәгънәдә булуларын нигезли алмый.

> ***"Күчеп йөрүче бәдәви гарәпләре әйттеләр: "Иман китердек",—дип, син әйт: "Сез иман китермәдегез, ләкин мөселманнардан куркып, яки мөселманнардан файдаланып, көн күрү өчен тыштан гына Ислам динен кабул иттек",—дип әйтегез! Әле күңелегезгә иман әсәре кергәне юк"[49:14].***

Коръән үзе индерелгән культураның һәм халыкларның эзен саклый. Изге китапта мондый сюжет бар: "Кунакларның сүзен ишетеп, Ибраһимның хатыны Сара, кунаклар алдына тавышланып чыкты, вә йөзенә сугып әйтте: *"Мин бала тапмый торган карчыкмын, миндә кайдан бала булсын",—дип."* *[51:29]*. Европа традицияләрендә тәрбияләнгән кешеләр моны сүзгә-сүз аңлый—хатын-кыз үзе үк үз битенә суга. Чынлыкта исә, бу хәрәкәт гаҗәпләнүне аңлата һәм ул Көнчыгыш хатын-кызларына хас.

Коръәннең теле сүзгә-сүз укыганда кайбер урыннарда аңлашылмый. Әйтелгән: "Кеше ашыгучан булып халык ителде! Ии, мөшрикләр газабыбызны сезгә бик тиз күрсәтербез, *"газаб булса тизрәк булсын"*,—дип мине газабка ашыктырмагыз" *[21:37]*. Бу бары тик образ гына, Кыямәт көнен тасвирлау да шундый, анда мондый сүзләр

---

[1] *Витгенштейн Л.* Философские работы. Ч.I. – М.: ГНОЗИС, 1994. – С. 86.
[2] *Шайдуллин Х.Л.* Вероучение Ислама. – В кн.: *Абу Ханифа Нугман ибн Сабит.* Трактаты. – М., 2001. – С. 15.

бар: *"Кайчан күк ярылса. Вә йолдызлар чәчелсә..."* Аңлашыла ки, йолдызлар чәчелә һәм күкләр ярыла алмый, ләкин шулай хиссиятле сурәтләнгән күренеш кешене ныграк ышандыра. Җәннәт тә әнә шулай образлы итеп тасвирлана.

Хатын-кызның Адәмнең кабыргасыннан яратылуы турындагы легенда, ул сөйләнгән телнең культурасын начар белү аркасында күп гасырлар яшәп килә. Фридрих Макс Мюллер бу турыда болай язган: "Адәмнең Хаувага: "Син мин яратылган кебек үк яратылган" дип әйтүе мөмкин, ә борынгы яһүд телендә ул үзенең фикерен: "Синең сөягең—минем сөягем кебек, синең тәнең минем тәнем белән бер" ("Ты кость от кости моей, и плоть от плоти моей") дип белдергән. Бу гыйбарә берничә буын гына кабатлана, тиздән аннан сүзгә сүз, кешене ялган мәгънәгә кертүче һәм, болай дияргә мөмкин булса—матди аңлатма килеп чыккан, һәм инде алга таба кешеләр, беренче хатын-кызның беренче ир-ат сөягеннән яки кабыргасыннан ясалуына ышана башлыйлар. Сәбәбе дә гади: күрәсең, Адәм кабыргадан башка яшәүне теләсә нинди бүтән сөякне югалтуга караганда җиңелрәк кичергәндер. Шушы аңлашылмаучылык, бер мәлне барлыкка килеп, бөтен сәерлегенә карамастан, сакланып калган".[1] Телдәге шушы клише—ялгышлыкның тотрыклы кузаллауга әйләнеп китүенә бик гыйбрәтле мисал.

Әкиятләштерелгән сюжетларны сүзгә-сүз кабул итәргә ярамый, алар тел сурәтләмәсенең бары тик кайбер элементлары гына. Гасырлар буе яшәү дәверендә исламда бик күп риваятьләр барлыкка килгән, алар, Коръәнгә турыдан-туры карамасалар да, кешеләр аңына шактый нык кереп калганнар.

Безнең тормыш урта гасырлар яшәешеннән тамырдан аерылып тора. Бүген коллык та, баскынчылык та юк, кешеләр кабиләләр тәшкил итми, милләт булып яши. Яһүдләр дә, христианнар да үзгәрде. Өстәвенә, Россиядә төрле халыклар яши, бередә икътисад та, климат та башка.

> ***"Ул—Аллаһ җирне вә күкләрне хаклык илә яратты, вә Ул кичнетөнне көндезгә кертеп көнне озынайтты, вә көндезне төнгә кертеп төнне озынайтты, вә кояш-айдан кешеләрне файдаландырды, кояш, ай һәм башкалары билгеле көнгә чаклы үз урыннарында йөрүчеләрдер"* [39:5].**

Коръәннең кайбер күрсәтмәләре бик катгый язылган, аларны кайбер үзенчәлекле шартларда кулланып булмый. Әйтелгән: *"Һәм сәхәр дә ашагыз, эчегез, хәтта таң яктысы беленгәнче, аннары уразаны тотып, тәмам итегез кояш баеганчы!"* [2:187]. Поляр түгәрәк янында яшәсән, уразаны ничек тотарга? Анда кояш чыкмый лабаса.

Коръәннең хәрефен генә түгел, рухын да яхшы аңлаган Муса Бигиев, әлеге вазгыятькә үз аңлатмасын тәкъдим иткән. Ул башка бер *аятьне* тикшергән: *"Ураза саналмыш көннәр, ягъни ураза ае 29 көннән һәм 30 көннән киләдер"* [2:184]. Ул бередә көнне төннән аерып булмый торган географик киңлекләрдә яшәүчеләр өчен күрсәтмә күреп алган. "Озын көннәрдә Рузә" дигән китабында ул болай дип яза: "Изге Коръәннең ап-ачык күрсәтмәсе буенча, мондый төбәкләрдә ураза бервакытта да мәҗбүри түгел. Чөнки ураза билгеле бер сандагы көннәргә генә билгеләнгән, ягъни мәсәлән, көн белән төн үзләренең озынлыклары буенча бер-берсенә чагыштырмалы булган төбәкләрдә генә. Ә ел бары тик көннән яки бары тик төннән генә торган полюсларда яки Поляр түгәрәк янында, көн дә, төн дә атналарга, айларга сузылган салкын өлкәләрдә яшәүче кешеләр, көннәрнең вакыт ягыннан чикләнгәнлеге сәбәпле, ураза тота алмыйлар. Бу географик өлкәнең үзенчәлекләреннән килеп чыга". Петербургның ак төннәрен күрмәгән гарәп бу мантыйкны аңламый да, кабул да итми, әлбәттә.

Полюсларда көнчыгыш та, көнбатыш та, зенит та юк, анда кояш чыкмый да, батмый да.

Коръәндә көннең төнгә алмашынуы бер дә үзгәрми торган, үзеннән-үзе аңлашылучы тотрыклы күренеш, нииндидер могҗиза һәм Ходайның барлыгын раслаучы күренеш шикелле бирелгән. Ходай Тәгалә Поляр түгәрәк артында яшәүче кешеләр турында белмәгән дип уйлау да дөрес булмас иде. Ләкин Аллаһ Коръәнне экваторга якын яшәгән гарәпләргә иңдергән, башкача бирелсә, алар моңа инанмаслар иде.

> ***"Барча хәлне ачык бәян итүче Коръән илә ант итеп әйтәмен! Без бу Коръәнне гарәб телендә кылдык—шаять, ии кешеләр, аңлап иман***

***китерәсез! Тәхкыйк ул Коръән Ләүхүлмәхфузда китаплар анасында сабиттер, сакланадыр. Безнең хозурыбызда ул гаять бөектер һәм гадел хөкем итүчедер" [43:2-4].***

"Коръәндә һәм хәдисләрдә—дип яза Рукайя Максуд,—кеше хокуклары турында күпсанлы хикмәтле фикерләр бар"[1] һәм ул аларның тулы исемлеген китерә: яшәүгә, тигезлеккә, фикер иregenә, сәяси ирекккә хокук һәм башка хокуклар. Болар барысы да заманча төсмергә ия. Чыннан да, әдәбиятта еш кына мәгълүм *хәдистән* өземтә китерәләр: "Хокуклар ни рәвешле бозыла? Хокуклар гөнаһлар ачыктан-ачык кылынганда һәм гөнаһ ияләрен ялгышлыктан тыеп торучы булмаганда бозыла". Бу сүзләр без бүген дә куллана торганнарына охшаган, әмма мәгънә башка: йөрәкне әгъза мәгънәсендә дә, җан мәгънәсендә дә бер үк "йөрәк" дигән сүз белән атаган шикелле. "Йөрәк" сүзе кайда да бертөрле языла, ләкин мәгънәсе кулланылган контекстта гына аңлашыла.

Борынгы заманнарда хокуклар ирекле кешеләр өчен генә каралган, колларны кешегә санамаганнар, алар милек булганнар. Мөхәммәт Пәйгамбәр колларны азат итәргә өндәгән һәм үзе моңа үрнәк күрсәткән, ләкин ул коллык институтын бөтенләй сызып та ташламаган. Шәригать коллыкны, аерым алганда әсирлек нәтиҗәсендәге коллыкны, хәзергәчә таный. Хәнифи *мәзһәб* әсиргә үлем җәзасы бирүне яки аны колга әйләндерүне кузда тота, ул хәтта, башка *мәзһәбләрдән* аермалы буларак, колны сатып алу мөмкинлеген тикшерми дә. Шуңа күрә, кеше хокуклары турындагы хәдисләрне бүгенге вәзгыятькә күчерергә ярамый.

Кеше хокукларын заманча шәрехләү АКШ Конституциясенә беренче ун төзәтмә керткән вакыттан башлана, ләкин биредә дә әлеге төшенчәнең эволюциясенә игътибар итәргә кирәк. Бу төзәтмәләрнең мәгънәсе федерациянең штат гражданнары мәнфәгатьләренә кул сузуыннан саклаудан гыйбарәт. Бары тик Икенче бөтендөнья сугышыннан соң гына кеше хокуклары шәхси хокуклар буларак аңлатыла башлый, һәм, әкренләп, аларның бүгенге мәгънәсе ныгытыла. Бу урында нокта куярга да мөмкин булыр иде, ләкин кеше хокуклары темасын тикшергәндә Россия үзенчәлекләрен күрсәтмәсәк, фикер төгәлләнми калачак. "Милләтчеләр" дип аталучылар кеше хокукларының төп өлеше итеп этник мәнфәгатьләрне яклауны санап, алар турында кайгырткан мәлдә, Россиянең урыс телле халкы кеше хокукларын гражданлык хокуклары дип аңлый. Шул рәвешле, Пәйгамбәр әйткән кеше хокуклары һәм безнең җәмгыятьтәге кеше хокуклары—икесе ике төрле күренеш. Бу очракларның һәммәсе өчен аерым терминнар куллану дөресрәк булыр иде, ләкин андый терминнар әлегә эшләнмәгән.

Коръәннең асылына шул чордагы яшәеш шартларын һәм шул чор культурасы вәкилләренең менталитетын яхшы белгән хәлдә генә төшенергә мөмкин. Аны, Пәйгамбәр XXI гасырда яшәгәндәй, сүзгә-сүз укырга, безнең җәмгыятькә VII гасырда килеп чыккан терминнарны көчләп тагарга ярамый.

***Әнә шулай һәрнәрсәне бәян итүче Коръәнне гарәб телендә иңдердек вә ул Коръәндә газаб белән куркытуны күп кабатладык, кешеләр газабтан куркып гөнаһтан сакланасыннар өчен яки әүвәлге кавемнәрнең хәлләрен бәян итүче көчле вәгазь булсын өчен"[20:113].***

Тел үз заманының һәм үзен кулланган халыкның тирәлеге контекстында гына яши.

Коръән гарәпләргә "ап-ачык гарәп телендә" билгеле бер вакыйгалар турында иңдерелгән. Аларны дингә ышандыру шулай җиңелрәк булган. Мәсәлән, Изге китапта әйтелгән: *"Әбү Ләһәбнең ике кулы корысын һәм һәлак булсын!" [111:1].* Сүз Мөхәммәт Пәйгамбәрнең аңа зарар тидерергә тырышкан абзасы турында бара. Бу очракта анык мәсьәлә һәм аның чишелешен табу ихтыяҗы булган. Бүген исә әлеге *аять* Пәйгамбәр тормышының бер күренешен искә төшерү булып кына тора, ул хәзерге заманда кулланыла алмый, өстәвенә, Әбү Ләһәбнең кулларына барыбер зыян килмәгән.

Теге яки бу хәрби экспедицияләргә кагылышлы рәвештә иңдерелгән *сүрәләр* бар. "Тәүбә" *сүрәсенең* 25 нче *аятендә* әйтелгән: "Аллаһ, сезгә күп урында вә хөнәен көнендә ярдәм бирде, ул хөнәен көнендә сезне үзегезнең күплегегез гаҗәбләндерде, ягъни без мөшрикләргә караганда бик күпбез, җиңелмәбез,—дидегез, хәлбуки

[1] Рукайя Максуд. Ислам. – М., 2001. – С.178.

куплегегез сезгә һич файда бирмәде, кин җир сезгә тар булды, сонра артка таба качтыгыз". Бу *аятьтә* күпсанлы тарихи вакыйгаларның берсе турында әйтелгән. Коръәндә гарәп кабиләләренең яшәешенә кагылышлы сюжетлар күп.

> ***"Әгәр без Коръәнне гарәб теленнән башка телдә кылсак иде, әлбәттә, әйтерләр иде:"Ни булыр иде бу Коръәннең аятьләре без аңлый торган гарәб телендә бәян ителгән булса, пәйгамбәр үзе гарәб, китабы башка телдә, дип, янә инкурләрен арттырыр иделәр"[41:44].***

Коръәннең күче аның тәгәллегендә, ул корәешләрне һәм башка кабиләләрне хак юлга бастыру мөмкинлеге биргән, ләкин шул ук вакытта шушы тәгәллек үзе үк безнең заман өчен кыенлыклар тудыра. Сорау туа: Коръәндә нәрсә билгеле бер вәзгыять өчен әйтелә, ә нәрсә мәңгелек өчен индерелеп универсаль үзенчәлеккә ия? Бар нәрсәне дә бүгенге көнгә күчерергә ярамый лабаса. VII гасыр гарәпләренең тормышы безнең өчен үрнәк була алмый. Бу, әлбәттә, бик әһәмиятле һәм гыйбрәтле тарих, ләкин барыбер тарих кына.

Мин Татарстанда яшим һәм минем урта гасыр гарәбенә охшыйсым килми, мин—татар һәм татар булып каласым килә. Минем өчен үз халкымның тарихы мөһимрәк, татарларның Евразия язмышына йогынтысы гарәпләрнең Көнчыгыш тарихына йогынтысыннан һич тә ким түгел. Минем өчен шулай ук урыслар тарихын һәм халкымның төп өлеше яшәгән Россиянең тулаем тарихын белү дә бик мөһим.

> ***"Ул пәйгамбәрләрне могҗизалар вә китап белән җибәрдек. И-и, Мөхәммәд г-м, Без сиңа Коръән индердек, кешеләр өчен хаслап индерелгән шәригать хөкемнәрен өйрәтмәклегең өчен, шаять иштеп, фикерләп карарлар вә аңлап кабул итәрләр!"[16:44].***

Мәккә чорында Коръән аятьләре барлык кешегә дә юнәлтелә. Әйтелгән: *"И-и, кешеләр, Без сезләрне ир вә хатын итеп халык кылдык, вә сездән тармаклар, вә кабиләләр кылдык, бер-берегезне аерып танымаклыгыгыз өчен" [49:13].* Анда ир-ат һәм хатын-кыз хокуклары арасында аерма юк, кешеләрне ислам юлына кертүдә көч куллану тыела, башка дин кешеләренә карата түземле мөнәсәбәт ачык чагыла.

Мәдинә чорында исә *аятьләр* күбрәк VII гасыр гарәпләренә юнәлтелә һәм мәҗүсиләргә карата мондый күрсәтмәләр бирелә: *"Каферләр сезгә каршы сугыш башласалар, кайда очратсагыз шунда үтерегез һәм алар сезне чыгарган кеби, аларны өйләреннән чыгарыгыз" [2:191].* Хатын-кызларны ир-атлар белән хокук ягыннан тигезсез итүче *аятьләр* барлыкка килә. Әйтелгән: *"Аллаһ мәхлукләрне кайберләрен кайберләреннән артык кылу белән, ирләр акылда, куәттә хатыннардан өстен булды һәм малларын хатыннарга инфак кылу белән дә ирләрнең дәрәҗәсе өстенлер" [4:34].* Яки: *"Аллаһ балаларыгыз хакында булган мирасны бәян итәдер, үзегез үлеп, балаларыгыз калганда, ир балага хатыннарга биргәннең ике өлеше бирелер" [4:11].* Әлбәттә, моны аңлатучылар табыла һәм моны гадел принцип дип атыйлар, чөнки тормышта ирләр җилкәсенә зуррак җаваплылык салына, ләкин тигезсезлек барыбер тигезсезлек инде ул.

Мәккә һәм Мәдинә чорлары аятьләре арасында каршылыклар ачык күренә һәм аларны бер-берсенә яраштыру мөмкин түгел—алар бер-берсен инкарь итә. Шуңа күрә, мөселман хокукы белгечләре Мәккә чоры аятьләрен, әлегрәк индерелү сәбәпле, гамәлдән чыккан дип саныйлар. Ләкин вәхи ителү вакыты—бер аятьләрне тәэсир көче буенча икенчеләреннән өстенрәк дип санау билгесе түгел. Әгәр дә алар чынбарлыкта гамәлдән чыгарылган булса, имеш "гамәлдән чыгарылган" дип аталучы әлеге аятьләрне Пәйгамбәр үзе Коръән текстына кертмәс иде. Мәгълүм ки, Коръәнне укытучы дүрт төп белгеч: Абдулла бин Масуд, Салим Мәүлә Аби Худхәйфә, Муаз бин Җабал һәм Гобәйя ибн Кааб турыдан туры аның күзәтчелегендә хәзерләнә. Аның бу мәсьәләдә ни дәрәҗәдә вакчыл булганлыгын бары тик бер генә сүзнең әйтелеше турындагы вакыйга ачык күрсәтеп тора. Гомәр бервакыт Мөхәммәт Пәйгамбәргә Абдулла бер фигыльне дөрес әйтми дип зарланган. Шуннан соң Мөхәммәт, аларның икесен дә тыңлап, авазның дөрес әйтелешен раслый. Пәйгамбәр исән чакта ук Коръәнне яттан белүчеләр күп булган. Бервакыт Пәйгамбәргә Әбү Мусаның үз йортында кешеләрне Коръән укырга өйрәтүе хакында хәбәр иткәннәр. Пәйгамбәр үзен шул йортның Мусаны тыңлап була торган бер бүлмәсенә яшерен рәвештә алып керүләрен үтенгән. Һәм ул, Коръән укуларын тыңлаганнан соң, канәгать калган. Мөхәммәт Пәйгамбәр Коръән текстының тәгал саклануын

игътибар белән күзәтеп торган. Әйткәнемчә, әгәр дә ул кайбер аятьләрне гамәлдән чыккан дип санаса, аларны Коръән текстына кертмәс иде. Инде Пәйгамбәр үзе аятьләрне гамәлдән чыгару вазифасын үз өстенә алмаган икән, ни өчен ниндидер башка берәүнең моңа хакы булырга тиеш?

***"Тиздән укырбыз сиңа Коръән аятьләрен һәм син онытмассың. Мәгәр, Аллаһ теләгәнне генә онтырсың, әлбәттә, Ул яшерен эшләнгән эшләрне дә, һәм әшкәрә эшләнгән эшләрне дә беләдер"[87:6-7].***

Бүген дә Мәккә чоры *аятьләрен* безнең заман өчен әһәмияте аз дип шул ук рәвешле гамәлдән чыгару ысулын кулланырга мөмкин. Габдуллахи Әхмәт Ән-Наим болай дип яза: "Коръәнне аңлатуга эволюцион караш—Коръәннең элегрәк гамәлдән чыгарылган текстларын хәзер кулланырга мөмкин булырлык итеп һәм, шуңа ярашлы рәвештә, шәригатьтә элегрәк кулланылган текстларны хәзер гамәлдән чыгару мөмкин булырлык итеп кире якка юнәлдерелгән *нәсех* (яки гамәлдән чыгару процессы) кенә ул".[1] Чынлыкта исә, *аятьләрнең* һәр төренең (Мәккә чоры, Мәдинә чоры *аятьләре*) үз кулланылыш даирәсе һәм үз *өммәте* булган: принципларның берләре барлык халыклар өчен һәм мәңгегә индерелгән, ә икенчеләре—күбрәк урта гасырлар башында яшәгән гарәпләр өчен индерелгән. Коръәндә бер генә нәрсә дә гамәлдән чыгарылмаган һәм чыгарылмый да, әмма алар юнәлдерелгән бергәлекләр төрле.

Мәдинә җәмгыяте беренче ислам дәүләте буларак барлыкка килгән. Яңа туган бала шикелле, ул зурлар ризыгын ашый алмый, ана сөте имә; тәүге мөселманнар да шулай ук: мәңгелек нәрсәне кабул итә алыр өчен үсәргә тиеш булганнар. Алардан шуннан да артыгракны таләп итеп булмаган. Мәдинә чоры *аятьләре* үз заманы өчен хакыйкать булганнар, алар ислам барлыкка килгән җәмгыятьнең теленә, уй-фикерләренә, хиссиятенә тыгыз бәйләнгәннәр, алар үзләренең тарихи чорына тулысынча тәңгәл киләләр. Һәм зур үскән бала сабый телен онытырга тиеш булган кебек, ислам да, ныгып, Мәккә теленә күчәргә тиеш булган. Вакыты җиткәч, "Китаплар анасыннан" алынган һәм бөтен кешелеккә җибәрелгән Мәккә чоры *аятьләре* үз көченә керә.

***"Аллаһ теләгән нәрсәсен бетерер һәм теләгән нәрсәсен бар кылыр, вә китаплар анасы Ләухүлмәхфуз—Аллаһу хозурындадыр"[13:39].***

"Китаплар анасын" аңлату, хакыйкатьне конкрет халыкларга һәммәсенең ана телендә житкерү өчен пәйгамбәрләр җибәрелгән. Мөхәммәт Пәйгамбәр әйткән:"Безгә, пәйгамбәрләргә, кешеләр белән алар безне аңларлык дәрәҗәдә сөйләшергә кушылды". Коръәнне гамәлдәге менталитетка һәм гореф-гадәтләргә яраштырып аңлатырга кирәк була.

*Аятьләрнең* берләрен икенчеләре белән гамәлдән чыгарылган дип санау—Аллаһ Тәгаләнең ихтыярын түбәнсетү яки аның вәхиләрен ялгыш дип санау. Әйтелгән: *"Әгәр кайбер аятьләрнең хөкемнәрен үзгәртсәк яки оныттырсак, ул аятьләргә охшашлы аятьләрне яки яхшыракны бирербез" [2:106]*. Беренче карашка сүз Коръәннең кайбер аятьләрен гамәлдән чыгару мөмкинлеге турында бара шикелле тоела. Ләкин алдагы аятьләргә карасак [102-105], фикер тулысынча ачыла. Анда сүз христианнар, яһүдләр, күп Аллаларга табынучылар турында бара, аларга да *"китаб җибәрелгән"*. Аннан соң килгән 106 нчы *аятьтә* инде сүз "аятьләрнең хөкемнәрен үзгәртү" турында бара. Димәк, "гамәлдән чыгару" принцибы Коръәнгә түгел, *китабка* карый.

Аллаһ Тәгалә Жиргә күп пәйгамбәрләр җибәргән, ләкин алар Алла сүзен тулысынча житкерә алмаганнар. Аларның дәлилләрендә ялгышлыклар һәм ачыкланып җитмәгән урыннар барлыкка килгән. Әйтелгән: *"Синнән элек тә пәйгамбәр вә рәсүл җибәрмәдек, мәгәр җибәргән рәсүл вә пәйгамбәр бер нәрсәне сөеп теләсә, шайтан аның теләгән нәрсәсенә вәсвәсәсен салыр иде, шайтан салган нәрсәне Аллаһ бетерер, вә аларга биргән аятьләрен мәхкәм таза кылыр иде, бит Аллаһ белеп һәм хикмәт белән эш кылучы" [22:52]*. "Китаплар анасы" буенча, Коръәнгә элеккеге язмаларның хаталарын бетерү вазифасы йөкләтелгән, әмма аның үзендә бернәрсә дә гамәлдән чыгарылмый, чөнки ул Ходайдан индерелгән вәхи.[2]

---

[1] Абдуллахи Ахмед Ан-Наим. На пути к исламской реформации (Гражданские свободы, права человека и международное право). – М., 1999. – С.70.

[2] Мөмкин булган бердәнбер компромисс "гамәлдән чыгару" төшенчәсен "кичектерү" мәгънәсендә аңлату булыр иде. Монысы да *мәзһәбләргә* нигез салучыларны аклар өчен генә кирәк, ә бәлки, кемне дә булса аклауның хаҗәте юктыр...

*Нәсех* ысулы урынына *иҗтиһад* кулланылырга тиеш, ул Мәдинә җәмгыятенә юнәлдерелгән аерым принциплардан әкренләп барлык кешелек өчен җибәрелгән нормаларга күчәргә мөмкинлек бирә.

Кайчандыр кешелек бердәм Ибраһим *өммәтен* тәшкил иткән. Аннан соң ул бүленгән. Төрле диннәр һәм берләшмәләр барлыкка килгән, алар бер-берсе белән дошманлашканнар да, хезмәттәшлек тә иткәннәр, кайвакыт берлекләр дә төзегәннәр. Империяләр барлыкка килгән һәм таркалган. Вакытлар узу белән *өммәт* төшенчәсе үзе дә үзгәргән. Бүген бөтен кешелек бердәм бергәлек булып тора.

*Иҗтиһад,* ислам нормаларын Коръән рухыннан чыгып заманча шәрехләүне тәкъдим итеп, җәмгыятьнең эволюциясен исәпкә алырга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, *җиһад,* кяферләргә каршы сугыш буларак, урта гасырларда аңлаешлы мәгънәгә ия булган, чөнки ул чор өчен көч сәясәте—гадәти күренеш. Ләкин Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, сугыш алып бару ысуллары һәм кешелек яшәешенә янаган куркыныч үзара чагыштырырлык дәрәҗәгә житкәч, шартнамә мөнәсәбәтләре һәм халыкара хокук элеккеге көч куллану принцибыннан өстенрәк булып чыктылар.

Пәйгамбәр көч кулланыла торган кече җиһадны, исламны Коръән ярдәмендә таратуны күздә тоткан бөек җиһадтан аерып караган. Әйтелгән: *"Инде син имансыз динсезләргә итагать итмә, аларга иярмә һәм аларга хезмәт итмә, бәлки ялган иман, ялган дингә вә имансызлыкка, динсезлеккә каршы Коръән белән көрәшү юлын ач, зур көрәшү белән көрәш!" [25:52].* Кече җиһад мөселманнарга башка дәүләтләр тарафыннан куркыныч янаган вакытта, урта гасырлар чорына хас рәвештә, ислам тарафыннан яңа биләмәләр яулап алынганда кирәк булган. Бүген сугыш һәм тынычлык мәсьәләләренең регламенты башкача билгеләнә. Шуңа күрә, җиһадны бүген турыдан-туры мәгънәсендә, ягъни "тырышлык", матди *дөньяга* каршы, рухи башлангыч өчен "көрәш", үз-үзенә ышанмаучылык белән "көрәш" дип аңларга кирәк. Бу мәгънә Аллаһ тарафыннан барлык заманнар өчен бирелгән. Кече җиһад, әгәр дә ул гадел булса, үз-үзенне яклау максатында, басып алучылар һәм тираннарга каршы көрәшү өчен игълан ителә, бу Коръән текстына гына түгел, халыкара хокук кысаларына да туры килә.

*Аятьләрне* шәрехләгәндәге мондый аерымлыклар бүгенге көндә бигрәк тә мөһим. Ваhhабичылык башка диннәр, хәтта исламдагы башка агымнарга да каршы көрәшкә юнәлдерелә. Исламның "сафлыгына" өндәп, чынлыкта, ул ханбали *мәзһәбнең* ахыр чиктәге чагылышына—рациональлекне тулысынча инкарь итүгә ияреп бара. Имеш, Коръәнне аңлау мөмкин түгел, ана бары тик ышанырга гына кирәк. Моның белән ул бернинди дә яңа күренешләрне танымый торган традициячелекне яклый.

> ***"Пәйгамбәр килгәнче дөньядагы кешеләр бер генә төрле иде, ягъни бар да мөшрик иделәр, Мөхәммәд г-м килгәч, берсе мөэмин, берсе мөшрик—икегә бүленделәр" [10:19].***

Ике бөтендөнья сугышыннан соң кешелек өченчесе барлыкка килүгә каршы механизмнар булдырды. Бүген мөселман *өммәте* эчендә *иҗмагъ* (консенсус) турында сүз куертуның мәгънәсе юк. Барлык мөселман илләре Мисыр *өммәте,* Иордания *өммәте* һәм башкалар кебек мөстәкыйль халыклар булып яшиләр. Кешелек—бердәм бергәлек һәм куркынычсызлыкны, тынычлыкны, тотрыклыкны барыннан да югары бәяли.

*Иҗтиһадның* тагын бер үрнәге. Әйтелгән: *"Аллаһ аларның күңелләрендәге яхшы ниятләрен белде, аларга күңел тынычлыгын бирде һәм тиздән Мәккә фәтех ителәчәк, мөселманнар кулына үтәчәк, дип аларны шатландырды. Дәхи күп табыш малларын бирде, алар ул табыш малларын Хәйбәрдән алырлар, Аллаһ җиңүче, вә эшне белеп кылучы булды. Аллаһ сезгә күп табыш маллары вәгъдә кылды, алырсыз ул табышларны Хәйбәрдән, һәм ашыктырды сезгә ул табышны, вә дошман булган кешеләрнең кулларын сездән тыйды, ягъни табыш малы алудан сезне туктата алмаслар. Аллаһ бу табыш малларын бирде, пәйгамбәрнең хаклыгына мөэминнәргә дәлил булсын өчен һәм сез мөселманнарны туры юлга күндермәк өчен" [48:18-20].* Үткән заманнарда табыш кешеләрне хәрәкәткә китерүче сәбәп булган. Бүген исә табыш бүлешү кыргыйлык булыр иде, гәрчә Коръәндә бу мәсьәләләр ныклап каралган булса да. Кешелек гасырлар буе сугышлар алып барган, сугышлар вакытында табышлар кулга төшергән, ләкин бу чорлар инде узган. "Табыш" сүрәсендә әйтелгән: *"Вә белегез сугышта ганимәт алган нәрсәгезнең биштән берсе Аллаһуга вә Аның рәсүленәдер, калган дүрт өлеше рәсүлгә якынлыгы булган кешеләргә, ятимнәргә, мескеннәргә вә мөсафирләргә бирелер, әгәр Аллаһуга һәм*

*бәдер сугышында хак белән батыл аерылган көндә индерелгән аятьләргә ышансагыз, ул көндә мөшрикләр гаскәре белән мөэминнәр гаскәре каршы юлыктылар" [8:41].* Табыш бүлешү бүгенге көндә дингез гизүче "диндар" юлбасарлар өчен генә актуаль булуы мөмкин.

Табыш темасын йомшартып та, ничек тә булса боргалап та булмый. Бу тема үткән заманда калырга тиеш. "Шәригать рөхсәт иткән бар нәрсә һәрвакыт файда китерә,—дип яза Йосыф әл-Кардави,—шәригать тыйган нәрсәләр исә һәрвакыт зыян китерә".[1] *Аятьләрнең* кайсы *өммәткә* җибәрелгәнен аермасак, коллыкны һәм табышны бүген дә файдалы нәрсәләр дип санарга туры килә, ә бу цивилизацияле җәмгыять нормаларына каршы килә.

Талау, кеше урлау һәм башка күренешләрне аклау өчен бернинди дә мөмкинлек калмаска тиеш, гәрчә боларны дин белгечләре *бидгать* дип исәпләсәләр дә. Ахыр чиктә, җәһәннәмгә, шәригать буенча "гадел" исәпләнгән табыш бүлешүне[2] аклаган өчен түгел, *бидгать* өчен керүең яхшырак. Чөнки андый мантыйкка иярсәң, теләсә нинди сәясәтне аклауга кадәр барып житәргә мөмкин. Әйтелгән: *"Динсезлек коткысына бирелү сугышта кеше үтерүгә караганда яманрак" [2:191].* Коръәнне гомуми контексттан чыгарып һәм кемгә әйтелгәнен исәпкә алмаган очракта мондый гыйбарәләрне теләсә ничек шәрехләргә мөмкин.

Мөхәммәт Пәйгамбәр заманында кешеләрне күпләп үтерү коралы булмаган. Ул заманда кяферләр белән көрәшкә өндәү башка мәгънәгә ия булган һәм башка ысулларны күздә тоткан. Бүгенге көндә мөселманнарга Мәккә чорында индерелгән, гомумтеләктәшлек дигән мәңгелек идеягә таянырга кирәк, чөнки игелеккә омтылучы кешелек—Аллаһ Тәгаләнең бер чагылышы ул.

Әлбәттә, Пәйгамбәрнең тормышы гыйбрәтле, X гасыр ислам илләренең тәҗрибәсе дә файдасыз түгел, ләкин бүген коллык та, баскынчылык та, табыш бүлешү хаҗәте дә юк. Шәригать буенча, кеше үтергән адәм бер колны азат итәргә тиешле. Әйтелгән: *"Бер мөэмин хаталык белән бер мөэминне үтерсә, кәсәфәте—мөэмин булган бер колны азат итүдер һәм үтерелгән мөэминнең варисләренә кан хакын түләүдер..." [4:92].* Шәригатьтә язылганны төгәл үтәү өчен янадан коллык кертергә кирәк түгелдер бит? Өстәвенә, Пәйгамбәр үзе үк колларны азат итүдә үрнәк күрсәткән һәм ул күңеленнән, коллыкка каршы булган, ул коллык институты белән карашы буенча түгел, мәҗбүрилек сәбәпле исәпләшкән. Пәйгамбәр заманында кәгазь акчалар, кеше әгъзаларын күчереп утырту, атом реакторлары булмаган һәм космоска да очмаганнар. Мөхәммәтнең, һичшиксез, клонлаштыру турында да, Берләшкән Милләтләр оешмасы эшчәнлеге турында да үз фикере булыр иде, чөнки заманалар нык үзгәрде.

X гасырда мөселман дин белгечлегендә *"иҗтиһад* капкалары ябылу" дип аталган күренеш барлыкка килгән. Тәнкыйди, аналитик фикерләү тыелган. Барлык кирәк нәрсәләр дин белгечләре тарафыннан тикшерелеп беткән инде дип саналган. Шул вакыттан бирле мөселманнар X-XIII гасырлар нормалары белән дүрт *мәзһәб* кысаларында яшиләр. Мәккә чорының уңайсыз *аятьләре* күрсәтмәләрен үтәмәс өчен, *нәсех* төшенчәсе кертелгән. *Мәзһәбләр*—Коръәннең һәм Сөннәтнең кешеләр тарафыннан шәрехләнүе нәтиҗәсе. Бу Ходайдан иңгән вәхи түгел, ләкин алар хәзергәчә сакланып килә.

*Мәзһәбләргә* нигез салучылар үзләре үк әһәмияте ягыннан шәригатьнең икенче чыганагы булган хәдисләрнең төгәл исәбе турында да төрле фикердә булганнар. Ибн Халдун сүзләренә караганда, имам Әбү Хәнифә бары тик унҗиде хәдис кенә кулланган, Мәлик исә өч йөз хәдис санап чыгарган, күренекле Әбү Абдуллах Мөхәммәт ибн Исмәгыйль әл-Бохари—хәдисләрнең иң мәшһүр җыентыгын төзегән кеше—хәдисләр санын җиде меңгә житкергән, ә имам Әхмәт ибн Ханбал 50 мең хәдис бар дип санаган. Ул заманда *иҗтиһад* хәтта шәригатьнең иң мөһим чыганагы булган Сөннәткә карата да кулланылган, ә бүген исә дин белгечләре аны икенчел дәрәҗәдәге мәсьәләләр белән чиклиләр.

> ***"Бәдәви гарәбләре, кяферлектә вә монафикълыкта тагы да куәтлерәкләр һәм алар Аллаһ үзенең рәсүленә иңдергән хөкемнәрне белмәскә бик лаеклыдыр, чөнки алар кырда яшиләр" [9:97].***

Аллаһ Тәгалә могҗизаларының берсе—һәркайсы үз телендә сөйләшә торган

---

[1] Юсуф аль-Кардави. Современный иджтихад... – С.60.
[2] Мәсәлән, Йосыф әл-Кардави, нефть сатудан килгән акчаларның бүленешен нигезләгәндә, үрнәк итеп табыш турында *аятьне* китерә. – Юсуф аль-Кардави. Современный иджтихад... – С.45.

күпсанлы халыклар. Әйтелгән: *"Җир вә күкләрнең төзелеше, вә телләрегез, вә төсләрегез төрлечә булуы Аллаһунын галәмәтләреннәндер, әлбәттә, Аллаһунын бу эшләрендә белем ияләре өчен дәлилләр бардыр"* [30:22]. Аллаһ Тәгалә, теләсә, барлык кешеләрне дә гарәп телендә сөйләшүче бер халык итеп яратыр иде. Ләкин Ул алай эшләмәгән. Һәрбер халыкның үз тормышы бар. Ходай өчен башкалар арасыннан сайлап алынган коткаручы (мессия) халык яисә, киресенчә, мөртәт халык юк. Яһүдләр һәм гарәпләр Аллаһтан вәхи индерелгән күп халыкларның кайберләре генә.

*Аллаһ Тәгалә теләсә нинди телне аңлый. Адәм баласы Ходай белән үз җанына якын ана телендә сөйләшергә тиеш. Күңел түрендәге уй-теләкләренне чит телдә аңлатып бирү мөмкин хәлмени?! Аллаһ Тәгаләгә тылмач кирәкми, ул бер генә халыкка да, бер генә телгә дә өстенлек бирми. "Ул—Аллаһ, күкрәк эчендәге нәрсәләрне белүчедер" [42:24].*

> ***"Әгәр Раббың теләсә иде, бөтен кешеләрне бер генә диндә кылыр иде" [11:118].***

*Бер генә халык та мәңгелек түгел. "Һәрбер өммәтнең билгеләнгән әҗәле бар, әгәр аларга әҗәлләре килсә, бер сәгать иртә килмәс һәм бер сәгатькә кичекмәс" [7:34].* Гарәпләр кайчандыр иң алдынгы халыкларның берсе булганнар, әмма алар заманы узган. Кайчандыр татарлар да бөтен Евразия белән идарә иткәннәр дә бит...

Мөселман цивилизациясе аерым халыкларны үз эченә йотмый, гамәлдән чыгармый. Татарлар, язмыш ихтыяры белән, исламның православие белән чолгап алынган төньяк терәге булып чыкканнар. Россиядә мөселманнарның үз традицияләре барлыкка килгән.

Россиядә ислам һәрвакыт икенче урындагы дин булган. Ләкин соңгы елларда протестантлык оешмалары мөселман оешмаларын сан буенча узып китте. Алар ыргылып үсеп киттеләр. Татар яшьләре дә, урыс яшьләре дә яна дингә тартылдылар. Руслар тумыштан ук православие динендә, татарлар—мөселманнар дигән тотрыклы стереотип күз алдында юкка чыкты. Бу күренешне аңлату авыр түгел. Протестантлар чиркәү-славян телендә яки урта гасыр гарәп телендә сөйләшми, алар кешегә балачактан якын ана телендә аралашалар. Протестантлар Тәүратне (Библия) заманча аңлаталар, ул борынгы һәм иске китап булып тоелмый. Алар кешеләргә тормышларындагы конкрет мәсьәләләрне хәл итәргә булышалар.

Сәид Мөхәммәт Нәкыйб әл-Әттас мөселман теле дигән төшенчәне керткән, аның фикеренчә, бу—"ислам динен тотучы халыкларның телләренә мөселман терминологиясенең төп сүзлеген кертү. Шул рәвешле, һәрбер мөселман халкының теле, барлык мөселманнар өчен дә үз булган сүзләрнең төркеме аша, башка мөселман халыкларының телләренә бәйләнгән булып чыга. Менә шул сәбәпле, мөселман халыкларының барысының да телләрен, нигездә, мөселман телләре дигән бер төркемгә кертеп булыр иде".[1] Чынлап та, татар теле мөселман терминологиясен шактый тулы чагылдыручы гарәп сүзләре белән тулган һәм бу хәл дин тотучыларның кин даирәсенә гарәп телен белүне артык нәрсәгә әверелдерә. Бу нисбәттән, Көнбатыш традицияләренә таянучы урыс теле, шундый ук мөмкинлекләргә ия түгел. Сәид Мөхәммәт Нәкыйб әл- Әттас тезисы—исламга лингвистика ягыннан национализация ясау файдасына бик җитди дәлил. XXI гасырда бу котылгысыз була бара.

> ***"Аллаһ ризалыгын өстәп көндезләрен вә кичләрен Раббыларына гыйбадәт кылган зәгыйфь яки фәкыйрь мөэминнәрне янынан кума! Ул кяферләрнең гамәлләреннән һичнәрсәне хисап итмәк синә тиеш түгел һәм синең гамәлеңнән һичнәрсәне хисап итмәк аларга тиеш түгел. Дошманнар сүзенә карап фәкыйрьләрне янынан кума! Әгәр кусаң, залимнәрдән булырсың" [6:52].***

Хакыйкатькә берәү дә дәгъва кыла алмый, хакыйкатькә бары тик Аллаһ Тәгаләнең генә хокукы бар. *"Әйт: "Хак юлга фәкать Аллаһу Тәгалә үзе генә күндерә!" [10:35].* Без үз фикерләребезне бары тик әйтә генә алабыз. Ихтимал, минем фикерләр исламны мөстәкыйль рәвештә аңларга тырышучылар, үз юлын эзләүчеләр арасында яңгыраш табар—без бит бер буын, бер дин һәм бер заман—Россия өчен югалган гасыр кешеләре.

---

[1] Сейд Мухаммад Накыб аль-Аттас. Введение в метафизику ислама – изложение основополагающих

Минем өчен тәрҗемәнең яки аерым *аятьләрне* шәрехләүнең нечкәлегенә төшенү, Аллаһ Тәгалә сыйфатларының санын, теге яки бу гарәп терминнарының дөрес әйтелешен белүне ачыклау зарурлыгы юк—бу эшләр барысы да дин белгечләре һәм имамнар карамагында калсын. Минем мәхәлләм дә, мәчетем дә юк, мин вәгазьче дә түгелмен. Миңа үз тарафдарларымның санын арттыру кирәкми, мине *сәдака* да кызыксындырмый. Миңа исламның теләсә нинди телдә дә бер төрле шәрехләнә торган төп принципларын белергә кирәк: ир-ат һәм хатын-кыз—тигезме, түгелме; бүгенге көндә имамнарның вазифалары нинди; кешелек *өммәтме*, яки бергәлек мөселманнар арасында һәм саф ислам илләрендә генә була аламы? Һәм, мөгаен, иң мөһиме: ислам минем халкыма алдынгы милләт булырга ничек ярдәм итә ала? Чөнки бүген халыкны нииндидер мөселман резервациясендәге экзотик этнос сыйфатында саклап калу бурычы тормый, максат башка—конкурентлыкка сәләтле булу. Ислам прогресс юлын күрсәтергә тиеш. Минем өчен ислам һәм прогресс сүзләре—синонимнар. Әмма моңа җавап итеп мин укыйм: "Аларның иң куркынычлары—прогресс тарафдарлары".[1]

Татар яшьләре замана университетларына омтыла, кайберләре, чит телләрдән инглиз теленә өстенлек биреп, Европа уку йортларына юнәлә. Инглиз теле эшкуарлыкта, сәясәттә, фәндә ярдәм итә, инглиз теле аша без иң яңа идеяләрне, заманча технологияләрне, соңгы ачышларны белә алабыз. Шәһәр (авыл) татарлары арасында балалары гарәп телен белергә теләүчеләр 13% (25%), төрек телен—10% (19%), Көнчыгыш Европа телләрен—74% (33%). Татар яшьләре арасында Көнчыгыш Европа телләрен өйрәнергә теләүчеләр саны ата-аналары арасындагыдан күбрәк. Тенденция шундый:гарәп теле ритуаль яки саф һөнәри тел булып кала, ә чит телләр арасында "киң массалар" теле булып инглиз теле санала башлады. Бу—заман таләбе, чөнки гарәп теле безнең җәмгыятькә артта калганлык төсмере кертә, ә Көнчыгыш Европа телләре исә безгә алгы сызыкка чыгарга мөмкинлек бирә. Әгәр дә без Европадан өйрәнмәсәк, "КамАЗ" "Вольво"га һәм "Мерседес"ка оттырачак, Казан вертолетлары "Еврокоптер"ныкыннан начаррак булачак, безнең пассажир самолетлары "Боинг"ка конкуренция ясый алмаячаклар. Имамнар республиканың икътисады һәм культурасын үстерүгә катнашырга тиешләр! Алар биш вакыт намаз турында гына искә төшерергә түгел, безнең тормышны яхшырта торган икътисадый һәм социаль проектлар тәкъдим итәргә, мөселман дөньясындагы базарларны яулап алуга ярдәм итәргә тиешләр. Россия ислам университетлары, дин белгечлегеннән тыш, үз алдына яңа икътисадый теорияләргә өйрәтүне иң мөһим бурыч итеп куярга, Татарстанның югары технологияле төбәк буларак үсешендә үз юлларын табарга тиеш. Әбү Хәнифә әйткән: "Үз белемегезне гамәлдә кулланыгыз, чөнки гамәлсез белем—җансыз гәүдә".

Муса Бигиев "Ходай рәхмәтенең абсолютлыгы" ("Рәхмәт Илаһия Борһанлары") теориясенең нигезләрен чыгара башлагач, дуслары аңа бераз гына дипломат булырга, имамнарның ачуын китермәскә киңәш итәләр. "Син берниндй файдасыз проблеманы вакытсыз һәм урынсыз күтәрдең һәм давыл кузгаттың",—диләр аңа. Муса Бигиев исә: "Мин, әлбәттә, дусларыма үгет-нәсихәтләре өчен рәхмәтлемен. Ләкин үземнең фәнни эзләнүләремдә мин, имеш-мимешләрдән куркып, яки үземнен ашар икмәгем хакына үз абруемны корбан итә алмыйм. Әгәр дә берәр хакыйкать бөтен дәлилләре белән минем йөрәктә тамыр җәя икән, кешеләр кабул итә алмас дип, мин аны яшереп кала алмыйм",—дип җавап биргән.

Кешегә хөкем кылмагыз һәм хурламагыз!

> ***"И-и, мөшрикләр, кояш чыга торган якка һәм кояш бата торган якка юнәлеп табынуларыгыз Аллаһу хозурында изгелек түгел. Ләкин берәү Аллаһуга, ахирәт көненә, фәрештәләргә, китапларга һәм пәйгамбәрләргә иман китереп, үзенә кадерле малыннан мохтаҗ булган якын кардәшләренә, ятимнәргә, мескеннәргә, мөсафирләргә, мохтаҗлыктан ярдәм сораучыларга һәм колларны азат итү юлына садакалар бирсә, шулай ук зәкәт, гошер садакаларын бирсә, намазларын вакытында үтәсә, янә Аллаһуга биргән гаһеден, кешеләргә биргән вәгъдәсен үтәсә, янә ярлы вакытта нинди дә булса бәла-каза ирешкәндә, ачлык яки сугыш килгәндә сабыр итсә, Аллаһуга чыдамлылык күрсәтсә, әнә шул эшләр изгелекләр" [2:177].***

Мәккәдә чагында Мөхәммәт Пәйгамбәр Кәгъбәгә карап дога кылган, Мәдинәгә

[1] Юсуф аль-Кардави. Современный иджтихад... — С. 67.

качканнан соң, ул догаларны Иерусалим ягына борылып укыган. Мона яһүдләр бик шатланганнар. Ләкин унжиде айдан соң ул янадан Кәгъбә тарафына борылган. Күпләр аның болай икеләнүен өнәмәгән: мөселманнарның *кыйбласы* кайда соң? Шул вакытта яна *аять* барлыкка килгән.

**"Кояш чыгыш тарафы да, кояш батыш тарафы да Аллаһу Тәгаләнекедер. Аллаһ, үзе теләгән бәндәсен туры юлга күндерер" [2:142].**

Дога кылганда кая таба юнәлеп басуны билгеләү Ходай ихтыярында. Мөселманнар шуннан бирле Кәгъбәгә карап дога кылалар. Ихтимал, бу мөселманнарны яһүдләрдән һәм христианнардан аеру өчен индерелгәндер, әйтелгән бит: *"Һәр милләтнең үз кыйбласы бар, һәрберсе үз кыйбласына юнәлер" [2:148]*. Ходай Тәгалә һәрбер халыкка үз *кыйбласын* билгеләгән, ләкин ул үзе үк аларны берләштерәчәк һәм ходай рәхмәте барысына да житәчәк.

Татар телендә *кыйбла* төшенчәсе дога кылу ягы гына түгел, аның мәгънәсе тирәнрәк. Тормыш принципларын нинди? Синен өчен нәрсә изге? Иманың бармы? *Кыйбла* сүзенең асылы менә шунда. Һәр телдә сүзләрнең үз мәгънәләре бар, аларда милли тарих туплана...

Вакытлар уза һәм дөнья бик тиз үзгәрә. Вакыйгаларның хәзерге өермәсендә күпләр үз *кыйбласын* югалтты. Алар Мәккәнең кайда икәнен оныттылар. Дөресен генә әйткәндә, бүген Мәккә безнең өчен Кәгъбә ташы урнашкан җирдән гайре нәрсәне аңлата? Тарихи вакыйгаларнымы? Өметләрнеме? Яки аңлатып булмый торган тагын берәр нәрсәме?

Чын *кыйбла* билгеле бер урыны булмаган Ходайга мөрәҗәгать итү дигәнне аңлата. Ходай Мәккәдә дә, Иерусалимда да түгел, аның тирәлектә дә, вакытта да үлчәмнәре юк. Ул—бөтен җирдә һәм бар нәрсәдән хәбәрдар...

***"Әгәр Аллаһ теләгән булса иде, әлбәттә, барчагызны бер диндә кылыр иде, ләкин Аллаһ теләгән кешеләрен адаштыра вә теләгән кешеләрен туры юлга сала, кылган эшләрегездән, әлбәттә соралырсыз, сакланып эш кылыгыз!" [16:93].***

Социологик тикшеренүләр буенча, татар яшьләренең 80% тан артыгы үзен мөселман дип саный, ләкин аларның бары тик 1%ы атнага бер, 4% ы айга бер тапкыр мәчеткә йөри. Татарстанда ачыктан-ачык атеистлар 1%тан азрак, ләкин барлык дини йолаларны үтәүчеләр дә аз. Дин нигезләре *(ислам һәм православие)* буенча дәресләргә дә бик аз кеше *(1-3 %)* йөри.[1] Әлеге яна күренешләрне постсовет феноменына, атеистик пропаганда тәэсиренә сылтап куярга мөмкин булыр иде. Тик бу исламның бөтен планетага хас шушы гомуми проблемаларын аңлатып бирерме соң? Аңлата алмас, мөгаен. Чөнки дөнья һәм аның белән бергә кешеләрнең ихтыяҗы һәм яшәү рәвеше үзгәрде. Иҗтимагый кыйммәтләр һәм мәсләкләр үзгәрде. Без барыбыз да үзгәрдек.

Татарлар мөселманның күзгә күренеп торучы тышкы билгеләрен хәзер элеккечә югары бәяләми. Ислам культураның бер өлешенә әверелгәндер, мөгаен. Әлбәттә, ураза тотмаган, биш вакыт намаз укымаган кешеләрне динсез дип атап буладыр. Әмма ул кешеләр үзләре өчен бу мәсьәләне башкача хал итәләр. Аларның *кыйблалары* бар. Ихтимал, алар Коръәнне һәм ислам традицияләрен начар беләләрдер. Бәлки дин алар өчен этник яктан үзбилгеләнү факторы гынадыр. Бәлки... Ләкин аларның җавап биргәндә сайлау мөмкинлеге булган һәм алар исламны сайлап алганнар. Әбү Хәнифә әйткән:"Без аларны сүзләренә, нәрсәне таный, нәрсәне кире кагуларын күрсәтеп торучы фактларга, дини нормаларга һәм йолаларга карап кына диниләр яки кяферләр дип кабул итәргә тиеш түгел. Әгәр дә без мәчетләргә йөри торган, безнең кыйблага карап, безнең кебек дога кыла торган кешеләрне очратсак, алар турында башка берни белмәсәк тә, без аларны диндар кешеләр дип санарбыз... Шуна күрә без, күз алдындагы фактларга карап кына кешеләрне диндар дип кабул итәргә тиеш дип саныйбыз. Гәрчә Аллаһ өчен алар бәлки кяферләрдер дә. Башкаларны без, аларда динлелек билгеләре күрмәү сәбәпле, кяферләр дип санарбыз. Ә Аллаһ Тәгалә өчен бәлки алар динле кешеләрдер..."[2] Моннан да яхшырак әйтеп булмыйдыр, мөгаен.

Ходай өчен ни мөһимрәк—дини йолаларны, гореф-гадәтләрне үтәвенме яки

---

[1] *Мусина Р.Н.* Этноконфессиональные процессы в Республике Татарстан. – В кн.: Ислам и христианство в диалоге культур на рубеже тысячелетий. – Казань, 2001. – С. 261-264.

эчке иманыңмы? Тышкы билгеләрме яки инанунын үз формуласын эзләүме? Әлеге сорау риторик булып тоела, әмма ни өчен ислам турында күбрәк йолаларга карап фикер йөртәләр һәм ни өчен исламның асылы кайчак йолаларга гына кайтарып калдырыла?

Йолалар мөһим социаль вазифа үтәгәннәр, аеруча урта гасырлар Гарәбстаны шартларында. Алар ярымкыргый кабиләләрне цивилизацияле тормышка күнектергәннәр. Гарәпләрне мәҗүсилектән чыгарыр өчен кагыйдәләр һәм нормалар кирәк булган, чөнки, мәсәлән, алар кыз бала тууны хурлыкка санап, аларны терелэй җиргә күмә торган булганнар. "Дәхи Аллаһуның кызлары бар, дип, ифтира кылалар, мондый кимчелектән Аллаһуны пакъ дип белегез! Алар фикеренчә: үзләре сөйгән ир балалар аларга була да, әмма алар сөймәгән кыз балалар Аллаһуга була, имеш. Әгәр ул мөшрикләрнең берсенә "кыз балаң туган", дип, сөенеч бирелсә, хатынына ачуланып, дусларыннан оялып йөзе каралып китәдер. Кыз белән сөенеч бирелгәнлектән хурланып кауменнән качадыр, уйлап торадыр: бу кызны хурланып кына асрыйммы икән? Яки терелэтә туфракка күмеп таптыйммы икән, дип. Әгаһ булсыннар, кылган эшләре нинди яман кабахәт эштер!" [16:57]. Бүген бик күп нәрсә эчке культура элементына әверелде һәм кешеләр җәмгыять күзәтчелегенә мохтаж түгелләр.

Кеше сурәте ясауны тыю ислам үсешенең билгеле бер чорына бәйле, ул вакытта балбалларга, потларга каршы көрәшергә кирәк булган. Ләкин бүген без кыргыйлар түгел, Әфганстан талиблары кебек, Будда сынын туптан атып ваттыру зарурлыгы юк.

Кыргыйлык һәм ислам үзара сыеша алмый.

Бүген рәсем сәнгате, сынлы сәнгать образлары—югары мәдәнилек, кеше рухында югары нормалар ныгуы һәм намуслылык билгесе. Ислам намуслылыкка өндәмимени?! Кешеләр һәм хайваннар рәсемнәрен ясауны Аллаһ Тәгалә иҗатына тинләштерү дип атап, аны тыю архаизм булып күренә. Инде чыннан да мондый дәлилдән чыгып фикер йөртсәк, хайваннарның һәм үсемлекләрнең яңа төрләрен, клонлаштыруны, генетиканы, һәм, гомумән, фәнне дә, теләсә нинди иҗатны да Аллаһ Тәгаләгә тинләшергә тырышу дип санарга кирәк. Бу исә чып-чын мәгънәсезлек.

Ислам кешеләрне кыргыйлыктан чыгарыр өчен индерелгән. Тәкъвалык кешеләрнең цивилизацияле, культуралы, белемле булуыннан гыйбарәт . Йолалар кешеләрне даими рәвештә төп кануннарга кайтаралар, аларны хакыйкать эзләүгә юнәлтәләр. Аларның вазыйфасы шул. Ә хакыйкать үзе прогресстан, ягъни фәннәр, технологияләр, техника үсешеннән, белемне күтәрүдән, гадел җәмгыять һәм уңышлы икътисад булдырудан, әхлакый югарылыктан гыйбарәт.

*Тыюларның һәм йолаларның кайберләре XXI гасырда үз мәгънәләрен югалттылар. Мөселман күрсәтмәләре буенча терлекне кулдан сую тикмәгә генә түгел, кешеләр сыйфатлы ит ашасыннар өчен уйлап табылган. Бу Ходайга түгел, үзенә кирәк. Кеше әлеге йола ярдәмендә Аллага хезмәт итми, үзенә игелек эшли. Әгәр дә безнең заманда терлек конвейер ярдәмендә сыйфатлы итеп суела икән, кеше дә оттырмый, димәк, Аллаһ Тәгалә дә канәгать кала. Коръән йолаларның физик формасына карап түгел, рухи мәгънәсе аркасында кыйммәткә ия. Әйтелгән: "Чалган дөяләрегезнең итләре вә каннары Аллаһуга ирешмәс, ләкин сездән Аллаһуга тәкъвалык вә изге гамәлләр ирешер..." [22:37].*

Дини йолалар кеше тормышын катлауландыру өчен түгел, җиңеләйтер өчен бирелгән, ләбаса. Ислам—кысан аяк киеме түгел. Ул—кешеләрнең сәләтләрен ачып бирү ысулы. Коръән буенча, Пәйгамбәр *"аларда булган авырлыкны вә диннәрендәге каты хөкемнәрне алардан бетерер" [7:157]* өчен җибәрелгән.

Бүген нидер тыюдан бигрәк, унай ниятләр мөһимрәк. Кеше күп очракта куркудан да яки бүләк өчен дә түгел, ә рухи нияттән чыгып, яшәүнең иң яхшы рәвешен сайларга тырыша. Мин, цивилизацияле дөнья кешесе, Әфганстан кабиләләре дәрәҗәсенә төшеп, аларга тигезләшә алмыйм бит инде. Бәлки анда йолалар фән һәм белемгә карата мөһимрәктер. Татарлар кыз балаларын җиргә күммиләр, таш сыннарга, ошатмаган очракта да, туптан атмыйлар. Талиблар—кыргый, һәм шуна күрә тәкъва түгел.

Артта калганлык һәм тәкъвалык үзара сыеша алмый, алар капма-каршы нәрсәләр. Урта гасыр шәригате буенча яшәүче Судан халкы минем белемле, мәгариф һәм фәнни тикшеренүләр системасы үсешендә үз традицияләрен булдырган халкымнан тәкъварак дигән фикер белән килешү мөмкин түгел. Ислам кешеләрне кыргыйлыктан чыгарып, аларны үстерү, гаделлек юлына бастыру максатында барлыкка килгән.

Тәкъвалыкка беренче адым—белем алу, ә догалар һәм йолалар белемнен әһәмиятен анларга ярдәм генә итәләр. Котылу чарасы йолаларда түгел, прогресста. Муса Бигиев "Инсаннарның гакыйда Илаһияларына бер назар" дигән хезмәтендә болай дип язган: "Дин мәсьәләсендә рәсмилек юк. Дин ниндидер формаль тышчага төренсә, кешелек яшәеше өчен мәгънәсен югалта. Кешене явызлыктан һәм бозыклыктан читләштерүче, аны игелекле эшләргә этәрүче—шәригать олылаган дин шул була. Шәригать күзлегеннән чыгып карасаң, кеше яшәеше өчен әһәмияте булган дин яхшы. Әгәр дә диннен кеше тормышына йогынтысы юк икән, андый дин, андый шәригать файдасыз". Хакыйкать ул—йолаларны үтәп, *хиҗабка* төренеп, сакал үстереп җәннәттә үзенә урын тәэмин итү түгел. Ул матди *дөньяның* каршылыгын җинүдә, җәмгыятьне рациональ коруда, кешеләрнең тормышын яхшыртуда, гомумкешелек акылының бер өлешенә әверелүче унай тәҗрибә туплаудан гыйбарәт.

Матди *дөньяга* каршы, дөньяны рухилаштыру өчен көрәш кешене коткару предметын билгели дә инде. Әгәр дә бу эштә йолаларның файдасы бар икән, алар булсыннар, әмма җәмгыятьнең культура дәрәҗәсе югары һәм кешеләр фән һәм белемнең Ходай Тәгаләгә якынаюда әһәмиятен анлыйлар икән—йолаларның мәгънәсе икенче планга күчә, алар кешенен шәхси эше, өстенлекләрне шәхсән билгеләү мәсьәләсенә кайтып кала. Әгәр дә ниндидер сәбәпләр аркасында йолаларны үтәү катлаулы икән, бу очракта аларның максатка ярашлыгына һәм игелекле гамәлләргә юнәлеш тоту мөгъкуль. Пәйгамбәр әйткән:" Чынлап ки, дин ул—җиңеллек, диндә чама белми тырышкан кеше оттырачак. Тураегыз, һәм якын килегез, һәм шатланыгыз",—дигән.

Ходай кеше үти алмый торганны таләп итми. Ул рәхимле һәм кешегә үтәргә кыен булган нәрсәләр йөкләми. Мөмкинлекләр чигеннән чыгып нәрсәләр йөкләү—тиранлык. Коръәндә язылганнар барысы да кешенен көченнән килерлек, җиңел һәм файдалы нәрсәләр. Пәйгамбәр әйткән: "Җиңеләйтегез, катлауландырмагыз, куандырыгыз, күңел кайтармагыз".

Аллаһ Тәгаләгә безнен сукырларча табынуыбыз һәм йолаларны чамадан тыш тырышып үтәвебез кирәк түгел. Пәйгамбәр әйткән: "Аллаһу динлелекне күрсәтүдә чамадан тыш табынуны һәм ахыр чиккә җитүне яратмый". Ул монахларча яшәүне хупламаган, йолаларны үтәүдә адәм баласы булдыра алганнан артыгын таләп итмәгән, гыйбадәт кылу бәрабәренә дөнья рәхәтлекләреннән баш тартучыларны өнәмәгән. "Мәгарәләр, тау башлары һәм чүлләр шикелле ерак һәм кешесез җирләрдә яшәмәгез. Андый җирләрдә яшәү кабердә яту белән бер",—дигән ул. Синен шәхсән котылуың ул—җәмгыятьне хәрби, сәяси, экологик, рухи һәлакәттән коткару дигән сүз.

Мөхәммәт Пәйгамбәр йолаларга зур игътибар биргән, ләкин шул ук вакытта шактый сизгер дә булган. Ул: "Кирәкле белем алуга киткән бер сәгать Аллаһ өчен дога кылып үткәргән бер көнгә караганда яраклырак",—дигән. Ә бит дога кылу исламның беренчел нигезләренен берсе булып санала. Димәк, чын мөселман өчен белемнән дә өстен нәрсә юк. Өстәвенә, Коръәнне белү генә түгел, гомумән, төрле фәннәрне белү күздә тотыла. Пәйгамбәр әйткән: "Бишектән алып кабергә кадәр гыйлем эстәгез. Кытайга кадәр барып булса да белем алыгыз. Бу дөньяда рәхәт күрергә теләгән кеше сәүдә итсен, теге дөньяда рәхәт күрергә теләгән кеше сабырлык һәм тәкъвалык эзләсен, ә ике дөнья рәхәтен күрергә теләгән кеше—аны белем алуда һәм гыйлемдә эзләсен".

Суны баскан килеш эчәргәме яки утырган килеш эчү дөресрәкме[1] дип бәхәсләшүгә бик күп вакыт сарыф итәргә, бу турыда диссертацияләр, китаплар язарга, конференцияләр үткәрергә мөмкин. Нәтиҗәдә кайсы якның хаклы икәнен дә исбат итәргә була, ләкин моның исламга нинди мөнәсәбәте бар соң? Пәйгамбәр чыннан да су эчкән, бары шул гына.

Хикмәт Пәйгамбәрнең киенү рәвешендә, йолаларны нинди вакытта һәм ничек үтәгәнендә түгел. Хикмәт—аның боларны ни өчен эшләгәнлегендә. Йолалар, зәкәт, мирас хокукы һәм шәригатьнең башка нормалары җәмгыять тизрәк алга китсен өчен кирәк булган. Иң мөһиме шушы. Хикмәт мирасның күпме өлеше ир балага, күпме өлеше кыз балага тиешлегендә түгел, ә мирасны тапшыруның тотрыклы һәм гадел булырга тиешлегендә. Үткән заманда гадел булган нәрсә бүген дә һәр очракта

[1] Суны баскан килеш эчү файдасына дәлилләрне карау өчен: *Юсуф аль-Карлави.* Исламское … – Казань, 2002. – С. 47.

гадел була алмый. Безнең заманда кыз балаларны ир балалардан ким күрер өчен сәбәпләр юк, алга киткән җәмгыятьтә хезмәтне җенес билгеләренә карап бүлмиләр.

Исламда нормалар үзгәрә, ә төп максат—гаделлек сакланып кала. Бөек дин белгече Әбу Хәмит әл-Газали болай дигән:" Бер сәгать гаделлек йөз ел дога кылуга тин".[1] Коръән "үзегезгә каршы юнәлгән булса да" гаделлекне сакларга өнди.

*Зәкәт*—үз табышыңның бер өлешен җәмгыятькә бирү белән түгел, ярлыларның кимүенә, бурычларның түләнүенә, җәмгыятьтә тулаем муллык артуга,[2] байлыкка мөкиббәнлекнең, нәфеснең, саранлыкның, акча җыючылыкның кимүенә ярдәм итү белән Ходайга яраклы гамәл. Болар барысы да җәмгыятьне гаделрәк, димәк, яшәүгә сәләтлерәк итә.

*Зәкәтне* колларны азат итүгә тоту нәрсәне аңлата? Моның бернинди дә мәгънәсе юк, чөнки хәзер коллар юк. Ләкин исламның төп мәгънәсе үзгәрми—җәмгыятьне тотрыклырак, кешеләр тормышын мулрак итү. Пәйгамбәр: "Һәр игелекле гамәл—сәдака ул",—дигән. Менә кайда исламның асылы! *Зәкәт*—игелекле гамәл, ә теләсә нинди игелекле гамәл—ислам ул.

Тәкъвалыкның мәгънәсе хәер бирүдә түгел, ә ярлылыкны бетерүдә. Ярлылыкка каршы көрәшүнең башка ысуллары юк икән, димәк, бу очракта хәер бирергә генә кала. Әгәр дә байлыгың башка кешеләрне дә баета икән, бу—игелекле эш, аның максаты *зәкәт* бирү максаты белән бер үк! Игелекле эш—сәдакага тиң. Кеше игелек кылган саен Аллаһ Тәгаләне искә төшерә.

> ***"Сезне ахирәт өчен кирәк гамәлләрдән гафил кылды, алдады, мәхрүм итте, дөнья малын күбәйтү белән мактанышуларыгыз. Хәтта үлеп кабергә кергәнегезгә хәтле, алдануыгызны дәвам иттердегез. Юк, алданмагыз, әле дөньяга ышанып тыныч кына яшәсәгез дә, тиздән белерсез алданганыгызны! [102:1-8].***

Ислам өйрәткәнчә, байлык үзмаксат була алмый. Пәйгамбәр әйткән:"Әгәр дә кешенең алтын сибелгән бер үзәне булса, ул аның икәү булуын теләячәк, икәү булса—өченчесен... Аны ахыр чиктә бер уч туфрак кына тынычландырачак"; "Якыннары ач калган вакытта туйганчы ашый алган кеше динле түгел". Җәмгыять мәнфәгатьләре белән яшәү—хакыйкать юлы. Ходай бурычлар җыелу, чамадан тыш шәхси байлык һәм ярлылар арту аркасында җимерелүне булдырмый торган икътисадый система төзергә өндәгән. Шуңа күрә ул рибачылыкны кире каккан: *"Янә Аллаһ тарафыннан каты тыелган булсалар да, риба, ришвәт алулары һәм кеше малын юлсыз ашаулары сәбәпле хәләл нәрсәләрне аларга хәрам кылдык, һәм яһүдләрнең кафер булганнарына рәнжеткүче газабны әзерләдек" [4:161].* "Алтын бозау"га табыну теләсә нинди рәвештә—мал-мөлкәт, көчемле яки көчемсез милек җыюмы; банкларда акчаны хәрәкәтсез яткыра торган счетлар ачумы; тормышында артык муллык булдыруы—барысы да мәҗүсилек. "Безнең хәзерге тормышка һәм үзебезнең таш балбалларга ***(йортлар)***, тимер потларга ***(машиналар)***, кәгазь аллачыкларга ***(дипломнар, сертификатлар)*** киткән вакыт, мәхәббәт һәм энергия күләменә карагач,—дип яза Фәрит Исак,—мин җәберлек караңгылыгыннан Муса тарафыннан ирек яктысына чыгарылган израильлеләрнең акылсызлыгына гаҗәпләнмим. Алар белән безнең арада аерымлык шунда гына ки, "Алтын бозау" культына нигез салган Самири берьялгызы һәм беркатлы эш итсә, капитализм һәм табыш җыю идолларын бүген бөтен бер сыйныфлар ясый, аларның бар тормышы теге яки бу рәвештә табыш алу тирәсендә бөтерелә".[3] Капиталистлар гына түгел, хәтта руханилар да кайвакыт матди якны рухи яктан ныграк кайгырта. Алар ярлы түгел. Аларны дәрвишләр дип атап булмый. Нәфесне, матди *дөньяны* җиңү, аңа рухият өстәү байлыктан шәхси тормышың өчен түгел, кешеләргә хезмәт итүдә файдалануны күздә тота.

Дини тәгълимат китапларын укыганда, өстенә хәзерге заманга берничек тә бәйле булмаган терминнар, чамадан узган схоластика ишелеп төшә. Мәхмүт Топташның "Аллага ышану һәм аның алты нигезе" дигән китабында фәрештәләргә ышануга, аларның көчләренә, үзенчәлекләренә, бурычларына анализ ясала, фәрештәләр төркемнәргә бүленә.[4] Дин галимнәре компьютерлар һәм телефоннар кулланмый,

---

[1] Суфии. Собрание притч и афоризмов. – М., 2002. – С.45.
[2] Закят. – Казань, 2001. – С.67.
[3] *Фарид Исак.* Быть мусульманином... – С.184.
[4] *Махмуд Топташ.* Вера в Аллаха и шесть ее основ. – Стамбул, 2000. – С.69-81.

бервакытта да самолетларда очмый икән дигән тәэсир кала. Алар бу әйберләрнең кем тарафыннан ясалуы һәм бу өлкәдә ислам илләренең Европа илләре белән конкурентлыкка ничек чыга алулары турында уйланмыйлар. Аларның һәммә сорауга да җаваплары бер—дога укырга кирәк. Самолетлар дога уку аркасында оча диярсең! *Фикъһа* аэродинамиканы алыштыра алмый лабаса. Бер *хәдис* турында тау-тау китаплар язалар, ә хәзерге университетларның нинди булырга тиешлеге, мөселманнарга алга китәр өчен нинди фәнни юнәлешләрне үстерергә кирәклеге турында ләм-мим. Дин белгечләре чалбар балагының озынлыгы темасын җентекләп тикшерә алалар, ә заманча технологияләр турында бер сүз дә әйтмиләр. Катлаулы сорауларның барысына да җаваплары бер: "Ислам—уй-фикерне дөресләүче иман, йөрәкне пакъландыручы гыйбадәт, җанны сафландыручы әхлак, гаделлекне раслаучы законнар чыгару, тормышны бизәүче традицияләр һәм культура".[1] Алайса ни өчен дөньяда иң артта калган илләр—чын мөселман илләре? Самолетларны кем ясарга тиеш? Христианнармы?

Ислам күп гасырлар буе бик зур территориядә хакимлек иткән, әмма хәлифәтләр эчке низаглар аркасында җимерелгәннәр. Шуңа да карамастан, дин белгечләре моның сәбәпләрен хәзергәчә тыштан эзлиләр: башка илләрдәге дошман көчләрне—сионистларны, бөтендөнья христианлыгын һәм капитализмны гаеплиләр.[2] Әлеге күренеш хәтта гаҗәп кенә дә түгел. Бу—исламның кешеләргә ни өчен җибәрелгәнен аңламау, исламның гамәли ягын белмәү. Аллаһ Даутка *"байлык һәм пәйгамбәрлек бирде һәм аңа үзе теләгән нәрсәләрне өйрәтте" [2:251]*, ягъни Ул аңа файдалы белем биргән. Әгәр дөньяви законнар тормышны яхшырак, гаделрәк итәләр, икътисадны көчәйтәләр, ярлылыкны киметәләр икән, димәк, алар Ходайга яраклы.

Мәгариф системасын үзгәрткән күренекле татар реформаторы Габдулла Буби болай дип язган: "Безнең бурыч бер үк вакытта ике юлдан: рухи һәм матди юнәлешләрдә бару, дини нәрсәләрне дә, дөньяви нәрсәләрне дә берьюлы алга этәрү". Дөньяви нәрсәләр исламга чит түгел. Һәм дә Пәйгамбәр тормышына бәйле һәрнәрсәне дә дини дип санарга ярамый. Ул, мәсәлән: "Тешләрегезне чистартыгыз",—дигән. Бүген теләсә кайсы табиб кына түгел, хәтта реклама да шул кинәшне тукый. Балалар, сөйләшергә өйрәнгәнче, тешләрен чистарта башлыйлар. Пәйгамбәр бик күп гамәли киңәшләр биргән һәм аларның күбесе мөселман булу-булмауга карамастан, хәзерге заман кешесе өчен нормага әйләнгән. Менә охшашлы нормаларда, әйтик, чалбар балагы озынлыгында, суны басып яки утырып эчүдә, сакал үстерүдә яки үстермәүдә, *хиҗаб* киюдә һәм башкаларда бернинди дини тәсмер дә юк, болар—саф дөньяви нормалар. Ислам, культура буларак, дини нәрсәләрне дә, дөньяви нәрсәләрне дә үз эченә ала. Ислам дөньявилыкка каршы тормый, аны кысрыкламый, аңа каршы көрәшми, ислам иман һәм белем, мәңгелек һәм мизгел, дини институтлар һәм дәүләт, аерым кеше һәм җәмгыять, рухи һәм матди нәрсәләр арасында гармония тудыра.

Хәзерге заман цивилизациясе кешеләрдә ашауда һәм спиртлы эчемлекләр эчүдә чама хисе тәрбияли, сыйфатлы ит ашарга һәм гигиена кагыйдәләрен үтәргә киңәш итә. Болар мөселманнарга гына хас билгеләр түгел, алар мөселман *өммәте* кысаларыннан чыгып, инде күптән гомумкешелек нормаларына әйләнделәр. Культуралы теләсә кем аларны үтәп килә. Йолалар динле кешене дин тотмаучыдан аеручы билге була алмыйлар. Әгәр дә кеше: "Аллаһ Тәгаләдән башка тәңре юк, Мөхәммәт—Аллаһның пәйгамбәре" дип әйткән булса, ул—динле кеше, ә йола һәм гореф-гадәтләр аның дингә ышануын билгеләмиләр, ә бары тик ныгыталар гына.

*Ахыры киләсе санда*

[1] *Юсуф аль-Кардави.* Исламское сознание... —С. 87.
[2] *Юсуф аль-Кардави.* Исламское сознание... —С. 77.

*Дискуссия: "Безнең заман герое*

**Дания Заһидуллина**

# УҢАЙ ГЕРОЙ ЮГАЛУ: СӘБӘПЛӘР, НӘТИҖӘЛӘР.

Татар әдәбиятында тәнкыйть кимеп бара дисәк тә, матбугатта егерменче гасыр ахыры татар прозасына кагылышлы булып үткән бәхәсләр, "Казан утлары" журналы ачып җибәргән дискуссиядә катнашкан язмалар милли әдәбиятка мөнәсәбәтле шактый каршылыклы бәяләр яшәп килүне, фикер төрлелеге хөкем сөрүен күрсәтте, тәнкыйди барышны җанландырды. Тәнкыйди фикердәге каршылыкларның сәбәпләре дә күп. Шуларның берсе—соңгы дәвер татар әдәбиятының төрле юнәлеш һәм агымнарда иҗат ителеп тә, ана бәя бирүнең нигездә бер агым таләпләренә җавап кебек башкарылуында. Шуна күрә, мин, башлыча, алдарак басылган мәкаләләрдә телгә алынган проза әсәрләренә мөрәҗәгать итүне, шулар хакында сөйләшүне исә XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятындагы әдәби күренешләр белән бәйләп алып баруны кирәк таптым.

Тормыш-яшәештә теләсә нинди төр ваграк төркемчәләргә бүленә. Кеше дип гомумиләштерсәк тә, без аннары ир-ат һәм хатын-кызны, балалар, яшүсмерләр, картларны, туганнарны һәм таныш түгелләрне һ.б. бик күп яссылыкларда аера башлыйбыз. Яки тагын бер мисал. Урманга килеп керсәк, андагы нарат, каен, усак яки балан—һәрберсе үзенчә кирәк һәм файдалы, һәрберсе үзенчә кадерле һәм якын тоела. Аларга мөнәсәбәт тә, аларны куллану-файдалану да, бәяләү дә төрле. Каеннан балан җыеп булмаган кебек, усакны яна елга бизәк итеп бастыру мөмкин түгел.

Әдәбият та шундый ук үзенчәлекле якын килүне сорый. Кызганычка каршы, бездә озак вакытлар әдәбият бер иҗат ысулы *(агымы)* белән языла, бер идеалга хезмәт итәргә тиеш дип саналды. Шушы ышану, күрәсең, безнең күзаллавыбызда бик нык утыра әле. Татар әдәбиятында реализм белән янәшә романтизм һәм модернизм үз урынын тапкан булса да, төрле юнәлешләрнең яңадан-яңа агымнары формалашса да, без һаман социалистик реализмга хас сыйфатлар эзләп, башка канунннарга нигезләнеп язылган әсәрләрне үзебезгә мәгълүм ноктадан карап кына бәяләүне дәвам итәбез.

Шушы урында гел ишетелә торган фикер янгырап китсән төсле: "Теләсә кайсы әсәрне теләсә нинди агымга кертеп карап була бит", дияргә яратучылар шактый. Ләкин наратны усак дип булмый. Яки Бауман урамында капма-каршы торучы ике бина бар. Аның берсе—матбугат йорты—конструктивизм, ә каршыдагысы—Париж күлмәкләре сата торганы—модернизм стилендә салынган. Бу ике атаманы бутау мөмкин түгел. Дөрес, аларны кулланмаска, "бина, йорт"

дип кенә атарга була. Каен, усакка бүлмичә, агач дигән төсле. Ләкин бу вакытта проект авторларының модернизм яки конструктивизм стилендә нинди үзенчәлекле алымнар кулланганын, нинди детальләргә мөрәҗәгать итүен, шулар ярдәмендә нәрсә белдерергә теләгәнен дә ачыклау мөмкин булмас.

Әлбәттә, журналда барган дискуссия бик киң, аңа кушылу өчен материалны чикләп куярга кирәк. Чөнки җәмгыятьтәге әхлакый һәм эстетик кыйммәтләр үзгәрү мәдәният һәм сәнгатьне күчеш чигенә китерде. "Социалистик" кысаларыннан арынган реализм кеше характерын аның субъектив казанышы итеп аңлату белән эш-гамәлләрне тарихи-иҗтимагый мотивацияләү *(детерминизм)* арасында алтын урталыкны тапты, типиклаштыруны иҗтимагый-сыйнфый баскычтан гомумкешелек югарылыгына күтәрде. Бу юнәлештә иҗат ителгән әсәрләр шәхес һәм чынбарлык арасындагы бәйләнешләрнең барлык төрләрен колачлап алырга омтыла башлады. Реализм *(яки соцреализмнан соң булганга "яңартылган реализм" төшенчәсен кулланабыз)* чын мәгънәсендә каһарман дип аталырга лаек соклангыч геройлар да бирми түгел. Җәмгыятьнең барлык катламнарын чолгап алган ялганга каршы чыгарга җөрьәт иткән Нуриасма *(Ф.Садриев, "Таң җиле")*, тормышның барлык сынауларын да күңелендәге мәрхәмәтлелек орлыгын саклап кичкән Гөлҗиһан *(Ф.Сафин, "Гөлҗиһан")*, илкүләм афәт вакытында да үз гомере өчен түгел, халык язмышын алга куеп намуслы хезмәт кешесе булып калган Әхмәтсафа Дәүләтьяров *(Ф.Сафин, "Саташып аткан таң")*, тормышны яңа кануннар белән янабаштан төзерлек көчкә ия, мәрхәмәтле һәм көчле Арслан *(Н.Гыйматдинова "Ак торна каргышы")* шундыйлардан. Ә инде соңгы униеллыкта яңадан күтәрелеш кичерә торган романтизм юнәлеше кеше рухының бөеклегенә сокланырлык каһарманнары белән истә калырдай әсәрләр бүләк итте. Мәсәлән, Ә.Салахның Газизе *("Соңгы вальс")*, М.Кәбировның Гөлзилә һәм Таһиры *("Мәхәббәттән җырлар кала")* шундыйлардан.

Бүгенге әдәбиятта яңа геройлар юк түгел. Ләкин алардагы үрнәк булу хасияте холык-фигыль, эш-гамәл, уй-фикер, хис-мөнәсәбәт берлегендә чагылдырылмый, нинди дә булса бер як, сыйфат кына калкытыла. Мәсәлән, Н.Гыйматдинованың "Пәри утары" повестенда Хаят образын алыйк. Әсәрдә ике төрле: ялгыш кануннар *(байлык җыю, хыянәт, көнчелек, җавапсызлык, явызлык)* буенча яшәүче авыл һәм сафлык, ярату, мәрхәмәтлелек үрнәге булган пәри утары—тормыш модельләре тудырыла. Хаят—авторның дөрес, табигый кануннар белән яшәү идеалы. Аның шәхси эш-гамәлләре, уй-фикер һәм кичерешләре менә дәлил. Ләкин Хаят иҗтимагый эшчәнлектә күрсәтелми, ул Нәфисә *(Г. Бәширов)* яки Гөлзифа *(Р. Төхфәтуллин)* кебек иҗтимагый хезмәт алдынгысы түгел. Чөнки заман үзгәрде, әсәрнең иҗат агымы башка. Әгәр язучы Хаятне хезмәт алдынгысы итеп күрсәтергә теләсә, әсәр уйланмасының үзәгендә яткан тормыш моделен тергезү мөмкин булмас иде.

Яки М. Маликованың "Өермә"сендә Җәүһәрия һәм Харис—хәтта соц.реализм әсәрләре көнләшерлек уңай геройлар. Җәүһәрия—һәм иҗтимагый, һәм рухи яктан көчле, идеаль герой статусында тәкъдим ителә. Ләкин язучы сурәтләгән җәмгыятьтә мондый геройга урын юк: роман Җәүһәрияне үтерүчене эзли. Дөрес, Харис сурәтләнеше ягыннан Җәүһәриягә бик якын тора. Ләкин язучы бу очракта аның иҗтимагый эшчәнлеген укучыны ышандырырлык дәрәҗәдә тәгәл һәм тирән күрсәтә алмый: юкса йә әсәрнең жанрын әкият кебегрәк үзгәртергә, йә сурәтләнгән вакытны алыштырырга кирәк булыр иде.

Ф.Бәйрәмова "Алыплар илендә" әсәрендә бар яктан идеаль образ тудыра. Ләкин Камил исемле мондый малайның тормышта булу мөмкинлеге шикле. Шуңа да ул тормышчан түгел, ә шартлы-схематик образ кебек кабул ителә. Шулай булганда гына әдәби кыйммәткә ия дә.

Әйе, бар яктан уңай геройлар бирә торган иҗат агымы саекты. Әдәбият үзгәрә, герой да үзгәрә. Ләкин бүгенге әдәбиятта укучы тегеяки бу сыйфатына сокланып, теге яки бу ягын үрнәк итеп карар геройлар бар. Еш кына алар икенче пландагы геройлар буларак әсәргә килеп керәләр. Ләкин бу аларның дәрәҗәсен төшерми.

Тик минем сүзем алар хакында түгел. Чыннан да, әдәбиятның тулы бер катламында, күнегелгәнчә әйткәндә, төп геройны, унай геройны, үрнәк геройны аерып алу мөмкин түгел. XIX йөз инглиз әдәбияты классигы, реалист У.Теккерей үзенең бер әсәрен "Герое булмаган роман" дип атый. Татар әдәбиятында да шушы—герой югалу тенденциясе күзәтелә.

Бу күренешнең сәбәпләре күп, әлбәттә. Иң әһәмиятлеләреннән, 1980 елларга татар әдәбиятының тематик, стиль ягыннан баюын, төрләнүен билгеләргә кирәк. Бу чор милли прозасында психологик *(Ә.Еники)*, лирик *(М.Мәһдиев, Ә.Баянов, Г.Сабитов)*, тәнкыйди *(А.Гыйлажев)*, поэзиядә—шартлы-фәлсәфи башлангычлар көчәя. Ә инде 1980 еллар ахырына фәлсәфи-публицистик *(М.Галиев)* һәм шартлы-метафорик *(Ф.Бәйрәмова)* башлангычлар үзен нык сиздерә. *(Җәя эчендә күрсәтелгән исемнәр—тармактагы аеруча калку иҗат ияләре генә, аларны санау эшен дәвам итәргә мөмкин булыр иде).* XX гасырның буеннан-буена татар әдәбиятында әйдәп баручы булган реалистик һәм гасыр әдәбиятындагы һәр дәвердә яна статуста күтәрелеш кичереп, бер "шартлап" ала торган романтизм юнәлешләрен баетып, яна башлангычлар әдәби әсәрнең төп элементларыннан булган образ-герой бирелешенә дә йогынты ясый.

Мәгълүм ки, әдәби әсәрдәге образларны анда сурәтләнгән дөньяга мөнәсәбәтле ике чиккә аеру кабул ителгән. Объектив образлар нәкъ менә сурәтләнгән дөньяда хәрәкәт итә, аларга кеше, әйбер, табигать образларын, җыелма һәм ясалма образларны кертеп карыйбыз. Субъектив образлар исә сурәтләнгән дөнья һәм әдип, сурәтләнгән дөнья һәм укучы арасында арадашчы ролен башкара. Без аларны хикәяләүче, лирик герой, автор образы дип йөртәбез. Классик әдәбиятта, автор позициясе ачык күренеп торса да, объектив образлар беренче планда тора. Төп герой, унай герой бер үк вакытта авторның идеалы да, аның фикерләрен укучыга җиткерүче дә, идеаль тормыш моделенең нигез ташы да була.

Ә инде үзенчәлекле стиль башлангычлары белән баю вакытында әдәби әсәр элементларының урыны, статусы, дәрәҗәсе үзгәрә. Мәсәлән, М.Мәһдиев иҗатын мисалга алып карыйк. Лирик башлангычның көчәюе бу иҗатта субъектив образны алга этәрә. Автор үзенең әсәрләрендә *("Бәхилләшү", "Торналар төшкән җирдә" һ.б.)* чын мәгънәсендә характерлар булган, һәрберсе үзенчәлекле холык-фигыльгә ия, "тарихы-легендасы" кызыклы күп геройлар иҗат итә. Ләкин субъектив образның—хикәяләүченең—роле-урыны үзгәрә һәм ул әсәрдәге автор образы, вакыйгаларны күзәтүче генә булмыйча, аларда катнашучы герой баскычына күтәрелә.Әсәр чынбарлыгын сөйләүче-күрсәтүче түгел, бәлки шушы чынбарлыкка мөнәсәбәтен үсеш-үзгәрештә, хәрәкәттә сурәтләүче автор "мин"е, шуның тирәсенә тупланган лирик-субъектив катлам вакыйгалар *(сюжет)* катламыннан да зураеп китә, мозаика кебек чәчелгән вакыйга-күренешләрне үз янына—бер үзәк тирәсенә туплый. Нәтиҗәдә, әсәрдәге төп каһарман булган "мин"нең рухи дөньясы, аны укучыга тәэсир итү вазифасын үз җилкәсенә ала. Әсәрнең иҗатчысы, язучы-автор белән янәшә әсәр тукымасында тагын бер—автор образы пәйда була. Язучы-автор унай герой ярдәмендә белдерергә мөмкин булган фикерләр, идеал нәкъ менә автор образы аша укучыга ирештерелә. Автор образы унай геройга хас булырга мөмкин барлык сыйфатларга ия: вакыйгаларны, кешеләрнең эш-гамәлләрен бәяләүдә гадел, нечкә һәм саф күнелле, күзәтүчән, туган җирне-туфракны яратучы, хезмәт кешесе, тормыштагы күнелсез моментларны авыр кичерүче һ.б. шундый яклары белән укучы күз алдында бербөтен булып калка. Шуңа күрә дә, әдәбилек кануннары буенча, әсәр эчендә тагын бер шушы ук дәрәҗәдәге унай яки үрнәк герой була алмый, булырга мөмкин түгел. Андый герой уйлап табылган, әсәр сюжетына кертелгән очракта, ул автор образын артка чигендерер яки әсәрнең ышандыру көчен киметер иде.

Прозадагы субъектив катлам кинәю белән бәйле үзгәрешләр 1970—1980 елларда кече жанр—хикәя кысаларында күзәтелә башлый. Бу яктан Ф.Хөсни, Г.Сабитов хикәяләре әлеге процессның асылын, структурасын күрергә ярдәм итә. Аларда вакыйгалар катламы янәшәсендә хикәяләүче-геройның хис-мөнәсәбәт үзгәрешен хәрәкәт рәвешендә сурәтләүче катлам хасил була. Ул

вакыйгалар катламына караганда мөһимрәк роль уйный. Мәсәлән, Ф.Хөснинең "Чыбыркы" хикәясендә Рәшитнең авылдан чыбыркы алып кайтуы һәм бу эшнең малайга җәза бирү белән тәгәлләнүе кебек үзгәргән вакыйгалар *(объектив катлам)* сюжет тәшкил итә. Шуның янәшәсендә хикәяләүче статусындагы әтинең малаена мөнәсәбәте үсеш-үзгәреш кичерә.

Күп кенә хикәяләрдә хикәяләүче ике: вакыйгаларда катнашучы яшь кеше һәм еллар биеклегеннән шул вакыйгаларга бәя бирүче олы кеше кебек, вакыт ягыннан ерагайтылып күрсәтелә. Олы хикәяләүче күтәргән мәгънәви йөк яшь хикәяләүче белдергән фикер-идеядән зуррак булып чыга. Мәсәлән, Г.Сабитовның "Тәүге соклану" хикәясендә малай-хикәяләүче алтын балык тоту һәм югалту тарихын сөйли. Көнчелек—башкалар бәхетен, өметен җимерүче, дигән фикер вакыйгалар катламында белдерелә. Шуның янәшәсендә олы хикәяләүче урын алган. Ул туган җирнең кеше өчен иң кадерле урын булуын ассызыклый. Шушы ике хикәяләүчене берләштереп, уртак идея тәкъдим ителә: матурлык кешене бәхетсезлектән коткара! *("Башымны күтәрдем, күккә карадым. Һәм кинәт шунда бөтен кайгы-хәсрәтләрем, юып алгандай, юкка чыкты. Күктә-биектә, зәп-зәңгәр төпсез тирәнлектә ике генә өем ак болыт йөзә иде", дигән сүзләр малай-хикәяләүченеке. "Ак болытлар, ак болытлар! Шул көннән соң гомерем буена юлдаш булды алар миңа. Урманнарда йөрсәм, яфракларны аралап, зәңгәр күктән эзләдем. Су коенсам, дулкыннарда чалкан ятып, һаман күккә бактым. Җырласам, җырларыма керде шул өем болытлар, ятсам—төшләремә", дигәне өлкән хикәяләүче сөйләме булып тәгәлләшә. Матурлык символы кебек кулланылган ак болытлар вакыт ягыннан ерагайтылган хикәяләүчеләрне дә, объектив һәм субъектив катламнарны да берләштерә.)*

Шул рәвешле, татар әдәбиятында субъектив катлам әсәр тукымасында мөстәкыйль һәм әһәмиятле урын яулый бара. Бу хәл повесть, роман кебек күләмле жанрларга да тәэсир итә. Һәм, үсә-кинәя барып, гасыр ахырына мона кадәр милли әдәбиятыбызда күзәтелмәгән, күнегелмәгән яңа төрле әсәрләр язылуга китерә. Мәсәлән, Ф.Латыйфиның "Бәйсез этләрне атарга" повесте *(автор аны роман-нәсер дип атый)* шундыйлардан.

Повестьның объектив, ягъни вакыйгалар катламы икенче класста укучы авыл малае Харис исеменнән хикәяләнә. Сугыш елларында туган, балалык вакыты авыр елларда уза торган нәни геройның хыялы әсәрне башлап җибәрә: гыйлем алып, матур һәм белемле кешеләр булып туган якларына әйләнеп кайту ул! Харисның икенче—тачка ясау хыялы—сюжет барлыкка китерә.

Әсәрдә шушы сюжет үстерелешен озатып яки әйдәп баручы, аннан да зуррак катлам бар. Субъектив катламның хикәяләүчесе—өлкән кеше. Ул ирония һәм сатира белән сугыштан соңгы җәмгыять, совет хөкүмәте дип аталган система хакында сөйли. Әлеге җәмгыятьне халык һәм житәкчеләр дигән ике чиккә аерып, беренчеләрнең—ачлы-туклы яшәвен, хөкүмәтнең халыкка каршы талау сәясәте алып баруын күрсәтә. Бу системаның эш башында наданнар һәм эшлексезләр утыруны таләп итүе, халыкны куркытып һәм икейөзлелеккә күнектереп буйсындыруы, үткәнне пычрату һәм бүгенгене мактауның, милли аңны буу һәм руслаштыруның вазгыятькә әверелүе билгеләнә. Заман нәселсезләр, милләтсезләр, динсезләр, телсезләр, намуссызлар заманы буларак бәяләнә. Әдәбият белемендә җыелма образ дип бәяләнә торган—система образы тудырыла. Язучы-автор хәзерге әдәбияттагы иң үтемле алымнарның берсе—уенга мөрәҗәгать итә. Моны әсәр эчендә үк искәртеп китә: "Өлкәннәр икейөзле, чыршы бәйрәмендәгечә, йөзләренә катып калган елмаюлы яисә кайгылы битлек киеп алганнар да шул рольне уйныйлар да уйныйлар кебек". Битлек кидергән совет системасы хакында сөйләү дә битлекне һәм аның астындагы хакыйкатьне күрсәтү кебек башкарыла. Ә инде шул системаның чын йөзен күргән, фаш иткән унай герой—әсәр чынбарлыгында тудырылган автор образы.

Шулай итеп, ироник модусның алга чыгуы икенче хикәяләүченең—өлкән, ирония һәм сатира ярдәмендә бәя бирә алырлык субъектив образның—пәйда булуына китерә. Ул—яшьлеге сугыштан соңгы чорга туры килгән, хәзерге югарылыктан үткәннәргә тәнкыйди мөнәсәбәт белдерерлек акыллы кеше. Нәкъ

менә шушы герой әсәрдәге унай герой вазифаларын үз җилкәсенә күтәрә. Ул малай Харисның хәзерге һәм үткән тормышка бәясен формалаштыра, бала күнелендә позитив күренеш буларак урнашкан һәр нәрсәнең чынлыкта система кимчелеге икәнлеген ассызыклый. Иске мәдрәсәләрнең пычраклык оясы булуын, совет мәктәбендә генә чын белем эстәү мөмкинлеген балаларның аңына сендерүме ул, тавыкларга ашату өчен фермадан ат тизәге алып кайтуны тыймаган өчен җитәкчеләргә рәхмәт укумы, камыш янә булган өчен—өй түбәсенең матурлыгына, тәрәзәләр аз булганга—өй җылы булачак дип сөенүме, русларның татар-монголларны җинүен белеп дәрестән горурланып кайтумы—болар бөтенесе дә малай Харис тарафыннан унай күренеш кебек шәрехләнә, автор образы белән тәнгәл өлкән хикәяләүче аларны ирония һәм сатира дәрәҗәсенә күчерә.

Сюжет катламында бирелгән, милиционерның малайдан җинаятьче ясарга омтылуы, этне атып китү кебек вакыйгалар шулай ук җәмгыятькә хөкем чыгара. Совет идарә системасы бәйсезлеккә каршы көрәшә, хөр фикерне һәм хөр фикерлеләрне юк итә, диелә. Харисның хыялына аерым игътибар бирү бәйсез, хөр кешеләрдә генә зур хыяллар, олы максатлар булырга мөмкинлек хакында сөйли. Әлеге фикерләр олы хикәяләүче яки автор образы ярдәмендә үстерелә. Автор образы татар милләтенең, 1917 ел революциясеннән соң яшәгән буыннарның һәм аерым шәхес фаҗигасен совет системасы тәрбияләгән коллык психологиясенә бәйләп аңлата.

Мондый әсәрләр ике төрле укучыга атап иҗат ителгән булуы белән аерылып тора. Бер яктан, вакыйгалар кысаларында әдип киң катлам укучыны гыйбрәтле, кызыклы хәлләр белән таныштыра, сугыштан соңгы чор балалар тормышы, аларның шатлык-борчулары хакында сөйли. Бу материалда төп герой—хикәяләүче "мин" исеменнән алып баручы малай Харис кебек тоела. Икенче яктан, шушы хикәяләү өлкән Харис яки автор образы тарафыннан озата барыла. Һәр өзек, һәр монолог яки диалог җәмгыятькә бәя булып яңгырарлык итеп сайланган. Ул инде интеллектуаль һәм әдәби әзерлекле укучыга юнәлтелгән, төп герой да—малай Харис вакытын искә төшергән, шул заманның төп сыйфатларын бүгенге әнгәмәдәшенә күрсәтергә омтылучы автор образы булып калка. Һәм ул—объектив материал катламындагы герой—малай Харистан зуррак, тирәнрәк.

Әдәби әсәрдә ироник модусның көчле һәм үзенчәлекле сөйләм чаралары ярдәмендә бирелүе әдәбият белемендә пастиш дип атала. Ул рус һәм элеккеге СССР территориясендә яшәүче милләтләр әдәбиятларында нигездә соцреализм иҗат агымының хикәяләү манерасына охшату ярдәмендә көлү кебек башкарыла. Чиктән тыш арттырып унай сыйфатларны сөйләгән булып, чынлыкта тормыштагы чарасызлыкка җиткән, абсурд чигендәге гаделсезлек, хаерчелек, кансызлык, мәгънәсезлекне күрсәтү бу. Ф.Латыйфи повестенда пастиш сөйләмгә йөкләтелә. Ә инде Т.Галиуллинның гасыр ахыры татар матбугатында күп бәхәсләр уяткан "Тәүбә", "Элмәк", "Төнге юллар" трилогиясендә ирония вакыйгалар сайланышында күзәтелә.

Романнар беренче карашка мажаралы әсәр кебек тәэсир калдыра. Җинаятьләр, үтерешләр үзәккә куела. Ләкин традицион мажаралы жанрда җинаять эшләнү һәм шуны ачу, дөреслекнең тантана итүе сюжет барлыкка китерә, детектив геройлары арасында җинаятьче, корбан һәм үтерүчене фаш итүче булу мәҗбүри. Һәм шуларның берсе: йә үтерүчене табучы, йә шик төшкән кешеләрдән берәү, йә корбан—унай герой итеп сурәтләнергә мөмкин. Бу романнарда без бөтенләй башка күренеш белән очрашабыз. Җинаятьләр эшләнә, кан коела—ләкин җинаятьчеләрне фаш итү омтылышы юк. Аларның кем булуы да яшерелмәгән. Чөнки язучы мондый максат куймый. Ул туктаусыз үтереш, акча өчен көрәш, кан коеш, үч алу, куркыту, дустынны сату кебек хәлләрнең җәмгыятьтә нормага әверелүен күрсәтә. Ә мондый җәмгыятьне сурәтләгәндә унай герой кертелә икән, әсәр берәүне дә ышандырмас иде. Биредә бердәнбер унай герой—авторның шушы җәмгыятькә мөнәсәбәте, тәнкыйте, укучыны шушы хәлләрне акыл аша уздырып, уйланырга чакыруы.

Соңгы еллар татар әдәбиятында мондый структурадагы әсәрләр шактый күп язылды. Алар төрле жанрда, төрле агымда иҗат ителәләр. Мәсәлән,

В.Имамовның татар укучысын сискәндереп җибәргән, шәһәрләшүгә, КамАЗ һәм Чаллы кебек үзәкләргә башка күзлектән карарга мәҗбүр иткән "Могикан" повесте. Әсәр үзәгенә куелган Вәлит һәм аның аты Могикан язмышы ышандыра һәм тетрәндерә. Әсәрдә лирик башлангыч көчле булу аны тәэсирле ясый, мавыгып укырга этәрә. Заман проблемалары белән баетылган, Әфган сугышы кебек фаҗигаләрне дә колачларга омтылган әсәрдә, аерым геройлар язмышыннан бигрәк, система образы алгы планга чыга. Шуңа күрә дә объектив кеше образы—Вәлит унай герой түгел. Дөрес, герой буларак, ул язучы-авторның бәясен күтәрә, берничә сыйфаты үрнәк итеп бирелгән. Ләкин аннан да әһәмиятлерәк образ, җыелма образ—идарә итү системасы бар. Шушы система өчен җир яки ил, милләт, тел язмышы да, кеше гомере дә, табигать тә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр матурлыгы да, ягъни автор-язучы өчен иң мөһим әйберләрнең берсе дә кыйммәтле түгел. Әгәр әсәргә унай герой табарга кирәк булса, ул, һичшиксез, шушы системадан көчлерәк, аңа каршы чыгарлык һәм җимерерлек булырга тиеш. Ләкин моның өчен шәхес булу гына җитми, димәк, андый унай герой, тормышта була алмаган кебек, әсәр тукымасында тудырыла калса да, укучыны ышандыра алмас иде. Шушы хакыйкатьне аңлаган, укучыга җиткерергә омтылып әсәр уйланмасын нигезләгән интеллектуал-автор образы аны алыштыра.

Ә инде М.Кәбировның "Сары йортлар сере" повесте бүгенге көнгә әлеге күренешнең милли әдәбияттагы иң югары казанышы дип бәяләнә ала. Бирелә пастиш, ирония чиктән тыш арттырылып, абсурд чигенә җиткерелгән һәм социалистик тормышны гротеск формасында, антиутопия итеп сурәтләү урын тапкан. Һәм әсәрдәге вакыйгалар тезмәсе дә, төзелеш тә, фәлсәфи катлам да бер нәтиҗәгә алып килә: кешеләр ерткыч, кол, мескен хәлендә яшиләр. Аларны рухи "доктор" да, изге Ана да, гөнаһсыз сабыйлар да үзгәртә алмаячак! Бирелә ирония кеше тормышының мәгънәсезлеге, кешелекнең юкка чыга баруы хакындагы сызлану фәлсәфәсе белән үрелә.

Әсәрнең сюжеты катлаулы түгел. Вакыйгалар берничә көн: Мәдинә карчыкның күккә ашуы һәм Мәрьям үлеме арасын иңли, 1990 елларны сурәтләү кебек тәгалләшә. Завод янындагы баракларда яшәп ятучылар янына бер карчык килеп урнаша, биш еллап яши, аларга ярдәм итәргә тели. Ләкин кешеләр аның үлеменә сәбәпче булалар.

Әсәрдә иң әһәмиятлесе сюжет түгел. Автор җәмгыятьнең коммунизм төзүчеләр тәрбияләве—коллар булдыру икәнлекне, коллык психологиясенең—куркуга нигезләнүен, яхшылыкның—яхшылык, явызлыкның—явызлык булып әйләнеп кайтуын һ.б. нәтиҗәләрне тормыш кагыйдәсе төсендә билгеләп бара. Укучы күңелендә ассоциацияләр уятырлык билге-сүзләргә мөрәҗәгать итеп, повесть текстын мәгънәви яктан киңәйтә. Мәсәлән, исемгә чыгарылган "сары йорт" төшенчәсе юләрләр йорты мәгънәсендә билгеле. Билге вазифасында, ул әлеге йортларда яшәүчеләргә һәм җәмгыятькә беренчел бәя булып яңгырый. Шуның белән янәшә китерелгән "алтынчы подъезд" А.П.Чеховның "Алтынчы палата"сы белән ассоциацияләшә. Реминисценция, аллюзия кебек әдәби алымнар әсәрне мәгънәви "уйната". Мәсәлән, гомумбилгеле дини мифны—Мәрьям-ананың Исусны гөнаһсыз килеш табуы хакындагы мәгълүматны хәтердә янарта һәм Мәрьямнең малаен кешеләрне коткарачак пәйгамбәр итеп карау мөмкинлеген күрсәтә. Шуның ярдәмендә бу кешеләрне берниндн пәйгамбәр дә коткара алмас дигән уйны ныгыта.

Ироник сүз уйнату шулай ук җәмгыятьне тәнкыйтьләүгә юнәлтелгән. Мәсәлән, Мәдинә карчыкның өч көннән соң үләчәк кешеләргә "Сезнең өчен коммунизм өч көннән соң киләчәк" дип эндәшүе коммунизм хакындагы сафсатаны сатира объектына әверелдерә.

Гомумән алганда, М.Кәбиров укучыга күп кенә "табышмаклар" тәкъдим итә, вакыйгаларның сәбәбен әсәр ахырына кадәр "сер томанында" саклый. Нәтиҗәдә, сатирик, ироник һәм фәлсәфи башлангычларны автор тәкъдим иткән уен ярдәмендә тирәнәйтүгә ирешә. Шуңа күрә мондый тип әсәрләрдә автор уены—унай үрнәкне алыштыручы да.

Мондый күренешне нигезләү өчен, югарыда мисал итеп китерелгән автор—Ф.Латыйфиның элегрәк язылган "Ак-карага тимәскә" повестена күз төшерергә мөмкин. Әсәр заман һәм шәхес каршылыгына корылган һәм шулай ук системаның төп сыйфатын: хакыйкатьне, ягъни акны—кара, ялганны—дөрес дип күрсәтүгә, алдауга корылган булуын ача. Повестьта уңай герой, көрәшче герой Рәис Хаков образы тудырыла һәм аның аңындагы үзгәрешләр: "ак-карага тимәү" кагыйдәсенең төп канун икәнен аңлауга килү юлы сюжет җебен хасил итә. Ләкин ул ак-кара буталышын аерым кешеләрнең намуссызлыгына бәйләп аңлата. Рәис Хаков та, уңай герой буларак, шундый намуссыз аерым кешеләргә каршы көрәшкә чыга. Чыннан да, системадагы аерым бер кимчелекләргә, шул кимчелекләрне гәүдәләндергән аерым бер кешеләргә каршы намуслы, көчле шәхесләр күтәрелергә мөмкин, әсәр ышандыра. Ә инде "Бәйсез этләрне атарга!" повестенда көрәш объекты үзгәрә. Язучы-автор гаепне аерым кешеләрдә түгел, системаның дөрес түгеллегендә таба. Шуңа күрә бу әсәрдә Рәис Хаков кебек ялгызаклар уңай герой статусына күтәрелә алмый, мона әдәбиятның үз кануннары каршы чыга.

Уңай герой статусы үзгәрүнең бер юлы татар әдәбиятында психологизм үсү белән билгеләнә. Мәгълүм ки, 1960-80 елларда Ә.Еники, элгәргеләрдән Ф.Әмирханнар, Ш.Камаллар башлаган традицияне дәвам итеп, кешенең рухи дөньясын, психологиясен сурәтләү объекты дәрәҗәсенә күтәрде. Ул шәхеснең уй-фикер, хис-кичереш, теләк-омтылышлар үзгәрешен аның эш-гамәлләре сәбәбе итеп карады, күп кенә иҗтимагый күренешләрне дә кеше күңелендәге хәл-халәткә бәйләп аңлатты. Шуңа күрә Ә.Еники әсәрләрендә матди һәм рухи кыйммәтләр бер-берсенә комачауламый: рухи дөньясы бай булган геройлар *(Акъәбиләр, Кларалар, Зөһрәләр)* дөрес эш-гамәлләр дә кылалар, җәмгыятьтән дә читләшмиләр, һәм киресенчә, рухи дөньясы ярлы булган кешеләр матди байлыкны бар нәрсәдән өстен саный.

Ләкин әдәбияттагы һәр күренеш үсеш-үзгәреш кичерә килә. Психологизм белән дә шулай. 1980 еллар ахырына хис һәм фикер өлкәсен сурәтләү яна бер биеклеккә күтәрелә һәм бу баскычта инде матди һәм рухи кыйммәтләр капма-каршы якка әйләнә.

Бу юнәлештәге беренче әсәр дип Ф.Бәйрәмованың "Болын" повестен күрсәтергә кирәк. Матурлык эзләүче Алсу җәмгыятьтә матди байлыклар тудыручыларның бер өлеше—үзләренә файда эзләүчеләргә каршы куелган. Повестьның сюжеты—матурлык эзләүче Алсуның башкаларга *(үзенә түгел!)* файда китерүчегә әверелү тарихы ул. Тирән психологизм ярдәмендә тудырылган, рухи дөньясы нечкә, бай, матур булган Алсу, әлбәттә, уңай яки үз артыннан башкаларны ияртерлек көчле герой түгел. Ләкин ул авторга тормыш-яшәеш моделен тудырырга ярдәм итә. Аның ярдәмендә кешеләрнең төрле булуы, файда эзләүчеләрнең дә, матурлыкка табынучыларның да үз юлы, үз сукмагы барлык ассызыклана. Тормыш авырлыкларының матурлыкка табынучыларны үзгәртү-сындыру мөмкинлеге искәртелә.

Шунысы кызык, әсәр 1980 еллар уртасында—җәмгыятьтә идеал буларак коммунизм төзүче хөкем сөргән бер вакытта—язылa. Рәсми идеология тарафыннан тудырылган мифка каршы торырлык, укучыны сискәндерерлек булу өчен шәхеснең уй һәм хис дөньясы Алсуныкыдай чиктән тыш арттырып, авыру чигенә житкереп сурәтләнүе кирәк булгандыр. Һәм мондый герой, рухи яктан никадәр саф һәм бай булмасын, ялгызлыкка хөкем ителә.Чөнки җәмгыять үзе матурлыкка табыну юлында түгел.

"Битлек", "Кыңгырау" кебек повестьларында шушындый геройлар хакында сөйләшүне дәвам итеп, Ф.Бәйрәмова бер хакыйкатьне ассызыклый: рухи дөньялары бай булган, нәфис-нечкә күңелле кешеләр башкаларга зыян китерми, алар намуслы һәм саф булып кала. Үзенә файда эзләүчеләр исә башкалар белән хисаплашмый. Нәтиҗәдә, автор кешеләрне рухи баету кирәклеге, шәхеснең хис һәм акыл дөньясын тәрбияләү мөһимлеге хакында чаң суга. Хисләр белән яшәү фәлсәфәсен пропагандалый. Мисалга "Күл балыгы" повестен алсак, бирелә мәхәббәт тарихы бәян ителә. Ләкин бу мәхәббәт шулкадәр олы, шулкадәр

каршылыклы, шулкадәр акылга буйсынмас көч, автор аны кеше белән кеше арасында гына сурәтли алмый, бәлки мифологик образ—су кызы һәм жир егете мәхәббәте кебек тасвирлый. Мәхәббәтне яшәү мәгънәсенә әйләндерә.

Эш-гамәлләр, ижтимагый файда китерү ягыннан традицион реалистик әдәбияттагы унай герой дәрәжәсендә булмасалар да, Ф.Бәйрәмованың психологик башлангыч алга чыккан әсәрләре хис-кичерешләр тирәнлеге, уй-фикерләрнен сафлыгы-самимилеге, риясыз яратуга сәләтлелеге ягыннан үрнәк геройлар: Алсулар, Рәшидәләр, Айсылулар тудырды. Алар укучыны да биологик зат булып түгел, рухи жан иясе статусында яшәргә чакыралар.

Безне кызыксындырган аспектта Ф.Бәйрәмованың болардан сон язылган повестьлары аерым урын тота. Чөнки сонгы унъеллыклар татар прозасындагы иң зур үзгәреш дип, һичшиксез, интеллектуаль тенденциянен көчәюен күрсәтергә кирәк. Әдәбияттагы бу күренеш тә автор-укучы сөйләшүен турыдан-туры алып бару мөмкинлеген кинәйтте. Сюжет һәм вакыйгалар кысасында тудырылган тормыш моделе аша фикер һәм мөнәсәбәт белдерү белән чикләнмичә, мондый әсәрләрдә фәлсәфи, ижтимагый, әхлакый кануннар турыдан-туры, автор күзаллавы кебек тәкъдим ителә башлады.

Татар әдәбиятында интеллектуаль тенденцияле әдәбият фәлсәфи-психологик (Ф.Бәйрәмова), ижтимагый (Р.Сибат, М.Кәбиров), әхлакый (Г.Гыйльманов) төсмерләр белән баетылып мәйданга чыкты. Һәм моны Ф.Бәйрәмованың "Канатсыз акчарлаклар" повесте башлап жибәрде дисәк, ялгышмабыз. Аннан сон язылган әсәрләрдәге төп үзенчәлекләрне күрер өчен, әлеге повестька кинрәк тукталырга кирәк.

Төп сюжет сызыгын хатынның эчке каршылыгы хасил итә. Ул кешенен үз-үзен, үз асылын, урынын, яшәү максатын эзләве белән билгеләнә, повестьның темасы да шулай формалаша. Ул, Хатын, Ир, Алар, Йорт дип исемләнгән образлар һәрберсе ярдәмче сюжет сызыклары барлыкка китерә. Һәм язучы унай яки тискәре герой тудырудан китеп, шартлы-метафорик образлылыкка йөз тота. Унай герой, аның эш-гамәлләре, уй-фикерләре, теләк-омтылышлары, хис-мөнәсәбәте аша укучыга житкерелергә мөмкин булган мәгълүматның бер өлеше шушы шартлы образларга йөкләтелә. Язучы бөтенләй үзгә язу рәвешенә мөрәжәгать итә. Йорт кебек символлар да, жемелдәүче эстетика алымы ярдәмендә бер үк персонажның өч яссылыкта бирелүе дә кош, жил, гөнаһ кебек билгеләр дә әһәмиятле биредә. Традицион әдәбияттагы күренеш-хәлләрне, төрле ситуацияләрнен нинди нәтиҗәгә китерүен тасвирлау, күрсәтү урынына, хәзер инде язучы белән укучының шартлы образлар-кодлар ярдәмендә турыдан-туры сөйләшүе, табышмак-уен тәкъдим итеп, укучыны шуны чишәргә мәжбүр итү күзәтелә.

Ярдәмче сюжет сызыкларындагы әһәмиятле каршылыкларның бер өлеше эчке каршылык төсле бирелә. Мондый үзенчәлек әсәрнен психологик тирәнлегеннән килеп чыга. Ләкин әлеге каршылыкларның сәбәбе һәм чишелүе тормыш кануны булып аңлашыла. Мәсәлән, хатынның эчке каршылыгы—асылда хис һәм акыл көрәше ул. Хисләрнен артык нечкә, тормыштан аерылган булуы, бары тик хисләргә буйсынып яшәргә омтылу акылдан язуга китерә. Ирнен эчке каршылыгы теләк һәм акыл көрәше кебек тогаллонә. Ләкин теләкләрнен артык кечкенә, мескен булуы эчүчелеккә алып килә. Мин—Мулланың—эчке каршылыгы Илаһи һәм жир хатын-кызына мәхәббәт арасында сайлау белән бәйле. Жир мәхәббәтенә ирешә алмау шулай ук акылдан яздыра.

Тышкы каршылыклар да тормыш кануннарын барлый. Ир-хатын каршылыгы кешеләрнен төрлелеге проблемасын ача. Йорт символы тирәсендәге югарыдагылар һәм түбәндәгеләр каршылыгы властька омтылу проблемасын куя, яратуның властька омтылышны жинә алуы яна канун кебек белдерелә. Жир кешеләре һәм күктән ингәннәр каршылыгы теләкнең акылны жиңүнен канун бозуга китерүе проблемасы булып әйләнеп кайта.

Нәтиҗәдә, язучы тормыш-яшәешнен канунлаштырылган булуы хакында зур гомумиләштерүгә алып килә. Һәм галәм канунын бозуның *(күктән төшкәннәр мисалында)* юкка чыгуга; система *(йорт)* канунын бозуның үлемгә, жирдәге

тормыш канунын бозуның юләрләнүгә китерүе ачыклана. Вакыйгалар шушы фикергә мисал булып тезеләләр.

Шуның белән янәшә, кешелек тарихына караган тулы бер фәлсәфи күзаллау булдырыла. Яшәеш фәлсәфәсе галәмгә бәя бирә. Галәм—җаннар яши торган җир, югары культурага ирешкән җан ияләренең бер өлеше кайчандыр, бик борынгы заманнарда кешеләргә ярдәм итәр өчен җиргә җибәрелгән, безгә цивилизация бүләк иткәннәр. Ләкин галәм канунын бозып, аларның бер өлеше җир кешеләре белән кушылган. Бу кешеләрне үзгәрткән, мондыйлар күккә омтыла башлаганнар, җаннары үлемсезлек алган.

Тормыш фәлсәфәсе шуннан үсеп чыга. Кешеләрнең бер өлеше тупас һәм примитив булып калган. Икенче өлеше җаннарында илаһи кыйпылчыгын йөртә. Ләкин алар да җир кануннары белән—җирләшкән кануннар белән яшәргә мәҗбүр.

Моннан тыш, әсәрдә дин фәлсәфәсе дә урын алган. Ул кешеләрне канун бозмыйча яшәтүче көч, иманга кайту юлы, рухи булышлык күрсәтүче итеп карала. Гайсә һәм Мөхәммәт пәйгамбәрләр, Коръән һәм Тәүрат китаплары кешегә ярдәм итәр, аны начарлыктан, явызлыктан саклар өчен күктән төшерелгән иман буларак анлатыла. Нәкъ менә дин җирләшкән кешеләрнең күк кыйпылчыгы йөртүчеләр артыннан иярүен, җирдәге ерткыч кануннар урынына башка, илаһи кануннар урнашуын тәэмин итә алырлык чара кебек бәяләнә.

Кеше фәлсәфәсе ярату белән бәйләнгән. Беренче повестьларындагы кебек үк, автор «очар өчен яратырга кирәк» дип белдерә. Шушы өлештә лирик башлангыч бик көчле.

Шулай итеп, интеллектуаль тенденция әдәби әсәрдә язучы әйтергә теләгән фикернең законнар кебек белдерелүен гамәлгә куя. Без анализлый торган әсәрдә ул төрле өлкәгә караган кануннарны бергә җыя. Соңрак язылган аерым бер әсәрләрдә иҗтимагый кануннар (М.Кәбиров “Сары йортлар сере”), дини тәгълимат (Ф.Бәйрәмова “Алыплар илендә”), тормышка кагылышлы фәлсәфә (Г.Гыйльманов “Албастылар”) чагылыш таба. Ләкин һәрчак укучыга юнәлтелгән мондый кануннарны “уку”, тану җиңел.

Тагын бер сыйфат аерым игътибар бирүне сорый. Ул—кешенең чиктәш халәттә сурәтләнүе. “Канатсыз акчарлаклар” повестенда вакыйгалар төш күрү, акылдан язу, үлем алды саташуы халәтендә сурәтләнәләр. Бу—үткәндәге ирхатын яшәгән чынбарлыктан (өй, эш, урам, мәчет) киләчәккә (үлем, кош булып очу) күчү аралыгы. Чиктәш халәттә аң төпкелендә туган сурәтләр чынбарлык кебек тәкъдим ителәләр. Алым шушы халәттә аңланган, табылган законнарның гомумкешелек кыйммәтләре дәрәҗәсендә ныгытылуын тәэмин итә. Мондый кыйммәтләрне укучыга җиткерү өчен уңай герой—объектив образ тудыруның кирәге калмый.

Алга таба иҗат ителгән, интеллектуаль тенденция ачык белдерелгән әсәрләрдә шушы сыйфатлар кабатлана. Ләкин һәр язучы укучы белән үзе әһәмиятле дип тапкан нәрсәләр хакында “сөйләшә”.

Г.Гыйльмановның “Албастылар” романында беренче төп сюжет сызыгы армиядән кайткан Хәлим исемле егетнең тормыш тарихы кебек бирелә. Шуның белән янәшә үк эчке каршылыкның, Хәлимдәге ак һәм кара көрәшенең үсешүзгәреш тарихы рәвешендәге икенче төп сюжет сызыгы килә. Анда Хәлим чиктәш: төш, авырып саташу, хыяллану, аң төпкелендә казыну халәтендә. Беренче сюжет сызыгын ачыклап килгән мифологик—албастылар утары хакындагы ярдәмче сюжет тормышны ике: авыл (аклык)—урман (явызлык) чикләренә аера, тормыш фәлсәфәсен колачлый. Ә инде икенче төп сюжет сызыгында ул кеше аңындагы шартлы күзаллау, шәхес фәлсәфәсе төсен ала. Кешедән өстен көч—албасты—адәмнең аң төпкелендә яшеренеп ята, дигән канунга китерә.Ул сүз катламында да кабатлана: “Кешенең асылы менә шушы ак-кара көрәшеннән тора”.

Романның буеннан-буена тормышка һәм кешегә караган законнар тәкъдим ителеп килә. Кеше җиде буын бабасына кадәр кылынган гөнаһ өчен җавап бирә; Явызлык сөюгә алдап та эшләнә; Күңел барысын да алдан сизә; Курку—

берни жинә алмас көч; Хис кешене көчсезләндерә; Явызлыкка каршы явызлык эшләргә ярамый; Дөреслек юк, шәфкатьлелек кенә бар—кебек кануннар вакыйгалар һәм геройларның эш-гамәлләреннән дә үсеп чыга, тел катламында да әйтелә.

Тормыш кануннары берничә тармакка туплап урнаштырылган. Табигать һәм табигыйлек фәлсәфәсе табигатьне кешенең, барлык тереклекнең анасы дип белдерә. Дөньяда һәр тереклек иясе—бертуган, дигән раслау белән янәшә, үзенчәлекле фикер ассызыклана: аң төпкелендә табигать кочагына янадан кайтырга теләү яшеренгән. Ахыр чиктә, язучының табигый кануннар, табигать законнары белән яшәргә чакыруы аерымачык.

Җәмгыятьтә кабул ителгән кануннарның ялгыш булуын исбатлау белән бергә, язучы фаҗигане булдырмау юлын иманга—аның фикеренчә, изгелек эшләп яшәүгә—кайтуда күрә. Җәмгыятьтәге явызлык, кара көч буларак, көнчелек, битарафлык, эчкечелек, усаллык аерып чыгарыла.

Табигать һәм җәмгыять кануннарыннан камилрәк законнарны язучы ислам тәгълиматында таба, дин кешене көчлерәк, чистарак, шәфкатьлерәк булырга өнди, өмет бирә дип белдерә. Асылы ак һәм кара көрәшеннән гыйбарәт адәм баласының изге, пәйгамбәрлеккә ия зат икәнлеген кабатлый."Җир пычрагына буяла барган саен кеше пәйгамбәрлектән ерагая, еш кына Аллаһы тәгалә биргән изге сыйфат-хасиятләрен бөтенләй югалта". Шул рәвешле, язучы-укучы сөйләшүе әсәр чынбарлыгы кысаларында гына калмыйча, турыдан-туры да алып барыла.

Роман герое Хәлим беренче карашка унай герой өчен кирәкле барлык сыйфатларны үзенә туплаган кебек күренә. Ул көчле, яшь, матур, унган-булдыклы, чиста күнелле, мәрхәмәтле. Ләкин егетнең романда сурәтләнгән өч ел гомере эзләнүдә уза: ул урман хакыйкатен, иман хакыйкатен, кеше хакыйкатен эзли. Дөрес, егет көрәшкә, үз артыннан башкаларны ияртергә сәләтле. Ләкин бу аның үзмаксаты түгел. Эзләнүләр юлындагы Хәлим, иң беренче чиратта, үз аң төпкелендәге албастыны җиңү юлын табарга тиеш. Әсәрдә тормышның гомуми канун-кагыйдәләрен китерсә дә, язучы әлеге көрәшнең һәр кешедә үзенчәлекле булуын искәртә. Хәлим—универсаль, кешелекне коткару юлын табарлык унай герой була да алмый. Кешелеккә караган кануннарны әсәрдәге автор образы җиткерә.

Романда шартлы, ясалма образлар кулланылышы шулай ук соңгы чор татар прозасында киң таралган рәвешне алган. Милли әдәбиятыбызда мифологик образларга мөрәҗәгать итүнең ешаюы инде күп тапкырлар әйтелде. Урман албастылары—гомерләрен явызлыкка явызлык белән җавап бирүгә багышлаган карчыклар—татар мифларыннан күчкән. Ләкин әсәр эчендә алар мифологик образ статусында калмый, бәлки шартлы образ-символга әвереләләр. Кешенең үз эчендәге кара—албасты һәм ак-фәрештә ягы кебек шәрехләү урын таба.

Әсәрдә лирик башлангычның көчле булуы күзгә ташлана. Хикәяләүче, ниндидер вакыйга-күренешләрне йомгаклап, үзенең шәхси кичереш-мөнәсәбәте хакында укучыга мөрәҗәгать итеп сөйли башлый. Ак-кара көрәшенен эчке тартыш кебек гомумиләшүе психологизмны тирәнәйтә. "Җемелдәүче" образлар шулай ук ассоциатив тәэсирлелекне арттыра. Романның без күреп үткән аерым бер сыйфатлары нәкъ менә автор хакыйкатен, әсәр чынбарлыгы хакыйкатен, фәлсәфи-мәдәни хакыйкатьне укучыга җиткерү өчен хезмәт итә.

Р.Сибатның "Ялгызак" романы да шушы тезмәдә каралырга лаек. Әсәрдә шулай ук лирик-эмоциональ башлангыч көчле (дөрес, шуны бозып текстка кергән ямьсезлек, тупаслык каршылыклы фикер уята һәм авторның осталыгы житеп бетмәү хакында сөйли) һәм ул әсәрнең буеннан-буена "ияреп барган" хикәяләүче-автор образы мөнәсәбәте, кичереше, фәлсәфәсе булып формалаша. Шушы катламда яшәешкә караган экзистенциаль фәлсәфә (мәсәлән, гомернең чиклелеге өчен сызлану), совет хакимиятенә тәнкыйть рәвешендә китерелгән иҗтимагый фәлсәфә (мәсәлән, җиен әтрәк-әләмнең властька килүе), Заһидулла эләккән тормыш ситуацияләренең нәтиҗәсе төсендә, кеше фәлсәфәсе (мәсәлән, тыелган нәрсәләрнең кызыктыргыч булуы) кануннарга охшатып текстка урнаштырыла.

Ләкин бу ноктада тукталынмый. Татар кешесе өчен язылган кануннар, герой Коръән китабы эченнән тапкан кәгазьдәге Җидән баба васыяте кебек шәрехләнеп, бер урынга туплап тәкъдим ителә. Бу кануннар арасында кешегә йөкләнгән бурычлар (тәненне үстер; хисенне үстер; акылынны үстер һ.б.), кешегә хас тискәре сыйфатлар (үзенне генә ярату; тәкәбберлек; алфикер һ.б.), унай сыйфатлар (вәгъдәле булу; ялган сөйләмәү; ярдәмгә әзер тору һ.б.), яшәешне, кешенең асылын, тормышны, гомерне аңлату чагылыш тапкан. Димәк, укучыга автор җиткерергә теләгән сүз менә шуннан гыйбарәт. Романда Заһидулла һич тә уңай герой итеп куелмый. Ул—катлаулы, каршылыклы ялгызак характер. Аның тормыш тарихы белән язучы укучыны кызыксындыра, ә хикәяләүче-автор образы ярдәмендә исә укучы белән сөйләшү алып бара, үз фикерләрен уртаклаша.

Соңгы унъеллыклар татар прозасын күзәтүләребез әдәбиятның бу төрендә тәнкыйди, лирик, психологик, интеллектуаль башлангычларның алга чыгуын, калку билгеләнүен дәлилли, дигән идек. Нәкъ менә шушы үзенчәлекләр әдәбиятның, сурәтләнгән дөнья, вакыйгалар үрнәгендә укучы белән сөйләшүдән, турыдан-туры автор-укучы сөйләшүенә күчә баруын, герой югалу тенденциясенең дә шуна барып тоташуын күрсәтә. Автор үзе ике: автор-скриптор (язучы-автор, әсәрнең биографик авторы) һәм автор-трикстер (әсәрдәге автор образы, автор маскасы) кебек аерымлана. Нәкъ менә автор традицион әдәбияттагы уңай герой образының вазифаларын үз җилкәсенә ала.

Соңгы сорау булып, мондый күренеш милли әдәбиятта уңай бәяләнергә тиешме, әллә дискуссиядә катнашкан кайбер авторлар фикеренчә, татар әдәбияты дини пропаганда чарасы буларак, әхлак-үгет вазифаларын үз җилкәсенә алып, әхлаклы уңай герой ярдәмендә укучыга тәэсир итү юлын сайларга тиешме, дигән мәсьәлә калка. Әлбәттә, бүген татар җәмгыяте дини традицияләрне, иманлылык кебек кыйммәтләрне тергезә. Яшьләрнең бер өлеше кешелеклелек дәресләрен дини белем-мәгълүмат ярдәмендә үзләштерә. Димәк, дини әдәбият та языла.

Шулар белән берләттән, без телибезме-теләмибезме, рус һәм дөнья мәдәниятеннән хәбәрдар, рус һәм чит телләрне дә белгән яшьләр буыны олы тормышка атлый. 2000 еллардан соң без нәкъ менә хәбәрдарлык, демократия җимешләренең шифасы тәэсирендә татар гимназияләренә, төрек лицейларына, татар сыйныфларына беренче сыйныфка кереп, шуларны тәмамлаган яшьләрнең күпләп югары уку йортларына килү күренеше белән очраштык. Бүгенгә алар күп, иртәгәге көндә нинди уку йортларын тәмамлаучылар күпчелек булыр—билгесез. Ләкин хәзер шушы яшьләр татар әдәбиятын укый, әдәбиятның киләчәктә укучысы булу-булмау да аларга бәйләнгән. Әлеге яшьләр дөнья әдәбиятындагы интеллектуаль, модернистик, постмодернистик әсәрләр белән мавыга. Мәсәлән, студентлар арасында Коэльо әсәрләренең популяр булуы билгеле. Укучы шул ук "Алхимик"ны кичәге сарык көтүче егетнең сәяхәтләрен—ягъни вакыйгалар катламын күзәтергә теләп укымый. Һич юк. Ул әлеге әсәрдә автор яшергән табышмак-фикерләрне, кодларны-символларны табып, шуларны чишеп-шәрехләп, эстетик һәм интеллектуаль ләззәт кичерә. Мондый укучыны татар әдәбиятындагы автор-укучы сөйләшүенә нигезләнгән әсәрләр белән кызыксындырырга мөмкин. Һәм ул кешелеклелек, иман кагыйдә-кануннарын да шушы код-табышмаклар аша үзләштерә. Бу начармы? Мина калса, һич юк. Җәмгыятьтә генә түгел, әдәбиятта да фикер төрлелеге яшәгәндә, интеллектуаль һәм эстетик ихтыяҗлары бер-берсенә тәңгәл булмаган төрле укучылар катламнарына аталган әсәрләр язылганда, татар әдәбиятының укучысы югалмас.

◉

Бикә
Рәхимова

# ҖИҢ СЫЗГАНЫП ЭШЛӘҮ ЗАМАНЫ КИЛДЕ

Тарих дигәнебез су кебек ага. Тарих—вакыт шул ул. Төрекләрдә датаны да тарих диләр. Менә безнен ун-унбиш елларны эченә алган вакытыбыз тарихка әйләнеп очып китте...

Әле кайчан гына мәйданнарда халыкны азатлыкка чакырып ярсулы шигырьләр укый идек. Шигъри сүз яратып тынланыла, өметләнгән көнелләргә шифа булып сенә иде... Тик бәгъзе башкалар да йоклап ятмаганнар икән (алар бездән күпкә алданрак, планлаштырып, әзерләнгән булып чыктылар), безнен чиста, саф, кешелекле, кешене кеше итеп тәрбияләргә чакырып язылган әсәрләребезгә каршы ялтыр тышлы, кара-пычрак эчтәлекле китаплары карурман кебек тезелеп басты. Кибетләрне генә түгел, бөтен урамны каплап алды. Аннан олыларнын, балаларнын кулларына, зиһен капчыгына күчте. Элеккеге СССР һәм хәзерге Россия халыкларын "янача тәрбияли" башладылар. Телевизоры, радиосы, ата торган, ота торган һәртөрле автоматлары, гәжитләре-журналлары, тәмәкеләре, аракылары-сыралары, рекламалары—һәммәсе бер булып, тыгыз стартка бастылар да, килепме-киләләр безнен бичара халык өстенә, тәгәрәтеп кенә калдыралар мескенкәйләрне! Бәнданен аракы дингезе эчендә батмыйча йөзә алганы, автоматны үз кулларына ала алганы бизнесмен булды... Калды башка халык сасы дулкын астында, инде тыпырчынмый да, күнегеп, ынгырашып кына ята...

Шул ялтыр китапларны һәм башка нәрсәләрне дә безнен хатын-кызларыбыз сата. Дөньяда татар китаплары да барлыгын аларнын ишетәселәре дә килми, алар яна хуҗаларга хезмәт итәләр. Болар—совет заманындагы манкортлардан да яманрак, куркынычрак. Болар—хуҗанын колы, акча колы.

Глобализация дигән шаукымнын тарафдарлары безнен җирлектә, безнен өчен бик куркыныч максат куеп эш итәләр. Әйткәнебезчә, аларнын уе: әдәбиятнын кешелекле тәрбияви ролен алып ташлау. Менә аларнын максатлары. Изге, бик олы нәрсәгә кул күтәрү ич бу! Нишләрләр икән дип, алар безгә сынау үткәрәләр. Ә XX гасырнын сонгы ун еллыгы башларында безне башкача итеп сынаган булып чыктылар. Ул елларда җөмһүриятебезне Америка һәм Көнбатыш журналистлары сырып ук алган иде, дисәк, ялгыш ук булмастыр, мөгаен. Якут-Саха, Бурәт, Башкортстан, Чувашстан кебек җирләрдә дә алар мыжлап торды. Шулар безнен халык хәрәкәте житәкчеләреннән көне-төне диярлек интервьюлар алдылар. Безнекеләр, суверенитетны гына алыйк әле, без милли, мөселман дәүләте төзиячәкбез, дип саксызлык күрсәттеләр кебек. Безгә әле менә шунын өчен дә бәйсезлек эләкмәде бугай... Бу да зур сәбәп иде. (Нишләптер, без—вак-төяктә, хәтта ки кирәкмәгән урында хәйләкәр, кирәгендә—юк.) Болай сөйләштерү-сөйләттерү сер алу гына булган икән бит! Яратмый икән ич ул Көнбатыш дигән җир мөселманлыкны да, мөселман дәүләтләрен дә! Бу фикерне аларнын бертуктаусыз мөселман илләренә психологик һөҗүм ясап торулары һәм утлы корал белән ташланулары раслый. Безгә карата эшләнгән порнография һәм ерткычлыкны фильмнары аша сеңдерү гамәлләре дә шул бер очтан кылына. Халык-балык "рәхәтләнеп" йөзә пычраклыкта, шакшылыкта... Кая инде безгә, без мөселман, дип кычкыру. Кайда ул безнен мөселманлык? Аракы, сыра дингезендә йөзеп, дунгыз ите һәм колбасасы ашап яткан халык ничек мөселман булсын ди? Нишләп көлке ситуациядә калырга? Оятсыз, вәхши, затсыз аракы белән сырадан авызны чистартыйк әлек, хәләл ризык әзерләргә өйрәник. Аннан сон да әле мин

мөселман дип сөйләнергә иртә. Мөселманлыкның бурычлары катгый: рухи һәм физик чисталык—шуның башы гына. Без мөселман булсак, татар язучылары дәррәү рәвештә түбән инстинкны чагылдырган әсәрләр язарга керешмәсләр иде...

Миллилек ягыннан да татарның хәле мактанырлык түгел. Хәер, бер нәрсә безгә бераз гына өмет тә бирә кебек. Эш шунда ки, үз дәүләтләре булган халыкның да милләт өлеше күп булмый, аз өлеше генә милләт, калганнары халык-балык булыбрак яши. Милләт—ми иләтеннән килеп чыккандыр әле, мөгаен дә...

Ә татарның исә милли җанланыш чорында активлашканнары да менә бүгенге көнгә трагедия-драма, хәтта ки әкәмәт комедияләр дә кичерде инде. Ләкин! Безнең арабызда, күзгә бәрелеп тормасалар да, кыйбланы югалтмаучылар да бар. Аллаһега шөкер, аларның саны бераз күңел тынычлыгы бирерлек. Менә шулар арасыннан сайлап алып, татарның унай, чын мәгънәсендә үзебезнеке булганнарын, һәрбер сүзе күңелгә җылылык бирүче затлар итеп, әдәби сәхнәбезгә—китап битләренә күтәрсәк иде... Чын күңеленнән дин тотучылар да юк дип әйтеп булмыйдыр. Бар шундый гаиләләр: алар дин тота, аларда тәртип, аларда... күңелле. Дин тирәсендә ялагайлар яисә икейөзлеләр дә йөри икән, башкаларыбыз саф булсак, шул булыр иде риядан гына йөрүчеләр белән безнең көрәш.

*Гает гаеп булган чаклар,*
*Ходайга шөкер, үтте.*
*Яшертен укып доганы*
*Чыдарга иде күпме?*
*Гает—гаеп дигәне дә*
*Бүген йөри мәчеткә.*
*Төренгән үзе дә акка,*
*Гүя ап-ак бәхеткә.*
*Кем гөнаһлы, кемнәр хак—*
*Бер Аллаһе ачыклар.*
*Җенгә атланып кайтмасын*
*Динсез яшәгән чаклар.*

Язучылар игътибар итәме икән, Тукай урамындагы дини китаплар сата торган кибеткә керсәң, бер яналык күрәсең: чират торып, ябырылып ала халык дини китапларны. Димәк, безнең геройларыбызның сукмагы шул якта икән. Бу унай фал. Тик, ябырылып ала, дисәк тә, әле бу безнең халыкның барыбер дингездән бер тамчысы гына. Язучы халкының язары шул тирәләрдә аны көтеп торадыр, бәлки...

Тагын икенче бер нәрсәне искә төшерик әле. Каләм иясе белә, чынында унай геройны тудыру барыннан да читен. "Бармактан суырып алып" язсаң, укучыны ышандырып булмый, ә әйткәнебезчә, тормышта унай герой ялтырап, күзгә бәрелеп тормый, аны эзләп табасы шул. Ә менә киресе, ягъни кара як үзе күзгә бәрелеп, чекрәеп, мине яз, дип тора. Аларның рәвешен, образын тудыру да үзеннән-үзе килеп чыккандай. Чөнки кеше күңеле шул кара яклар тудырган рәнҗешләрне бик тиз тотып ала. Язучы да—адәм баласы, аның да әле күңеленең ин нечкәләп яраланучысы...

Дөресен генә әйткәндә, безгә хәзер янәдән Гаяз Исхакый образлары әйләнеп кайтты. Мин әле бирелә, без көтеп-көтеп алган язучының үз әсәрләрендәге образларны гына әйтмим, эш шунда ки, нинди генә башаяк әйләндерелгән шәкелдә булмасын, Россиягә янәдән капитализм әйләнеп кайтты. Шәхси милекчелек булгач, капитализм инде ул, бездә ерткычлыгы гына үзенчәлекле... Ә менә Гаяз Исхакый әсәрләренә кертә әле бүген дә бар. Шуларның берсе—Габдулла Тукай һәм бөек прозаигыбыз үзе тудырган сыгылмалы, чын мәгънәсендәге... татар теле. Моннан ун-унбиш еллар элек Гаяз Исхакый әсәрләрендә тезелеп кенә матур итеп кулланылган сүзләрне тиз-тиз генә кайтара башлаган идек тә, хәлләр үзгәрә дип күрәсең, телчеләребез шым булды... Ул

әсәрләрдәге мәгълүм сәбәпләр аркасында онытылып киткән байтак кына үзенчәлекле сүзләрне актив сөйләм телебезгә кайтармый торып, совет чорындагы дәреслекләрдән укыган татарга аларны аңлау читенгәрәк туры килергә мөмкин. Бүгенге көндә, мәсәлән, йомшак кына әйтелә торган җөмһүрият сүзе урынына янәдән тамакны ерта торган республика әйтелә һәм языла башлады. Әле аңысын да, әйтеп калыгыз әлегә дигәндәй, куркытып торалар...

Прозага караганда шигърияткә җинелрәк кебек тә күренергә мөмкин. Аның сандугачларын, мәхәббәтен, сагыну-сагышларын әрнүле-ачык буяуларда житкерергә зур комачау юк кебек. Чын шигърияткә пычрак та ертлачланып керә алмый, чын булмаганнары—көнлекче гамәле генә. Күңел сизә: бүгенге көндә сюжетлы поэмалар соралып кебек. (Монолог-публицистик поэмаларның роле азая дигән сүз түгел бу, билгеле. Халыкның аңын үстерү өчен—алар кирәкнең дә кирәге.) Сәбәбе дә күренеп тора: укучыны яхшы мәгънәсендә мавыктыру, шигърияткә якынайту мөһим. Бу татар әдәбиятында бер дәвамчылыкны да күрсәтеп торыр иде.

Ә менә иҗтимагый-лирик, фәлсәфи шигъриятнең бурычлары тагын да катлауланыбрак тора: безне—татарны—тагын да дөнья барышыннан, тормыш агышыннан читкә тибәрергә тырышалар. "Юк алар, бөтенләй юк", дигән пәрдә элмәкче булалар. Яхталарга горур эленгән Татарстан әләменен жилфердәп дингезләрне ярып йөрүе дә бер матур истәлек кенә булып калды... Ләкин бәйсезлек өчен көрәшүчеләр—безнең заман геройлары, алар әдәбиятыбызда чагылдыруны көтә... Язучылар ашыкмый... Әллә соң, шул елларда халык тарафыннан ташланган гаеп—язучылар көрәш мәйданында катнашмыйлар дию дөрес булганмы? Тик, мең кат гафу, бөтен язучыларны тоташтан гаепләп булмый. Кемнәрнең кайда булуы бүгенгедәй күз алдында...

Әгәр дә татар әдәбияты турында сөйләп тә, татар авылына бер-ике җөмлә булса да багышламасаң, гөнаһ булыр иде. Менә чаклы авыл безнең төп таянычыбыз булды. Ләкин, хәзер авыл үзгәрде, генә дисәк, бу шулай ук берни дә әйтмәү булыр иде. Төп афәт—авыл деградацияләнә. Бер генә юаныч—татар авыллары башкаларныкына караганда матди яктан отышлырак хәлдә. Ә менә рухи тормыш хакында уйласаң, кычкырып ела. Кайсы гына татар авылында татар китабы сатыла икән? Мәсхәрә дәрәҗәсендәге шундый хурлыкның булганы юк иде әле. Әле ярый, район үзәкләрендә нинди дә бер шәкелдә китап кибетләре ачылгалый башлады.

Авылның бүгенгесен уйлаганда элеккегесен искә төшерергә туры килә. Патша Россиясе заманында безнең авылларда авыл җыеннары булган. Җыен исеменнән мәсьәләләр күтәрелгән, хәл ителгән. Урысларда да булган андый җыен. Урыс интеллигенциясе, авылларга йөреп, алар белән эшләгән дә. Менә хәзер татар авыллары да татар интеллигенциясен көтеп ята. Нәкъ менә шушы җыеннарны оештыру өчен, бер унайдан, авыл халкының эчке дөньясын күбрәк аңларга, белергә бер сәбәп тә булыр иде. Аннан соң бит инде, бәлки әр-яна образлар да туарга мөмкин, унай образ!.. Чөнки, ни генә әйтсәк тә, кире образның безнең өчен кабул итмәстәй икәнлеген бик нык сиздертеп язган очракта да, хәтта күңелне рәнҗеткән вакыйгаларны, хәлләрне тасвирлап әрнеп язган очракта да андый образлар белән кимсенгән халыкны, милләтне генә тәрбияләп чыгарырга була. Безнең үзебезнең империяләр чәчәк аткан чорда да каләм ияләре, нишләптер, гел әрнүле якларны гына чагылдырып калдырганнар... Шулай мескенлек үрнәге алу дәвам итәрме?.. Уеның-чынын бергә кушып әйтсәк, бу бит әле үзенә-үзен мөһер сугу—кодирование дигән нәрсәнең килеп чыгуы да түгелме икән? Ягъни, безнеңчәгә күчерсәк, фәрештәләрнең амин дигән чакларына ялгыш туры килүеме?.. Бер Аллаһе белә, ә күңел сизенә: үз-үзенә гел матурлык, яктылык, яхшылык, иминлек телә, ди. Һәркем шундый теләктә булса, баш түбәсеннән таралган унай, җылы дулкыннар барысы бергә җыелып, кушылып, татарлар өстендә якты аура—дога торыр иде. Бәлки нәкъ бүгенге авыр заманда әдәбиятта нинди дә бер яңа алымны һәм агымны башларгалыйр?..

Китапларда татар теле укытучысының кире образын бирү дә—зыянга.

Укымыйлар, дип зарлансак та, безнен китапларның әле барыбер шактый сандагы укучылары бар. Укыганы укымаганына сөйли. Шуннан зарарлы сүз китә. Туган телебезнең кадере кими. Бигрәк тә совет чорында татар матур әдәбиятында татар теле һәм әдәбияты укытучысынын кире образын бирү модада иде... Чынында, тормышта, алай түгел. Мәсәлән, еш кына сыйныфташларның чыгарылыш кичәләре өчен, яисә, еллар үтеп, шул сыйныфташларның очрашу тантанасына дип, шигъри шәкелдә матур сүз әйтергә ярдәм итүне үтенәләр. Үтенүче укытучылар исемлеген бирә, кайсының нинди фәннән укытуын терки һәм кырыена плюс билгеләрен тезә, ягъни мактау сүзләрен кайсына... күпме әйтергә. Шунда шатлык биләп ала: татар теле укытучысы исеме турысына иң күп плюслар куелган! Үрнәк алып яшәде безнең халык татар теле—туган тел укытучыларыннан. Һәрхәлдә моңа чаклы шулай булды. Менә хәзер шул биеклекне саклау өчен бергәләп көрәшү сорала. Бу гамәл татар теле һәм әдәбияты укытучыларының үзләре өчен генә кирәк булганга түгел, ә гомумән халкыбызны тәрбияләү өчен мөһим. Укытучылар—татар әдәбиятын халыкка җиткерүдә иң ышанычлы күпер...

Без Финляндиядә 1972 елда ук булган идек. Анда яшәүче безнен татарлар: "Безгә әшәке фильмнар Һолландиядән, Даниядән килә",— дип зарланганнар иде. Ә югары сыйныф укучысы татар кызы Тинәт: "Мин табиблыкка укыячакмын, наркоманнарга терелеп аякка басарга ярдәм итәсем килә",— дигән иде. Без аларның сүзләрен бөтен тирәнлеге белән ул чакта анлап та бетермәгәнбездер, бәлки. Безгә ул вакытта наркоманнар, спид һәм башка шуның ише нәрсәләр башка бер планетадагы хәлдер кебек тоела иде. Тик шунысы билгеле: мөселман динен тотуны беркайчан да ташламаган безнең андагы кардәшләребез үзләре өчен түгел, башкаларны уйлап борчыла иде. Мөселман дине белән бергә кулга-кул тотынышып, ул илдәге туганнарыбызны татар теле дә саклашты һәм саклаша.

Бу хәлләр шуңа да искә төште әле, дөньяның безнең өскә ташлаган бүгенге афәтеннән котылуның башка юлы юктыр да шул: дин, туган тел, туган әдәбият. Менә шуна күрә дә бүгенге әдәбиятның геройлары кем булуы бик мөһим дә. Шуңа күрә "Казан утлары" журналының "Безнең заман герое" дигән дискуссияне оештыруы күркәм эш. Үзләренең фикерләре белән уртаклашкан Рәфыйк Шәрәфиев, Радик Фәизов, Рәшит Фәтхерахманов, Әхмәт Рәшитов, өлкән әдәбиятчыбыз Рафаэль Мостафиннарның борчылуларын бөтен күнелен белән анлыйсың, фикерләрен уртаклашасың, безгә килепябешкән бу катлаулы хәлләрдән чыгу юлын да үзенчә күз алларга тырышасың. Миңа калса, бу дискуссия Рөстәм Зариповның реплика-мәкаләләреннән үк башланды бугай әле... Ә иң кызыгы: әдәбиятыбыз язмышы турыдан-туры язучыларыбыз кулына калуы. Өстән бернинди күрсәтмә бирүләр, төртеп күрсәтүләр юк ич инде. Менә без хәзер тулысы белән азат каләм әһелләре... Хәзер, кысалар, дип зарланыр урын юк... Хәзер менә җиң сызганып халкыбыз өчен эшләргә генә калды... Бирсен Ходай!

*Хәтер*

**Лирон Хәмидуллин,**

*1967-1983 елларда СССР Литфондынын Татарстан бүлеге директоры.*

# СССР ӘДӘБИ ФОНДЫНЫҢ ТАТАРСТАН БҮЛЕГЕ

Мәгълүм ки, СССР Әдәби фондын оештыру турындагы карар СССРда яшәүче язучыларнын Беренче съездында, 1934 елнын августында кабул ителә һәм шунда ук аның дәүләт оешмалары тарафыннан хупланган Уставы да раслана. Әдәби фонднын (сөйләм телендә—"литфонд") төп максаты—язучыларга унайлы иҗат шартларын тудырудан гыйбарәт. Ул фондка (бабаларыбызчарак итеп әйтсәк—вакыфка) язучынын тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту, сәламәтлеген саклау, иҗат итү мөмкинлекләрен булдыру һәм иҗтимагый-сәяси белемен үстерүгә булышу бурычлары йөкләнә. Фондка тупланасы акчаны исә язучының "иҗат җимеше"н товарга әйләндерүче оешмалар—китап-журнал нәшриятлары, театрлар, концерт заллары хөкүмәт карары белән расланган бер күләмдә (хезмәте өчен автор алган "каләм" хакынын ничәдер процентына тин рәвештә) күчерергә тиеш була. Фонд шул керемнәр исәбенә яши.



*Татарстан язучыларының Әдәби фонд директоры Л. Хәмидуллин язучылар алдында чыгыш ясый. Уңнан сулга—Лирон Хәмидуллин, Нури Арслан, Риза Ишморат, Тихон Журавлев, Авзал Шамов. 1974 нче ел.*

Уставта бәян ителгәнчә, Әдәби фонд кереме исәбенә СССР Язучылар берлеге идарәсе аппаратын, Мәскәүдәге Үзәк язучылар йортын (ЦДЛ), М.Горький исемендәге Әдәбият институтын һәм анын карамагында эшләүче Ике еллык югары әдәбият курсларын тоту каралган иде. Айлап-еллап уздырылган махсус курс-семинарлар (сценарий авторларынын еллык курслары, сугыш турында, авыл хуҗалыгы һ.б. турында язучыларнын семинар-курслары) эшчәнлеге дә Әдәби фонд кереме исәбенә оештырыла килде. 70нче елларда шушы оешмаларны һәм курсларны "ашатуга" елына уртача 2,5 млн. сум акча тотыла иде. Чит илләр белән эшләү комиссиясенен генә дә еллык чыгымы СССР Әдәби фонды карамагындагы күпсанлы иҗат йортлары чыгымыннан ким булмады. Бу чыгымнарнын бер өлешен "Литературная газета" һәм "Советский писатель" нәшриятынын өстәмә кереме исәбенә каплауны үтенеп партия Үзәк комитетына берничә мөрәҗәгать кабул ителде. (Совет хакимияте дәверендә барлык матбугат органнарынын кереме Үзәк комитет карамагына күчерелде. Мәсәлән, "Казан утлары" журналы гына да шул хисапка һәр елны 450-500 мең сум чамасы керем акчасын күчереп барды. Журнал редакциясе тарафыннан уздырылган әдәби конкурсларда җинүчеләргә дә бүләкне керем исәбенә түли алмыйча, Әдәби фонд өлешеннән бүлеп бирәләр иде.) 1979 елның декабрендә, ниһаять, иң югары дәрәҗәдә кабул ителгән карар нигезендә СССР Язучылар берлеге идарәсе аппаратын тотуга каралган ярты миллионлык чыгымны каплауны "Литературная газета"га йөкләделәр. Шушы саннардан күренә ки, Әдәби фондка аерым бер

язучының тормышын-көнкүрешен уңай якка үзгәртергә омтылудан тыш башка төр зур бурычлар да йөкләнгән була.

Россиядә хәйрия җәмгыяте рәвешендәге беренче рәсми "язучылар фонды" унтугызынчы йөзнең алтмышынчы елларында ук та барлыкка килә. Аны И.Тургенев И.Гончаров һ.б. күренекле рус әдипләре (барлыгы җиде кеше) оештыралар. Ләкин алар фондының кулланыш даирәсе тар, кереме дә санаулы гына була. Чөнки ул фондка ярдәм итәргә теләгән язучылар, башка төр меценатлар акчаны үз кесәләреннән чыгарып түлиләр ("спонсорлар" булалар), ягъни ул даими рәвештә тулыландырылып тормый. Ул фондка тупланган акча матди яктан авырлык кичергән сәләтле язучыга яисә билгеле бер оста каләм иясенең фәкыйрьлектә калган гаиләсенә ярдәм итү өчен тотыла. Революциягә чаклы татар дөньясында шуңа охшаш берәр төрле хәйрия оешмасының оешуы мәгълүм түгел.

Совет хакимияте урнашкач, НЭП чорында, мондый үзара ярдәмләшү тәртибе җанланып ала. Ваграк берничә шундый хәйрия җәмгыяте тергезелә. Аннары, 1920 еллар ахырында, ул традицияне рәсми рәвештә оешкан язучылар төркемнәре (эшчеләргә мөнәсәбәтле РАПП, ТАПП яки ирекле карашта торучы Сулфронт һ.б.) дәвам иттерәләр, үз фондларын оештыралар. Шул елларда беренче иҗат йортлары барлыкка килә: Кырымның көнчыгышында, Күктүбә авылы янәшәсендәге рәссам һәм шагыйрь Максимилиан Волошинның һәм Мәскәү өлкәсенең көнбатышында, Руза елгасы янәшәсендәге әдип Александр Серафимовичның дачалары шул максат өчен сатып алына. (Мәскәүдән 60-70 чакрымдагы "А.Серафимович исемендәге Малеевка иҗат йорты"нда 1931 елның көзендә Хәсән Туфан белән берничә язучының иҗат итеп ятулары турында истәлекләр бар. Аларның шунда бергә төшкән фоторәсемнәре дә матбугатта басылды.)

СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге 1934 елда ук оештырыла. Аны барлыкка китерүдә Язучылар берлеге идарәсе рәисе Кави Нәҗми актив катнаша. СССР Әдәби фондының урындагы вәкиле ("уполномоченные") вазифасын үтәү К.Нәҗминең якын танышы, элекке хәрби Закир Самитовка тапшырыла. (70нче елларда Самат Шакирның Гражданнар сугышында милли батальон комиссары булган З.Самитовка багышлы әдәби очеркы басылды.) Хәрби тәртипкә күнеккән З.Самитов йөкләнгән бурычны бик тырышып үти: нәшрияттан, театрлардан кергән акча исәбенә барлык язучы гаиләләренә утын, күмер китертә. (Гомәр ага Бәширов сөйләвенчә, ташкүмер тутырылган капчыкларны йөктән үз җилкәсенә салып та ташый торган була.) Югары Ослан авылында шәхси йортларда "бүлмәләр арендалап", "Язучылар дачасы"н оештыра. Әдәби әсәр язудан аргач, язучылар иркенләп ял да итсен дип, берничә көймә һәм кечерәк бер катер сатып ала. (Югары Ослан дачаларында язучыларның ничек эшләүләре һәм ял итүләре турында истәлекләр булгалады. Шул исәптән Муса Җәлил белән бергәләп Шота Руставилинең "Юлбарыс тиресен ябынган батыр" дастанын Идел өстендә "литфонд көймәсендә" йөзгәндә күмәкләп тәрҗемә итүләре турында да хәбәрләр булды.)

Әмма ләкин Закир Самитовның язмышы фаҗигале тәмамлана. 1937 елда аны Кави Нәҗми белән бер вакытта кулга алалар. Хатыны, мәрхүмә Зәйнәп апаның һәм кызы Розаның (Казанда, Татарстан урамындагы йортларның берсендә яши) сөйләүләренчә, З.Самитовның төп гаебе: К.Нәҗмигә якынлык һәм Ялтада дәваланып ятучы авыру Галимҗан Ибраһимовка ярдәм итеп тору, аның белән хат алышуларга мөнәсәбәтле була. Мин Әдәби фондта эшләгән дәвердә 1937-1940 елларга караган "Карарлар кенәгәсе" саклана иде. (1983 елның апрелендә ул "документ"ны яңа бер җитәкчегә тапшырып киткән идем. Ләкин 90нчы еллар урталарында, Язучылар берлеге яна бинага күчкәннән соң кабат эзләсәм дә, аны таба алмадым. Анда ул чор язучылар язмышына, шул исәптән Хәсән ага Туфанга кагылышлы язмалар да бар иде.) Шунда Мәскәүдән килгән вәкил катнашында 1938 елның башында уздырылган бер утырыш протоколы да теркәлгән иде. Ул утырышта З.Самитовның, "кемнәргәдер буйсынып", күп акча тотуы, арендага йортлар, катерлар алуы бәян ителә, шулар өчен ул гаепле дип белдерелә. Билгеле, гаепләнүче үзе утырышта катнашмый. Аның инде ул вакытта атып үтерелгән булуы да ихтимал. Бу документның фәкать гаепнең исәннәр өстенә дә төшмәвен тәэмин итү өчен генә оештырылуы чамалана иде.

З.Самитов 1938 елның гыйнвар урталарында Пелатән төрмәсендә атып үтерелгән.

Зәйнәп Самитова Иске бистә кешеләре аркылы иренен хәлен белгәләп, ашамлык җибәргәләп торган. Һәлак булу көнен һәм төрмәдән чыгарып җирлисе төнне дә ана хәбәр иткәннәр. Тоткыннарны, гадәттә, атнага бер генә чыгарып күмә торган булганнар. Казанның Архангель зиратында ул иренен үле гәүдәсен үзе каршылый, тоткыннарның "күмәк кабере" булган чокырдан ике-өч метрга читкәрәк илтеп җирли. Зәйнәп апа раславынча, шул ук атнада төрмә хастаханәсендә вафат булган Галимҗан Ибраһимовның гәүдәсен дә ире белән бер чанада алып чыгалар. Илленче еллар урталарында Г.Ибраһимовның аклануы турында хәбәр алынгач, аның кайда җирләнүен ачыклау өчен җитди бер комиссия оештырыла. "Әдипнең кайда җирләнүен ачыклау акты"на сугыш алды елларында төрмәдә эшләгән кешеләр, шул исәптән табибә бер татар хатыны сөйләгәннәр белән бергә Зәйнәп апа сөйләгәннәр дә теркәлә. Шул документ нигезендә— шаһитлар күрсәткән "күмәк чокыр" өстенә классик әдибебез Галимҗан Ибраһимов истәлегенә затлы кабер ташы урнаштырыла. Шуннан өч-дүрт адымда гына Закир Самитов каберенә куелган гадирәк бер язулы таш та бар. Ул һәйкәл-ташларны кую чыгымнарын Әдәбият фондының Татарстан бүлеге күтәрде.

Закир Самитов башлаган эшне тиздән шагыйрь Әхмәт Исхак дәвам иттерә һәм ул вазифаны сугышка киткәнче башкара (1938-42). Бүлекнең баш хисапчысы хезмәтен яшь шагыйрь, 1925-1928 елларда "муллалар коткысына бирелеп" "Ислам баласы" кульязма журналын чыгаруда катнашкан Исхак Закиров үти. Соңрак ул сугышта вафат була.

1941 елгы Бөек Ватан сугышы башлангач Татарстанга Мәскәү, Ленинград һ.б. зур шәһәрләрдән завод-фабрикалар һәм анда эшләүче йөз меңнәрчә кеше күчеп килә. СССР Фәннәр академиясе һәм аның кайбер институтлары ике-өч ел дәвамында Казанда эшли. СССР Язучылар берлегенең оешмалары, шул исәптән СССР Әдәби фонды идарәсе эшчәнлекләрен Казанда һәм Чистайда дәвам иттерәләр. Язучылар берлегенә караган "Советский писатель" нәшрияты, "Знамя", "Иностранная литература" һ.б. журнал редакцияләре монда эвакуацияләнә. Бауман урамындагы Матбугат йорты бүлмәләре, шул исәптән Г.Тукай исемендәге клуб бинасы илкүләм танылган язучы, журналистларның һәм аларның гаиләләренең торак йортына әвереләдерелә. Шул дәвердә Язучылар берлегендә һәм Әдәби фонд бүлегендә эшләгән Гази Кашшаф белән Әхмәт Исхак агалар хәтерләвенчә, аларга үз вазифаларын үтәүдән тыш (яу кырындагы сугышчылар белән элемтә тоту, "Совет әдәбияты" журналын вакытында чыгару һәм язучы гаиләләренә ярдәм итәргә тырышу), эвакуацияләнгән язучыларны урнаштыру һәм көндәлек кирәк-ярак белән тәэмин итү бурычы да йөкләнгән була.

Шушы унайдан бер фаҗигале язмышка тукталып үтмичә һич мөмкин түгел. Чөнки аның язмышында Әдәби фонд оешмасының да катнашы бар. Сүз күренекле рус шагыйрәсе Марина Цветаеваның үлеменә бәйле вакыйгалар һәм шул тирәдә "куерган" мәсьәләләр турында бара. Мәгълүм ки, соңгы өч-дүрт атнасын ул Татарстан җирендә уздырган. Хәзер аның ул көннәренә һәм үлеменә карата төрле хәбәрләр таратыла. Шулар арасында уйдырмалары да бихисап. Элегрәк елларда хәтта татар халкына карата әйтелгән гайбәт сүзләрен дә ишеткаләргә туры килгаләде. Кайбер "кумирлары": "Татары убили ее",—дип әйткаләүдән дә тартынмадылар. Янәсе, Алабугада "татарлар аны эшкә урнаштырмаганнар". Әйе, М.Цветаева да сугыш афәтеннән качып килеп, Татарстанга сыенган йөз меңләгән качакның берсе була. Татарстан җиренә ул Мәскәү Язучылар оешмасы вәкилләре белән бергә эвакуацияләнеп килә. Ләкин аны "үз" каләмдәшләре бөтенләй дә үз итеп бетермиләр. Чөнки ул да бит элегрәк Совет хакимиятен үз итеп бетермәгән, чит илгә киткән була. Утызынчы еллар ахырында гына Мәскәүгә әйләнеп кайта. 1941 елның җәендә Мәскәүне бер корабта ташлап киткән язучыларның күпчелеге Чистай каласында тупләнә (язучылар саны гына алтмыштан ашкан, һәрберсенең гаиләсе, ә кайберләренең әле "домработница"сы да бар). СССР Әдәби фонды җитәкчелеге дә шунда урнаша. Ә кечерәк дәрәҗәле ваграк төркемнәрне Алабуга, Бөрсет һ.б. тирәләренә озаталар. М.И.Цветаева уналты яшьлек улы белән Алабугага эләгә. Әмма Чистай каласына, андагы каләмдәшләре янына баргалап йөри. Чистайда эшли башлаган СССР Язучылар берлеге оешмаларына эш сорап мөрәҗәгать итә. Андагы бер түрә әдиптән "Һич югы литфонд столоваенда савыт-саба юарга булса да алу"ын үтенә. Ләкин аны беркая да эшкә алмаганнар. Шуннан кайткач та шагыйрә асылынып үлә. Аны шәһәр зиратының бер почмагына

жирлиләр. (Дин-йолалар үзенә "кул салучы"ны зиратка кертмәү ягында бит.) 60нчы еллар урталарында, М.И.Цветаева иҗатына әһәмият бирелә башлаган бер вакытта, аның каберен табу һәм истәлек ташы кую мәсьәләсе кузгатыла. Бу хакта СССР Язучылар берлеге идарәсенең махсус карары чыга. Шул карар нигезендә комиссия төзелә. Аның эшендә Алабуга шәһәре җитәкчелеге дә катнаша. М.Цветаеваны күмешеп йөргән, аның белән аралашкан кешеләр барлана. Шулар сөйләгәнгә нигезләнеп кабер урыны билгеләнә, шул хакта "ачыклау акты" төзелә. 1967 елның декабрь башында Казанга Мәскәү вәкиле килде (исем-фамилиясен оныткан мын инде, Язучылар берлегенең шул замандагы кечерәк бер түрәсе иде). Татарстан Язучылар берлеге идарәсе җаваплы секретаре Зәки Нури, әлеге вәкил һәм мин шәһәрнең Коммуналь хуҗалык җитәкчелеге карамагына бардык, фаҗигале үлем белән үлгән күренекле рус шагыйрәсе каберенә куярга лаек булырдай затлы кабер ташы табышып бирүен үтендек. Ул елларда затлы кабер ташын табуы бик тә читен иде. Икенче көнне безгә андый ташны күрсәттеләр - алсурак төстәге матур гранит иде ул. Мәскәү вәкиленә таш ошады. Аңа нинди сүзләр язасын күрсәтеп, билгеләнгән акчаның тиз арада Казанга күчереләсен белдереп, вәкил китеп тә барды. 1968 елның җәендә ул ташны Алабуга зиратына илтеп урнаштырдык. Машинада аны ул вакыттагы яшь шагыйрь Зөлфәт озата барды. Ташны урынына кую эшләрен Алабуга шәһәре идарәсе башкарды. Шулай итеп, элек Татарстанга бәйләнеше булмаган, хәтта ки шигырьләрендә татар халкына карата берничә мыскыллау сүзе кулланудан да тайчынмаган күренекле рус шагыйрәсе безнең изге җиребездә җирләнде. Аны олылап без кабере өстенә затлы истәлек ташы куйдык. Урыны җәннәттә булсын.



*Татарстан Язучылар берлеге һәм язучыларның Әдәби фонд хезмәткәрләреннән бер төркем. 70 нче еллар ахыры.*

Сугыш алды елларында Әдәби фонд бүлеге карамагында клуб ачыла. Китапханә оештыру турында карар кабул ителә. Алар өчен Бауман урамындагы Матбугат йортының 5нче катында махсус бүлмәләр арендага алына. Татар әдәбиятында, татар матбугатында еш телгә алынган, 1950-1990 еллар аралыгында әдәбият сөючеләрнең яратып йөргән урынына әверелгән Г.Тукай исемендәге язучылар клубы иде ул. Литфонд акчасына җан асрады. 50нче еллардан башлап клуб мөдире вазифасын шагыйрьләр Маннур Саттаров, Гөлшат Зәйнашева, аннары Котдус Дәүләтшин, Лариса Сәйфуллина (1965-76), Әхмәт Рәшитов (1976-86) башкардылар.

Әдәби фонд штатында булган Язучылар китапханәсе рәсми рәвештә 1946 елда ачыла. Китапханәнең беренче мөдире Нәфисә Сүнчәләева була шикелле (1939-48 елларда ул Язучылар берлегендә башка эшләр дә башкара). Анардан соң эшләгән ханымның исем-фамилиясе хәзер истән чыккан, 50нче еллар ахырында аның Педагогия институты китапханәсенә күчүе генә мәгълүм. Аннары шактый вакыт анда Гасимә Гобәйдуллина-Вәлиуллина (1960-69), Шәһидә Максудова-Ахунова (1969-83), Римма Миннуллина (1983-2004) эшләделәр. (90нчы еллар урталарыннан мөдиргә эш хакын Язучылар берлеге идарәсе түли башлады.) 1968 елдан китапханәгә башкорт телендәге "Агыйдел"дән кала тугандаш төрки телдә чыгучы тагын берничә журнал алдырылды (казакъча "Жулдыз", үзбәкчә "Шәрык юлдузы", кыргызча "Ала-тау"). Ләкин язучылар алар белән кызыксынмады диярлек (Н.Арслан, Ә.Исхак, Н.Исәнбәттән тыш). Шул сәбәпле аларны алдыру туктатылды.

Сугыштан соң СССР Әдәби фондының Татарстандагы вәкиле итеп язучы Халикъ Садри билгеләнә(1945-1954). Олы яшьтә булуына карамастан ул сугышта катнаша, полк комиссары була. Яралана. Кызыл Йолдыз һәм Икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә. Сугышка кадәр ун ел чамасы "Спартак" аяк киемнәре

фабрикасы директоры була. Димәк, абруйлы, тәҗрибәле җитәкче. Әдәби фонд эшчәнлеген дә тиз җайга сала. Бигрәк тә Язучылар берлеге идарәсе башлыгы Гомәр ага Бәширов белән бик килешеп эшлиләр. Язучыларның иҗади активлыгына куәт өстәү максатыннан чыгып, кечерәк бер иҗат йортын төзү кирәклеген Мәскәү белән үзебезнең Республика җитәкчелеге алдында дәлилләп чыгуга ирешәләр. Ул елларда барлык Союздаш республикаларда да шундый йортлар ачыла (Әзәрбайҗанда—"Шүвәлән", Әрмәнстанда—"Севан", Үзбәкстанда—"Дүрмән", Киев янәшәсендә—"Ирпень" һ.б.) Сугышка чаклы Татарстанда—Тәтеш шәһәре янында, алпавыт Молоствовларның элекке утарында да шундый бер иҗат йорты эшләп килгән. Турыдан-туры Мәскәүгә буйсынган булса да, татар язучылары да анда барып иркенләп эшләп һәм, режимлы ашау-эчү оештырылганлыктан беркадәр савыгып, ял итеп кайта торган булганнар. Сугыш башлану белән анда яралыларны савыктыру пункты ачыла һәм инде кабат СССР Әдәби фонды карамагына кайтарылмый. Тәтеш янәшәсендәге иҗат йортында җәмгысы унбишләп эш бүлмәсе була. 1954 елда шул чамада ук эш бүлмәсе булдыруга исәп тотылган Иҗат йортын ачуга рөхсәт алына. Республика җитәкчелеге ярдәме белән аны 1955 елда төзеп тә бетерәләр. Анда өчәр бүлмәле һәм верандалы дүрт җыелма фин йорты, алты бүлмәле һәм иркен ике верандалы зур бүрәнә йорт һәм алты почмаклы бүрәнә ашханә биналары төзелә. Шул рәвешле Казан үзәгеннән унсигез чакрымда, Аккош күленнән ике чакрым чамасы төньяктарак булган бер урында язучыларның "Аккош күле иҗат йорты"на нигез салына. (Хәзер анда язучыларның күмәк бакчачылык ширкәте.) Аларны Халикъ Садри төзетә башлый, ләкин ачу тантанасында катнаша алмый инде, 65 нче яшендә вафат була. Төзелеш барышында анда комендант вазифаларын шагыйрь Нәби Дәүли башкара. Сугышның беренче көннәрендә үк дошман тарафыннан әсир ителгән, шул сәбәпле рәсми хакимият вәкилләреннән генә түгел, кайбер каләмдәшләреннән дә битәрләү сүзләре ишеткәләп яшәгән Нәби абыйга бу эш ошап куя. Кыш дәвамында урман аланында ялгыз яткан озын төн-көннәрендә ул тынычлап иҗат итә, булачак шигырь китапларыннан тыш, "Яшәү белән үлем арасында" повестының караламасын язуга да керешә. Атналык ризыкны аңа Казаннан язучылар берлеге шоферы Майшакәр белән "Литфонд" җитәкчелеге китереп торалар. Х.Садридан соң бүлек җитәкчесе булган Сөнгать ага Сафиуллин (1955-1964) хәтерләвенчә, ул елларда Аккош күле тирәсендә бушлык булган, юл бик начар чистартылган. Майшакәргә еш кына кар көртләрен ерып барырга туры килгән. "Сугыш юлларында да машина йөрткән чая хатын, өстәвенә Нәби дигәндә утка керергә дә әзер иде. Шул рәвешле без Нәбине кыш буе бәрәнге белән икмәктән өзми яшәттек",—дип сөйләр иде Сөнгатулла абый.

Нәби Дәүли төзелеш беткән көннән башлап вафатына чаклы (1989, май урталары) җәй айларында шунда яшәде, иҗат итте. Ашау-эчүле һәм көнкүреш хезмәте күрсәтүле тулы мәгънәле Иҗат йорты буларак төзелсә дә, ни сәбәпледер аны язучыларга арендага бирешле "дача"лар рәвешендә калдыралар. Ашханә өчен дип төзелгән аерым йорт идарә рәисе Г.Бәширов гаиләсенә бирелә. (Бер үк вакытта Гомәр ага утыз биш ел чамасы "дача" коллективының рәисе дә булды.) "Аккош күле иҗат дача"сының беренче арендаторлары күренекле язучылар Нәкый Исәнбәт, Афзал Шамов, Фатих Хөсни, Хәсән Туфан, Абдулла Әхмәт, Салих Баттал, Гали Хуҗи, Галимҗан Латыйп, Зәки Нури, Сафа Сабиров, Мария Елизарова, Алексей Талвир булалар. Шәүкәт Галиев, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Нил Юзиев, Ренат Харис кебек яшьрәк буын вәкилләре дә анда җәйләрен җиләк-җимеш үстереп һәм иҗат итеп яшиләр. Җәен-кышын шунда торучылар да булгалый. Башлангыч чорда Габделхәй Сабитов гаиләсе, 70нче елларда исә булачак Г.Тукай бүләге лауреаты, шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов гаиләсе кыш айларында да яшәделәр. Илленче еллар ахырында "литфонд" йортларыннан бер почмактарак Ибраһим Гази белән Сибгат Хәкимнәрнең хосусый йортлары төзелә. 70нче еллар ахырында аларга өчәр бүлмәле тагын ике литфонд йорты өстәлде. Дөресрәге, җыелма каркаслы шундый өч йорт төзүгә идарә рәисе булган елларда Зәки Нури акча һәм рөхсәт алган иде. Соңрак ул йортларның берсе язучыларның Васильево бистәсе янәшәсендә алынган яңа бакчачылык ширкәтенә күчереп төзелде. Төзелеп беткәч тә анда янарак кына Тольятти шәһәреннән күченеп килгән шагыйрә Флера Гыйззәтуллина гаиләсе ике-өч ел яшәде.

Төзелештән соңгы елларда "Аккош күле дачасы"нда комендант һәм өч-дүрт

хезмәткәр эшли. Комендант вазифасын берничә ел дәвамында отставкадагы подполковник башкара. 1960 еллар урталарыннан анда комендант-охранник штаты гына калдырыла. "Дача"ларны тотуга СССР Әдәби фонды тарафыннан акча бирелми башлый диярлек. Ибраһим ага Гази Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп сайлангач, 1968 елның августында шушы мәсьәләгә дә ачыклык кертү, "акча сорау" өчен урынбасары Гариф Ахунов белән мине (1967, апрель—1983 апрель аралыгында бүлек директоры булдым) Мәскәүгә—СССР Әдәби фонды идарәсенә җибәрде. Безне идарә рәисе, язучы Варткес Тевекелян кабул итте. "Язучыларның Переделкинодагы дачаларын беләсезме?—дип сорады башта. Уңай җавап алгач:—Анда кемнәр яши, беләсезме? СССРның иң күренекле язучылары,—дип, кайберләренең исемен, дәрәҗәсен санап чыкты.—Секретариатның карары белән хәзер ул дачаны тотуны да чиклибез. Йортларны хосусый милек итеп үзләренә сатып бирәбез. Сезгә дә шулай эшләргә кирәк." Әйе, шактый кырыс сөйләште безнең белән СССР Язучылар берлеге идарәсе секретаре, Әдәби фонд рәисе. "Секретариат карарын үтәү йөзеннән дачаларны бетерү эшенә кагылышлы документлар әзерләнә. Тиздән сез дә аларны алырсыз",—дип ул сүзен тәмам итте.

Ләкин... "Аккош күле дачалары" бетерелми калды. Күпмедер вакыттан соң Тевекелян вафат булды. Җитмешенче еллар башында аның вазифасын үтәү күренекле кабардин шагыйре Алим ага Кешоковка йөкләнде. ( Шуны да әйтеп үтим, Мәскәүгә барган саен ул Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов агаларга сәлам әйтеп җибәрер, аларның хәл-әхвәлен сорашыр иде. Беренче танышу вакытында бугай, мин ана Муса Җәлил белән Габдулла Тукайның русча чыккан китапларын бүләк иттем. Тукай китабын актаргалап карады да, әйтә бу: "Тышлыгына "Тукай" дип язылган, шагыйрь үзе менә монда "Тукаев" дип язган". Шулай дип ул шагыйрьнең гарәп хәрефләре белән куелган имзасын күрсәтте. Аннары Кавказ таулары арасындагы бер мәдрәсәдә укыганда ук "Тукаев" шигырьләре белән таныш булуын сөйләде.)

1964 елның беренче гыйнварыннан бүлекнең статусы, ягъни мөстәкыйльлек дәрәҗәсе бераз күтәрелә һәм вәкил урынына директор вазифасы кертелә. Язучылар берлеге идарәсе карары белән директор итеп Хәсән Сарьян билгеләнә. Ул 1965 елның декабренә кадәр эшли. Күләмле "Нокталы өтер" повестен яза башлавы сәбәпле эштән китә. Декабрьдә аны икенче бер прозаик—Мәсгут Шәрифуллин алыштыра. Ләкин ул да озак эшли алмый—заманыбыз зәхмәте—ашказаны яман шеше аның гомерен өзә. Шуннан соң ул вазифаны үтәүгә мин алындым. Дөрес, идарә рәисе Мирсәяф ага Әмиров чакырып, эшкә алынырга күндергәч тә әле тиз генә аңа тотына алмадым. Ярты ел дәвамында мине элекке эшемнән җибәрмичә интектерделәр—дүрт мең чамасы кеше эшләгән коллективта партком секретаре идем. Литфонд бүлеге белән иң озак җитәкчелек итүче саналам. Шул дәвердә башкарылган кайбер эшләр турында алдарак сүз булыр. Миннән соң идарә иткән язучыларны да санап китәм: Әхмәт Гадел (1983-84), Ренат Вахитов (1984-86), Ләбиб Лерон (1986-88), Шаһинур Мостафин (1988-92), Рафис Корбан (1992-94), Мансур Шиһапов (1994-96), Данил Салихов (1996 елдан башлап).

СССР һәм 1959 елдан оеша башлаган РСФСР фондларының үз идарәләре булды. Автономияле республикалардан беренче буларак бездә дә Литфонд идарәсе 1963 елдан бирле эшли. Аның җитәкчесе итеп Язучылар берлеге идарәсе әгъзасы, әзмекүпме хуҗалык, җитәкчелек эше белән таныш булган абруйлырак бер язучы сайлана иде. Хезмәт хакы алмыйча, җәмәгать тәртибендә эшләгән шундый рәисләрнең исемлеге: Афзал Шамов (1963-79), Азат Әхмәдуллин (1979-92), Әхсән Баян (1992-99). 1999 елдан Әдәби фонд бүлеге рәисе итеп Язучылар берлеге идарәсенең элекке рәис урынбасары Гәрәй Рәхим сайланды. Төрле елларда РСФСР Әдәби фонды идарәсе әгъзасы булып торучылар: А.Шамов, Л.Хәмидуллин, М.Хәбибуллин. СССР Әдәби фонды таркалгач (90 нчы еллар башы), аның вазифасын Халыкара Әдәби фонд башкарырга алынды. Аның 1992 елгы оештыру пленумында элекке СССР Әдәби фонды бүлекчәләреннән Әзәрбайҗан, Казакъстан, Ленинград, Кыргызстан, Әрмәнстан, Грузия һ.б белән бергә Татарстан вәкилләре дә катнашты. Халыкара Әдәби фонд идарәсендә бүгенге көндә Гәрәй Рәхим әгъза булып тора.

Татарстанда яшәүче язучыларның иҗатына булышлык итү, тормыш шартларын яхшыртуга юнәлтелгән нинди эшләр башкарылды соң? Алда Халикъ ага Садри

эшчәнлегенә бәйле рәвештә "Аккош күле иҗат дачасы"на кагылышлы вакыйгалар беркадәр бәян ителде. Казанда өйләрне мич ягып җылыту заманнарына караган бер эпизод та телгә алынган иде. Язучы гаиләләрен ягулык белән тәэмин итү бурычы литфонд җитәкчелеге тарафыннан 70нче еллар башына чаклы үтәлеп килде. Күп утын таләп ителгән "убырлы мичле" өйләрдә ин соңгы яшәүчеләр Әмирхан Еники белән Хәсән Сарьян булдылар. Әмирхан аганы Достоевский урамындагы шактый иркен үз өеннән 1968 елның көзендә күчердек. Ул баштарак "казна" йортына күчүгә бик каршы булды. Хәтерлим әле, язучылар оешмасында профсоюз эшен башкаручы Сарьян белән мина ул мондыйрак тәкъдим дә әйтеп карады: *шәһәр хуҗалыгына минем йорт урыны кирәк икән, мина алар якын тирәдән шундый ук урын сайлатырга һәм өй салып бирергә тиешләр. Шуна ничек ирешергә?* Ул елларда Казанда шәхси йортлар төзү тыелган иде. *"Ә Нурихан төзеде бит әнә",—ди* аксакал әдип. Нурихан Фәттахның шәхси йорт төзергә рөхсәт алып йөрүләре Сарьян литфонд директоры булган чорга туры килә иде. Шуна ирешү өчен Нуриханның элекке сабакташы булган Республика җитәкчесенә ялынып йөрү вакыйгаларын сөйләп биргәч кенә Әмирхан ага үзенә аерым утар-йорт төзетү фикереннән кайтты шикелле. Шмидт урамындагы "казна" фатирына да без аны Сарьян мәрхүм белән бергә күчерешкән идек. Шул хезмәтем өчен ул мина илленче елларда кулдан ясалган бик зур бер китап шкафы бүләк иткән иде. Ләкин, өйдә аны сыйдырып булмаганга күрә, байтак еллар мин аны Аккош күле дачасы сараенда тоттым. Шуннан соң гына үз бакчама алып китеп, ике өлешкә бүлеп, астын верстак итеп куллана башладым. Әмирхан ага бервакыт мина Достоевский урамындагы йорт күршесенең "Рәшә" повестындагы баш каһарман чалымнарына ия булуын да сөйләгән иде. Ул инженер шул елларда бер зур заводның абруйлы директоры булып эшләде.

Өйләр, йортлар турында сүз чыккач, Әдәби фонд тарафыннан язучыларның торак мәсьәләсен хәл итү эшчәнлегенә тулырак тукталыйк. Сугыштан соңгы дәвердә СССР әдәби фонды бүлекләргә акчаны рәсми теркәлгән язучылар санына нисбәтләп бүлеп бирә иде. Шуна урындагы Язучылар берлеге төзегән исемлеккә карап ( ә ул әгъза булып торучы язучылар саныннан артмаска тиеш) яшь иҗат көчләре белән эшләү өчен дә беркадәр өстәлә (Хрущев заманында кабул ителгән акча белән ул кеше башына 15-20 сумнан артмас иде). Вафат булган язучы гаиләсенә ярдәм итү өчен дә шул ук нисбәттә акча бирелә иде. Смета төзегәндә ел саен ул исемлекләр Мәскәүгә җибәрелеп торды. Әгәр шәһәр һәм республика җитәкчеләре яна төзелә торган йортлардан түләүле фатир алуга рөхсәт кәгазьләре бирсә (үндүрт имзалы, уңлап битле "документ") һәм шуны вакытында Мәскәүгә илтеп тапшырсан—СССР Әдәби фондының язучыларга фатирлар булдыру өчен өстәмә акча бирүе дә ихтимал иде. Мондый мөмкинлектән бигрәк тә Зәки Нури белән Гариф Ахунов Язучылар берлегендә җитәкче булганда еш файдаландык.

СССР Әдәби фонды исәбенә ин беренче булып мул итеп фатир алу бәхетенә безнен язучылар 50 нче еллар ахырында ирешә—Гомәр ага Бәширов Язучылар берлеге идарәсе рәисе, СССР Язучылар берлеге идарәсе секретаре һәм СССР Югары Советы депутаты булган вакытта. Тимерюлчыларнын Маяковский урамында төзелгән 5 катлы кирпеч йортында берьюлы сигез зур өй түе була: анда Г.Бәширов, М.Әмир, А.Шамов, Х.Туфан, Ф.Хөсни, Ә.Исхак, Г.Әпсәләмов, Т. Журавлев гаиләләре күчenә. 60-70 нче елларда Мәскәүдән алынган акча исәбенә язучыларга елына ким дигәндә 3-4 фатир бирелә килде. Шул максат өчен СССР Әдәби фондыннан соңгы акча 1983 елда алынган иде. Ул вакытта инде республикада торак мәсьәләсе җинелрәк хәл ителә башлады шикелле, "горплан", "госплан", "Татстрой", шәһәр идарәсе оешмаларына йөреп, имза-документлар җыеп мәшәкатьләнәсе калмаган иде, ахрысы.

Дисталәгән татар язучысы ел саен төрле өлкә һәм Союздаш республикаларга булачак әсәрләренең геройлары белән очрашуга яисә материал тупларга дип командировкага барыр иде. Шул ук максат белән ун-унбиш көнгә үз районына яисә авылына литфонд исәбенә кайтып килүчеләр саны тагын да күбрәк булды. Сирәгрәк кенә чит илләргә дә Әдәби фонд исәбенә йөргәләүчеләр булды. Анын өчен нинди максат белән баруынны дәлилләп Язучылар берлегенә гариза язу һәм берлек идарәсенен рөхсәтен алу гына кирәк иде. "Муса" романын язар алдыннан Шәйхи ага Маннур Германия Демократик Республикасына, В.И.Ленинның Польшадагы тормышын чагылдыручы очеркларын

әзерләгәндә Зәки Нури Польшага, "Сызгыра торган уклар" романын язарга керешкәч Нурихан Фәттах Монголиягә барып кайттылар. Рафаэль Мостафин, Сибгат Хәким, Әминә Җәлил һ.б. М.Җәлилгә һәм Җәлилчеләргә бәйле истәлек-хатирәләр барлау, яңа материаллар туплау өчен дип литфонд исәбенә ике-өч мәртәбә шулай ук Берлинга барып кайттылар. Рөстәм Кутуй, Габдерахман Минский, Алимә апа Кутуева Гадел Кутуй каберенә зиярәт кылу ниятеннән шулай ук Польшага бардылар. Төрле делегацияләр белән чит илләргә йөрүче язучылар да Әдәби фонд акчасына баралар иде. Хәтта чит илләргә Язучылар берлеге юлламасы белән турист рәвешендә баручыларның да юл чыгымының бер өлешен литфонд каплый иде. Безнең язучылардан андый сәяхәтләрдә Җәвад Тәрҗеманов, Хай Вахит, Сажидә Сөләйманова, Аяз Гыйлаҗев, Гәрәй Рәхим, Мөхәммәт Мәһдиев, Мәдинә Маликова, Әхмәт Рәшит һ.б. бик күпләр булып кайтты. Алар Һиндстанда, Төркиядә, Японлиядә, Гарәп илләрендә һәм Европаның барлык җирләрендә булып, киләчәк әсәрләре өчен мая, фикер тупладылар.

СССР Әдәби фонды тарафыннан финансланган М.Горький исемендәге Әдәбият институтында укып чыгучылар исемлеген Г.Әпсәләмовтан башларга тиешбез. Сугыш алды елларында ул шунда белем ала, бер җәйдә Казанга килеп, икенчесендә Урта Азиягә литфонд исәбенә барып практика үтә. Сугыштан соң әдәбият институтында Әдип Маликов, Рәшит Гәрәй, Габделхай Сабитов, Вахит Монасыйпов, Булат Сөләйманов, Әхмәт Гадел, Роза Кожевникова, Солтан Шәмси һ.б. укыды. 2 еллык Югары әдәбият курсларында белем алучыларның саны иллегә якынлашса кирәк: З.Нури, А.Гыйлаҗев, М.Шәрифуллин, Ш.Галиев, Р.Батулла, Т.Миннуллин, Р.Кәрами, Р.Мингалим, Ризван Хәмид һ.б.



*Әбрар Кәримуллинга 60 яшь тулу уңаеннан Тукай клубында (Бауман, 19) узган кичә. 1985 нче ел, 31 нче май.*

Әдәбият фонды язучының авырган көннәре өчен акча түли, курорт-шифаханәләргә ярым түләүле юлламалар белән дәваланырга җибәрә иде. Язучылар шулай ук СССР Әдәби фонды карамагындагы иҗат йортлары мөмкинлекләреннән дә шактый иркен файдаландылар. (Кара диңгез буенда гына шундый 6 йорт эшләде.) Күпчелеге анда гаиләсе, бала-чагасы белән бара, иҗат та, ял да итеп кайта иде. Татар әдәбиятын баетырдай байтак кына әсәрләр шунда языллы дияргә була. Мәсәлән, Г.Ахунов "Хәзинә" романының башлангыч житмеш битен "Гагра" иҗат йортында язып кайттым дип еш кына искә ала иде. Ә.Еники, А.Гыйлаҗев һ.б.ның матбугатта дөнья күргән хатларында да иҗат йортларында ни-нәрсәләр өстендә эшләүләре бәян ителә.

Бөтенсоюз күләмендә танылган иҗат йортларыннан берничәсе санаторий-шифаханә рәвешендә эшли, язучыларны беркадәр дәвалап та кайтара иде. Мәскәү өлкәсендәге Малеевка, Фин култыгы буендагы (Латвия) Дубулты шундыйлардан булып, аларга башлыча олырак яшьтәгеләр ешрак йөрделәр. Кайбер бик актив иҗат итүче язучылар, мәсәлән Г.Бәширов, Ә.Еники, А.Гыйлаҗев, М.Хөсәен кыш айларында Мәскәү янәшәсендәге Переделкино, Малеевкада айлап, икешәр айлап эшләсәләр, җәен көньяктагы диңгез буендагы иҗат йортларын да үги итмәсләр иде.

Соңгы сүз итеп шуны әйтергә кирәктер, СССР Әдәби фонды җитәкчелеге безнең оешмага карата нигездә уңай фикердә булды. Безнең үтенечләрне үтәргә тырыша иде. 60-70 елларда Әдәби фондның Татарстан бүлеге берничә мәртәбә Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Шәхсән үземә бирелгән шундый ике мактау кәгазе архивымда саклана.

## Нәҗибә Сафина

# КАРА ШИКӘР

### ИСТӘЛЕК-ХИКӘЯ

*Йөрәгемне, татар китабыдай,*
*Ачам уртасыннан—*
*Укыйм дисәм, аннан Альберт Фәтхи*
*Атлап чыгар сыман.*

Мөдәррис Әгъләм.

I

Мин бу серле сәхифәне беркайчан да бәян итмәм дигән идем. Чөнки ул чакта яшьмен, дөнья алсу-зәңгәр буяулар аша күренә. Өстәвенә, социалистик реализм методы белән иҗат ителгән унай геройларны җирдә йөри дип белгән чаклар. Мина унсигез яшь! Мәхәббәт йөрәкне читлегеннән үк чыгарга әйдәгән мәлләр! Һәм мин студент кисәге. Әнә шундый йөрәкне фәнгә буйсындырып, уку залларында көннәр уздырып кара әле син! Монысына да тырыштым ди. Ә менә имтиханда буласы сорауларга җавап табар өчен бирелгән исемлектә бөтенләй дә мин белмәгән имляда язылган китаплар да бихисап булып чыкты. Ә алар исә китапханәнен сирәк китаплар бүлегендә икән.

Шулай беркөн лекцияләргә кадәр (ә без төштән сон укыйбыз) каталоглардан гына торган бүлмәгә кереп, тиешле китапларны сорап алдым да өнсез калдым: мин боларны иҗекләп укып чыкканчы имтихан вакытлары гына түгел, яшьлек үзе үк узып китәчәк ләбаса! Алай гына да түгел, иҗекләп кенә дә укып булмый бит әле. Имля өстендә имля. Кадимчәсе, җадитчәсе...

Үз-үземне кызгануданмы, бу хәлдән чыгу юлын күрмәү авырлыгыннанмы, күзләремнән яшьләр бәреп чыкты. Кычкырып ук елап җибәрүдән үземне чак тыеп, хафалы күзләремне бер кулым белән каплый төшеп, беренче сыйныф баласы әлифба өйрәнгәндәй бер көн утырдым, ике көн... Каталоглар артында үзем генә дисәм, ялгышканмын икән. Ачык көрән төсле костюм кигән бер абый минем янга ук килеп баскан да:

—Әллә бик үк укып булмыймы?—дип сорады, китапларга күрсәтеп.

—Авыррак шул,—дидем мин, аның ни белергә теләвен аңламаган хәлдә.

Ул сак кына минем алдымдагы китапларның исемнәренә күз салды. Сак кына дим, чөнки ул китапны куллары белән тотмый да диярлек. Әллә ничек биләүдәге баланы ачып карагандай гына итә сыман тоелды мина.

—Ә укырга кирәк бит инде, әйме?—диде ул, бу юлы мина сынаулы караш ташлап.

"Берәр укытучыдыр инде, Ходаем",—дип, куркып та куйдым. Бу кадәр дә укый белмәгәнемне күреп торса, имтиханга ук кертмәскә мөмкиннәрдер ич? Абый кеше тагы телгә килде.

—Кая исемлегенне күрсәт әле, Чибәркәй!

Мин йөзләгән китапны эченә алган исемлекне ана суздым. Анын исә бер дә исе китмәде. Шулкадәр китап укыйсын бар икән дә димәде, ә киресенчә, монда әле Ибн Фазлан... тагы әллә нинди китаплар җитми дип санап китмәсенме! Ә аннары, шулай булырга тиеш, дигәндәй генә, минем янга утырды да бер китапны алып салмак кына укый башлады. "Бик мөһим урыннарын язып барсан да ярый...—дигән сүзне ишетүгә мин каләмгә тотындым. Ул укый, мин тынлыйм, язам. Бу көнне каталоглар артыннан без соңгы кешеләр булып чыгып киттек.

Икенче көнне сәгать тугызда мин тагы мәгарәдә идем инде. Берәр сәгатьләп укуга, ул тагы пәйда булды. Китапханәчеләр белән нидер сөйләшеп алды да:

"Катановны кичәге кыз алдымы?"—дип сорады һәм мин утырган өстәлгә таба атлады. Аннан, берни булмагандай, минем белән рәттән утырды да китапны аз гына алдына тартып куйды һәм укуын дәвам итте. Бераздан, кинәт тавышы тынгач, мин аның йөзенә күтәрелеп карадым һәм бигрәкләр юаш кешедер бу, нишләп олы башы белән миңа китап укып утыра икән дип уйлап алдым. Ул өстәлгә кул сәгатен салып куйган икән. Вакытны күргәч, аптырап калдым: ул туктаусыз өч сәгать буе укыган лабаса! Бу кыршылып беткән каешлы иске сәгать бәлки дөрес тә күрсәтмидер? Ләкин стенадагы сәгать тә шул ук вакытны күрсәтә иде. Шулчак аны чәй эчәргә чакырдылар. Тик ул йомышка кергән авыл малае шикелле кыенсынып кына:

—Юк, ни, мин монда гына,—дигән сүзләрне әйтте дә тиз генә урыныннан торып, ике стакан чәйне минем алга китереп куйды. Аннары пинҗәк кесәсеннән нидер эзләгәндәй итте һәм аннан чүпләнеп беткән ике шакмак шикәр алды. Учына салып, чүпләрне өреп очырса да, тузаннан каралган шикәрләр агармады. Тик ул барыбер бер шикәрне миңа сузды һәм бераз елмайгандай итеп:



*Уңнан сулга: Альберт Фәтхи, Хәмид Вәлиди, Тәүфикъ Әйди. 26 апрель 1970 ел.*

—Тәме барыбер шикәр аның,—диде.

Шикәрне кулыма кыстым да кайнар чәйне болай гына эчә башладым. Аның стаканындагы шикәре эрегәч, чәй өстенә юка гына тузан элпәсе чыккан иде. Әмма ул аны күрми дә иде шикелле. Шикәр-кәнфитләр аның кесәсеннән башка көннәрдә дә чыкты һәм мин, инде ничә көннәр бергә китап укып утырганнан соң, беренче тапкыр аннан сорарга булдым:

—Сез укытучымы?

Сорауны ишетүгә ул кинәт тирә-ягына карангалап алды да:

—Тагы кем бар монда?—дип үзе сорау бирде. Мин аптырап калдым.

—Белмим, китапханәче апалардыр...—дидем, җавапсыз калмас өчен генә. Ә ул исә:—Ник алайса күплек санда сөйлисең? Алай булгач, минем турыда гына бара инде сүз. Юк, мин укытучы түгел, мин—укучы, үзен күрәсең ич,—дип, китапларга ымлады.

—Исемем минем Альберт, Нәҗибә,—дип, мине шаклар катырды. Исемемне әйтмәгән дә идем ич, каян белде икән дип, сәерсенеп үк калдым. Өстәвенә, "Нәҗибә" дигән сүзне шундый үз, шундый тылсымлы итеп әйтте, миңа монарчы беркемнең дә алай дәшкәне юк иде шикелле.

Бу сөйләшүдән соң икенче көннәрне минем икеләнебрәк калуымны китапханәчеләр сизде, ахры.

—Альберт абыең озакламый килеп җитәр, укый тор,—дип, исемлектәге яңа китапны сораганчы ук кулга тоттыра торган булдылар. Ә мин үземчә уйлыйм: килсен инде ул Альберт абый, имтиханнарга кадәр укып та өлгерергә кирәк бит.

Шулай өзгәләнеп иҗекләр укып утырган бер иртәдә мәгарәгә өлкәнрәк курста укучы ике егет килеп керде. Болар кызып-кызып ни хакындадыр бәхәсләшәләр. Һәрхәлдә, аларның сүзләреннән мин ниндидер искиткеч вакыйга булганлыгын аңлап алдым. Кемнендер язмышы куркыныч астында шикелле сүзләр дә колагыма килеп ирешкәч, ярымпышылдау рәвешендә генә барган сүзләрен дә ныклап тыңлый башладым һәм Альберт Фәтхи исемен ишетүгә чак кычкырып җибәрмәдем.

Ул—Альберт Фәтхи гаҗәеп зур галим икән. Искиткеч принципиаль кеше һәм галим, чукындырсалар да, үз фикерендә кала һәм хаклыгын исбат итә алырлык мәгълүматы бар икән. Менә нинди кеше мина китап укып утыра икән бит! Әле үзен полиглот та, әллә архивариус, әллә археолог та дип атадылар. Бер кеше өчен бигрәк күп инде бу атамалар. Кыскасы, минем башка гына сыеп бетә торган түгел инде.

Кич тулай торакка кайтсам, студентларның телендә тагы шул Альберт Фәтхи. Бүлмәдән бүлмәгә күчерә-күчерә "Казан утлары"нда чыккан мәкаләсен укыйлар. "Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби багланышлар" дип атала иде ул зур күләмле язма. Чират мина житте. Язманы укый башлауга исләрем китте. Әстәгъфирулла! Безнен Башкортстан турында ич бу!

Әмма... әмма бу фәнни язмага беренче курс студентының теше үтәрлек кенә түгел иде. Минем хәсрәтле башкайларыма бу язманы аңлар өчен тагы дистәләгән мәҗмуга укып чыгу өстәлде. Ул хезмәтләрнең исемлеге Альберт Фәтхи язмасының һәр битендә күрсәтелеп барган икән. Әй, тырышыплар да укыдым инде шуларны! Тик барысының да очларына чыга алмадым. Үз-үземне кыйный-кыйный бу китапларны укуымның тагы бер сәбәбе бар иде: студентлардан, хәтта кайбер укытучылардан да ишетеп калдым: Альберт Фәтхинең шушы "Казан утлары"ндагы язмасы фәнни карьерасына киртә булачак икән. Димәк, нинди дә зур хатасы булырга тиеш инде моның. Әйе, ул чакта шулайрак фикер йөртә идек шул. Әмма мин Альберт Фәтхинең шул хатасын таба алмадым һәм Ибраһим ага Нуруллинга мөрәҗәгать иттем:

—Аның хатасы нидә?

—Бу хезмәт,—диде ул, иреннәрен каклап-каклап чәйни-чәйни,—гасырлар буе төйнәлгән төенне чишә башлау ноктасы, русчалап әйтсәк, точка отсчета булырга тиеш-тиешен... Шулай булмаса, ул төрки кавемнәрнең тамагына утырачак... син әле күрерсен бәлки. Тик бу мәкалә беренче курс студенты өчен катлаулырак, бераз тәҗрибә тупларга кирәк. Син Мөхәммәт абыеңа (Мөхәммәт Мәһдиев) фольклор, үз төбәгеңдәге халык авыз иҗатын җыйнап бирә аласың әлегә—диде.

Шуның белән бу хакта безнен сөйләшү тәмам булды. Безнен генә түгел, гомумән, бу темага сөйләшүләр ничек кинәт башланган булса, шулай кинәт тукталды да. Альберт Фәтхи исемен инде беркем авызыннан да ишетми башлагач, кышкы каникуллардан соң, янадан тиешле китапларны укырга теләп, янә мәгарәгә киттем. Альберт абый атнадан артык мәгарәдә күренмәде. Тик инде килер дигән өмет бөтенләй өзелде дигәндә, ул мәгарәгә килеп керде дә якты итеп елмаеп:

—Әллә инде кирәгем дә калмадымы? Әллә инде бик кызу да укый башладыңмы? Йә! Йә!—дип тезеп китте.

Әгәр дә Альберт Фәтхи атлы галим, күренекле археограф белән язмыш очраштырмаса, ул ярдәмгә килмәгән булса, Ибраһим ага Нуруллин миннән: "Әллә син исемлектәге барлык китапларны укып барасыңмы?"—дип сорамаган да булыр иде.

Ул иске имлядагы мәҗмугаларны укып чыгу бөтенләй мәҗбүри булмаган икән. Фәкать татар теле һәм әдәбияты белгече аларның барлыгын белергә тиеш китапларның исемлеген генә күрсәткән булганнар икән.

Эреле-ваклы ничә дистә китап укыганбыздыр. Тик ул аларның берсенә генә дә аңлатма да бирмәде, бер генәсен дә шәрехләмәде дә. Альберт абыйның бер җөмләсе хәтердә калган: бишенче курсларга житкәндә аңлашыла башлый ул китаплар. Шулай булды да. Ул китапларның әле бүген генә аңлашыла башлаганнары да юк түгел.

Ул чакта аңлашылмаган сәер бер нәрсә тагы шул булды:

—Тагы кайсы көнне керәсен? Кайсы вакытта?—дип һушымны алды,—мин шушында эшлим,—дип тә өстәп куйды.

Менә сина кирәк булса! Ә мин юләр, кешенең вакытын алам дип, уңайсызланып йөргән булам. Укый белмәгән студентларга укып торучы булып эшли күрәсең. Әле урамда очрагач та, кайчан керәсен, кер яме, дип, чакырып

китте. Шул урамда очраганда мин бу абый, мөгаен, бакчадан кайтып килəд дип, уйлаган идем. Чөнки кара көрән жиләненең кайдадыр аунап яткан жирд алып кына киелгәнлеге күренеп тора иде. Шул киеменнән унайсызланыпть ахры, теге вакытта чәйгә чакыргач, ык-мык иткәндәй нидер мыгырданд иреннәрен бөрештереп нидер әйтмәкче дә булды кебек. Өс-башы өчен га үтенмәкчедер кебек тоелды мина. Ана унайсыз булмасын дип, тиз генә кит бардым. Ә ул шул урында никтер бик озак басып торды. Мин университ ишегеннән кереп киткәндә тагы бер борылып карадым. Ул әллә кул болгаганд итте. Әллә берәр әйтер сүзе калды микән? Шулай уйлый-уйлый китеп бардь һәм озак мин аны күрмәдем.

II

Егерменче гасыр туксанынчы елларны күрсәткән көннәр. Ирек мәйданын өметләре сүнмәгәннәр хөррият даулый. Йөзләгән, меңләгән халык плакатл күтәреп, демонстрация, митингларга чыккан. Мин дә шулар арасында һәм һ көтелмәгән очрашу: каршымда Альберт абый пәйда булды. Бераз кечерәйгән кебе Өстендә кара пәлтә. Бик искеме инде? Альберт абыйның йөзендә бу мәйдан бүген һич кенә дә хас булмаган елмаю. Ул иреннәрен нәкъ теге вакыттагы бөрештерә төшеп: "Нәҗибә! Нәҗибә! Мин сине таптым!"—дип кычкырь жибәрде, калтыранган куллары белән мине иңнәремнән үк тотып алды. Ми аның сәерлегенә күпмедер күнеккән идем, ахры, тыныч кына:

—Исәнмесез, Альберт абый!—дидем. Ә ул елмая. Өстемә авып төшәрдәй булы талпына. Үзем дә сизмәстән читкәрәк тайпылдым, күрәсең, ул мине кулларымна ук элəктереп алды да шашкан кешедәй тагы кычкырып жибәрде:

—Мин ...мин синең хөрмәткә, синең белән очрашу хөрмәтенә ак күлмәк киде Менә, ышанмасаң, кара!

Бер селтәнүдә пәлтә изүен ачып та җибәрде ул. Өстендә, чыннан да, күзләр чагылдырырлык ак күлмәк иде. Тик пәлтәсе орынып торган төшләренә генә ка сырлар ягылган. Мин берни дә аңлый алмыйм:аекмы соң бу кеше? Ник минс белән очрашу хөрмәтенә? Ник шулай тилесыман елмая ул? Ник кулларга тотына

Бу сораулар Ирек мәйданына түгелделәр дә таралдылар. Ә Альберт абый, та да сәеррәк хәрәкәтләр ясый-ясый, минем алдыма ук килеп тезләнде. Шатлык т хәвеф тә тулы күз карашы мина төбәлгән. Аны, мондый күз карашлы кешен тынламаска мөмкин түгел иде. Минем кулларым аның учларында... Күнелемнә "Бу кеше шашкан, ахры"—дигән уй йөгереп узды. Тик ул күзләр...

...Андый күзләр шашканнарда түгел, ә акыл ияләрендә генә буладыр... Н булган соң ана? Әйтерсең, ул минем уйларның очын элəктереп алды:

—Әйе, ни булган моңа?—дип уйлыйсыңдыр... Яраттым мин сине... Яратам... дигән сүзләрне иреннәре арасыннан түгеп җибәрде дә башын тезләремә салд Шулчак шаулап торган мәйдан тынып калдымы, әллә искән җил көтелмәг сүзләргә абынып егылдымы, дөнья беравык өнсез торды. Йә Хода! Минем хәл башка бер хатын-кыз булса, ни эшләр иде икән? Ярый әле шул ук мәрхәмәт жил ярдәмгә килде: аркамнан эттеме... Мин аны кулларыннан тартып торгызды да :атып калдым... Аның ачылган изүенә жил ачыктан-ачык керә... әллә мин ш жилне куып чыгара аламмы?

—Гафу итегез, белмәгән идем...—дидем мин, шулкадәр мәгънәсез сөйләнүе үзем дә үртәлеп. Мина шулчак кемдер дәште, ахры... Кайсыдыр нык кына бәрел узды. Альберт абыйның иреннәре тагы нидер әйтергә бөрештеләр генәме, әл нидер әйтте дәме—мин урынымнан кубып читкә атладым һәм күпмедер атлау борылып карадым.

Йөзләрчә демонстрантлар аңа бәрелеп-сугылып узса да, ул шул урынынн кузгалмаган иде. Аның адашкан мәхәббәт сүзләре Ирек мәйданы аша үтүчеләрн аяк асларына кереп уралдылар кебек... Мәйданнан барлык кешеләр китеп бетк тә, каккан казыктай басып калган бу кешенең олуг галим булуын да, кайчан булса очратасы мәхәббәтен көтеп ялгыз гомер итүен дә, гомеренең соңгы көннә

якынлашканда гына Ирек мәйданында хисләрен ирекка чыгаруын да миннән башка беркем дә белмәгәндер... Белгәндер. Жанына ук кереп чыккан көзге салкын жил ник үкси дисен?! Жилме сон бу үксүче?! Жил генә түгел, уфтанып искән көзге сагышка кушылып минем жаным да үкси лә!

Жанымны хатирәләр богавы кысып алды. Инде теләсәм дә, борылып карый алмадым. Ул чакта, моннан дистә еллар элек, мине кара шикәрләр белән сыйларга тырышкан егет күз алдыма килеп басты. Ул чакта... кара шикәрне учыма кысып, шикәрсез генә чәй эчкән идем. Бүген бу ак күлмәк өстеннән керләнгән пәлтә элгән кеше мина үзе үк кара шикәр булып күренде. Тик мин бүген дә анын сүзләрен, татлы сүзләрен йөрәгемә кыстым да, кара шикәрле көннәремне үкенечле сагыну белән атлап китеп бардым.

III

Мин бу серле сәхифәне бервакытта да беркемгә дә бәян итмәм дип уйлаган идем. Әмма кара шикәрле көннәрем кире кайтмасалар да, Альберт Фәтхи атлы олуг галимнен ул чакларда анлап бетерә алмаган язмасынын серенә төшенү, шул сернен көзге салкын жилләрдәй үзәкләргә үтүе мине ул үткәнемә кабат кайтырга мәжбүр итте.

Ул чакларда... ул да, мин дә, ул үз тирәнлегендә, мин студент тирәнлегендә фән дингезенә кереп чумган булганбыз икән.

1967—1968 еллар. "Казан утлары" журналында баш мөхәррир Рафаэль Мостафин. Димәк, Альберт Фәтхинен "Мәгариф төбәкләре һәм әдәби бәйләнешләр" дип аталган язмасын дөньяга чыгарырга ул фатиха биргән. Язма басылып чыгуга язучыларны Тукай клубына жыеп алалар. Жыелышта Мөжәһит Вәлиев, Мөдәррис Мусин, Роза Тутаева да катнаша. Алар инде, баш китәрлек кенә хәлләр килеп чыкмаса, язучылар жыелышына килеп йөрми. Андый хәл булган икән. Уфадан Альберт Фәтхи язмасына карата нәфрәт тулы хатны, әлбәттә, Татарстан өлкә комитетына юллаганнар. Өлкә комитетыннан Уфага кичекмәстән жавап китә: Рафаэль Мостафин эшеннән алынды. Әле баш мөхәррир үз эшен башкара. Аны эшеннән бушату турында әле бернинди карар да чыгарылмаган. Тик инде хат киткән. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, шушы көннәргә язучылар съезды туры килә бит. Рафаэль Мостафин трибунадан кискен генә сүзләр белән чыгыш ясап торганда, академтеатрнын балконнарыннан яшьләр листовкалар сибеп жибәрмәсеннәрме! Шушы вакыйганы сәбәп иткән булып, гаепне Рафаэль Мостафинга сылап та куйдылар: баш мөхәррирлектән алып ташладылар. Ә Альберт Фәтхи һаман шул мәгарәсендә калган калуын.

Моннан утыз-кырык еллар элек язмасы белән дәһшәтле тавыш-гауга күтәреп, күпме кешеләрнен язмышларын ярдан түбән тәгәрәткән галим ни хакында язган булган сон?

Кабаттан укып чыктым да, мин дә көзге Ирек мәйданында калаклангандай катып калган Альберт Фәтхи хәлендә калдым: без ул куйган нокталан бер генә адым да алга китмәгәнбез ләбаса! Алай гына да түгел, күз күреме житмәслек ижтимагый-тарихи ераклыкка—артка ташланганбыз...

Әйе, әдәби бәйләнешләрдә. Әйе, ижтимагый-тарихи бәйләнешләрдә. Әйе, әдәбият—ижтимагый-тарихи күренеш. Ул халкы тарихы белән аерылгысыз рәвештә бәйләнгән. Әллә тел ижтимагый күренеш түгелме дә әдәбият телдән башка туа, яши аламы?

Әллә аерым яки уртак байлыклар булган әсәрләр шул халыкларнын яшәү рәвеше, теле белән дөньяга тудырылмыймы?

Шулай, әлбәттә! Бары тик шулай гына! Бу—аксиома! Альберт Фәтхи инде ул чакта ук, әле Башкортстан дип бүленгән жирдә татар теленен рәсми статусы бетерелгәнче үк, әле Уфа губернасы үз жирләрендә, үз телләрендә укып белем алу хокукына ия чагында, әле меңләгән татар мәктәпләре исән, урман-кыр, елга-күлләргә дә "башкортса" дигән мөһер сугылмаган һәм әле бер генә татар кешесенен дә бер генә башкорт кешесенә дә тамчы да нәфрәт хисе тумаган чакларда ук,

мәсьәләне бар булган дөреслеге белән дөньяга ачып күрсәткән икән бит. хакыйкать, әлбәттә инде, Мәскәү сәясәтенең үтенә тигән. Чөнки фәнне адашты алса, фәнсез саннарны адаштыруны ул корал ярдәмендә дә башкара ала бит.

Әйе, нәкъ Ибраһим ага Нуруллин әйткәнчә, Альберт Фәтхи язма тат тормышында глобаль мәсьәләне дөрес якка хәл итә башлау ноктасы булыр тиеш булган. Соңыннан гына аңладым: ул чакта Альберт Фәтхигә дә каныкканн икән бит. Чөнки хезмәтләрен дөньяга чыгармау, аларны тормышта кулланмау галимне терелəй җирләү бит инде ул. Әгәр шулай булмаса, башка галимнәр д дәүләт эшлеклеләре дә, аның милләтебез мәнфәгате өчен тарихи әһәмиятле булг язмасын күтәреп алып, халкына хезмәт иттерер иде. Әмма нәкъ киресе кил чыккан. Хакыйкатьне тотып буганнар да тарих тәгәрмәчен кирегә бары җибәргәннәр һәм... Башкортстан административ чик сызыгы эчендә калга татарлар өчен озакка сузылган теш кысып түзү гасыры килгән. Ул җирләрдә татарлар үз җирләрен үзләренеке түгел, үз телләрен үз теле түгел дип таныр тиеш иделәр. Менә шушы хәлләргә дучар ителү нәтиҗәсендә Башкортстанда татар зыялылары Татарстан һәм башка җирләргә депортацияләнделәр. Ә ин зыялылар, бигрәк тә әдәбият әһелләрен, рух җырчыларын җуйган төбәк халкын тиз генә үз сүзен әйтә алмавы табигый хәл иде.

Әйе, бу—мал вагоннарына төяп депортацияләү түгел. Бу—йомшак җәеп, ка утырту. Мондый юлның әкренләп кенә сулар һавасын, җанын кысу икәнлег гади халык тиз генә төшенә алмады, әлбәттә. Әгәр дә, Альберт Фәтхи әйткәнч әдәби харитә төзегән булсак, зыялыларны депортацияләү аерым-ачык күрен торыр иде.

Безнең әдәби харитәбез бүген дә юк. Альберт Фәтхинең моннан 30-40 ел эл дөньяга чыккан язмасы бүген тагын да актуальрәк икән ләбаса. Әдәби харитәб инде бүген дә төзелмәсә, бу язма бүген дә татар дөньясы өстенә байрак ит күтәрелмәсә, гомумтатар әдәби мирасына караш тамырдан ялгыш юлга кер китәчәктер. Кемнәрдер ялган тарих яза дип, без дә шул чоңгылга төшеп ки алмыйбыз ич инде!

Альберт абый! Син чакырып кайтарырлык җирләрдә булмасаң да, синә дәшә телне, мирасны пычрак итекләр белән таптап китмәкчеләр монда! Инде "Кичер дип тә әйтә алмыйм. Ул чакларда сине шикәр, тәти кием кайгысыннан күп югары хәсрәтләр баскан булган да бит... Сине фән белән шашкан, фанат, ки зат, диләр иде шул. Ник яшь булганмын?"—дип үкенер көннәр дә килә икән...

Альберт абый! Синең шушы язманнан соң Башкортстандагы татарла мәсьәләсендә башка фундаменталь хезмәт чыкмаса да, Айдар Хәлимнең тарих хөкем карары булырдай елъязмасы, Татарстаннан читтә булса да, дөньяга чыкты шөкер. Мин дә дистә еллар инде үз төбәгем халкы мәнфәгатен яклап тат матбугатында сүз әйтә алмый интегәм. Синең карьераңа гына түге Башкортстандагы татарлар язмышы хакында сүз кузгаткан һәр кешегә каныгала икән... Йә Ходаем! Хакыйкатьне таптап үтереп буламы да, хакыйкатьне тыеп як аңа рөхсәт биреп буламы?

Альберт абый! Әнә син һаман анда, Ирек мәйданында каккан казык кебе әйе, фән мәйданына каккан хакыйкать казыгы булып һаман басып торасың. мин сиңа таба йөгерәм...

Ләхет... Ул синекедәй булса, әллә нинди тәхетләрдән дә биегрәк вә бөегр була ала икән! Ләкин андый ләхетләр милләт җанына уела. Кара шикәрл көннәремне сагынам да айга карыйм. Ай үзе дә кара шикәр төсендә түгелме сон Әллә соң ай үзе дә тапталган татар җаннарыннан төйнәлгән хәсрәт төенеме у Бәлки хакыйкатьне таныган җаннардан җыелганга да кара төннәрне яктыр аладыр ул?!

# БӘХЕТЛЕ ИҖАТ ИЯСЕ

Соңгы елларда татар матбугатында әсәрләре еш басылган һәм үзенең активлыгы белән аерылып торган шагыйрьләрнең берсе, мөгаен, Резеда Вәлиева булгандыр. Укытучылар гаиләсендә туып-үскән, әдәбиятка илленче елларда килеп, алтмышынчы елларда таныла башлаган шагыйрә, 2000 нче еллар татар әдәбиятында да үз урынын, үз тавышын саклап калырга омтылды һәм теләгенә иреште дә. Соңгы елларда дөнья күргән "Күнелем гөлләре" (2002), "Кояшлы янгыр" (2003) җыентыклары мона матур мисал. Әлеге китапларда шагыйрәнең яна шигырьләре белән бергә күп еллар дәвамында язган уңышлы әсәрләре тупланган һәм алар хис-кичерешләргә, лирик уйлануларга бик бай.



Әйтергә кирәк, әлеге җыентыкларында да Резеда Вәлиева мона кадәр тоткан максатына тугры калган. Аны яшьлек иҗатыннан башлап, көн саен борчып торган, уйландырган, һаман тынгылык бирмәгән тема — ул туган як, туган җир:

*Әй лә, газиз туган җирем,*
*Ипи тәмен тойган җирем.*
*Тик синдәдер тиңсез бәхетем —*
*Үз телем, үз моңым минем...*

"Исәнә ал бу баланны".

Туган җир, халык, һәм аның рухы мәсьәләсенә төп игътибарны юнәлтеп, шагыйрә үзе әсәрләренен кыйммәтен түбәндәгечә билгеләгән иде:

*Җырларымда минем үз халкымның*
*Кайгы-шатлыклары чагыла.*
*Әле тургай булып кагына алар,*
*Әле моңнар булып агыла...*

"Тик бер йөрәк әгәр сагынса".

Чыннан да, шагыйрәнең иҗаты халык күңеленнән аерылгысыз. Шуңа күрә геройлары да кызыклы, алар тормышның үзәгендә кайныйлар: үсәләр, хыялланалар, үзгәрәләр. "Күнелем гөлләре" һәм "Кояшлы янгыр" — язучының талантын дәлилләүче җыентыклар. Мәгълүм ки, уй-фикерләр, хис-тойгыларны бүгенге көн кешесенә житкерү, аны кызыксындыру — зур язучылык сәләте сорый. Резеда Вәлиеваның бу китапларга тупланган әсәрләре исә укучыны битараф калдырмый, уйландыра, дулкынландыра:



*Янма, йөрәк, сызма, күңел,*
*Өзгәләнмә, җан гынам.*
*Күк айкала, җир чайкала,*
*Сынма, рухым, бул чыдам.*

*Халкыңны күр, хәленә кер,*
*Мәрхәмәт кыл, суз кулың.*
*Чыңласын саз, җырларың яз,*
*Аңа бир бар җан җылың.*

"Янма, йөрәк, сызма, күңел".

Резеда Вәлиева - лирик шагыйрь. Лирик шигырьләр, Г. Афзал сүзләре белән әйтсәк, "сайрап-чынлап торган сизгер күңелнең бер ихтыяҗы буларак туа". Тыйнак, саф, ихлас ярату үз тәсе белән туып, каләм алырга мәҗбүр итә, күрәсең. Шагыйрәнең бу темага язылган "Син — минем язларым", "Аерылышу", "Китмә, сөю", "Сүрелмәс җырым син", "Юксыну", "Йөрәгемә куштым", "Яралы язмыш" һ. б. шигырьләре һәм поэмалары мәхәббәтнең сихри көченә ышандыралар.

Резеда Вәлиеваның лирик иҗаты үзәгендәге төп тема—матурлыкны күрә белү, аны саклый белү:

*Син—минем язларым, сүрелмәс назларым,*
*Кояшым син күңел күгемдә.*
*Беренче язмыдай, онытылып назыңда,*
*Яратам, яратам бүген дә.*

"Син — минем язларым".

Шагыйрә үзенең "хәтер хәзинәсендә" *(Х. Туфан)* сакланып калган балачак, яшьлек елларындагы кичерешләргә дә мөрәҗәгать итә. Алар вакыт-вакыт янарып, лирик әсәр рәвешендә дөнья күрә. Ягъни, биредә язучының акылы

Резеда Вәлиева. Күңелем гөлләре. — Казан: «Идел-Пресс» нәшрияты, 2002 ел.
Резеда Вәлиева. Кояшлы янгыр. — Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2003 ел.

да, йөрәге дә, хәтере дә, хыяллары да катнаша. Бу аеруча сугыш темасына караган шигырьләрдә һәм "Канатлы җайдак", "Яралы язмыш", "Хәтер", "Муса Җәлил — халкым улы" кебек поэмаларда ачык чагыла:

*Шул җиңүгә илткән ут эчендә*
*Эзләреңне ничә җуйдык без,*
*Ничә тапкыр салкын толымнарың*
*Кайнар яшьләр белән юдык без...*

"Толымнарың синең".

Шагыйрә тыныч тормышка мәдхия җырлый. Сугышка көчле нәфрәт исә бер әсәрдән икенчесенә яңа төсмерләр белән байый, заманчалаша, дөньядагы үзгәрешләргә җавап рәвешен ала:

*Сүнмәс ут кагына мәйданнар түрендә,*
*Аналар күңеле борчулы бүген дә.*
*Аналар бүген дә улларын сагына.*
*Кешеләр, басыгыз тынычлык сагына!*

"Һәйкәлләр янында".

"Канатлы җайдак", "Яралы язмыш", "Муса Җәлил — халкым улы" поэмалары һәм "Далада", "Ять-яшь кызлар китте ут эченә", "Бала мәхәббәте турында баллада", "Кояшларым сүнде", "Әнкәемнең иске өен сүттеләр..." кебек шигырьләр дә җанны тетрәндерерлек образлар белән сугарылган. Сугыш беткәнгә ничә еллар үтсә дә, һаман да балаларын көтеп саргайган ана образы истә кала:

*Инде кайтмас бәбкәйләрем, кайтмас инде,*
*Кайтсалар да туган йортны тапмас инде.*
*Алар төсе булган йортым сүтелде,*
*Соңгы өметкәйләрем дә киселде...*

"Әнкәемнең иске өен сүттеләр".

Уйлап карасаң, бу заманда укучының игътибарын җәлеп итәрдәй сүз әйтү бик кыен кебек. Ә Резеда ханым безне хисләр дөньясына алып керә, бер моңландыра, бер юата, күңелдә якты хисләр уята:

*Мин бәхетле, чөнки бу дөньяда*
*Алтын-көмеш коймый бәхетне,*
*Мин бу җирдә саф хисләрем белән,*
*Якты рухым белән бәхетле.*

"Бәхетлеме син, дип сорыйсыз сез".

Резеда Вәлиева үзен төрле жанрларда сынап карый. Һәр жанрның исә үзенең таләбе бар. Лирикада беренче чиратта хис-кичереш һәм шул хисләрне ышандырырлык, укучының күңелен кузгатырлык итеп әйтә белү булса, чәчмә әсәрләрдә сюжетны кора белү, образны тулы итеп үсештә күрсәтү осталыгы тора. Бу исә, үз чиратында, хыял көче, фантазия һәм психологик халәт белән бәйләнгән. Болар шагыйрәнең балалар өчен язган әсәрләрендә аеруча ачык чагыла.

"Кояшлы яңгыр" җыентыгы тулысы белән балаларга багышланган. Бу китапка тупланган әсәрләрнең теле, рифма, ритм җырлап тора. "Балалар шигъриятендә рифманың төгәллеге бик мөһим. Чөнки балалар матур яңгырашлы, аһәңле шигырьләрне генә яраталар. Мин бу мәсьәләгә аеруча нык игътибар итәм, сак булырга тырышам", дип яза шагыйрә үзе дә. Резеда ханым балаларның нәрсә белән кызыксынуларын, хыялларын, теләкләрен белеп, бала күңелен тоеп эш итә. Әсәрләре фантазиягә, фикер, образлы сурәтләүләргә, матурлыкка бай, шунлыктан аларның идея-эстетик кыйммәте дә зур. Бу, күрәсең, традицион алымнарны уңышлы файдаланудан да киләдер. Шагыйрә батырлык һәм куркаклык, акыллылык һәм наданлык, көнчелек һәм киң күңеллелек кебек төшенчәләрне капма-каршы куеп, тәрбия бирү юнәлешендә оста куллана. ("Ялкау карга баласы", "Ак песи", "Апа белән сенел", "Нужа", "Койрыксыз тиен" һ. б.)

Бүгенге яшәешебездә иң актуаль тема — хезмәт аша тәрбия мәсьәләсе — китапта аеруча киң яңгыраш алган. Мондый фикерләр кайчак беркадәр дидактик формада яңгыраса да, образлы тел, ритм һәм рифманың камиллеге әсәрләрнең уңышын тәэмин итә:

*Кешене кеше иткән,*
*Яман чирдән терелткән*
*Тик хезмәт кенә бары,*
*Онытма моннан ары!..*

"Кышкы әкият".

Резеда Вәлиеваның иҗаты танып белү ягыннан да әһәмиятле. Әмма ул барлык сорауларга да җавапны әзерләп бирми, бәлки, баланың үзен уйлануга этәрә, теге яки бу вакыйгада кемнең хаклы яки хаксыз, нәрсәнең яхшы яисә начар булуына җавапны кечкенә укучының үзеннән ишетергә тели, моның өчен балага мөрәҗәгать итә, аны сөйләшүгә чакыра:

*Аптырап басып тик тора малай,*
*Нигә дип миннән качалар болай?*
*Ул нигә алай ялгыз калды соң?*
*Укучым, бәлки син аңлатырсың?..*

"Масайган Наил".

Шагыйрә әдәплелек, әхлак тәрбияләү мәсьәләләренә дә зур игътибар бирә. "Акыллы малай икән", "Тәрбияләү бик кыен", "Оялдык...", "Урман һәм мин", "Иркә чеби", "Тамгалы куян", "Калган эшкә кар ява" әкиятләре һәм шигырьләре нәкъ менә шул темага багышланган.

Тәрбия мәсьәләсендә әби-бабайларның, әти-әниләрнең изгелеге, матур күңеле балалар теле белән, аларның үзенчәлекләрен анлап яктыртыла.

"Кайтырсынмы икән?", "Әбине җәлләп кенә", "Әниләр бәйрәме", "Туган көнен белән, әнием", "Минем әтием — гармунчы", "Дәү әнигә барабыз" һ. б. мона матур мисал:

*Әлли-әлли-әлли лә,*
*Әй рәхәт дәү әнидә,*
*Иртәсен дә, кичен дә*
*Гөл бакчалар эчендә,*
*Кошлар сайрап торганда,*
*Өчпочмак ашаганда...*

"Дәү әнигә барабыз".

Җыентыктагы бер төркем шигырьләр юмор һәм сатира белән сугарылган. Мәгълүм ки, аерым очракларда балаларны җинелчә чеметкәләп алу да зарур: "Елак-мылак", "Ишегалды бозлавык", "Бишле Барый", "Саран малай—алама", "Оныттым", "Кире курчак" һ. б. нәкъ менә шундый максаттан чыгып язылганнар. Биредә дә шагыйрәнең нечкә тоемлавы, психолог булуы ачыла, ул баланың "авырткан" җиренә җинелчә кагылып, дәваларга омтыла:

*Иң тыйнак дип... ни инде,*
*Яз инде малай үзең...*
*Юкса, беләсең ич инде,*
*Иң тыйнагы — мин үзем...*

"Тыйнаклык".

Аерым очракларда нәтиҗә көтелмәгән юнәлеш тә ала. Мәсәлән, кояш, әтәч, сандугачның үзен йокыдан уятуларына кәефсезләнгән балага әбисе:

*—Сине яраталар,*
*Шуңа уяталар,* — дип аңлата.

Икенче бер: "Мин ничек арслан булдым" шигырендә исә вакыйгалар лирик герой исеменнән сөйләнелә. Төрле халәтләргә кереп уйнаган малай азактан арслан була һәм:

*Ы-ы-ыр!!!*
*Нәкъ шул чакны әнием кайтып керә...*
*Арсланнан песи булдым,*
*Өйне җыярга тотындым...*
*Их!..* — дип куя.

"Мин ничек арслан булдым".

Балаларга хас садәлек белән язылган әлеге юллар күнелдә үзенчәлекле матур хис калдыра, елмайта.

Резеда Вәлиева — халык авыз иҗатына хөрмәт белән караучы шагыйрә. Аның "Иң матур җир", "Минем сеңелем дәү үскән", "Кояш, чык", "Әйдә, атым, чап, чап", "Сыер эзләгәндә" һ. б. шигырьләренең һәм балалар сәхнәсе өчен сценарийларының, күп сандагы әкиятләренең уңышын нәкъ менә фольклор белән тыгыз элемтә билгели. Халык җырларына хас шигырь үлчәме, аерым очракларда такмак һәм такмазаларны, иярмешләр һәм эндәшләрне, әкият алымнарыннан уңышлы файдалану, фольклор традицияләрен куллану — иҗатны халыкка һәм, иң әһәмиятлесе, балаларга якын итә. Халык авыз иҗатына кыю таяну тагын баланың фантазиясенә, хыялына зур урын бирүгә китерә: әсәрләрдә без кызгану хисен дә, бәйрәм шатлыгын да, үзенчәлекле юмористик һәм сатирик аһәңнәрне, шаянлыкны да күрәбез:

*Саран, саран сарана,*
*Алан-йолан карама:*
*Без артыңнан ыржмибез,*
*Саран малай — алама.*

"Саран малай — алама".

"Кояшлы янгыр"ның "Кем әйтеп бирер икән?" дигән бүлегендә шигъри табышмакларның матур үрнәкләрен дә табарга мөмкин. Шагыйрә йөгерек тел, музыкага хас ритм һәм рифма ярдәме белән баланы табышмаклар дөньясына алып керә, аңлата, уйландыра, куандыра:

*Нилэр эшли соң тагын*
*Елның бу матур чагы?*
*Урманнарны агарта,*
*Бар дөньяны яңарта,*
*Сафландыра кешене,*
*Ничек аның исеме?*

"Ничек аның исеме?"

Резеда Вәлиева — балалар өчен матур-матур җыр текстлары авторы да. Аның "Кил син, язым", "Елак песи", "Курчакка күлмәк тектем", "Мин машина ясатам", "Рәхмәт, әнкәй, сина", "Янгыр, яу", "Казански күн итек", "Мин — джазмен" һ. б. җырлары төрле җыр бәйгеләрендә катнашып, мактаулы урыннар яулап килә. Шулай итеп, Резеда Вәлиева бу юнәлештә дә актив иҗат итүчеләр рәтендә саналырга хаклы. Җыентыкка тупланган яна җырлары да балалар һәм өлкәннәр күнеленә хуш килер дип ышанабыз.

Шагыйрә бүгенге көндә дә иҗатын кызыклы жанрлар, матур әсәрләр белән баету юнәлешендә актив эшчәнлек алып бара, илһамланып, янып яза. Бер шигырендә ул:

*Туган халкым минем, газиз халкым,*
*Синең рухың белән мин яшим,*
*Син куансаң, бәхетем чәчәк ата,*
*Син еласаң, түгелә күз яшем...* —

дип язган иде. Бу сүзләр, чыннан да, дәреслеккә туры килә: шагыйрә һаман да Ил язмышы, халык язмышы өчен янып-көеп яши, иҗат итә.

**Ләйлә МИНҺАҖЕВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

*Хәтер*

# АКТҮБӘ МИЗГЕЛЛӘРЕ

Игътибар белән күз салыгызчы, җәмәгать: нинди ягымлы, чиста, нинди сөйкемле, нур чәчеп, илһам бөркелеп торган йөзләр, карашлар! Татар рухияте шау-гөр килеп кайнаган Казаннан бик еракта яшәсәләр дә, алар милли мәдәниятне дә, ана телен дә онытмыйча, үзләрен һәрдаим олуг татар милләтенең бер өлеше итеп тойдылар, санадылар.



Татарларның сәхнәгә гаҗәеп хөрмәт белән каравы һәркемгә мәгълүмдер. Алар, кайда гына яшәсәләр дә, гел сәхнәгә тартылалар, моның бик тә күркәм нәтиҗәсе буларак исә үзешчән театрлар калкып чыга. Андый театрлар заманында Ерак Казакъстандагы Актүбәдә дә бар иде. Рәсемнәргә янә күз салыйк әле. 1933 елда алынган бу фотосурәттә—татар мәктәбе каршындагы драмтүгәрәккә йөрүчеләр. Театр сәнгатенә гашыйк бу милләт уллары вә кызлары, бакчы, нинди затлы горурлык белән дөньяга, киләчәккә карап торалар! Кем белә, берәрегез бу фотода бәлки әле туганына да тап булгандыр. Кем белә *(һәм бирсен Ходай!)*, сурәттәге әнә теге яшь скрипкәче егет әле бүген дә, биредәге башка егет-кызлар кебек үк, Татарстаныбызда, йә башка төбәктә исән-имин генә яшәп ята торгандыр.




Инде 1938 елда татар мәктәбен тәмамлаучыларга күз салыгыз. Мөгаен, аларның бик күбесе яу кырында ятып калгандыр. Безнең игътибарыбыз бу катлаулы язмыш ияләренең исталегенә, рухына бер дога булсын.




Менә янә бер фото. 1926 ел. Актүбәнен татар коммунарлары. Ерактагы якты киләчәккә—социализм белән коммунизмга ышанган, өметләнгән заманнарны искә төшерә ул.

Жидееллык татар мәктәбенең чыгарылыш сыйныф укучылары бу рәсемгә 1928 елда төшкәннәр. Әйе, татар баласы аң-белемгә, мәгърифәткә яшьтән үк омтыла. Бу анын канына сенгән.



Менә, ниһаять, соңгы фоторәсем. Ул 1925 елның беренче маенда демонстрациядән соң төшерелгән. Типография эшчеләре, татар матбугаты вәкилләре үзләренең гаиләләре белән бергә жыелганнар. Олпат карашлы өлкәннәр, йөзләрендә самими нур балкыган балалар. Рәсемдәге бу сабыйлар, ышанам ки, гомер юлын исән-имин генә үтеп, бүген инде бәхетле картлык кичерәләрдер. Ерак казакъ даласындагы Актүбә шәһәрендә узган гасырда алынган бу фотоистәлек әлеге сурәттәге милләттәшләребезнең нәселен-токымын дәвам итүчеләргә бер бүләк булсын иде.

Актүбә каласында татарлар бүген дә гөрләтеп яшиләр: милли якшәмбе мәктәпләре ачып жибәргәннәр, туган телдә концертлар, кичәләр оештыралар, туйларны, бала туу йолаларын үзебезчә үткәрәләр, гореф-гадәтләребезне онытмыйча саклыйлар. Ел саен сабантуйларын бик күркәм итеп уздыралар, кала түрендә мәчет тә салып куйганнар.



ПЕЧАТНИКИ Г. АКТЮБИНСКА В ДЕНЬ 1 МАЯ 1925

Бу фоторәсемнәр—татар халкының, анын тарихының аерылгысыз бер өлеше. Шушы рәсемнәрдә сурәтләнгән затлар, бер уйласаң, татар дигән милләтне бар итә, яшәтә икән ләбаса.

**Рауль МИРХӘЙДӘРОВ**

Гәп
Фән

Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ЗИФАФ, ЗӨФАФ*** *г.* – Кыз янына кияү булып керү, беренче кавышу төне; туй; никахланышу. *// Зөфаф кичәсе. Зөфаф көннәре.*

Х.Чантайның Коръән тәфсирендә "зөфаф кичәсе"нә түбәндәге аңлатма бирелә: "Зөфаф кичәсе – никахтан соң ир белән хатынның бер ятакта төн уздыру мөддәтедер. Зөфаф алдыннан бу хатынны яратмаячагызны сизенеп, аның сезгә охшамаган гадәтләрен күреп, аның чирле икәнен белеп, җенси якынлык кылмыйча талак итсәгез, шәригать кануннары бозылмый" *(төрекчәдән Рабит Батулла тәрҗемәсе).*

Билгеле булганча, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең Әсма исемле хатын белән никахы бик кыска булган. Зөфаф алдыннан Әсма аңардан үзен талак кылуын сорый һәм Пәйгамбәр аны аерырга карар кыла. Шуңа күрә Госман хәлифә Әсманы Пәйгамбәр хатыны булган дип санамаска карар да чыгарган. "Гаскәрләр" (33) сүрәсенең 49 нчы аяте нәкъ шушы вакыйгага нисбәтле дип уйлыйлар: "Ий мөэминнәр, мөэминә хатыннарга никахлангач, якынлык кылмыйча аларны талак итсәгез, ул хатыннан гыйддәт таләп итәргә сезнең хакыгыз юк. Әгәр аларга мәһәр атамаган булсагыз, бер кат кием бирегез, вә аларга зарар итмичә яхшылык белән җибәрегез."

***ЗИҺАР*** г. – *Заһыр (арка)* сүзеннән ясалган термин. Җаһиллек чорында гарәпләрдә гаилә тормышында яшәп килгән гадәт. Әгәр ире хатынына: "Син миңа анамның аркасы кебексең" дип әйтсә, ул аны үзеннән читләштергән дип исәпләнелә, ләкин никах өзелми, хатын ире өендә кала, башка кияүгә чыга алмый. Бу гадәт Коръән-кәримнең "Әхзаб" *(33)* сүрәсендә *(4 нче аять)* гамәлдән чыгарыла.

Бу очракта "арка" дип әйтү эвфемизм гына булса кирәк.

***ЗОБАНИ*** – **1**.Тәмугта яндырып торучы, газап фәрештәсе. Тәмугта җитмеш бер зобани бар дип исәпләнелә. Зобанилар кулларына гөрзиләр тоткан булалар. Күчерелмә мәгънәдә төрмә сакчыларына карата да зобани дип әйткәннәр. **2**.Сатлык җан*(нар).*

***ЗӨЛФИКАР*** *г.* – "Арка умырткасын кисүче" кылыч. Мөхәммәд Пәйгамбәрнең *Бәдер* янындагы сугышта кулга төшергән кылычы. Соңыннан бу кылыч хәзрәти *Галигә* кала. Аны бер озынаю, бер кыскару хасиятенә ия булган диләр.

***ИБАН*** – Электә Иван исеменең татарча әйтелеше. Кайбер рус акчаларындагы татарча сугылган язуларда да очрый *(Мәс., Алтын Урда чоры заманнарга караган рус тәңкәләрендә "Ибан Тәбирчә" – Иван Тверской, "Ибан Москов акчасы будыр" кебек язулар очрый).*

***ИБ(Е)Н*** *г.* – Угыл, ир бала. Күплек саны шәкеле – *ибнаэ, ибнан* (балалар).
*Ибнә* – берәүнең кызы.
*Ибне Адәм* – Адәм баласы, бәндә. *// Нәсыйхәт сал колакка, ибне Адәм.* Мөхәммәдъяр.
*Ибнелвакыт* – замана баласы.
Тагын кара: ***ГАРӘПЧӘ ТУЛЫ ИСЕМ.***

***ИБЛИС*** *г.* – Иблис әш-Шайтан – барлык шайтаннарның башлыгы. Башка исеме – *Галү Аллаһ (Аллаһның дошманы),* яки кыскача: *әл-Галү.* Адәм каршысында сәҗдә кылырга боерылгач, Аллаһы әмерен тыңламаган өчен күктән сөрелгән бердәнбер фәрештә. Сәрйан халкы һәм аларга ияреп борынгы гарәпләр Иблисне сөрелгәнгә кадәр *Харис* яки *Газазил (русча чыганакларда – Азазелло)* дип атап йөрткәннәр. Иблис сүзен грек телендәге

*Дәвамы. Башы журналыбызның алдагы саннарында.*

*"диаболос"* — дьявол сүзеннән килеп чыккан дип тә исәплиләр. Ахыр чиктә немецчә *тойфель*. *Мефистофель* сүзләре дә шушы бер тамырдан. Мәулана Мөхәммәд Алиның "Священный Коран" китабындагы комментарийларда Иблис сүзе *"баласа"* сүзеннән чыгарыла *(мәгънәсе — "ул өметен өзде")*. Шайтан сүзе исә "ул читләште", "ул ераклашты" мәгънәсендә дип аңлатыла. "Тау тишеге" сүрәсенең 50 нче аятендә Иблис турында "ул җеннәрнең берсе иде" диелгән һәм шуңа карап күп кенә дин белгечләре Иблисне фәрештәләр исәбенә кертү ялгыш дип тә чыгалар *(мәс., шул ук Мәулана Мөхәммәд Али)*. Ләкин "Сад" сүрәсенең 71, 72, 73, 74 нче аятьләреннән Иблиснең фәрештәләрдән булуы аңлашыла: 71.Раббың фәрештәләргә әйтте: "Мин балчыктан Адәмне хәлык кылачакмын". 72.Аны хәлык кылып тәмам иткәч, аңа җан кертеп тергездем, фәрештәләр Адәмне зурлап сәҗдәгә бардылар. 73.Фәрештәләрнең барчасы берьюлы сәҗдә кылдылар. 74.Мәгәр Иблис сәҗдә кылмады. Тәкәбберләнде һәм кяферләрдән булды.

Кыскасы, Иблиснең фәрештәләрдәнме, әллә җеннәрдәнме булуы анык түгел.

Суфилар Иблисне трагик фигура дип саныйлар. Чөнки Иблиснең Аллаһтан башка бер генә затка да сәҗдә кыласы килми, асылда ул, Аллаһның үзенә каршы килеп, бер аллалыкны яклап чыга.

Ривайәтләрдә Иблиснең хатыны *Лиһа* исемле булган дип тә сөйләнелә. Аннары Иблис үзенең *"әт-тарика әл-мәзмума"* дигән тыелган сихер белемен кызы *(яки улының кызы) Байдаһага* тапшырган имеш. Ләкин болары бәхәсле. Чыннан да, фәрештәләрнең җенесе юк. Ләкин, югарыда әйтелгәнчә, Коръән-кәримнең "Тау тишеге" сүрәсендә Иблис "җен" дип тә аталган. Әгәр җеннән булса, Иблиснең ирле-хатынлы булып яшәвен кире кагып булмый.

Ривайәтләргә караганда, Туфан ябырылыр алдыннан Нух пәйгамбәрнең көймәсенә ишәк белән бергә Иблис тә үтеп кергән һәм исән калган дип сөйләнелә. Бу да Иблиснең фәрештә затыннан булуына шик тудыра, чөнки фәрештәләргә туфаннан саклануның кирәге юк.

Шуңа күрә, тулаем алганда, мөселман теологиясендә Иблиснең җәннәттән сөрелгән фәрештә булуы турындагы фикер бик үк хупланмый *(В.Порохова)*.

Дөньяда таралган явызлыкларны һәм имансызлыкны Ислам Иблис казынуларыннан килә дип аңлата. Иблиснең *Гаду Аллаһ (Аллаһның дошманы)* дигән исеме дә бу затның гади фәрештә түгеллегенә ишарәли, чөнки Аллаһның дошманы һәрхәлдә вак һәм зәгыйфь була алмый. Кайчагында ул Аллаһның капма-каршысы буларак хәрәкәт итә.

"Китаб әл-милаль вә-н-нихаль" *("Диннәр һәм мәзһәбләр турында китап")* авторы *Әш-Шаһрастани Мөхәммәд ибн әл-Кәрим (1086 – 1153)* Иблиснең күңелендә җиде шик туып, соңра ул шикләр адәмнәрнең башларына үтеп кергәннәр дип яза. Ул сораулар кызыклы гына.

Беренче сорау. "Иблис әйткән: "Мине хәлык кылганга кадәр ул *(Аллаһ – А.Т.)* миннән ни чыгасын белгән бит инде. Шулай булгач, нигә ул мине беренче итеп хәлык кылган?"

Икенче сорау. "Бәс мине үз ирege һәм теләге белән хәлык кылган икән, нигә ул мине үзен танырга һәм буйсынырга бурычлы итә? Әгәр дә ул минем буйсынуымның файдасын, тыңлаусызлыгымның зыянын күрми икән, бу бурычта ни мәгънә бар?"

Өченче сорау. "Бәс ул мине хәлык кылган һәм миңа бурычлар йөкләгән икән һәм мин ул куйган таләп буенча аны таныганмын һәм аңа буйсынганмын икән,.. нигә соң әле ул миңа Адәмгә буйсынырга һәм аңа сәҗдә кылырга куша?"..

Дүртенче сорау. "Нигә ул Адәмгә буйсынмаганым һәм аңа сәҗдә кылмаганым өчен мине ләгънәтләде һәм җәннәттән сөрде?" Моның мәгънәсе нидә?

Бишенче сорау. Әгәр дә бусы гакыллы эш булса, нигә соң шуннан соң Аллаһ миңа Адәмгә якынлашырга юл куйды һәм мин, икенче тапкыр җәннәткә кердем дә, коткымны салып, Адәмне юлдан яздыра алдым?

Алтынчы сорау. Шушы әйткәннәрдән соң да нигә Аллаһ миңа Адәмнең нәселе өстеннән хакимлек бирде һәм мин кешеләрне алар мине күрмәгән вакытта күрәм, минем вәсвәсәм аларга тәэсир итә, ә аларның көче вә куәте миңа тәэсир итә алмый?..

Ниһаять, җиденче соравында Иблис үзенең Аллаһ тарафыннан яратылган булуын таный һәм барлык кылган бозыклыкларыннан соң да "Миңа кешеләрнең кабердән кубарылачак көннәренә тикле мөддәт бир, дөньяда калдыр" – дигәч, нигә Аллаһ минем белән килеште? Әгәр ул мине шундук һәлак иткән булса, Адәм дә, аның каүеме дә миннән ял итәрләр һәм дөньяда бернинди явызлык калмаган булыр иде", – дип дәгъва белдерә.

Коръәннән соңгы ривайәтләргә караганда, Ахырзаман көнендә Аллаһы Тәгалә үлем

фәрештәсе Газраилгә Иблиснең җанын алырга боерачак һәм аның җанын алганда газапны ике өлеш артыграк кылырга кушачак.

Күп кенә суфилар, мәсәлән Ибн Гарәби, ахыр чиктә Аллаһы Тәгалә Иблисне гафу кылачак дип исәпләгәннәр.

*Әгузе биллаһи минаш-шайтани-р-рәҗим ("Таш атып сөрелгән шайтаннан Аллаһуга сыенам")* сүзләреннән башка, Иблис-шайтанга каршы "Ихлас" *(112)*, "Әл-Фәләкъ" *(113)* һәм "Ән-Нәс" *(114)* сүрәләренең соңгы аятьләрен укыйлар.

Кайбер төбәкләрдә Иблисне *явыл* дип атап йөртәләр икән *("дьявол" сүзеннән булырга тиеш)*. "Явыл" сүзен, мәсәлән, татар шагыйре Хәсән Туфан да кулланган.

*Иблис галәйһелләгънә*— ләгънәт ителгән Иблис. *Иблис галәйһел- ләгънәти*— Иблискә ләгънәт булсын.

Тагын кара: ***АДӘМ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ, ФӘРЕШТӘЛӘР, ШАЙТАН.***

***ИБНЕ ХАЛДУН*** *(1332–1406)*— Әбү Зәйд Габдеррахман бине Мөхәммәд. Күренекле гарәп тарихчысы, социолог һәм философ.

"Әл-Мокаддимә" *("Кереш")* дигән хезмәтендә Ибне Халдун тарихка карата структур анализ ысулын кулланып, мәдәниятләр тәгълиматын бәян итә.

Ибне Халдун фикеренчә, тарих милләтләрнең туу, аларның куәткә ирешү, әкренләп зәгыйфьләнү һәм түбән төшү чорлары кабатлана торган циклдан гыйбарәт. Ибне Халдунча, шәһәр—мәдәни җәмгыятьнең нигезе. Шәһәр кешесе нәзәкатьлерәк һәм ачыграк булганга, ул сугышырга яратмый һәм шул ягы белән бәдәвиләрдән көчсезрәк. Туганлык җепләре белән бәйләнгән бәдәви кабиләләр шәһәрне бик җиңел буйсындырганнар, ләкин дүрт буын алмашынуга шәһәр аларны "боза" һәм алар үзләре яңа буын бәдәвиләрдән җиңеләләр. Тарихта циклы кабатланулар турындагы фикере белән Ибне Халдун ХХ гасырның күренекле тарихчысы Лев Гумилевның теориясен дә хәтерләтә. Хәер, тарихтагы цикллар турындагы концепция, милләтләрнең тууы, куәткә ирешүе, әкренләп артка китүе, түбән тәгәрәве, аннары яңарыш кичерүе турындагы фикер Библиядән үк килә. XVII—XVIII гасырларда яшәгән итальян тарих философы Вико Джамбатиста да халыкның балалык чоры каһарманнар чоры—яшьлек белән алмашына, аңа алмашка җитлегү чоры—гуманитар *(кешелек)* дәвере килә дип күрсәтә. Аның идеяләре Н.Данилевский, К.Леонтьев, О.Шпенглер һәм, мәгълүм дәрәҗәдә, А.Тойнби фикерләренә якын. "Империяне кулга төшергәннән соң,—дип яза ибне Халдун,— җиһангирлар үз-үзләрен алҗытуга биреләләр... Алар гөлбакчалары һәм фонтаннары булган сарайларга хуҗа булып,... Аллаһының әмер биргәнен *(көтеп яталар)*... Иртәме, соңмы империяләргә картлык килеп җитә, алар да, кешеләр кебек үк, үсәләр, җитлегәләр, ә аннары түбән тәгәри башлыйлар". Шунысы кызык, XIX гасырда аның бу фикерен математик Н.Лобачевский сүзгә-сүз диярлек кабатлый.

Ибне Халдун яһүдиләрне җир йөзендәге иң затлы каумнәрдән саный, чөнки Ибраһимнан алып Мусага кадәр барлык пәйгамбәрләр дә яһүдиләрнең ата-бабаларыннан чыкканнар, ди ул. "Хәзерге еврейләрнең мәкерлелеге һәм каты күңеллелеге—аларның илдән куылуы, башкаларга буйсынуы һәм тормыш итү рәвешләре нәтиҗәсе,"—дип яза Ибне Халдун. Аның фикеренчә, бу милләт инде бер тапкыр яңарыш кичергән, һәм шушы нәрсә аларның тарихны ничек күзаллавын билгеле һәм киләчәккә перспективалар ача.

***ИГЕЗӘК***— Игез бала. Борынгы төрки телдә *иккиз*— икелек, икеләр. Охшаш тамырлы сүзләр монгол, төрек, чуаш, мари, эвенк телләрендә дә бар. Гарәпчә *тәвәәм*—игез, игезәк; игәч, икеләч. Тәвәәмнең икелек саны шәкеле— *тәвәәман*. Тарихта игез балаларның җидәү һәм хәтта артыграк туган очраклары да билгеле. Теге яки бу дәрәҗәдә тоташып үскән игезәк балалар да туа, аларны *Сиам игезәкләре* дип атыйлар. Мәшһүр игезәкләр: Адәм пәйгамбәрнең улы *Кабил* һәм чибәр *Әкълимә*, Адәмнең икенче улы *Һабил* белән игезәк кыз *Ләбуда*, *Йагкуб* пәйгамбәр һәм аның туганы— *Гаяз*, Пәйгамбәрнең игезәк оныклары— имам *Хәсән* белән имам *Хөсәен*, борынгы грек риваятьләреннән *Кастор* һәм *Поллукс* h.б.

Мөселманнар арасында еш кына игезәк ир балаларга *Хәсән* һәм *Хөсәен* исемнәре кушылган. Игез туган кыз балаларга *Фатыйма* һәм *Зөһрә* исемнәре биргәннәр.

Биологиядә бер күзәнәктән яралган игезәкләрне һәм төрле күзәнәкләрдән яралган игезәкләрне аерып карыйлар. Бер күзәнәктән яралган игез балалар арасында биологик

тәңгәллек күзәтелә. Хәзерге вакытта русча махсус әдәбиятта соңгыларын *двойняшки* дип атау кабул ителгән *(икеләч бала? куш бала?).*

// *Су игезәк булу*—бала туганда алдан су китеп бетү. Бу вакытта бала үле туа *("Диалектологик сүзлек", 1993).*

***ИГЪЛЯМ*** *г.* — Белдерү, аңлату; белдермә, аңлатма, хәбәр. // *Намаз укылачак вакытны халыкка игълям итү (кылу).*

***ИҖАЗӘТНАМӘ*** *гф.* — Мәдрәсәләрдә мөдәррисләрдән шәкертләргә сабак укытырга бирелгән рөхсәт язуы; шәһадәтнамә, аттестат, диплом. Иҗазәтнамә гарәп телендә язылып, Аллаһы Тәгаләгә мактау, Мөхәммәд Пәйгамбәргә, аның нәселенә, сәхабәләренә, башка пәйгамбәрләргә салават әйтүдән башлана, гыйлем хакындагы аять һәм хәдисләрдән соң, иҗазәтнамә иясенең исеме, атасының исеме һәм укыган дәресләренең исемлеге китерелеп, ахырда кәлимәи шәһадәт, тәүхид, салават һәм догалар белән тәмамлана.

Суфи шәехләр дә мөридләренә иҗазәт*(намә)* бирә торган булганнар.

***"ИҖЕК ЫСУЛЫ"***—Кадими ысул белән укытуда гарәп сүзләрен иҗекләргә аерып, сузыкларның нинди хәрәкә белән булуын әйтеп уку. Мәс., "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә моңа мондый мисал китерелә: "*кәп өсте кә, ләм асты ли, мим өсте мә, т гә ике өтер—кәлимәтен* дип уку." Мондый кадими укыту ысулы шәкертләр өчен чиксез авыр булган. Әлифба укытудагы бу ысул тарафдарларын *иҗекчеләр* дип йөрткәннәр. 1883 елда Исмәгыйль Гаспралы Кырымдагы Бакчасарай мәдрәсәсендә яңа ысул—"ысулы җәдид" куллана башлап, "аваз ысулы"на күчә, аннары бу ысул безнең мәдрәсәләргә дә үтеп керә.

***ИҖТИҺАД МӨНКАРИЗ*** *г.* — Мөстәкыйль фикер йөртү заманының бетүе, хәзерге вакытка ачыласы ачылып беткән, иҗади эшчәнлек заманы узган дигән караш. Билгеле булганча, Ш.Мәрҗани мондый карашны кире кага.

***ИКЪЛИМ*** *г.*—Грек сүзе "klima"ның гарәпчә транскрипциясеннән *(иелү мәгънәсендә).* Климат поясы *(путасы).* Борынгылар Җирнең экватордан алып төньяк котыпка кадәр булган арасын җиде өлкәгә бүленә дип кабул иткәннәр, ләкин төрле авторларда бу бүленеш төрлечәрәк. әл-Хәрәзми I климатның урта параллеле дип 16 нчы градусны кабул иткән, калган икълимнәр түбәндәгечә: II—24°, III—30°, IV—36°, V—41°, VI—45°, VII—48°. Гарәпләр кеше яшәү өчен иң кулай икълим—дүртенчесе дип санаганнар. Казан төбәге VII икълимгә караган. // *Җиде икълим (әкалиме сәбага)*—бөтен дөнья.

Тагын кара: ***ӘКАЛИМ*** һәм ***МИНТАКА.***

***ИЛ***—Борынгы төрки сүз. Электә ул бер өлкәне яки аерым кабиләне белдергән, "солых", "тынычлык" мәгънәсенә дә ия булган. Мәс., Пугачев гаскәре Казанны алгач, Иске бистә татарлары аларны: "Илме? Ямы?"—дип каршылыйлар. Тегеләр "Ил", ягъни "Тынычлык" дип җавап биргәч, бистәнекеләр аларга сый-хөрмәт күрсәткәннәр. *(Каюм Насыйри.)* Илче сүзе үзе үк "тынычлык алып килүче" мәгънәсенә ия булган дип уйларга кирәк. Элекке татар телендә "ил" сүзе "авыл" мәгънәсен дә белдергән. *(Мостафа Ногман.)*

***ИЛ-АТ***—Ил, халык, илдә яшәүчеләр. Ибраһим Хәлфин *(XIX гасыр)* бу сүзне "авыл халкы" мәгънәсендә куллана. Русча "*население*" мәгънәсенә дә туры килә. Әзәрбайҗан телендә дә "*элат*"/"*елат*" сүзе шулай ук кавем-кардәш, тугандаш халык мәгънәсендә икән *(Н.Исәнбәт).* // *Ул кичке чәй янында хуҗа хатыныннан аның ничек көн күрүен, ил-атның ничек торуын сораштырып, сөйләшеп утырды.* Ф.Хөсни. *Ил-ат хурлыгы булу.*

Нәкый Исәнбәт "ил-ат" сүзен киңрәк мәгънәдә аңлый: "Идел елгасы һәм аңа койган зур-зур елгалар өстендә борынгы һун төрекләре, соңыннан Хәзәр-болгар, алардан соң Болгар-кыпчак һәм Казан мәмләкәтләре яшәгән һәм ат менгән ирләр кулында идарә ителгән ил әче димәк". Аның фикеренчә, "борынгы Идел-Атил *(Ат-ил)* мәмләкәте дигәнебез хәзерге Әстерхан тирәсендә булган Атил *(Ат-ил)* шәһәре янында диңгезгә койган Атил *(Идел)* елгасыннан алып хәзерге Татарстан—Мари АССР арасындагы

Илләт *(Ил-ат)* елгасы тамагынача булган җирләр булып, борынгы болгар-угыз һәм фин-угорлар һәм соңыннан Казан ханлыгы яшәгән ил эче, шулай ук алар белән бәйләнештәге кәрван, су юллары һәм бу араның ат белән йөрелеше күздә тотылган тәгъбир." Бүгенге *"Мари Эл(ь)"* атамасы, гыйбри *(борынгы еврей)* телендәге *"Израэль"*, *"Йакуб-эль"*, *"Йосыф-эль"* атамалары Н.Исәнбәтнең әлеге фикерен тагы да куәтлиләр, "ил" сүзенең тарихи чикләрен һәм географиясен тагы да киңәйтәләр кебек.

Тагын кара: ***ИЛӘТ.***

***ИЛӘК*** – **1.**Он яки ярманы, орлыкларны эрерәк катышмалардан аеру җайланмасы. Вак таш һәм комны фракцияләргә аеру өчен дә махсус иләкләр кулланыла. Тел тарихы белгече Р.Әхмәтьянов "иләк" сүзен *ил, әл, әл* "кул" сүзе белән бәйли. **2.**Металл акчаның бәһасен күрсәткән ягы, реверс. Электә акчаның алгы ягын (аверсны) *кун* дигәннәр.

Акча чөеп уйнаганда акчаның язулы *(легендалы)* ягы өскә карап төшсә (*"иләк"*), уйнаучы оттырган санала. *Кун (герблы, ягъни көнле/кояшлы ягы белән)* төшкәндә исә ул ота. Русларда "иләк" як *решка* яки *решето* дип атала. Бездә: "Иләкме, күнме?" дип сорасалар, русларда "Орел или решка?" яки "Копье аль решето?" дип сораганнар. "Орел" – рус акчасында ике башлы сәмруг кош төшкән герблы як, "копье" дигәндә иске рус акчаларындагы сөңге тоткан атлы Георгийны күздә тотканнар. Даль күрсәткәнчә, соңгы очракта басым һәр ике сүзнең *("копье" һәм "решето" сүзләренең)* беренче иҗегенә төшкән. Шушы ук автор "решето" ягы акчаның "көдрә вензельле тискәр ягы" дип ачыклап күрсәтә. Без бу "вензель"не рус акчаларындагы гарәпчә язу дип фараз итәбез. Билгеле булганча, мондый гарәп хоруфатындагы татарча язулар әле ялагай Дмитрий Донской акчаларына да сугылганнар. Моннан ни сәбәпле руслар өчен "решето"ның оттырыш икәнлеге аңлашылса кирәк.

Акча чөеп уйнауга кадәр бу ысул юрауның бер төре генә булган. Шул ук вакытта электә иләк белән юрау ысулы да яшәп килгән. Гадәттә иләк фалы ярдәмендә угрының кем булуын "белгәннәр", бу да иләккә карата хорафатчыл тискәре мөнәсәбәт тудырырга тиеш. Икенчедән, акчаның бер ягы *кояшлы (көндезге)* булгач, табигый, аның икенче ягы төнге яки *йолдызлы* булырга бик мөмкин. Чыннан да, XIII гасырга караган болгар акчаларында аерым йолдыз сурәте төшерелгәннәре дә, күпсанлы тәрткеләр сугылган акчалар да бар. Мәс., бер язусыз тәңкәнең алгы ягында сәмруг кош *(яки лачын)* сурәте төшерелгән, ә икенче ягы тәрткеләр белән әйләндереп алынган тамгалардан тора. Соңгырак чорга караган акчалар арасында бер ягына биш чатлы зур йолдыз төшкәннәре дә аз түгел. Тарихчы Ә.Мөхәммәдиев: "Кайбер типтагы акчаларда "пул" сүзенә болгар-татар теленә хас булмаган "у" *(?)* кушымчасы ялгана *("пулу Болгар")*, ә арткы якта уртасына "гали тамга" куелган биш канатлы йолдыз тора". – дип яза. Мәгълүм булганча, күктә күзгә ташланып тора торган йолдызлар арасында Иләк йолдыз төркеме яки Өлкәр йолдыз бар. Риваятьләрдән Өлкәрнең җиргә салкыннар җибәреп торуы да билгеле. Кыскасы, безнеңчә, акчаның төнге, йолдызлы ягын әүвәлгеләрнең иләк дип атаган булуы ихтимал. Моңа турыдан-туры ишарәле торган табышмак та бар: "Төн әйләнә кара иләк, Эче тулы алтын кибәк" *(җавабы – күк йөзе һәм йолдызлар).*

Янә шунысы кызык, кояш белән иләк "кояшка иләк каплый алмассың" дигән" татар мәкалендә дә очрашалар.

Шушылардан чыгып, без русча "решка" белән татарча "иләк" сүзенең мәгънәдәш булуын татар йогынтысы белән аңлату җиңелрәк дип саныйбыз.

***ИЛЕКМӘН*** *тар.* – Манара, маш, башня.

***ИЛҮ*** *бор.* – Р.Әхмәтьянов бу сүзне "халык" *(население)* мәгънәсендә куллана: "Тик терлекчелеккә күчкәч кенә төрки һәм монголларның тормышлары яхшыра, илүләре арта, кабилә оешмасы камилләшә, катлаулана һәм – башта төркиләр, соңрак монголлар – бөтендөнья тарихында атаклы, "классик" сугышчан, агрессив көч булып әвереләләр."

XVIII гасыр юридик документларында "волость" мәгънәсендә кулланылган термин. *// Буләр илүе. Сарайлы илүе. Байлар илүе.*

Тагын кара: ***ИЛӘТ.***

***ИЛҺАМ*** *г.* – "Гарәпчә – татарча – русча алынмалар сүзлеге"ндә: **1**.Күңелгә салынган нәрсә. **2**.Күңелгә салыну; күңелгә салу.

// *Илһаме илаһи* – Алла илһамы. *Хәким Сөләйманга илһаме илаһи булып белде, күңелендән кәчүрде: "Моннан да карага барурсән."* – Хәким Сөләйманга Алладан илһам килеп, моны белде, күңеленнән уйлады: "Моннан да карага барырсың." Кол Шәриф. *Гаязга илһам ителгән "Ике йөз елдан соң инкыйраз" каһарманы Җәгъфәрнең...* Ф.Әмирхан.

***ИЛХ*** *г.* – "һәм башкалар", "ахырына чаклы *(дәвам итү)*" мәгънәсендәге *ила ахириһи* сүзләреннән кыскартылган: *һ.б.*

***ИМДЕ, ИМДИ*** *иск.* – Инде. // *Никадәрле язсам да, мөмкин түгел бетәргә, Имди безгә тиешле мохтәсар кыйлып бетәргә.* "Урта Тигәнәле бәете"ннән. *Табмас ирди бере беренгә зафәр, Тыңла имди, итәйем уш мән хәбәр.* Мөхәммәдьяр.

***ИМЕШ*** – Борынгы төрки телдәге мәгънәсе: *булган.* // *Аңдый көйле каһан имеш* – шундый данлы каһан булган. *(Тәнйокукның каберташындагы поэмадан.)* Мөхәммәдьярда "әймеш" формасында очрый: *"Ике нәүбәт бозган әймеш тәүбәсен, Гаси булуб, онутубән тәңресен."* Хәзерге әдәби телдә "Теге яки бу хәбәрнең берәр кешедән ишетелгәнен һәм аның дөресме, түгелме икәнлеген сөйләүче кистереп әйтә алмавын күрсәтү өчен кулланыла." *("Татар теленең аңлатмалы сүзлеге").* Бу очракта ул "икән" мәгънәсенә дә якын. Кайчагында "имеш" сүзе җөмләдә кереш сүз булып катнаша һәм өтер белән аерыла.

***ИНКЫЙРАЗ*** *г.* – **1**.Үлеп юкка чыгу, яшәүдән туктау, бетү, тукталу, нәселе өзелү. *Инкыйразга йөз тоту.* **2**.Түбән китү, артка китү, регресс. *"Милләтне инкыйраздан саклау юлы бер генә – дөньябыз, хаят вә мәгыйшәтебез өчен файдалы гыйлем вә сәнагатьләрнең һәммәсен өйрәнеп гамәлгә кую".*

***ИНТИФАДА*** *г.* – Азатлык өчен көрәш *(мәс., Фәләстыйн шәкертләренең һәм талибларының Израиль оккупациясенә каршы көрәше).* Террор оешмаларыннан аермалы буларак, иттифада көч куллануны принципта кире кага. Дөрес, Фәләстыйн студентлары Израиль солдатларына төбәп таш ыргыталар, ләкин бусы да түзгесез нерв киеренкелегеннән бушану өчен генә эшләнә. Сергей Кара-Мурза әйткәнчә, "...интифаданың бөтен процедурасы культуролог һәм психологлар катнашында халыкара гыйльми төркем тарафыннан җентекләп эшләнгән һәм конфликтларны көч кулланмыйча гына хәл итү юлларын эзләүдә мөһим эксперимент булып тора".

***ИРӘН, ИР*** *бор.т.* – Борынгы төрки әдәбиятта гадәттә "чын ир-егет, яугир" *(сугышчы)*, "камил кеше", "изге", "вәли" *(әүлия)* мәгънәсендә кулланыла. Корьәндәге "әүлийәуллаһ"ка туры килә. Монгол телендә *эр* – ир, батыр, герой. Тәсаувыфта суфилыкның бер югары баскычы, дәрәҗә. Бу дәрәҗәне алган хатын-кыз да "ир" дип аталырга хокуклы. Ирәннәргә *бәзәрг* дип эндәшкәннәр. Әдәбиятта *иран* һәм *әйран* языльшлары да очрый һәм буталчыклык тудыра. // *Гыйшык юлга һәркем керсә хәле харап, Иранлардан юлны сорап йөрдем мән.* Әхмәт Ясәви. *Әйраннар дөнья димәде, Дөнья гамен жыймады, Хаклин үзгәне димәде, Дөньяны салып китәрем.* Әхмәт Ясәви. *Ирәннәрнең аткан угы кире кайтмас* – бу әйтем изгеләрнең бәддогасы һәрвакыт кабул була дигән ышанудан килеп чыккан. *Ирән күрке – сүз.* Борынгы төрки мәкаль.

Дөньяви әдәбиятта *ирәннәр – (сугышчы) ир-егетләр.* // *Йөз баһадир ирәннән Йорт-җиреңне бастырдын.* "Туктамыш дастаны". *Корыч ирән* – тимердәй нык кеше*(ләр)*.

"Хәзерге төрек телендә *ерен* – алланы таныл-белү серләрен төшенүче, изгелек кылучы кеше". *(Н.Фәттах.)* "Төрекчә – русча сүзлек" дәрвишлек дәрәҗәсенә ирешкән изгенең дә ерен дип аталуы турында әйтә. Нурихан Фәттах бу сүзне *ирә-н* рәвешендә таркатып, "Ата улы (penis)" мәгънәсендә аңларга да була дип яза. Бу фикер нигезләнми.

Тагын кара: ***ГАИБ ИРӘННӘР***.

***ИРТӘК*** – Әкият, легенда; борынгылар турында сөйләк.

***ИРТӘКЧЕ*** *тар.* – Әкиятче, әкият сөйләүче. */ / Казакъ акыннары, башкорт курайчысы, татар иртәкчеләре, Урта Азия бәхшиләре аны ("Кузы Күрпәч" дастанын – А. Т.) көйләп-җырлап яки хикәяләп сөйләгәннәр.* Исмәгыйль Рәмиев.

***ИСЛАМ ҺӘМ ГАМӘЛИ МЕДИЦИНА*** – Әүвәлге мөселманнар *тыйб* гыйлеменә, ягъни медицинага зур әһәмият биргәннәр. Чит телләрдән төрле дәвалау ысуллары турында китаплар *(мәс., грек теленнән Галенны һәм Гиппократны)* тәрҗемә иткәннәр, үз араларыннан мәшһүр табиблар җитештергәннәр, хастаханәләр ачканнар, тыйб мәдрәсәләре булдырганнар. 306 нчы һиҗрәдә Багдад шәһәрендә "*Әлсәидә*" һәм "*Әлмоктәдир*" исемендәге хастаханәләр эшли инде *(Доктор Рахманның "Краткая история ислама" китабында Багдад шәһәрендә беренче җәмәгать хастаханәсенең миляди 809 елда ачылганлыгы әйтелә).* Беренче аптеканың Багдад шәһәрендә 184/801 елда ук ачылганлыгын әйтеп китик. Тиздән һәрбер зур шәһәрдә шундый хастаханәләр булдырыла. Алар бер үк вакытта уку институтлары да булып хезмәт иткәннәр, булачак табиблар аларда практика үткәннәр, тәҗрибә туплаганнар һәм дипломнар алганнар. Фармацевтлар да шушы хастаханәләрдә имтихан тоткан.

Сугышка барачак гаскәрләрнең сәламәтлеген тикшерү *(хәзерге медкомиссия кебек)* беренче мәртәбә 302 нче һиҗрәдә Багдадта оештырыла. 259/873 елда Мисырда беренче зур шифаханә төзелә. Анда ирләр һәм хатын-кызлар өчен аерым мунчалар да булган. Шифаханәдән чыкканда пациентларга ризыклану өчен бер тавык һәм бер ипи биреп җибәрә торган булганнар. Р.Фәхреддин: "Мондан соң һәрбер мәшһүр шәһәрләрдә хастаханәләр вә тыйб мәдрәсәләре ачылды. Андалузия мәдрәсәләрендә укып кайтучы яһүдиләр Монплия шәһәрендә Аурупада беренче мәртәбә хастаханә тәэсис иттеләр вә Ислам табибларының әсәрләре буенча дәва кылып тордылар", – дип яза.

XIII гасырда бер Багдадта гына да 800 табиб эшләгән. Ә шул ук вакытларда Парижда нибары алты бөртек табиб исәпләнгән, ә Рейн елгасы буйларында бер генә табиб та булмаган.

Электә мөселманнар арасында "Китабы нәбыз" *("Тамыр тибү турында китап")* абруйлы исәпләнгән. "Кыйссаи Йосыф" поэмасыннан күренгәнчә, болгар табиблары да диагноз куйганда авыруларның тамыр тибешен, ягъни пульсларын билгели торган булганнар.

Йогышлы авырулардан саклану мәсьәләсе хәдисләрдә ачык хәл ителгән. Мәсәлән, "Бер урында чума хасталыгы барлыгын ишетсәгез, анда бармагыз. Әгәр дә үзегез булган җирдә чума хасталыгы беленсә, аннан чыкмагыз" дигән мөһим кагыйдә "Сахих Бохари"да теркәлгән. Бактерияләрне ачканчы күп элек бөек табиб *әр-Рази (Көнбатыш чыганакларында: Разес, 865 ел тирәсе – 925)* гигиенаның әһәмиятен яхшы аңлаган һәм Багдадта шифаханә төзетер алдыннан шәһәрнең төрле мәхәлләләрендә ит калҗалары элеп куйган. Шифаханәне ул ит әкренрәк бозылган җирдә төзергә тәкъдим итә. Ул төрле авыруларны тасвирлый, аларны дәвалау ысуллары эшли, акушерлык хезмәтенә башлангыч сала. Дезинфекция максатларында спирт кулланырга тәкъдим итүче дә ул.

Әхмәтһади Максудиның "Шәригать хөкемнәре"ндә "Табибсыз шәһәрдә вә табибсыз авылда тору", "Йогышлы авырулы кешегә өч аршиннан артык якын килү" мәкруһ гамәлләр исәбенә кертелә. Тәһарәт һәм гомумән чисталык турындагы катгый күрсәтмәләр, ир балаларны сөннәтләү, Исламда ашау-эчү әдәбе, аерым ризыкларны тыю һ.б.ның медицина күзлегеннән дә зур әһәмияте булуы бәхәссез. Мәсәлән, бер хәдистә: "Йокыдан торгач та, кулыгызны өч мәртәбә юмый торып, аш савытына таба сузылмагыз, чөнки йоклаганда берегез дә кулыгызның кайда йөргәнен белми", – диелә. Хәдисләрдә теш чистарту гына түгел, теш чистарткычның үзен юуу да телгә алына. Йокыга ятканда тәһарәт белән яту, мисвәк, щетка белән авызны чистарту сөннәт гамәлләрдән санала.

Теш чистарту өчен мисвәк куллану, тамакка су алып гаргарә кылу, борын эченә су алу, мыек кисү, сакал тарау, тырнак кисү, гаурәт төкләрен һәм култык төген кыру, ир баланы сөннәтләү, истинҗа кылу Ибраһим пәйгамбәр керткән сөннәт гамәлләр булып исәпләнә. Ягъни ул халыкны пакьлеккә, гигиена кагыйдәләренә өйрәткән.

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2005 елның икенче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә. **«Казан утлары»ның индексы—73210**, ярты елга язылу бәясе 117 сум.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан биел да абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар журналга «Горпечать» киоскларында языла алалар. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була. Фатирыгызда почта әрҗәсе бик үк ышанычлы булмаса, сезгә моннан да кулай ысул юк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

*Казан утлары*
(наименование издания)

Количество комплектов: 

на **2005** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ________ (почтовый индекс) ________ (адрес)

Кому ________ (фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | ли-тер |
|---|---|---|
| | | |

на ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

*Казан утлары*
(наименование издания)

| Стои-мость | подписки | ______ руб. ______ коп. | Количество комплек-тов |
|---|---|---|---|
| | пере-адресовки | ______ руб. ______ коп. | |

на **2005** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ________ (почтовый индекс) ________ (адрес)

Кому ________ (фамилия, имя, отчество)

*«Казан утлары» архивыннан*



*Композитор Нәҗип Җиһанов, Мостай Кәрим, Әмирхан Еники Г. Тукайның Кырлайдагы музеенда. 1986 нчы ел.*



*Җырчы Хәдичә Гыйниятова мәшһүр композитор Рөстәм Яхин романсын башкара. Рояльдә автор—Р. Яхин. 70 нче еллар.*



*Язучы Идрис Туктар, шагыйрь Сибгат Хәким, драматург Туфан Миңнуллин. 1980 нче ел.*



*Язучы Нәбирә Гыйматдинова. 2002 нче ел.*



*Шәйхи Маннурның Мамадыш шәһәрендә куелган һәйкәле.*



*Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин. 1998 нче ел.*

*Котлыйбыз!*

## Җан сәгате

"Һәркемнең үз җанында үз сәгате бар. Ул сәгать кабатланмас язмышларның елларын, минутларын саный. Ул сәгатьнең алтын теле — хәтер. Узган көннәрнең караңгы чоңгылыннан хәтер үзенә кирәкле һәр мизгелне тартып чыгара, узган гомернең һәрбер өлешен терелтә ала".

Әлеге юллар язучы һәм шагыйрә Фирдәвес Әһлиянең "Йөрәкнең соңгы кылы" исемле китабындагы "Актриса" дип аталган повестеннан алынды. Әйе, шигырь язу өчен җаның, күңелең хис белән тулы булу кирәк булса, проза, бигрәк тә документаль әсәрләр язу өчен, автор үзе әйткәндәй, "үз җанының үз сәгате булу кирәк, хәтер кирәк".

1954 елның 11 октябрендә Казанда туган кыз урта мәктәпне тәмамлауга М. Горький исемендәге Мәскәү Әдәбият институты студенты булу бәхетенә ирешә. Һәм моның матур нәтиҗәсе дә озак көттерми, 1976 елны Татарстан китап нәшриятында чыккан "Запах мяты" исемле русча җыентыкта аның тәрҗемәсендә берничә татар язучысының хикәясе басыла.

Зур иҗат дәрте белән Казанга кайткан Фирдәвес остазы Рафаэль Мостафинның киңәшен тотып, халкыбызның күренекле кызы Галия Кайбицкая иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнеп, "Актриса" исемле документаль повесть иҗат итә. Берничә елдан соң "Мәдәни җомга" газетасының сәнгать бүлегенә эшкә килү аңа тагын да зуррак мөмкинлекләр бирә. Татар халкының күренекле шәхесләре Шәүкәт Биктимеров, Марсель Сәлимҗанов, Нәҗибә Ихсанова, Дания Нурлы, Хәйдәр Бигичев, Зөһрә Сәхәбиева, Абрек Абзгильдин, Йолдыз Исәнбәт һ. б.га багышланган язмалары төрле газета-журналларда, соңрак аерым китап булып дөнья күрделәр.

Шунысы игътибарга лаек, автор туктаусыз эзләнә, көчен төрле жанрларда сынап карый. Ул балалар әдәбиятын да чит итми, берничә ел дәвамында әкият жанры өлкәсендә эшләү нәтиҗәсе булып, 1990 елны Татарстан китап нәшриятында "Ак күгәрчен" исемле китабы чыга. Шушы ук елларда Ф. Әһлия шигърият жанрында да, бигрәк тә тыңлаучыларыбыз тарафыннан яратып кабул ителгән җырлары аша танылу ала башлый. *(Зөфәр Хәйретдинов көйгә салган "Гафу итәрсең микән?", "Ак манара" — Резеда Ахиярова, "Тукай һәйкәле белән сөйләшү" — Илгиз Мәҗитов җырларын укучыларыбыз әле дә хәтерли булыр.)* Яшәешнең төрле якларын яктырткан, тирән фәлсәфи, бары тик хатын-кызларга гына хас булган ихлас яратудан туган әсәрләрен җыйнаган "Кош баласы" (1999) исемле шигырь китабы чыгу да аның инде өлгергән шагыйрә булуын раслый.

*Кеше булып калыйм азаккача,*
*Әйләнмәсен ташка күңелем.*
*Һәм яшәсен иде бу дөньяда*
*Исән-имин халкым һәм илем,*

дип яза шагыйрә үзенең "Минем бәхет" исемле шигырендә.

Шулай ук "Әлмәндәр әманәте" (2001), "Ай тулган төндә" (2001), "Йөрәкнең соңгы кылы" (2004) исемле китаплар авторы да ул.

Язучы һәм шагыйрә Фирдәвес Әһлия иҗатына матур һәм эшлекле бәя белән язучыларыбыз Рафаэль Мостафин, Әхәт Сафиуллин, Рөстәм Мингалимнәр республикабыз газета-журналларында язып чыктылар. 2002 елда исә ул татар әдәбиятындагы хезмәтләре өчен "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исемгә лаек була. 1993 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Редакция коллективы юбилярны олы бәйрәме белән котлый, аңа озын гомер, иҗат уңышлары тели.**

*Юмор-сатира*



## Тәлгать Нәҗмиев

# САБА ХИКМӘТЛӘРЕ

### Татар таныклыгы

Дөресен әйткәндә, Михаил Горбачев белән "фотога төшеп" кайтканнан бирле Мәскәүдә булганым юк иде. Моннан ун ел элек булган башкала түгел икән инде ул. Эшмәкәрләргә, төрле төркемнәргә сатылып беткән сәүдә мәйданнары... Хәтта түләүсез медицина хезмәте күрсәтү дә калмаган бугай. Бераз температурам күтәрелгәч, үзебезнең комплекстагы медицина пунктына белмичә кергән идем. Шәфкать туташы бәяне санап күрсәтте:

—Кабул иткән өчен 170 сум, градусник куйганга—30, сулыш юлларын тыңлаганга—40, пульс санаганга—тагын 30 сум...

—Житте-житте, булды,—мин әйтәм.—Даруыгыз да, үзегез дә, акча түләгәнгә кәгазегез дә кирәк түгел,—дия-дия, өстәлендә бер йөзлек калдырдым да ашыгыч ярдәм күрсәтү пунктыннан чыгып тайдым.

...Ул метро тирәсендә нәрсәләр генә сатмыйлар! Мең төрле таныклык, дипломнар тәкъдим итәләр. Күзләрең камаша торган. Мин карап-карап тордым да "Удостоверение татарина" дип алтынсу хәрефләр белән язылганын сатып алдым. Эчендә мөһере һәм "Общество спасения утопающих силами самих утопающих" җәмгыяте хуҗасының кул тамгасы да бар. Тагын мондыйрак җөмлә дә чәпәп куйганнар: "В ком юмор вызывает зло, тому с умом не повезло!"

Төсле фотомны тиешле жиренә әйбәтләп ябыштырып куйдым.

Казанга кайткач, "Татарстан" дәүләт телевидениесенә керергә кирәк булды. Гомер буе шунда иҗат иткән, озак еллар "Җомга көн кич белән" тапшыруларын алып барган Индус Сирматов чакырган иде.

Килдем Шамил Усман урамындагы телевидение капкасына. Кем икәнемне аңлаттым һәм район Советы халык депутаты таныклыгымны күрсәттем. Каравылчылар тышкы кыяфәтемә, күкрәктәге значогыма тагын бер мәртәбә чекерәеп карадылар да кертеп жибәрделәр бит мине, рәхмәт яугырылар...

Индус Сирматов мине күргәч:

—Ничек кердең, кем кертте, мин бит пропуск яздырып чыгармаган идем?!—дип тезеп китте.

Мин горур кыяфәт белән башны артка ташлап:

—Мәхмүт Хөсәен әйтмешли, безне "белялар"!—дидем һәм "Удостоверение татарина"ны чыгарып кулына тоттырдым.

Индус Сирматов шундый итеп сөзеп-сөзеп карады минем таныклыгыма. Мондый карашка күзлек пыялалары ничек чыдаганнардыр?!

## Өмет итәрләр ул

Укытучы-остазым Мөхәммәт Мәһдиевне бик еш искә алам. Үзеннән-үзе шулай туры килә. Чөнки кулга газета-журналмы, китапмы алып утырсаң, Мөхәммәт Мәһдиев әйтмешли, дигән фразага юлыгасың. Алай гына да түгел, аның лекцияләрен тыңлау үзенә күрә бер дөнья рәхәте иде. Сөйләү алымнары, үз-үзен тотышы, нәзакәтле итеп тәмәке тартуы күз алдында тора.

Мөхәммәт абый турындагы истәлекләрне көннәр буе сөйли алам. Ләкин монысын зиратта булган бер хәл белән түгәрәкләп куям.

Җәйге матур көндә Мөхәммәт Мәһдиев туганнан туган Гәндәлиф апасы белән Гөберчәккә кайткан. Әлбәттә инде, нәселләренең төп йортларына зиярат кылганнар.

—Бездән дога көткән әрвахлар рухына багышлыйм,—дип укый икән Гәндәлиф ханым.

Мөхәммәт абый тыңлап-тыңлап торган да:

—Апа, өмет итүче күп булыр ул, бездән дога тиешле әрвахлар рухына багышлыйм, дип укы син, яме,—дигән.

## "Сәмигулла" сакчысы

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы оештырган "Авыл: кеше һәм хезмәт" конкурсларында катнашып җиңүләр яуларга насыйп булды бу юлларның авторына. I дәрәҗә Дипломга лаек булган "75 яшьлек егет" дигән очеркым хакында аерым сөйлисем килә минем. Чылбырлы тракторда ярты гасырдан артык эшләгән "Шынар" крестьян (фермер) хуҗалыгы механизаторы Зариф ага Шәрипов турында иде ул. 2003 елда "Ел ир-егете хатын-кыз күзеннән" республика бәйгесендә имтихан тотып ул Президентыбыз тарафыннан да хөрмәтләнде.

—И, гомер буе онытылмаслык вакыйга булды, иптәш Нәҗмиев (Зариф ага элеккеге гадәт буенча миңа гел шулай мөрәҗәгать итә),—дип сөйләп китте ул шуннан кайткач.—Башта теге "Пирамида" дигәннәрен күреп шаккаттым. Ничәмә йөз хатын-кыз арасында берүзем диярлек идем мин анда. Янымa киләләр дә: бабай, син нишләп йөрисең монда? Кайда эшлисең, дип сорыйлар. Җылы җирдә генә утырам, кабинетым да әйләнә торган, минәйтәм. Ялт итеп кызылга буялган үзе. Шуңа күрә җитмеш биш яшьтә эшләп йөрим инде мин, дигән булам. Нинди кабинет ул, дип әсәрләнәләр ханымнар. Аптырагач: трактор кабинасы ул, дип, дөресен әйттем.

Менә тантана башланды. Башта хатын-кызлар хөрмәтләнде. Алар бәйрәме бит. Аннан сәхнә түренә—Минтимер Шәрипович белән Зилә Рәхимҗановна янына мине, алтын куллы хирург Леонид Миролюбовны һәм "КамАЗ"—мастер" командасының узышчыларын чакырдылар. Дулкынлана-дулкынлана менеп киттем баскычлардан. Мин үз гомеремдә хөрмәтне күп күрдем. Әмма бу кадәр биеккә күтәргәннәре юк иде. Чәчәк, диплом, бүләкләр тапшырдылар. Президентыбыз кочаклап та алды. Җир кешесен шундый олылаганнары өчен рәхмәт аларга!

...Гомумән, әңгәмә корырга уңайлы кеше ул Зариф абый.

Аларга барып кергәч, район агитбригадасы белән тамаша кылып йөргәнебез һәм 1968 елда йоклаган верандабыз искә төште.

Хуҗабикә—Зөлхәбирә апа, бик житез, телгә беткән, киң күңелле апа иде мәрхүмәкәй. Без әйткәнне дә көтмичә, ягъни үзе белеп, иртән торуыбызга мунчасын өлгерткән булып чыкты. Авылдан авылга куна йөреп, каралып-тузанланып беткәннәрдер, дип уйлагандыр инде, рәхмәт яугыры. Өстәле дә сыйдан сыгылып тора.

Кичкә таба агитбригада җитәкчебез:

—Апа, ирегез күренми, кайда эшли соң?—дип сорап куйды.

Җавап бик төгәл булды:

—Тракторда. Көндез сукалый, төнлә ... тырмалый!

Мин шуларны искә төшереп торганда, әңгәмә корырга махир тракторчы бабай сүзгә кушылды.

—Әйе, ул мәзәгенне беренче китабыңнан укыдык. Искә алганың өчен рәхмәт. Менә өченче китабыңны язасың икән. Хәзер сөйләячәгемне шунысына кертерсен.

Бервакыт төнлә авырып китте бит әле Зөлхәбирәм. Урысча әйтсәк, приступ булды. Әлеге дә баягы, Белоруссиядән уракка килгән шоферлар фатирда тора иде. Иван дигәнен уяттык. Сабага алып китте. Хатынның өстен алыштырырга да арасы булмады.

—Апа, эчке киемнәрен керләнгән бит,—диләр икән моңа кабул итүчеләр. Зөлхәбирәм бер дә аптырап тормаган:

—Каралмыйча, гомер буе тракторчы белән йоклыйм бит мин,—дигән...

Ә фатирга кемнәр генә кермәде инде безгә. Элек гостиница, ашханә шикелле нәрсәләр юк иде бит. Барысын безгә җибәрделәр. Илһам Шакиров та кунды инде... Берсендә, әле әти исән чакта, Сабаның милиция начальнигын бер кичкә керттеләр. Ул йоклаган карават астында куган нәрсә булган икән. «Исхаков әйбәт саклаган "сәмигулла"ны—бер шешәсе дә югалмаган», дип шаярткан булды әти иртәгесен...

## "Нимес" телле якташыбыз

Тәнкыйтьче, галим һәм мөгаллим Рифат Сверигинның җитмеш яшьлек юбилее туган җирендә дә—Әбрар Кәримуллин исемендәге Саба үзәк китапханәсендә уздырылды. Профессор Рифат Хәсән улы адресына бихисап җылы сүзләр әйтелде, матур җырлар башкарылды, изге теләкләр ирештерелде, истәлекле хатирәләр яңартылды.

...Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган егетне еракка—Аксубай районына эшкә билгеләләр.

Иске Ибрайда алай канат җәеп каршы алмыйлар үзен. Директор татар теле һәм әдәбияты укытучысына ялгышып кына заявка биргән була ахрысы. Бу фәннәрдән атнага уникe сәгать кенә дәрес җыйнала, калганын немец теле белән тутыралар.

Уку елы башланып озак та үтми, мәгариф бүлегеннән инспекторлар килеп төшә. Шуларның берсе немец теле дәресен тикшерергә алына. Кереп утыра өлкән яшьтәге инспектор абый, дикъкать белән тыңлый. Соңыннан бик яхшы итеп дәрескә анализ ясый.

—Произношениегез, ягъни сүзләрне әйтүегез камил түгел,—ди ул.

Каян килеп дөрес булсын инде ул! Мәктәптә дә, университетта да имтихан бирерлек кенә укылган фән бит. Сугыш вакытында тәрҗемәче ролен башкарган зыялы белгеч өметле, яшь егеткә киңәшләрен әйтә, Германиядә чыга торган берәр газетага язылырга куша, үзендә булган немецча пластинкалар бирергә вәгъдә итә. Чын "нимес" ясарга уйлый бу Рифаттан.

Белемле, таләпчән, ыспай, тәртипле-әдәпле, тырыш булуы белән педагогик коллективка тиз кереп китә Рифат. Директор белән дә уртак телне тиз таба. Үзе кебек яшь белгечләр җитенкерәми Иске Ибрайга. Шуннан мәктәпне мактап "Советская Татария" газетасына мәкалә яза Сверигин (русчасы камил була аның). Янәсе, менә дигән мәктәп! Эшләү һәм яшәү өчен шартлар җитәрлек. Килегез...

Бу хәбәрне Римма исемле кыз да укый. Һәм физика-математика белгечлеге дипломы белән Иске Ибрайга килеп төшә. Үз-үзен тотышы, чибәрлеге белән сокландыра яшь мөгаллимә. Рифат өчен якты бер җисемгә әйләнеп, күктән

нур сипкәндәй итә ул. Дуслык чын мәхәббәткә әйләнә. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел бит, газета аша үзен чакырып китергәч! Алар, озакламыйча никахлашып, бер җан булып яши башлыйлар.

Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил, дигәндәй, үз якларына кайтасы килә боларның. Кукмараның тәҗрибәле мәгариф бүлеге мөдире Павел Башаев биш куллап каршы ала белгечләрне һәм тимер юлдан шактый эчкәре булган Ошторма Юмья урта мәктәбенә юнәлдерә.

Булачак галимнең оештыру сәләтен тиз күреп алалар Кукмара житәкчеләре. Ядегәр сигезьеллык мәктәбен кабул итеп алырга әмер бирелә гаилә башлыгына. Яна урынга ияләнеп киләм дигәндә, "Социалистик Татарстан" газетасында аспирантурага чакыру турындагы игъланга күзе төшә бит. Язмышын сынап карарга була ул.

Бер урынга җиде кеше җыйнала көндәшләр. Еллар үткәч, аларның байтагы танылган язучылар, галимнәр булып китә. Ул чакта бәхет Рифат Свериганга елмая. Немец теленнән "5"ле ала да конкурсантларын ике баллга узып китә бу телне Иске Ибрай мәктәбендә өйрәнгән педагог. И рәхмәт укый Аксубайдагы теге тылмач абыйга яшь аспирант...

## Армиягә... барыргамы?

Татарстан Республикасының халык язучысы Фәнис Яруллин тагын районыбызга килеп китте. Кырыкка якын китап авторы, татар Корчагины Балалар иҗат үзәгендәге тулы залда укучылар, педагоглар, китапханәчеләр һәм әдәбият сөючеләр белән очрашкан иде. Эзмә мәктәбе коллективына һәм авыл халкына да елмайды Фәнис абыйлары. Кичәләр гаҗәеп матур узды. Автограф белән китаплар да өләште автор. Минә "Шәфәкъ вакыты" дигән шигырьләр җыентыгы эләкте. "Тәлгат! Минем турында да бер мәзәк чыгар әле. Ихтирам белән Фәнис Яруллин. 23.05.03",—дип язган иде ул.

Очрашуның икенче өлеше турында сөйләп тә, язып та бетерә алмамдыр... Тарихи калкулыкта—1552 елда Казан җимерелгәннән соң, унсигез ай буе каһарман татарларның милли үзәге булып торган Өтернәс—Мишә-Тамак кирмәненнән (шәһәрлегеннән) ерак булмаган урында, ягъни Калатау елгасы буендагы табигать кочагында утырдык. Матур гына өстәл әзерләнгән иде. Өстәл, дигәч тә, яза торганы түгел инде, милли ризыкларыбыздан, табигать хәзинәләреннән һәм башка тәмләткечләрдән торган сый-хөрмәт турында әйтүем. Фәнис абый өчен дә җайлы итеп урнаштырдык табынны. Янәшәсендә—тугрылыклы җәмәгате Нурсия ханым.

Мәҗлесне хуҗалык рәисе Рүзәл Мөбарәков алып бара. Халык шагыйре адресына күрше-тирә хуҗалык рәисләре, Казан шәһәреннән кайткан, район үзәгеннән килгән кунаклар күнел түрләрендәге ин самими теләкләрен дә җиткерәләр. Тост әйткән саен киеренкелек кими, "пар" чыгарып алабыз.

Мәҗлес дәвам итә. "Бу дөньяда яхшы тормыш Путин юлыннан гына",—дип җырлап та җибәрдек берзаман.

Ярый, хуш, хөрмәтле укучым, әлеге мәҗлесне дә йомгакларга вакыт җитеп килә бугай. Чөнки тел, кул, ботинка баулары чишелде. Саубуллашканда тагын Фәнис абый янына җыелдык.

—Кәефегез ничек?—дибез.

—Менә Армиягә повестька килде әле. Барырга микән?!—дигән кинаяле җавап ыргытты ул.

## Шәп бит!

Тагын бер якташыбыз, язучы Нурислам Хәсәнов иҗатына да тукталып

китик әле. Дөрес, аның туган авылы хәзер Теләчегә керә. Әмма ул: "Минем паспортымда, Саба районының Шәдке авылында туган, дип язылган",—ди дә икеләнүләрне юкка чыгара. Әдәбиятка ул ин элек "Җиңү байрагы" ("Саба таңнары") газетасы аша шигырьләре вә нәсерләре белән килеп керде.

Нурислам Хәсәнов "Теләче хәбәрләре" газетасында мөхәррирлек иткәндә еш аралаштык. Язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында үткәрелгән алтмыш яшьлегендә дә катнашырга туры килде.

Юлга чыгар алдыннан, "Росгосстрах—Татарстан" акционерлык җәмгыятенең Саба филиалы директоры, Шәдке кызы Зөлфирә Котдус кызы шылтыратты.

—Мин үзем бара алмыйм. Бүген генә ишетеп белдем. Юбилярга конвертымны тапшыра алмассызмы?—диде ул.

Ничек инде тапшырмаска! Эчендә акчасы гына булсын!

...Менә кичә башланып китте. Җиренә җиткереп, матур итеп алып бара аны Зөһрә Шакиржанова. Миннән алда утырган Барлас абый Камалов (юбилярның остазы) борылды да:

—Тәлгат, бер-ике сүз әйтәсеңдер бит?—дип сорады.

—Сүзен белмим, Барлас абый, ике конверт тапшырасым бар,—дидем.

Шуннан соң, озак та үтмәде, миңа да микрофон тоттырдылар. Юл буе күңелемә салып килгән җөмләләремне һәм ике конвертлы амәнәтне Нурислам Хәсәновка тапшырдым.

Тантана дәвам итә. Кинәт, алып баручы: "Сабадан Зөлфирә Иксанова котлавын сезнең игътибарга җиткерәбез",—диде дә, гаҗәеп матур, сыгылмалы телдә язылган ун минутлык текстны укып чыкты.

Зөлфирә Котдусовна ни өчен мондый икеләтә уен ясады икән, дигән аптыраулы уйда калдым.

Миңа кайтырга вакыт иде. Аерылышканда: "Нурислам абый, Зөлфирә Котдусовнаның котлавы ничек килеп ирешә? Синең юбилей турында бүген генә белгән бит ул",—дип, ачыклык кертмәкче булдым.

—Бер дә борчылма, туган!—диде ул.—Моннан биш ел элек, илле биш яшемә атап үзе тапшырган котлауны бирдем мин алып баручыга. Шәп чыкты бит!

## Эчемдәге—тышымда

Без, Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары, район һәм шәһәр газеталары мөхәррирләре арасында ике генә бөртек. Берсе—ызандаш күршебез, Балык Бистәсендә чыга торган "Авыл офыклары"н җитәкләүче Минневазыйх Фатыйхов. Әллә нигә бер очрашкан вакытта тиз-тиз генә әңгәмә корып, киреәксә шаяртышып, үртәшеп тә алабыз.

—Иҗат эшләрең ничек?—ди бу берсендә.

—Әйбәт,—дим,—монарчы чыккан китапларым барысы да спонсорлар ярдәме белән дөнья күргән иде. Алдагысын нәшрият планына кертә алдык әле...

—Планга керсә дә китап булып чыкканчы бик озак йөри ул,—дип нәфесемне тыймакчы булды каләмдәшем.

Мин дә җавапсыз калмадым:

—Йөрсә—йөрер. Китабы язылмаган да бит әле аның,—дип ычкындырдым.

## Текә машина

Чирек гасырга якын редактор булып эшләү чорында күчле кешеләр белән бик күп очраштым.

1986 елның җәендә районыбызның Ямбулат (хәзер Теләче районына керә) авылына чакыру алдым. Бөек Ватан сугышы ветераны, тыныч хезмәттә җәен үләннәргә су сиптерүче, кышын тимерчелектә эшләүче Зәкиҗан ага белән

Миңнежамал апаның алты килене, ун оныгы бергә җыйналасы икән.

Минем "УАЗ"ик машинам бик тузган иде. Әлеге "тимер ат" белән башта КПССның Лаеш райкомы беренче секретаре Дания Салиховна Дәүләтшина-Мөхетдинова (аның әтисе заманында Теләче районы партия оешмасын җитәкләгән) йөргән булган. Аннары Татарстан Югары Советындагы депутатыбыз Мөхәммәт Сабиров ярдәме белән безгә күчереп арканланган иде. Шул җайдә "УАЗ"икның арткы ике ишеге ачылмый башлады. Ямбулатка дип китеп барганда Сатыш егете, КПСС райкомының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире Фәнил Габдерахманов белән, шул ук бүлекнең инструкторы Нәҗип Хаҗипов каршыга чыгып кул күтәрделәр. Райком кешеләрен утыртмыйча кара! (Хәзер Фәнил Исхак улы Татарстан Республикасының хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү министры урынбасары, ә Нәҗип Нәкыйпович ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары булып эшлиләр). Туктадык. Төштем.

—Егетләр,—минәйтәм,—арткы ишекләр кадакланган. Унайсыз димәсәгез, алгы ишектән керегез дә артка таба мүкәләгез!

Башта, кеше күрмиме, дигәндәй, як-якларына карандылар да аннары, туңкая-туңкая алгы утыргыч арасын узып, артка чумдылар болар.

Ярар. Ике йөз еллык тарихы булган мәдрәсәле Сатышның үзәгенә якынлашабыз. Кибет янындагы болыттай халыкны күргәч, институтны кызыл диплом белән тәмамлаган Фәнил Исхак улы әйтә куйды:

—Тәлгат Саматович, моның кадәр кеше алдында баш белән түбән таба төшеп булмас, безне авыл читенә чыгарып аудар инде, яме?!

## Ипи кирәк

Сүз бозау имезер, диләр.

Берсендә, табигать кочагында—урманда, җинелчә генә чәйләп утырабыз.

—Әйдә, бер мәзәк хәл сөйлә әле,—диде кайсыдыр.

Табынга күз салсам—җиде-сигез кешегә бер генә телем икмәк калганын күреп алдым...

—Бер ханым кисәк кенә чирләп киткән,—мин әйтәм.—Аңа халык табибәсе, күкрәгенә пәри оялаган, дип, балигъ булган ир-атны имезергә киңәш итә. Уйлашалар-киңәшәләр дә авылдагы акылга зәгыйфьрәк бер егетне күндерәләр бу яшерен эшкә.

Дөрестән дә, бик тәмле итеп имә Аллаһының рәнҗетелгән бәндәсе. Бу рәхәтлек авыру ханымның күнелен әллә нишләтеп—җилкендереп-хисләндереп, иләс-миләс итеп җибәрә. Шуннан соң ул:

—Сиңа башка берәр әйбер кирәкмиме?—дип сорап куя.

—Берәр кисәк ипи дә бирсән, әйбәт булыр иде,—ди.

Көлешеп кенә туктаган идек, ипи алырга китү сәбәпле, безнең сөйләшүне ишетмичә калган Лесхоз урта мәктәбе директоры Хәмит Мөгътәсимов килеп:

—Егетләр, ипи кирәкмиме?—дип сорап куйды.

Мәзәк тыңлаучылар егыла-егыла көлүләрен дәвам иттеләр...

## Барып сора

Районыбыз газетасы үзенең 75 еллык юбилеена әзерләнә. Шушы чор эчендә зур үзгәрешләр кичерде ул. Башта "Колхоз байрагы" буларак дөнья күрде. 1963 елда "Җиңү байрагы"на әйләнде. 1990 елның 22 сентябреннән "Саба таңнары" дип исемләнде һәм бөек шагыйребез Габдулла Тукайның "Әйдә, халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә!" дигән сүзләре кыйбла итеп алынып, газетаның "маңгаена" язып куелды.

"Кечкенә гәҗит" буларак, сигез елга якын компьютерда җыелып, "Дубликатор", "Ризограф", "Дупло" дигән чит ил машиналарында басылды.

Ә менә 2004 елның 1 гыйнварыннан "Саба таңнары" редакциябездә эшләнеп һәм электрон почта—интернет аша Казандагы "Идел-Пресс" нәшриятына бирелә башлады һәм олы—"А-3" форматына күчте. Аның тәүге санын тарихта беренче мәртәбә дүрт төрле төс белән чыгаргач, әбүнәчеләребез шау-гөр килде.

1963-1992 елларда газетабыз русчага да тәрҗемә ителде әле. Башта "Знамя Победы" иде, аннары "Вестник района" булды. Теләче районы кабат мөстәкыйльлек алгач, бу басманы алучыларыбыз бармак белән генә санарлык калды. Шуннан соң, учредитель карары белән, әлбәттә, 1993 елның 1 гыйнварыннан район газетасын рус телендә чыгаруны туктатырга булдык.

...Казанда редакторлар кинәшмәсе бара икән (мин—ялда). Шунда, әз генә тираж белән урысча газета чыгарып азапланучы, Сарманның тәҗрибәле мөхәррире, сатира-юмор остасы Илгизәр Кушаев сикереп торган да:

—Урысча гәҗитне ничек бетереп була?—дип, турыдан-туры, татарчалатып сорау биргән.

—Сабага барып сора!—дигән ана ул вакыттагы Мәгълүмат һәм матбугат министры Ислам Әхмәтҗанов.

## Аякларың төз генә

Күрше-тирә районнар белән уртак шәхесләребез байтак безнең. Әйтик, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисткасы, СССР Композиторлар берлеге әгъзасы, опера җырчысы Мәрьям Рахманкулованың әтисе Габделмәннан Рахманколый (1858-1908) Әтнә районының Олы Мәңгәр авылыннан безнең Олы Шыңарга асрамага алына, үсеп җиткәч укып кайтып, ундүрт ел буе бирелә балалар укыта. Үз заманының алдынгы карашлы, ачык фикерле мәгърифәтчесе була. 1988 елда Олы Шыңарда Габделмәннан белән Мәстүрәнең (Кукмара районының Арпаяз авылыннан) Солтан исемле уллары туа. 1900 елда Рахманколыйлар Казанга күчә (Мәрьям башкалада туа). Солтан яшьтән әдәбият белән мавыга. А. Пушкинның "Дубровский", "Борис Годунов", И. Тургеневның "Төтен", М. Горькийның "Дуслар", В. Гюгоның "Туксан өченче ел" әсәрләрен тәрҗемә итә. Алар аерым китап булып чыга. Солтанның хикәяләр җыентыгы беренче тапкыр үзенең вафатыннан соң 1917 елда басылып чыга.

Бу урында СССРның халык артисты, атаклы композитор, Татарстан Республикасының Дәүләт гимны авторы Рөстәм Яхинның әтисе Мөхәммәтхаҗиның Рахманколыйлар белән туганнар икәнен дә искәртеп китү кирәк булыр. Күп кенә олы шәхесләрне Сабаныкы итеп бетерә, дип уйлыйсыздыр инде... Нишлим соң?

Татарстан Республикасының Дәүләт флагы авторы танылган рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов та Йосыф-Алан авылыннан бит!

Ә инде 1997 елның июнендә бер төркем сәнгать осталары килеп, бөек композитор Рөстәм ага Яхинның чыгышы белән Олы Шыңардан икәнен тагын бер мәртәбә раслап киттеләр.

Татарстанның халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты, Бөтенроссия конкурсы лауреаты Гали Ильясовның да әтисе Саба районының Юлбат авылыннан, әнисе—Кукмара төбәгеннән.

Дөрес, танылган җырчы монда тумаган. Тарихи бишьеллыклар башлангач, әтисе Гани ага Ерак Көнчыгыш шахталарына күмер чабарга китә. Шунда—Приморье өлкәсенең Сучане шәһәрендә, Кукмара кызы Маһинур белән гаилә кора. Беренче уллары Гали туа. Үсеп җиткәч, Галине дә шахта мастеры итәргә уйлыйлар, шуңа укыталар. Әмма... егетнең гаҗәеп тембрлы тавышы сәнгатькә тарта. Аның иҗат мөмкинлекләре диңгез авиациясендәге хәрби хезмәттә ачыла. "Айлы серенада" дигән чит ил киносы ариясе өчен ана ул вакыттагы округ командующие маршал Радион Малиновский үз куллары белән кыйммәтле бүләк тапшыра...

Ә инде 1960 елларда Совет Армиясенең данлыклы ансамбле житәкчесе, СССРның халык артисты Б. Александров Галине Мәскәүгә укырга чакыра...

Бара ул башкалага. Поезда җиде тәүлек буе килә. Әмма инде Гали керергә ниятләгән училищеда имтиханнар узып, кабул итү төгәлләнгән була. Ул, кирәкле профессорны эзләп табып, үзен тынлауларын үтенә.

—Минем Ерак Көнчыгышка кире кайтырга акчам юк,—ди ул катгый итеп.

Зуррак йодрык кадәрле Галинең киң диапозонлы лирик тенорын тыңлый профессор. Һәм таңга кала. Башта концертмейстерга, аннары Г. Ильясовка карап-карап тора да:

—Какой рост, а какой голос,—дип гаҗәпләнүен белдерә.

Ул Италиядә укыган укытучылардан белем ала, опера җырчысы булырга әзерләнә. Музыка училищесын уңышлы тәмамлый. Сирәк очрый торган тенор тавышлы Гали Ильясовка Мәскәүдә берничә җирдән эш тәкъдим итәләр. Ләкин Татарстан, әти-әнисенең туган яклары аны үзенә тарта. Гали Ильясов Казанга кайтып, утыз елдан артык филармониядә эшли.

Кая гына бармасын—авыл, район сәхнәләрендәме, чит илләрдәме—Ильясов көтеп алынган кунак була. Италиядән тыш, ул тагын егермедән артык илдә чыгыш ясый.

Гали Ильясов композитор буларак та танылды. Үзе исән вакытта (ул вакытсыз кинәт вафат булды) аның утыз җырын эченә алган затлы җыентыгы дөнья күрде.

Әтисенең туган авылында—Юлбат сәхнәсендә рәсми төстә бер генә тапкыр—алтмыш яшьлек юбилеенда гына җырлады ул. Юбилярга хөрмәт тә, бүләкләр дә мулдан булды. Ә сәхнәдә таныш куплетлар ("Казан кызы"—Заһит Хәбибуллин музыкасы):

*...Атлыйсың тиз-тиз генә,*
*Аякларың төз генә,*
*Үкчәләрең без генә,*
*Тимәс микән күз генә лә...*

Аяклар, дигәннән, Гали ага бер аягын ике урыннан сындырган булган. Бу күңелсез хәбәрне ишеткән ханым:

—Шундый кыска аяк, ничек итеп ике җирдән сынарга мөмкин икән,—дип утырып елаган ди.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

## İctimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ТӨП БӘЙРӘМЕБЕЗ

30 август—Республика көне—хәзер ин көтеп алына торган бәйрәмебез. Ул көнне олысы да, кечесе дә тамаша карарга мәйданнарга, стадионнарга агыла.

Башкалабыз Казан халкы өчен 30 август — икеләтә бәйрәм. Бу көнне Республика көне дә, Шәһәр көне дә билгеләп үтелә. Киләсе елда Казаныбыз үзенең 1000 еллык юбилеен көткәнлектән, быелгысы шуңа репетиция булды, дисән дә ярыйдыр. Ә бәйрәм чаралары Казанның бер генә төбәген дә читләтеп узмады. Алар иртәдән ук башланды һәм төнгә кадәр дәвам итте.

Казан Кремлендә, Сөембикә манарасы янындагы театраль тамаша бәйрәм күренешләренең башы булды. Менә тарихи манарада мәшһүр Сөембикә үзе күренде. Аның нурлы йөзеннән киләчәгебезгә ныклы ышаныч, бәхет үзе балкыды сыман. Ханбикә кулыннан күккә күгәрченнәр күтәрелде. Аннары зур-зур шарлар югарыга юл алды. Әлеге тамашаны Президент М. Шәймиев, Президент аппараты җитәкчесе Ә. Гобәйдуллин, Премьер-министр урынбасары З. Вәлиева, Казан хакимият министры И. Тарханов, Бөтендөнья банкының Россиядәге директоры К. Георгиева һ. б. хозурланып карады.

"Казан" милли-мәдәният үзәге янындагы мәйданда "Дуслык җилләре" дигән бәйрәм шулай ук бик күпләрне үз янына җыйды. Биредә төрле милләт вәкилләре үзләренең җыр-биюгә, төрле һөнәргә осталыкларын күрсәтте. Биредә Президент М. Шәймиев тә булды һәм үзара дус-тату яшәүче Татарстан халыклары вәкилләренә җылы сүзләрен әйтте.

Г. Тукай мәйданында узган Шигърият бәйрәме белән Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры янындагы тамашаны татар әдәбияты тантанасы диярга дә мөмкиндер. Шагыйрьләребез анда, бәйсезлеккә омтылышыбызны куәтләп, ялкынлы шигырьләрен укыды. Президент М. Шәймиев бөтен халык алдында язучы М. Юныска 2004 ел өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе тапшырды.

"Биектау" автодромында Татарстан Президенты Кубогына автоузышлар бәйрәменең тагын бер чарасы булды. Быел анда Үзбәкстан, Литва, Латвия, Чехия, Словакия, Мәскәү һәм Тольятти спортчылары катнашты.

Бәйрәм тамашаларының йомгаклау өлеше Үзәк стадионда узды. Монда сәнгать осталарыбыз, спортчылар чыгыш ясады. Аларны Президент М. Шәймиев, Премьер-министр Р. Миннеханов, Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков, республикабызның башка җитәкчеләре тәбрикләде. Нәкъ 22 сәгатьтә башкала күген фейерверклар уты балкытты.

### Төньяк Осетия—Алания Республикасының Беслан шәһәрендәге фаҗигале вакыйгаларга бәйле рәвештә иҗат интеллигенциясе МӨРӘҖӘГАТЕ

Без, иҗат интеллигенциясе вәкилләре, илебез өчен кайгылы бу көннәрдә явыз террорчыларга каршы көрәшкә көчебезне берләштерергә чакырабыз. Журналистлар интернет, радио һәм телевидение аша әлеге кайгыны планетаның һәр йортына, һәр гаиләсенә җиткерделәр. Барыбыз да әлеге кайгыны шәхси фаҗигабез итеп кабул иттек.

Кулына корал алып, бер гаепсез балалар һәм хатын-кызларны аткан вәхшиләрне берничек тә аклап булмый. Алар күңелләребезгә курку салуга һәм милләтара ызгыш китереп чыгаруга ирешә алмадылар, илебез гражданнары буыны тәрбияләнгән идеаллардан баш тартырга мәҗбүр итә алмадылар. Террорчылыкка урын булмас!

Кызганыч, соңгы вакытларда әхлакый кыйммәтләрнең югалуы нәтиҗәсендә җәмгыятьтәге тискәре күренешләр белән көрәшү һаман катлаулана бара. Вакыт чакыруына иҗат интеллигенциясенең җавап бирү чоры килде.

Террорчылар, кара эшләренә милли һәм дини төсмер бирү өчен, дини идеяләрне байрак итеп күтәрәләр. Моңа каршы: "Террорчылыкның милләте юк!" — дип белдерәбез.

Явызлыкны явызлык тудыра, дигән хакыйкать яши. Бүген никадәр генә авыр булмасын, без бер гаепсез кешеләрнең газапларьі өчен үч алырга түгел, ә, бәлки, илебез халкының иминлеген тәэмин итү өчен тәртип урнаштырырга чакырабыз. Без әлеге гамәлләр Конституция кысаларында һәм гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклап башкарылырга тиеш дип саныйбыз.

***Ф. Галимуллин,*** *ТР Язучылар берлеге рәисе;* ***Р. Калимуллин,*** *ТР Композиторлар берлеге рәисе;* ***А. Абзгильдин,*** *ТР Рәссамнар берлеге рәисе;* ***Р. Ратникова,*** *ТР Журналистлар берлеге рәисе;* ***Р. Нургалиева,*** *ТР Архитекторлар берлеге рәисе;* ***Р. Тажетдинов,*** *ТР Театр эшлеклеләре берлеге рәисе.*

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ

Мәгълүм булганча, 1944 елның 25 августында Германиянең Плетцензее төрмәсендә халкыбызның каһарман уллары—унбер җәлилченең гомере фаҗигале төстә өзелә. Һәр елның шушы көнендә 12 сәгатьтә башкалабызның 1 май мәйданында патриот-шагыйрь Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләрнең барельефлары алдында хәтер җыены үткәрелә. Аның быелгысы батыр көрәштәшләрнең җәзалап үтерелүенә 60 ел тулуга багышланды.

Хәтер җыенында республикабыз җитәкчеләре, сугыш ветераннары, хәрбиләр, җәлилчеләрнең туганнары, әдәбият-сәнгать әһелләре һәм күпсанлы җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты. Искә алу тантанасы каһарманнарыбыз мемориалына чәчәкләр кую һәм бер минут тын торудан башланды. Хәтер җыенын Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин ачты. Аннары Татарстан Президенты М. Шәймиевкә сүз бирелде. Илбашыбыз үзенең чыгышында җәлилчеләрнең әлеге тиңсез адымга чын рухи әзерлекле халәттә барулары, шушы батырлыклары белән халкыбызны бөтен дөньяга танытулары, мәдәниятебез һәм патриотик тәрбия өчен мәңгелек мирас калдырулары турында ассызыклап әйтте һәм аларның якты истәлеге алдында бүген һәрбер гамәлебездә җаваплылык тою зарурлыгы хакында искәртте.

Искә алу җыенында М. Җәлилнең кызы Чулпан, әдипләр Р. Мостафин, Р. Харис чыгыш ясады. Камал театры артистлары Р. Таҗетдинов, Н. Ихсанова һәм тагын бертөркем сәхнә осталары, җырчылар З. Сөнгатуллина, В. Васильев, Р. Харисов, мәктәп укучылары М. Җәлил шигырьләренә язылган җырлар, җәлилчеләргә багышланган әсәрләрдән өзекләр башкарды. Тантанада шулай ук Оренбур өлкәсеннән һәм Мари-Элдан килгән делегация җитәкчеләре дә сүз әйтте.

Хәтер җыенында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова, мәдәният министры И. Тарханов, башка кайбер дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре катнашты.

***

25 август иртәсендә Россия Федерациясе илчелеге вәкиле, Германиянең татар-башкорт мәдәни үзәге активистлары, шулай ук үзәк рәисе Рәис Хәлилов һәм аның ярдәмчеләре Венера Герасимофф һәм Әлфирә Шульце, "Россия дуслары" җәмгыяте әгъзалары татар халкының герой уллары истәлеген яд итәргә Плетцензеега килделәр. Чәчәкләр салганнан соң, РФ илчелеге вәкиле Владимир Найденов: "Муса Җәлил — татар халкының гына түгел, ә Россия герое", — диде. Монда килүчеләрнең күбесенең кулында шагыйрьнең татар, рус, немец һәм инглиз телләрендә басылган шигырь китаплары иде.

Туган җирләреннән еракларга сибелгән татарлар герой-шагыйрь истәлеген көнелләрендә янарту өчен Плетцензеега еш килә. Әлеге куркыныч урында фашистларга каршы көрәшкән йөзләгән немец, чех, бельгияле, француз көрәшчеләре дә һәлак булган. Шуна күрә дә шагыйрь төрмә зинданнарында ятканда Германиянең якты киләчәге турында хыялланган. Әле шушы вакыйга алдыннан гына 1944 елның 18 августында үтерелгән Эрнест Тельманны искә алу да аерым бер мәгънәгә ия.

## БӨЕК ИДЕЛ ЮЛЫ АЛГА ӘЙДИ

Ниһаять, "Казан" теплоходы башкалабызга әйләнеп кайтты. Аның бортында "Бөек Идел юлы" халыкара фәнни-гамәли конференциясендә катнашучылар иде.

Конференциянең дүртенче этабы Түбән Новгород ярминкәсенең Герб залында тәмамланды. Конференция 4 августта Санкт-Петербургта старт алды. Аның эшендә 7 илнең 200дән артык вәкиле катнашты. Алар арасында хөкүмәт әгъзалары, шәһәр башлыклары, тарих, мәдәният, икътисад һәм экология белгечләре бар иде.

Конференция кысаларында "Бөек Идел юлы һәм туристлыкның үсеш перспективалары", "Төбәкара хезмәттәшлекне үстерү — Бөек Идел юлы төбәге шәһәрләре икътисади тотрыклылыгының нигезе" дигән темаларга "түгәрәк өстәл"ләр үткәрелде. Конференциянең дүртенче этабында катнашучылар Ярославль һәм Кострома шәһәрләрендә булды. Алар "Спасо-Преображенский монастырь" тарихи-архитектура комплексын карады, "Иске шәһәр" мәдәни күргәзмә комплексында конференциянең пленар утырышын үткәрде. Шуннан соң Кострома шәһәре мэры "Бөек Идел юлы" шәһәрләре килешүенә кул куйды.

"Бөек Идел юлы" халыкара проекты, Казан шәһәренең 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек буенча, Россия Федерациясе дәүләт программасының үзәк өлеше булып тора. Ул Россия Тышкы эшләр министрлыгы, ЮНЕСКО эшләре буенча Россия комиссиясе, Икътисади үсеш министрлыгы, Россия Фәннәр академиясе, Мәдәният һәм гаммәви коммуникацияләр чаралары министрлыгы, шулай ук "Бөек Идел юлы" илләренең хөкүмәтләре һәм шәһәр хакимиятләре тарафыннан оештырылды.

Халыкара конференция үткәрү идеясе 2000 елда барлыкка килгән иде. Аның төп максаты — мәдәниятләр арасындагы күпер буларак, Бөек Идел юлын кабат торгызу. Бу проект әлеге төбәктә урнашкан илләрнең фәнни, мәдәни, икътисади хезмәттәшлеген ныгытуга ярдәм итәчәк. Проект 5 елга исәпләнгән һәм ул киләсе елда Казанда тәгәлләнәчәк. 2005 елда башкалабызда Бөек Идел юлы шәһәрләре ассоциациясенең конгрессы үтәчәк.

## ТӨРКИ ДӨНЬЯ БЕРЛЕГЕ ӨЧЕН

Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты каршында төрки дөньясы хатын-кызларының дуслык һәм теләктәшлек ассоциациясе республика филиалы төзеләчәк. 23 августта Татарстан Министрлар Кабинетында Премьер-министр урынбасары Зилә Вәли-

ева белән ассоциациянең башкарма комитеты рәисе Шенол Бал (Төркия) очрашуы вакытында шул хакта килешенде. Шенол Бал республика башкаласына 2005 елда Казахстанда үткәреләчәк III Корылтайга әзерлек кысаларында биш көнлек танышу визиты белән килде. Ул инде мона кадәр Кырым, Башкортстан, Кыргызстан һәм Казахстанда булган.

Төрки хатын-кызларының беренче берләштерелгән корылтае 2001 елда Анкарада уздырылды. 32 илдән 200гә якын вәкил катнашкан икенче корылтай 2003 елда Төркия башкаласында булды. Әлеге корылтайда алдагы ике елга эшчәнлек программасы кабул ителгән иде. Программа хатын-кызлар оешмаларына ярдәм итү, шулай ук аз тәэмин ителгән гаиләләрдә тәрбияләнүче талантлы мәктәп укучыларына һәм студентларга халыкара уку программалары төзү, наркомания, эчкечелек, СПИД белән көрәш чаралары уздыруны күздә тотып төзелгән.

Министрлар Кабинетындагы очрашуда балаларны милли тәрбияләүнең төрле юнәлешләре, татар гаиләләрендәге мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча фикер алышынды. Шенол Бал Зилә Вәлиеваны III Бөтендөнья корылтаенда катнашырга чакырды.

### "СӘЙДӘШ БЕЗНЕ ЖЫЙНЫЙ, БЕРЛӘШТЕРӘ..."

Инде бишенче ел рәттән август уртасында Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылында Сәйдәш бәйрәме, сәнгать бәйрәме үткәрелә. Ул елдан ел күбрәк абруй казана бара. Быел да алан үзенә жыр-музыка яратучыларны жыйды. Бәйрәмгә барырга теләүчеләр шулкадәр күп иде — алар ике теплоходка гына сыймады, шактый кеше нәүмизләнеп, ярда басып калды...

Бәйрәмне мәдәният министры И. Тарханов ачты. Бөек композиторыбыз рухын яд итеп, һәйкәлгә жәйнең аллы-гөлле чәчәкләре салынды. Аннан соң сүзне Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, галим Фоат Галимуллин алып, Сәйдәшнең сәнгатебез үсешендәге роле турында сөйләделәр. Өч сәгать буе сәхнәдә Илһам Шакиров, Эмиль Жәләлетдинов, Нажия Теркулова, баянчылар Рәшит Мостафин, Кирам Сатиев, Рамил Курамшин, жырчылар Идрис Газиев, Георгий Ибушев, Римма Ибраһимова, Рафаэль Сәхабиев, Хәмдүнә Тимергалиева, Айдар Фәйзрахманов, Искәндәр Биктаһиров, Фуат Әбүбәкеров житәкчелегендәге Камал театры оркестры һәм театрыбызның мәшһүр артистлары берсен-берсе алмаштырды. Бәйрәмдә Сәйдәш нәселенең дәвамчылары катнашу ямь өстенә ямь өстәде.

### ДОКУМЕНТЛАР СӨЙЛИ

Татарстан Милли архивында Республика көне уңаеннан "Татарстан — 1941 — 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында жиңүнең арсеналларыннан берсе" дигән тарихи документлар күргәзмәсе ачылды. Анда төп урынны ТР Милли архивы һәм ТР Үзәк дәүләт тарихи-сәяси документацияләр архивы фондында саклануы, сугыш елларындагы фидакарь хезмәт хакында сөйләүче документлар алып тора. В. И. Ленин исемендәге Казан фәнни-житештерү предприятиесе, 16 нчы һәм 22 нче заводларның фондларыннан алынып, бүген сер булудан туктаган уникаль документлар исә күргәзмәгә әле беренче мәртәбә генә куелуын да әйтик. Биредә шулай ук сугыш елларында төшерелгән фотосурәтләр һәм плакатлар белән дә танышырга мөмкин.

### ЮБИЛЕЙ УҢАЕННАН

Сентябрь аенда Мәскәүдә элеккеге халык хужалыгы казанышлары күргәзмәсендә 17 нче халыкара китап ярминкәсе ачылды. Анда төрле чаралар да уздырылды. Мәгълүм булганча, Мостай Кәримгә 85 яшь тула. Шул уңайдан, Мәскәүнең "Ватан каһарманнары" нәшрияты Башкортстанның халык шагыйре турында "Мостай Кәрим: сугышчы, шагыйрь, гражданин" дигән китап чыгарды. Аның авторы — Ильяс Вәлиев. Жыентыкта Мостай Кәримнең катлаулы тормыш юлы жентекләп тасвирлана һәм рус телендә күп кенә әсәрләре тәкъдим ителә. 3 сентябрьдә күргәзмә-ярминкәдә шушы китапны тәкъдим итү тантанасы булды. Бирегә Башкортстан, Татарстан һәм Мәскәү жәмәгатьчелеге вәкилләре жыелган иде. Казаннан бу бәйрәмдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин һәм Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис катнашты һәм чыгыш ясады.

### "ШҮРӘЛЕ"ГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Казанда милли рух өретелгән "Шүрәле" аттракционнар паркы ачылды.

Паркта ел дәвамында, ягъни кыш көне дә күңел ачарга мөмкин булачак. Проект инвесторлары аны туристлар жәлеп итүенә дә булышыр дип өметләнә. Казанның 1000 еллыгы алдыннан бу бигрәк тә актуаль.

Проект житәкчесе Андрей Кузьмин сүзләренә караганда, "Шүрәле"дә бар аттракционнар да әзер түгел әле. Парк Казанның меңьеллыгына ахыргача төзелеп бетәчәк. Әлеге проектны тормышка ашыру өчен 6 миллион доллар акча тоту каралган.

"Шүрәле" аттракционнарын өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин. "Экстрим-зона" дип аталганында гигант "Пират" таганы, ирекле төшү башнясы һәм Россиядә бердәнбер булган "Оча торган тәлинкә" аттракционы урын алган. "Гаилә" зонасында — автодром карусель һәм бамперлы көймәләр. "Балалар" зонасы "Көнгерә" башнясыннан, "Олд Вестерн" әкияти поездыннан, "Тропиканка" уен комплексыннан һәм башкалардан тора. Ә 55 метр биеклегендәге "Күзәтү тәгәрмәче"нә утырып тирә-як белән хозурланырга мөмкин булачак.

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев "Шүрәле" паркының ачылган көнендә булып, аланлыкта агач утыртты, со-

ныннан паркны карап, ял итәргә килүчеләр белән аралашып, монда менә диган итеп күңел ачып кына калмыйча, республиканың милли төсмерләрен дә тоярга мөмкин икән, дип белдерде.

## ФИНЛЯНДИЯ РӘССАМЫНЫҢ БҮЛӘГЕ

15 сентябрьдә Финляндиядә яшәүче милләттәшебез—рәссам-график Хәйдәр Сәетбатталов Татарстанның фән, сәнгать һәм җәмәгать эшлеклеләреннән үзе иҗат иткән 100ләп портретын Дәүләт сынлы сәнгать музеена бүләк итте. Анда дистәдән артык язучыларыбызның да портретлары бар. Бу уңайдан музейда зур тантана булды.

Хәйдәр Сәетбатталов 1923 елда туган. Мәскәү полиграфия институтын тәмамлаган. 30 елга якын Санкт-Петербургтагы Гамәли сәнгать академиясендә укыткан. Ленинградның баш рәссам-графигы булган. Ун елдан артык инде Финляндиядә яши. Ул Финляндиянен Алтын мактау билгесе белән бүләкләнгән.

## "ТӨРКИ ДӨНЬЯ"—ЯҢА БАСМА

Мәскәүдә Шәрык белгечләренең Халыкара конгрессы эшләгән көннәрдә әнә шундый исемдәге яңа фәнни басма дөнья күрде. Аны "Инсан" нәшрияты өч телдә—рус, татар, инглиз телләрендә бастырып чыгарган. Басмага Мәскәү һәм Казан шәһәрләреннән төрек дөньясын өйрәнүче мәшһүр галимнәрнең кызыклы фәнни язмалары кертелгән.

Мәскәүдә төрки халыкларның фәнни һәм мәдәни тормышын киң яктыртып барырлык журнал рәвешендәге җыентык чыгару фикере узган гасыр азакларында ук яралган иде инде. Ләкин бу изге ният Мәскәүнең гыйльми даирәләрендә дә, үзәк мөфтият җитәкчелегендә үз вакытында яклау тапмады. Әмма бу максатка барыбер ирешергә насыйп булды.

Яңа җыентыкның үзәгендә күптән түгел арабыздан киткән мәшһүр тюрколог, Россия Фәннәр академиясе академигы Әдһәм Тенишевның "Хәзерге заман тюркологиясенең мөһим проблемалары" диган соңгы фәнни мәкаләсе, Әбрар Кәримуллинның әлегә чаклы киң катлау укучыларга аз билгеле булган "Садри Максуди — Арслан" мәкаләсе, Миркасыйм Госмановның "Исмәгыйль Гаспралы", Мирфатыйх Зәкиевнең "Төрки халыкларның килеп чыгышы" дигән монографиясе кебек кызыклы язмалар урын алган.

## ХӘЙДӘР БИГИЧЕВ ЙОЛДЫЗЫ

Узган елның 29 августында — Республика көне алдыннан Казанның Бауман урамында татар эстрада йолдызлары аллеясе ачылган иде. Андый аллея АКШның артистлар каласы буларак танылган Голливуд шәһәрендә дә бар. Татар халкының йолдыз кебек балкыган сәнгать әһелләре дә байтак безнең. Казан хакимияте һәм "Барс-Медиа" агентлыгы тырышлыгы белән беренче ике таш куелган иде инде. Алар мәшһүр җырчылар Илһам Шакиров белән Әлфия Афзалова багышлап салынды. Менә бер елдан соң алар янына Хәйдәр Бигичев "йолдызын" белдергән таш та өстәлде.

## ӘДИП РУХЫНА БАГЫШЛАП

Август аенда күренекле каләмдәшебез — Киров өлкәсенең Нократ Аланы районындагы Түбән Шөн авылында яшәгән һәм иҗат иткән Рафаэль Шәйхулла улы Хуҗиннын (Рафаэль Сибат) вафатына бер ел тулды. Шул уңайдан ул туган йортта мәрхүмне искә алу мәҗлесе үткәрелде. Бирегә авылның дин әһелләре, мөхтәрәм аксакаллары, әдипнең якын туганнары җыелды. Казаннан исә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, аның урынбасары Шәһинур Мостафин, Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Вахит Имамов, "Мәйдан" журналының баш мөхәррире Факил Сафин килгән иде.

Рафаэль Сибат рухына багышлап Коръән уку мәҗлесендә катнашучылар әдипне зурлап, сагынып искә алдылар, аның киң колачлы иҗатын укучыларга җиткерү өчен киләчәктә башкарылырга тиешле эшләр турында сөйләштеләр. Аерым алганда, киләсе елда Р. Сибатның Татарстан китап нәшриятында "Кайту" тетралогиясен дөньяга чыгару, "Мәйдан" журналының бер санын тулысынча аңа багышлау, ул укыган һәм укыткан мәктәпкә әдип исемен бирү күздә тотыла.

## КИТАПЛАРНЫ — ПОЧТА АША

"Мәгариф" нәшриятында янадан-яңа китаплар басылып тора. Яңа гына "табадан" төшкән китапларны үзегездә булдырырга теләсәгез, әллә кая барып йөрисе дә юк. Бары тик безнең адреска, кирәкле китап исемен, авторын күрсәтеп, хат кына язып җибәрегез. 10-12 көн эчендә теләгән китабыгыз сезгә почта аша килеп ирешер. Ләкин почта аша китап алу якынча ике тапкырга кыйммәтрәк булуын искәртергә кирәк. Почта аша алырга мөмкин булган китаплар янына нәшрият бәясе куелган.

**"Мәгариф" нәшриятында чыккан китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып ала аласыз:**

*Әмирхан урамы, 17 нче йорт;*

*Сул Болак урамы, 42/2 нче йорт;*

*Зур Кызыл урам, 68 нче йорт ("Аист-Пресс" Сәүдә йорты кибетләре);*

*Кремль урамы, 21 нче йорт ("Книгомир" кибете).*

*Нәшрият бәясе белән китапларны турыдан-туры "Мәгариф"тә, ягъни Бауман урамындагы матбугат йортының 3 нче катындагы 24 нче бүлмәдә сатып алырга мөмкин.*

**Хат язу өчен безнең адрес:**

*420111, Бауман урамы, 19 нчы йорт, а/я 447.*

# КЫЗЫЛ МАТӘМ

Милли мәдәни үзәк соңгы елларда сәнгать күргәзмәләренең иң күләмле һәм самими театрына әверелде: монда нинди генә юнәлештәге Казан һәм җөмһүриятебездә иҗат иткән шәхесләрнең күргәзмәсе булмады да һәм нинди генә яналыклар—авангард, модерн, әле дә урынлы рәвештә яшәп килүче реализм җимешләре тәкъдим ителмәде! Инде 90 еллар гайрәте башкалабызның күп кенә мәдәни учакларында сүнә барган бер вакытта—бирелә Алабуга рәссамы Рабис Сәлаховның төрки татар риваятьләренә багышланган гаҗәеп сәнгать күргәзмәсе ачылды.

Башкортстанның Бүздәк районында туган һәм Уфада сәнгать белеме алган рәссам иҗат энергиясен Шишкин ватаны, Цветаева, Надежда Дуровалар яшәгән Алабуга шәһәрендә тернәкләнеп киткән кеше күнеленә кулай архитектурасын мәдехләүгә һәм шул ук вакытта шәһәр ихтыяҗына яраклы—балчыктан яндырып бизәкле савыт-саба—керамика эшләүгә юнәлткән иде. Аның иҗатының ике юнәлешенә дә бу чорда гасыр башында оешкан һәм дөньяны пластик яктан “каты итеп”, читләтеп күрүгә корылган “Бубновый валет” дигән рус сәнгатькярләренең тел үзәнчәлекләре тәэсир иттеләр. Ләкин Алабуганың тәбәнәк кызгылт йортлы провинциаль урамнарын, кайчандыр базаркәннәр яшәгән алсу ташкормаларын, тимер йозаклы, ажур торбалы кибетләрен, февраль, мартларын ул барыбер керамикага охшатып, балчыктан әвәләгән уенчык сыман итеп сурәтләде. Рабис бу чорда—дуслары белән борынгы купецлар шәһәренең караңгы подвалларында керосин лампасы яндырып музей сыман тамашалар корып, фикердәшләре һәм оппонентлары белән әчтән сүз көрәштереп, яна татар сәнгатенең чалымнарын эзләде.

Аның бүгенге нәкыше—яшәгән җирендәге үзле балчыгының йомшаклыгын, җир тәмен, моңын, алтын-су төсен саклаган кебек. Ләкин инде теге архитектур формалар, ясссылыклар, каты сызымнар, исемсез кызыл, сары таплар язылып, эреп киткән сыман. Җитен тукымалардагы Алып сыман зур гәүдәле каһарманнарны, әйтерсең, каллиграфия сызымнары, әллә нинди дөньяда булмаган орнамент өстәп, татар халкының иң гүзәл, иң моңлы эпик образлары итеп китереп бастыра: “Таһир—Зөһрә”, “Түләк белән Су-сылу”, “Сак—Сок”, “Аллуки”, “Шүрәле”, “Су Анасы” һәм башкалар. Миллилек билгеләре ярылып яткан динамикалы бу сурәтләрдә, орнамент белән беррәттән, тагын бер образ—аллы-гөлле кием, корал һәм башка җисемнәр өстендә ярылып яткан, нота билгеләре кебек музыка—моң балкышы төсмерләнә.

Һәм менә кызык яналык: Казанда эстетлык, купшылык һәм сатым галереяләрендә үтәр өчен ясалган чәчәк, натюрморт, пейзажлар өстендә тапталудан бераз югала башланган зур тарихи башлангыч Рабис Сәлахов иҗатында дәвам итә. Форсаттан чыгып, аның “атлы яугирләрен”, Япанча,

халык дастанының геройлары—Чура батыр, Идегәйләрне әйтеп китәргә кирәк. Әйе, нәкъ "Идегәй" дастанында сурәтләнгәнчә:

*Кузагачтан биекмен,*
*Болытка җитми тынмасмын;*
*Башымнан давыл өрсә дә,*
*Мин аңардан сынмасмын!*
*Гөрелдәсәм, сугыр яшенмен,*
*Көлсәм мин бер чуакмын;*
*Киреләнсәм, йокың бозармын,*
*Көрәшсәм, сине егармын...*

.....................................................................

*Каргышым кара таштан үтәдер,*
*Аһым җирне-күкне тотадыр...*

Ләкин Рабисның иҗаты—тигез генә, дулкын-дулкын гына, Әдрән дингезе кебек чайкалып кына бармый. Анда бүре токымы гайрәте кабына, ул бер ягы белән Иделгә тоташкан хәлдә, рухы белән Урал тауларына да авышкан. Һәм, гомумән, аның шагыйрь чичәннәр, су каһарманнары, канатлы елан—сазаганнар тулган дөньясы—Илаһи төрки дөнья! Монда шәхес галәм белән тоташкан, бер төрки гыйбарәдә сөйләнгәнчә, "каһарман көлгәндә, таулар көлә"; ул дәшмәгәндә, күкләр куырыла. Мондый пантеизмны һәм төркилекне без аның күп картиналарында күрәбез. Аның дөньясы ап-ачык, матур, киң; анда һәр күңелгә, һәр милләткә азык һәм наз бар!

Сәлаховның иҗатында милли романтизм киеренкелеге, әллә нинди бетмәс-төкәнмәс канатлану хөкем сөрә: болар—балалык хыяллары темасында, авыл тормышының сихри гүзәллеге—печән чабулар, гашыйк булулар, халкыбызга хас булган дала моңын, тормыш хикмәтен һәм ышанычын саклаган карт-коры образларында! Бу әсәрләр арасында "Сөембикә алмасы" дигән бер табышмак бар... Хан-бикәнең образы һич трафарет булмаган, юнан, Рим мифларының тылсымын саклаган кебек... "Сөембикә алмасы"—гүзәллек символы Венера башка Аллаларга ызгыш өчен томырган алмадан аермалы буларак—иң илаһи, иң зирәк, иң мәрхәмәтле шәхесләр һәм буыннар өчен затлы мирас. Аңа, тәгаен, рәссам Рабис Сәлахов та лаектыр...

Күңеле—мәңге җилкенүле гүзәллек һәм гаделлек җайдагы булган өчен.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
*сәнгать белгече.*

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* ***Рабис Сәлахов****. Татар эпосына багышланма (реквием).*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Шагыйрә **Фирдәвес Әһлия**.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Рәшит БӘШӘР. **Ачык капка.** Хикәя, повестьлар.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.—254 бит. Тиражы—3000 данә.




Чаллыда яшәп иҗат итүче күренекле балалар язучысы Рәшит Бәшәрнең сайланма рәвешендәге бу китабына төрле елларда язылган хикәя һәм повестьлары ("Ачык капка", "Ак балык", "Бер өйдә жиде кеше", "Минем әтиемне сугышта үтерделәр" исемле повестьлар, "Адашкан кош тавышы" хикәясе) тупланган. Автор уйчан да, хыялый һәм шаян да. Ул, үгет-нәсихәт укымый гына, балаларга тормыш кырыслыгы, кешеләрнең катлаулы язмышлары турында сөйли, тормышта чын кеше булып яшәргә өйрәтә.

Китапның мөхәррире—Р. Сабирҗанов, рәссамы—И. Вәлиәхмәтов.

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. **Татар тажы.** Нәни хикәяләр.—Казан: "Мәгариф" нәшр., 2004.—104 бит. Тиражы—3000 данә.




Казанның 1000 еллыгына багышланган "Без тарихта эзлебез" сериясендә нәшер ителгән әлеге әдәби-нәфис басмада нәни хикәяләр тупланган. X—XVIII йөзләрне колачлаучы һәм татар халкының таҗы булган олуг шәхесләр—дәүләт ирәннәре, шагыйрьләр, халык күтәрелеше юлбашчылары (Кол Гали, Бату хан, Мөхәммәдъяр, Мәүлә Колый, Бәхтияр Канкай һ. б.) турында бәян итүче китап кече яшьтәге мәктәп балалары өчен тәкъдим ителә.

Китапның мөхәррире—И. Кадыйрова, рәссамнары—Рушан һәм Рэм Шәмсетдиновлар.



Фирдәвес Әһлия

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)